# НУРИХАН ФАТТАХ

## ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

В ПЯТИ ТОМАХ

1

ТОМ

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2002

# НУРИХАН ФӘТТАХ

## САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

БИШ ТОМДА

# 1

## ТОМ

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Ф96

***Редколлегия:***

*З.Р.Вәлиева, Р.М.Миңнуллин, Ф.Г.Галимуллин,
Т.А.Миңнуллин, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

**Фәттах Нурихан**

Ф96 Сайланма әсәрләр. — 5 томда, 1 том. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 464 б.

ISBN 5-298-01199-3 ©Татарстан китап нәшрияты, 2002



## Нурихан

Сулар ага... Җир йөзендә сулар бертуктаусыз агалар да агалар. Җәй агалар, яз агалар, көз агалар... Өзелмичә, туктамыйча, бөек Чулман кебек, Итил кебек, көн-төн җирдә тормыш ага...

«Итил суы ака торур» романының башламындагы бу моңсу сурәт, Нурихан Фәттахка җитмеш яшь тулуны уйлап торганда, кылт итеп искә төште. Әйе шул, сулар ага. Сулар кебек өзелмичә, гомер ага.

Нурихан — минем сабакташым. 1946 елда без Казан университетының татар бүлегенә бергә укырга кердек. Илле ике елдан артык гомер үткән дә киткән. Дистә ярымга тулыр-тулмас шәкерттән торган безнең группада Нурихан, бик алай чәчрәп күренүче егет булмаса да, үзенчәлекле иде. Чандыр гына гәүдәле (ул хәзер дә шулай) Нурихан җитезлеге, тәгәллеге, эшчәнлеге һәм беркадәр сәер йомыкыйлыгы белән аерылып тора иде. Аның шул вакытта ук вак кына язулар белән тулган калын куен дәфтәре Нуриханга ниндидер бер серлелек тә бирә иде. Баксаң, шул чакта ук ул инде зур әдәбиятка килергә җыенган икән. Хәтергә нык кереп калган тагын бер ягын мин аның белән бергә «Әдәби сүз» дигән язма гәзитебезне чыгарганда күрдем. Ул шактый зур күләмле стена гәзитенә кара тушь белән хәрефләрне басмача итеп бик оста яза иде. (Ул минем соңыннан «Совет әдәбияты» журналында чыккан беренче шигыремне дә шул кара тушь белән «Әдәби сүз» гәзитенә «басты».)

Билгеле, ул вакытта әле безнең группа шәкертләренең киләчәктә кемнәр буласын белүе кыен иде. Нурихан Фәттах — шушы группада беренче әсәрләрен язып канат чыгарган һәм, беренче булып, киң җәмәгатьчелеккә танылган олы әдип. Тормыш юлы да барыбызныкы кебек. Ярлы крестьян гаиләсендә туган. Башкортостанның атаклы Яңавыл мәктәбен тәмамлап, университетка юл тоткан. Укып бетергәч, бераз төрле гәзитләрдә эшләп алган. Әмма, күпләрдән аермалы буларак, тиз арада фәкать язучылык эше белән генә шөгыльләнә башлаган һәм, әйтер идем, ялгышмаган.

Нурихан Фәттахның иҗаты гаҗәеп күптармаклы һәм мул җимешле. Дөрес, ул ашыкмый, кабаланмый гына яза. Әмма җиренә җиткереп, үзенчә эшли. Шунысын да әйтәсем килә, аның шәкерт чагында ук сиземләнгән кайбер сәерлекләре дә сакланып калган. Мәсәлән, ул ниндидер бер мәгънәдә йомыкыйрак булып калды. Үзенә йорт алып, хосусый милекче кебегрәк яшәүне хуп күрде. Ул элеккечә үк үҗәт, хәтта тискәре кеше булып калды. Син инде аның әсәрләрендәге кайсы да булса сүзне үзгәрттерермен димә, ул инанган нәрсәдән аны биздерермен димә. (Ихтимал, шуңадыр аның холкын бик өнәп бетермәүчеләр дә юк түгел.)

Кыскасы, Нурихан гомере буе Нурихан булып калды, Нурихан булып иҗат итте һәм итә. Әле мәктәптә чакта ук (1944 елда) беренче шигырьләре матбугатта күренсә дә, ул шигырь язу юлын сайламады, чәчмә әсәрләргә тартылды. Әмма шунысы кызыклы, шигырьгә хас сурәтлелекне ул еш кына чәчмә әсәрләрендә дә «эшкә җигүдән» туктамады. Һәм бу аның киң колачлы сурәтләренә бик ятышып, шигъри матурлык биреп яши. Менә бер өзек:

«Авыл юлы.

Очсыз-кырыйсыз юл. Таш та түшәлмәгән. Тигез итеп асфальт та җәелмәгән, читләренә тезеп агач та утыртылмаган. Кайда уңай урын бар, шуннан үзенә эз салып, әрәмә-урманнар, тигезле-тигезсез басулар, чокыр-чакырлар аша үтеп, елгалар, таулар кичеп бара да бара. Кемнәр генә узмаган аннан, кемгә генә дус-иптәш, тавыш-тынсыз сердәш булмаган ул! Кемне генә кая гына алып бармаган ул!

Һәм кайчандыр шушы тузанлы, бормалы-сырмалы тар гына юл гади авыл егетен киң, олы юлга алып чыкты».

Нуриханның «Сезнеңчә ничек?» дип исемләнгән беренче романыннан китерелгән бу өзекне кем шигырь димәс?! 1954 елда, университетны тәмамлауга 2 — 3 ел да үтмәс борын язылып беткән бу роман җитлеккән каләм белән эшләнгән иде. Һәм ул шунда ук әдәбиятыбызга чын талант килүен раслады, хуплап каршы алынды. Мин, мәсәлән, өлкән әдибебез Әмирхан Еникинең романны бик рәхәтләнеп мактавын хәтерлим. Роман укучыны сурәтләнгән тормышның әдәбиятыбызга яңалык алып килүе, табигыйлеге, яшьлек романтикасы белән үзенә тартты. Дөресен әйткәндә, мин анда үзебезнең группа студентларының тормышын күрдем. Хәтта Сәгыйть һәм Ида кебекләрнең прототипларын да чамалап була иде. Авылның тар юлыннан чыгып, олы юлга баскан Нуриханның үзен дә роман каһарманнарының прототибыннан берсе дияргә мөмкин.

Тормышчанлык, табигыйлек, лиризм һәм хәрәкәтчән сюжет Нурихан прозасының үзәк сыйфатына әйләнде. Мин аның «Артта калган юллар», «Мөдир Саҗидә», повестьларын, «Бала күңеле далада», «Кичү» романнарын күздә тотам. «Артта калган юллар»дагы Хәмдия, «Мөдир Саҗидә»дәге медсестра Саҗидә образларын гына искә төшерик. Мәсәлән, авыл кызы Хәмдиянең сугыш елларында күргәннәре хәзер дә тетрәндерә.

Нуриханның, «Бала күңеле далада» романын язар өчен, Павлодар өлкәсенә барып, «Казан» совхозында эшләве үзе генә ни тора! Ул әсәр геройлары арасында үзе яши. Һәм, нәтиҗәдә, замандашларыбызның һәркайсының үз йөзе, үз рухи һәм гамәли дөньясы булган сурәтләрен тудыра. Прицепчы кыз Фәридә, тракторчы егет Һарун, яратмаган хатыныннан качып, чирәм җиренә киткән Ислам кебек яшьләрдән торган бригада әгъзаларының һәркайсы үз холкы, үз күңел-җан сыйфатлары белән гәүдәләнә. Әммә Нурихан аларга җан биреп кенә чикләнә торган әдип түгел. Аның һәр әсәрендә эчкә яшерелгән, бөтен сурәтләү тукымасына сеңдерелгән тел төбе мәгънәсе бар. «Артта калган юллар» повестындагы Хәмдия язмышын сурәтләп, ул кешене хаксыз рәнҗетүнең имансызлык булуын, «Кичү» романындагы Габделхәй кичерешләре аша сугыштан соңгы замана түрәләренең күсәккә әйләнгән мәгънәсезлеген, «Бала күңеле далада» романында иң гади кешеләрнең дә ялган патриотизм шаукымыннан өстен торуларын күрсәтә.

Әйтеп үткән әсәрләрне күзәтү генә дә Нуриханның әдәбиятыбызда күренекле урын тоткан әдип булуын расларга җитәр иде. Әмма Нурихан канәгатьләнеп, яңа юл ачмыйча яши торган әдип түгел. Алтмышынчы елларда аны бөтенләй яңа бер юл — халкыбыз үткән тарих үзенә суырып ала. Ул, җиң сызганып, татар халкы тарихын һәм фәнни, һәм әдәби өйрәнүгә керешә, озак еллар буена тузан җыеп яткан китаплар эченә кереп чума, «Ерак гасырлар авазы», «Фест дисбесенең сере», «Шәҗәрә» кебек чын мәгънәсендә фәнни хезмәтләр яза. Нуриханны, һич тә икеләнмичә, тарихны, телне, археологияне тирән белүче галим дип әйтеп була. Мин шәхсән аның Фест дисбесен үзенчә укуын, татар теленең төзелешен иҗекләр ясалышыннан чыгып яңача аңлатырга омтылуын бик кызыклы ачышлар дип саныйм. Халыкның тарихына, го-

реф-гадәтләренә, ыру-кабилә мөнәсәбәтләренә галимнәрчә үтеп керү һәм төшенү язучыга бөтенләй яңа иҗат офыклары ача. Нурихан иҗаты яңа биеклеккә күтәрелә. Ул тарихи романнар остасына әверелә. Иң элек чын канәгатьләнү белән шуны әйтергә телим. Нурихан сайлаган бу юл бик тә бәрәкәтле һәм хәерле юл булды.

Әлбәттә, беренче ныклы адымны Нурихан Фәттах атлап китте. Бу аның 1969 елда тәмамлаган «Итил суы ака торур» романы иде. Язучы нигә тарихка борылды соң? Заман хәвеф-хәтәреннән качып, җиңел юл сайладымы? Тарихи хәлләргә сюжет төзү осталыгы җитмәүчеләр дә еш ябышкалый. Юк, Нуриханның тарихка мөрәҗәгате бөтенләй башка нияткә — олы максатка нигезләнгән. Ул: «Тарих ул — гыйбрәт, акыл һәм тәҗрибә!»— дип фикер йөртә, бүген мең еллар буена туплана килгән культура казанышларын, кешелек җәмгыятен саклап калып булырмы, дигән сорауга җавап эзли һәм — иң мөһиме — туган халкының язмышы турында тирәнтен уйлана. «Мең мәртәбә үлеп, мең мәртәбә терелгән, мең мәртәбә таркалып, мең мәртәбә яңадан кушылган һәм бернинди җил-давылга, бернинди кар-буранга, бернинди янау-куркытуларга, ачлык, туфанга карамыйча, һәрбер җан иясе кебек, һаман яктыга, һаман кояшка үрләгән тырыш, чыдам халкымның тарихы миндә һәрвакыт ышаныч, ныклык һәм горурлык тойгысы тудыра»— Нуриханның тарихка мөрәҗәгате әнә шул олы мәхәббәт туфрагында шыткан, шуннан азыклана. Шуңа күрә «Итил суы ака торур» романында ук ул, үзенә кадәрге традицияләрне искә алган хәлдә, үз юлын, үз концепциясен таба — тарихи фактларны җанлы һәм мавыктыргыч вакыйгалар эчендә «эретә». Идел буе болгарларның дәүләт булып оешуын күрсәткән тарихи вакыйгалар акбүре ыруының язмышы, гореф-гадәтләре, кабиләләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр итеп, Күрән би, Койтым бикә, Утташ кам, Тотыш, Тәңкә, Аппак кебек җанлы образлар язмышы итеп сурәтләнә. Йотылып укыла торган бу матур әсәрнең күркәм сыйфатларын, андагы романтик табигать күренешләрен күрсәтеп бирү күп урын сорар иде. Кызганыч, мәкалә күләмендә генә аны эшләп булмас.

Тиздән Нурихан моннан мең ел элек булган тарихтан тагын да ераккарак китә — безнең дәвергә кадәр 2—3 йөз еллар элекке, ягъни ике мең елдан да борынгырак чорга — сөннар тарихына мөрәҗәгать итә һәм «Сызгыра торган уклар» дигән эпопеясын иҗат итүгә керешә. Бик хаклы рәвештә Тукай бүләгенә лаек булган бу дилогиясендә Нурихан Фәттахның сүз рәссамына хас күп сыйфатлары тулы ачылды. Борынгы бабаларыбызның яшәеше, кабиләләр белән кабиләләр, илләр белән илләр арасындагы көрәш-сугышлар, борынгы кешеләрнең эшгамәлләре, уй-хисләре Туман каган, аның улы Албуга, каганның күпсанлы хатыннары, каганлыктагы дистәләрчә, йөзләрчә кешеләрнең язмышлары рәвешен алып, киң колач белән чын сәнгатьчә, оста рәссамнарча җанландырыла. Дилогия бүгенге әдәбиятыбызның казанышы булып әверелде.

Тарих, халкыбызның күренекле вәкилләре, аларның яктылыкка, бәхеткә омтылышы, гаделсезлеккә, кан коюларга нәфрәт Нуриханның барлык әсәрләре аша кызыл җеп булып сузыла. Мин моны бигрәк тә аның «Кол Гали», «Сармат кызы Сәринә» трагедияләрендә ачык күрәм. Сүз уңаенда әйтәсем килә: бу әсәрләрендә Нурихан талантлы драматург буларак та ачылды. «Кол Гали» трагедиясендә шулай ук Нуриханның яшь вакыттан килгән шигъри куәсен дә күрми мөмкин түгел.

Сүзем озынга китсә дә, Нурихан Фәттах иҗатының тагын бер тармагын әйтми калдыру гөнаһ булыр иде. Бу — аның тәрҗемәчелеге. В.Гюгоның «Хокуксызлар» романын ул 1954 елда ук тәрҗемә итеп бетергән иде. Аннан О.Бальзакның «Горио»сы, И.Гончаровның атаклы

«Обломов»ы. Шушы тәрҗемәләр генә дә Нуриханның эш сөючән табигатен артыгы белән күрсәтәдер.

Нурихан бүген дә армый-талмый эшли, ерак тарихларда калган серләрне эзли, иҗат итә, халкыбыз язмышы өчен олы борчылу белән яши. Каләмдәшемә һәм сабакташыма киләчәктә дә Итил суы кебек бетмәс иҗат агымы, каләменә сызгыра торган үткен уклар көче һәм үзенә озын-озын гомер телим.

*Зәет Мәҗитов,*
*7 ноябрь, 1998*

# СЕЗНЕҢЧӘ НИЧЕК?

*Роман*

## Автордан

«Сезнеңчә ничек?» дип аталган бу китап минем беренче зур әсәрем. Мин аны моннан илле еллар чамасы элек иҗат иттем. 1956 елда ул «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналында басылды, 1957 елда Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып чыкты.

«Сезнеңчә ничек?» алтмышынчы елларда татар әдәбиятында зур яңалык буларак дан казанды. Китапны яшьләр дә, урта буын, өлкәннәр дә яратып укыдылар. Ул вакытта китап укучылардан күп кенә хатлар килде. Рәсми даирәләрдә роман шактый ыгы-зыгы тудырды. Әсәрне тикшерүгә багышланган җыелышларда, вакытлы матбугат битләрендә яшь язучыга карата тәнкыйть сүзләре дә әйтелә башлады. Төп тәнкыйть шуңа кайтып калды: Н.Фәттах, имеш, тормышны бозып сурәтләгән, романда, имеш, Коммунистлар партиясенең җитәкче роле күрсәтелмәгән.

1961 елда китап Мәскәүдә «Молодая Гвардия» нәшриятында русча басылды. Берничә елдан соң, «Молодая Гвардия» шул ук китапны икенче тапкыр чыгармакчы булды. Гадәттәгечә ул нәшриятның тематик планына да кертелде. Ләкин шуңа да карамастан русча китап икенче тапкыр дөнья күрә алмады. Монда, үзебезнең Казанда, «Сезнеңчә»не татарча яңадан бастыруны үтенеп, югары дәрәҗә кешеләренә һәм нәшриятка хатлар яздым. Колак салучы булмады.

Дөнья хәзер үзгәрде, бик нык үзгәрде. Дөнья үзгәрү белән, безнең аңыбыз, карашларыбыз, таләпләребез дә үзгәрде. Инде картайгач «Сезнеңчә»не — кайчандыр макталган, ләкин читкә тибәрелгән «Сезнеңчә»не яңадан укып чыктым. Кайбер тел-җөмлә кытыршылыкларын төзәттем дә, йомшак урыннарын сызгалап ташладым да, Татарстан китап нәшриятына тәкъдим иттем. Икенче басма итеп. Төзәтсәм, сызгаласам да, әсәр, нигездә, үзгәрешсез калды. Узган гомерне төзәтеп булмаган кебек, узган гомердә иҗат ителгән әсәрне дә «яхшыртып» яисә бүгенге көнгә яраклаштырып булмый. Элекке заманда туган әсәр, шул заманның көзгесе булып, бүген дә яши ала. Аның моңа хакы бар. Бу миңа шулай тоела. Китап укучыга ничегрәк тоелыр — монысы инде тулысынча аның хөкемендә.

*Нурихан Фәттах*
*Октябрь, 2001 ел. Казан*

## Беренче бүлек

### 1

Утыз беренче группа студентлары политэкономиядән имтихан бирәләр. Бу — соңгы имтихан. Инде бөтен группа диярлек тапшырып бетергән. Имтихан бара торган аудитория ишеге алдында азакка калган берничә кеше генә үз чираты җиткәнен көтеп тора. Ялтыравык паркет идәнле, биек түшәмле озын коридор йә әкрен генә гүелдәргә тотына, йә кисәк кенә бөтенләй тынып кала, һәм шул вакыт аудиториядәге җавап бирүче студентның дулкынланган тавышы ныгытып ябылган ишек аша да аерм-ачык булып ишетелә башлый.

Коридорның икенче бер башындагы зур тәрәзә каршысына җыелган студентлар — егетләр, кызлар, шаулашып, кызып, үзләренә чыккан билетлар, авыр сораулар, доцент Захаровка биргән җаваплар хакында, теге-бу турында сөйләшәләр, көлешәләр, бәхәсләшәләр. Аларның хәзер бернинди кайгылары юк — дүрт яклары кыйбла. Ләкин алар әле беркая китәргә ашыкмыйлар — үзең генә түгел бит, бүтәннәрнең «котылып» чыгуын да көтәргә кирәк.

Сәгыйть, тәрәзә янындагы төркемнән аерылды да, коридорның бу башына таба юнәлде.

Ул өстенә кыска җиңле күлмәк кигән; гәүдәгә калку гына; буй-сыны килешле, хәтта матур дип әйтергә була. Язгы сессия аны яхшы ук суырган. Күрәсең, зачет-имтиханнарга аңа бөтен дөньясын онытып әзерләнергә, студентлар әйтмешли, көн-төн «штудировать» итәргә туры килгәндер — кояшта янып каралган киңчә бите тартыла төшкән; яңак сөякләре почмакланып калкып чыккан; уйчан соргылт күзләрендә арыганлык һәм шул ук вакытта ни өчендер борчылу сизелә; озын кара чәчләре чигәләренә кадәр төшеп үскән, хәтта ияк очларындагы, борын астына төртеп чыккан кара төкләре дә кырылмаган.

Ул, ишек төбендәгеләр янына туктады да, кемнедер эзләгән шикелле, игътибар белән иптәшләренә күз йөртеп чыкты һәм беркемгә дә төбәп кенә әйтмичә:

— Кем сөйли? Ничәнче билет?— диде.

Аңа җавап бирүче булмады, ул иптәшләре арасыннан алгарак узды.

Аркасы белән стенага терәтеп куелган урындыкта, бәләкәй генә алсу кулъяулыгын селти-селти, кызарынган озынча битле Муся утыра. Ул тыныч түгел; аның дугаланып торган нечкә кашлары нәрсәгәдер бик нык

аптыраган төс белән бер югары күтәрелә, бер аска төшә. Аның тезләре өстендә бер кочак конспект, китап. Ул аларны имтиханнарын тапшырып чыккан иптәшләреннән алган һәм хәзер ашыгып, кабаланып, билетлар буенча җаваплар әзерли. Бик нык тынычсызланудан дымланган күзләрен әле берсенә, әле икенчесенә төби, муенын сузып, игътибарсыз гына тыңлап тора да, берәрсенең җиңеннән тарта, ялварулы кыяфәт белән, берәр аңлашылмаган сорауга җавап бируләрен үтенә башлый.

— Ой, Сәгыйть!— диде Муся, егетне күрүенә чиксез шатланган кебек, һәм калтыранган нечкә бармак очларын аның кулына тидереп алды.— Дифференциаль рента беренче, дифференциаль рента икенче... Әйт әле, зинһар? Уф, кызлар, беттем, беттем! Бер генә мәртәбә укып чыгарга да өлгермәдем. Сәгыйть! Ой, Бикчурин, әйтче, зинһар... Җир рентасы, абсолют рента, дифференциаль рента беренче...

Сәгыйть башта аның сүзләреннән бер генә нәрсә дә тотып ала алмады. Шулай да колагына эленеп калган «дифференциаль рента беренче» турында үзе белгәнне аңлатырга тотынды. Ләкин Мусяда хәзер икенче кайгы — тыңлаган кеше шикелле әз генә тынып торды да, кинәт исенә бөтенләй икенче нәрсә төшеп, шатыр-шотыр дәфтәрләрен актарырга кереште.

Сәгыйть, аның илтифатсызлыгына кәефе кырылгандай, тиз генә читкә китеп барды. Аскы катларга төшә торган баскыч алдына килде дә баскычның таш култыксасына таянган көе, борчылып аска карады.

Йортның беренче катыннан югары катына кадәр спираль кебек әйләнеп-әйләнеп баскыч күтәрелә, уртада — кое кебек тирән бушлык һәм иң аста, коеның төбендә, бәләкәй генә дүрт почмак булып шакмаклы таш идән ялтырап ята.

Сәгыйть, астагы беренче басмадан күзен алмыйча, озак кына түбәнгә карап торды, ләкин көткән кешесе һаман күренмәде. «Кая китте икән инде?»— диде ул күңеленнән, һаман ныграк борчыла барып. Һәм кире кузгалып кына китмәкче булган иде, аста баскыч култыксасына тотынган бер ак кул күренеп китте. Ул аның кем кулы икәнен шундук танып алды.

Баскыч буенча өскә менеп килгән кешенең бераздан киң читле ак эшләпәсе, елкылдык, зәңгәрсу крепдешин күлмәк итәге, җиңнәре, кулбашы күренә башлады. Кыз, икенче кат коридорына менеп җиткәч тә, өстән кемнеңдер үзен күзәтеп торганын сизенгән кебек, башын күтәреп югары карады.

— Мен инде тизрәк! Тизрәк! — дип кычкырды Сәгыйть, кул болгап.

Тулы, таза гәүдәле һәм бераз гына авыр сөякле күренгән шат кыяфәтле кыз, менеп җитәргә берничә басма калгач, кисәк кенә тукталды да, бер кулы белән баскыч култыксасына тотынган көе, башын арткарак ташлап, елмаеп Сәгыйтькә карады.

— Уф, тын бетте,— диде ул, еш-еш сулыш алып.

Аның ап-ак, матур бит очларына — әллә ашыгып килгәнгә, әллә инде баскычтан менгән чакта гына — җиңелчә алсулык йөгергән иде. Аның күперенке, бөдрә соргылт чәчләре, эшләпә читеннән чыгып, кулбашына салынып төшкән иде.

— Кайда йөрисең? Әйдә тизрәк!— диде Сәгыйть, ачуланырга тырышып һәм, кашын җыеру урынына, тыела алмыйча, бер дә юктан елмаеп җибәрде.

Кыз, өчпочмаклы бәләкәй генә нәфис кызыл сумка тоткан уң кулын алга сузып:

— Хәл бетте... бир кулыңны, тартып ал,— диде сизелеп торган иркәләнү тавышы белән.

Сәгыйть кызга каршы берничә басма аска төште һәм чынлап та аны тартып алмакчы булган шикелле, кулын сузды. Кыз исә егетнең кулыннан кысып тотты да, көлә-көлә, кинәт аның үзен тартып җибәрде. Егет чайкалып китте, чак-чак кына башы белән барып төшмәде, ярый әле сул кулы белән култыксага тотынган иде.

— Җүләр! Шаярма!— диде ул, каушап калып.

Кыз да агарынып китте. Ләкин аңа берни булмаганын күреп, тагын елмайды. Башын кыек салды да, хәйләкәр күзләре белән егеткә карап, назланып:

— Күтәреп мендер, ату менмим!— диде пышылдар-пышылдамас тавыш белән.

Сәгыйтьнең бер дә шаярып вакыт уздырып торасы килми иде. Ул бер ачуланды, бер елмайды, көлде, кызны тизрәк менәргә ашыктырды, аның кулын авырттырудан куркып, сакланып кына беләгеннән тартты. Уң кулы белән баскыч култыксасына тотынган кыз урыныннан да кузгалмады.

— Җә, шаярма, дим!.. Анда хәзер беркем дә калмаган, хәзер синең чират...

Шул вакыт аның тавышы йомшап калды. Кызга карата кырыс булырга тырышуы аңа кинәт мәгънәсез булып, кыстау сүзләре — кирәксез, ышандыргысыз булып тоелды. Ул, нәрсәдер буласын сизенгән шикелле тынып, юашланып калган һәм бөтен килеш-килбәте белән, бөтен йөзе белән чиксез ярату, бәхетле куаныч нуры балкытып

торган кызга таба тартылып куйды. Бер басма аска төште дә, кыздан һаман күзен алмыйча:

— Үбеп алырмын да...— диде, авыз эченнән мыгырданып.

Кызның йөзенә шундук җиңелчә курку билгесе йөгерде, күзләре зуррак ачылды, һәм ул көчсез хәрәкәт белән кулын селтәп, әз генә чигенгәндәй итте.

— Кит аннан!..

— Нәрсә, үпмәс дисеңме әллә!

Сәгыйть, баскычта үзләреннән башка бүтән берәрсе юкмы, дигән шикелле, аска-өскә ялт-йолт каранды да, кызның бармак очларыннан тотып та алды, ак, җылы кул аркасын тиз генә үбеп тә алды. Кыз, ничектер уңайсызланып, ләкин шулай да артык нык каршылык күрсәтмәгән кыяфәт белән, башын иеп тик торды.

— Кеше күрсә!..— диде ул, иреннәрен әкрен генә кыймылдатып, нindидер уртак, яшерен сер турында сөйләшкән кебек.

— Күрсә ни!..— диде Сәгыйть һәм, чыннан да, көтмәгәндә, кеше-ни килеп чыгу куркынычын да, үзләренең кайдалыгын да онытып, кызның кыска чәч бөртекләре белән капланган йомшак муенына, алсу колак турысынарак, иреннәрен якынайтты.

Аста таш баскычка шак-шок басып менгән туфлиле аяк тавышы ишетелде. Кыз да, егет тә кинәт дерт итеп киттеләр. Тиз генә урыннарыннан кузгалдылар да, берберсенә хәйләкәр елмаешып, баскыч буенча югарыга йөгерделәр.

Аудитория ишеге ачылып китте, аннан әле генә мунча кергән шикелле кызарынып, тирләп-пешеп, ләкин бик канәгать төс белән көлемсери-көлемсери, бер егет килеп чыкты. Аны шундук иптәшләре уратып алдылар, сораштырырга, зачет кенәгәсен кулдан-кулга йөртергә тотындылар. Әле генә баскыч уртасында үбешеп торган Сәгыйть белән кызга, аларның гаепле кешенеке шикелле йөзләренә беркем дә игътибар итмәде.

Эшләпәле кыз, ишек тоткасына тотынып торган Мусядан:

— Хәзер кем керә? Синең чиратмы?— дип сорады, соңга калуы өчен бераз борчылган тавыш белән.

Шатлыктан Мусяның чытык йөзе ачылып китте.

— Ой, Ида, Идочка!— диде ул, кызның җиңеннән тарткалап.— Ида, Ид, бар, син кер! Куркам, берни белмим... Ой!..

Муся зур ишекне ачты да, нәрсә уйларга да белми торган Иданы төрткәләп диярлек эчкә кертеп җибәр-

де, үзе, бик куркыныч, авыр нәрсәдән котылган кебек, җиңеләеп көрсенеп куйды һәм, дәфтәрләре белән җилләнә-җилләнә, яңадан урындыгына утырды. Аның гадәте шул — имтиханмы, зачетмы тапшыру вакыты җитте исә кабалана, калтырана. Укытучы каршысына ул беркайчан да беренче булып керми, гел артка кала. Моның үзенә күрә хәйләсе бар: көне буе аудиториядән чыкмыйча, имтихан алып утырган укытучы, аныңча, соңга таба арый, алҗый башлый һәм, шулай булгач, иң азактан җавап бирүче кешедән бик үк төпченеп тә тормый, юк-барга «бәйләнеп» тә маташмый. Ләкин мондый хәйләнең әле Мусяга беркайчан да диярлек шатлык китергәне юк — ул соңга кала һәм күп кенә очракта барыбер соңгы, калдык билгеләрне генә алып чыга.

Сәгыйть яшертен генә баскыч ягына карап алды: менүче кеше күренмәде. Ләкин ул әле һаман иптәшләренә күтәрелеп карарга уңайсызланып торды, аңа аларның үбешүләрен мондагыларның бөтенесе дә күргәндер һәм алар бу турыда бары тик аны оялтмас өчен генә үзенә әйтмиләрдер шикелле тоелды. «Менә сиңа кирәк булса! Бөтен кеше алдында мәсхәрәгә калуың бар!»— диде ул, үзенең шундый башсызлыгы, акылсызлыгы өчен оялу катыш курку тоеп.

Ишек янында тагын Муся тавышы ишетелде.

— Ой, Степка, Степанушка! Кил әле монда!— диде Муся, әле генә имтихан биреп чыккан күзлекле егетне үз янына чакырып.

Степканың тар балаклы кыска чалбары ботларына артык нык сыланып, тартылып тора; шуңа күрә аның болай да тәбәнәк гәүдәсе бигрәк тә бәләкәй булып күренә. Киресенчә, аның полтыранган аксыл чәче башын бик зур итеп күрсәтә. Степка, костюм җиңе очыннан чыгып торган кызыл куллары белән егетләрнең, кызларның аркаларына кагылгалап, кеше арасыннан үзенә юл салып, Муся янына килде.

— Э-э, син әле һаман ишек төбе саклыйсыңмыни?— диде ул Мусяга, озын бармаклары арасына кысып тоткан папиросын суыра-суыра.— Аена күпме түлиләр? Болай булгач, стипендия дигән булып, политэкономия белән башны авырттырып та торасы юк.

Ләкин Мусяның хәзер бер дә мәзәк тыңлыйсы килми. Ул, чыраен сытып, борыны төбенә үк килеп җиткән тәмәке төтенен куып җибәрде дә, Степкага бер-бер артлы сораулар яудырырга тотынды.

— Ой, Степка!.. Сөйләле Давид Рикардо турында? Ә

нәрсә ул «акча»? Кызлар, кызлар, «акча» калган, нәрсә ул «акча»? Ой, кызлар!..

— Давид Рикардо?— диде Степка, уйланган шикелле күренергә тырышып.— Давид Рикардо — дөньяда беренче булып бөек фәнни ачыш ясаган. «Кем ашамый — шул яшәми»— аның теориясе.

Муся көлгән булды, әмма шулай да берәр рәтле сүз ишетмәкче булып, өметен өзмичә, тагын Степкага күзен текәде.

— Сиңа «акча» кирәкмени?— диде Степка, бик җитди тонда.— Акча — политэкономиядән «өчле» алган студентларга түләнми торган стипендия.

Муся, кулын селтәп, яңадан дәфтәрләренә кадалды.

— Ой, Степан Иванович, экзаменыңны биреп чыккач та син идеалистка әйләнгәнсең. «Акча»ны син миңа Маркcча итеп әйт!

— Ә син Маркcның үзеннән сора, алай бик материалист булгач...

Муся бернидән дә канәгать түгел. Ул үз-үзенә ышанмыйча һаман зарланды да зарланды, әле бер дәфтәренә, әле икенчесенә тотынды, нидер сызгаларга, актарырга тотынды. Аның бертуктаусыз чәпчүенә Сәгыйтьнең ачуы килә башлады. Ул Мусялар яныннан китеп барды, тәрәзә каршысына килде, беркемнең дә сүзенә-ниенә катышмыйча, бик бирелеп тыңлаган кебек, бераз гына басып торды да тагын урыныннан кузгалып китте.

Ул Иданың бүген бик кәефле булуы һәм аның хәзер имтихан бирергә кереп китүе турында уйлады. «Үбешүен үбешү дә, политэкономиядән нишли бит әле!»— диде ул күңеленнән, кызы өчен тирән бер борчылу кичереп. Бүтән фән булса, әллә ни курыкмас та идең, бу бит — политэкономия! Политэкономиянең дә нинди әле — доцент Захаровка тапшырырга кирәк!

Группа кызлары: Захаров кызларны яратмый, кызларга билгеләрне юри саранланып куя, дип сөйлиләр. Кызлар арасында аның турында хәтта анекдот кебек бернәрсә дә йөри икән. Бу турыда аңа Ида сөйләгән иде.

Захаров, имеш, студент чагында бер кыз белән йөргән. Алар, имеш, бер-берсен бик нык яратышканнар, өйләнешмәкче булганнар. Бер атнадан загска барырга дип торганда гына, кызы, имеш, моны алдап, бер лейтенантка кияүгә чыккан да, самолетка утырып, каядыр очып та киткән. Шуннан соң, имеш, Захаров кайгысыннан чакчак кына акылдан язмаган. Бу аның иң беренче һәм иң соңгы мәхәббәте булган. Шул кыздан башка ул, имеш,

беркайчан да беркемне дә сөймәскә үз-үзенә ант иткән. Шуңа күрә ул, имеш, шуннан соң бөтен хатын-кызга дошман күзе белән карый икән. «Боже мой, ничек шулай булырга мөмкин!— дигән иде Ида, үзләренең сөекле укытучыларын алдап качкан кыз турында, нәфрәтләнеп.— Андый кызларның мин бөтенесен дә атып бетерерием!»

Мондый имеш-мимешләр дөрестерме-түгелдерме, Захаровның чыннан да хатыны бармы-юкмы — Сәгыйть бу турыда рәтләп берни дә белми иде. Билгеле, кызлар кайчакта тузандайны тубалдай итеп, арттырып та сөйләргә яраталар. Шулай да аларның сүзендә дөреслек юк түгел шикелле. Чынлап та ул үзен кызлар белән бик сәер тота, беркайчан диярлек аларга игътибар итми. Ләкин, ни генә булмасын, лектор Захаров, укытучы Захаров бик шәп кеше. Аның лекциясе вакытында бөтен актовый зал шыгрым тулы була, ул сөйләгәндә урындык шыгырдаткан, кәгазь шыштырдаган тавыш та ишетелми, һәм студентлар аны чын күңелләреннән бирелеп, яратып тыңлыйлар.

Доцент Захаров турындагы имеш-мимешләрне исенә төшергәч тә, Сәгыйтьнең кинәт күңелендә калыккан ниндидер ачу, нәфрәт хисеннән йодрыклары кысылды, кашлары җыерылды. Аның уйлары үзеннән-үзе Идага күчте, һәм ул аны, үзе дә сизмәстән, ишетеп белгән шул намуссыз кыз белән чагыштырып карады. Аның күз аллары караңгыланып китте. Әгәр хәзер аңа, Хуҗа Насретдинча әйткән кебек: иртәгә дөнья бетә, дисәләр, ул моңа бер шиксез ышаныр иде, әмма инде: синең Идаң да Захаров кызы шикелле, дисәләр, билгеле, мондый нәрсәгә ышану түгел, шул сүзне хәтта әйтергә батырчылык иткән кешенең үзен юләрләр йортыннан чыккан, дип уйлар иде. «О-о, ул андый түгел!— диде ул, эчке бер горурлык, бәхетле бер мактану белән.— Элек кенә, безгә кадәр генә булган ул андый кызлар. Хәзер — юк!»

Ләкин үзе, кызының имтихан биргән арада гына да икенче кешегә әйләнүеннән курыккан шикелле, тизрәк аны күрмәкче булып, ишек откасына тотынды.

Шундук берничә кеше берьюлы:

— Ачма!— дип пышылдады.— Илья Кузьмич ачулана.

Әмма Сәгыйть ишекне бераз гына ачып өлгергән иде инде. Ул, ишек ярыгы турысына иелеп, сыңар күзе белән генә аудитория эченә карый башлады.

Захаров озын кара өстәл янындагы аркалы урындыкка утырган. Бүтән вакытта ягымлы, ачык йөзе хәзер бик

җитди, хәтта бераз кырысрак та бугай әле. Менә ул язганда яисә укыганда гына кия торган зур күзлеген ялтыратып, башын әкрен генә уңга, билет сорауларына җавап әзерләп утыручылар ягына борды да кемгәдер нәрсәдер әйтте, һәм шул чакны Сәгыйть урындык кузгаткан тавыш ишетте. Өстәл арасыннан чыгып, Захаров янына килүче кешенең аяк тавышыннан ук Ида икәнен аңлап алды. «Кара, нинди тиз!»— диде ул күңеленнән. Ул аның тән төсендәге капрон оек кысып торган тулы, матур балтырларын, аяк атлаган саен як-якка салмак кына чайкалып киткән күлмәк итәкләрен, берничә бит ак кәгазь тоткан нәфис ак бармакларын күрде.

Ида, күлмәгенең кабарынкы иңсәләрен төзәткәләп, Захаров өстәле янына ук килеп җитте дә, доцентны Сәгыйтьтән бөтен гәүдәсе белән каплап, туктап калды. Дулкынланудан җиңелчә генә тамак кырып куйды, бер ярты адымга кире чигенде һәм, уң кулы белән өстәл читенә таянган көе, гадәттәгедән бераз күтәренкерәк тавыш белән, ашыкмыйча гына сөйли башлады. Каршыдагы зур тәрәзәдән кыйгачлап кояш төште, шуңа күрә аның күперенке чәчләре алтынга манчылган шикелле булып күренде, күлмәгенең җыерчык сыртларында көмешсыман елкылдык нурлар җемелдәште.

Ишек янындагылар барысы да, алдан килешеп куйган шикелле, Ида сөйләргә тотынгач та тынып калды. Әз генә ачык ишек аша Иданың һаман ныгый, һаман җайлана барган көр тавышы ишетелде. Сәгыйть баштарак аның сүзләрен бик үк аера алмады, ләкин соңыннан, аңа «яхшы» билет эләккәнлеген аңлап алгач, өстеннән авыр таш төшкән кебек, җиңел генә бер көрсенеп куйды. Бишенче билет! Ул аны белә. Кичәгенәк кенә, обсерватория бакчасында утырганда шул билет сорауларын кабатлап чыккан иде. Менә ничек шәп булган!.. Ныгытып әзерләнсә, булдыра ул, менә дигән булдыра!

Сәгыйть, үзенең тыңлап торуы белән Иданы каушатудан курыккан шикелле, ишектән күзен алды да тагын читкә китеп барды һәм әрле-бирле коридор буенча йөренергә тотынды.

Иданың тизрәк сөйләп бетерүен, тизрәк зачеткасын тотып чыгуын Сәгыйть кебек үк түземсезләнеп, тынычсызланып көтеп торган Муся кинәт кенә кулын күкрәгенә куйды да Сәгыйтькә таба муенын сузып:

— Соңгы сорауга күчте!— диде.

Сәгыйть ашыгып тагын ишек төбенә килде.

— ...Бездә,— диде Ида, үз-үзенә ышанган нык тавыш белән,— физик хезмәт белән акыл хезмәте арасын-

да аерма көннән-көн бетә бара. Бездә хезмәт кешенең иң беренче таләбенә әйләнде...

«Нигә билетта булмаганны сөйли инде ул?»— диде Сәгыйть күңеленнән, аның билеттагы сораудан читкә чыгуын сизеп.

Захаров та шулай дип уйлады, ахры. Ул аңа нәрсәдер әйтте, Ида исә, ләззәтләнеп, кызып сөйләгәндә генә бүлдерүләренә кәефе киткән кебек, кисәк кенә туктап калды. Захаров нәрсәгәдер икеләнә иде бугай. Ул аңа ниндидер өстәмә сорау бирде һәм бары тик Ида анысына да «шатырдатып» җавап биргәч кенә, алга табарак иелде дә каләменә тотынды. Бик әкрен генә кыймылдап, каләмен карага манды, башта ведомость кәгазенә, аннан соң Иданың зачет кенәгәсенә язып куйды.

Ида, бер кулына кәгазьләрен, икенче кулына ачык көе калган зачеткасын тотып, уттай янган шат йөз белән коридорга килеп чыккач та, аны шундук уратып алдылар.

— Ничек?

— Кая, күрсәт әле?— диештеләр.

Шатлыктан ни әйтергә дә белмәгән кыз җавап урынына биш бармагын гына тырпайтып күрсәтте.

## II

Уку белән, җыелышлар белән, кызу, дәртле бәхәсләр һәм бер дә юкка акыл сатулар белән үткән кышкы көннәрдән соң; китап-дәфтәрләрдән башны калкытмыйча уздырган озын төннәрдән соң; сессия вакытында гына була торган борчылу, нәрсәдер көтү, икеләнүләрдән соң азаккы имтиханны бишкә биреп, үзеңне бөтенләй иркен сизү нинди рәхәт! Иртән-иртүк күзеңне ертып, авырткан баш белән йокыдан тору, ашык-пошык киенү, рәтләп ашарга да өлгермичә, университетка чыгып йөгерү; ялыктыргыч лекцияләр; «башка керми торган» беренче чыганаклар; имтихан тапшыру алдыннан гына була торган үзенә бертөрле киеренкелек; хәтта иң башлы егетләрнең дә йөрәгенә җаваплылык тойгысы, шикләнү шомы сала торган тыгыз атмосфера; тапшырылган беренче зачеттан соң җиңел сулыш алу һәм шундук яңа көч, яңа омтылыш белән икенчеләренә — беренчесенә караганда да авыррак тоелган сынауларга әзерләнә башлау; тырышлык, өмет-ышаныч — хәзер боларның барысы да артта калды. Үтеләсе ара үтелде, тормыш юлындагы исәпсез-хисапсыз максатларның тагын берсе эшкә ашты. Алда кояш нуры белән балкып торган киңлек, иркенлек. Бөтен җәй синең кулда...

— Кая барабыз хәзер?— диде Ида, зачеткасындагы «отлично»га тагын бер мәртәбә карап алып.— Кабангамы, ашаргамы?

— Чынлап та! Мин бит сине бүген көймәдә йөртергә тиеш болай булгач...

— Но мин дә сиңа бурычлы!

Алар әгәр соңгы имтиханнан Ида «отлично» алса, Сәгыйть аны көймәдә йөртергә, ә Сәгыйть «отлично» алса, Ида аңа «Анна Каренина»ны алып бирергә, дип сүз куешканнар иде.

— Киттек!.. Ах, киттек!..— диде кыз, Сәгыйтьнең беләгеннән тотып.— Мин сиңа китапны хәзер үк алып бирәм, Кабанга ашагач барырбыз.

Һәм ул тәрәзә төбенә җәеп ташланган конспектларын тиз генә җыештыра башлады.

— Киттек!

— Туктале,— диде Сәгыйть, китәргәме, китмәскәме, дигән шикелле бераз икеләнеп.— Әллә әзрәк көтеп торабызмы соң?.. Бөтенесе дә биреп бетермәгән бит әле... Синең дусың Муся да анда.

— Муся? Ну-у, тапкан көтеп торыр кеше! Нишләп ул минем дус булсын — синнән башка минем тагын нинди дусым булсын...— Елмаеп ул аның күзләренә карады.

«Чыннан да,— дип уйлады Сәгыйть,— бүтәннәрдә минем ни эшем калган — көтәселәре килә икән, көтсеннәр! Тиздән сәгать өч тула, иртәннән бирле ашаган юк — күптән инде көчекләр өрә башлады».

Алар кузгалып киттеләр.

— Мин синең «отлично» алырыңа бик үк ышанмаганыем,— диде Сәгыйть.

— Мин үзем дә!— диде Ида, чын күңеленнән танып, көлә-көлә.— Карасам — кичә син кабатлаттырган билет! Син кабатлатмаган булсаң, мин аны җиңел дип бөтенләй төшереп калдырадырыем... Захаров бүген уң ягы белән торган, ахры, алай төпченеп тормады.

Алар «ВЛКСМ» дигән язулы кара пыяла кисәге беркетелгән ишек турысына гына җиткәннәр иде, каршыга комсорг Гасыйм Таҗетдинов килеп чыкты.

— Кая барасыз? Китмәгез әле,— диде ул, аларны туктатып һәм җавап биргәнне дә көтмичә, аудитория алдында өелешеп торган группадашлары янына китте.

Шундук аның начальникларча боеручан тавышы ишетелде:

— Таралышмагыз, тапшырып бетергәч тә җыелыш була... Комсомол җыелышы.

Зур башын бераз алгарак иеп йөри торган, киң җилк-

әле Гасыйм артыннан Ида сүзсез генә карап торды, торды да, Сәгыйтькә борылып, чыраен сытып куйды.

— Нинди җыелыш инде ул тагын... уку беткәч! Йөри шунда кеше тапмаганны табып...

«Җыелыш» сүзен ишеткәч, Сәгыйтьнең дә шундук кәефе китте. «Кемнең тагын бер-ике сәгать авызын чөйгә элеп утырасы килер икән? Чыннан да, нинди җыелыш инде ул хәзер!»— диде ул, Гасыймның үзләренең юлын бүлүенә ачуы килеп.

Сәгыйть Гасыйм белән бер бүлмәдә тора иде. Ул Ида белән йөри башлаганга кадәр, Гасыйм аның иң беренче дусы, иң беренче иптәше иде. Ул аның белән кызлар турында да, лекцияләр, укыган фәннәр, профессорлар турында да, театр, кино турында да — теләсә нәрсә турында рәхәтләнеп сөйләшә ала иде. Бер-берсен алар бер-ике сүздән үк аңлыйлар иде. Ләкин бу дуслык көннәрдән бер көнне бозыла, ямьсезләнә башлады. Сәгыйть үзенең Ида белән йөрүенә Гасыймның бик салкын каравын сизеп алды. Гасыйм үзе кызлар белән йөрми һәм күбрәк вакытын китапка «кадалып» уздыра иде, ләкин шулай да, теләсә нинди егет кебек, кызлар турында сөйләгәнне тыңлаудан беркайчан баш тартмый торган иде. Соңгы вакытта ул бу тема белән бөтенләй кызыксынмаган шикелле булып кылана башлады.

Бәлки, Гасыймның да күңелендә кайчан да булса Идага карата берәр хис булгандыр, бәлки, андый хис хәзер дә юк түгелдер — каян беләсең аны! Бит алар Ида белән күрше районнан гына. Казанга килгәндә дә, авылга каникулга кайтканда да аларга еш кына бер үк пароходка утырырга туры килгәли. Ләкин нишлисең, Ида аны — Сәгыйтьне — ярата икән, моңа каршы кем ни әйтә алыр? Группадагы матурларның, менә дигән гүзәл, яхшы кызларның берсе, бердәнбере бары тик аны гына сөйгәнгә, бәлки, Гасыймның гына түгел, тагын кайбер бүтән егетләрнең дә эче сызлана торгандыр да бит! Аңа нәрсә, сызлансын әйдә! Ида аныкы — шуннан башка аңа берни кирәкми, беркем кирәкми. Нигә тагын бөтен дөньясы баш-аяк килми Гасыймы-фәләннәре белән — аның өчен ике тиен бер акча!

Ни генә булмасын, аларның арасы күзгә күренеп начарланды. Ул хәзер Гасыйм белән сакланып сөйләшә торган булып китте, аның алдында күңел хисләрен элеккечә бер дә юкка чыгарып түкмәде, шатлыгы-куанычы булса да, кайгысы-хәсрәте булса да, ничек тә үзе генә кичерергә, бүлмәдәш дусына берни сиздермәскә тырышты.

Бервакытны Гасыймның, гадәтенчә, бик тупас рәвештә, бернинди тартынусыз-нисез, аның Ида белән икесе арасындагы мөнәсәбәткә, аның бары тик үз эше — янына бер генә читне дә якын җибәрми торган нечкә күңел эше булган нәрсәгә кысылырга маташуыннан соң ул бөтенләй үз эченә бикләнде, Гасыймга хәтта рәтләп эндәшми дә башлады. Эндәшәсе килмәде. Шуннан соң ул комсоргны, үз-үзен бүтәннәрдән акыллы да, белемле дә итеп куярга ярата торган һәм, дөресен сөйлим дигән булып, кирәккә дә, кирәкмәгәнгә дә кешенең йөзенә бәреп әйтә торган тупас, кырыс холыклы комсоргны яратмау гына түгел, хәтта күралмый башлады.

«Кеше әз генә өскә күтәрелдеме, әз генә начальник булдымы — шундук борынын чөя башлый,— дип уйлады Сәгыйть.— Җәрингә икенче бүлмәгә күчәргә кирәк, барыбер аның белән борчак пешмәс».

...Аудитория тиз генә тынычланмады. Тышта шундый матур җәй булганга, тапшырыласы имтиханнар инде тапшырылып беткәнгә, инде хәзер барысы да дүртенче курс студентлары булып исәпләнә башлаганга һәм иртәгәдән үк, бүгенннән үк күптән зарыгып көткән ял, каникул башланганга һәркемнең күңеле күтәренке иде, һәркемнең нәрсәдер сөйлисе, иптәшләре белән нәрсәдер уртаклашасы килә иде.

Шуңа күрә комсоргның җыелыш җыеп торуына берәү дә диярлек игътибар итмәде — җыелыш җыймагае, инде кирәгем исә теләсәң нишлә...

Тик Мусяның гына йөзе һаман чытык, ләкин шулай да баягысы кебек мескен түгел. Захаров аңа «урта» куйган. Захаровны Муся тетә генә, саран, ди, фәлән, ди, төгән, ди. «Шундый нык тырышып әзерләндем, бөтенесен дә белә идем, шул өченче сорауда гына төртелдем»,— ди. Шунда ук, артта, кызлар уртасында Степка утыра, ул нәрсәдер сөйли, кызларны көлдерә, аларның шат күңеллелегеннән файдаланып, аудиториядә иркенләп тәмәке тарта. Ида да шунда, Мусялар янына утырган. Сәгыйть, алар өстәленә барып утырмакчы булып, урыныннан гына торган иде, Гасыйм җыелышны башлап җибәрде.

— Шауламагыз! Тукта!— дип кычкырды ул, кулын күтәреп. Карандашы белән өстәлгә шакып алды да, тагын кабатлады: — Иптәшләр, башлыйбыз... Муся, чыккач зарланырсың... җитте!

Ул, үзара сөйләшкәндәге кебек, ләкин бераз рәсми төстәрәк итеп, группаны өченче курсны уңышлы тәмамлау белән котлады. Аңа пыр туздырып кул чаптылар. Гасыймның гел җитди була торган кырыс йөзендә ел-

маю билгесе күренеп китте. Бу котлауны деканат яисә кафедра җитәкчеләренең берәрсе әйткән булса, тагын да яхшырак булган булыр иде дә бит, каян табасын инде аларны хәзер генә!

— Ә хәзер — бер яңалык...— диде Гасыйм, тавыш басыла төшкәч, бөтенләй икенче тонда.

Комсорг, һәркемнең кызыксыну катыш игътибар белән үзенә текәлгән күз карашларын тойган хәлдә, «яңалык»ның нидән гыйбарәт икәнлеген аңлатып бирде.

Шәһәрдән бик үк ерак булмаган «Заря» колхозы яз көне шаулап кар суы ага торган бер чокырны буып, ясалма күл булдырмакчы булган икән. Ләкин моны башкарып чыгарга колхозның үз кул көче генә җитәрлек түгел икән. Дәүләт колхозга бу эш өчен акча биргән, ә инде эшчеләр мәсьәләсенә килгәндә, идарә, ярдәм сорап, университетның комсомол комитетына мөрәҗәгать иткән. Факультетның егерме җиденче группа студентлары колхоз идарәсенең бу тәкъдименә, бу соравына шундук ризалык белдергәннәр һәм, бөтен группалары белән бергәләп, буа буарга бармакчы булганнар. Шуның өстенә алар, факультетның барлык комсомолецларын колхозга ярдәмгә барырга чакырып, мөрәҗәгать тә язганнар. Мөрәҗәгатьне бюро яхшы дип тапкан, һәрбер группада тикшерергә тәкъдим иткән. Колхозга иң кимендә өч йөз илле кеше барган вакытта да, буаны буып бетерү өчен бер атналап вакыт кирәк булачак икән. Һәркемгә, күп дигәндә, алтыҗиде көн эшләргә туры киләчәк икән. Аларын инде исәпләп чыгарганнар, барлык нәрсә әзерләнгән — бөтен тотка хәзер студентларда гына икән.

Гасыйм, иптәшләрен егерме җиденче группаның мөрәҗәгате белән таныштыргач:

— Хәзер менә уйлашырга кирәк,— диде, аудиториягә сынаулы караш ташлап.

Тагын да ныграк тынлык урнашты. Мондый нәрсәне, әлбәттә, беркем дә көтмәгән иде, һәм бу хәбәр студентларның күбесен аптырашта калдырды.

Сәгыйть утырган урынында кымырҗып куйды. Бу «яңалык» аның, дөресрәге, аларның алдан уйлап куелган планнарын җимерә иде. Алар уку беткәч тә берничә көнгә шәһәрдә калырга, Маркизга чыгарга, Аккош күленә, Зәңгәр күлгә, тагын шундый берәр җиргә барырга сүз куешканнар иде. Аннан соң ул Иданы пароход белән ярты юлга кадәр озатып куярга һәм якындагы тимер юл станциясенә чыгып, үзләренә кайтып китәргә тиеш иде.

Нәрсә, шулай итеп, план тормышка ашмас микәнни? Бер атна вакыт анда узачак, аннан соң инде Маркиз кайгысы да, ни кайгысы да калмаячак, тизрәк кайтып киту ягын гына карарга туры киләчәк — күркә кебек җил белән туенып ятмассың бит монда! Менә сиңа кирәк булса — хәерчегә җил каршы!.. Әллә соң?.. Әйе шул, анда бер дә Маркизлардан ким булмаячак... артыграк булмаса әле... Ялыктыргыч укулардан, шушы кысан, бөркү аудиториядән соң иркен кырда, саф һавада... икәүләп эшләве нинди күңелле булачак! Бәлки, анда урман да бардыр әле. Суы юктыр инде, ансы бераз үкенечлерәк, ләкин — бик үк кайгырыр нәрсә түгел. Юк, бик шәп булачак, менә дигән булачак! Ул анда аның белән бергә эшләячәк, аларны фатирга авыл йортларына урнаштырачаклар... Бәлки, лапас түбәсендә печәнлектә дә йокларга туры килер әле... Барырга!

Ул Ида ягына карап алды. Аның йөзендәге нәфис алсулык һаман шул көе иде, ул, башын бераз ия төшеп, Муся белән, Әмирхановалар белән нәрсә турындадыр пышылдашып утыра, әледән-әле башын селкеп елмаеп куя иде.

Сәгыйтькә бу минутта ул шундый якын, шундый матур булып күренде. Аңа тагын да күңеллерәк булып китте. Ул да барачак! Әлбәттә, барачак!..

Сәгыйть, беренче булып урыныннан торды да, дәртле бер күтәренкелек белән:

— Барабыз!— дип кычкырды.— Без дә бөтен группа белән барабыз!

Аудитория кисәк кенә гөрелдәргә тотынды. Шулай да аның тәкъдименә бик тиз генә кушылырга ашыкмадылар, кайберәүләр хәтта ризасызлык белдереп, мыгырдап та алдылар.

Ләкин шундук группа старостасы Самаринцевның калын тавышы ишетелде:

— Дөрес, Бикчурин, бөтенебез дә барабыз! Берәү дә калмый!

Аны тагын берничә тавыш күтәреп алды:

— Барабыз, әлбәттә! Ник бармаска?!

— Нәрсә ул бер атна!

— Кайчан китәргә, иртәгәме, бүгенме?

— Юк,— диде комсорг, тыныч кына.— Юк, бөтен группа белән бару мәҗбүри түгел. Мәсәлән, Әмирханованың санаторийга путевкасы бар, аңа бүген үк Кырымга китәргә кирәк. Арада, бәлки тагын шундыйлар бардыр? Сәбәбе булган кеше — кала!

«Мин беренче булып кычкырганга, бөтенебез дә бара-

быз, дигәнгә юри каршы килә инде»,— дип уйлап алды Сәгыйть ачу белән.

Сәбәбе булганнар чыннан да тагын табылды. Галя дигән кызга туганнары, тизрәк кайтырга кушып, Владивостоктан телеграмма җибәргәннәр икән, ә кыз самолетка алдан билет алып куйган булган икән. Степка: «Мин археологик экспедициягә катнашам, миңа кайда да җир казыйсы»,— диде; аларның экспедицияләре берике көннән чыгып китәргә тиеш икән.

Группа өч кешене берсүзсез азат итәргә булды. Эшкә бармаска сәбәбе булган бүтән кеше күренмәде. Сәгыйтьнең куанычы эченә сыймады.

Гасыйм авызын ачып нәрсәдер әйтмәкче генә булган иде, шул вакыт арткы рәттә әкрен генә бер кул күтәрелде. Ида, башын бераз аска иеп, урыныннан торды. Аның йөзе хәзер бик боек, җитди, хәтта кайгылы да кебек иде.

— Мин әйтмәскә уйлаганыем,— диде ул.— Иртән хат алдым. Әнием бик чирле... шуңа күрә...

Аның тавышы сизелер-сизелмәс кенә калтыранып киткәндәй булды. Берәү дә бер сүз әйтмәде, аның кайгысы болай сүзсез дә аңлашылып тора иде. Сәгыйть тынсыз, хәрәкәтсез калды. Әйтерсең өстенә кинәт салкын су койдылар һәм аның булачак бәхетле минутлар белән куанган ашкынулы кайнар күңеле, утлы күмер кебек, кинәт чыжылдап сүнде. Ул, гаҗәпләнеп, аптырап, сораулы караш белән Ида ягына карады. Аның күңелендә шундук әллә нинди сораулар туды. Ничек? Нәрсә дигән сүз бу? Иртән бит әле берни юк иде, әле генә ул шундый шат, шундый ваемсыз иде.

Аның тизрәк Ида янына барасы, сораштырасы, бөтенесен беләсе килде, аннан нишләптер аерым утыруына ачуы килде, ә җыелыш коточкыч озакка сузылды, Таҗетдинов мәсьәләне һаман да очлап куярга ашыкмады.

Иданы буа буарга барудан азат иттеләр.

— Ләкин,— диде Гасыйм, кисәтү тонында,— хәзер группа белән эшкә бармаучылар: котылдык, дип тынычлана күрмәгез. Каникулга кайткач сезгә нәрсә дә булса эшләргә туры киләчәк. Нәрсә эшләргә? Авыл кешеләренә — сезнең күбегез авылныкылар — урак вакытында колхозга ярдәм итәргә, халык алдында лекция, доклад сөйләргә була. Була гына да түгел, бу — сезнең өчен мәҗбүри. Бюроның карары шундый... Соңыннан комитетка кереп, кирәкле инструкцияләр, лекция өчен темалар алырсыз. Аңлашылдымы? Аңлашылса, тагын шул — үзегезнең эшегез турында шулай ук справка кебек берәр язу да алып килергә туры киләчәк... сезнең чыннан да

тик ятмаганлыгыгызны белдерү өчен... Монсы да шулай ук мәҗбүри!

Сәгыйть атылып Ида янына килеп җитте. Ул, нәрсәдән сүз башларга белмичә, тын гына атлап китте. Алар урамга чыктылар.

Кызлар, бер-берсен култыклап алдылар да, җанлы бер стена булып, бөтен урамны иңләгән көе, кычкырып сөйләшә-сөйләшә, көлешә-көлешә, алдан киттеләр. Алар артыннан егетләр атлады. Бөтен группа бергәләшеп башта ашханәгә, аннан соң киногa бармакчы булды.

Сәгыйть белән Ида арткарак калдылар. Сәгыйть кемнеңдер үзләренә:

— Әйдәгез!— дип кычкырган тавышын ишетте.

Ләкин хәзер анда бүтән кайгы иде. Ул ишетмәмешкә салынды, һәм алар, адымнарын һаман әкренәйтеп, тагын да арткарак калдылар, читкә тайпылдылар да икәүләшеп бөтенләй икенче якка китеп бардылар.

— Хәзер Маркизга чыгып булмас...— диде Ида, күңелсез генә.— Ә син юкка дулыйсың,— диде ул бераздан, Сәгыйтьнең ни өчен эндәшми барганын аңлап.— Хат килгәнгә ышанмыйсыңмы? Шуңа ачуланасыңмы? Әллә ышанмыйсың?

— Нәрсәгә?— диде Сәгыйть, ничек тә тынычрак сөйләшергә тырышып.— Минем белән барасың килмимени?

— Кая? Әле син һаман ышанмыйсың икән — иртән миңа хат килде! Әтием язган, әниең урыннан да торалмый, дигән... Беләсеңме, әнием мине ужасно ярата! Нишләр ул минсез?— Ул, егетнең күзләренә төбәп карады да, шаянланып аның кулына сугып алды.— Син дә мине яратасың! Шуның өчен дә мин сиңа иртүк әйтмәдем дә... сине борчыйсым килмәде.

— Ә?!

— Әйе, шуңа да әйтмәдем. Хәзер инде ышанасыңмы? Экзаменыңны провалить иткән булсаң шуның өчен — нишләриең? Син бит минем күлмәгем чирләсә дә кайгыга сабышасың,— диде ул, көлеп.— Ах, нинди әйбәт рыцарь син!

### III

Сәгыйтьнең яңадан күңеле күтәрелеп китте. «Менә бит нинди дөнья бәясе кыз!»— диде ул күңеленнән, аның: «Сине борчыйсым килмәде»,— дигән сүзенә кәефе килеп.

Ләкин мәсьәлә үзе өчен ачыклана, аңлашыла төшкәч, ул үз-үзен шелтәләргә тотынды. «Нинди эгоист мин!—

дип уйлады ул, күңелендә ниндидер ачы бер хис тоеп.— Анда аның әнисе чирләп ятсын, ә син аңа ачуланып тор, имеш! Эченнән ул ут йотса да, тышыннан берни сиздерми. Синең — эчеңдәге тышыңда!..» Аның күңелен Иданың ерактагы әнисенә карата чын-чынлап кызгану, борчылу хисе биләп алды. Кызының әнисе хәзер аңа үз әнкәсе кебек үк бик якын, бик кадерле булып тоелды, аның Иданы юатасы, кайгысын уртаклашасы килде.

— Идеалым!— диде ул, күңелендә туган яңа, көчле бер хистән тәэсирләнеп.— Сиңа бүген үк кайтып китәргә кирәк... Мин сиңа ачуланмыйм, мин каршы түгел... әниең янына, ул бит сине көтеп ятадыр...

— Бүген? Хәзерме? Әһә, тизрәк кайтып китсен дә, иркенләп калырмын дисеңме?

— Нәрсә син?— диде Сәгыйть, хәтере калып.— Без монда синең белән гүләйт итеп йөрибез, ул анда...

— Кума, кума!— диде кыз, ачуланып, үпкәләп.

Аннан соң кинәт көлеп җибәрде дә, яратып, йомшак бармаклары белән аның кул аркасын сыйпарга кереште.

— Булмый шул, Сәгыйть,— диде ул инде бөтенләй җитди, күңелсез тавыш белән.— Мин инде барысын да белештем. Бүген пароход юк, иртәгә иртән генә була.

— Ну, алайса...

— Әйдә ул турыда бүген... бөтенләй сөйләшмибез. Синең янда хәзер минем бер дә борын салындырып йөрисе килми. Безгә бер генә көн... ярты гына көн калды. Аннан соң ике ай буена аерылышып торырга... Ике ай! Саргаеп үләрсең! Әнием турында бүгенгә онытыйк, яме? Искә төшермәсәң дә, ужасно кыен... Аның йөрәге бик начар. Ике мәртәбә үлгәндә чак калды. Мин инде иртәннән бирле нишләргә белмим... «Отлично» алгач, онытылып торганые...

— Була! Онытабыз!— диде Сәгыйть.— Соңыннан да... аерылышкач та күңелсезләнергә өлгерербез әле.

Алар Бауман урамына төштеләр, китап магазинына керделәр. Букинистик бүлектә яхшы итеп тышланган, бөтенләй диярлек тотылмаган «Анна Каренина» бар иде. Ида кассага барып акча түләп килде, алар китапны алдылар да, ашарга дип ашханәгә киттеләр.

Ашханәдә кеше бик күп иде. Биленә ап-ак кыска алъяпкыч бәйләгән официантка бик әкрен кыймылдады. Ул заказ алганчы озак кына көтеп утырырга туры килде. Алар менюдагы иң кыйбатлы ашларны гына алдылар.

Ида, Кабан күленә көймәдә йөрергә барганчы, башта торакка кайтып, өс киемнәрен алмаштырмакчы булды. Ашханәдән чыккач алар, әкрен генә атлап, Идаларга киттеләр.

Бүлмәдә өстәл янында китап укып утыручы бер кыз-

дан башка бүтән беркем дә юк иде. Сәгыйть кыз белән исәнләште дә, Ида артыннан түргә узды.

— Безнең бүлмә җыештырылмаган, син инде карап торма,— диде Ида, үзенең чиста ак җәймә ябылган кабарынкы койкасына утырып.

Сәгыйть бу бүлмәдә еш кына була торган иде, һәм мондагы җыйнаклык, чисталык аның күңелендә һәрвакыт гаҗәп бер җылылык тудыра торган иде. Монда бөтен нәрсә үз урынында, бөтен нәрсә матур, искиткеч булып, ә тегендә, үзләренең бүлмәсендә, бөтен нәрсә ташландык, ямьсез һәм котсыз булып тоела торган иде. Монда тумбочка өстенә куелган хушбуй, пудра савытлары гына түгел, хәтта өстәл, урындыклар да, тәрәзә кашагалары да, хәтта һава үзе дә нindидер якын ис, җиңел, серле ис аңкыта шикелле иде.

Сәгыйть бүлмәгә игътибар беләнрәк күз йөртеп чыкты һәм бүген монда аңа чынлап та бүтән вакыттагы кебек үк пөхтәлек, җыйнаклык юк кебек күренде. Кызларның берничәсе кайтып киткән, бүтәннәре дә шулай ук юлга чыгарга әзерләнеп кенә торалар иде бугай. Ида «почмагындагы» посташлык бигрәк тә күзгә нык ташланып тора иде. Кабартып куелган мендәрнең бер почмагы яньчелгән, шунда ук бите ачык бер китап аунап ята, идәндә, койка астында, тышына аш катып беткән, юылмаган кәстрүл утыра иде. Тумбочка өстендә дә гадәттәге тәртип күренми иде.

Ида, Сәгыйтьнең күз карашын сизеп алды да, кәстрүлне аягы белән эчкәрәк этеп куйды.

— Инде айдан бирле бернигә кул бармый... кайтып китәсе булгач,— диде ул, җиңелчә кызарып, һәм артка табарак авыша төште дә, башын мендәргә терәп, күзләрен йомды.

— Син нәрсә, әллә йокламакчы буласыңмы?

— Йокы килә... ашагач...— диде Ида.— Мин йоклыйм, син саклап тор.

Өстәл кырыендагы кыз, китабын алып, шкаф артына, үз койкасына барып утыргач, Сәгыйть, урындыгын Ида янынарак китерде дә, пышылдап кына:

— Мин гомергә шушы бүлмәдә торыем...— диде,— синең белән генә, әлбәттә...

Иданың озын керфекләре сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп китте, күз кабаклары әкрен генә өскә күтәрелде, һәм, ул күзләрен зур ачып, берни аңлатмый торган тыныч караш белән Сәгыйтькә карап тора башлады. Аның бит очларына оялчан алсулык йөгерде. Ул, үзенең килешсез бер рәвештә ятып торуына уңайсызланып, тиз генә башын калкытты да, янбашына әйләнеп, терсәгенә таянды.

— Смотри-ка, нишләмәкче була икән!— диде ул, күзләрен кысып.— Мин сине барыбер куалап чыгарыыем...

— Ни өчен?

— Тик. Юри.

— Укып бетергәч, эшкә башлагач, безнең шушындый гына, бәләкәй генә, җыйнак кына бүлмәбез булыр, әйеме?— диде Сәгыйть, хыялга бирелеп.

— Бер генәме?— диде Ида, күзләрен зур ачып.

— Нигә — җитмәгәнмени?

— Минем берүземә бер бүлмә кирәк.

— Укып бетергәч без кая китәрбез?— диде Сәгыйть, «без» сүзенә аеруча басым ясап.

Алар арасында инде күптән «без» турында сүз булган һәм бу «без» соңгы вакытта бигрәк тә еш телгә алына башлаган иде.

— Мин әйттем инде, мин Камчаткага китәм. Сине алмыйм,— диде кыз, шаянланып.

— Юк, без тайгага, калын урман эчендәге берәр яңа шәһәргә китәрбез,— диде Сәгыйть, аның «без»гә юри каршы килеп, үртәшеп утыруына игътибар итмәскә тырышып.

— Тайгага? Аюлар арасынамы?! Ах, ужасно шәп булачак! Син аюга атланырсың да минем янга Камчаткага килерсең, мин сине тәрәзәдән карап торырмын! Ха-ха!..

— Нигә аюга атланып?— диде Сәгыйть, аның хыялны кирәкмәгән якка борып җибәрүен бик үк ошатмыйча.— Эшли башлагач, без «Победа» алырбыз... ну, «Победа» булмасын, «Москвич»ы да ярап торыр...

— Минем берүземә бер «Москвич» булыр! Без узышырбыз да, син җылгага батып калырсың, җә тайгада адашырсың...

Сәгыйть «җылга» сүзен ишеткәч тә, шундук сикереп торды.

— Нишләп утырабыз әле без монда?— диде ул.— Әйдә Кабанга!

— Торгыз!— диде Ида, кулын сузып. Торып утыргач, ишеккә төртеп күрсәтте дә, ясалма боеручан тонда: — Ну-ка, марш бүлмәдән!— диде.— Мин эндәшмичә кермә, колагыңны борырмын... ярар, мин үзем чыгармын...

Сәгыйть аны коридорда көтеп торды.

Ида, эшләпә астындагы чәч толымнарын ике куллап рәтли-рәтли, ашыгып килеп чыкты. Ул өстенә бизәкле гади кофтасын, киң итәкле көрән юбкасын, ә аякларына җиңел, нәфис чүәкләрен кигән иде.

— Болай син бигрәк тә матур!— диде Сәгыйть, аңа карап, соклануын яшерә алмыйча.

Ида, моңа бик кәефе килеп, үзенә генә хас шаянлану, иркәләнү сизелеп торган яңгыравык тавыш белән көлеп җибәрде.

— Мин сиңа мең кат гашыйк булырга әзер!— диде Сәгыйть.

— Әһә, син әле гашыйк түгелмени? Болай гына сөйләнеп йөрисеңмени?!

— Чынлап... син хәзер королеваларга охшыйсың.

— Смотри-ка, минем аркада король булырые бугай!

— Нигә — синең янда мин әле дә король!

— Синме?.. Син король генә түгел... син — Сәгыйть, минем Сәгыйть!

Алар шулай телләренә ни килә, шуны сөйләнеп, берберсенең якынлыгыннан исереп, бер дә юкка көлешә-көлешә, киң тротуар буенча бардылар. Бүген көн шундый якты, шундый җылы иде, шәһәр шундый матур иде һәм кешеләр барысы да елмая, барысы да нигәдер куана, каядыр ашыга иде.

«Нинди күңелле бу дөнья!»— диде Сәгыйть, тәэсирләнеп.

Ләкин күл буендагы «Спартак» су станциясенә килеп җиткәч, дөньяның яме кинәт сүрелгәндәй булды. Буш көймәләр юк иде һәм чират җиткәнен бик зур сабырлык белән көтеп, касса алдында егермеләп-утызлап кеше басып тора иде. Көймәләр бушаганны көтәргә булсаң, чиратта кимендә бер-ике сәгать торырга туры киләчәк иде.

Иданың кәефе кырылды, Сәгыйтьнең ачуы килде. Ул, эше юктан китап укып утырган кассир кызга: «Безобразие!»— дип тә, «Нигә алай?»— дип тә карады, ләкин барыбер бернинди рәт чыкмады. Кыз, ичмасам, күтәрелеп тә карамады. «Чиратыгызны көтегез, гражданин»,— диде дә тәрәзәсен шапылдатып ябып та куйды.

Чиратта көтеп торасылары килмәде. Болак күпере аша чыктылар да, Кабан күленең икенче як ярындагы «Динамо» станциясенә киттеләр. Ләкин монда чират тагын да зуррак булып чыкты. Сәгыйтькә бүген бөтен шәһәр, юри аларга үч итеп, көймәдә йөрергә чыккандыр шикелле тоелды.

— Менә сиңа кирәк булса! Нишлибез?— диде ул.

— Нишлисең, чиратка басарга туры килә,— диде Ида, теләр-теләмәс кенә.

Алар ал погонлы бер суворовчы малай артыннан чират алдылар да яр буена таба китеп бардылар.

Күл тирәсе чыр-чу килә. Кая карама кояшта янган кара-кучкыл тәнле җитез егетләр, кызлар, бала-чагалар. Йөзәләр, чумалар, су чәчрәтәләр, кычкыралар. Күл

эченәрәк кертеп ясалган биек вышкадан суга сикерәләр, кисеп аударылган кебек кисәк кенә ычкынып китәләр дә түбән сузылган куллары белән яшькелт Кабан өстенә барып кадалалар. Яр буена көймәләр килеп туктый, кулларына ишкәкләр күтәреп, такта басмалардан аска егетләр, малайлар йөгерә. Бөтенләй дип әйтерлек шәрә яшүсмерләр, беләкләрен иренеп кенә селти-селти, өсләреннән су тамчылары тамызып, әледән-әле судан чыгалар, яр читендәге скамьяларга утыралар, шапылдатып бер-беренең тәннәренә сугалар, шаяралар. Яшь кызлар, агач аяклы бер агай, студентлар, зәңгәр күлмәкле фзөчеләр, цирк тамашасы караган кебек, онытылып, су керүчеләрне, еракта кыймылдашкан көймәләрне күзәтәләр. Күлгә Болак килеп кушылган турыда малайлар, ачы чыелдап, кычкырып, кап-кара бер зур этне суда йөздерәләр. Һавага кычкырыш, чыр-чу белән, чәчрәгән су тамчылары белән бергә яшьлек дәрте, көч, энергия тарала иде кебек.

— Без көймәдә йөргәнче кич булыр...— диде Ида, күңелсезләнеп.

— Әйдә, без дә су керәбез,— диде Сәгыйть.

Ида икеләнде, тиз генә җавап бирмәде.

Алар каршысына чуен китеге кебек карайган, кояшта янган битле, бөкрерәк бер озын ир кеше килеп туктады.

— Көймә кирәкме?— диде ул, әле Сәгыйтькә, әле Идага карап, гыжылдавык тавыш белән.

— Кирәк.

— Миндә бар. Сәгате ун сум.

Бу кешенең кыяфәте бик шикле, бик оятсыз күренсә дә, кассада сатыла торган билет хакы ун сумнан ике-өч өлеш очсызрак булса да, Сәгыйтьнең күңеле күтәрелеп китте, ләкин шулай да ул тиз генә җавап бирмәде.

— Кайда көймәгез? Әйдә, Сәгыйть! Ах!..— диде Ида, куанып.

— Паспыртыгыз бармы?— диде кеше.— Булмаса, берәр дакумит калдырырга туры килер.

Ида кабаланып сумкасын актарырга тотынды. Зачет кенәгәсеннән башка берни юк иде.

— Менә!— диде ул, зачеткасын кара кешегә сузып.

Алар өчәүләшеп яр астына төшеп киттеләр. Сәгыйть көймә хуҗасына ун сум тоттырды.

Көймә, су станциясендәге бүтән көймәләр кебек үк, зәңгәргә буялган, номерланган иде. Сәгыйть көймәгә утырса да утырды, утырмаса да утырды. Ул берни турында да уйламаска тырышты. Ишкәк башларын суга чумырып бер киерелгәч, ялыккан, тик торып арыган беләк

мускуллары, бөтен тәне буенча куңелле бер рәхәтлек йөгергәч, юк-бар нәрсә онытылып, артта, яр читендә, торып калды.

Ида каршыга утырды. Сәгыйть, ишкәк белән су каерудан тансык бер ләззәт табып, дәртләнеп-җилкенеп иште. Ишкәкләр, тыгыз суны көрәп югары күтәрелгән саен, су өстенә, шыбыр-шыбыр килеп, көмеш борчаклар сыман, тамчылар коелды; такта бортларга тиеп аста әкрен генә су чайпалды. Кичке кояш нурында җемелдәп яткан тигез күл өстеннән көймә җиңел генә алга шуышты. Күлмәк итәкләрен балтырларыннан югары күтәреп куйган көе, яртылай бөгелеп, яр читендә кер чайкаучы хатыннар, су керүчеләр, тузан кунган яшел бакчалар, кызыл түбәле, ак морҗалы таш йортлар һаман ераклаша барды. Болак күпереннән тыз-быз үтеп торган трамвай, автомашина тавышлары, шәһәр гөрелтесе һаман тоныклана барды. Көймә, үз юлында бернинди каршылыкка очрамыйча, як-якка тирбәлеп һаман алга омтылды.

Кызу ишкәнгә Сәгыйтьнең битләре кызарды.

— Бир, мин ишим,— диде Ида.

Алар урыннарын алмашып утырдылар. Ида ике куллап ишкәкләргә тотынды да, Сәгыйть кебек каерып ишмәкче булып, бар көченә селтәнергә тотынды. Ләкин берни дә барып чыкмады — авыр ишкәкләрне бер-ике мәртәбә күтәргәч тә, аның беләге арый башлады. Ишкәк очы, тирәнгә батмыйча, су өстеннән генә ерттырды. Тирәякка су чәчрәде, көймә алга да, артка да китә алмыйча һаман бер урында таптанды. Сәгыйтьнең өсте чыланып бетте.

— Ныграк батыр! Суга батыр ишкәгеңне!— дип кычкырды ул, куллары белән Идага ничек ишәргә кирәген аңлатып.

Кыз аның саен су чәчрәтте, аның саен көймәне чайкалдырды, эче катып көлде. Аңа кушылып Сәгыйть тә көләргә тотынды, көймә читенә үрелде дә, учы белән җылымса су алып, аның өстенә сипте. Аларның өс-башлары манма су булып бетте.

— Уф-ф!— диде Ида, ишкәген кулыннан ычкындырып.— Җитте!.. Мир!.. Арытты...

Сәгыйть яңадан ишкәк янына утырды, көймә тагын тыныч су өстеннән алга шуышты. Көтмәгәндә күл тарая башлады, яр буендагы йортлар, йөзәр еллык биек тирәкләр зурайгандай, якынайгандай булды. Алар озын агач күпер астыннан чыктылар — Кабан бөтенләй елга кебек кенә булып калды. Сәгыйть һаман иште. Ида үзенең бала чагы турында кызык нәрсәләр сөйләде.

— Бервакытны укырга бармадым. Ышанмыйсыңмы? Бармадым. Бәләкәй генә ием әле мин ул вакытта. Ужасно бәләкәй! Әнә теге яр буенда чирәм йолкып йөргән кызый кебек кенә. Икенче көнне әнием әйтә, укытучы апаң, нигә килмәдең, дип сорады исә, бизгәк тотты, дип әйт, ди. «Нигә килмәдең, Мәхмүтова?»— ди укытучы. Бастым да: «Мин, апа, кичә бизгәк тоттым»,— дим. Менә бөтен класс көлә, ха-ха да ха-ха!.. «Ничек тоталар соң аны, бизгәкне?— ди укытучы,— икенче килгәндә әниеңнән сорап кил»— ди.

— Бик шәп бизгәк тоткан сине! Әниең ни диде инде?

— Көлде. И, кызым-кызым, ди, әзрәк алдаша да белмисең, шундук тотылгансың, ди...

Малай чакларын искә төшереп, аннан соң Сәгыйть сөйләде. Алар тагын көлделәр. Моның өчен ул истәлекләрнең, ул «кызык нәрсәләр»нең бик үк тапкыр, бик үк мәзәк булуы да кирәкмәде, моның өчен аларга бер-берсенең шатлык-куаныч белдергән күзләренә, саф һавада алсуланган бәхетле йөзләренә карау да җитте. Алар вакытның ничек үткәнен дә сизмәделәр.

Су өстендә тирбәлгән алтын таплар тиздән эреп беттеләр, каядыр юк булдылар, шәрә беләкләрне, ачык муеннарны кичке салкынлык сыйпады. Сәгыйть көймәне киргә борды.

Көймә борыны белән ярга килеп төртелгәч тә, Ида, кинәт исенә килеп, көмеш беләзекле сәгатенә күз төшереп алды.

— О-о! Счастливые часов не наблюдают, ди. Ике сәгатькә якын йөргәнбез ләбаса!

Аларның колак төбендә генә таныш, гыжылдавык тавыш ишетелеп китте:

— Дөрес, сездән тагын ун сум.

Икесе дә шундук башларын күтәреп карадылар: яр читендә, бер кулы белән биленә таянып, көймә хуҗасы басып тора иде.

— Ун сум?— диде Сәгыйть.

— Әйе. Ун сум.

Студент егетнең кесәсендә бер тиен дә акча юк, ул бая соңгы ун сумын чыгарып биргән иде. Аның чырае сытылып китте. Аның шушы оятсыз кешене сүгеп, әйләнеп тә карамыйча, китеп барасы килде, ләкин ул үзе генә түгел иде, моның шулай икәнен бу кеше дә бик яхшы күреп тора иде. Шуңа күрә дә ул, болар уңайсызланырлар, каршы килә алмаслар, дип, үз-үзен шундый оятсыз-кыю тота иде. Сәгыйть ут белән су арасында калган кебек булды. Кызың белән көймәдә йөре дә, түләргә акчаң да булмасын, имеш! Менә кайда икән ул кызык!

Бу жуликтан бернинди өмет көтәрлек түгел, «Акча юк»,— дидең исә тавыш куптарыр, бөтен кеше алдында сине тиргәргә, әшәке сүзләр белән кычкырынырга тотыныр, җитмәсә, Иданың зачеткасын алып калыр.

Сәгыйть, көймәчегә берни җавап бирмичә, ярга сикерде.

— Кая зачетка?— диде Ида, тыныч кына.

— Булыр, булыр — менә ул,— диде көймә хуҗасы.— Давай чыгар унлыгыңны.

— Хәзер,— диде Ида, сумкасыннан акча эзләргә тотынып, һәм унлык көтеп торган көймәченең кулыннан зачет кенәгәсен тартып алды да шундук урыныннан кузгалып китте.— Йөзлек кенә икән, әйдә, кассада ваклыйбыз...

Көймәче, авыз эченнән нидер мыгырдый-мыгырдый, алар артыннан иярде.

Урам якка чыгып, касса авызы янына килгәч, Ида кинәт туктады да, кара битле кешегә усал күз карашы ташлап:

— Сезгә ун сумы да җиткән! Йөрмәгез арттан!— диде.— Или мин сезне милициягә әйтермен...

Мондый көтелмәгән җавапка аптырап калган көймәче авызын ачарга да өлгермәде, Ида Сәгыйтьне култыклап алды, һәм алар, берни булмаган кебек башларын югары тотып, китеп тә бардылар. Көймәче сүгенергә тотынды, шулай да студентлар артыннан куарга батырчылык итмәде.

Сәгыйтьнең исе китте. Менә сиңа Ида! Менә сиңа шайтан кыз! Нинди оста итеп төп башына утыртты жуликны! Котылды... ләкин аның алдында үзенең җебегәнлеген күрсәтте.

Сәгыйть ни өчендер үзенең кызарганын сизде.

Бераз җир киткәч, Ида артына борылды да, көймәчегә булган ачуын чыгарып:

— Тот — тагын ун сум!— диде.— Вот нахал, күзен дә чытмый! Шундый жуликларның барысын да Кабанга гына батырып бетерәсе бар!

## IV

Икенче көнне иртәннән башлап суык җил иste, кояш әз генә күренеп алды да, күк йөзен Идел ягыннан шуышып, агылып торган соргылт, ертык болытлар каплады. Кискен көчле җил тротуар читләрендәге, йорт буйларындагы ташландык кәгазьләрне, чүп-чарны очыртып йөрде, агач башларын тарткалады, яшь яфракларны өзгәләде. Урамнарда бертуктаусыз коры тузан, ком өермәсе бөтерелде.

Сәгыйть Идалар торагына иртүк килеп җитте. Ида да гадәттәгегә караганда иртәрәк торган, юлга аласы бөтен

нәрсәсен әзерләп куйган иде. Алар, бүлмәдә артык тоткарланып тормыйча, пристаньга төшеп киттеләр.

Билет бик җиңел алынды. Әле пароход килеп тә җитмәгән иде. Алар ачык калдырылган тар капка аша Идел ярына чыктылар.

Вакытсыз уятуларына ачуы килгән шикелле күренгән, ямьсезләнгән елга шашынып ургылды, кайнады. Авыр, кара дулкыннар, шаулаша-шаулаша, үзара мыгырдаша-мыгырдаша, ярга таба йөгереп килделәр дә, ак чуер ташлар, ташландык агач кисәкләре, тутыккан чылбыр, якорьлар өстенә килеп егылдылар, бераз гына хәл җыеп яткач, тагын юаш кына, ипләп кенә кире шуыштылар, нидер пышылдаштылар, чыжылдаштылар. Авыр, юан чылбырлар белән яр кырыена тартылып куелган дебаркадер як-якка әүмәкләнде, түгәрәк тәрәзәле кыска катерлар, дегеткә буялган кара, җәенке көймәләр чайкалды, баш өстендә эчне пошырып телефон чыбыклары сызгырды. Нindidер болганчык, салкын элпә белән капланган Идел аръягыннан һаман соргылт, ямьсез болытлар агылды, җәй көне булганга бигрәк тә күңелгә нык тия торган бәйләнчек ачы җил исте.

Иданың дыңгычлап тутырылган чемоданы ватылырлык түгел иде — алар икесе дә шуның өстенә утырдылар да, котырынган, төбеннән кузгатылган Иделгә карап, тынсыз калдылар. Бөтенләй көтмәгәндә, бөтенләй кисәк кенә булды бу аерылышу.

Ида костюм якасын күтәреп куйды, әледән-әле җил ачкан күлмәк итәкләрен төзәткәләде. Көн начар булганга, Идел буенда алардан башка бүтән беркем дә юк иде. Сәгыйть, кабыргасы белән җилне каплап, кызны биленнән кочаклап алды.

— Шулай итеп, китәсең...— диде ул, беравык сүзсез утырганнан соң.

— Да-а, аерылышабыз...— диде Ида, күңелсез генә һәм, олы кеше куенында җылы эзләгән бала кебек, Сәгыйтькә якынрак елышты.

Тагын сүзсез калдылар. Аста чуерташларга дулкыннар килеп бәрелде, телефон чыбыклары сызгырды. Сөйлисе сүз шундый күп иде, күңел чишмәсе шундый тулы иде, ләкин ни генә сөйләсәң дә, барыбер йөрәктәге тулысынча аңлатып булмас, нинди генә сүз әйтсәң дә, барыбер мәгънәсез, көчсез чыгар шикелле тоелды. Күңелсез тынлыкны бетермәкче булып, Ида көлдерергә тырышып карады, бүлмәдәш кызлары турында, тагын нәрсәдер турында сөйләде, ләкин көләсе дә, хәзер менә аерылышуга кагылышсыз нинди дә булса бүтән нәрсәне тыңлыйсы да, ишетәсе дә килмәде.

— Хат яз, кара аны...— диде Сәгыйть, инде кырыкмаса-кырык мәртәбә әйтелгән нәрсәне тагын исенә төшереп.

— Сәгыйть!— диде Ида, ничектер бераз тантана һәм шул ук вакытта иркәләнү сизелеп торган тавыш белән. Ул аның җил полтыраткан чәчләрен артка яткырып куйды.— Сәгыйть, әйдә көн дә язабыз! Иртәгәдән башлап!.. Колхозга эшкә барып төшкәч тә, син миңа язасың, мин үзебезгә кайткач, сиңа язам, сезнең авылга... Буламы? Вот шәп булачак! Беренче хатыңны син самолет белән җибәр. Пароход белән кайтып төшүгә, өйдә мине синең хат көтеп торыр! Вот шәп булачак!..

Сәгыйть җанлана төште.

— Мине үзебезнең авылга кайтуга синең хат көтеп торыр — шулаймы? Була! Әйдә шулай итәбез!..

— Только, смотри, иртәгә үк язасың, миннән алда барып җитсен, кара аны!

— Син дә шулай ук!

— Ах, Сәгыйть, миңа синсез нинди күңелсез булачак!.. Ә син, смотри, анда, буа буган җирдә, кызлар белән йөри күрмә... Мусялар белән... көз көне килгәч колагыңны борырмын!

Сәгыйть күңелсез генә елмаеп куйды. Ул үзенең ирене турысына якын килгән чәч бөртекләрен үбеп алды.

...Пароход борылма артына кереп күздән югалганчы, Сәгыйть яр буенда басып карап торды. Идел ягыннан авыр, ямьсез болытлар агылды, үзәкләргә үтеп, суык, күңелсез җил исте, бөтен тирә-як төссезләнеп, шыксызланып калды. Әйтерсең аның күкрәгеннән тормыш өчен, яшәү өчен иң кирәкле, иң кадерле нәрсәсен суырып алдылар. Әйтерсең ул аны пароходка утыртып озатмады — шаулаган, котырынган шушы Идел төбенә төшереп җибәрде, һәм аны аннан алырга, аны кире кайтарырга хәзер дөньяда бернинди әмәл дә, бернинди көч тә юк иде. Аларның әле беркайчан да бер-берсеннән аерылышып торганнары булмады, һәм шушы минуттан соң ул үзе өчен аның никадәр якын икәнен, хәзер инде аннан башка яши алмаячагын бөтен тулылыгы белән, бөтен ачыклыгы белән аңлады.

Сәгыйть, башын түбән игән көе, күрмәс күзләре белән үзалдына текәлеп, күңеле белән ераклаша барган пароходтан әле һаман аерыла алмыйча, әкрен генә кузгалып китте. Аяклары аңа, икешәр потлы гер таккан кебек, коточкыч авыр булып тоелды. Көн тагын да ныграк ямьсезләнде, һавада, бөтен нәрсәне каплап, тузан бөтерелде, күзгә ком тулды һәм, эчне пошырып, күңелләрне игәп, телефон чыбыклары сызгырды, агач башлары чайкалды.

Төштән соң ул иптәшләре белән колхозга китте.

## Икенче бүлек

### I

Авыл юлы.

Ике ягында да каты, кыска үләннәр, әремнәр үскән басу юлы. Кыш көннәрендә аны калын ак кар каплап китә, аның өстеннән кар-бураннар себереп, бозлы җилләр исә, салам салган туң табанлы чаналар йөгертеп уза, ә яз җитеп, кар сулары агып беткәч, җылы кояш нурына кызынып, кибенеп, ул тагын да ачыла, чистара һәм аның коры, такыр күкрәген аяк табаннары, ат тояклары, автомашина, арба тәгәрмәчләре таптый башлый.

Авыл юлы.

Очсыз-кырыйсыз юл. Таш та түшәлмәгән, тигез итеп асфальт та җәелмәгән, читләренә тезеп агач та утыртылмаган. Кайда уңай урын бар, шуннан үзенә эз салып, әрәмә-урманнар, тигезле-тигезсез басулар, чокыр-чакырлар аша үтеп, елгалар, таулар кичеп бара да бара. Кемнәр генә узмаган аннан, кемгә генә дус-иптәш, тавыш-тынсыз сердәш булмаган ул! Кемне генә кая гына алып бармаган ул!

Кайчандыр шушы тузанлы, бормалы-сырмалы тар гына юл авыл малаен киң, олы юлга алып чыкты, яшелгә буялган тимер вагонга утыртып, күз күрмәгән ерак җирләргә, шаулап торган зур шәһәргә озатты.

Менә хәзер ул, чит җирләрне күргән, үскән, олыгайган егет яңадан таныш, ышанычлы юлдан туган авылына кайтып бара...

Шәһәр урамнарын таптап үкчәсе ашалып беткән брезент туфлиен салып кулына тоткан, чалбар балакларын балтырына кадәр сызганып куйган. Озын чәчләрен әкрен генә искән җил тирбәтә. Артта, йомшак калын тузан өстендә, бишәр бармаклы тирән табан эзләре батып кала.

Туган җир, туган басулар...

Бара торгач кинәт кенә туктый да, йә артына борылып үзенең аяк эзләренә карый, йә кулларын маңгаена куеп кемнедер, нәрсәнедер күрергә теләгән сыман, еракларга күзен текәп күзәтә башлый.

Туган җир, туган басулар...

Никадәр якын, никадәр таныш аңа монда бар нәрсә! Туган җир, туган юл, туган күк йөзе...

Арыш әле ямь-яшел. Яңа эч керә башлаган. Сөт кебек. Камылга биек. Күкрәктән уза. Кызу кояш нурына коенып яткан киң арыш басулары, яшькелт диңгез кебек дулкынлана, тирбәлә-чайкала. Кылчыклы башаклар,

бер-берсенә тиеп шыштырдашалар, пышылдашалар. Борынга әчкелтем төтен исе, чыршы ылысы исе, бал исе килеп бәреләә.

Һәм аның бөтен күңелен, бөтен тәнен биләп алган исерткеч хистән, ачы да, татлы да булган дәртле бер хистән нидер җырлыйсы, ерак-ерак басуларга кадәр, күк читеннән югарыга калкып торган зәңгәрсу тауларга кадәр ишетелерлек итеп нидер кычкырасы килә.

Туган як, туган басулар...

Ул һәрвакыт, кайда да булса берәр җирдә йөреп, яңадан үзләре авылына кайтканда үзенең хисләре яңарганын, күңеле нечкәргәнен сизә торган иде, туган авылында аны кемдер бик сагынып көтеп торадыр, анда хәзер бөтен нәрсә искитәрлек булып үзгәргәндер шикелле тоела торган иде. Ләкин аның әле беркайчан да үзләре авылына бу кадәр дәртләнеп, бу кадәр ашкынып кайтканы юк иде бугай, әле беркайчан да туган йортын бу кадәр зарыгып, үләрдәй булып сагынганы юк иде бугай. Моңарчы бервакытта да булмаган ниндидер яңа хис, йөрәкнең яңача җилкенүе аңа һәр елны шулай чайкалып утырган арыш басуларын да, алтын кояш нуры белән сугарылган, чикерткәләр, бал кортлары тавышыннан чыңлап-зыңлап торган эссе һаваны да, гаҗәеп биек зәңгәр күк йөзен дә — күрергә, ишетергә, тоярга мөмкин булган барлык нәрсәне тагын да гүзәлрәк, тагын да мәгънәлерәк, әһәмиятлерәк итеп күрсәтә иде.

Аерылышканга хәзер сигез көн. Сигезенче көн... Баштарак ансыз сигез көн түгел, сигез сәгать тә торып булмас шикелле тоелган иде. Ул чын-чынлап, бу кадәр кайгыга мин акылдан язармын, ахры, дип уйлаган иде. Ләкин хәтта сөйгән кызыңнан аерылгач та акылдан язмый калырга була икән. Иптәшләре белән гел бергә булу, гел бергә эшләү, авылның тыныч һавасы акылсыз йөрәкне бераз баса төште, Ида турындагы тынгысыз, сагышлы уйны — юк, онытырга түгел!— вакытлыча истән чыгарып торырга ярдәм итте. Инде эштән бушап, туган авылына кайтырга чыккач, беркайчан да күңелдән китми торган бу көчле уй аны яңадан үз кулына алды, ләкин хәзер инде ул баштагы кебек аңлашылмаган ниндидер газап та, сәбәпсез сагыш та тудырмады, киресенчә, аны күкләргә ашырды, йөрәгендә яшерен ләззәт, шатлыклы өмет ялкыны дөрләтеп җибәрде.

Әйе, ул бүген аның белән сөйләшәчәк. Бүген сигезенче көн. Сигез хат! Юк, сигез үк түгел — нишләптер алай бик күпкә китә,— алты... биш хат булсын. Җиткән! Ул үзе дүрт хат язды. Дөрес, күп түгел, аныкыннан әзрәк.

Үпкәләр микән? Юк, үпкәләмәс, ул бит анда, колхозда, вакытның тыгыз икәнен белә. Менә хәзер кайткач аның вакыты күп булачак, ул аңа көненә берне генә түгел, икене язачак. Әйе, икешәрне язачак, аның дүрттән арткан хатлары өчен дә язачак. Алты... биш хат...Ниләр генә юктыр анда!

Сәгыйтьләренә көн дә хат килә башлагач, өйдәгеләр нишләргә дә белмәгәннәрдер, гаҗәпкә калганнардыр инде. Почтальон китереп биргәч тә, әнкәсе хатны кулына алгандыр да, алай иткәндер, болай иткәндер, кемнән микән, дип баш ваткандыр, ярар, үзе кайткач бирермен әле, дигәндер дә, берәр иске китап эченә кыстырып куйгандыр. Икенче көнне почтальон тагын килгәндер, әнкәсе, почтальонны каршылап, Сәгыйтьтәнме? дигәндер, ә тегесе әйткәндер, юк, Миңнисәттәй, Сәгыйтькә, дигәндер. Ай Алла, дигәндер әнкәсе, көн саен хат яза торган нинди кеше булды соң ул? дигәндер. Почтальон, серле генә елмаеп, һей, Миңнисәттәй, дигәндер, җегет кешегә кем язсын соң — кызлар яза! дигәндер. Анысын да алгандыр да әнкәсе тегесе янына салып куйгандыр. Өченче көнне тагын килгәндер... Әгәр Барислар өйдә чакта китерсәләр?— Да-а... Ачарлар да укырлар.

Сәгыйтьнең тәне эсселе-суыклы булып китте. «Тизрәк кайтып җитәргә кирәк!»— диде ул, куркып. Әйе, укысалар, оятыңнан кая керер тишек тапмассың!.. Укысалар соң? Укысалар? Кем курка алардан! Малаймы соң әллә ул! Барислардан куркыр күлмәк күптән тузган инде... Юк, курыкмассың, шулай да уңайсыз булыр. Ашыгырга кирәк...

Юл түбәнгә таба авышты. Күп тә үтмәде — ике ягыннан да тигез, киң кырлар сузылып киткән үзәнлек төбенә таралып утырган зур авыл күренде, елга буендагы карт таллар, очлы башлы, текә сыртлы такта түбәләр, киртә баганалары күренде.

«Исәнме, Янтык!»— диде Сәгыйть, үзалдына елмаеп.

## II

Урам яктан ике тәрәзәле, ян-яктан ике тәрәзәле, түбәсе уртадан сыгылып төшкән, кайбер бүрәнәләре череп куышланган, бераз гына алга сөрлеккән, бераз гына читкә янтайган, тәбәнәк кенә, иске генә йорт — инде зур булып җиткән студентның бала вакытындагы кечкенә серләрен дә, үпкә-кайгыларын да, шатлык-куанычларын да, өмет-омтылышларын да белә, күрә килгән туган йорт үзенең якын дусына ерактан ук сөенеп елмайды.

Әйтерсең берни дә үзгәрмәгән, әйтерсең бөтен нәрсә шул көе иде. Элеккегә караганда бары тик һава гына тагын да тынычрак, тагын да чистарак иде бугай, бары тик урамда йортлар арасында яктылык һәм кояш нуры гына тагын да күбрәк иде бугай, аннан соң... өйләр генә бераз тәбәнәкләнеп калганнар, искергәннәр иде бугай.

Юк, нишләп берни дә үзгәрмәсен! Һәрбер йорт алдына килеп баскан озын, яңа баганалар нәрсә ул?! Зәңгәр күктә кояш нурларын чагылдырып җемелдәшкән, дерелдәшкән корыч чыбыклар, тәрәзә түбәләре янына парлы ак күгәрченнәр шикелле килеп кунган телефон тәтәйләре нәрсә ул?! Электр ич! Электр шул. Май бәйрәме алдыннан электр кертәләр, дип язганнар иде ич. Ул чакта аның моңа әллә ни исе китмәгән иде, күрмәгән, белмәгән электр түгел, дигән иде. Кара син аны, күргән, белгән электр булса да, монда, үз авылыңда, ул бөтенләй икенче төрле икән.

Сәгыйть, күзен тәрәзәдән алмыйча, елмая-елмая шыгырдавык капканы каерып ачты да, ишегалдына керде, аннары ишеккә килде. Ләкин ишектә моңаеп асылынып торган зур йозакны күргәч, кинәт туктап калды.

— Менә сиңа, торалар икән көтеп!— диде, үзе дә сизмәстән, ишеттерерлек итеп.

Һәм ул аптыраган кыяфәт белән бераз урынында басып торды да, кулындагы чемоданын җиргә куйды, туфлиләрен баскыч өстенә ташлады. Шуннан соң, җиңеләеп калып, сап-сары итеп юылган, такталары шомарып, агарып беткән, уттай кызу баскычка килеп утырды.

Кая булып беттеләр икән соң болар? Барис белән Гамбәр басуда, тракторлар янындадыр инде, йә МТСта ремонтта яталардыр. Ләкин алардан башка тагын өйдә әнкәсе булырга тиеш бит. Ярар, кайтырлар әле, әллә кая китмәгәннәрдер...

Болындагы кебек бал кортлары безелдәшә, чикерткәләр сайрый, үзе шундый тын, шундый әйбәт... Киртәгә чыпчыклар килеп кунды, чыр-чу килеп, үзара нидер кычкырыштылар да пырылдап очып та киттеләр — кем кайткан бу, дип гаҗәпләнделәр микән инде үзләренчә. Чыпчыклар артыннан алакола саескан килеп җитте, башын якякка боргалап шыгырдады, шыгырдады да, түбәннән генә очып, каядыр китеп югалды. Лапас буена әлерәк кенә киселгән бүрәнәләр өеп куйганнар. Кайберсенең әле кайрысы да каезланмаган. Ак чыршының җептән юнылган ботак урыннарыннан тамчы-тамчы булып, сары бал төсле пешек сытылып чыккан. Пешек исе, яңа киселгән чыршы исе килә. Быел көзгә Барис йорт күтәрмәкче була бугай...

Бөтен тәненең авыраеп, оеп киткәнен, күз кабакларының йомыла башлаганын сизми дә калды. Баскыч күтәрмәсендә шулай ярым йокылы килеш утырганда, кинәт аңа яланаякларына ниндидер тере, йомшак нәрсә ышкынган шикелле тоелды. Күзләрен ачып җибәрсә, ике аягы арасында бер җөнтәс кара көчек шыңшып торганын күрде.

— Ә-ә, син икәнсең...— диде ул, арып сулкылдаган аякларын авыр гына урыныннан кузгатып.— Нишләп кеше куркытып йөрисең? Каяле мин сине...

Ул аны тотып кына алмакчы булган иде, көчек, ышанучан сабый күзләрен бер күтәреп карады да, ярамый шул, абзыкай, дигән шикелле, тиз генә читкә тайпылды һәм, яфрак колакларын селкетә-селкетә, ава-түнә лапаска таба йөгереп китте.

Тирестә тибенеп яткан сары тавык, үзенә таба якынлашып килгән коточкыч нәрсәне күреп, куркып, бакча киртәсенә таба йөгерергә тотынды. Аннан күрмәкче бүтән тавыклар да чыркылдаша башлады, шул арада эре кыяфәт белән тырт-тырт басып, озын каурыйлары як-якка таралып торган койрыгын селкетеп, кызыл кикрикле купшы әтәч килеп чыкты. «Кем йөри анда?»— дигән кебек тиргәшеп алды да таралышып беткән тавыкларны яңадан үз янына җыя башлады. Шаулаштылар, кычкырыштылар, көчек исә аларның тавышын колагына да элмәде, лапас тирәсендә иснәнеп йөрүендә булды.

Шул вакыт Сәгыйть якында гына кемнеңдер елак тавыш белән:

— Бичти, бичти! Ма! Ма!.. Апа, карале, бичти тагын кереп китте!— дигәнен ишетте.

Кара чәчле, матур кара күзле, ләкин елак кыяфәтле, алты-җиде яшьләрдәге бер малай, бер кулы белән кыска чалбарын тотып, икенчесен бик нык селти-селти, көчек янына томырылып бара иде. Сәгыйть урам якка карап алды. Анда, сукмак өстендә, ике кыз бала туктап тора иде. Кызларның берсе, олырагы Заһирҗан агайның кече кызы Тәгъзимә иде бугай. Ә бу малай аның энесе иде бугай. Исеме ничек иде соң әле? Әһә, Фәүзи бугай. Әйе, Фәүзи.

Малай, үзенә таба елмаеп карап утырган ят кешене күреп алды да, кисәк кенә туктап калды.

— Кем малае син?— дигән булды Сәгыйть, күзгә-күз карашып торгач.

Фәүзи борылды да урамга ташланды. Бераздан аның апаларына нидер әләкләгәне ишетелде. Капка аратасыннан башын тыгып караган Тәгъзимә, кинәт:

— Сәгыйть абый! Сәгыйть абый кайткан!— дип кычкырып җибәрде.

Шундук балалар: «Сәгыйть абый кайткан! Сәгыйть абый кайткан!»— дип кычкыра-кычкыра, су юлы белән кирегә, чишмәгә таба йөгерделәр. Шыңшый-шыңшый алар артыннан Фәүзи дә иярде. Ләкин аларга ерак йөгерергә туры килмәде — тыкрыктан менеп килүче Миңнисәттәй үзе күренде. Кызлар, аны уратып алдылар да, нидер кычкырырга, куллары белән өй ягына төртеп күрсәтергә тотындылар.

Сәгыйть әнкәсе каршысына чыкты. Миңнисәттәй, капка янына да килеп җитмичә, авыр чиләкләрен шап итеп җиргә утыртты, көянтәсен-ниен сукмакка ташлап, кулларын алъяпкыч итәгенә сөртә-сөртә, улына таба атлады. Чиләкләр, әллә тигезсез җиргә туры килгәнгә, әллә инде бик саксыз куелганга, түгәрәк төпләрен ялтыратып, шундук яшел чирәм өстенә аудылар. Суның тамчысы да калмый агып бетте. Миңнисәттәйнең күзләреннән яшь бөртекләре атылып чыкты.

— Сәгыйтькәем!— диде ул, улын кочаклап.— Әй Ходай, нишләп бик озак тордың? Кит аннан, чәчләре җиткән... Һей, Сәгыйтькәем!..

Ул аны ныгытып, сабый чагындагы шикелле яратып, иркәләп кочаклады. Гомере буе кара, авыр эштә ярылып, корышып беткән кайнар куллары белән улының беләкләреннән, аркасыннан, чәченнән сыйпады; аннан һаман күзен алмыйча, бармакларын, күлмәк сәдәпләрен тоткалап карады.

Шундый зур егеткә әнкәсеннән — җитмәсә, бала-чага алдында — кочаклатып тору бераз уңайсыз иде инде уңайсызын, әмма Сәгыйть, каршылык күрсәтмичә, аның иркәсенә бирелеп, елмаеп басып тик торды. Әнкәсе аңа бик картайган, чүккән, бәләкәйләнеп калган шикелле күренде. Аның маңгайларындагы, күз төпләрендәге, авыз читләрендәге җыерчыклары да күбәйгән, тирәнәйгән, кайчандыр соргылт булып та, хәзер төсен югалткан күзләре тагын да эчкәрәк яшеренгән һәм сирәк, йомшак чәчләре тагын да ныграк көмешләнә төшкән шикелле күренде. Ләкин ул төссез күзләрдә, җыерчыклы, картайган йөздә аңа карата никадәр җылылык, никадәр мәхәббәт, якынлык нуры балкый иде!

— Нишләп яттың бу гомер?— диде әнкәсе, күз яшьләрен сөртеп.— Дүрт күз белән көттем... Былтыр да күзгә башка күренмәдең. Ай Алла, менә син!.. Ыстудиннар инде күптән кайтып җыелды...

Миңнисәттәй тәмам каушап төште, әле Сәгыйтьтән

юл хәлләрен сораштырырга тотынды, әле аны көтеп үзенең ут йотуы турында сөйләп китте. Бераз исенә килгәч, артына борылып караган иде, анысы анда, монысы монда аунап яткан көянтә-чиләкләрен күреп, кулын гына селтәде «Самавыр куярга гына җитәрлек суым бар әле, килен кайткач барырмын тагын»,— диде дә, буш чиләкләрен күтәреп, капкага таба юнәлде.

Өй эче Сәгыйтькә бик кысынкы, бик тәбәнәк булып күренде. Тәрәзә төпләре эреле-ваклы чүлмәкләргә утыртылган гөлләр белән тулган, түрдәге почмакка бизәкле чаршау белән капланган яңа койка куйганнар, идән уртасында як-якка селкетеп тирбәтелә торган аяклы бишек тора. Бишектә — Барисларның былтыр кыш туган малайлары йоклап ята. Аяк атлаган саен шыгырдап, сыгылып торган идән сайгаклары ап-ак итеп ышкып юылган. Өй эче элеккечә дә, шулай ук бик үк элеккечә дә түгел. Һәрбер нәрсәдә ниндидер яңа кешенең, яңа хуҗаның барлыгы сизелеп тора. Ләкин, ни генә булмасын, бу — туган йорт иде.

— Килен белән Барис мытыеска киткәние... Каяле, чәй куеп җибәрик. Ай Алла, менә син, арыгансыңдыр инде, ятып ял ит,— дип сөйләнде Миңнисәттәй, нишләргә дә, нәрсәгә барып тотынырга да белмичә, ишекле-түрле йөренеп.

Шул чакны чоланга урамнан бала-чага кереп тулды. Алар, кыюсыз гына ишек төбенә килделәр дә, күзләрен зур ачып, читтән кайткан студент абыйларына карап тора башладылар.

— Әһә, күчтәнәч кирәкме?— диде Сәгыйть, ягымлы елмаеп.

Урыныннан кузгалды да, чемоданын ачып, китаплар, төргәкләр арасыннан бер кәгазь янчык чыгарды. Яңа ел бәйрәмендә Кыш бабай бүләк өләшкәндәге кебек, кәгазь янчыгын тотып, балалар янына килде, аларның һәрберсенә икешәр печенье белән кәгазьле берәр конфет өләшеп чыкты. Аның шәһәр күчтәнәче Кыш бабай бүләгенә караганда бик әз иде, әлбәттә, ләкин балаларның аңа да түбәләре күккә тиде, авызлары үзеннән-үзе ерылып китте.

Күлмәк җиңенең ике як терсәге дә кара ямаулык белән ямалган, башына козырегы урталай сынган зәңгәрсу кепка кигән бер малай, үзе янында басып торган Фәүзинең янбашына төртте дә, шатланып:

— Ул гармун уйный беләә!— диде.

Фәүзи исә апасына борылды да пышылдап әләкләшеп алды.

— Карале, төртешә!

— Исемең ничек?— диде Сәгыйть, «төртешкән» малай алдына иелеп.

— Галиева,— диде малай, борынын тартып, бер дә аптырап тормыйча.

— Галиева? Син кыз кешемени?— Балалар кыюсыз гына елмаешып алдылар.— Нишләп «Галиева» булсын? Ансы әнкәңнең фамилиясе, синеке — Галиеф. Исемең, үз исемең ничек соң?

Малай, башын түбән иеп, тынсыз калды.

— Ләбип... Ләпкә аның исеме!— диделәр балалар.

— Безнеке — Тәлләт!

Миңнисәттәй йокысы туеп уянган, алма кебек кызарынган, әз генә тирләгән алсу битле малайны бишектән күтәреп алды.

— Абыкай, ниңә миңә дә күстәнәс билмисең? Абыкай, калале мине!— диде ул, Тәлгать өчен сөйләнеп.

Бәләкәй генә ап-ак беләкләре буылып торган малай, картыйсының кулына утыргач та, өй эчендәге зур кешеләрне күреп, көлеп җибәрде.

— Менә инде безнең матур җегетебез, батыр җегетебез. Хәзер менәтерә сөт кайнатырбыз... Җә, җә, бир инде абыеңа кулыңны. «Исәнме, абыкай, диген, миңа нәлсәләл алып кайттың, абыкай?»— диген.

Сәгыйтькә ул бер дә батыр да, матур да булып күренмәде — әллә нинди генә шунда, ниндидер тотрыксыз ит бүкәне... Ул аңа печенье суздың. «Батыр җегет» печеньене алмады, студент абыйсын ят итеп, шундук читкә борылды.

— Кемгә охшаган соң ул?— диде Сәгыйть.

— Кемгә охшасын — нәкъ әнкәсе инде, суйган да каплаган. Бигрәк тере безнең улыбыз, тәпи баса, әйбергә тотынып атлый.

— Мин бит аңа аю алып кайттым!

Сәгыйть чемоданын актарып, кара бәрхеттән тегелгән, кызыл пыяла күзле курчак аю чыгарып куйды. Аннан соң кием-салымнарын, үзе белән алып кайткан китапларын, дәфтәрләрен әвеш-түеш китерде, таушалган костюмын газета белән төреп, чөйгә элеп куйды.

Озакламый балалар да чыгып китте, мич алдына, идәнгә утыртылган самовар гөрләргә тотынды. Әмма әнкәсе хат турында нигәдер бер сүз дә чыгармады, һаман Тәлгать белән, аш-су белән булышты. Аның Сәгыйть өчен бик кирәкле, бик әһәмиятле нәрсә турында онытып, бөтенләй чит нәрсәләр белән кайнашуы шулай да бераз сәеррәк, гаҗәбрәк тоелды. Ниһаять, Сәгыйть беренче булып үзе сүз башламакчы булды.

— Әнкәй...— диде, бик арыган-алҗыган һәм шуңа күрә бернәрсәгә дә исе китмәгән шикелле күренергә тырышып,— әнкәй... хатларны кая куйдың, алып кына бир әле?

— Хат?— диде Миңнисәттәй, аның нәрсә турында сораганын аңлап җитмәгән кебек.— Нинди хат? Теге, үзеңнекенме? Хәзер...

— Түгел... Минем... үземә килгән хатларны...— диде ул, бөтенләй көчсезләнеп калган тавыш белән.

— Белмим шу-ул... Кайчан килде икән соң? Җук, сиңа хат-фәлән килмәде бугай...

— Килмәде?!

— Килсә, күрерием димен шул.

— Чынлапмы... әнкәй?..— диде Сәгыйть, аның сүзенә һич тә ышанасы килмичә.

— Ай Алла, менә син, бик кирәкле хатыемыни соң? Күрмәдем шул. Килен белән Барис кына алмаса тагын, белмим...

«Ни дигән сүз бу?»— диде Сәгыйть үзалдына, нишләргә дә белмичә.

## III

Кичкә таба, көн сүрелә төшкәч, Барис белән Гамбәр кайтып керде. Сәгыйть чолан идәнендә сузылып йоклап ята иде. Абыйсының таныш тавышын ишетеп, ул күзләрен ачып җибәрде, ләкин урыныннан тормады, йоклаганга салышып ята бирде. Күңелен шундук агач корты кебек нидер кимерергә, тынычсызларга тотынды. Нишләп болай соң әле бу? Ул бит шундый ашкынып кайткан иде!

Өй ишеген ябып куйганнар. Анда шаулашып нидер сөйләшәләр. Барис аны чыгып уятмакчы була, ахры, әнкәсе каршы килә: «Җокласын әле, бик арып кайткан»,— ди. Ләкин шул чакны ишек ачылып та китте, чоланга яланаяклы Барис килеп тә чыкты.

— Кайттыңмы, студент?— диде ул, күтәренке көр тавыш белән.— Нәрсә көпә-көндез җоклап ятасың? Каяле, тор әле!

Барис белән Сәгыйть арасында ике яшькә аерма бар иде. Ләкин алар, бер-берсенә бик еш кына «абый-эне» дип эндәшсәләр дә, бер-берсенең яшь аермасын бөтенләй диярлек сизмәделәр. Тик соңыннан, үсә төшкәч кенә, бер-берсеннән ераклаша башладылар кебек, ләкин бу, әлбәттә, читләшү түгел иде.

Барис авылда җиденче классны бетерде дә, колхозда

эшли башлады. Укуга ул әллә ни күңел бирмәде, аннан соң укуын дәвам итәргә ул чакта бик үк мөмкинлек тә булмады, беренче чиратта, тормышны алып бару турында уйларга кирәк иде. Ул күбрәк машина тирәсендә чуалды: әле тракторда плугарь булып эшләде, әле ашлык суктыра торган двигатель тирәсендә йөрде, аннары колхоз автомашинасына шофер ярдәмчесе булып утырды. Сугышка алынган елны ул инде үзе машина йөртә башлаган иде. Ул фронтка машинасы-ние белән китте.

Аларның тагын Баристан да олырак бер туганнары — Бибинур апалары бар иде. Ул яшьтән үк шат күңелле булып үсте. Ләкин ул барыннан да бигрәк эшкә җәптәш, эшкә уңган иде. Бибинур апалары бер генә эшкә дә калмый йөрде: тиресен дә түкте, яшелчә бакчасында да эшләде, ул чакта әле хатын-кызлардан кулына чалгы тотучылар бик сирәк булса да, ирләр белән бергә җимертеп печән дә чапты, көлтә дә кертте, ә көз көне, басулар тынып, бушап калгач, йөк-йөк төяп ашлыгын да алып кайтты. Вакытында аны мактадылар, газеталарга яздылар, ул хәтта Мәскәүдә Авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә дә булып кайтты. Аның яшьлегенең иң матур чагы дәһшәтле сугыш елларына туры килде. Җиләк чәчкәседәй вакытын ул сугышта үлгән беренче саф мәхәббәте — Мулланур турында саргаеп уздырды. Сугышта яраланып кайткан Асафка кияүгә чыкканда, ул инде яшь кызлар рәтендә түгел иде.

Шул елны, Барис армиягә алынгач, Сәгыйть әнкәсе белән генә торып калды. Дөньяны алып баруы бик авырга туры килде, бераздан Бибинур аларны Карманга, үзләре янына алдырды. Асаф каршы килмәде — алар бик тату, шуның өстенә бик иркен, мул яшиләр иде, аларның колхозы иң авыр елларда да, ичмасам, әз генә дә какшамаган, бай, нык колхоз иде. Сәгыйть белән әнкәсе, өйләренең тәрәзәләренә аркылы такта кадакладылар, ишекләренә богау йозагы салдылар һәм таулар артындагы Карманга күченеп киттеләр.

Бибинур, үзе яшьтән үк укымаганга, зурайгач, тормыш тәҗрибәсе алгач: «Эх, укымый әрәм булганмын!» — дип үкенүче кайберәүләр кебек, укыган кешегә ихтирам белән карый торган иде. Ул Сәгыйтькә урта мәктәпне бетереп чыгарга көченнән килгәнчә булышлык итте, энесе хәтта студент булгач та аны ярдәменнән ташламады.

Барис, армиядән кайтып бер ел эшләгәч тә, өйләнеп җибәрде, яшь киленне туп-туры үзләре нигезенә алып килде дә, тәрәзәнең такталарын куптарып ыргытты, ишегалдындагы әрем, алабутаны чабып ташлады, әнкәсен

кире үзләренә алып кайтты. Бибинурлар ак тояклы кызыл тана бирделәр, икенче елны ул сыер булды. Барис белән Гамбәр тракторда эшләде — китте тормыш гөрләп элеккечә.

Сәгыйтьнең инде күптән абыйсын рәтләп күргәне юк иде. Былтыр ул өйләрендә ярты айдан артыграк кына булды, Барислар ул вакытта икенче авылда эшлиләр иде. Менә ул аның алдында елмаеп басып тора. Олыгая, басыла төшкән кебек. Күренеп тора, чын-чынлап ир кеше.

— Сине дә күрер көн бар икән!— диде Барис, энесен бик җиңел генә урыныннан тартып торгызып.— Әйдә, әйдә, җитәр иркәләнеп ятырга!

Каядыр ашыккан шикелле җитез-җитез атлап, авызын колакларына кадәр ерып-елмаеп, ак чырайлы, чандыр гына, җиңел генә Гамбәр килеп чыкты. Берьюлы ике кулын сузды да, күптәнге таныш, якын кешесенә эндәшкән кебек, күңелгә кереп:

— Исән-сау гына кайттыңмы, Сәгыйть?— диде.— Пуездан төшкәч тә мытыеска сугылсаң, бергә кайткан булырыек лабаса... И-и, үзгәреп беткәнсез... Нишләп чоланда утырасың, әйдә өйгә керегез...

Ул шулай тиз-тиз генә тагынниләрдер сөйләнде дә, көянтәсен-чиләген шалтыр-шолтыр китереп, суга китеп барды.

Алар өйгә керделәр. Әнкәләре, тар ушага җәйләп утырган көе, бик эшлекле кыяфәт белән җиңнәрен сызганып җибәреп, тавык йолкый иде.

— Кая, самавыр куйдыңмы, әнкәй?— диде Барис, кулына Тәлгатьне алып.

— Нинди самавыр ул — менәтерә аш салабыз, берәр нәрсә генә капкалап торыгыз инде. Ай Алла, менә син, нәрсә әйтмәкче булганыем соң әле?.. Киленне әйтәм, үзе җугында сөйлим әле... Уңдык киленнән — ут уйната, эшкә дисеңме, аш-суга дисеңме... Шушы көнгә кадәр бер генә тел-тешкә килгән дә җук, Аллага шөкер. Җук, Сәгыйть, донҗада әллә нинди кешеләр дә бар. Әнә Инсаф катыны укымышлы да бит, укытучы да бит... инде әллә ничә терит балтага-пычакка килгәндә генә калдылар. Шулай булганда да күңелле түгел, дөресен дөресчә әйтерсең...

— Ярар, ярар, мактама,— диде Барис, әнкәсен кырт кисеп.

— Мактарлыгы да бар шул. Барис ул үз эшен генә белә, бераз җортны да карарга кирәк... Килен белән без кыстамасак, әнә ул бүрәнәләр дә булмыйдырые әле. Жарар, ди, гомер торганны тагын бер генә җыл торырбыз

әле, ди. Җук, Сәгыйть, әйбәт җортта да торып каласы килә бит. Дүрт ситнир бодай саттык, әле тагын...

— Саттың!— диде Барис, сизелер-сизелмәс үртәлеп. Бу турыда аның бик үк сөйләшәсе килми иде бугай.— Сез генә инде киленең белән! Каян килә соң ул бодай?

Сәгыйтькә абыйсы өчен бик уңайсыз булып китте, ләкин ул, берни эндәшмичә, тыңлап кына утырды. Беренче көнне үк алар арасына керәсе килмәде. Аннан соң аларның сүзенә артык колак та салмады. Ул, бик үк өметләнеп, бик үк ышанып булмаса да, Барисның хат чыгарып бирүен, һич югы, шул турыда сүз башлавын көтте. Ул аның авызына гына карап торды, аның һәрбер хәрәкәтен күзәтте. Барис, үч иткәндәй, ул турыда һаман берни кузгатмады.

— Ашарга бар быел, Сәгыйть, зарланырлык түгел,— диде Барис бераздан, тыныч кына, ләкин бераз мактану, масаю кебек нәрсә сиздереп торган тавыш белән.— Ун ситнир бодай гына алдым былтыр, алты ситнир арыш...

— Мин — кырык өч кила!— диде әнкәсе, көлеп.

— Кырык өч! Җөрдең шунда җәй буе корыны бушка әйләндереп, гырам өчен селкенеп. Быел инде ике аягыңның берен дә атламыйсың — менә шул!

— Үзебезнең авылда эшлисеңме?— диде Сәгыйть, сүзне икенчегә борып.

— Быел үзебездә. Әлегә чаклы «килен» белән тырактырда җөрдек.

— Әлегә чаклы? Ә хәзер?

— Хәзер римунтта. Камбаен римунтлыйбыз, энекәш! Арыш җиткәч тә камбаенга утырам. Менә шул.

— О-о, син алайса!

Сыгыла-сыгыла, авыр чиләкләр күтәреп, Гамбәр судан кайтты. Барис, зур саплы калай чүмечне чиләккә чумдырып алды да, тәмләп салкын су эчәргә тотынды. Аның авыз читеннән, чүмеч төбеннән пыяладай ялтырап торган салкын тамчылар тамды, йоткан саен бугаз төере кыймылдап торды. Тулы чүмечне ул тын да алмыйча эчеп бетерде дә, ат кебек пошкыра-пошкыра, эчен угалап алды.

— У-ух, бик эчәсе килгән икән!

Гамбәр тагын тышка чыгып китте, әнкәсе, тавык белән эшен бетереп, учак алдында булаша башлады. Өй эче тынып калды. Тәлгать кенә «у-у, гү-гү», дип, үз телендә нәрсәдер сөйләнде.

— Хат-фәлән... алмагансыңдыр син?..— диде Сәгыйть, абыйсының күзенә карамыйча гына. Бераз тотлыккандай итеп торды да, аңлатып әйтеп куйды: — Миңа хат килергә тиешие... бергә укыган иптәштән...

— Җук, алмадым,— диде Барис, коточкыч тыныч, чит тавыш белән.

Сәгыйть телен тешләгән кебек тынып калды. Кичке аш җитешкәнче ул рәтләп бер генә сүз дә эндәшмәде.

Бөтен өйгә тәмле тавык ите исе таратып, өстәл өстенә зур табак белән аш килеп утырды. Әнкәсе, җиңнәрен югарырак сызганып куйды да, һәркемнең коштабагына шаулатып кайнар аш бүлә башлады.

Барис үзенең каршысында утырган Гамбәргә каш сикертеп алды. Тегесе исә тиз генә урыныннан торып китте дә, каяндыр бер яртыны китереп чыгарды. Барис, ялтырап, чайкалып торган шешә төбенә учы белән сугып, бөкене аттырды, алдындагы ике бәләкәй стаканны күздәй итеп тутырды да, Сәгыйтькә ымлап:

— Әйдә, тот,— диде.

— Барисның-ни, авыз аңа килешеп кенә тора инде,— диде әнкәсе.— Сәгыйтем, ичмаса, тәүфикъллы булды — тартмый, эчми... Әткәгез мәрхүмнең дә — шушындый шатлыклы көнне искә төшерим әле — беркайчан эчеп-исереп кайтканы булмады...

— Туктале, шауламале син, әнкәй,— диде Барис, йомшак кына итеп.— Гел очрашып тормыйбыз.— Стаканны беренче булып үзе күтәрде дә, тагын Сәгыйтькә ымлады: — Әйдә, синең кайту хөрмәтенә!

— Юк, әнкәй,— диде Сәгыйть, кинәт телгә килеп,— бүген эчәм!— Һәм көттереп-нитеп тормыйча, үзенә дигән стаканны Барисныкы белән чәкештерде дә, «беткән баш беткән!» дигән шикелле, ниндидер тиле кыюлык белән, акның тамчысын да калдырмый авызына каплады. Тамагын ярып үткән утлы нәрсәдән чыраен сытып, башларын чайкап, буш стаканны яңадан абыйсы алдына утыртты һәм:

— Сал тагын! Сал!— диде.

Гаҗәпләнгән Барис телен генә чартлатып куйды.

— Тукта! Ни булды сиңа, студент?!

## IV

Эчми эчкәнгә, аракы аның шундук башына китте. Бөтен тәне таралып, тотрыксызланып китте, кул-аяклары сизелмәс дәрәҗәдә җиңеләеп калды, теле көрмәлде. Ләкин ул барыбер аңын югалтмады, һаман эчен борып, бөтен нәрсәсен авырттырып, күңелендә Ида торды. Ул, газаплы уйлардан котылмакчы булып, күңеленә ниндидер җиңеллек тапмакчы булып, икенче стаканны да йөзен дә чытмый эчеп җибәрде.

Икенче көнне уянып киткәч, чатнап башы авыртты. Аның беркемгә дә карыйсы, беркем белән сөйләшәсе килмәде. Ул кичәгенәк үзенең бик күп аракы эчкәнен хәтерләде, тамак төбендә аның ачы, шакшы тәмен тойды һәм, косасы килер дәрәҗәдә җирәнеп, бөтен тәне белән тетрәнеп-тетрәнеп куйды. Кешеләрнең, үз акылында булган таза, сау кешеләрнең шундый агулы нәрсә эчеп ләззәт табуларына ул чын күңеленнән гаҗәпләнде. «Икенче беркайчан да эчмәм!»— диде ул, ант итеп.

Баш авырту кичкә кадәр сузылды. Бары тик икенче көнне иртән генә ул үзен ниндидер авыр газаптан, куркыныч чирдән котылган кебек итеп, җиңеләеп, тазарып калган итеп сизде.

Көндәгечә елмаеп кояш чыккач та, җир өстенә капланып яткан куе караңгылык эреп югала, тарала башлады, көндез бала-чагаларны куркытыр өчен идән асларына, базларга, мунча, каралтыларга кереп яшеренде. Яшеллеккә төренеп, күкрәп утырган чыклы җир өсте яктырып китте. Дөнья аңа яңадан шундый матур, шундый ачык, аңлаешлы булып күренде. Бүген инде Идадан хат булмавы аны һич тә борчымый шикелле тоелды. Ул аек баш белән бөтенесен уйлап, исәпләп карады һәм, хат әле юлда булырга тиеш, дигән нәтиҗәгә килде. Ул көтәргә булды. Аның өчен хәзер бернинди шик калмады. Ул үзен яңадан бәхетле итеп сизә башлады.

Җәй көнен авылда ничек үткәрү турында ул инде күптән план корып куйган иде. Аңа, беренчедән, яхшылап ял итәргә кирәк, ягъни: балык каптырырга, су керергә, кояшта кызынырга, урманда, басуда йөрергә кирәк; икенчедән, көз көне фәнни түгәрәктә тикшереләчәк докладын язып бетерергә кирәк. Өченчедән? Өченчедән — тагын ял итәргә, күңел ачарга, ерактагы-якындагы туган-тумачаларга кунакка барырга кирәк булачак. «Бибинур апа бик ачулана, ди ич, шәһәрдә укыгач та, кеше булгач та, апасы кирәкмәс булды, безне бөтенләй онытты, былтыр да килмәде, дип әйтә, ди ич. Апаларның хәтерен калдырырга ярамый, әлбәттә, анда да барырга кирәк булыр»,— дип уйлады ул.

Шулай да иң элек ул үзләрендә ял итәргә булды. Ашады, эчте дә, шәһәрдә чакта ук әзерләп куйган кармак-җепләрен алып, авыл читеннән калкып күренгән биек таулар ягына — елга буена китте.

Ул елганың кайчандыр үзе малай чагында балык каптырган җиренә килде. Текә яр астына төште дә, авып, башы белән суга чумган юан карама өстенә утырды, кармак салды. Ул тын гына, әкрен генә аккан яшькелт су

өстенә карады, кызыл балчыклы ярларга, ишелгән яр кырыеннан озын-озын баулар кебек салынып торган агач тамырларына карады һәм бер генә мәртәбә дә диярлек калыкмага күз төшермәде.

Кармак сабын сындырып суга ташлады да, яр өстенә менеп китте. Ул чабылмаган яшел болыннар буйлап йөрде, бер дә юкка әрәмәләр эченә кереп чыкты, кинәт кенә туктап калды да, йә аяк астында, йә берәр агач башында ишетелгән кыштырдауга колак салды, аннан соң яңадан кояшлы, иркен болыннарга килеп чыкты, йомшак, яшь печән өстенә сузылып ятты, зәңгәр күктәге аксыл болытларны күзәтте, кошлар чыр-чуын, чикерткәләр чыңын тыңлады.

Аның бөтенесен бер көнне карап, бер көнне күреп бетерәсе килде. Аның бөтен күңеле гүзәл бер тәэсир белән, сабыйларча куаныч белән тулды.

Иске арба юлы аны биек тау башына алып менде. Ул кыядан аягын салындырды да, аста зур масштаблы картадагы шикелле булып җәелеп яткан әрәмәләргә, болыннарга карап утырды. Арыса, ял итте, тамагы кипсә, адым саен диярлек чылтырап агып яткан чишмәдән ятып су эчте.

Әйтерсең ул иксез-чиксез биләмәләре булган ниндидер бик зур хуҗа иде, һәм хәзер, читтә йөреп кайтканнан соң, үзенең байлыкларын энәсеннән җөбенә кадәр җентекләп тикшереп йөри иде. Аңа монда бөтен нәрсә тансык, күңелле иде, бөтен нәрсә искиткеч матур, яңа иде.

«Менә ичмасам — ял!»— диде ул, тәэсирләнеп.

Ләкин кире авылга кайткан чакта, күңеле бөтенләй икенче нәрсә өмет итеп тирбәлә башлады. Аңа өйдә аны берәр нәрсә көтеп торадыр шикелле тоелды. Ул йөгерә-йөгерә кайтты. Ишекне ачу белән тизрәк:

— Әнкәй, почта килдеме?— дип кычкырды.

— Җук,— диде әнкәсе, йөрәгенә тагын шом салып.

Бу хәл аны бик нык аптырашта калдырды, гаҗәпләндерде, куркытты. Бу турыда ул ничек дип уйларга да белмәде.

Йокысы йокы булмады, ашы аш булмады. Бөтен тормышының мәгънәсе аның өчен хәзер бары тик бер генә нәрсәгә — аннан зарыгып хат көтүгә генә кайтып калды.

Өйдә торгандамы, урманда, болында йөргәндәме, су буенда, комда кызынып яткандамы яисә юлда, сукмакта баргандамы — кайда гына булмасын, ул хәзер үзенең ялгызлыгын, бәхетсезлеген ныграк сизә башлады.

Ул һаман да үзен шат, күтәренке күңелле дип исәп-

ләргә тырышты, һаман да үзенең дәртлелеген, бөтен нәрсәгә сокланып, яратып каравын шул көе сакларга тырышты. Шулай да балаларча ваемсыз куаныч көннән-көн сүрелә барды; агач күләгәләренең, кошлар тавышының, әле тынып, әле оеп яткан, әле чуер ташлар өстеннән сикерә-сикерә алга ыргылып, ургылып аккан елганың, якты көннең, зәңгәр күк йөзенең, җир өсте тараткан хуш исләрнең яме-тәме кимегәннән-кими, беткәннән-бетә барды. Күңеленә һаман әкренләп сыек кургаш кебек авыр, салкын сагыш саркып керде: кул-аягын, фикерен, ихтыярын тотып, буып, башында тынгысыз тере уй, аның турындагы уй тыпырчынды. Бу инде сөю генә түгел, бу — чын-чынлап газап, берничек тә аңлатып та, җиңеп тә булмый торган көчле газап, кайгы-хәсрәт иде.

Беркөнне ул урманга бик эчкәре керде. Йөри-йөри алҗып бетте, аяклары сызлый башлады. Кайтырга чыкканда инде күләгәләр озынайган, һавада кечке тынлык, кичке моңсулык сизелә башлаган иде.

Кояш инде үзе күренми иде. Ул куе зәңгәр төскә кергән таулар артына яшеренгән. Бөтен күк читенә алсу-кызгылт нурлар сибелгән. Бер очы тау сыртына эләгеп калган озынча болыт икенче очыннан, кемдер ут төртеп җибәргән кебек, кызарып елкылдап яна, куырыла, шул ук вакытта аның уртасы кара күмергә әйләнә бара иде.

Менә кызгылт нурлар әкренләп куердылар, үзгәрделәр, һәм итәгенә ут капкан әлеге болыт кисәге дә, сизелмичә генә тау сыртыннан ычкынып китте дә күзгә күренеп эри, кечерәя башлады. Көтмәгәндә әллә каян куе кызыл, карасу-зәңгәр болытлар килеп чыктылар. Алар торган саен зурайдылар, кыймылдадылар, хәрәкәтләнделәр. Күк читеннән кызгылт-алсу кояш ялкынын куалый-куалый, сыек, аксыл яктылык тарала башлады. Һаман кояшка таба шуышкан кабырынкы болытларны үтә-сүтә тишеп, кинәт туры сызык буенча алтын очкыннар сибелде, һәм тау читләренә, болын өсләренә, агач башларына берничә минутка якты нур тасмалары сузылды.

Шундый тизлек һәм осталык белән, шундый гүзәл итеп табигать тудырган бу җанлы күренешне Сәгыйть исе китеп карап торды. Анда, күк белән җир тоташкан урында, аңа нindидер тере, дәү нәрсәләр хәрәкәтләнә, ниндидер икенче бер тормыш бара шикелле тоелды. Һәм аны тагын да берни белән җиңеп булмый торган сагыш биләп алды. Ида аңа шул яктадыр, шул җанлы болытлар, җанлы кояш нурлары ягындадыр, шул җанлы таулар артындадыр шикелле тоелды, һәм бертуктаусыз шул якка гына карап китсәң, кайчан да булса аның янына

барып чыгарга мөмкиндер төсле тоелды. Бу уй шундый ләззәтле, шундый ачык, аңлаешлы иде, кинәт аның йөрәге, кулга менә хәзер бәхет төшәсен сизенгән шикелле, шатланып, өметләнеп тибәргә тотынды. Күңелендә шундук татлы хыял дулкыны күтәрелде. Үзен Ида янында итеп, аның белән бергә итеп күрү хыялы аны каты җир өстеннән күтәреп алып, җиңел генә очырта-очырта, гыйшык ялкыны белән яктыртылган шул моңсу, серле болытларга илтеп утыртты. Ул берни күрмәс, берни ишетмәс булды. Юл буе ул аның белән хыялланып кайтты.

...Кыш иде, Яңа елны каршылау кичәсе иде. Һәрвакыт ниндидер тантаналык, ниндидер җитдилек хөкем сөргән биек, иркен Актовый зал да, киң коридорлар да, баскычлар, вестибюльләр дә шау-шулы, яшь, матур студентлар белән тулган иде. Актовый зал уртасында урманнан яңа гына кисеп алып кайткан зур чыршы утыра иде. Ул көнне бер генә кешенең дә йөзе боек, күңелсез, чытык түгел иде, һәркем елмая, көлә, шаяра иде. Бер генә кешенең дә өсте-башы начар түгел — һәркем иң әйбәт киемнәрен киеп, яхшыланып, матурланып килгән, идән уртасындагы чыршы да төрле уенчыклар, шарлар, төймә кебек кенә ал, кызыл, зәңгәр утлар белән бизәлгән иде.

Ул кичне Сәгыйть гел аның янында гына булды, гел аның белән генә диярлек биеде, көлде, тиеләнде, каяндыр мәзәк, көлке сүзләр эзләп тапты. Аның әле беркайчан да шундый оста телле, шундый шат күңелле булганы, үз-үзенә шундый нык ошаганы юк иде бугай. Ида да гадәттәгегә караганда да гүзәлрәк, чибәррәк иде. Ул бертуктаусыз аңа карап елмайды, шаянланып күзләрен кысты, җиң очына кыстырган бәләкәй генә кулъяулыгын алды да тирләгән, кызарынган маңгайларын, битләрен сөртте.

Менә бер заман залдагы хәрәкәт тынып калгандай булды, музыка тынды, аяк тавышлары, күлмәк итәкләренең шыштырдавы, сөйләшү, көлешүләр басыла төште һәм шуннан соң берничә секундка тирән тынлык урнашты. Һәркем сәгать минутларын санады. Унике туларга ике минут калды. Унике тулды. Ул чакта шундый гади, шундый ягымлы булып күренгән ректор, ир уртасы кеше, бәхетле елмаеп, яңа ел хөрмәтенә берничә котлау сүзе әйтте. Бөтен зал дәррәү күтәрелеп, ура кычкырды, һәркем шаулашып, шатлыклы йөз белән, берберсен Яңа ел белән котларга тотынды. «Яңа ел белән, яңа бәхетләр белән!»— диде Ида аңа, ул кичне һәркем әйткән сүзләрне кабатлап. Ләкин ул гадәти сүзләрдә аның өчен үзенә бертөрле яшерен мәгънә бар иде.

Студентлар ректорны күтәреп алдылар, аның карышырга тырышып, кулларын селтәвенә дә карамастан, көлешә-көлешә, күккә чөйделәр. Ректор бик зур, бик авыр гәүдәле кеше иде, һәм ул егетләрнең уннарча кулларыннан аерылып киткәч, аның аяклары югары күтәрелде. Аны шундук тотып алдылар, тагын чөйделәр. Көлешүнең чиге-чамасы булмады. Күңелле, искиткеч күңелле иде.

«Әйдә, урамга! Ах, урамга!» — диде кинәт Ида. Аның кулыннан тотып алды да, кешеләр арасыннан ырып-ерып, ишеккә ташланды. Сәгыйть аның артыннан көчкә җитеште. «Ах, урамга чыгабыз! Монда бөркү, әйеме, Сәгыйть!» — диде ул, тимер баскыч буенча аска йөгереп.

Элгеч янында кеше күп түгел иде. Ул чиратка басты, аның да, үзенең дә пальтосын алды. Ида киенергә көзге каршысына килде, бер аягына гына басып торган көе икенче аягының туфлиен салырга тотынды. Егылып китмәс өчен ул аның кулына тотынып-тотынып алды. Аякларына озын куныччлы җылы ботинкаларын киде дә, ялтырап торган туфлиен шакылдатып идәнгә куйды. «Туфлине сумкага сал әле, Сәгыйть, — диде, иркәләнеп. — Мин аның бигеен каптыралмыйм». Аның теләген ул бик риза булып үтәде. «Хәзер пальтоны кидер!» — диде Ида аннан соң, шул ук иркәләнү сиздереп торган боеручан тонда.

Алар тышка чыктылар. Сәгыйть сул кулына аның туфлие салынган кадерле сумканы тотты, уң кулы белән аны култыклап алды. Тышта шундый иркен, шундый рәхәт, кышкы салкын һава шундый чиста, шундый җиңел иде. Күктән әкрен генә, иренеп кенә күбәләк кар төшә, ике як тротуар буена тезелгән электр фонарьларыннан, йорт тәрәзәләреннән бәйрәмчә җыйнак, ягымлы урамга шундый күп яктылык бөркелә иде.

Кинәт Ида аны карга төртеп екты. Екты да үзе, артына да борылып карамыйча, эче катып көлә-көлә, йөгерергә тотынды. «Туктале, мин сине!» — диде ул, кычкырып. Тиз генә урыныннан сикереп торды да, өстен кагакага, аның артыннан куып китте. Әллә бик нык көлгәнгә, әллә пальто итәге аягына уралганга — Ида ерак йөгерә алмады. Ул аны шундук куып җитте, буш кулы белән аркасыннан төртеп җибәрде, Ида кар өеменә барып төште. «Мин шунда ятып калам! Монда рәхәт!» — диде ул, башын кар өстенә салындырып. Сәгыйть, нindидер бер көчкә буйсынып, Иданы тиз генә җилтерәтеп торгызды да, үзе дә сизмәстән аның биленнән кочып алды. Ләкин үз кыюлыгыннан үзе куркып, шундук кулын кире алды.

Ул үзен ниндидер начар, ярамаган эш эшләгән кебек хис итте. Аңа хәзер Ида менә аны ачуланырга, гарьләндерергә тотыныр, аның бер үзен урам уртасында калдырып кайтып китәр шикелле тоелды. Икесе дә, уңайсызланып, сүзсез калдылар. Аның бик нык гаҗәпләнүенә каршы, Ида ачуланмады да, китеп тә бармады, берни булмаган кебек, пальто итәгенең карын сыпырып тик торды. «Бәхетем!..»— диде ул күңеленнән, искиткеч куанып.

Күктән иплап кенә, сагаеп кына йомшак кар яуды. Эре кар бөртекләре, тирбәлә-тирбәлә төшеп, аның елтыр мехлы пальто якасына, мамык шәленә, керфек очларына кунды. Аяк астында ниндидер серле, ягымлы тавыш белән кар шыгырдады. Кышкы һава нишләптер бик җылынып китте, хәтта бераз бөркү дә иде бугай әле.

Алар Черек күлдәге зур чыршы янына, шәһәргә килгәч, төрлечә бизәлгән, «ёлка»га әйләнгән чыршы янына бардылар, җыелган кешеләргә, утларга карап тордылар. «Бездә дә шундый чыршылар үсә»,— диде Сәгыйть. «Бездә чыршы юк, бездә каен гына»,— диде Ида. Һәм тагын нигәдер сагаеп, куркып тынып калдылар. Аннан соң Ирек мәйданына бардылар, анда да шундый ук зур «ёлка» карадылар. «Монысының йолдызы яктырак яна,— диде Ида,— монда халык та күбрәк».

Сәгыйть Иданы торагына кадәр озата барды. Алар, бер-берсеннән тиз генә аерылып китә алмыйча һәм шул ук вакытта, авызларына су капкан кебек, бер-берсенә әйтер сүз таба алмыйча, ишегалдында озак кына таптанып тордылар. «Сау бул, Сәгыйть»,— диде Ида. «Сау бул»,— диде ул һәм, аннан күзен ала алмыйча, урыныннан да кузгалмыйча басып тик торды. «Сәгыйть,— диде Ида,— иртәгә нишлисең? Кил безгә... Давай иртәгә катокка барабыз! Ах, катокка барабыз! Барабызмы?» «Барабыз!— диде ул, ашыгып.— Киләм! Йөгереп киләм, очып киләм! Иртән-иртүк килергә буламы?» «Иртүк? Иртүк кирәкми... Юк, иртүк кил, иртүк! Киногa барырбыз! Ә кич — катокка!.. Ну, сау бул, Сәгыйть...»

Кыз кереп киткәч тә, Сәгыйть, ни өчендер үзалдына елмаеп, һаман урынында басып торды.

Моңарчы әле аның беркайчан да Иданың үзен генә озатып куйганы да, хәтта аның белән култыклашканы да юк иде. Ул чакта, яңа елны каршылаган кичне, әллә ничек кенә булды шунда — ул аны үз гомерендә беренче мәртәбә күргән шикелле булды. Аякларының ничек атлаганын да сизмичә, кулларын селти-селти, якты урамнардан кызу-кызу атлап кайтканда, ул күңеленә нинди-

дер ят нәрсә кереп калуы турында уйлады. Нәрсә иде икән соң ул? Бу турыда ул үз-үзенә дә танарга курыкты, ләкин шулай да аңа искиткеч рәхәт иде. Аның күзенә һаман Ида күренде, колак төбендә аның тавышы яңгырап торды, ул аның кул җылысын, тәненең хуш исен яңадан тойгандай булды.

Бер дворник хатын, иелеп, озын саплы тимер көрәк белән йорт буендагы каты карны ваткалап ята иде. «Шундый күңелле вакытта ничек эшкә кулы бара икән моның?— дип уйлады Сәгыйть, гаҗәпләнеп һәм, хатын турысына җиткәч: Яңа ел белән! Ташлагыз көрәгегезне!»— дип кычкырды. Хатын, туң асфальтка тук-тук шакый-шакый, нидер сөйләнеп калды. Кышкы бакчада, кары сыпырып төшерелгән скамья янында, бер солдат белән бер кыз үбешеп тора иде. «Яңа ел белән!»— диде ул аларга һәм әллә гашыйкларны куркытуына, әллә болай гына, бик көләсе килгәнгә, кычкырып көлеп җибәрде. Тегеләр, уңайсызланып, башларын күтәреп карадылар. «Яңа ел белән!»— диде солдат, соңга калып булса да. Урам уртасыннан кочаклашып, җырлап килгән эшчеләр очрады. «Яңа ел белән!»— диде ул аларга да, кулын болгап. «Яңа ел белән, яңа бәхетләр белән!— диде ул, Ида әйткән сүзләрне күңеленнән кабатлап.— Яңа бәхет... Чынлап та яңа бәхет булыр микәнни?.. Яңа бәхет...»

Баштарак, беренче курсларда, группадаш иптәшләрен әле ныгытып белмәгәндә, бер-береңә әле үз туганыңа өйрәнгән кебек өйрәнеп җитмәгәндә, Ида аңа ошамый иде. Ул гына да түгел, ул гомумән аның кебек кызларны яратмый иде. Хәер, ул чакта әле ул нинди кызларны яратканын үзе дә рәтләп белми иде.

Аның күзгә бәрелеп торган ап-ак тулы йөзе, әле теләсә кемгә, теләсә нәрсәгә гаҗәпләнеп карый торган, әле кылтаеп кысыла торган күзләре, бик үк дөрес формалы булмаган зур, калын иреннәре, ниһаять, әз генә кызып сөйләшсә дә, бит очларының шундук алсулана башлавы нигәдер аның ачуын китерә торган иде. Аның үз-үзен тотышында да аңа ошамый торган ниндидер нәрсәләр бар иде. Егетләр белән сөйләшкәндә ул юк нәрсә өчен дә бәхәсләшергә тотына, күп кенә очракта, фикере дөрес булмаса да, үз сүзен сүз итәргә тырыша, йә бик төчеләнә, кылтая, йә бик шат күңелле булып кычкырып көлә торган иде.

Группада Ида иң хәлле студентлардан исәпләнә иде, өйләреннән аңа ай саен акчадыр, посылкадыр салып кына торалар иде. Ул һәрбер сезон саен берәр яңа кием ясатмый калмый. Ида группадагы барлык кызларга да бераз

өстен торып, җиңелчә ирония белән карый иде бугай. Шуңа күрә кызларның күбесе аны бик үк яратып бетермиләр, үзе ничек булса, аның үзенә дә шулай булырга тырышалар иде бугай. Ул бер генә яңа спектакльне дә, бер генә яңа опера-балетны да, кинокартинаны да карамыйча калдырмый һәм һәрвакыт музыка турында, кино артистлары турында үзенә генә хас белдеклелек, ышанучанлык белән бик җиңел, бик оста фикер йөртә ала иде. Шуның өстенә ул бик шат күңелле иде. Ул кеше белән, бигрәк тә егетләр белән, бик тиз аралашып китә ала иде бугай.

Хәер, башта ул аның яхшы якларына караганда, гадәттә күзгә ныграк ташланып торган кимчелекләрен генә күрә иде, ахры. (Бәлки, бүтән кызларга караганда аңа ныграк игътибар иткән өчен бу шулай тоелгандыр, кем белә аны!) Инде тәмам күзе-башы әйләнгәч, тәмам гашыйк булгач, ул аңа бары тик матур гына булып, ягымлы, әйбәт кенә булып күренә башлады.

Икенче көнне алар кино карадылар, кич катокка бардылар һәм төне буе урам кары таптап йөрделәр. Алар кинәт олыгаеп киткәндәй булдылар: көлмәделәр дә, шаярмадылар да, бер-берсен карга да төртеп екмадылар. Алар бүтән чакта бөтенләй кызыксыз булган нәрсәләрдән ниндидер яшерен мәгънә табып, кыш турында, кар бөртекләре турында, чана шуучы малайлар турында, үзләренең группадашлары турында һәм — телләренә, күңелләренә ни килә, шул турыда сөйләштеләр. Әмма үзләренең бер-берсенә карата уянган яңа хисләре турында бер генә сүз дә ычкындырмадылар — кинәт туган ул хис шундый бөек, шундый саф, көрсез иде, аны нинди сүз белән генә әйтсәң дә, бары тик бер-береңнең күңелен генә рәнҗетүең мөмкин иде.

— Сәгыйть...— диде Ида, шундый серле дә, шундый аңлаешлы да итеп.— Сәгыйть... синең белән булганда... миңа... ужасно рәхәт!— Шуннан соң үз тавышыннан үзе өреккән кебек, туктап калды.— Ә сиңа?

Аның кулы Иданың бармакларына тиеп китте.

— Миңамы?.. Миңа...

Ул бүтән бер сүз дә әйтә алмады. Бакчада фонарьлар янмый иде, тирә-якта беркем дә юк иде. Алар бер-берсенә ничек якынлашканнарын сизмәделәр дә. Ул аның мех якасыннан, салкын чәченнән, пальтосының ат күзе кебек зур төймәсеннән килгән татлы, әйбәт исне йотлыгып сулады, калын киеме аша аның йомшак тәнен тойды.

Алар бер-берсеннән башка тора алмый башладылар.

Иптәшләренең кызыксынучан күз карашыннан да кыенсынмыйча, кайбер кызларның пышылдашуыннан да курыкмыйча, кирәк лекциядә булсын, кирәк урамда, ашханәдә булсын, гел диярлек бергә була, бергә йөри башладылар. Алар үзләреннән башка, үзләренең бәхетеннән башка дөньяда тагын ни дә булса, кем дә булса булуы турында уйлап та карамадылар. Тиздән аларны һәркем белә башлады.

Әйе, ул аны яратты. Ярата!

## V

Авылга кайтып җиткәндә, караңгы төшмәгән иде әле. Сәгыйть олы урамга кереп тормыйча, аяк очтан гына китмәкче булды. Сукмактан башын түбән иеп барганда, үз исемен ишетеп, ул сискәнеп китте. Аның каршысында избач Нәсим басып тора иде.

Безнең авылларда еш кына бертөр кешеләрне очратырга була. Алар теләсә нинди язу-сызу эшен булдыра ала торган «укымышлы», «башлы» һәм бары тик җитәрлек белемнәре булмау аркасында гына «профессор» булмый калган кешеләр. Мондый кешеләр яхшы гына шигырь дә язалар, әгәр берәрсе сорап килә икән, шул сораучының сугышта һәлак булган иренә яисә суга төшеп үлгән баласына, туган-тумачасына багышлап бәет чыгарудан да баш тартмыйлар. Бәйрәм вакытларында, концертларда, һәркемнең исен китәреп, сәхнә түреннән «декламация» сөйлиләр, һәм авыл клубындагы бер генә кичә дә, бер генә җыелыш та, концерт-спектакль дә алар катнашыннан башка узмый. Мондый чакларда алар гадәттә кичә җитәкчесе дә, шул ук вакытта биюче дә, гармунчы да, хәтта режиссер һәм артист та булалар. Алар арасында бик оста телләләр дә, ягъни сәнгатьчә итеп сөйли белүчеләр дә, әкиятчеләр дә, җырчылар һәм үзлегеннән өйрәнгән художник, композиторлар да бар. Бу төр кешеләр — чын-чынлап халык талантлары.

Тик аларның кайберләре, бик тиз башлары әйләнә торганнары яисә мөмкинлекләре булмаганнары, биек, текә кыяның өстенә үк күтәрелә алмыйча, аста, түбәндә торып калалар һәм гомергә «авыл артисты», «авыл шагыйре», «авыл художнигы» булып йөриләр. Аларга кайвакытта белем генә түгел, кыюлык та, ихтыяр көче дә җитеп бетми.

Избач Нәсим нәкъ шундыйларның берсе иде. Сәгыйтьтән ул берничә яшькә олырак, аның инде бер малае белән бер кызы бар иде. Ул, барыннан да бигрәк, художник

иде. Ул фоторәсемнән күчереп кешеләргә зур портретлар ясап бирә, акварель белән дә, майлы буяу белән дә копияләр ясый ала иде. Май бәйрәме яисә Октябрь бәйрәме җиттеме, авылның мәктәп бинасында, идарә, кибет, почта йортларында аның кулы белән язылган лозунглар эленеп куела. Ул гына да түгел — ул үзенә күрә скульптор да. Аның йортында балчыктан әвәләп ясалган атлар, кеше башлары, төрле уенчыклар табарга була. Һәрбер художник язу-сызу белән дә шөгыльләнгән кебек, ул пьесалар да язгалый иде. Мәктәптә укыган чакта Сәгыйть үзе дә аның бер пьесасында уйнаган иде.

— Сәгыйть кайткан диләр — менә кайда җөри икән ул!— диде Нәсим, күрешер өчен озын бармаклы ябык кулын сузып.— Исәнме, Сәгыйть.

— Әлегә исән,— диде студент, елмаерга тырышып.

— Кайчан кайттың, нигә бер дә күренмисең?

— Минем кайтканга инде бишбылтыр!

— Ни... балыкка бардыңмыни? Кабамы соң?

— Юк, капмый.

Шулай кыска-кыска гына берничә сүз әйтешкәч, Сәгыйть, китәргә җыенган кебек, урыныннан кузгалып куйды. Нәсим белән артык сүз озайтып торуның аңа хәзер кызыгы юк шикелле тоелды.

— Ни... ашыгасыңмыни?— диде Нәсим, аның нәрсә уйлаганын сизеп алган кебек.

— Ашыгам дисәң дә ярый...

— Нигә бер дә кич чыкмыйсың... клубка килмисең?..

Сәгыйтьнең әле авылга кайтканнан бирле бер генә мәртәбә дә кич чыкканы юк иде. Нишләптер вакыт та табылмады, аннан соң, дөресен әйткәндә, теләге дә булмады.

— Нәрсә бар соң анда?— диде ул, сүлпән генә.

Нәсимнең моңа хәтере калды, ахры.

— Нәрсә бар дип ни... үзенә күрә бар инде,— диде ул, гаепле төс белән елмаеп.— Яшьләр җыела, бииләр, җырлыйлар дигәндәй... Кирәк икән, кызлар бар!— Нәсим кеткелдәп көлеп куйды. Ләкин кызлар турында юкка ычкындырды: озын чәчле студентның шундук кашлары җыерылды, күз карашы төссезләнеп, салкынаеп калды. Аның Нәсимгә каты гына, кырыс кына берәр сүз әйтәсе килде, ләкин шундый зарарсыз, эчкерсез кешене нахакка рәнҗетүдән куркып, шундук үз-үзен тыеп калды — ул бит аның Идасы барлыгын, аңа аннан башка бүтән беркем кирәкмәгәнлеген белми иде!

— Клубыңа да өлгерербез әле... җәй озын бит,— диде ул, туры гына җавап бирмичә.

— Озынын озын да... ни, кил әле син, Сәгыйть, шулай да. Сөйләшеп утырырбыз...

Сәгыйть Избачның тел төбеннән аның тагын да нәрсәдер әйтергә теләвен, ләкин хәзер генә ул турыда сүз кузгатырга уңайсызлануын сизеп алды. «Нәрсә турысын гына әйтми соң?— дип уйлап алды ул.— Минем өчен барыбер түгелмени!»

— Ярый, сау бул.

— Чынлап, кил әле, Сәгыйть,— диде Нәсим.

Икенче көнне Сәгыйть «балык каптырырга» бөтенләй бармады. Урманнарның да, елга буйларының да инде кызыгы, яме югалды. Аны хәзер берни дә кызыксындырмады, берни дә күңелен юата алмады. Ул өйдә калды. Аңа моңсу булып китте. Ул бик озын итеп, зарланып Идага хат язды. Хатны шундук почта йортына алып китте. Кайтканда кибет алдында тәмәкечеләр белән гәпләшеп торды; юл уңаенда беренче курсны бетереп кайткан Уфа студенты Хәйбер дигән егет янына кереп чыкты. Аннан соң төш җитте. Төштән соң аны бөтенләй ялкаулык басты. Шулай да ничек тә вакытын үткәрү өчен, Тәлгать янында булашты, аны кулына алды, көлдерде, күккә сикертте. Кичкә таба әнкәсенең бөтен вак-төяк эшләрен эшләп ташлады: казан аска утын чапкалап кертте, бозауларын куалап алып кайтты, хәтта яшь киленнәр кебек, малай чагындагы кебек, чишмәгә суга да чыгып йөгерде. Әнкәсе: «Утыр Тәлгать янында, үзем барырмын. Җегет кеше суга йөрими!»— дип караган иде дә, аның сүзен колагына да элмәде, «Җегет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә әз!»— дигән булды, чишмәдән кайткач, әнкәсенә булышудан үзе өчен кинәт бер күңеллелек, канәгатьләнү табып, көлә-көлә:

— Капка төбендә сыер көтеп тора, тиз генә савып кертимме?— диде.

— Әй, катынша, катынша!..— диде әнкәсе.

Тагын кич булды, кояш тагын лапас түбәсе турысына якынлашты да, күзгә күренмәгән авыш сызык буенча офык астына тәгәрәде. Бөтен юлны тутырып, аркылыга күләгәләр сузылды, көнбатыш яктагы тәрәзә пыялалары, кызгылт очкыннар чәчрәтеп, күзләрне чагылдырып ялтырый башлады. Кичке дымсу һавага яңа сауган сөт исе, чыбык-чабык төтене исе, аш исе таралды. Басу ягында көне буе ишетелеп торган гөрелдек — трактор тавышы кинәт тынып калды. Күз кабакларына, кулга, колакка оятсыз, зәһәрле черкиләр кундылар, бөтен тәнне сырып алдылар, үзәкләргә үтеп тешләделәр. Йөрәген һаман нәрсәдер өтеп торды. Тагын бер көн узды.

Барис белән Гамбәр МТСтан кайтты. Машина мае, керосин, бензин исе аңкыткан керле, пычрак киемнәрен тышка салып калдырдылар да, юынып, чистарынып, өстәл янына килеп утырдылар. Әнкәсе тагын зур табак белән аш китереп утыртты, тагын һәркемнең коштабагына буы чыгып торган кайнар аш бүлеп чыкты. Барис белән Гамбәр үзләренең комбайннары турында, җитешмәгән әле теге, әле бу часть турында сөйләделәр, сөйләшкәндә сүз арасында үзләре генә аңлаган ниндидер сүзләр кыстырдылар, һәм өстәл янында сүз бары тик комбайн турында гына, җитешмәгән частьлар турында гына барды.

Сәгыйть тә баштарак аларга катышмакчы булды, ләкин үзе бөтенләй диярлек аңламаган нәрсәләр турында тыңлап утыру, җитмәсә, шул турыда акыл сатарга тырышу аны тиздән бөтенләй кызыксындырмый башлады.

Барис, энесенең авызын йомып утырганын күреп:

— Бүген ничә балык тоттың... койрыгыннан?— диде, көлеп.

— Бүген беркая да бармадым,— диде Сәгыйть, «көлсәң көләрсең инде, миндә аның кайгысы юк әле»,— дигән кебек, теләр-теләмәс кенә.

— И барма да!— диде Барис, киңәш биргән тонда, җитди итеп.— Ач тамагың җук, балык артыннан чапмасаң да... Капчык тулы бодай утыра, сөт бар, тавыклар күкәй сала — сиңа тагын ни кирәк?! Аша да ят, ял ит рәхәтләнеп. Менә шул.

Сәгыйть, ял итүгә, «балык артыннан чабу»га икенче төрлерәк караса да, абыйсына каршы бер сүз дә әйтмәде, елмайган сыман итеп авыз читен генә кыйшайтып куйды.

— Һи-и, тиатыр була лабаса бүген кылупта!— диде Гамбәр.

— Кемнәр куя? Нинди пьеса?

— Үзебезнекеләр... яшьләр. Ике пәрдәлек писса, аннан соң — кансирт. Барасыңмы?

— Ю-ук,— диде Сәгыйть, иренеп кенә.

Ләкин шул вакыт кичә Нәсим белән булган очрашу, аның клубка килергә чакыруы, нәрсәдер әйтергә теләве исенә төште. «Нигә, барсаң ни була? Күңел ачылмаса да, вакыт үтәр ичмасам»,— дип уйлады ул эченнән һәм бераз кызыксыну белдергән тавыш белән сорап куйды:

— Сәгать ничәдә башлана соң? Соң түгелме әле?

— Һи-и, нинди сәгать ул! Сәгатькә карау юк инде ул авылда — кеше җыелды исә, тоталар да башлыйлар. Әле беркем дә юктыр.

Сәгыйть ашап туйды да ашыкмыйча гына әзерләнергә кереште. Газета белән төрелгән килеш чөйдә эленеп торган костюмын тышка алып чыгып, аның тузаннарын каккалады, селеккәләде, щетка белән әйбәтләп чистартты. Чемодан төбеннән яхшылыкка гына киелә торган ефәк күлмәген, галстугын алды. Кеше арасына чыкканда әйбәтрәк киенеп чыгарга кирәк иде, ни әйтсәң дә — студент кеше, шәһәрдән кайткан кеше. Халыкның күз очлы — шундук бөтен нәрсәңне баштанаяк үлчәп, тикшереп, бәяләп чыгарлар. Аннан соң яшьтәшләрне, бүтән вузларда укучы студентларны да очратуың бар.

Ул киенергә кереште, ләкин өстәге киемнәрен яңалары белән алыштыра башлагач, бу эш аңа бик ялыктыргыч, бик мәшәкатьле булып күренде. «Нигә болай төзәнәм соң әле мин? Кем өчен төзәнәм?» — диде ул, үз-үзенә сорау биреп. Киенүдән, кич чыгудан кинәт күңеле кайта башлады. Аның үз-үзенә, үзенең киемнәренә ачуы килде. Башта беләк будыргычлары, җиң очын эләктереп куя торган каптырмалары табылмады, алары гына табылган иде, күлмәге инде тәненә җайлап кына утырган иде, галстугының рәте китте: төене ычкынды. Аны җайлаганчы әллә никадәр вакыт узды. «Бу эсседә кем галстук тагып йөри соң? Әллә кемнәр юктыр әле!» — диде ул, бөтен нәрсәдән тәмам гайрәте чигеп. Галстугын муеныннан алып өстәлгә ташлады, костюмын салып урындык аркасына элеп куйды — аның иркенәеп, җиңеләеп каласы килде, аңа әле болай да бөтен дөнья тар, бөркү иде.

Миңнисәттәй, ул киенә башлаганнан бирле, сүзсез генә аның һәрбер кыланышын, һәрбер хәрәкәтен сокланып һәм шул ук вакытта җентекләп күзәтеп торды. Аның костюм итәкләрен, күлмәкләрен тотып карады, өстәл читендәге галстугын ипләп кенә урындыкка якынрак китереп куйды, әле алдына чыкты, әле артыннан килеп карады.

— Бу типкеңне киясеңме соң? — диде ул, кадакта эленеп торган кепканы алып.

— Юк, кимим, — диде Сәгыйть, чәчен тararга тотынып.

— Әллә кәчтүмеңне дә кимисеңме?

— Юк, кимим.

— Яңа батинкаңны киясеңме соң?

— Юк, аякны кыса, — диде Сәгыйть, иренеп кенә. Аның аягын чишенеп торасы килмәде.

— Шул буламыни! — диде кинәт әнкәсе ризасызлык белән. — Иске батинка киеп чыгарга! Менә син!.. Миң-

ниса малае кайткан — өсте-башы хәерченеке кебек диярләр... Кит аннан, шул буламыни! Кәчтүмеңне дә ки, типкеңне дә ки, гыластугыңны да так.

— Туктале, әнкәй, кем җәй көне галстук тагып йөри?— диде Сәгыйть әнкәсенә, бик үк каршы килмичә генә.

Ләкин Миңнисәттәй чын-чынлап ачуланырга-тотынды.

— Үзең беләсең тагын... Чыгарга булмыймыни кояш кебек ялтырап, ниең бар — шуны киеп! Хәзер халык културнай, калхуз артта дигәч тә... Бик төзү халык, якшы киенә... Син-ни, авылга ярар әле димәкче буласыңдыр да... Киен, киен, кит аннан!

Студент егетнең күңелен оят кебек бер нәрсә чеметеп алды. Ул аптырап калды, әнкәсенең һич югы хәтерен калдырмас өчен генә булса да, аның теләген үтәргә кирәк иде. Ул яңа туфлиен дә, костюмын да киде, галстугын да такты, хәтта кепкасын да кулына тотты да, аны чоланда калдырып, урамга чыкты.

Вакыт әле, күрәсең, иртә булгандыр — клуб ачылмаган, уку өенә ут алынмаган иде. Күптәнге таныш ис — коры кәгазь һәм тәмәке төтене исе сизелеп торган ярым караңгы бүлмә эченә килеп кергәч, Сәгыйть, кая барырга белмичә, беравык урынында басып торды. Уку өе дип аталган бу зур гына, иркен генә бүлмә клуб йортының бер почмагына урнашкан иде. Уку өенең эчендә, түрдәге почмакта, такта белән бүленеп алынган тагын бер бүлмә бар иде. Сәгыйть, эчке бүлмәнең ябылмый калган ишеге аша ут яктысы күреп, шул якка таба атлады. Бу — Нәсим бүлмәсе иде, анда авыл китапханәсе урнашкан иде.

Өстәл өстенә иелгән көе нәрсәдер эшләп утырган Нәсим, шыгырдап ишек ачылгач та, башын күтәреп карады.

— Ә-ә!— диде ул, сузып, гадәттәге юашлыгына бер дә хас булмаган күтәренке тавыш белән.

Аның ниндидер соргылт таплар белән капланган бәләкәй йөзендә ягымлы елмаю, эчкерсез шатлану билгесе чагылып китте. Ул тиз генә торды да Сәгыйтькә урындык тәкъдим итте.

— Менә гәзит чыгарып утырадырыем әле,— диде ул.— Ни... тиздән печәнгә төшәләр бит. Утыр әйдә, утыр, Сәгыйть. Менә журналлар кара, бүген генә килде. Мин хәзер бетерәм.

«Нәрсә әйтмәкче була икән?»— дип уйлады Сәгыйть, Нәсимнең дүрт почмаклы ак кәгазь өстендә җитез хә-

рәкәтләнгән кулын күзәтеп. Нәсим стена газетасына баш ясап утыра иде.

Менә ул эшен бетерде, кәгазьне түгәрәкләп бөтәрләде дә стенага терәтеп куелган шкаф эченә ташлады. Башы белән түшәмгә кадәр үрелгән озын, яссы шкаф янында ул тагын да бәләкәйрәк булып күренде. Сәгыйть, үзе дә сизмәстән, үзен шул шкаф белән чагыштырды. Ул да, студент Сәгыйть тә, Нәсимнән әллә кайда биегрәк иде һәм шкаф эче белемнәр — китаплар белән тулы булган кебек, аның да башы китаплар белән, белем белән тулы иде, һәм избач Нәсим, никадәр генә аңа тиңләшергә теләсә дә, шул шкаф башына үрелеп җитә алмаган шикелле, барыбер аның кебек була алмаячак иде. Мондый чагыштыру аны үз күз алдында масайтып җибәргәндәй булды. «Үзеңне студент итеп, культуралы кеше итеп тотарга кирәк аның алдында»,— диде ул күңеленнән.

— Бер җомыш барые сиңа,— диде Нәсим, яңадан өстәл янына килеп утыргач.

— Нинди җомыш?— диде Сәгыйть, ул ни әйтсә дә тыңларга әзер торып.

— Даклат сөйләле, Сәгыйть, ә?

— Нәрсә? Доклад?

Сәгыйтьнең кашлары җыерылып китте, йөзендәге ясалма киң күңеллелеге шундук юк булды. «Авыртмас башка тимер тарак! Шуңа гына әзерләнеп торадырыем әле менә!»— дип уйлап алды ул күңеленнән.

— Ни... даклат булмаса, лекция-фәлән дә ярый. Үзең ни телисең.

— Ничек? Кайчан?— диде Сәгыйть, һаман берни аңламыйча, дөресрәге, аңларга теләмичә.

— Яшьләр өчен. Клубта сөйләсәң дә була, шушында да ярый... Үзең ничек телисең...

— Кем куша? Персидәтелме, сикритармы?

— Персидәтел! Аның үзенә даклат укырга кирәк әле даклат укырга кушар өчен... Сикритар да түгел. Ни... мин сорыйм... мин дип, яшьләр. Яшьләргә кирәк. Кыш көне даклат-фәлән еш була торганые, хәзер укытучыларның да койрыгын бик тиз тотып булмый, кайсы кая таралышып беткән. Нигә, сиңа авыр булмас ул, Сәгыйть. Бер якшылыгың тияр. Материал дисәң — табабыз, китабы да, брошуралары да җитәрлек.

— Мәсәлән, нинди темага?

— Чит ил хәлләре турында да ярый, кешенең килеп чыгуы турында, Мичурин турында да... үзең ниндиен телисең — карарбыз...

Сәгыйть, өстәлдәге калын пыялага бармаклары белән

шакылдата-шакылдата, беразга сүзсез калды. Аның әле беркайчан да диярлек халык алдында доклад яисә лекция сөйләгәне юк иде. Ул үзендә бернинди ораторлык сәләте, тел осталыгы юк дип исәпли иде. Дөрес, иптәшләре белән бәхәсләшкәндә ул бик яхшы итеп, ышандыргыч итеп, кайнарланып сөйли ала, кайчакларда хәтта бик нык кызып та китә торган иде. Ләкин күп кеше алдында, тып-тын утырган аудитория алдында сөйләргә туры килсә, кинәт күңелендә булган нәрсәсен азагына кадәр әйтеп бетерә алмыйча, бутала башлый, кызара, тирләп төшә торган иде. Шуңа күрә дә Степка көлеп, аны «ялкынлы трибун» дип атаган иде.

Ярый, монда студентлар түгел, монда — гади авыл яшьләре булачак. Аларны студентлар белән чагыштырып булмый. Нәрсә сөйләсәң дә, авызларын ачып, шуны тыңлап тик утырырлар. Ләкин ни өчен үз өстенә бер дә кирәкмәгәнгә ниндидер мәшәкать, ниндидер тынычсыз эш алып торырга?! Аннан соң авылга ул лекцияләр сөйләп йөрергә кайтмаган ла! Ел буена шул уку, тыңлау, сөйләүләрдән арып, шуларны онытып торырга, көзгә кадәр көч җыярга кайткан! Буа бууда катнашты, алдынгы булып эшләде, мактау алды — үзенең комсомол бурычын үтәде — җиткән шул! Кемнәр җир казымаган, кемнәр балчык ташымаган — сөйләсен шулар...

Избач Нәсимгә аның: «Булмый, туган, юк белән эчемне пошырма, мин инде төзелештә булдым, җиткән»,— дип әйтәсе килде. Ләкин шул ук вакытта ул үзенең нәрсәдәдер хаксыз икәнлеген, Нәсимнең, ул әле генә күңеленнән кимсетеп утырган «белемсез» избачның, кайсыдыр ягы белән үзеннән өстен икәнлеген сизенгәндәй булды.

— Уйлап карарга кирәк,— диде ул, кистереп кенә җавап бирмичә.— Ләкин минем беркайчан да докладфәлән сөйләгән юк бит. Барып чыкмас кебек... Авыр булмас булуын, шулай да барып чыкмас кебек. Сөйләгән юк минем.

— Чыгар! Ник чыкмасын! Барып чыкмаган эш җук икән ул дөньяда!— диде Нәсим, аның сүзенә каршы төшеп.— Мересьев турында укыгансыңдыр ич?— Ул Сәгыйтьнең йөзенә төбәп карады.

Нәсимнең мондый тонда сорау алуы студентка бик үк ошап җитмәде. Аның Мересьев турында бик күп ишеткәне генә бар иде, китабын әлегә кадәр укырга туры килмәгән иде — вакыты булмады. Соңгы вакытта аның гомумән китап укырга вакыты булмый торган иде. Менә сиңа шкаф! Ул үзенең кызарынганлыгын тойды, Нәсим

янында аңа ни өчендер оят булды. Ләкин аның алдында үзеңнең наданлыгыңны күрсәтеп булмый иде инде. Ул, аның сүзен ишетмәмешкә салынып, берни җавап бирмәде.

— Беләсең ич мине,— диде Нәсим, сүзен дәвам итеп, ниндидер яңа хәбәр әйтергә җыенган кебек,— беләсең ич, нинди җебегәнием мин... Җир тишегенә керердәй булган чаклар була торганые. Армиядә җөреп кайткач та бетмәде. Җомшак агачны корт баса, ди, мине теләсә кем бала-чагага саный торганые, көлә дә, тирги дә торганые. Ни... авызыңа су капкан кебек тик торасың. Мересьев турында укыгач, Сәгыйть, чәчләр үрә торды, гарьлегемнән нишләргә белмәдем. Ни... Шуннан соң үземне үзем чыбыклый башладым, аның кебек гимнастика ясыйм — аяк-кул белән түгел... ни... ничек соң... баш белән, ихтыяр белән!

Сәгыйть аның ябык, ямьсез йөзенә игътибар беләнрәк карады һәм бу йөз аңа беренче мәртәбә элеккечә йомыкый булып түгел, бәлки, матур булып, горур, хәтта кыю булып күренде. Ул үзендә аңа карата кызыксыну, ихтирам хисе уянганын тойды, аңа тагын үзе өчен, үзенең әлерәк кенә коры куыкланып утыруы өчен бик уңайсыз булып китте. Ул хәзер аның һәрбер сүзенә колак салырга әзер кебек иде.

— Быел мин сигезенчене бетердем,— диде Нәсим. Үзе турында сөйли алу аның өчен барыбер шул ук кыюлык иде, һәм ул студент алдында әзрәк мактанып алырга уйлады.

— Сигезенчене? Кайда?

— Кичке мәктәптә, районда... Авыр булды башта. Бар да яшьләр диярлек. Мин генә ике бала атасы. Ни... тырышсаң була икән. Бер генә өчле дә юк!

— Унны да бетерәчәксеңме? Аннан соң кая китәргә уйлыйсың, художество академиясенәме, әллә тагын училищегәме?

Өченче ел Нәсим, Казанга художество училищесына керергә дип баргач, барлык имтиханнарын да яхшы гына бирсә дә, әлеге дә баягы шул кыюсызлыгы аркасында, ниндидер сәбәп табып, укырга кермичә кире кайткан иде.

— Җу-ук, Сәгыйть!— диде ул, бераз тантаналы төс белән.— Художник та, скульптор да чыкмады инде миннән. Нефтьче булачакмын мин... инженер... Нефтьче чыгачак!

Ул, артык җәелеп китүен үзе дә сизеп алган шикелле, кинәт тынып калды, аннан соң Сәгыйтькә күтәрелеп карады да:

— Ничек,— диде,— шулай да сөйләп булыр дисеңме?

— Була. Риза,— диде Сәгыйть, үз-үзенә ышанган нык тавыш белән. Аннан соң, әз генә тотлыгып, кызарып, өстәп куйды: — Борис Полевойны бир әле... булса... Мересьев турында, дим, укымаганмын икән, малай...

## VI

Бер килгәч, тиз генә кайтып китәсе килмәде. Сәгыйть «тиатыр» карарга калмакчы булды.

Озакламый уку өенә яшьләр җыела башлады. Иң элек япь-яшь кенә берничә егет килеп керде. Үзләрен зурларча тотарга тырышып, салмак кына атлап, түргә уздылар да, шаулашып, кызыл япманы җыерып, озын өстәл арасына кереп утырдылар.

Сәгыйть, үз алдындагы журналыннан аерылып, керүчеләргә карап алды. Аларны әле чынлап егетләр дип тә атарлык түгел иде, алар әле яңа гына егет булып килгән зур малайлар иде. Ләкин кара чалбар балагын йомшак күн итегенең сырлы кунычыннан чыгарып куйган, бик ачык йөзле, нindидер эчке бер куанычы булган шикелле гел елмаерга гына торган бер малай-егет бүтәннәренә караганда буйга да озынрак, яшькә дә зуррак сыман күренде. Ул инде малай-егет кенә дә түгел иде, ул инде егет иде бугай. Кулларын чалбар кесәсеннән алмыйча, ул, Нәсим бүлмәсенең ишегенә якынлашты да, карлыкканрак, ләкин әле бик үк ныгып җитмәгән калын тавыш белән:

— Нәсим абый, шахмыт бармы?— дип кычкырды.

Сәгыйтьне күреп алды да, тавышын әкренәйтә төшеп, соравын тагын кабатлады:

— Шахмыт бирегез әле, Нәсим абый? Кеше килгәнче уйнап торыйк...

— Рәшит түгелме соң?— диде Сәгыйть, егетне танып алып.

Рәшит тә шундук аны таныды, «һе-ей!» диде дә, уң кулындагы шахмат тактасын сул кулына күчереп, уңын Сәгыйтькә сузды.

— Исәнмесез, Сәгыйть абый? Кайттыгызмы? Казанда ни хәлләр бар?.. Авылда җәм табып буламы?— диде ул олыларча, үзенең яшьтәше белән, элекке дусы белән сөйләшкән кебек.

«Кайчан гына таякка атланып, урамда тузан туздырып йөри торган малай иде, ничек үскән!.. Былтыр комбайнда эшләгән иде бугай»,— дип уйлады Сәгыйть Рәшит турында.

— Бик әйбәт әле,— диде ул, аның белән күрешеп һәм

юри аның тонында сөйләшергә тырышып.— Исән-сау гына кештердәп ятабыз шунда. Эш кырган да юк, тик торган да юк. Казаннар да сау-сәламәт кенә торып калдылар, сезгә сәлам әйттеләр.

Рәшитнең иреннәре ерылып китте, борынының ике ягыннан да иягенә таба дугаланып тирән җыерчыклар сузылды, итләч күз кабаклары тирәсендә кыска гына сызыклар барлыкка килде, елтыр күзләре ярык арасына кереп кысылды.

— Үсеп буламы соң, Рәшит?— диде Сәгыйть, шундый ук җиңелчә шаяру тонында.

Рәшиткә бу һич тә ошамады, ахры, кашлары сизелерсизелмәс кенә тартышып куйды, йөзендәге шат елмаю билгесе сүнә төште.

— Үсәбез, кая ул үсмәгән!— диде Рәшит, сер бирмәскә тырышып һәм кырт кына борылды да, зур-зур атлап, иптәшләре янына китеп барды.

Сәгыйтькә ул нәрсә беләндер Рәшитнең хәтерен калдырды шикелле тоелды. Гаҗәп, ул бит аның белән дусларча булырга тырышкан иде. Нишләп соң бөтен нәрсә бүген аңа гел каршы килеп кенә тора әле?

Анда үз-үзеннән канәгатьсезләнү кебек бер нәрсә уянды. Менә ул Нәсимнең тәкъдименә риза булды. Шәһәрдән күңел чемоданына салып алып кайткан әзер планга беренче төзәтмә кертергә туры килде. Моны ул үз теләге белән эшләде. Ләкин күңеле тынычмы соң? Юк бит, юк, тыныч түгел! Ул нидәндер риза түгел, аңа нидер җитми, нидер кирәк. Аңа монда, бүрәнә араларыннан коры мүк кисәкләре күренеп торган кара стеналы шушы бәләкәй генә бүлмәдә, шушы авыл егетләре арасында хәзер, дөресен генә әйткәндә, күңелсез иде, аңа иркенлек, яктылык җитми шикелле иде. Ни өчен шулай — моны ул һич кенә дә аңлый алмады.

Яшь егетләрдән соң бераз вакыт үткәч, бер төркем кызлар килеп керде. Стена буена терәтеп куелган скамьяларга барып утырдылар да, чыш-пыш килеп пышылдарга, шарт-шорт көнбагыш чартлатырга тотындылар. Алардан соң икенчеләре, өченчеләре керде, һәм бераздан тышкы ишек ачылып-ябылып кына тора башлады. Уку өе берничә минут эчендә яшьләр белән, аларның сөйләшүе, көлешүе белән тулды. Өстәл өстенә башлар иелде, кәгазь шыштырдаткан, өстәл тактасына шакылдатып домино суккан тавышлар ишетелде, идән уртасында әрле-бирле кешеләр кайнашты, стеналарда, түшәмдә, ак тәрәзә кашагаларында күләгәләр биеште. Кайберәүләр кулларына чите чүбекләнеп беткән иске яисә өр-яңа китаплар то-

тып, туп-туры Нәсим бүлмәсенә уздылар. Нәсим исә, керер юлны бүлеп, үзенең тар өстәлен ишеккә аркылы китереп куйды да, бөтен эшен бер читкә ташлап, китап шкафларын ачып җибәрде.

— Эшләре булмаганнар залга чыгыгыз, зал ачык!— дип кычкырды ул, шау-шу көчәя башлагач.

Тиздән бүлмә бушап, иркенәеп китте, тавышлар тына төште һәм уку өендә бары спектакльгә катнашучылар гына торып калды.

Сәгыйть җәйге умарта кебек гөж килеп торган зал ягына чыкты. Инде халык җитәрлек җыелган, урыннарга кешеләр утырышып беткән, соңгарак калганнары тәрәзә төпләренә кунаклаганнар, ишек төбенә, мич тирәсенә, почмакларга өелешкәннәр һәм барысының да күзе сәхнәне каплап торган зур яшел пәрдәгә төбәлгән иде.

Сәгыйть, чәчен артка сыпырып җибәрде дә, кызларның, яшь хатыннарның, бала-чагаларның үзенә юнәлгән кызыксынучан күз карашларын тойган хәлдә, кешеләр башы өстеннән залга карарга тотынды. «Басып торырга туры килер микәнни?» — дип уйлады ул күңеленнән, бераз кәефсезләнеп.

Шул чакны аның артында гына кемдер:

— Исәнме, Сәгыйть,— дип эндәште. Ул тавыш килгән якка борылып карады.

Бик эссе булганга күрә яшькелт солдат кителенең изүен чишеп җибәргән, очлы ияген, сөякчел каты яңагын кара төк баскан, куе кара кашлы Мәрдәншә агай, Сәгыйтьнең кая басар урын тапмыйча идән уртасында аптырап торуын күргәч:

— Урының җукмы әллә, Сәгыйть? Әйдә, утыр, тере сөяк ничек тә сыярбыз әле,— диде, урыныннан кузгала төшеп, һәм үзе янындагы яшьләргә бераз кысылырга кушты.— Менә катын белән эспиттәкел карарга килдек әле. Әйдә, әйдә, сыярбыз.

Сәгыйть, мондый яхшылыкка ничек рәхмәт әйтергә белми торганда, үзен чакырып кул болгаган Гамбәрне күреп алды, юкка борчуы өчен Мәрдәншә агайдан гафу үтенде дә, тыгызланып утырган кешеләрнең аяк очларына, тезләренә, кулларына орынып, кысыла-кысыла, Барислар янына узды.

Бүген ул минут саен диярлек әле бер кеше белән, әле икенче кеше белән исәнләште, кул кысышты. Туган авылының олысы-кечесе — барысы да аның белән чын күңелдән, ачык йөз күрсәтеп сөйләштеләр, аның укуы белән, ял итүе белән кызыксындылар. Һәркемнең игътибарлы, ягымлы, эчкерсез карашын тою, аларның гади, туры сүзләрен ишетү

аңа бик рәхәт булды. Бу анда үзенең эч пошуын, күңел китеклегән онытырга, үзен бәхетле итеп, һич югында — тыныч, иркен итеп сизәргә ярдәм итте. Аны кайчандыр, малай чакта беренче мәртәбә сабан башы тотарга өйрәткән олы кешенең, Мәрдәншә агайның кечелеклеге Сәгыйтьне тагын да күтәреп җибәрде. Аның күңелендә әйбәт, җылы бер хис уянды, аның һәркемгә ни өчендер рәхмәт әйтәсе, һәркемнең яратып кулын кысасы килде.

Гамбәрләр бәләкәй Тәлгатьне дә үзләре белән алып килгәннәр иде.

— Оһо, Тәлгать тә «тиатыр» карарга килгән!— диде Сәгыйть, баланың биләү аша чыгып торган бәләкәй генә, йомшак кына ак кулын тотып.

— Соң ул бит җегет инде, җегет ул! Яхшырак кара тиатырны, улым, кайткач дүрәнкәңә сөйләрсең,— диде Гамбәр, үзенең алдында йоклап яткан малаена сокланып карап.

— Кайда йөрдең?— диде Барис энесенә.

— Көтәбез, көтәбез — җук! Һи-и, сорап торасың, кайда булсын, җегет кешенең-ни, кызлар янында булыр инде!

Пәрдә тартылып куйды. Бер малай, ике куллап чаршау читеннән тоткан көе, аны үз артыннан өстерәп, абына-сөртенә сәхнә аша йөгереп үтте. Залдагы тавыш басыла төште. Иягенә ясалма сакал — кара сарык тиресе кисәге таккан, кашын бик калын итеп карага буяган япь-яшь «карт» һәм битенә курчакныкы кебек итеп түгәрәкләп кызыл сөрткән, чын кыяфәте белән карт күренгән «яшь кыз» сәхнәдә әрле-бирле йөренергә, берберсенә көттереп-көттереп ниндидер сүзләр әйтергә тотындылар. Сәхнәгә тагын шундый ук ясалма кыяфәтле бүтән кешеләр дә кереп-чыгып йөрделәр. Аларның барысы да бик авырлык белән генә хәрәкәтләнде, әйтерсең алар үләр дәрәҗәгә җитеп арыганнар, хәлсезләнгәннәр яисә аларның бик нык йокылары килә иде. «Артистлар»ның куллары, башлары — бөтен гәүдәләре агачтан ясалган кебек, ачу китергеч дәрәҗәдә җансыз, үлек иде.

Сәгыйть аларның сөйләгәннәрен аңларга, күңеленнән үткәрергә тырышты, ләкин бер генә сүзләре дә, бер генә мимикасы, бер генә хәрәкәте дә йөрәгенә барып җитмәде, бер генә хис-тойгы да уятмады, киресенчә, аның күңелсез уйларын көчәйтә, куерта гына төште, һәм ул үз-үзенә ачуы килеп, сәхнәдә кыймылдашучылар өчен, үзе өчен оялып, уңайсызланып утырды. Аның тизрәк тышка чыгасы, саф һава сулыйсы, үзе генә каласы килде.

Пәрдә ябылды, залда ут кабынды, халык тагын шаулаша башлады. Пәрдә артында чүкеч белән шак-шок ка-

дак кактылар, нәрсәләрнедер урыныннан күчерделәр, идәнгә стакан төшеп ватылды. Ун минуттан соң пәрдә тагын ачылды, бакчадагы агачларны гәүдәләндерергә тиеш булган зур фанер янында — дөресрәге, фанерга ясалган агач рәсеме янындагы скамьяда бер егет белән бер кыз озын, авыр сүзләр сөйләп, бер-берсен яратулары турында ләчтит сата башладылар. Сәгыйтьнең эче пошты, күңеле үртәлде. Ул бары фанердагы агач рәсеменә генә карап утырды. Рәсемне, билгеле, Нәсим ясаган иде, һәм ул аңа бик матур булып, чын агач булып күренде.

Һаман әнкәсе алдында таралып йоклап яткан Тәлгать дерт итеп сискәнеп китте, бәләкәй генә кулларын селтәп җибәрде дә, тынып, тыңлап утырган залны яңгыратып еларга тотынды. Якындагы кешеләр, кайсы елмаеп, кайсы ачуланып, шундук Барислар ягына — тәртип бозган гражданинга борылып карадылар. Гамбәр, кешеләрдән уңайсызланып, ашыгып, Тәлгатьне юатырга тотынды. Ләкин малай елавыннан туктамады. Ул арада алдагы скамьяда утыручы ана белән атаның да кызчыклары үзе ише кешенең тавышын ишетеп алды, ахры, нәрсәдәндер риза булмыйча, шыңшырга кереште. Аның да тиз генә авызын капламакчы булып пышылдарга, кабаланырга тотындылар. Әмма залда яшь балалылар ярыйсы гына иде. Тәлгать белән аның күршесенә тагын бер бәләкәй тамашачы тавыш бирде. Һәм кинәт таң атканын белдереп, бер-берсенең тавышын тыңлый-тыңлый кычкырышкан яшь әтәчләр шикелле, анда да, монда да берьюлы берничә бала акырып еларга тотынды.

Алдагы рәтләрдән ниндидер ир кеше, ачуланып:

— Иптәшләр, тыегыз балаларыгызны!— дип кычкырды.

Әмма, аның кисәтүенә дә карамастан, балалар тавышы һаман көчәйде, бөтен бер хорга әйләнде, һәм халык, инде ун минуттан бирле бер-берсен төче, буш сүзләр белән сыйлаучы егет белән кызга бөтенләй игътибар итмичә, үзе дә сизмәстән, яшь тамашачылар тавышына кушылып, тыела алмыйча көләргә тотынды.

## VII

Спектакль төн уртасына кадәр сузылды. Халык таралыша башлагач, Сәгыйть тә Барислар белән кузгалды. Гамбәр, ишек янына килеп җиткәч, үзләре артыннан ияргән Сәгыйтьне күрде дә, бик гаҗәпләнгән булып:

— Сәгыйть, кая болай?.. Әллә без картларга иярмәкче буласыңмы?— диде.— Кал уенга. Кулда менә бу булма-

са, белериек әле нишләргә кирәген, әйеме, карт?.. Матур кызлар күп хәзер авылда.

Җанагасына карата күңелендә бернинди начар уй сакламаган беркатлы җиңгәйнең ике сүзнең берендә «кызлар» дип авыз ачуы Сәгыйтькә бөтенләй ошамады. Ул аңа берни дә җавап кайтармады.

Алар артыннан йөткеренә-йөткеренә Нәсим килеп җитте.

— Кайтмале, Сәгыйть, хәзер уен була,— диде Нәсим, аның аркасына кагылып.— Менә без дә катын белән калабыз. Карап булса да утырырбыз.

Сәгыйтькә барыбер иде, ул кыстатып тормады.

Олыраклар чыгып бетте, япь-яшьләрне куалап чыгардылар, клубта тулы хуҗа булып яшьләр генә торып калды.

Халык чыгып киткәннән соң тәртипсез рәвештә торып калган, гадәттәге урыннарыннан кузгатылган аркалы озын скамьяларны күз ачып йомган арада арткы почмакка ташып, берсе өстенә берсен өеп куйдылар. Утырыр өчен дип, стена буйларында берәр рәт кенә скамьялар калдырдылар да, гармунчыга идән уртасына бер урындык китереп куйдылар.

Уен бик тиз башланып китте. Башта кызлар, егетләр, кулга-кул тотынышып, җырлап әйләнделәр, аннан соң — җырны һаман туктатмыйча — парлы уен уйнадылар. Уеннар һаман үзгәрә торды, җыр көйләре алмашына торды. Күз алдында бертуктаусыз гәүдәләр бөтерелде, куллар җилпенде, тигез такта идәндә биек, тәбәнәк, яссы үкчәле туфлиләр, ботинка, күн итек табаннары шапылдады-шакылдады, һәм борын төбеннән генә җилбер-җилбер җилләнеп, төрле төстәге, төрле бизәктәге озын, кыска итәкләр бөтерелеп узды, балтырлар, чалбар балаклары чалынып калды. Кемдер Сәгыйтьнең кулыннан килеп тотты. Аның икеләнеп торуына да карамастан, урыныннан тартып торгыздылар да, чарага куймыйча, көлешә-көлешә, үзләре белән ияртеп киттеләр. Ул, ниндидер кызларның кулыннан тоткан көе, түгәрәк әйләнде, җырлады, хәтта уртага да чыкты һәм бер кыз белән култыклашып биеп тә алды. Ул тирләп төште, аңа яңадан күңелле була башлады.

Бөтерелгән, кайнашкан, чайкалган зал туктап калды, җыр тавышлары, шыштырдау, шапылдаулар басылды, барысы да, уртада ачык урын калдырып, читкә таралдылар. Бүген сәхнәдә гашыйк егет ролен уйнаган һәм кулларын-аякларын кая куяр урын тапмыйча, әле бер урында таптанып торган, әле килешсез, авыр хәрәкәтләр ясаган Галәү — колхоз шоферы — уртага йөгереп чыкты да,

ясалма тантаналы тонда, комик-конферансьеларга охшатырга тырышып:

— Янтык авыл яшьләре... гафу! Авыл картлары кичәсенең чираттагы номерында: аерым бию, җыр һәм башкалар!— дип белдерде.

Галәү клуб активистларыннан санала һәм уеннарны һәрвакыт үзе башлап йөрергә ярата иде. Аның түгәрәк, тере гәүдәсендә, бик җанлы, тиз үзгәрүчән һәм бераз көлке кыяфәтендә чыннан да артистлык галәмәтләре сизелә иде.

Тыпыр-тыпыр килүдән әле генә туктаган һәм ычкынып китәргә җаен гына көтеп торган җиңел, дәртле аяклар кузгалып куйды, йөрәкләр җилкенеп типте.

— Башта үзең бие!

— Әйдә, Галәү!

— Сиптер!— диештеләр төрле яктан, аңа көч бирергә теләгәндәй.

Галәү ялындырып-нитеп торырга уйламады да: костюмын салып бер малайга тоттырды, алсу күлмәктән генә калып, ботларына шапылдатып сугып алды. Залдагы кешеләргә дә, аларның күңел ачуларына да — дөньядагы бернигә дә исе китмәгән шикелле, күзләрен әле бер ноктага, әле икенче ноктага йөрткәләп утырган эре кыяфәтле гармунчыга каш сикертеп: «Әпипә!»— дип кычкырды һәм кулларын югары күтәреп, бармакларын шартлата-шартлата, җиңел, йөгерек адымнар белән түгәрәк әйләнеп биеп китте. Аннан соң гармун тавышына гына риза булмаган сыман, үзенә-үзе дәрт биргән кебек, кулаякларының тигез, ритмлы хәрәкәтләренә туры китереп, такмаклар әйтергә башлады:

Бас, кызым, Әпипә,
Син басмасаң — мин басам,
Синең баскан эзләреңә
Мин дә китереп басам!..

Анысын бетергәч, тавышын кырт кына үзгәртте дә, җилкенеп-җилкенеп, икенче куплетка тотынды:

Безз бас-сабыз, бас-сабызз,
Менә шулай бас-сабызз!
Күрмәгәннәр күреп калсын —
Бас-са Галәү абзагызз,
Их, ха-ха... һа-һа!..

Кинәт ул, кызлар биегәндәге кебек итеп, уң кулын чигәсе турысына китерде, сул кулы белән уңының терсәгеннән тотты да, шулай төрлечә кыланып бии-бии, залны әйләнеп чыкты. Аннан соң кулларын бик нык селтәп,

очына-очына, табаннары белән идәнгә шапылдатырга тотынды. Шул вакыт гармунчы, әллә биюче белән алдан ук килешеп куйганга, әллә аның гадәтләрен болай да яхшы белгәнгә, тиз генә икенче көйгә күчте, һәм Галәү күз ачып йомганчы рус биюенә керешеп китте. Идәнгә сеңгән кебек, кисәк кенә чүгәләде дә, әле бер аягын, әле икенче аягын читкә ташлап, куллары белән беркая тотынмыйча, аяк бармаклары очында сиптерә башлады.

Һәркем кузгалырга да, тын алырга да кыймыйча, шаккатып, елмаеп, идән уртасында бөтерелгән җанлы бөтерчекне күзәтте. Менә Галәү уң аягын читкә сузып җибәрде һәм идәнгә сул аягының үкчәсе белән генә тиеп торган көе, зырылдап әйләнергә тотынды. Кисәк кенә бөтен гәүдәсе белән югары атылып, кулларын җәеп җибәрде, ике аягына басты да, искиткеч осталык, җиңеллек белән яңадан тыпырдап китте, шундук зал читендә җыелышып басып торган кызлар каршысына килеп җитте һәм, аларның берсен биергә чыгарга чакырып, такта идәнгә тыпырдатырга керешге.

Зал, калай түбәгә көтмәгәндә шыбырдап бозлы яңгыр яугандагы тавыш чыгарып, бердәм кул чаба башлады. Биергә чакырылган кыз исә, бары тик Галәүнең тәкъдимен генә көтеп торган шикелле, күлмәк итәкләрен җилфердәтеп, шундук җиңел генә кузгалып китте.

Аның артыннан тагын бер кызны, тагын бер егетне биеттеләр. Уен, күңел ачу дәвам итте.

Ишек төбендә өелешеп торган малайлар арасында шулчак ыгы-зыгы башланды. Яңадан үз роле белән үз костюмына кереп өлгергән Галәү, тирләгән, кызарган битен сөртә-сөртә, йөгереп ишегалдына килде. Башына яңа түбәтәй кигән бәләкәй генә Фәүзине кулыннан тотып алды да күтәреп иңбашына утыртты. Фәүзи тыпырчынды, елак тавыш белән нидер кычкырды, Галәү исә уйлап та бирмәде һәм аны, бөтенесенең көлешүе, шау-шуы астында, зал уртасына алып килде. Буш урындыкка утыртты да идәнгә төшеп киткән түбәтәен башына кидереп куйды.

Фәүзи шундый бәләкәй, шундый сабый иде, Сәгыйть аның зурларга күрсәтерлек нинди дә булса һөнәре булуына шикләнеп куйды, ләкин шулай да бүтәннәр кебек кызыксынып көтә башлады.

Галәү Фәүзи алдына аның үзеннән дә зур гармун китереп утыртты. Фәүзи, кинәт тынычланып, күптән өйрәнелгән бер гади эш башкарган шикелле, гармунның киң каешын аркасына киде дә, өч-дүрт метрдан да көчкәкөчкә генә күренгән нечкә, көчсез бармакларын басма-

ларга тидереп алды. Урынына җайлабрак утырды да тыныч, җитди йөз белән Галәү абзасына текәлде. Аның каткан, ярылып беткән шәрә аяклары, идәнгә җитмичә, урындыктан асылынып калды.

— Авылыбызның бөек гармунчысы — бәләкәй Фәүзи! «Яңа каз канаты»!— диде Галәү, кычкырып.

Фәүзи уйный башлады. Гармун телләре, кинәт шушы елак малайга буйсынып, искиткеч чиста, саф тавышлар чыгарды һәм залда һәркемнең күңел кылларын тибрәндерерлек тигез, ашкынулы көй агылды.

Сәгыйть, музыкадан әллә ни шәп белгеч булмаса да, халык көйләрен һәрвакыт яратып тыңлый торган иде. Ул Фәүзинең никадәр оста уйнавын тиз генә бәяли алмады һәм бәяләргә дә теләмәде, шулай да аңа гармун күриген дә ныгытып тартырга көче җитмәгән шушы бала чын гармунчы булып күренде, аның уйнавы шундый хисле, шундый дәртле һәм гаҗәп дәрәҗәдә сокландыргыч булып тоелды.

Фәүзидән тагын ике көй уйнаттылар. Шуннан соң ул гармун каешын иңбашыннан алды да, бүтән уйнарга теләмәвен белдереп, китәргә җыенды. Аның тагын уйнавын сорадылар, кызлар мактау сүзләре кычкырдылар, көлделәр, кул чаптылар. Фәүзи идәнгә сикереп төште: «Беләк талды ла!»— диде дә, сул кулы белән чалбар балагын тотып, уң кулы белән башындагы зур түбәтәен рәтли-рәтли, ишек төбендәге малайлар янына йөгерде. Барысы да эчләре катып көләргә тотындылар. Галәү, малайның артыннан җитеп, аны тотып алды, ике куллап югары күтәргән көе, түгәрәк ясап, зал уртасыннан әйләнеп чыкты.

— Ур-ра! Фәүзи!

— Җитәр, күп җөртмә, ыштаны төшеп калыр!— дип кычкырдылар тирә-яктан.

Галәү малайны идәнгә төшереп җибәрде һәм, шау-шу басыла төшкәч, кулын күтәреп:

— Уен тукталмады! Аерым номерлар дәвам итә!— дип белдерде.

Галәү, үргән чәчен түбә өстеннән уратып, артка җибәргән урта буйлы, шундый сылу, шундый түгәрәк йөзле бер кыз янына килде. Сәгыйть кызны шундук танып алды. Йөрәге шул вакыт әйтерсең кисәк кенә урыныннан кузгалып куйды.

Бүген инде кичтән бирле күп кенә кызлар белән очрашуына да карамастан, алар белән күзгә-күз карашып сөйләшүенә, култыклашып биюенә, кайберләренең хәтта матурлыгына соклануына да карамастан, аларга карата

ул күңелендә ниндидер салкынлык, катылык, кырыслык саклаган иде. Аның күңеле «читләр» алдында искиткеч тыныч, аек, горур калган иде. Хәзер анда көтмәгәндә ниндидер ят нәрсә уянды. Ул шушы япьяшь кызда, аның йөзендә, аның бөтен торышында үзенең Идасын күргәндәй булды. Бу бик гаҗәп, бик сәер тойгы иде. Аннан да гаҗәбрәге — ул кыз аның күршесе иде.

Сәгыйть, сокланып, исе китеп, Зәйтүнә ягына карап торды. Заһирҗан агай кызы, Фәүзинең апасы Зәйтүнә аның күз алдында диярлек үсте. Сәгыйть аның үзе ише малайлар белән чабышып, качышлы уйнап йөргән чакларын исенә төшерде. Ул бик чая, тиктормас бер кызый иде, шуның өстенә (Заһирҗан агайның теләсә кайсы баласы кебек) бар якка да уңган, булдыклы кыз иде. Сәгыйть беренче курсны бетереп кайткан елны ул әле шундый ябык, шундый чандыр һәм озын торыклы бер бала гына иде. Быел унынчыны бетерә бугай... Чын-чынлап кыз кеше булган, чын-чынлап җиткән кыз булган. Гәүдәсе тулыланган, формалашкан, билләр сыгылып тора. Күз карашында — оялчан, мөлаем тыйнаклык һәм шул ук вакытта — көчле дәрт, саф, керсез яшьлек нуры. Менә нинди сылу икән, менә нинди чибәр икән ул аның күршесе!

Зәйтүнәгә ныграк караган саен, Сәгыйтьнең күңеле һаман нигәдер тынычсызлана барды, йөрәге әллә нишләп сулкылдап-сулкылдап типте. Әйе, ул үзенең Идасын тагын исенә төшерде. Ул үзенең хәзерге ялгызлыгы турында, Иданың кайдадыр еракта булуы һәм аннан һаман хат-хәбәр килмәве турында уйлады.

Зәйтүнә буй-сыны белән дә, кыяфәте-чырае белән дә Идага бөтенләй охшамаган иде. Ида ак, ә бу — каракучкыл иде. Моның йөзе дә Иданыкы кебек тулы, түгәрәк иде, ләкин аныкына караганда шундый яшь, шундый сабый иде. Ул аннан буйга да тәбәнәгрәк, яшькә дә, әлбәттә, яшьрәк иде, төскә-биткә килгәндә — Зәйтүнәдә табигый матурлык күбрәк иде бугай. Шулай да кайсыдыр җире белән ул — Ида иде. Әйе шул, кайсы ягы белән, нәрсәсе белән охшый икән соң ул аңа? Кай җире белән бу кызый аның күңелендә көчләп яшеренгән тынгысыз хисне уятып җибәрде икән соң? Үзенә карата аның Сәгыйть абзасында хис-фәлән тудыра алуы турында әйтеп тә торасы юк. Моның өчен әле ул артык бәләкәй, артык көчсез, ятим. Ул әле яңа гына шытып, яңа гына күтәрелеп килә. Аннан соң Сәгыйть абзасында хәзер бер генә кыз да үзенә карата нинди дә хис тудыра алмаячак. Бу — аның өчен ташка чокып язылган закон. Шулай да

ни өчен ул аны аңа охшатты икән соң? Күрәсең, студент егетнең мәхәббәт мәсьәләсендә үткер күзе андагы зур, бөек үзгәреш дәртен, аның бөтен торышыннан, бөтен күз карашыннан тышка бәреп торган эчке шатлык, бәхет нурын сизеп алгандыр, шуны бөтен йөрәге белән тоеп аңлагандыр. Әйе, бәлки шулайдыр.

Галәү, Зәйтүнә янына килгәч, башын бераз ия төшеп, аңа нидер әйтте дә, колакка каты кеше сыман, колагын кызның авызына якынрак китерде. Зәйтүнә, башын артка ташлап, көлеп алды. Галәү һаман нидер сөйләнде. Сәгыйтьнең Галәүгә ачуы килә башлады. Үзенең тупаслыгы, кыланчыклыгы белән ул яшь кызның сафлыгын, матурлыгын хурлый шикелле тоелды, Зәйтүнәнең исә үзен шулай мыскыл итүләренә риза булып торуы бик гаҗәп, бик аяныч булып күренде.

Галәү Зәйтүнә яныннан кузгалып китте, озын, ямьсез кулларын алмаш-тилмәш селтәп, яңадан уртага чыгып басты. Ул, гомумән, гел уртада чуалырга ярата иде бугай.

— Атказанган җырчыбыз — Зәйтүнә!— дип белдерде Галәү һәм бераз гына тынып торгач, өстәп куйды: — Кул чабып каршы алыйк!

Яшьләр кыймылдашып куйдылар, скамья, урындык шыгырдаткан тавышлар ишетелде, арттагылар, кешеләр арасыннан кысылып, алгарак үтәргә тырыштылар. Залдагылар дәррәү күтәрелеп кул чабарга тотындылар.

Зәйтүнә, башын кыяр-кыймас кына югары күтәреп, зал уртасына таба атлады. Түшәмгә эленгән зур лампочка астынарак килеп туктагач, аның йөзенә яктылык күбрәк сибелде, һәм Сәгыйтькә аның күкрәгенең сизелер-сизелмәс кенә бер күтәрелеп, бер төшеп торуы да, кара-кучкыл битенә, колак очларына йөгергән җиңелчә кызыллык та, кара, түгәрәк күзләрендәге гүзәл оялчанлык та күренде.

Зәйтүнә, тигез ак тешләрен күрсәтеп, шундый тыелгысыз, шундый шат елмаю белән елмаеп җибәрде — Сәгыйтьнең дә ирексездән иреннәре ерылып китте; бөтен тәне буенча нindидер җиңеллек, җылылык йөгерде.

— Әллүки!— диде Галәү, яңадан уртага чыгып.

Зәйтүнә, кулларын бер-берсенә китереп кушырган көе, эчке дулкынлануын ничек тә сиздермәскә тырышып, үз тирәсенә бер күз карашы ташлап алды да, каядыр еракка, бушлыкка текәлеп, җырларга кереште...

Чыңлап торган чиста, моңлы авазлар, каяндыр бик-бик ерактан, кояшлы, чалт аяз күк төбеннән чыгып, электр нурлары кебек, идәнгә, түшәмгә, тирә-якка коела, тарала башлады. Сәгыйтькә күңеленең ул моңарчы

беркайчан да белмәгән ниндидер бик нечкә кылы искәрмәстән бик каты тартылып, зыңлап киткән төсле тоелды. Ул, бармак кыймылдатырга да батырчылыгы җитмичә, ялгыш ишетмим микән дигән сыман, әле күршеләренә — бер-берсенә сыенган көе тынып калган кешеләргә — әле зал уртасындагы җырчыга күз йөртте.

Саф, салмак тавыш, әле бик үк җитлекмәгән яшь тавыш һаман үсә, һаман югары күтәрелә барды, бөтен залны, бөтен күңелләрне гаҗәеп моң белән, йөрәк өзгеч, җан тетрәткеч моң белән тутыра барды. Әйтерсең зал эченә көтмәгәндә көзге урман җиле исте һәм үзе белән соңгы кояш нурларына коенып, моңсу гына тирбәлеп, чайкалып утырган агачлар шаулавын, саргайган яфраклар шыштырдавын һәм бушап калган ашлык басулары тынлыгын алып керде. Тора-бара бу моң иң каты йөрәкләрне дә ярылырга мәҗбүр итәрдәй булып үсте, күңелләрнең моңа кадәр басылып яткан иң нечкә, иң газиз хисләренә барып тиде, әйтерсең кешеләрне үзенең канатларына утыртып, салмак кына, җиңел генә каядыр очыртып алып китә башлады. Рәхәт тә, коточкыч та иде.

Җырчының тавышы нгыганнан, нгыды, ниһаять, ул, ярларына тулып аккан көчле елга кебек, көчәнмичә, киерелмичә, сихерле авазларын иркен генә, талгын гына агыза торды.

Сәгыйть җырның бигрәк тә күтәренке урыннарында бөтен тәненең тетрәнеп, чымырдап киткәнен тойды, аның чәч төпләренә тыелгысыз, рәхәт салкынлык йөгерде. Күзләрен яшь пәрдәсе каплады. Аның әле беркайчан мондый нәрсә кичергәне юк иде бугай.

Баскан, утырган урыннарына берегеп калган, сихерләнгән, онытылган кешеләр, җыр туктагач та, күңелләренә артылып тулган ниндидер чиста, үтә күренмәле нәрсәне чайпалдырудан курыккан сыман, селкенмәделәр дә ичмасам. Куалап чыгарганнан соң тагын кереп тулган малайлар, ишек тоткасына тотынган көе, авызларын ачып катып калганнар иде, шат күңелле, пошмас Галәүнең йөзенә караңгы җитдилек билгесе чыккан иде.

Сәгыйть якында гына ниндидер бер малайның кулбашына таянып торган Рәшитне күреп алды. Аның бу минутта бик уйчан булган күз карашында, бөтен кыяфәтендә җырга гына түгел, бәлки, җырчының үзенә дә ачыктан-ачык соклану, ис китү билгесе бар иде бугай. Сәгыйть, тәҗрибәле гашыйк буларак, Рәшитнең күңеле Зәйтүнәгә карата бик үк тыныч түгел икәнлеген сизеп алды. «Нигә, бер-берсенә бик пар килгәннәр!»— дип уйлады ул күңеленнән, кем беләндер бәхәсләшкән шикелле.

Менә Зәйтүнә ипләп кенә, тыйнак кына башын иде дә, шулкадәр күп кеше булган залдагы тирән тынлыкка сәерсенгән шикелле, тагын да ак, тигез тешләрен күрсәтеп, елмаеп җибәрде. Һәм, гаҗәп хәл, Сәгыйтьнең тагын да ни өчендер елмаясы килде.

Кинәт исенә килгән халык ду килеп, буран уйнатып кул чабарга тотынды. Көчле һава дулкынына тәрәзә өлгеләре дерелдәде, стенадагы ике почмагыннан гына эләгеп торган бер плакат, кнопкаларын куптарып, әкрен генә, теләр-теләмәс кенә идәнгә очып төште.

Зәйтүнәне тагын җырлаттылар, тагын кул чаптылар, ләкин башта алган беренче тәэсир Сәгыйтьнең күңелендә саф, тулы көенчә һаман сакланып калды.

Ул үзен ничектер чистарып, җиңеләеп калгандай хис итте. Көндәлек борчулары, вак-төяк кайгы, сагынулары, әйтерсең көчле җил исеп киткәннән соң очып бетә торган тузан кебек, өстеннән сыпырылып төште. Ул каядыр югарыга, биеккә күтәрелде, кисәк кенә үсеп, ныгып китте. Юк, Зәйтүнәнең җырлавыннан соң гына түгел,— ул инде баядан бирле, шушы яшьләр белән җырлап, биеп әйләнгәннән бирле, аларның шат уеннарына карап торганнан бирле үзендә яңа бер омтылыш, яңа бер теләк уянганын сизде. Ә Зәйтүнәнең җыры моңа тагын да ныграк этәргеч кенә булды. «Көн дә килергә кирәк монда!»— диде ул үз-үзенә, моңа кадәр бу турыда уйлап та карамавына аптырап.

Ул берүзе генә кайтты. Инде таң атып килә иде. Алда да, артта да төркем-төркем яшьләр тавышы ишетелде, авылның югарыгы очында да, түбәнге очында да, кайдадыр кемнәрдер гармун сыздырдылар. Күңеле белән ул яңадан клуб залына әйләнеп кайтты, яңадан Зәйтүнәнең идән уртасында басып торуын күрде, аның искиткеч моңлы, чиста тавышын ишетте. Ул тагын да аны үзенең Идасы белән чагыштыруы турында уйлады, Ида белән аның арасында ниндидер охшашлык табуы турында һәм моның үзендә татлы хисләр уятуы турында, аның җырлавының ни өчен шулкадәр күңелгә нык барып җитүе турында уйлады.

Нәрсә, мәсьәлә монда бары тик җырчыда гынамы соң әллә? Әллә соң — җырда дамы? Әйе шул, ни өчен шундый көчле, шундый күңелгә, йөрәккә үтемле икән бу борынгы җырлар, борынгы көйләр? Һәм, киресенчә, ни өчен бүгенге көндәге дистәләп, йөзәрләп язылган көйләрнең күбесе күңелгә, йөрәккә түгел, хәтта колакка да барып җитми икән, дөресрәге, бер колактан кереп, икенчесеннән чыгып китә дә, бернинди эз, бернинди тәэсир калдыр-

мыйча, шундук онытыла икән? Бәлки, аларга борынгы җырлардагы кебек табигый моң, көчле хис, көчле йөрәк дәрте җитеп бетмидер?..

Кинәт аның артыннан ак якалы бер кара шәүлә куып җитте. Куып җитте дә ашыга-ашыга узып та китте. Сәгыйть, иснәнә-иснәнә, абына-сөртенә һаман үз юлында булды.

Бераздан, инде өйләренә якынлашып килгәндә, әлеге ак яка тагын очрады. Ул хәзер, теләр-теләмәс кенә атлап, каршыга таба килә иде. «Рәшит ич!» — диде Сәгыйть күңеленнән, караңгыда аның хәтта йөзен дә танып алып.

Заһирҗан агайлар йорты турысына җиткәч, ул ирексездән шул якка борылып карады. Ут балкыган тәрәзә аша, бүлмә эчендә кыймылдаучы Зәйтүнә шәүләсен күреп алды. «Менә кем артыннан килгән!— дип уйлады Сәгыйть, Рәшитнең икенче мәртәбә очравын исенә төшереп.— Ләкин нигә алай бик тиз борылды икән соң ул?..»

## Өченче бүлек

### 1

Ниһаять, көтелгән хат килде. Сыек зәңгәр конверт, берничә кеше кулында булып, таушалып беткән, артында да, алдында да печать сугылган.

Хатны бөтенләй көтмәгәндә китереп бирделәр. Сәгыйть бу кадәр зур шатлыкка башта каушап калды. Кинәт хәлсезләнгән бармаклары белән тиз генә конвертны ачты да аның эченнән бер бит дәфтәр кәгазе чыгарды. Ул укырга тотынды. Бер укып чыкты — туймады, икенче мәртәбә укыды — барыбер күңеле булмады. Сүзләрнең мәгънәсенә башта бөтенләй игътибар итмәде, аларны башыннан түгел, йөрәгеннән генә кичерде. Хатны өченче мәртәбә укыганда, ул инде анда нәрсәдер язылганын да аңлый башлады.

Сөенде дә, көенде дә.

Сөенде шуның өчен, чөнки бу хат Иданың барлыгы турында, аның дөньяда яшәве, аны — Сәгыйтьне — онытмавы турында, аның соңга калып булса да, үз вәгъдәсен үтәве турында сөйли иде. Бу анда яңадан үз-үзенә, аңа ышаныч тудырды, әле кайчан гына күңелен туктаусыз газаплаган шик-шөбһәләрне җуеп ташлады. Хат кәгазеннән аңа хәтта аның исе, таныш ис килә шикелле тоелды.

Көенде шуның өчен, чөнки хатны укыганнан соң туган шатлык хисе көткәнгә караганда әзрәк, көчсезрәк булды. Күңелендә хәтта канәгать булмау кебек бер нәрсә утырып калды. Хат кыска, бик кыска, ифрат та кыска иде. Бер бит кәгазьнең бер ягы гына тулганчы язылган, икенче ягы яртылаш ак көе калдырылган иде. Ә бит ул аның авылга кайтканнан бирле нишләве, нәрсәләр уйлавы, көннәрен ничек уздыруы турында тулы итеп, киң итеп язылган хат күрергә теләгән иде, шуны өмет иткән иде, аның да үзе кебек үк дүртәр-бишәр битле хат җибәрүен көткән иде. Һәрбер гашыйк кызның да, һәрбер гашыйк егет кебек, озын-озын хатлар язарга һәвәс түгеллеген ул әле белми иде.

Ул хатның кайчан язылуына игътибар итте. Ида аны үзләренең авылына кайтып, кимендә бер атна торгач язган иде. Бер атна! Ул аны бер атна буе онытып торган, бер атна буе аның турында уйлап та карамаган! Бу инде һич тә башка сыйдырырлык нәрсә түгел иде!

Ул торган саен күңелсезләнә барды.

«Монда страшно күңелсез, эч поша, просто ужас!» —

дип укыды Сәгыйть инде дүртенче мәртәбә һәм канәгатьләнеп уйлап куйды: «Аңа күңелсез — шулай булгач, ул мине сагына!» Хатның ни өчен соңга калып язылуы турында бернинди сүз юк иде. Сәгыйть уенча, бу — аның ике арадагы килешүне бозуы өчен гафу үтенмәвен, аның белән аңлашырга теләмәвен күрсәтә иде. Әйе, ул аңа ни өчен шулкадәр озак вакыт хәбәр итмәве турында берни дә әйтмәгән. Бу исә Сәгыйтьнең канәгать булмау тойгысын тагын да ныграк арттыра төште. Инде хатның азагындагы берничә юл аны яхшы гына уйланырга да мәҗбүр итте.

«...*Ике хатыңны алдым,*— дип язган иде Ида.— *Әнием турында борчылгансың, авыруы опасный түгелме, дисең. Сәгыйть, мин бит теге вакытта, группа җыелышында, хат килде, дип юри әйттем. Ну, аңлыйсыңдыр инде... Әниемнең авыруы бер бүген генә түгел, хронический аның... вообщем, сау-сәламәт дияргә була. Мин сиңа ул чакта дөресен әйтмәкче булган идем дә, батырлык җитмәде. Күзгә-күз карап әйтүгә караганда, хатка гына язу җиңелрәк. Минем анда авыл хатыннары кебек кызыл балчыкка пычранып йөрүемә үзең дә каршы килер идең әле, әйеме?.. Шул гына нехватало еще!..*»

Сәгыйть хатны бөкләп костюм кесәсенә салып куйды. Ул аны бүтән алып карамады. Аның башында берберсенә капма-каршы булган мең төрле уйлар кайнашты.

Димәк, буа буарга барудан ул курыккан, шуңа күрә... ялганлаган... Кайчан гына булмасын, кем алдында гына булмасын, һәрвакыт дөреслекне сөйли торган, алдашу, ялганлашуны җаны-тәне белән күрәлми торган саф күңелле Сәгыйтьне башта бу хәл чиркәндереп җибәргәндәй булды. Ул моны ничек дип аңлатырга да белмәде. Шундук Иданың политэкономиядән имтихан биргән чакта әйткән сүзләре исенә төште. «Менә сиңа физик хезмәт белән акыл хезмәте!»— дип куйды ул, көрсенеп.

Ярар, буа буарга бармаган икән — бармаган, ансы инде узган эш, берәр доклад-фәлән сөйләр дә авылларында, шуның белән эше дә бетәр. Ләкин моның әле икенче ягы бар. Болай булгач, аның әнисе турында ул юкка гына кайгырган булып чыга түгелме соң? Аннан соң аның хат язмавының сәбәбен дә шуннан, ягъни әнисенең чирләвеннән эзләү, шуның белән үз-үзеңне юатулар, алайса нигезсез булып чыга түгелме соң? Ул бит аның әнисен үз әнкәсе кебек үк яратып өлгергән иде. Аның хәле куркыныч булмавы бик яхшы, әлбәттә. Бик шәп хәтта. Тик... Нигә дөресен әйтмәде икән соң ул шулай да? Ул бит аны

аңлар иде, барасың килми икән, барма — көчләмим, дияр иде.

Аңа Ида түгел, бәлки ул үзе нindидер ярамаган, начар эш эшләгән кебек тоелды һәм әйтерсең менә хәзер шуның өчен кызарырга, газапланырга туры килә иде. Һәркемне, бигрәк тә үзенең сөйгән кызын, үзе кебек үк булырга тиеш, дип исәпләргә гадәтләнгән егет әз-мәз генә ялганлауның кайбер кызлар өчен әллә нинди зур гөнаһ саналмавын әле белми иде. Ләкин тора-бара баштагы кире тойгы сүрелә төште, онытыла башлады. Күңелендә бары тик аның хаты гына, аның «эч поша» дигән сүзләре генә, ул үзе генә торып калды. Бераздан ул бөтенләй күңелләнеп: «Тапкан кайгырыр нәрсә!— диде үз-үзенә.— Ялганлаган икән, ялганлаган — нәрсә булган аңа? Хәзер инде ул үзенең ялганын, шушы хатында, миңа язган хатында таный. Шулай булгач, хәзер бернинди ялган юк! Хәйлә, бүтәннәргә беленгәч тә, хәйлә булудан туктый, дигәнме әле Суворов? Ни өчен ачыктан-ачык язган ул миңа бу турыда — яраткан өчен ич! Ура! Берни юк!»

Үз-үзен ул шулай юатты, әмма күңелендә нигәдер шатлык хисе бик әз иде. Хат, билгесезлекне бетерү белән бергә, аңсыз сагышны, соңгы көннәрдә бераз басыла төшкән газаплы сагышны яңадан кузгатып җибәрде. Вакыты гел бушка үтте һәм бик авыр үтте.

Хат килгәннән соң икенче көнне ул, Нәсим белән сөйләшү буенча, авыл яшьләре алдында чит ил хәлләре турында беседа кебек бер нәрсә үткәргән иде. Бөтенесе нәкъ ул алдан уйлаганча, дөресрәге, алдан күңеле сизенгәнчә булып чыкты, ягъни беседа барып чыкмады, аның агитаторлык, ораторлык карьерасы челпәрәмә килде. Берни рәтләп сөйли алмады, буталды, кызарынды, шыбыр тиргә төште. Ике сүзнең берендә: «Иптәшләр...»— диде, «Без беләбез...»— диде, ләкин аның нәрсә белгәнен «иптәшләр» белми калдылар. Аңа сөйләргә комачаулап шаулашучылар да, сүзен бүлдерүчеләр дә булмады, ихтирам күрсәтеп, тыныч кына, тыйнак кына тыңлап тик утырдылар, ичмасам тын алган тавыш та ишетелмәде. Ләкин ул туктап калгач та нindидер шелтә, нindидер үкенү сиздереп торган шундый ук авыр тынлык дәвам итте: беркем бер сорау бирмәде, бер генә сүз дә әйтмәде. Җыелышны алып барган Нәсим: «Аңлашылдымы, иптәшләр?»— диде. Аңа каршы бер-ике тавыш, студентның хәтерен калдырмыйк инде, дигән сыман, теләр-теләмәс кенә: «Аңлашылды...»— дип җавап бирде. Җыелыш беткәч, усал телле кызлар чыш-пыш пышылдарга, көлешергә тотындылар. Оятыннан ул кая керер

тишек тапмады. Нәсимнең юатып, аның күңелен күтәрергә тырышып әйткән сүзләре барыбер йөрәгенә барып җитмәде, һәм ул икенче беркайчан да уку өенә килмәс булып, яшьләр күзенә күренмәс булып, үз-үзеннән, үзенең уңышсызлыкка очравыннан гарьләнеп, хурга калып кайтып китте.

Иртән Миңнисәттәй:

— Кая барасың бүген, улым?— диде.

— Беркая да бармыйм,— диде Сәгыйть.

Ике-өч көн элек колхоз печәнгә төшкән иде. Кызу эш өстендә улының вакытын бушка уздырып, сөрән сугып йөрүен Миңнисәттәй бик үк килештереп бетермәде. Билгеле, бу хакта ул аңа турыдан-туры әйтмәде, улының, җитмәсә, ял итәргә кайткан студент улының күңелен кырудан курыкты. Шулай да Сәгыйть әнкәсенең читләтеп-читләтеп сорап куюларыннан аның тел төбен аңлап алды. Иртәнге салкында, таң тишегеннән күзеңне ертып печән чабарга китүгә караганда өйдә яту яисә кулыңны селтәп урманда, су буенда йөрү рәхәтрәк иде, әлбәттә. Һәм ул, бернигә колак салмыйча, үзеннән, үзенең сагышыннан башка берни турында уйламыйча, һаман «ял итү»ен белде.

— Печәнгә барырга уйламыйсыңдыр ич?— диде әнкәсе, тагын сүзгә башлап.

— Юк.

— Ай Алла... интегеп җөрергә теге... өйдә тынычлап ятуга ни җитә...

— Өйдә дә ятмаячакмын. Бибинурларга китәм. Кунакка.

— Ә?.. Барма димим, бар. Менәтерә, бик әйбәт булыр. Бибинурларның да хәлен белеп кайтырсың, кияүнең дә... тазалыклары ничегрәк икән... чирләп-нитеп ятмыйлар микән... Бүген үкме?

— Хәзер үк.

Сәгыйть, ашап-эчкәч тә, юлга әзерләнергә кереште.

Урам якта шул чакны чаптырып килгән җиңел кәрендәс тавышы ишетелде. Бригадир Низамый, башын югары күтәреп, юыртып килгән туры атын туп-туры капка алдына китереп туктатты да, ике аягын да берьюлы күтәреп алып, кәрендәстән сикереп төште, атының каеш тезгенен багана башына бәйләп куйды һәм чистартылмаган авыр күн итекләрен өстерәп атлый-атлый, ишегалдына керде.

Сәгыйть тышта, баскыч өстендә, китапларын актарып утыра иде.

— Укыйбызмы?— диде Низамый, аның алдына тук-

тап. Ул, аякларын аерып басты да, каядыр ашыккан кеше шикелле еш-еш тын алып, беравык Сәгыйтьнең нишләгәнен карап торды. Сәгыйть аның әз йоклаганга йончылган, төссезләнгән йөзенә, кыек салынган кепка астыннан чыгып торган чәчләренә күз төшереп алды һәм бераз көттереп:

— Укырга исәп,— диде.

— Ничек җиләмисең шул китаплардан,— диде бригадир, студент кешегә карата ихтирам сизелеп торган тавыш белән.— Ул кадәр китапка башың чатнар.— Шуннан соң болай гына, сүз арасыннан гына әйткән кебек, бригадирларга гына хас боеручан һәм шул ук вакытта үтенү сиздергән тонда, өстәп куйды: — Печәнгә барыйк әле, Сәгыйть?

— Печәнгә?

— Печән чабарга... Бишкә ярылырдай булып җөрим — кеше юк,— диде Низамый, чыбыркы сабы белән күн итек кунычына суккалап. Күн итектән пырхылдап тузан очты.— Әйдә, барсаң, хәзер үк утыртып алып китәм. Инсафка кердем, катыны белән кунакка киткән.

— Кунакка?..

— Ояты да юк кешенең, шундый вакытта да калхузга ярдәм итмәгәч... Киттекме?

Сәгыйть икеләнеп калды. Бибинурларга баргач укырга дип сайлап алган китапларын кулына алды да, билен язып урыныннан торды.

— Минем чалгы да юк бит әле...— диде.

— Кешесе булгач, чалгысы гына табылыр!— диде Низамый.— Савыт-саба ал, аш вакытына гына барып җитәбез.

...Низамый, кузгалып киткәч, Сәгыйтьне ни өчен борчып йөрүен аңлаткан кебек, зарланып:

— Кеше юк бит, эшләр кеше юк,— дип куйды.— Беркем калмады калхузда, көн-төн чабасың — шулай да тыңлатып булмый халыкны... Ялкаулыкка салышып бетте халык — кайсы базар җулы таптый, кайсы үз бакчасында ята. Болынны шул көе калдырасыңмыни!

Сәгыйть берни эндәшмәде. Бригадир атны туктаусыз чаптырды. Басу юлына чыккач, каршыга җил исте, тәгәрмәчләр астыннан җиңел, коры тузан күтәрелеп калды. Бер ярты чакрым җир киткәннән соң юл сөзәк тау астына йөгерә башлады, авыл артта калды. Алар кояш нуры төшмәгән куе урман эченә килеп керделәр. Йомшак, дымлы урман юлында кәрендәс як-якка тирбәлде, әле бер тәгәрмәч, әле икенче тәгәрмәч кисәк кенә су җыелып торган берәр чокырга барып төште, юл читендәге

абага яфракларына, агач ботакларына пычрак су чәчрәде. Биткә әледән-әле чыбык сугылды, кәрендәс читенә зелпе, юкә ботаклары сыдырылып калды. Юл барды да барды. Биек, төз усаклар, юкәләр, ат килеп җиткәч тә кисәк кенә ике якка аерылып, кәрендәс тәгәрмәчләре генә үтәрлек ара калдырдылар да, алар узып киткәч, яңадан бергә килеп кушылдылар, арттан да, ян-яклардан да тезелешеп, һаман тавыш-тынсыз гына ияреп бардылар. Агачлар арасыннан көн яктысында ялтырап яткан, читчитләре яшел, шома төнбоек яфраклары белән капланган тирән күлләр күренеп калды. Кайчакларда ат кояш нуры тулган, чәчәкләргә күмелеп, бал исе, кызган үлән исе аңкытып утырган түгәрәк болыннарга килеп чыкты.

Сәгыйть юл буена диярлек рәтләп сөйләшмәде. Ул һәрбер нәрсәне үз күңелендә алдан ук туган теләк кушуы буенча, һәрвакыт үзе аңлап, үзе яратып эшләргә гадәтләнгән иде, һәм бары тик үз теләгенә туры килгән эш кенә анда канәгатьләнү, үз-үзеңнән риза булу тойгысы тудыра торган иде. Ул инде кичә кичтән ук Бибинурларга барырга дип план корып куйды, кичәдән бирле шул уй белән генә яшәде. Менә хәзер көтмәгәндә аңа бөтенләй икенче җиргә, күңеле бик үк теләмәгән җиргә барырга туры килә. Билгеле, ул бармый да кала алган булыр иде, беркем дә аны көчләп печән чабарга алып китә алмаган булыр иде. Ләкин бригадирның сүзенә каршы килергә ул үзендә бернинди көч тапмады. Менә ул шулай Нәсим тәкъдименә дә бик тиз генә риза булды. Әгәр тагын икенче мәртәбә адәм хуры булсаң? Әгәр печәндә дә берни барып чыкмаса? Әгәр анда да аннан көлсәләр?

Кәрендәстә озак кына тирбәлеп килә торгач, иң тынгысыз, иң какшаган нервларны да җайга, рәткә сала торган шифалы урман һавасын күбрәк сулый торгач, ул боларның барысын да әкренләп оныта башлады. Ул шушы тын, тирән урманның сиздермичә генә үзен иркәләгәнен, иләп кенә юатканын тойды, аңа шушылай тирбәлә-тирбәлә утырып бару бик күңелле булып күренә башлады. Аның бераз дымсу, караңгы урман эченнән гел шулай барасы, беркайчан да туктамыйча барасы килде.

Алда чалгы тавышлары ишетелгәч, ул сискәнеп китте. Алар һәр ягыннан биек, купшы юкә урманы белән уратып алынган бер зур гына болынга килеп чыктылар. Болынның аргы башында, бер-бер артлы тезелеп, уртадан узган юлга таба чабып килүче печәнчеләр күренде. Алар, уң аякларын алгарак җибәреп, чалгыларын бер җайга селти-селти, салмак кына, ашыкмыйча гына чабалар иде. Арттан тигез булып рәт-рәт яшел печән өемнә-

ре сузылып кала, һавада берничә чалгының бергә чыжлавы ишетелеп тора иде.

— Менә сезгә бер кеше!— диде Низамый, печәнчеләр янына килеп җиткәч, атын туктатып.

Печәнчеләр, кем килгәнен күрергә теләгән сыман, эшләреннән туктадылар да, ашыкмыйча гына башларын борып, кәрендәс ягына карап тора башладылар. Сәгыйтькә якынрак басып торган Гөлсем, бригадирның сүзенә каршы беренче булып:

— Син безгә кунак алып килмә, үз катыныңны алып кил, бригадир иптәш!— дип кычкырды.

Аның тавышы ирләрнеке кебек калын, тупас булып, шуның өстенә — ачулы булып яңгырады. Ләкин бригадирның колагы мондый сүзләргә генә күнегеп беткән иде, күрәсең. Ул Гөлсемгә әйләнеп тә карамады. Инде Гөлсем һаман туктамагач, бәйләнчек кигәвенне куып җибәргән шикелле, кулын селтәде дә:

— Җә-җә, күп сөйләнмә,— диде,— телеңә тилчә чыкмасын... Синекен язмам, курыкма!

— Язган чакларың да була, бригадир иптәш!— диде Гөлсем, һаман туктамыйча, һәм чалгы сабының очын җиргә терәде дә, чалгысын сул кулы белән ныгытып тоткан көе, корычка ачу белән басып-басып янырга тотынды.

Үзләрен болай караңгы йөз белән каршылауларына күңеле кырыла башлаган Сәгыйть:

— Исәнмесез,— диде, ләкин алай гына бик коры чыкканын үзе дә сизеп алып: — печәнчеләр...— дип өстәп куйды.

— Бик әйбәт.

— Исәнме, Сәгыйть,— диештеләр печәнчеләр, җавап итеп.

Гөлсем кинәт янауыннан туктады да, төртке-төртке сипкел белән капланган усал йөзен студентка таба борып:

— Даклат сөйләргәме?— диде кырт кына. Аның төймә кебек бәләкәй генә зәңгәрсу күзләрендә әллә мыскыллау, әллә шаяру белдергән ниндидер очкын ялтырап китте.— Төкле аягың белән, түрдән уз, авылдаш! Түлке даклатыңны тыңладык инде. Менә безнең кебек кулыңа чалгы тотып карасаң да мишәйт итмәсие.

Сәгыйтькә әле авылда беркемнең дә моңарчы болай саксыз, каты бәрелгәне юк иде. Гөлсемнең уенын-чынын бергә кушып әйткән сүзләре шундук аның йөрәгенә барып тиде. Башына ярсып кызу кан йөгерде. Аның Гөлсемнең үзеннән дә усалрак, үзеннән дә тешлерәк итеп

берәр нәрсә әйтәсе яисә, берни ишетмәгән кебек, аны санга да алмаганын белдергән салкынлык белән читкә китеп барасы килде. Ләкин алай иткәндә дә, болай иткәндә дә ул барыбер кеше алдында көлкегә генә калыр иде, хур булыр иде. Үзен ярамаган, начар эш эшләүдән һәрвакыт саклап кала торган бер инстинкт ярдәмендә ул моны шундук сизеп алды һәм ачуын эченә йотты да, үзен бик гади итеп, чын авыл кешесе кебек тотарга тырышып, Гөлсемнең үзе шикелле үк ярым шаян, ярым җитди тонда:

— Мин генә печән чаба беләм дип мактанасыңмы әллә? Бир әле чалгыңны, ничек чапканнарын күрсәтим!— диде һәм Гөлсем алдындагы чабылмаган печәнне таптап, туптуры аның янына атлады.

Гөлсем тирә-якны яңгыратып көлеп җибәрде.

— Ашыкма, ыстудин иптәш, уч төбең кабарыр!.. Таптама печәнне, ристан! Җүри әйтәм, чынга ала күрмә тагы...

Болынның бер кырыенда, елга буенда, яшел юкә яфракларына урала-урала, күккә сыек зәңгәр төтен күтәрелә иде. Анда печәнчеләр өчен зур казанда төшке аш пешә иде. Бригадир атын шунда борды.

— Әйдә, сиңа чалгы рәтлибез,— диде ул Сәгыйтькә.

Аш пешерүче Хәбирәттәй — Зәйтүнәнең әнкәсе — Сәгыйтьне күреп, зур калай табакка бәрәңге турап утырган җиреннән күтәрелеп карады да, якты йөз белән:

— Әйдүк, Сәгыйть,— диде,— мактап кына җөрисең икән, менә хәзер аш җиткерәбез, әйдә... Үзең генә килдеңме, каян белдең безнең монда икәнне? Ә-ә... Низамый белән килдегезмени?..

Агач астына туарылып куелган арба янында, күләгәдә, чал кергән кәҗә сакаллы Гайнулла карт, җиргә тезләнгән көе, чәк-чәк килеп, чалгы таптап утыра иде. Көн кызу булса да, Гайнулла карт башына мескен бүрек, өстенә калын сырма кигән иде.

— Берәр әйбәтрәк чалгың бармы, бабай?— диде Низамый, Гайнулла карт алдына чүгәләп.

Гайнулла карт, әкрен генә башын күтәрде дә, аның соравын кабатлап:

— Чалгы?— диде.— Карап кара, ы-ы, әйбәтме-юкмы... Әнә куак астында...

Чалгы яңа гына тапталып, яңа гына сапланып куелган иде. Сәгыйть башта аның үзенең буена яраклымы, түгелме икәнен тикшерде. Бөгәлҗә кендек турысыннан бераз астарак иде, ул аны әз генә югарырак күтәрде. Аннан соң ул чалгының үткәнен-үтмәгәнен тикшереп, җир өстеннән бер-ике мәртәбә селтәнеп карады — чалгы бик начар алдырды.

Низамый, чалгының йөзенә бармагын тидерде дә, авыз эченнән генә мыгырдап куйды:

— Балта кебек! Гайнулла карт та чалгы рәтләсен, мин дә рәтлим... Кеше исеме күтәреп җөри шунда. Менә күр инде — донжаның тоткасы хәзер шул Гайнулла картларга калды.

Сәгыйть аңа каршы бер сүз дә кайтармады, үзе, Гөлсемнең сүзләрен исенә төшереп, күңеленнән: «Синеке кебек яшь хатыннар өйдә ятса, әлбәттә, дөнья Гайнуллаларга калыр»,— дип уйлап алды.

Кинәт аның тизрәк печәнчеләр янына барасы, бүтәннәр кебек үк каерып-каерып печән чабасы килде. Ләкин чалгыны яңадан бер мәртәбә игәргә туры килде. Ул, сабырсызланып, Низамыйның тизрәк эше беткәнен көтте. Чалгы әзер булгач, бригадир:

— Вакыт әз калган, төшкә кадәр барыбер чабалмассың, җөрмә,— диде.

— Ярар әйдә,— диде Сәгыйть,— булдыралган кадәр чабарбыз әле.

Ул иң арттан чабып барган Гөлсем янына килеп басты, кулларын төкерекләп җибәрде дә чалгысын янарга тотынды. Әле ныклап үлән исе татып карамаган корыч йөзеннән очкыннар чәчрәде, күңелгә дәрт салып, болыннарны яңгыратып, чалгы чыңлады. Сәгыйть, чалгы сабыннан кысып тотты да, беләкләренә, бөтен тәненә тынгысыз рәхәтлек, көч-куәт йөгергәнен тоеп, бер селтәнеп җибәрде. Үткер корыч, үз артыннан киң дуга шикелле такыр эз калдырып, чыжылдап, үлән сабакларын кырып салды, дымсу, яшел печән, бергә җыелып, сул аяк янына килеп өелде. Сәгыйтькә чалгы үзеннән-үзе хәрәкәтләнә шикелле тоелды — ул үзенең көчәнгәнен дә, чалгысының бик үк үткер түгеллеген дә, чалгы сабының авырлыгын да сизмәде. Ул тагын каерылып-селтәнеп җибәрде, тагын сул аяк янына йомшак печән килеп өелде, чалгы астында тагын тап-такыр булып чабылган, тигез, чиста җир өсте торып калды.

Тиз арада ул эшкә бирелеп китте, аңа шушылай җир өстеннән чалгы белән печән чабып барудан да, алсу чыпчык сабыннарының, ак тәтәйләрнең ашыгып-кабаланып, үткер корыч алдында берсүзсез баш июләрен күрүдән дә, чалгы чыжлавын тыңлаудан да күңеллерәк, мавыктыргычрак берни юктыр шикелле тоелды. Аның маңгаена кызу кояш нурлары кадалды, култык аслары, аркасы шундук тирләп чыкты, иртәнге чык кибеп бетмәгән куе печәндә аяк киемнәре юешләнде. Ләкин ул чалгы тавышыннан башка берни ишетмәде, күз алдындагы яшел

болыннан башка берни күрмәде, яңа эш рәхәтеннән башка берни сизмәде.

Көтмәгәндә чалгы куе печән арасыннан күренмәгән бер түмгәккә килеп төртелде. Сәгыйть, кеше-ни карап тормый микән дип, тиз генә башын күтәрде. Печәнчеләр эшләреннән туктап, аның ничек чапканын күзәтеп торалар иде. Сәгыйтькә ничектер уңайсыз булып китте — профессорлар имтихан ала дип торырсың!

— Печәне әйбәт икән... яхшы...— диде ул, чалгысын түмгәктән тартып алып.

— Син аны үз көенә генә җибәр, үз көенә,— диде чалгысын кулбашына салып, Сәгыйть каршысында басып торган Мәрдәншә агай.— Бик үк басма, иркенрәк җибәр син аны, Сәгыйть...

Печәнчеләр, ашыкмыйча гына, яңадан үз алларына борылып, эшкә тотындылар. Сәгыйть Гөлсем артына бик тиз барып җитте. Гөлсем, әллә арыганга, әллә бик авыр сөякле булганга, ачу китергеч дәрәҗәдә әкрен кыймылдады. Сәгыйтькә, аның үкчәсенә ялгыш чалгы тидермәс өчен, әледән-әле туктарга, вакытлы-вакытсыз чалгысын янарга туры килде. Гөлсем исә аның бер адым калмый арттан ияреп килүен бик үк яратып бетермәде, ахры. Сипкелле йөзен борды да, ачуга караганда ныграк шаянлык сизелеп торган чая тавыш белән:

— Кая ашыгасың, ристан!..— дип кычкырды көлә-көлә.— Ашка төшә күрмә!..

Ниндидер бәхетле куанычтан исергән Сәгыйть, кинәт теле чишелеп киткәнен тоеп:

— Юл бир! Чык читкә!— дип кычкырды.— Буталма аяк астында!

Һәм аңа, әгәр алда беркем дә булмаса, ул, ыһ та итмичә, бер-ике селтәүдә бөтен болынны берүзе чабып чыга алыр иде, хәтта — кирәк икән — кызу кояш нурлары астында сагаеп, исе китеп утырган калын урманны да шушы корыч чалгысы белән, шушы кинәт көчләнгән, гайрәтләнгән куллары белән күз ачып йомганчы кырып ташлар иде шикелле тоелды.

## II

Печәнчеләр, эштән туктап, чалгыларын иңбашларына салдылар да бер-бер артлы тезелеп, яр буена таба китеп бардылар.

Аш инде җитешкән — ашаучыларны гына көтеп тора иде. Барысы да яр астына төшеп, битләрен-кулларын юып менделәр, кайсы-кайда җәйлап урнаштылар да өйләрен-

нән алып килгән янчык-төенчекләрен чиштеләр. Калай савыт, кашык шалтыраганы ишетелде, өстенә больницалардагы сестралар кебек ак халат кигән Хәбирәттәй буы чыгып торган кайнар казаннан һәркемгә аш бүлеп бирә башлады.

Ашыкмыйча гына, тәмләп кенә ашарга тотындылар. Ләкин гадәттә кеше күп җирдә була торган көлешү, кычкырып сөйләшү бөтенләй диярлек ишетелмәде. Әйтерсең барысы да телләрен кыймылдата алмаслык дәрәҗәдә арыганнар, әйтерсең һәркем бер-берсенә ни өчендер ачуланган һәм шуңа күрә сөйләшер сүзләре дә юк иде. Бары тик Гөлсем генә ара-тирә берәр сүз әйткәләп куйды да, Хәбирәттәй генә, ашын мактый-мактый, туктаусыз ашарга кыстап йөрде. Мондый күңелсезлек, мондый тынлык Сәгыйтькә бик сәер тоелды. Аннан соң печәнчеләр әз, бик әз, нибары алты-җиде кеше генә иде. Хәтта сугыш еллары белән чагыштырганда да, бу — бер бригада өчен җитәрлек түгел иде.

Сәгыйть баштарак үзен бөтенләй ачыкмаган да, арымаган да шикелле тойган иде. Ләкин ашарга утыргач, ул үзенең бик нык ашыйсы килгәнен белде. Урманда, зур казанда пешкән куе, итле аш бик тәмле иде. Ашны ул бик яратып ашады. Бер тәлинкәне шундук юк итеп куйды да, икенчесен бүлдереп алды. Аштан соң чәй эчтеләр. Чәй калай чиләктә кайнаган иде, шуңа күрә аңа бераз калай тәме, ыс тәме сеңгән иде. Чәй дә Сәгыйтькә бик тәмле тоелды.

Ашап тую алдыннан гына моңарчы кайдадыр йоклап яткан Низамый килеп чыкты. Киеменә эләккән печән чүпләрен иренеп кенә сыпыргалый-сыпыргалый, ашаучылар янына килеп утырды да, беркемгә карамыйча, тезләрен куллары белән кочаклаган көе, тынып калды.

— Әй, син мондамыни?— дигән булды Гөлсем, аны күреп бик гаҗәпләнгән шикелле.— Без тагын сиңа аш та калдырмадык, кайтып киткәнсеңдер дигәниек.

— Калдырдым, калдырдым, утырма кеше куркытып,— диде аңа каршы Хәбирәттәй.— Менәтерә, Низаметтингә аш калдырмаска! Ашагыз, ашагыз, барыгызга да җитәрлек...

Ашап туйгач, печәнчеләр урыннарыннан авыр гына кузгалдылар да, үзара бер-ике сүз әйткәләшеп, шулай ук әкрен генә, иренеп кенә таралышып та беттеләр һәм җайлы урын сайлап алып, йә арба астына, йә берәр агач төбенә — печәнгә башларын төртеп, йокыга да киттеләр.

Сәгыйть тә, кешедән күрмәкче, баш астына яңа гына чабылган печән салды да черки килмәсен өчен битен

иске бишмәте белән каплап, йокларга ятты. Ләкин тиз генә күзен йома алмады. Урман һавасы шундый саф, шундый җиңел иде, тирә-якта шундый күңелле булып кошлар тавышы чыңлап тора иде, күк йөзе шундый аяз, төпсез зәңгәр иде һәм бөтен нәрсәдән шундый хуш ис аңкып тора иде — шушындый вакытта, шушындый урында йоклап яту аңа чиктән тыш мәгънәсез булып, кирәксез нәрсә булып тоелды. Аның йөрәге җилкенеп типте, тамырларында кайнар кан йөгерде, күңелендә исә ниндидер шатлык, куаныч хисе ташып торды. Кинәт аңа йоклау түгел, хәтта шушылай җирдә берниндн хәрәкәтсез сузылып яту да бик мәгънәсез, кирәксез нәрсә булып тоелды, аның сикереп торасы, каядыр йөгерәсе килде, болында ашанып йөргән кара бия янындагы колын кебек сикергәләп йөрисе килде.

Ул, тиз генә урыныннан торды да, елгага таба китте. Текә яр битенә эләгеп үскән талларга, озын сабаклы үләннәргә тотына-тотына, су кырыена ук төште. Аның артыннан балчык кисәкләре коелып калды, аның суга якынлашканын күреп, елгага шап-шоп бакалар сикерештe.

Чит-читләре озынча яфраклы сыек таллар белән күмелгән елга, көндезге кояшка сыртын куеп, ялкау гына, тын гына агып ята, югарыдан төшкән көмеш нурлар белән уйный, шаяра. Ул бөтенләй акмый да кебек. Тик еракта, борылма турысында, вак-вак дулкыннарның ялт-йолт килүенә һәм яр читендәге тасма кебек яшел камышларның сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп, калтырап утыруларына карап кына аның тик тормаганлыгын, каядыр юл тотканын, кыймылдаганлыгын белергә була. Җил юк, ни юк. Тып-тын. Әйтерсең бөтен табигать ялга туктаган, әйтерсең бөтен нәрсә черем итә.

Сәгыйть өстен чишенде. Ул үзе алдында җәелеп яткан шушы елганы, шушы талларны, гомерендә беренче мәртәбә күргән кебек, ялангач тәнендә рәхәт эсселек тойган хәлдә, бөтен нәрсәгә сокланып, исе китеп карап торды. Якындагы текә таулар ягыннан, яшел урман өстеннән, төпсез күк бушлыгыннан — бөтен җирдән аңа ниндидер шатлыклы көй, үзенә бертөрле күтәренке, гаҗәп көй ишетелә шикелле тоелды. Бу җиңел, моңлы көйне ул бөтен күңеле белән ишетте, һәм әле кайчан гына — моннан берничә көн элек кенә шундый күңелсез, эч пошыргыч булып күренә башлаган урман, яшеллек дөньясы хәзер аңа яңадан үз кочагын ачкан шикелле булды.

Яшькелт пыяла япкан төсле тип-тигез, шоп-шома су өсте кинәт чәлпәрәмә килде, як-якка чәчрәгән аксыл

пыяла кисәкләре кояш нурларында чагылып җемелдәш-теләр дә күз алдында эреп юк булдылар. Киң елга тирбәлеп куйды, һәм ярларга бер-бер артлы вак дулкыннар килеп бәрелде, су өстенә иелгән тал яфраклары чыланып-чыланып алдылар. Сәгыйть, кояшта янган көчле беләкләре белән тыгыз суны каерып ишә-ишә, авызыннан әледән-әле һава кысып чыгарып, үргә —ерактагы, икенче як яр читендәге биек карамаларга таба йөзеп китте.

Ул су кереп яңадан яр өстенә килеп менгәндә, печәнчеләр әле һаман тормаганнар иде әле. Алар аңа бик озак иркәләнеп яталар шикелле тоелды, аның тизрәк аларны уятып эшкә тотынасы килде. Ләкин ул монда яңа кеше иде, мондагы эшнең җаена ныклап төшенмәгән кеше иде. Арба төбеннән игәү эзләп алды да, тик торганчы дип, үзенең чалгысын игәргә кереште.

Чабылмаган болын ягыннан, кулына ак таштабак тотып, Хәбирәттәй килеп чыкты.

— Нишләп бик иртә тордың?— диде ул, Сәгыйтьне күреп.— Әллә вакыт та җиттеме — мин тагын көн уздырып, чабата туздырып җөрим, гонаһшымнык. Кая инде, чәй куярга кирәк, эчәсе килгән кеше эчәр тагын торгач...

Шулай сөйләнә-сөйләнә, таштабагын яулык белән каплап куйды да суга төшеп китте.

Беренче булып Гөлсем уянды. Башын түбән игән көе, бик бирелеп чалгы көйләп утырган Сәгыйтьне күреп алды да, көлеп:

— Бик эшчән кунак булдың, ахры, син,— диде.— Кеше җоклаганда да тик утырмый.

— Җитәр көпә-көндез җоклап ятырга!— диде Сәгыйть аңа каршы.

— Син әйткәч — була! Түлке син, ыстудин иптәш, чәчеңне алдырып ташла, иелгәч күзеңә керә.

— Керсәни, синең күзеңә керми ич!— диде Сәгыйть, юри үчекләшеп, үзе күңеленнән: «Чыннан да алдырырга кирәк»,— дип куйды.

Озакламый бүтәннәр дә тордылар, әкрен генә кыймылдап, сүзсез-нисез йә тәмәке төрергә, йә чалгыларын рәтләргә керештеләр.

Көн инде сүрелә төшкән, күләгәләр икенче якка авышкан иде.

Учакта чыртлап коры чыбык-чабык янды, таганга асып куйган корымлы чиләктә чәй кайнады. Гөлсем Сәгыйть янына килде, аның ничек эшләгәнен карап торды, торды да:

— Беркөн син бик шәп даклат сөйләдең,— диде, көлемсерәп.— Иллә дә шәп сөйләдең...

Сәгыйть, корт чаккан кебек, шундук артына борылып карады. Бу усал хатын тагын ни әйтергә җыена икән инде, дигән сыман сораулы караш белән:

— Шуннан?— диде, кызарып.— Сөйләсә ни булган?

— Шуннан — утырган да шуган... Кайткач Ярулладан сорыйм, нәрсә ул «испансия» мин әйтәм. Кит аннан, ди, нинди «испансия» булсын, ди, башыңа чүбек тутырдыңмы әллә, ди, Испанияне дә белмәгәч, ник җөрисең донҗада кеше булып, ди. Тәки аңламадым шул «испансия»не. Сәгыйтьнең үзеннән сорармын әле, мин әйтәм...

Сәгыйть аягына торып басты.

— Нәрсә — «испансия»?

— Чурт белсен инде аны — испансияме, иксансияме...

— Ә!— диде Сәгыйть, кинәт искәреп алып.— «Экспансия»ме?

— Ыы-ыы, шундыйрак нәрсә бугай...

Сәгыйть үзенең теге «доклад»ында чыннан да шундый «экспансия», «бизнес» кебек бик үк аңлашылмаган сүзләрне күп куллануын исенә төшерде. Ул үзен яңадан шунда, уку өендә итеп күз алдына китерде һәм яңадан чигәләрен ни өчендер оялу, гарьләнү тойгысы яндырып үтте. Ул Гөлсемгә «экспансия» сүзенең мәгънәсен аңлатырга тотынды. Сипкелле яшь хатынның шаян күзләре инде аңа игътибар белән, ышаныч белән карый иде. Сәгыйтькә бу кыюлык кертеп җибәрде. Аңлашылмаслык тоелган шундый бүтән сүзләрне дә хәтеренә төшереп, алар турында ул җәелеп сөйләргә керешә. Хәзер ул буталмады да, кызармады да, кирәкле сүзләр тел очына килеп кенә торды, һәм ул, үзе дә сизмәстән, берничә минут эчендә теге уңышсыз беседасын яңадан кабатлап чыкты.

— Аңладыңмы?— диде ул, бүтән әйтер сүзе калмагач, Гөлсемгә карап. Яңадан чалгысына тотынмакчы булган иде, үз тирәсенә җыелган печәнчеләрне күреп алды.

— Хәзер инде аңладым,— диде Гөлсем.

— Ул түгел — мин дә аңладым әле!— дип куйды Хәбирәттәй дә, мактанган сыман итеп.

Читтәрәк, әвәләнгән печән өстендә, аякларын бөкләп һәм уң кулы белән тез башына таянган көе, бик бирелеп тәмәке суырып утырган Мәрдәншә агай:

— Шулай ансы, хак сүз,— диде, әкрен генә.

Ул, тәмәке төпчегенә төкереп, аны күн итеге белән изеп куйды да, урыныннан кузгалып, Сәгыйть янынарак килеп утырды. Бүтәннәр дә бер җиргәрәк җыелдылар. Сәгыйть урталыкта торып калды.

— Шула-ай,— диде Мәрдәншә агай, тагын бер сузып.— Күптән инде шундый сүз ишеткән җук. Әйбәт сөйләдең син, шома сөйләдең, Сәгыйть... Бервакыт шулай, малайкай, безгә дә бер ликтырчы килгән, катын кеше, раюннан. Дәфтәреннән карый да, сиптерә генә! Тыңласаң, тыңлап кал, тыңламасаң, авызыңны күтәреп кал. Пуләмиттән атамыни! Тота да бу, сатсиалистик миллек, ди, тота да, сатсиалистик миллек, ди. Без-ни, авыл кешесе булсак та, милек белән миллекне генә аерабыз, сатсиализмда яшәсәк тә, камунистически аң бар бездә, ансы шулай, чөнки камунизмга барабыз... Хак сүз. Ярар. Шуннан, малайкай, тоттым да мин тегеңә сорау бирдем, ниндирәк була соң ул, иптәш ликтырчы, сатсиалистик миллек дигәнегез — каен миллеге кебекме, җүкә миллеге кебекме?..

Сәгыйть елмаеп җибәрде. Бүтәннәр дә, бу турыда бик яхшы белсәләр дә, тыелып кына көлешеп алдылар. Тик Мәрдәншә агайның гына мыек очы да селкенмәде, калын каш астындагы очлы күзләре генә сизелер-сизелмәс елтырап куйды, күз төпләрендәге сызыклар гына тагын да уртагарак җыела төште. Анда, күп кенә авыл кешеләренә хас булганча, табигый юмор һәм шул ук вакытта тыңлаучыларны авызына каратып тотарлык итеп сөйләү сәләте күренә иде.

— ...Ярар. Шуннан ликтырчы иптәш кып-кызыл булды. Алай итте, болай итте, сүз табалмый аптырады, шулай да әйтте: дөрес, иптәшләр, хак сүз, хата миндә, кайчакта мин шулай «миллек» белән «милек»не буташтыргалыйм инде, диде... Шулай. Ярар. Бездә дә кайчакта «милек» белән «миллек»не буташтыралар. Хөкүмәт безгә бертөрле куша, без икенче төрле эшлибез. Син укыган кеше, Сәгыйть, калхуз турында берәр яңалык җук микән гәзитләрдә? Бит, малайкай, сугыш бетеп, яңадан кулга сәнәк-тырма тотканга җитәрлек вакыт булды лабаса! Бер дә алга китү күренми — үзебезнең калхуз турында әйтәм... Берәр каты закун кирәк, болай барып булмый хәзер. Элек ничегие, сугышка кадәр? Ике-өч афтамашина гына барые. Ашлыгыңны сугып кына өлгерт — көн-төн төяп илебатырга озатып кына торадырыең, и тутырып та куядырыең пыланыңны. Үзеңә күпме каладырые? Лар тулы, капчык тулы булырые, аны кая куяр урын тапмый азапланып бетәдериең. Хәзер ничек? Аллага да юк, муллага да юк дигәндәй, пыланын да тутырып булмый, калхузчыга да рәт юк. Бер караңгыдан икенче караңгыга җөри торганыек, бил дә авыртмый торганые, беләк тә сызламый торганые. Персидәтеле дә Булатыф түгелие шул аның, әлифне таяктан, милекне миллектән аера белмәгән кеше түгелие. Үзенең наданлыгы белән дәрәҗәгә

күтәрелгәненә мактанып җөргән кешедән ни игелек көтәсең!.. Хаҗиеф диләрие аны! Ут уйната торган кешеие ләбаса. Үзе дә тынгылык белмәсие, кешене дә тынычландырып яткырмасые. Атка утырып барганда да кулыннан гәзитен калдырмасые. Чөнки хәзер аның кебек белеп, рәткә салып эшләтүчесе юк, эшләүчесе дә табылырые — җук... Бөтен тотка эшләтә белүдә... Әдәм көлкесе — бөтен бригатка өч бөртек кеше печән чабып җөрибез ич. Болай барса, малайкай, бер айсыз да чабылып бетмәс, калыр шул көе утырып, корып бетәр.

— Ала карга катынының кай җире бездән артык та, кай җире бездән ким?— диде шул вакыт Гөлсем, сүзгә кушылып, ачу белән.— Кайчан эшкә чыкканы бар? Чыгар сиңа, чәнчелеп китсә! Җәп-җәш, тап-таза, печәнгә җибәрсә шушында, катынының бер җире дә кителеп төшмәсие, тилчә дә булмасые. Әйтсәң, анда сезнең эшегез җук, дип кенә җибәрә.

— Аның катынының баласы барны, кешенеке юкмыни? Яслене шуның өчен ачтырдык. Безнекеләр җөри ич...

— Аныкы гына алтын башлы, көмеш кашлы түгелдер!— дип кыстырып куйды тагын Гөлсем.

Сәгыйть, үзе-ни ишетә күрмәсен тагын, дигән шикелле, бригадир кәрендәсе ягына борылып карады — Низамый кайтып киткән иде.

— Нигә кеше җөрми?— дип сүзен дәвам итте Мәрдәншә агай, баягыча, тыныч кына.— Чөнки монда ятып мәгънә юк. Әз генә укыштыра белдеме, читкә китә... Хәзер бит, малайкай, унны бетереп чыккан булалар да, кара эшкә чырайларын сытып карый башлыйлар. Бит аның, эшнең, карасы-агы җук, чөнки булмаска тиеш бездә, элек кенә ул ак кеше, кара кеше булган, эше дә ак эш, кара эш булган. Иныститут бетергәнен әйтмисең дә инде аның. Җыл саен укырга китәләр — берсен бер авылда күргән җук. Мин менә безнең Булатыф кебек чи надан персидәтелләргә берәр ыстудинны беркетеп куярыем, валлаһи!.. Әнә безнең раюнда да бар берәү, укыган-укыган, аңа күпме акча әрәм иткәннәр, ул синең янга туктап та тормый, үзе учонный агранум санала, машинадан башын тыга да, эшләпәсен болгап кына уза. Шулай, Сәгыйть... Әйләнәсең-тулганасың да, тагын шуңа әйләнеп кайтасың — булмый болай... Бөтен авырлык безнең җилкәгә төшә — авылда калган кеше җилкәсенә... Шуңа әйтәм, берәр яңалык җук микән безнең турыда, калхуз турында... гәзитләрдә?..

Мәрдәншә агай, сүзеннән туктап, тәмәке төрергә тотынды.

Сәгыйть тып-тын утырды. Ул үзен шушындагы кешеләргә — Мәрдәншә агайга, Гөлсемнәргә, бөтенесенә дә ниндидер сүз, дөрес, ышандыргыч сүз әйтергә тиеш итеп сизде. Ул — укыган кеше, алардан белемлерәк кеше, ул политэкономиядән дә, партия тарихыннан да имтиханнар тапшырган кеше, ул теорияне белә торган, абстракт нәрсәләр турында фикер йөртә ала торган кеше. Һәм менә ул хәзер үзенең шул белемнәрен практикада куллана алырмы? Әйе, һич югы, авылдагы хәзерге хәлгә төшенә аламы ул? Аларга нәрсә әйтергә? Газеталарда бернинди яңа хәбәр юк, шулай булгач, мин берни дә белмим дияргәме? Бит алай гына Мәрдәншә агай үзе дә белә, ул, яңа хәбәр турында сораса да, аның тел төбе икенче нәрсәне өмет итә — аның тирәнрәк, ныграк беләсе килә.

Сәгыйть күңеленнән үз-үзенә шундый сораулар бирде һәм шул вакыт алар алдында үзенең көчсез икәнен сизде. «Гасыйм булса, бәлки, аптырап тормас иде»,— диде ул күңеленнән. Аларның колхозларының хәле инде берничә елдан бирле шулай һаман рәтле түгел. Ел саен диярлек әле председателе, әле хисапчысы, бригадиры алышынып тора, ел саен диярлек игене рәтләп уңмый, йә уңганын да вакытында яхшылап җыеп ала алмыйлар. Ни өчен шулай? Бу турыда берәр уйлап караганы бармы соң аның? Юк бит, юк! «Начар булгач начар инде — нишләтәсең аны, кайчан булса да бер рәтләнер әле!»— шулай дип кенә карый түгелме соң ул? Мәрдәншә агай дөрес әйтә, әз-мәз белеме булды исә, күбесе «кара эштән» йөз чөерә башлый. Ә соң ул үзе дә шундый ук йөз чөерүчеләр рәтеннән түгелмени?

Ул мондый сорауга берничек дип тә җавап бирә алмады. Ул әйтерсең авыл тормышының әлегә кадәр үзенә билгеле булмаган икенче ягын, урман, болынлыклардан, үз күңелендәге хыяллардан тыш булган ягын күрде. Ул әйтерсең авылга кайтканнан бирле беренче мәртәбә авыл тормышы, авыл кешеләре турында яңа, дөрес хәбәр ишетте. Һәм боларның барысы да анда аңлашылмаган авыр, күңелсез уйлар тудырды.

Моңарчы тыңлап кына, бер читтә генә утырган баһадир гәүдәле Заһирҗан агай, Сәгыйтькә дә, бүтән печәнчеләргә дә карамыйча, каядыр читкә, еракка текәлеп:

— Син аның налугын әйт, налугын,— дип куйды, Мәрдәншә агай белән сөйләшкән кебек.— Киметәсие бераз... Язып җибәрәсие шул турыда министырга.

— Булмасны сөйлисең син, Заһирҗан,— диде Мәрдәншә агай, үзенең хаклыгына бик нык ышанып.— Булмасны... Министырның анда синең хатларны гына укып

утырырлык вакыты бар, ди. Ансы аның гомергә түләнә торган налук инде ул...

— Нишләп булмаслык булсын?— диде Заһирҗан агай, үзенә каршы төшүләренә бераз гына кәефе китеп.

— Булмагач булмый инде! Башта үз калхузыңны аякка бастырырга кирәк. Без бик җиңел генә уйлыйбыз — налугын да түләмә, калхузында да эшләмә! Алай булмый бит ул. Сине соң кем туйдырыр да, кем киендерер? Ишетеп торасың бит — теге яктагылар, Гитлер койрыклары, әнә ничек котыруналар! Алайга китсә, хәзер җимереп, басып керерләр, тычкан урынына буып ташларлар, малайкай!.. Түлибез инде аны, сугышка кадәр дә барые ул, без аны уйлап та бирмидериек. Тормышың яхшы булса, налук кына аяктан җыкмый.

Ләкин Заһирҗан агайны да үз фикереннән тиз генә кире кайтарып булмый иде.

— Хөкүмәт тә малның кырып бетерергә кушмый,— диде ул, сүзендә нык торып.— Кош-корт калмады, сарык калмады, кайберсенең сыеры да җук. Печәне дип бер кайгыр, саламы дип икенче кайгыр, тота да суя, илтә дә сата. Элек, сугышка кадәр, әйбәтие, әйтеп тә торасы җук. Хәзер дә шул берәр нәрсә эшләргәие, Булатыфлар белән генә була торган эш түгел ул, язып җибәрми ярамый моны.

Сүзгә хатын-кызлар да кушылды.

— Былтыр бодай саламы җыелмый калды, тирескә әйләнде!— диде Хәбирәттәй.

— Фирма маллары йөзәрләп кенә кырылды. Язга чыккач, мескенкәйләр, чирәмне яткан җирдән ашыйларые. Кайсыларын күтәреп алып бара торганыек басуга.

— Шул шул — кыш көне ике кибән печәнне кем сатып эчте? Белми дисәләр дә, бик белеп торабыз! Аларга-ни, үгез үлсә ит, арба ватылса — утын, ай-һайларында да жук, пошмыйлар да ичмасам.

Һәркемнең теле чишелде, һәркемнең үз күңелендәгесен әйтеп бирәсе килде. Күңелләрдә әйтеләсе сүз күп җыелган иде, ахры. Һәм аларның һәрберсендә гомуми эш өчен әрнү, кайгыру, колхозның булдыксыз җитәкчеләренә, үз-үзләренә ачу сизелә иде. Ләкин шунысы да ачык иде — тормыш гел болай тормаска тиеш, кайчан да булса бер үзгәрергә һәм үзгәргәндә дә, яхшы якка гына үзгәрергә тиеш. Сәгыйть аларның сүзләреннән, аларның йөзләреннән шуны сизде, шуны тойды.

Барысы да үз уйларына бирелеп, кинәт тынып калдылар. Елгада балык сикерде, ботак очларын селкетеп, каршыдан гына бер саргылт кош очып китте. Болында туктаусыз чикерткәләр сайрады, кайдадыр елга аръягын-

да кемдер: «Ау-у!»— дип кычкырды, күктән һаман күңелле кояш нуры коелды һәм бөтен җирдән исерткеч хуш ис аңкыды.

— Ай, гөнаһшымлык, чәемне онытканмын лабаса!— диде Хәбирәттәй.— Әйдә, суынмагандыр әле... Кемнең эчәсе килә? Кая... савытларыгыз кая, эчеп алыгыз әле...

— Нинди бетмәгән чәй инде ул?— дип кычкырды Гөлсем Хәбирәттәйгә, ләкин ниндидер бүтән кешегә ачуланган шикелле.

Мәрдәншә агай чалгысына тотынды.

— Җәгез, сөйләштек — җитәр,— диде, аягына басып.— Бу печәнне без чапмыйча, әллә кем килеп чапмас.

## III

Бик үк зур булмаса да, аның үз бүлмәсе бар. Кояш чыгыш якта бер тәрәзә, көн якта бер тәрәзә. Тәрәзәләргә яхшы материядән эшләнгән ак шторлар эленгән, тәрәзә төпләрендә, идән уртасындагы өстәл өстендә — эре яфраклы купшы гөлләр. Хәзер вакыт инде бик иртә булмаса да, шторлар күтәрелмәгән һәм шуңа күрә тәрәзә төпләрендәге гөлләр күренмиләр, елкылдавык калын материя аша кабарып кына торалар. Стеналарга алтын бизәкле яхшы обой ябыштырылган, түшәмнәр штукатурланган, агартылган — ап-ак булып ялт итеп тора. Идәннәр чиста. Идән буенча, өстәл астыннан үткәреп, бүлмәнең бер башыннан икенче башына кадәр, чит-читенә кызыл буй төшкән яшькелт йомшак палас җәелгән. Бүлмә эче җыйнак, чиста, бай.

Ул тәрәзәдән читкә, почмакка куелган үз койкасында, ап-ак йомшак одеял ябынып, ап-ак йомшак мендәр өстендә ята. Бу койка хәзер аның өчен бераз кыскарак, һәм ул киерелергә, тураерга кирәк булганда, койка башындагы тимер араларыннан аякларын сыйдыра алмыйча азапланып бетә.

Ул инде күптәннән бирле ярым уяу килеш ята, тик күзләрен ачасы, йомшак, җылы урыныннан авыр тәнен, кичә соң кайтканга авырайган башын калкытасы гына килми.

Бүлмә ишеген иплəп кенә ачып, кулына юеш чүпрәк тоткан, саргылт, ябык йөзле, бәләкәй генә, чандыр гына бер хатын килеп керде. Ул, гаепле кеше сыман үзалдына елмайган көе, ничектер уңайсызланган, хәтта бераз куркынган кыяфәт белән, сак кына, әкрен генә түргә узды. Шулай ук сак кына, иплəп кенә кыймылдап, чүпрәк белән өстәл өстендәге сулы графинны сөртте, аннан соң

койкага каршы почмактагы комод янына килде дә андагы зур түгәрәк көзгене сөртеп алды, эреле-ваклы хушбуй шешәләренең, вазелин, крем савытларының күзгә күренмәгән тузаннарын өрде һәм, өстәлне әйләнеп чыгып, итәге идәнгә салынып төшкән күлмәкне күтәрде, аны урындык аркасына элеп куйды. Шуннан соң шторларның итәген кайтарып, тәрәзә төпләрендәге гөл савытларына су сибелгәнме-юкмы икәнен тикшереп карады да, бүлмәдә артык тукталып тормыйча, шундый ук тавышсыз, куркак адымнар белән чыгып та китте.

Ида аның ничек кергәнен дә, ничек чыкканын да сизмәде. Чандыр, ябык хатын чыгып киткәч, озак та тормыйча, бүлмәгә өстенә алсу халат кигән, сытылып торган симез ак битле, артык акыллы да, шулай ук артык ахмак та булмаган кыяфәтле, бәлеш кебек тулы, юан гәүдәле икенче бер хатын килеп керде. Бу — Иданың әнисе иде. Ул да, Иданы уятудан куркып, тавыш чыгармыйча гына басарга тырышты, ләкин як-якка аунаклаган авыр гәүдә белән, күрәсең, иппәп кенә атлап булмый иде — лап-лоп баскан аяк тавышларын ишетеп, Ида бөтенләй уянып китте. Беренче булып үз каршысында әнисен күргәч тә шундук йөзе җыерылды. Аның әле җылы урында тагын бераз ятасы килә иде. «Тагын уятты инде!»— дип уйлады ул, әнисенә үртәлеп.

Әнисе кызының кыймылдаганын күргәч, аның койкасы янына, палас өстенә киез олтанлы җиңел чүәк куйды да кайгыртучан тавыш белән:

— Идәнгә баса күрмә, салкын идән...— диде.— Теге якта калган, менә йомшак катаң...

Ида өстеннән одеялын тартып җибәрде, күзләрен ачты. Кинәт аның йокылы кыяфәте бөтенләй бозылып китте. Көнчыгыш яктагы тәрәзә шторының бер кырые гөл ботагына эләгеп, күтәрелеп калган иде һәм шул ачыклыктан комод өстендәге көзгегә кояш нуры төшкән иде. Әрсез кояш нуры исә нәкъ аның баш очына, койка өстенә, стенага килеп кунган. «Әйтәм, биткә җылы бәрелгәндәй булды — кояш төшкән икән!»— дип уйлады Ида, коты алынып. Аның бар курыкканы кояш нуры иде һәм шуңа күрә аның бүлмәсенә беркайчан да диярлек кояш нуры кертелми, шторлар һәрвакыт төшерелеп торыла иде.

— Ничә әйтәсең ныгытып ябарга дип... Бар әле, бар, рәтләп куй!— диде ул, әнисенә ризасыз тавыш белән.

Әнисе шундук кабаланырга тотынды. «Рәхимә апаң кереп чыкканые» дип сөйләнә-сөйләнә, тизрәк тәрәзә янына килеп, шторны төзәтеп куйды да тагын кызына борылды.

— Тор инде, унбер тула,— диде. Аннан соң чыгып китте. Кухня ягында тагын аның тавышы ишетелде: — Рәхимә, самавырга күмер генә сал әле...

Менә башланды... Бүген тагын кәеф булмаячак. Кем кушкандыр аңа уятырга! Сәгать унбер тулсани, тулсын... Кирәгем исә бер тулсын, ике тулсын. Тагын йокы туймады, тагын баш авыртачак, тагын бөтен нәрсәгә ачу киләчәк. «Өйдә нинди бөркү!— диде ул, өстәл тирәсендә очып йөргән бер чебенне күзәтеп.— Тагын чебен тутырганнар инде...»

— Әни!— дип кычкырды ул, урыныннан кузгалмыйча гына.— Ач әле тәрәзәне. Шторны кыстырып куй, җил селкетмәсен.

Әнисе урынына бүлмәгә Рәхимә апа килеп керде. Гадәтенчә, киң итеп елмайды да:

— Тордыңмы, Һидая?— диде пышылдавык тавыш белән.

Тәрәзәне ачкач та, бүлмәгә саф һава керә башлады. Тышта ни өчендер кычкырышкан бала-чага тавышы ишетелде. Урамнан, дөбер-шатыр килеп, буш тимер мичкәләр төялгән автомашина узып китте. Аның тавышына бөтен өйләр, тәлинкәгә утыртылган графиннар, комод өстендәге шешәләр сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп калды. Аннары бераздан соң авыл егетләренең тупас, ямьсез тавыш белән кычкырып көлә-көлә, нидер сөйләшеп барулары ишетелде.

Ида ашыкмыйча гына урыныннан торды, бер ноктага карап, беравык тынсыз торды. Кинәт ул әле генә үзенең битен кояш нуры кыздыруын исенә төшерде. Тиз генә идәнгә сикереп төште дә көзге алдына йөгереп килде. Бәхеткә каршы, битендә шикләнерлек ул-бу юк иде, бит тиресе элеккечә ап-ак, нәфис иде. Ида тынычлангандай булды. «Аның өше кояшка гына бит караямыни!»— дип уйлап алды ул, үзенең куркуыннан көлеп.

Аның күңеле күтәрелде, уянгач та бер дә юкка ачу килү, үртәлү каядыр югалды. Ул иренеп кенә бер иснәде дә, баскан урыныннан үрелеп, көзгегә карап тора башлады. Ул башта үзенең полтыранган чәчләрен генә, чәч уртасындагы ак түгәрәк йөзен генә күрде. Шуннан соң көзгегә якынрак килде, авызын киереп ачып тагын бер иснәде һәм, үзенең ачык авызында азау тешләрен, тел төпләрен күреп, көлеп җибәрде. Аннан соң үз-үзенә, үзенең шәрә ак беләкләренә, иңбашына, бәләкәй кара күкрәкчә кысып корган күкрәкләренә сокланып, көзге алдында көязләнергә, төрлечә кыланырга тотынды. Әле бер ягы белән, әле икенче ягы белән, әле арты, әле алды

белән борылды, көзгегә йә якынрак килде, йә читкәрәк китеп карады да кулларын биленә таянды, күзләрен зур итеп ачты, иреннәрен күпертте, елмайды, ачуланды... Хәзер, йокыдан торгач та, ярым шәрә килеш, үз-үзенә ул бигрәк тә матур, бигрәк тә сокландыргыч булып күренде.

Көзге алдында шулай бер ун-унбиш минутлап вакыт үтте. Аннан соң ул комод өстеннән эре тешле тарагын алды да, иренеп кенә, ашыкмыйча гына, иснәнә-иснәнә, көзгедән һаман күзен алмыйча, чәчен тарарга керешге. Күперенке чәч көлтәсе ике якка таралып төште, йомшак кына итеп аның битен, ачык муенын кытыклады. Чәчләрен ике куллап тотты да, бөтен битен чәч белән каплады һәм, күзләре өчен генә ярык калдырып, көзге аша тагын үз-үзенә карарга тотынды.

Сәгыйть аңа: «Син — пумала баш»,— ди торган иде. Кара, болай чынлап та пумала кебек була икән. Аның үзенең дә башы пумала кебек. Юри ачулана башлагач, үпкәли башлагач, тәүбә итәргә, әбиләр кебек, әнисе кебек: «Әйттем исә кайттым»,— дип төкеренергә тотына торган иде. Аннан соң аның кулыннан алыр иде дә, иркәләп, яратып, тагын да ягымлырак итеп: «Аллы баш, гөлле баш — һай матур, гүзәл туташ!»— дип такмакларга керешә торган иде. Шундый көлдереп бетерә торган иде.

Ида үзалдына елмаеп куйды. Ләкин аның чырае шундук үзгәрде, күңел күтәренкелеге ничек тиз барлыкка килсә, шундый ук тизлек белән юк та булды. Яңадан нигәдер эче поша башлады, бөтен нәрсәгә ачуы килде, үртәлде.

Бөтен күңелне тырный, борчый торган бу эч пошу аны үзләре авылына кайтып төшкәч үк әзәрлекли башлады һәм эт тигәнәге кебек һаман ияреп, тагылып йөрде. Ул һич кенә дә үзләренең авылына ияләшеп, күнегеп китә алмады. Пароходта кайткан чакта аңа өйдә аны бик сагынып, бик җан атып көтеп торалардыр шикелле тоелган иде. Шуңа күрә аңа өйдәге бөтен нәрсә искиткеч матур, кызыктыргыч, мәгънәле булыр кебек иде. Дөрес, аны бик әйбәт, бик шәп, хәтта кирәгеннән артык шәп каршыладылар. Иптәш Мәхмүтовның кызы кайткан, дип бөтен күрше-тирә, бөтен авыл шау килде, очраган бер кеше диярлек аның белән исәнләшеп, елмаешып китте, әтисе янында эшләүчеләрнең кайберләре исәнлек-саулык сорашу өчен хәтта өйгә дә килеп җиттеләр. Тик элекке мәктәп дусларыннан гына килүче-нитүче булмады. Хәер, аның моңа әллә ни исе дә китмәде. Әтисе, студент кызы-

ма, дип, яхшы укучы кызыма, дип, яңа ефәк күлмәк алып куйган иде. Әнисе ул кайтып төшкәч тә шатлыктан бөтенләй акылдан язды, бер алдына, биш артына төште, аның бәләкәй генә теләген дә берсүзсез үтәргә тырышты. Рәхимә апаны әйтеп тә торасы юк инде. Кыскасы, аның кайтып төшүе бөтен семья өчен, хәтта бөтен күршекүлән өчен бер бәйрәм булды. Идага һәркем аны гына яратадыр, аның кайтуы өчен генә сөенәдер, куанадыр шикелле тоелды.

Ләкин беренче очрашу шатлыгы бик тиз узып китте. Икенче көнне алар әнисе белән, Рәхимә апа белән өчәүләп базарга чыктылар. Үзләренең авылын ул гомеренә беренче мәртәбә күргән кебек булды. Шаккатты. Авыл шундый бәләкәй, шундый ташландык иде, урамның бер очыннан карасаң, сөрелгән кара җиргә барып тоташа торган икенче очы шул көе күренеп тора иде. Салам түбәле, кара стеналы бүрәнә йортлар шундый тәбәнәк, шундый котсыз, шыксыз иде. Кешеләр бик начар, бик тупас киенгәннәр иде.

Аңа тормыш монда бөтенләй туктап калган, оеган, үлгән шикелле, тар урамлы кара авыл шау-шулы, шат, көләч дөньядан, ягъни шәһәрдән, әллә кайда мең чакрымнар еракта ята шикелле тоелды. Бары тик кайчакта узып киткән автомашиналар, сирәк-мирәк кенә күзгә чалынып калган җиңел машиналар гына монда әз булса да тормыш барлыгын сиздерде. Кайвакытларда елга ягыннан, ерактан, җил белән пароход тавышлары килде. Мондый чакларда бигрәк тә моңсу булды. Күз алдына шундук Казан урамнары килеп басты, колак төбендә күңелле гөрелдек яңгырады һәм шул чакта тирә-яктагы тынлык, торгынлык күңелгә тагын да үтергечрәк тәэсир итте. «Әгәр укып бетергәч, шушындый авылга җибәрсәләр, әгәр гел шушында торырга туры килсә, нишләрсең? Ужас!» — дип уйлады ул, коты алынып.

Беренче көннәрне, базарда йөреп кергәннән соң, ул бөтенләй диярлек урамга чыкмады — туган авылыннан аның шундый нык күңеле кайтты. Кояш нуры кермәсен өчен тәрәзәләрне томалады да, койкасына сузылып ятып, китап укыды. Өйдә җиләтә башлагач, өй артындагы бакчага, күләгәгә чыгып утырды, бернинди эше булмаганга, тагын китап укыды. Ул романнарны су урынына эчте. Ләкин эч пошуны барыбер китап укып кына басып булмады. Тиздән романнар да җиләтә башлады. Берни эшлисе, беркая барасы килмәде, әнисенең ялагайлану дәрәҗәсенә җитешеп, аңа карата үзенчә яхшы булырга тырышуы, аны иркәләргә, яратырга тырышуы та-

гын да ныграк ачуны китерде. Ул шәһәрдән кайтуына бөтен күңеле белән үкенә башлады.

Баштарак Сәгыйть турындагы уй гына күңеленә җылылык бирде — бәлки, эч пошу да шуның аркасында булгандыр — һәм тагын әтисе өйдә торган чакта бераз күңелле булды. Ләкин әтисе ул кайтып бер ике-өч көн генә торгач та, эше буенча ерактагы шәһәргә китеп барды. Ул, гомумән, өйдә бик сирәк була. Һәм Ида моңа инде бала чактан ук гадәтләнеп беткән иде. Сәгыйть турындагы уй, учакта янып көлгә әйләнә торган утлы кисәү кебек, тора-бара бөтенләй кечерәйде, үзеннән-үзе эри, юкка чыга барды. Аның еш кына күз алдына килеп, күңелләрне өтеп ала торган ягымлы сурәте һаман тоныкланганнан-тоныкланды. Ул аның янында түгел, ул кайдадыр еракта, билгесез җирдә һәм хәзер аның дөньяда булуы-булмавы да шикле. Дөрес, аннан бик еш хат килеп торды, ләкин хат, ни әйтсәң дә, ул үзе түгел, бары тик кәгазь кисәге генә, шуңа күрә ул хатны укыганчы гына, беразга гына тере булып, җанлы булып күз алдында торды да, тагын онытылды.

Ул үзе аңа бер хаттан башка бүтән берни язмады. Аңа көн дә хат язып торырга вәгъдә бирүен ул инде пароходка аяк баскач та онытканиде. Шулай инде, вәгъдәне аны бирүе генә җиңел! Аннан соң ул, укырга иренмәсә дә, язу мәсьәләсенә килгәндә, бик үк һәвәс түгел иде. Ул Сәгыйтьнең яратып, сагышланып язган кайнар сүзләрен укыды, һәм бу анда үз-үзең белән канәгатьләнү, горурлану тойгысы уятты. Ул аның бернинди җавап язмаганына ачуланып, ярсып язган сүзләрен укыды, хатлар аша аның яшеннәр яшьнәтеп тузынуын һәм шул ук вакытта аннан кош теледәй генә булса да кәгазь кисәге алырга зар-интизар булып ялынуын күрде, һәм бу анда тагын да үз-үзең белән канәгатьләнү, горурлану тойгысы уятты. Ул аның мондый хатларын укыгач, көлеп, күңеленнән: «Менә тиле!— диде.— Иртәгә үк җавап язарга кирәк». Ләкин икенче көнне хат та онытылды, теләк тә онытылды. Һәм шулай итеп көн артыннан көн үтте, ике атнадан артык вакыт узып та китте.

Кичәгенәк ул кичкә таба урамда, үзләре турысында, элекке дус кызы Рафиганы очратты. Рафига кайдадыр, ниндидер артельдә эшли иде. Очрашкач сөйләшергә туры килде. Урамда бераз басып торгач, ул аны үзләренә өйгә керергә чакырды.

Бүтән вакыт булса, Ида аның белән, бәлки, сөйләшеп тә тормаган булыр иде. Бала вакыттан ук ул үз-үзен классташ кызларыннан, барлык дусларыннан бар яктан да

өстен дип исәпләп үсте һәм аларга гел шулай өстен торып карарга гадәтләнде. Кайчандыр канына сеңеп калган бу караш анда үсеп җиткәч тә бетмәде, киресенчә, студент булгач, Сәгыйть белән дуслаша башлагач, тагын да ныгыды, төпләнде генә. Мәктәптә чакта аңа бөтен класста иң яхшы укучы ул гынадыр һәм укытучылар да бары тик аны гына яраталардыр шикелле тоелса, университет студенты булгач та аңа группада иң матур кыз ул гынадыр һәм барлык егетләр дә аны гына яраталардыр шикелле тоела иде.

Ләкин хәзер ул ялгыз иде.

Рафиганы ул үз бүлмәсенә алып керде. Аның өс-башына, аякларына тәнкыйть күзе беләнрәк карап алды да:

— Син каядыр барырга җыенгансың бугай?— диде.— Мин сине задержать иттем, ахры...

— Юк, вакыт бар әле... Кинога керергә дип чыкканыем.

— Нинди картина? Кайткач кинога да барган юк, үләм инде, ничек үткәрермен бу җәйне,— диде Ида, бик йончылган кыяфәт белән урындыкка утырып, һәм иренеп кенә авыр кулларын тез өстенә салды.

— Әйдә хәзер кинога,— диде Рафига.— Тарзанның өченче сериясе.

«Чынлап та, нигә өйдә бикләнеп ятарга?— диде Ида күңеленнән, моңарчы кино турында уйлап та карамавына беренче мәртәбә шундый нык гаҗәпләнеп.— Тарзан булгач, бигрәк тә барырга була».

— Билет алалырбызмы соң?— диде ул, риза икәнен белдереп.

Рафиганың йөзе яктырып китте. Иданың үзе белән кинога бармакчы булуына ул бик шат иде бугай.

— Булыр...— диде ул.— Алып бирүчеләрен дә табарбыз... Барабыз алайса, Идакаем? Әйдә, киен тизрәк. Кинодан соң танцыга калырбыз. Бакчада хәзер безнең көн дә танцы була, синең әле күргәнең юктыр.

— О-о, танцы да булгач, мин барам!— диде Ида, тәмам күңеле күтәрелеп.

...Рафига кичкә таба бүген дә килмәкче булды. Танцылары да ярыйсы гына була икән, радиола кычкырталар, кайчакта гармун уйный. «Кая инде ул монда духовой оркестрлар!.. Шулай да танцевать итәргә була,— дип уйлады Ида, көзге алдында һаман чәчләрен тарый-тарый.— Ничек тагын көнне уздырырга?.. Ужас, көн нинди озын!»

Һәм ул, түземсезләнеп, тизрәк кич булуын көтә башлады.

## IV

Эштән кайткач, Сәгыйть лапас алдына туарып куелган бер ат күрде. Тезгененнән яхшы кәрендәскә бәйләнелгән кара яшь бия, алгы аягы белән җирне тырныйтырный, нигәдер тынычсызланып тора иде. Ат, капкадан кайтып керүче Сәгыйтьне күрү белән, нечкә, матур муенын борды да, башын югары күтәреп, аңа дусларча кешнәп җибәрде. «Кем килде икән?»— дип уйлап алды Сәгыйть, кызыксынып.

— Әнкәй, нинди ат ул?— диде ул, ишекне ачкач та.

Аңа җавап булып, өй түреннән Бибинурның таныш тавышы ишетелде.

— Әллә күрми дә торасың?— диде Бибинур, энесенә каршы сикедән төшеп.

Алар, ике туган бер-берсен бик озак күрми торганнан соң ничек исәнләшсә, шулай бик шатланып, бер-берсенә бик куанып исәнләштеләр. Бибинурның авыры бар иде, Сәгыйтькә ул бик нык сүлпәнләнеп калган шикелле күренде.

— Менә үзегез килмәсәгез дә, килдем әле,— диде Бибинур.

— Бик әйбәт! Күптән кирәгие!

— Сабан туе булды, ат чаптырдылар, иллә дә күңелле булды инде. Асаф әйтә, әбиләр безне бөтенләй ташладылар, ди, ичмасам бер килеп тә чыкмыйлар, ди...

Ул ничектер бик авырлык белән генә, эретеп кенә сөйләде, һәм бу вакытта аның йөзе буйсынучан тынычлыктан башка, ниндидер ис китмәүчәнлектән башка берни белдермәде. Сәгыйтькә ул нигәдер бик кызганыч булып, ярдәмчесез булып күренде. Аның аңа нинди дә булса берәр яхшылык эшлисе килде.

— Атыңны эчертеп кайтыйммы?— диде ул.

— Үзем дә әйтермен дигәнием, килгәч тә эчмәде әле ул,— диде Бибинур һәм, әкрен генә кыймылдап, аның артыннан чоланга чыкты.— Аты җуаш, әйбәт ат бирделәр болай. Кайткач та килер дип, көтә-көтә көтек булып беттек сине... Бригадирга әйтәм, мин кунакка барам, җулда азап чигәрлек үшән ат бирмә, мин әйтәм. Бибинур, ди, хәзер бездә үшән атлар да, үшән кешеләр дә юк инде ул, ди... Печәне бүгенгә җитәр микән? Әйдә, бетсә тагын чабып алып кайтырсың әле. Бу кадәр үскәч тә үсәрсең икән!..

Сәгыйть елгадан кайтып кергәндә, Гамбәр белән Барис та өйдә иде. Әллә Бибинур килгәнгә, әллә инде бүген беренче мәртәбә печән чабып кайтканга һәм шуңа күрә

үз-үзеннән бик канәгать булганга, әллә әнкәсе шәңгә пешергәнгә, Сәгыйтькә өй эче бәйрәм вакытындагы кебек бик ямьле булып, бик матур булып күренде. Аш вакытында бертуктаусыз сөйләшү, күңелле шау-шу ишетелеп торды. Бибинурның туган йортын, әнкәләрен, туганнарын бик күрәсе килгән, мондагылар аның үзең бик сагынганнар иде.

Бибинур әледән-әле сүзгә кереште. Үзләре турында, Асаф турында, үзләренең яхшы яшәүләре турында сөйлисе килүе аның һәрбер сүзеннән сизелеп тора иде.

— Өч баш кортыбыз бар...— диде ул, ашыкмыйча гына шәңгә ашап.— Асаф әйтә, аерды исә, берәр баш кортны Барисларга бирербез, ди. Менә тиздән бал суыртыр вакыт җитә, ындыр артында гына карабодай, хәзер җүкә чичкә ата башлады... Кортка килешеп кенә тора...

— Рәхмәт сүзеңә. Түлке минем корт белән булашырга бер дә вакыт җук шул,— диде Барис.

— Калхузда ничегрәк соң, калхузда? Печәнгә төштеләрме әле?

— Калхуз безнең зарланырлык түгел, әнкәй. Игеннәр әйбәт, хәзер печәнне сыдырып баралар. Мин дә әлегә кадәр эшкә йөрдем. Беренче көнне Асаф белән печән чабарга чыкканыем, бырач килеп тиргәп китте, сиңа, ди, авыр эш эшләргә ярамый, ди. Шуннан соң менә — гел өйдә. Өйдә ятып та җиләтә лә, күңелсез. Калхуз хәлле безнең. Яз көне генә тагын бер афтамашина алдык. Персидәтел әйтә, Хәлиулла абзый әйтә, быел көз бер лифкавай алмый булмый инде, ди. Халыкның тамак тук, өс бөтен дигәндәй, тагын ни кирәк? Былтыр өч кила белән бүлдек, быел аннан да артып китәр дип торалар. Персидәтел шәп безнең, сугыш җылыңнан бирле эшли бит. Бик башлы кеше булып чыкты, ай башлы! Бераз усалрак та, шулай да халык ярата.

— Безнекеләр коры таякка калдырдылар инде... кирәк алды, кирәк арты,— диде Миңнисәттәй, эчке бер әрнү белән.— Әнә сиңа кунакка да берүзеңә бер ат биреп җибәргәннәр. Табарсың безнекеләрдән! Алып кайтасы бүрәнәләребез барые, ничә мәртәбә сорадым шул Низамый Ала каргадан.— «Җук! Калхузда эшләмәгән кешегә ат җук. Мытыестан сорасын!»— дип кенә җибәрә. Шул буламыни сүз? Мытыеста эшләсә, кем өчен эшли? Эчкене генә өмет итәләр...

— Эчертермен әле мин аңа!— диде Барис, гайрәтләнеп.— Вакыт кына тими...

— Җу-ук, бездә атны тотмыйлар. Утынга барасың киләме, базаргамы, кунаккамы анда... Туктале, мин әйтәм,

күптән инде әнкәйләрне күргән җук, Сәгыйть тә кайт-кандыр, барып кайтыйм әле, мин әйтәм. Кантурга барып сорады Асаф, берсүзсез язу язып җибәргәннәр.— Бибинур сулыккан, агарынган йөзен Сәгыйтькә борды.— Асаф ныгытып әйтеп җибәрде, Сәгыйть кайтса, бернигә карамый алып кил, диде. Ат бар, күңелең теләгәнчә ял итеп китәрсең, бал суыртабыз менә...

— Мин үзем дә бүген сезгә китмәкче булганыем,— диде Сәгыйть.

— Ярый әле китмәгәнсең. Минем килү бик әйбәт булды инде... Син ат тотарсың. Дилбегәне тотып кулларым калмады — аты яхшы, һич тотып тыяр хәл җук. Чапкачтын эчне селкетә...

Бибинурның ат белән килеп чыгуы Сәгыйть өчен чынлап та бик шәп иде. «Җизнәкәйләрнең күңелен табып, хәлләрен белеп кайтканда начар булмас иде»,— дип уйлады ул. Аларда урман, таулар да мондагы ише генә түгел, елга да якын гына — менә дигән итеп ял итәргә булачак.

Ләкин ул шундук үзенең бүген генә печән чабарга баруын исенә төшерде. Әгәр ул икенче көнне үк эшне ташлап, кунакка китеп барса, Гөлсемнәр, Мәрдәншә агайлар, Заһирҗан агайлар ни дияр? Бик йомшак буынлы булып чыкты, беренче көнне үк биленә тиде «ыстудин иптәшнең» дип әйтәчәкләрме? Әйе, шулай дип әйтәчәкләр. Беренче булып Гөлсем кычкырачак: «Һей, аның ише озын чәчле нәрсәдән нинди рәт чыксын соң! Даклат сөйләргә генә враштыра ул... анысына да әле тартып-сузып кына... Андый ялкауларның эшкә тотынгач, кулларыннан кул ярысы эш килми!..»— дип әйтер. Һәм бик дөрес әйтер.

— Печәнгә бардым бит әле мин,— диде Сәгыйть, уйланып, тиз генә җавап бирергә ашыкмыйча.

— Барсаң ни! Бездә дә болын бетмәгән, җөрерсез җизнәң белән икәүләп. Авал сөенеп бетәлмәс!..

Барис, Сәгыйтьнең печәнгә баруы турында ишеткәч, башын күтәреп карады да, ризасыз тавыш белән, кырт кына:

— Җөрмә юкка селкенеп!— диде.— Ач тамагың җук, барыбер эш көне язмас әле...

Сәгыйтьнең йөзе караңгыланып китте. Аның абыйсына каршы төшәсе, аның хаксыз икәнен аңлатып бирәсе килде, ләкин моның өчен ул ышандыргыч сүзләр таба алмас шикелле тоелды.

— Хәзергә барып булмастыр шул әле, апа,— диде ул Бибинурга, аның хәтерен калдырудан курыккан шикел-

ле, йомшак кына итеп.— Үзең уйлап кара: бер көн эшлә дә, икенче көнне үк кач!— Ярамый бит алай. Кеше ни әйтер? Печән чабу беткәч, мин сезгә үзем барырмын. Чынлап!

Бибинур үпкәләп та карады, ачуланып та, ялынып та карады, ләкин энесенең «кирелеген» барыбер җиңә алмады. Аннан соң әнкәсе арага кергән булды, Сәгыйтьне яклаган булды. «Үз вакыты белән барыр әле әйдә, юкка борчылма инде син»,— дигән булды. Аның хәзер әз генә кыек сүз әйтсәң дә хәтере калырга, күңеле кырылырга гына тора иде, энесенең үзен «туган итмәвен», «санга сукмавын» күреп, әнкәсенең аны яклап шундый сүзләр сөйләвен ишетеп, ул хәтта бераз гына балавыз да сыгып алды.

Шулай да Сәгыйть баштагы фикерен үзгәртмәде.

Бибинур, өч көн торгач та, Карманга берүзе генә кайтып китте.

Сәгыйть икенче көнне дә, өченче көнне дә, бригадир килеп әйткәнне дә көтмәстән, иртән-иртүк торды да, ат фермасына ашыкты, колхозчылар белән бергәләп болынга китте.

— Әллә миңа гашыйк булдың инде, ристан!— диде Гөлсем, аның шулай бер көн калмый эшкә йөрүенә күңеле булып.— Мөгаен, шулайдыр, Яруллага әйтми булмас. Сак бул, җегет!

Баштарак беләкләре, аяк балтырлары сызлады, эштән туктагач та мускуллары кайнарланып сулкылдарга тотынды. Кичләрен, арып-алҗып кайткач, авырайган, авыртынган тәнен кузгатасы да килмәде. Җитмәсә, ике уч төбе дә хан кызларыныкы кебек кабарып чыкты. Ләкин ул, кешеләрнең көлүеннән куркып, арыганлыгын да, куллары кабарганын да беркемгә дә сиздермәде. Торабара мускуллар да язылды, ныгый, чыныга башлады, тәненең авырлыгы да кул белән алгандай юк булды.

Ул көне буе саф һавада эшләүнең, ныгытып ашауның, яхшылап йоклауның үзенә никадәр әйбәт тәэсир иткәнен, моңарчы үз-үзенә урын тапмый сыкрап интеккән күңеленең чын-чынлап тынычлана барганын күрде. Ул хәзер Иданы элеккечә тиле, аңсыз сагыш белән сагынмады, аның турында шикле, көнчел уйлар уйлап газапланмады. Печән чабуга бирелеп киткәч, кешеләр белән, үзеннән олырак та, тәҗрибәлерәк тә кешеләр белән аралаша башлагач, әйтерсең әлегә кадәр аның күңелен каплап торган элпә ертылып ташланды, һәм ул үзенең Идага карата булган хисләрен аек акылга буйсындыра алды. Юк — ул аны күңеленнән чыгарып ташламады,

аңа карата салкынаю кебек нәрсә дә тоймады һәм үзалдында андый максат та куймады. Ул аңа бары тик бернинди шикләнү-икеләнүсез ышанды, моңарчы беркайчан да булмаган төпле, нигезле ышаныч белән ышанды. «Ул мине ярата, мин аны яратам, шулай булгач, нигә бер дә юкка кайгырырга!»— диде ул үз-үзенә.

Ялга туктаган араларда җыелышып сөйләшүләр көндәлек гадәткә кереп китте. Күп кенә очракларда сүз бригада хәлләре, колхоз, район хәлләре турында барды. Мондый чакларда Сәгыйть еш кына сүзгә катышмыйча, кеше әйткәнгә колак салып кына утырды. Кайчакларда Мәрдәншә агайлар, Заһирҗан агайлар үткәннәрне хәтерләделәр, берәр кызыклы вакыйганы искә төшереп көлешеп алдылар. Ләкин кайчан гына булмасын, иң азактан чират барыбер Сәгыйтькә килеп җитте. Аңа сораулар бирделәр, сөйләттеләр, күңел биреп, игътибар белән тыңлап утырдылар. Ул аларга бөтенесен дә исендә калган буенча сөйләде, аның алдында конспектлар да, китап, брошюралар да булмады. Ул үзе кайчандыр имтихан биргәндә сөйләгән нәрсәләрен казып чыгарды, хәтерендә онытылмый сакланган фактларны, исемнәрне, теория һәм законнарны, елларны, көннәрне исенә төшерде. Аңа хәзер бүтән вакытка караганда да ныграк газета укырга, яңалыкларны карап, күзәтеп барырга кирәк булды, ләкин ул уку өенә бер генә мәртәбә дә бармады. Газеталарны бригадир аша китертә башладылар.

Бер көнне ул эштән иртәрәк кайтты. Әнкәсе баскыч алдында Тәлгать белән, чебешләр белән ыгы-зыгы килеп ята иде. Шул вакыт урамда култыклашып килгән бер егет белән бер кыз күренде, Сәгыйть, кызыксынып, ачык тәрәзә аша аларга таба карап тора башлады. Авыл уртасында, җитмәсә, караңгы төшмәс борын, кызлар белән егетләрнең култыклашып йөрүе бераз сәеррәк иде, әлбәттә. Парлы кешеләрне, бер-берсенә карап елмаешып килгән яшьләрне күреп, Сәгыйтьнең күңеле тынычсызланып куйды. Аның да шулай үзләренең авыл урамыннан Ида белән бергәләп йөрисе килде; ул шуны күз алдына китерергә тырышты, һәм бу минутта ул бәхетле егеттән чынчынлап көнләшү хисе тойды. «Шулай да кемнәр икән соң алар?»— диде ул, үз-үзенә сорау биреп.

Бер кулына Тәлгатьне, икенче кулына җиме ашалып беткән таба тотып өйгә килеп кергән әнкәсе, башын иеп, урам якка карады да:

— Инсафлар лабаса!— диде, «тапкансың танымас кеше!» дигән кебек.— Катыны белән... Безгә киләләр түгелме соң?

Инсаф белән хатыны, урам уртасындагы юлдан кырт кына сулга борылдылар да, һаман култыклашкан көе, туп-туры Сәгыйтьләр өенә таба юнәлделәр.

Инсаф Сәгыйтьнең бала вакыттагы дусларыннан берсе иде, дөресрәге, Барисның дусы, Барисның яшьтәше иде. Ул әле быел яз көне генә армиядән кайткан һәм каяндыр чит авылдан килгән бер яшь укытучы кызга өйләнеп алган иде.

Инсаф, ишек башына орынмас өчен, бераз иелә төшеп, бусаганы аркылы атлады да, өй эчен гөрелдәвек көр тавыш белән тутырып:

— Исәннәрмесез, хуҗалар!— диде һәм зур-зур атлап түргә узды, беренче булып Миңнисәттәйнең кулын кысты, аннан соң Сәгыйть белән күреште.

Сәгыйтькә аның кулы бик каты, бик көчле булып тоелды. Инсаф артыннан аның хатыны да шуны ук кабатлады. Монысының исә кулы бик бәләкәй, бик йомшак, ләкин хатын-кызга хас булмаганча, салкын иде. Өй эченә очсызлы хушбуй, яңа плащ һәм яхшы хром итек исе таралды.

Сәгыйть шундук Инсафның хатынына игътибар итте. Әллә дөньяда үзенең Идасыннан башка матур кызлар булуы мөмкин түгел дип исәпләгәнгә, Сәгыйтькә ул беренче караштa ук ошамады. Аның бөтен нәрсәсе кара иде. Бик ямьсез итеп киселгән чәчләре, кырылган нечкә кашлары гына түгел, өстенә кигән җылы свитеры да, бөрмә итәкле юбкасы да, аягындагы елкылдап торган лаклы, биек үкчәле яңа туфлие дә, хәтта кәкрерәк, кыскарак балтырларын кысып торган ефәк оеклары да — бары да карадан иде. Әллә әрлән, әллә тычкан — гомумән, үткер тешле ниндидер җәнлек күзен хәтерләткән нурсыз, кысык күзләре дә шулай ук кипкән шомырт кебек кап-кара иде.

Күңеленнән Сәгыйть шушы килешсез гәүдәле бәләкәй генә хатын белән Иданы бергә куеп карады һәм Инсаф алдында үзенең сөйгән кызы өчен бәхетле горурлык хисе тоеп: «Юк, синеке минеке белән чагыштырырлык та түгел. Синең хатын, Инсаф дус, минем Иданың кисеп ташлаган тырнагына да торырлык түгел!»— диде үз-үзенә.

Инсаф хәзер инде саескан күкәе алыр өчен биек чыршы башларына песи кебек менеп китә торган җиңел сөякле, җиңел аяклы малай да, теләсә нәрсәсен дуслары белән бүлешергә әзер торган иптәш тә түгел иде, бәлки, бары тик йөзендә һәм тавышында гына әзрәк элекке Инсаф билгеләре булган ир кеше иде, чит кеше, ят кеше иде. Сәгыйть аңа карата үзен ничек тә якын итеп, дус

итеп тотарга тырышмасын, нигәдер аның янында ул үзен кыен сизде. Аны күреп шатланганлыгын күрсәтү өчен, ике арадагы сүзне өзмәс өчен аңа көчәнеп елмаерга, әллә ни әһәмиятле булмаган ниндидер нәрсәләр турында сөйләргә, юк-барны сораштырырга туры килде. Инсафның үз-үзен тотышы, юри тавышын күтәреп сөйләшүе, ике сүзнең берендә алдагы ике-өч алтын тешен елтыратып, теләр-теләмәс кенә, салкын гына көлеп куюы, үзенең дәрәҗәсен, тормыштагы урынын яхшы аңлаган тәҗрибәле кеше кебек, әкрен генә сөйләшүе һәм һәрбер сүзен бизмәнгә салып үлчәгән шикелле, металл кабыклар арасыннан суырып чыгаруы — барысы да ясалма, эч пошыргыч иде.

Алар шулай артык бирелеп, җанланып китмичә, тегебу турыда сөйләнеп утырдылар. Инсаф үзенең армиядә булуы, кайда хезмәт итүе турында, әлерәк кенә хатынннарының авылына барып кайтулары турында, бабаларының бик бай яшәүләре, хатынының бер абыйсы районда «зур кеше», икенчесе шофер, өченчесе кайдадыр еракта инженер булуы турында сөйләде. Бераздан самовар кайнап чыкты. Миңнисәттәй кунаклар килгән чакта гына куела торган тәм-төмнәрен чыгарды, барысы да чәй тирәсенә утырыштылар. Инсаф, шыгырдавык итәкле плащын ычкындырып җибәрде дә, башын боргалап, урам якка карап алды.

— Барислар бик соң кайта икән,— диде үзалдына сөйләнгән кебек.

— Эш кешесенең шулай инде, соң кайткан чаклары да була, кояш баемас борын да кайтып керәләр,— диде Миңнисәттәй, чәй ясап.

Инсаф җиңелчә генә тамак кырып куйды да, бер як күз кырые белән хатынына карап алды һәм:

— Карчык белән менә Урта Азиягә китәргә итәбез әле,— диде, Сәгыйтькә таба борылып.

— Урта Азиягә? Нигә?

Сүзгә Инсафның хатыны кушылды.

— Минем анда бер апа бар. Ике чемодан тавар алып кайткан, җаның ни тели, шул бар, ди...

— Нәрсә... бөтенләйгәме дигәндәй, әллә болай гына, тавар алып кайтырга гынамы?

Инсаф тагын сиздермичә генә хатынына күз төшереп алды.

— Бөтенләйгә дип торабыз инде,— диде ул, көттереп.— Кесәдә паспырт бар — ул яктан кайгы юк. Берике атнадан китәм, ди карчыкның апасы... Шулайрак... Китәргәме, юкмы...

— Соң үзебездә... калхузда ничек?— диде Сәгыйть,

Инсафның күзенә туры карап, әкрен генә.— Анда бар тавар монда да бар, бөтен җирдә дә бар ич хәзер.

Инсаф салкын гына көлеп куйды.

— Калхузда?! Калхузның ничек икәнен күреп торасың ич... Тирес түгеп кенә җөрисе калганые!

Мондый сүзләрне ишетү Сәгыйтькә бик авыр иде, Инсафның бернинди кайгысыз-борчылусыз үз туган авылын ташлап читкә китәргә теләве өчен, үзен үстергән, үзен кеше иткән туган колхозы турында шулай бик җиңел генә сөйли алуы өчен авыр иде.

Сүзгә тагын Инсафның хатыны кысылды.

— Җимеш белән буа буарлык, ди... Оҗмах инде, оҗмах, ди...

— Оҗмах теге дөньяда гына була ди түгелме соң?— диде кинәт Сәгыйть, коры гына.

Инсаф хатыны шундук тынып калды. «Әйттем мин сиңа!»— дигән шикелле, тычкан күзләрен зәһәрле елтыратып, иренә бер карап алды да, ашыгып эссе чәй чөмерергә тотынды. Сәгыйть алар арасында читкә китү, китмәү мәсьәләсендә бик күп сүз булганын һәм Инсафның икеләнгәндәй иткәнен сизенеп алды.

— Хатының укытучы инде — аңа эш булыр, син нишләрсең соң?— диде ул Инсафка.

Мондый сорау Инсафның үзе өчен дә ачык түгел иде, ахры.

— Күз күрер әле... Эш беткәнмени донҗада.

— Соң алайса монда да эш аяк асты тулы ич!— диде Сәгыйть, җанланып. Аның ничек тә Инсафны уеннан кире кайтарасы килә башлады.— Камбайнда эшләсәң дә була, тракторда да... Нигә, шулай түгелмени? Әгәр калхуз эшендә эшлисең килми икән, пажалыста! Эшлиләр дә, алалар да. Шулай ич?

— Инсафның тазалыгы начар, андый кара эшкә ярамый ул,— диде кара хатын, ирен яклап.— Тырактырчы? Бик кирәге барые! Шайтан кебек...

Сәгыйть, ирексездән, Инсафның янып торган кызыл, юан муенына, киң кулбашларына карап алды. Типсә тимер өзәрлек, басса бакыр өзәрлек шушы аттай егет турында «тазалыгы начар» дип әйтү аңа көлке тоелды.

— Әгәр бик читкә китәсең килә икән — кит нефтькә!— диде ул, һаман бирешергә теләмичә.— Бездә әнә нинди нефть чыгаралар! Менә шәп булачак! Нәсим әнә шушы яшенә җитеп тә, унынчыны бетерергә, нефть институтына китәргә хыяллана. Китегез икәүләп. Валлаһи! Нефтьчеләр өчен яңа шәһәрләр салалар, акчаны алар көрәп кенә ала — яхшы эшләгәннәре, билгеле...

Инсаф аңа каршы берни әйтмәде. Хатыны исә кинәт тынычсызлана башлады, утырган урынында кузгалып-кузгалып куйды, күзләрен тутырып, әледән-әле ире ягына карап алды. Ниһаять, чәй эчеп туйдылар да, урыннарыннан торып, саубуллаша башладылар. Сәгыйть аларны капка төбенә кадәр озата чыкты. Инсаф хатынын култыклап алды һәм ясалма ягымлы тавыш белән:

— Киттек, карчык,— диде.

Алар чыгып киткәч, Миңнисәттәй яңадан самовар янына килеп утырды.

— Ашаганым аш булмады,— диде ул, нигәдер үртәлеп. Аның Инсафлар бар чагындагы якты чыраеның эзе дә калмаган иде.— Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер... Тутырып куйганнар ди сиңа читтә! Игелексезнең кайда да игелексез — Азиягә түгел, Каф-тау артына олаксалар да, рәт чыкмас. Син дә шуларга телеңне әрәм итеп утырасың тагы... Кара син — тирес түгәсе килми икән шәп җегетнең! Тикмәгә килгәннәр дисеңме аларны — Барис янына килгәннәр алар. Бер заман безнең Барис та шулар белән бергәләп китмәкче булып котырып җөргәние, килен белән көчкә акылга утырттык. Салдаттан кайтканына ни гомер, бер эшкә дә кул тыгасы килмичә, эт сугарып җөри, әдәм көлкесе! Әзрәк ояла да белмиләр ичмаса. Уттай эш өстендә катын белән култыклашып җөргәч тә ни ул... Ярый инде — чиләгенә күрә капкачы. Каян тапкан Ходай Тәгалә шундый «уңган» катынны!

Сәгыйть, әнкәсенең үзалдында дулап утыруына гаҗәпләнеп:

— Нәрсә син, әнкәй,— диде,— кешенең күз алдында ал да гөл, үзләре юк чакта эттән алып эткә саласың!

— Кеше шикелле кешенең алдында да, артында да бер буласың,— диде Миңнисәттәй, һаман тынычлана алмыйча.— Куалап җибәрмәм ич инде мин аларны!

## V

Сәгыйть кич чыгып китте. Ләкин клубка якынлаша башлагач, ул үзенең кемнәндер, ни өчендер шүрләгәнен сизде, аяклары үзеннән-үзе карышты. Туктады да, Нәсим янына керергәме, кермәскәме дигән шикелле бераз икеләнеп торды һәм, кырт кына борылып, идарә йортына таба китеп барды.

Идарә йортының баскыч алдына да, чоланына да электр-фәлән куелмаган иде, шуңа күрә чоланда күзгә төртсәң күренмәслек караңгы иде. Ул, текә баскыч буенча

кармалана-сыйпалана менеп барганда, кинәт кемгәдер килеп бәрелде.

— Күзең жукмы әллә, кеше өстенә килеп менмәсәң!— диде кеше, кисәк кенә кабынып китеп, ачу белән.

Сәгыйть аның тавышыннан бакчачы Миңгали карт икәнен танып алды һәм шундук үзенең саксызлыгы өчен гафу үтенергә тотынды. Миңгали карт җавап кайтармады, бары тик ишеккә килеп җиткәч кенә, кем беләндер сөйләнгән кебек:

— Илектерне китерттеләр, бер фанар куярга да башларына килми,— дип куйды.

Ишек янында рәшәткә кебек барьер белән бүленеп алынган, бер-ике өстәле, бер-ике шкафы һәм стена буена тезеп куелган скамьялары булган иркен бүлмә эче япякты иде. Председатель өстәле янында, кыяфәтләренә караганда бригадирлардыр дип исәпләргә мөмкин булган берничә кеше Булатов белән нәрсә турындадыр киңәшләшеп утыралар иде. Сәгыйть Миңгали карт белән бергәләп түргә, скамьяга тезелешеп утырган берничә колхозчы янына узды.

Мәрдәншә агай да монда иде. Ул, Сәгыйтьне күргәч, ымлап аны үз янына чакырды.

— Безнең белән тәмәке тартырга килдеңме?— диде ул, дусларча елмаеп.

— Юк, тәмәке тартканны карап утырыр өчен генә...

Алар сөйләшеп киттеләр.

— Иртәгә өмә була, Җәйләү акланына чыгабыз,— диде Мәрдәншә агай, бик зур яңалык белдергән кебек.

Аның шулай үз итеп, тиң итеп сөйләшүе Сәгыйтьнең күңелен үстереп җибәргәндәй булды. Ул үзен шушы минутта тагын да олыгаеп, тагын да җитдиләнеп киткән итеп тойды. Үзе өчен көндәлек нәрсәгә әйләнгән, гадәтләнгән эш турында сөйләгән кебек, тыныч кына, олыларча гына:

— Өмә дисең, алайса?— дип куйды.— Болай булгач, Җәйләү акланын иртәгә бетерсәк... Аннан соң чабасы да күп калмый.

— Ансы шулай. Түлке, малай, Сәгыйть, печән бездә җитәрлек әле. Өмәне аны алданрак ясаргае да бит, печәнгә төшкәч тә... Ичмаса шулай бер-бер артлы өмә ясасаң, әллә ни күпкә бармасые...

— Халык күп булачак бит инде — чалгылары җитәрлек микән соң?

— Әнә шул турыда киңәшәләр әле...

Ул арада председатель өстәле тирәсендәгеләр кузгалыша башладылар. Шуны гына көтеп торган бакчачы,

җәһәт кенә урыныннан сикереп торды да, һич тә картларга хас булмаганча, җиңел-җиңел атлап, кызыл материя ябылган өстәл янына килде. Карбыз кебек түгәрәк, каты башлы, шешенке күз кабаклы, ияк аслары салынып төшкән, симез, итләч Булатов, өстәл өстендә яткан бер газета почмагыннан тәмәкелек кәгазь ертып маташа иде.

— Иптәш Булатыф,— диде Миңгали карт чиста, ачык тавыш белән, председательнең эше беткәнен көтеп тормыйча сүзгә башлап,— кайчан була инде ат? Бүтәннәр машина белән генә китереп ташлыйлар. Кеше алдында оят шул янбашсыз нәрсә белән.

— Кыскарак сөйләле, Миңгали абзый, аңлатыбрак...— диде председатель, башын күтәреп карамыйча гына, бик зур эш башкарган шикелле һаман тәмәкесе белән булашып.— Атың бар ич синең, тагын ни кирәк?

Бакчачы карт бик кызык кеше иде. Ул, үзен бүлдергәннәрен күреп, ачулана башлады.

— Бар!— диде ул, тавышын күтәрә төшеп.— Ярты ат ул, миңа бөтен ат кирәк... якшы ат... Җиләк шәп үтә, базарга барып атыңны туктатасың, сырып та алалар. Кая куяр урын җук, киптерергә туры килә. Якшы ат булганда көненә икешәр терит барып кайтырга булырые.

— Тагын нинди ат инде ул, Миңгали абзый? Берни эшләмичә, ашап кына яткан ат та ярамагач, каян алып бирим инде мин аны сиңа?

— Ята! Тик ята! Кем әйтә аны тик ята дип?! Гарип атны ашатмагае, нишләтсәң дә барыбер гарип. Базарга барып җиткәнче шыбыр тиргә төшә, тау менгәндә үзем арттан этеп мендерәм арбаны. Ашап ята!.. Җиләк үтә торган чак — бүген дә биш йөз тәңкә чыгарып кайттым. Печән дип төнге каравылчымны алдыгыз, төн куныпятам. Гайнулланың нинди печән чабар җире бар? Бакчада шапылдавыгын шакылдатып булса да ятадырые...

Булатов, Миңгали картның сүзен бик зур игътибар белән тыңлаган шикелле, тәмәкесен пошкыртып, тын гына утыра бирде. Аның гомумән бик авыр кыймылдаучан, сүлпән һәм җитәкче булу өчен артык тыныч, иренчәк холыклы кеше булуын Сәгыйть элек тә белә иде. Бу минутта ул аңа бик ачу китергеч булып күренде. Ул аның бакчачыга ни әйтәсен көтте. Булатов исә урыныннан кузгалды да, бик арыган, ләкин шулай да нәрсә турындадыр бик тырышып уйлаган кеше кыяфәте белән, Миңгали картка карамыйча гына:

— Ярар, абзый,— диде, аны тынычландырырга теләп,— булыр, булыр.

— Кайчан булыр?

— Иртәгә үк булыр. Бригадирлар бар чакта әйтмәдең, менә шунда уйлашырыек. Хәзер инде соң.

Бакчачы карт үзалдына нидер сөйләнеп куйды, ләкин шулай да күңеле булды, ахры, саубуллашып-нитеп тә тормыйча, туп-туры ишеккә юнәлде. Ул чыгып күп тә тормады, ишектән хатынын ияртеп Инсаф килеп керде. Бүлмәдәгеләрнең барысы белән дә кычкырып исәнләште дә, плащ итәкләрен кыштырдатып, тирә-якка вакса исе таратып, Булатов янына килде.

— Килденме?— диде Булатов, яңадан үз урындыгына утырып.

— Килдем. Үзем генә түгел — хатын белән,— диде Инсаф, елмайган булып.

Әлерәк кенә чыгып киткән Низамый яңадан килеп керде, авыр күн итекләрен шак-шок басып, председатель өстәле янындагы бер урындыкка килеп утырды да, башындагы кепкасын салып, өстәлгә ыргытты һәм Булатов каршысында атлы казак кебек аякларын аерып басып торган Инсафка караган көе, сүзсез калды.

— Ни эшләр бетереп ятасың, Инсаф?— диде Булатов.

— Бетергән эшләр җук әле хәзергә,— диде тегесе иренеп кенә, Низамый каршысындагы урындыкка утырып.

— Менә нәрсә, энекәем, иртәгедән печәнгә чыгарга кирәк булыр сиңа,— диде председатель нык, боеручан тавыш белән.

Инсаф, аның сүзен ишетмәгән шикелле, һаман илтифатсыз төс белән тын гына утыруында булды.

— Мин аңа әйттем, җә өйдә җук, җә кунакка китте, диләр. Бер кешене биш итәргә торган чак,— диде Низамый, сүзгә катышып.

— Шулай, энекәем, җитәр, яздан бирле гүләйт итәсең, эшкә тотынырга да вакыт.

Инсаф «сезнең бер генә сүзегез дә миңа кагылмый» дигән кыяфәт белән:

— Без читкә китәргә итәбез, Булатыф абый,— диде председательгә.

— Кайчан?

— Син моннан бер ай элек тә шулай дигәниең!

— Анысы бер ай элек, хәзер...

— Син җыенып киткәнче, тагы бер ай узар әле!

Инсаф коры, салкын күзләрен Низамыйга текәде дә, кырт кына:

— Ничә ай үтсә дә үтәр, анда синең эшең җук!— диде.— Мин калхузчы түгелме — түгел! Мине көчләп эшкә кушарга синең ни хакың бар?

Низамый урыныннан ук сикереп торды.

— Минем хакым җукмы?— диде ул, кызып китеп.— Күрсәтермен мин сиңа хакны!.. Калхузчы булмый — кем син?..

Ләкин Булатов өстәл яныннан чыкты да, аларның икесен дә килештермәкче булган кебек:

— Син, энекәем,— диде Инсафка,— китсәң кит, китмәсәң — җөрмә авылда кешегә күзегеп. Синең өчен менә монда сүз ишетергә туры килә.

— Шул гынамы, бүтән сүзегез җукмы, Булатыф абый?— диде Инсаф, председатель сүзләреннән күңеле үсеп киткән шикелле булып.

Аннан соң торды да, кулларын плащ кесәсенә тыккан көе, үз дәрәҗәсен төшермәскә тырышкан сыман, башын югары тотып, ишеккә таба юнәлде. Аның артыннан хатыны да иярде.

— Иртәгә өмә була. Катының белән икәүләп барыгыз!— дип кычкырып калды Низамый алар артыннан.

Инсаф борылып та карамады, җавап та бирмәде. Алар чыгып киткәч, ишек кенә шапылдап ябылып калды. Шундый нык шапылдады — түшәм ярыкларыннан өстәлдәге кәгазьләргә туфраклар коелды.

...Авыл бүтән көннәргә караганда иртәрәк уянды, урамнарда ыгы-зыгы башланды, бер-берсенә эндәшеп кычкырышкан, капка ачып-япкан тавышлар ишетелде, кулларына чалгы тоткан кешеләр күренде.

Барисларның бүген ял көне иде, алар өмәгә икәүләшеп бармакчы булдылар. Сәгыйть аларны көтеп тормады — үзенекеләрдән соңга калмас өчен, тизрәк ат фермасына чыгып йөгерде.

Заһирҗан агайлар инде кузгалып киткәннәр иде.

— Тукта! Көт!— дип кычкырды Сәгыйть ерактан ук, аларны күреп.

Аны шундук ишетеп алдылар, атларын туктаттылар да, көтеп тора башладылар.

— Җегет кеше бу вакытка кадәр җоклап ятамыни — тиз бул!— диде Гөлсем, кычкырып.

Сәгыйть килеп җитүгә, көчле кулы белән аның җиңеннән тотып алды да, үзе яныннан урын биреп:

— Утыр, нәрсә җебеп торасың!— диде.— Ярулла күрмәс әле... Күрсә тагын, ша-айтан, синең катының янына утырмадым, кызлар янына утырдым диерсең.

Сәгыйть, арбага җайлап утыргач, үзенең икенче ягына борылып карады. Анда Зәйтүнә утыра иде. Әллә аның өстендә эш киеме булганга, әллә ашыкканга, ул аны башта

ук күрмәгән иде. Студентның күз карашы белән очрашкач, Зәйтүнә нидәндер уңайсызланган шикелле тиз генә күзләрен аска төшерде; ирен читләрендә йомшак кына елмаю билгесе күренеп китте.

— Күрше дә монда икән,— диде Сәгыйть.— Бүген печән җыймыйбыз түгелме соң?.. Әллә син дә чабарга?

— Чабарга...— диде Зәйтүнә, оялчан хәрәкәтләр белән күлмәк итәкләрен җыештыргалап.

— Чалгы белән?!— диде Сәгыйть, Зәйтүнәнең чыннан да печән чабарга баруына гаҗәпләнгән булып.

— Урак белән!— диде Зәйтүнә һәм, ак тешләрен күрсәтеп, чын күңелдән көлеп җибәрде. Сәгыйтьнең теге кичәдәге шикелле тагын бер дә юкка көләсе килеп китте.

— Җә, булдыңмы, мыштырдык?— диде Гөлсем, Сәгыйтькә карап, һәм шундук дилбегә тотып утырган малайга борылды.— Кузгал!

Төне буе ашап чыкканга, корсагы мичкә кебек юанайган, хәл җыйган ат, колакларын шомартып, әкрен генә кузгалып китте. Ат, теләр-теләмәс кенә юырта башлагач, Гөлсем тагын команда биргән кебек кычкырып җибәрде:

— Уйна!

Әткәсе янына сыенып, кысылып утырган Фәүзинең кулына кемдер гармун тоттырды.

— Монда уйнап булмый,— диде малай, нигәдер шыңшып.

Сәгыйть аны ике куллап күтәрде дә, җилтерәтеп үзенең тез башына утыртты һәм аның биленнән иңләп кенә тотып алды. Фәүзи, уңай урынга утыргач, көчсез куллары белән гармун күрикләрен тартып җибәрде.

Җырны Гөлсем башлады. Аның тавышы, сөйләшкәндәге кебек, бераз калынрак, тупасрак, ләкин шулай да чиста, тигез иде. Ул бер дә артык көчәнмичә, тотлыкмыйча җырлады, һәм югары ноталарны алганда аның кыска муенындагы кан тамырлары бүртеп-бүртеп чыкты. Җырга Зәйтүнә дә, Сәгыйть тә, арбаның ике ягына да аякларын салындырып утырган бүтәннәр дә кушылды. Күмәк җыр тавышы, иртәнге авыл урамын яңгыратып, тирә-яккә агылды. Сепараттан кайтучы хатын-кызлар, урамда очраган агайлар өмәчеләрне туктап озатып калдылар. Туйга йә булмаса җыенга баралармыни!

Басу юлына чыккач, арттан бер ат куып җитте. Аның артыннан тагын икенче, өченче ат күренде. Аларга да өмәчеләр утырган иде, аларда да кычкырып гармунга җырлыйлар иде.

Кояш һаман югарырак күтәрелә барды. Килеп җиткәч, арбаларын болын читендәге карамалар күләгәсенә кертеп туардылар да, атларны тышаулап, бил тиңентен куе печәнлеккә ашанырга җибәрделәр.

Сәгыйтьләргә кадәр монда инде бер-ике ат килеп туктаган һәм тышлары корымланып беткән ике зур казан учак өстенә җайлап урнаштырылган иде. Шунда ук, арба янында, берьюлы ике җирдә, бер-берсен узып чекелдәшкән тавышлар ишетелә — анда чалгы таптыйлар иде. Иртәнге кояш нурында кәкре корычлар ялтырый, кеше башлары өстендә чалгы саплары бутала иде.

Атлар һаман килә торды, әрәмәлек буе берничә минут эчендә чегән таборына охшап калды, тавыш, чыр-чу торган саен көчәя төште.

Бүген монда бөтен авыл диярлек күченеп килгән иде. Монда, гадәттәге печәнчеләрдән башка, авыл интеллигентлары да, контора эшчеләре дә, бүтән вакытта «чирләп» эшкә чыкмый ятучылар да, каралган киемле МТС кешеләре дә, үз колхозларыннан китеп, район үзәгендә акча эшләүче элекке колхозчылар да, бик яшьләр дә, бик картлар да бар иде. Тик... бригадир Низамый хатыны гына юк иде.

Сәгыйть болында беренче мәртәбә бу кадәр күп кеше күреп: «Менә сиңа көч!»— дип уйлап алды һәм якында гына торган Заһирҗан агайга:

— Көн дә шулкадәр кеше булса, ә!— дип куйды.

— Яртысы да ярарые әле аның, Сәгыйть,— диде Заһирҗан агай.

Элек, колхоз нык чакта, сугышка кадәр, нәкъ хәзерге кебек була торган иде бит. Өмә вакытларында гына түгел, көн дә шулай була торган иде. Печәнгә төшәр вакытны колхозчылар бәйрәм көткән кебек көтеп ала торганнар иде, печәнчеләрне эшкә автомашина белән генә китереп куя торганнар иде.

Сәгыйть малай чакта үзенең Барис белән бервакытны печән кибәне төбендә яңгыр туктаганын көтеп утыруларын исенә төшерде. Аларны болынга баручы автомашинага утыртмаганнар иде, шуннан соң алар әнкәләре печән җыйган җиргә җәяүләп киткәннәр иде. Әнкәләре янына барып җитәргә бер ярты чакрымнар калгач, коеп яңгыр яварга тотынды. Шунда яңа гына салынган печән кибәне бар иде. Яңгыр туктаганчы дип, алар шул кибәнгә кереп утырдылар. Алар шундый арыганнар, шундый хәлсезләнгәннәр иде, шыбырдап яуган яңгыр тавышына эреп йокыга киткәннәрен дә сизми калдылар. Уянып китсәләр, яңгыр туктаган, күк йөзе ачылган, бөтен җир

өсте яшәреп, чистарып калган иде һәм шомырт, зелпе яфракларыннан бөрчек-бөрчек яңгыр тамчылары асылынып тора иде. Алар җылынган ояларыннан торып, әнкәләрен эзләп киттеләр. Алар барып җиткәндә, болында инде беркем дә калмаган, колхозчылар, чыланган печәнне җыярга мөмкин булмаганга, яңгыр туктагач та кайтып киткәннәр иде. Аларга кире өйгә борылырга туры килде. Бик нык ачыктылар, арыдылар — өйгә кайтып җиткәнче аяк атлар хәлләре дә калмады. Кайтырга исә бик ерак иде. Ашыйсы килүдән Сәгыйтьнең күз аллары томалана, башы әйләнә башлады. Алар әледән-әле хәл җыйдылар. Ул чакта аңа дөньяда үзеннән дә бәхетсезрәк беркем дә юктыр шикелле тоелды.

— Абый, син хәзер нәрсә ашарыең?— диде ул Бариска, җылы өй турында, булары чыгып торган кайнар бәрәңге турында хыялланып.

— Минме?— диде Барис, арттан өстерәлеп килгән энесенә борылып.— Мин хәзер пешкән шалкан ашарыем.

Сәгыйть аңа каршы берни дә әйтмәде: өйдә чакта Барисның пешкән шалканны күрәсе дә килмәгәнен ул бик яхшы белә иде.

Шушы болын аша кайтканнар иде түгелме соң әле алар? Әйе, әнә теге шомырт куагыннан Барис шыбын кебек төз чыбык кисеп алган иде бит.

Сәгыйть үзалдына елмаеп куйды.

Ул Низамый арбасы янына җыелган кешеләр янына китте. Анда аңа бер таныш кеше күренде. «Әһә, килгән түгелме соң?»— диде ул үз-үзенә, чалгы таптаучылар арасындагы Инсафны танып алып. Инсаф, калын табанлы кирза итек кигән аякларын аерып баскан көе, ак күлмәк җиңнәрен сызганып җибәреп, чалгы сабы рәтләп маташа иде. Ул гадәттә булмаганча, күтәренке күңелле күренә иде, башын артка ташлап, әледән-әле нигәдер кычкырып-кычкырып көлә, хатын-кызлар белән шаян сүзләр әйткәләшә иде. Аның теге көнне үзен олы итеп, дәрәҗәле кеше итеп күрсәтергә тырышуы Сәгыйтькә ничек ят, ничек чит тоелган булса, бүген дә аның мондый эшлеклe-дәртле кыяфәте ясалма, ялган булып тоелды.

— Барамы эшләр?— диде Сәгыйть, аның янына килеп.

Инсаф, чалгы сабы белән селтәнеп, башын күтәреп карады.

— Бара! Кая ул бармаган!

— Ничегрәк бара соң?

— Ат мөгезе кебек!

Көтмәгәндә каяндыр, усал ана каз шикелле муенын

сузып, берәр ярамаган нәрсә сөйләшмиләрме болар, дигән шикләнүле төс белән, Инсафның хатыны килеп җитте. Гадәт өчен генә, дигән сыман Сәгыйть белән елмаеп бер исәнләште дә, бүтәннәргә сиздермәскә тырышып, иренә мәгънәле генә күз карашы ташлап алды. Ләкин аның мондый кыланышына элек тә игътибар иткән Сәгыйть бу карашны шундук күреп алды, һәм аңа кинәт нигәдер, кем өчендер уңайсыз булып китте. Ул үзенең шушы төпек кенә кара хатынны, үз күңелендә кешеләргә турыдан-туры әйтелми торган ниндидер шикле, ниндидер керле уй саклаган шушы зәһәрле хатынны нишләптер дошман күрүен, нишләптер аннан чиркәнүен тойды. Ул тизрәк Инсаф яныннан китәргә ашыкты.

Күп кенә кешенең үз чалгысы юк иде, шуңа күрә эш башлаганчы складтан Низамый алып килгән яңа чалгыларны таптарга, сапларга, җайларга туры килде. Бу исә бик күп вакытны алды. Кояш һаман ныграк кыздырды, һаман югарырак күтәрелде, һәм өмәчеләрнең күбесе нишләргә белмичә, вакытларын бушка уздырдылар. Бүтән көннәрне бу вакытта инде бертын эшләп, ял итәргә утыра торганнар иде. Сәгыйтьнең эче поша башлады. Ул, эш юктан эш булсын дип, Гамбәрнең чалгысын икенче мәртәбә рәтләргә тотынды, дөресрәге, Бариска яңа бөгәлҗә куярга ярдәм итте.

Алар янына кулына кыскарак кына саплы җиңел чалгы тотып, Зәйтүнә килеп туктады.

— Игәүләп кенә бир әле, Барис абый?— диде ул. Аннан соң гафу үтенгән сыман әйтеп куйды: — Әткәй игәрмен дигәние дә... Эше бар...

— Була ул, күрше,— диде Барис, көттереп-нитеп тормыйча.— Шулай да бераз гына сабыр ит инде син, игәү юк. Әнә Гайнулла бабайдан бушасын да, ялт итеп игәп ташларбыз.

Сәгыйтьнең күңеле кинәт урыныннан кузгалган шикелле булды. Зәйтүнә Барис янына түгел, бәлки, аның янына — Сәгыйть янына килгән һәм шуңа күрә ул Бариска түгел, аңа — Сәгыйтькә эндәшә кебек тоелды. Аның шундук кызның теләген үтисе килде, ләкин ул, күңеленә килгән әлеге уйдан тиз генә исенә килә алмыйча, авызын йомып, баскан урынында катып тик торды. Ул арада алар янына Рәшит килеп җитте, кесәсеннән башланмаган яңа игәү тартып чыгарды да, кыю гына:

— Менә ул игәү!— диде, Зәйтүнәнең каршысына туктап.— Каяле үзем игеп бирим. Без аны бер ышкуда кыяк кебек итәбез!

Кыз бер сүз дә әйтмәде, Рәшит, аның риза булу-бул-

мавына да карамастан, кулыннан чалгысын тупас кына тартып алды да, чалгының нык сапланганмы-юкмы икәнен белмәкче булып, кыланып, аның әле бер җиреннән, әле икенче җиреннән тотып, тарткалап карады, аннан соң читкәрәк китте һәм шундый ямьсез, шундый килешсез бөгелеп, тапталган печәнне кыркырга тотынды.

— Авыр. Сиңа авыр бу,— диде Зәйтүнәгә.— Әйдә, алмашабыз! Чабасыңмы минеке белән? Карале, сизелми дә... Менә, ичмасам, чалгы, чәч пәкесемени! Әйдә, чап.

Зәйтүнә Рәшитнең җирдә яткан чалгысын күтәреп карады да көлеп җибәрде.

— О-о, җиңел икән! Биш пот. Минем үземнеке дә әйбәт. Үткерлә үземнекен.

Егет, мондый тәкъдимгә шатланып, бик риза булып, тапталган печән өстенә утырды да, аякларын бөкләп, шундук эшкә тотынды. Ирексездән гел алар ягына карап, аларның һәрбер кыланышларын күзәтеп торган Сәгыйтьнең күңелендә кинәт көнләшү шикелле бер нәрсә уянды. Зәйтүнәнең чалгысын башта ук үзе алмаганга ул үкенеп куйды. Аның Рәшит каршысына барып, аны Зәйтүнә чалгысы яныннан куалап җибәрәсе килде, ләкин бу аңсыз теләк шундый яшерен, шундый куркак иде, аның бу турыда хәтта үз-үзенә танырга да батырчылыгы җитмәде. Ул, Барисның бер үзен генә калдырып, читкә китеп барды.

## VI

Зур болын чабылып беткәч, печәнчеләр, берничәшәр кешелек вак төркемнәргә бүленделәр дә, әрәмә арасындагы яланнарга таралдылар.

Сәгыйть ниндидер аралыкта бүтәннәрдән аерылып калды һәм ике ягыннан да биек шомырт, кара зелпе агачлары кысрыклап торган озын, тар ачыклыкка килеп чыкты. Монда, кояш яктысы бик әз төшкән дымлы, йомшак җирдә, печән бил тиңентен булып, котырып үскән иде. Шулай да чабарга башта бик үк авыр булмады, калын сабаклы сусыл үләннәр, артык карышып тормыйча, үткер корыч алдында кыелып баш иделәр, егылып төштеләр, бергә укмашып тигез рәткә өелә бардылар. Ләкин эчкәрәк кергән саен, таяк кебек озын ат кузгалаклары, каты аткыйлар күбрәк очрый башлады, җитмәсә, чалгы әледән-әле чыбык-чабыкка барып төртелде. Болын пычранган, бозылган иде. Шуңа күрә Сәгыйтькә еш кына туктарга, үзалдын чыбыктан чистартырга туры килде.

Һәм ул туктаган саен, кемнедер көткән кебек, һаман артына борылып карады. Аннан аңа Зәйтүнә килеп чыгар төсле тоелды. Ул аның килеп чыгуын теләде, ул, онытылып, аның турында уйлады.

Үзе дә сизмәстән, ул тагын артына борылып карады. Куаклар артында чыннан да кемнеңдер чалгысы күренде. Сәгыйть туктап көтә башлады, ләкин бу — аның артыннан чабып килүче Инсаф булып чыкты. Ул, биле авырткан кеше шикелле, гәүдәсен яртылаш кына борып, нечектер куллары белән генә селтәнә иде. Бөтен кыланышыннан, бөтен кыяфәтеннән аның бик үк күңел бирмичә, иренеп кенә, авырсынып кына эшләве күренеп тора иде. Сәгыйть, аның белән очрашасы килмичә, үзалдына борылды да, Инсаф арттан килеп җиткәнче алдагы шомырт куаклары артына яшеренмәкче булып, кызу-кызу чабарга кереште. Ләкин Инсаф барыбер аны күреп алды.

— Сәгыйть! Тукта...— дип кычкырды Инсаф.— Арыттты, парин... Онытылган, печән чабу... Ичмасам тизрәк төш тә җитми.

— Мин әлерәк кенә туктап ял иттем шул. Әйдә, чабыйк әле тагын.

— Ашыкма... Бездән дә калыр әле!

Сәгыйть җавап бирмәде, һаман үз эшендә булды. Ул чаба торган озынча ачыклык икенче башта бик нык тараеп, бер чалгы киңлегендәге генә аралык аша әрәмә аръягындагы киң болынга барып кушыла иде. Сәгыйть кире китеп икенче ал башламаска, туп-туры болын ягына чыгып китәргә булды.

— Син анда минем артта калган җирне чабып бетер инде,— диде ул, үзе артыннан килгән Инсафка борылып.

— Ярар,— диде тегесе.

Сәгыйть, озынча ялан ягыннан алып чыккан алдын бер гөлҗимеш куагы янына китереп терәде дә, җыйнаулашып ял итәргә утырган ирләр янына китте.

— Әйдә, утыр, студент,— диде Барис, энесен каршылап.

Сәгыйть абыйсы янына йөзтүбән сузылып ятты. Гайнулла карт, ике сүзнең берендә корык-корык йөткерә-йөткерә, нидер сөйли, бүтәннәр тавыш-тынсыз гына тыңлап утыралар иде.

— ... Мифтахеттин абзый мәрхүмнекеие... ы-ы,— диде Гайнулла карт, сүтелгән тәмәке кәгазен тел очы белән чылатып.— Заһирҗан, син дә хәтерлисеңдер әле?.. Ы-ы... Яз саен килеп, чыбыкларын, чүп-чарларын җыеп китәрие, мәрхүм. Карап кына торыйе. Ы-ы... Ух-хаха... «Нигә чүп җыеп интегеп җөрисең, Мифтахеттин

абзый?» — диерием. «Һей, Гайнулла энем, диерие, көч җитсә, бөтен әрәмәсен төпләп болын итәрием әле, диерие, көч җук, көч...» — диерие. Ы-ы... Ух-ха-ха... Җылына бер-ике чана печән алырые. Барыбер ачка шешенеп үлде, ы-ы... Хәзер беткән болын бозылып. Аксыргак тулган, ат кузгалагы... Болын да карт кеше кебек тәрбия сорый шул ул, хәзер — җук, пошынучы җук, ух-ха-ха...

Рәшит, Гайнулла картка бик өстән генә карап, үзалдына көлеп куйды.

— Син тагын, бабай, болынны сөреп тырмаларга, түтәлләп куярга кушарсың! Каян машина җиткермәк кирәк аңа? Элек тә элек дисең — ни кырдыгыз соң элек?

— Кыруын кырмагандыр инде ансы, ы-ы... Түлке хәзер машинага гына ышанып яталар, җирне онытгылар, җирне... Җирнең аның телен белергә кирәк, исен сизәргә... Ух-ха-ха... Пырафисыр да куша аны, болынны чистартырга.

— Куша,— диде каядыр читкә, урман ягына карап утырган Заһирҗан агай, Гайнулла карт белән килешеп.— Аңа-ни, пырафисыр килеп кушканны көтеп ятасы да түгел, барысы да үзебездән, үзебездә гаеп. Дөрес, Гайнулла абзый, гел машинага салгашабыз хәзер. Машина ул бик әйбәт нәрсә. Шулай да аның җаны юк. Җансыз берни уңдарып булмый...

Сәгыйть, үз артында кемнеңдер аяк тавышын ишетеп, күтәрелеп карады. Куаклар арасыннан нәрсәдер ашана-ашана Инсаф чыгып килә иде. Ул ял итеп утыручылар янына туктады да:

— Тартыйк әле бер рәхәтләнеп,— диде.— Онытылган, парин. Арыта. Беләкләрне күтәрерлек тә түгел.

— Шул башыңнан арып торгач, минем яшькә җиткәч нишләрсең син?— диде Рәшит, авызын ерган булып.

Инсаф килеп бер-ике минут чамасы торгач та, Заһирҗан агайлар урыннарыннан кузгала башладылар — инде җитәрлек ял ителгән иде. Шул чакны Инсаф артыннан ук диярлек Мәрдәншә агай килеп чыкты. Аның куе кара кашлары җыерылган, бөтен йөзендә нәрсәдәндер ризасызлык, хәтта ачу кебек нәрсә сизелеп тора иде.

Мәрдәншә агай, печәнчеләр янына килеп туктагач, әле генә Сәгыйть Инсафны калдырып киткән тар ялан ягына күрсәтеп:

— Кем чапты анда?— диде коры гына.

Сәгыйть, нидер сизенеп, шундук Инсаф ягына карап алды.

— Нигә? Нәрсә булган, Мәрдәншә абзый?— диде Инсаф.

— Алай болынны пычратып җөрер булгач, җегетләр, бөтенләй килмәскә кирәк...

Гомуми эш өчен чын күңелдән яна торган Мәрдәншә агайның төпченергә, тикшеренергә яратуын һәркем яхшы белә иде. Барысы да, нәрсәдер буласын көтеп, тынсыз калдылар һәм әле ис китмәүчән-тыныч кыяфәтле Инсафка, әле ачулы, бозылган йөзле Мәрдәншә агайга карап-карап алдылар. Рәшит исә, Мәрдәншә агайның сүзен уенга борырга тырышып:

— Кызмале, Мәрдәншә агай, кызма. Мә ичмасам бер тартып җибәр, жөрәк ялкыннарың басылыр,— диде, аңа көйрәтелгән папирос сузып.

Инсаф та өзек-өзек итеп кеткелдәп куйды һәм, дусларча булырга тырышып, җирдә яткан папирос кабына төртеп күрсәтте.

— Менә ал моннан, Мәрдәншә абзый. Сиңа да җитәр, безгә дә җитәр.

— Мин чапканыем,— диде Сәгыйть, борчылулы төс белән.— Нәрсә?.. Алай начар чапмадым кебек.

— Әйбәт чапкан җире дә бар аның. Уң якта әрәмә буе бөтенләй ташлап калдырылган. Алай эленке-салынкы җөрсәк, җегетләр, әзерләрбез печәнне!

— Әллә ут капканмы дип торам, шуңа кызасың икән, Мәрдәншә абзый,— диде Инсаф, һаман сер сынатмаска тырышып, һәм тагын салкын гына кеткелдәп алды.— Анда аның рәтле печәне дә юк — коры чыбык та ат кузгалагы.

— Җук сиңа! Анда калдыр, монда калдыр — кышка ни кала? Малың кырыла башлагач, кыш көне тагын күршеләрдән теләнербезмени? Кулын черемәгәндер ич бөтенесен селтәп чыксаң!

Мәрдәншә агай тикмәгә генә кызмады. Ул Инсафның иренеп кенә эшләвенә башта ук игътибар итте. Инсаф, ирләр төркеменә кушылмыйча, юри хатын-кызлар арасында чуалды, бүтәннәр баш калкытмый эшләгәндә, әле ял итәргә туктады, әле тәмәке тарткан булды, әле печән арасыннан җиләк эзләргә тотынды. Боларның берсе дә Мәрдәншә агайның күзенә чалынмый калмады. Аның инде күптән саруы кайнады. Инсафның, Сәгыйть калдырган җирне чабып бетермичә, ярты юлда ташлап, урманга карагат ашарга кереп китүен күргәч, аның тәмам ачуы кабарды. Барыннан да бигрәк, шушы алсу битле, үгез кебек таза хөрәсәннең үз-үзен шундый тыныч, шундый гаепсез тотуы җенен котыртты. Аның шушы шәп егетнең яңагына уңлы-суллы чабып җибәрәсе килде. Һәм ул, якында гына кызлар, хатыннар булуына да карамас-

тан, атасын-анасын калдырмыйча, кычкырып сүгенеп алды.

Инсаф исә әйтерсең аның сүзләренә колак та селкетмәде: һаман шул ук катып калган ялган тыныч йөз белән папиросын төтәсләвендә булды. Шулай да үзенә карата әйтелгән ачулы сүзләрне җиңел генә уткәреп җибәрү бик үк килешмәс дип уйлады, ахры, Мәрдәншә агайны бөтенләй санга сукмаганын белдерергә тырышкан сыман, ис китмәгән төс белән кычкырып көләргә кереште.

— Кит әле, Мәрдәншә абзый, бәйләнмә каз чебене кебек. Җукка кычытынасың калхуз өчен, барыбер артыгын язмаслар.

Мәрдәншә агай кинәт агарынып китте, бөтен тәне пружина кебек җыерылып, кысылып калды, калын кашлары гаҗәпләнеп өскә сикерде, күзләре, Инсафны юк итәргә теләгән шикелле, нәфрәт һәм җирәнү сиздереп торган очкын чәчрәтеп, зуррак ачылды. Ул, кемдер кисәк кенә артыннан төртеп җибәргән кебек, бер-ике адым Инсафка таба тартылып куйды.

— Нәрсә?..— диде куркыныч тавыш белән.— Нәрсә?.. Син... кайда туып үстең? Теге якта тудыңмы әллә? Кеше булдыңмы? Шәп җегет!.. Калхуз кирәкмәс булган... Җык җилкә...

Инсафның тыныч йөзе шундук җимерелде.

— Бәйләнмә!.. Куркыталмассың... Синең ишеләрне генә күп күргән инде,— диде ул, зәһәрле ыжгырып.

— Шулаймы? Шулаймы?.. Бик шәпләп куркытырмын мин сине, тирес кортын... җир косыгын... Менә моннан!..— Мәрдәншә агай тамырлары кабарып чыккан каты, зур куллары белән чалгы сабын шыгырдатып кысты да, кизәнеп, тагын Инсафка таба омтылды.

Заһирҗан агай, зур, авыр гәүдәсен бик җиңел күтәреп, шундук Мәрдәншә агай янына килеп тә җитте, күз ачып йомганчы аның беләгеннән тотып та алды.

— Мәрдәншә, Мәрдәншә!— диде ул, чын-чынлап куркуга төшеп.— Ташла. Бетте... Кагылма... сасысы чыгар...

Мәрдәншә агай кинәт исенә килгәндәй булды, үз-үзен кулга алды, кул арты белән авызын сөртеп куйды һәм кара төкләрен сыйпаштыргалады да, берни булмаган кебек, чалгысын җир өстенә сузып салды.

— Шундый тирес кортлары белән калхузың ничек алга барсын! Менә син, малайкай, ни сөйли бит, ә!

Шуннан соң ул калтыранган бармаклары белән Рәшит кулындагы папиросны алды, йотлыгып-йотлыгып суырырга тотынды һәм, тавышын бөтенләй әкренәйтеп, үгетнәсихәт тонында:

— Кайда синең камунистик выҗданың? Ә?— диде, Инсафка туры карап.— Безнең кеше ләбаса син... теге як кешесе түгел!

## VII

Сәгыйть авылда туды, авылда үсте, шунда аның күзе ачылды. Ул, авыл балаларының күбесе кебек, тормыш дигән нәрсә белән бик иртә очрашты, һәм ул тормыш аңа беркайчан да гел битен генә, ягымлы елмаюын гына күрсәтеп тормады. Аңа, алтын балакаен күзгә төшкән чүп кебек кадерләгән һәм аның төчкерүеннән дә коты алынып торган йомшак күңелле әбиләр-әниләр иркәсен тоеп, шоколад, печенье генә ашап үсәргә туры килмәде.

Колхозда бер эш кулы фронттагы бер таза солдатка тиңләшә торган ел — сугыш елы иде. Бер көнне ул таң аткач та торды да, йокылы күзләрен уа-уа, ат фермасына йөгерде. Бригадир, сугыштан яраланып кайткан кулсыз Морат, сары тешләрен күрсәтеп, аны әллә кайдан кычкырып каршы алды. «Әнә бер тырмачы килә! Бик әйбәт! Атаң буе булгансың инде, шар тибеп җөрер вакытың узган. Бүгеннән башлап тырмага җөрерсең». Аңа бик хәлсез, бик ябык бер ат бирделәр. Ул аны-моны төпченмәде, үзенә карата шундый зур хөрмәт күрсәтүләренә, шундый зур эш ышанып тапшыруларына түбәсе күккә тиде. Шул көнне ул беренче мәртәбә чын-чынлап колхоз эшенә чыкты, беркемгә иярмичә, үзе генә чыкты һәм шул көннән соң аның үзенә күрә олы тормышы башланды.

Ул үзенең тәҗрибәсез, яшь җилкәсенә төшкән авыр хезмәтнең ачысын-төчесен татый башлады, маңгай тире белән табыла торган икмәкнең кадерен белергә өйрәнде. Ул, тар чүлмәктә үскән зәгыйфь гөл кебек, бары тик мәктәп стеналары эчендә генә үсмәде, буразна арасында да үсте, шаулап утырган иген басуларында да, гөр килеп торган ындыр табакларында да, чана табаннары астында шыгырдап калган кышкы урман юлларында да үсте, эш сөючән, тырыш һәм киң күңелле, якты чырайлы гади халык арасында үсте. Аны мәктәп кенә түгел, бәлки, авыр һәм гүзәл хезмәт белән тулы тормыш — колхоз тормышы да аякка бастырды, малайдан егет ясады.

Ләкин, бала чактан ук укырга һәвәс булганга, ул, үзенең кайбер авылдашлары шикелле, сабан башы гына тотып калырга уйламады. Ул каядыр еракка, югарыга омтылды. Хезмәткә мәхәббәт һәм китапның тылсымлы сүзенә ышану аның өчен искиткеч шифа булды.

Ул читкә, шәһәргә китеп студент булгач та, үзләре авылын, үзләре колхозын, аның кешеләрен тиз генә онытмады. Авылдан еракта булса да, әйтерсең һаман да алар белән бергә яшәде. Аны авылдагы, үзеннән ерактагы бөтен нәрсә кызыксындырды. Әйе, бер-ике елга кадәр шулай булды.

Ләкин быел ул үзенең ничектер үзгәргәнлеген күрде. Күңелендә әллә гыйшык ялкыны дөрләгәнгә, әллә инде икенче тормышка — шәһәр тормышына, студент тормышына күнегеп киткәнгә, ул, каяндыр читтән килгән кунак сыман, үзенең туган авылын бөтенләй диярлек күрмәде, ишетмәде. Ул аның сулышын, аның хисен тоймады. Хәтта колхозчылар белән эшкә йөри башлагач та ул, беренче көннәрдә, алар алдында үзен ничектер уңайсыз итеп, чит кеше итеп сизде. Мәрдәншә агайларның, Гөлсемнәрнең булдыксыз председатель турында, колхозның бүгенге көндәге артталыгы турында ачынып сөйләүләре аның йөрәгенә тулысынча барып җитмәде, ул аларның кайгысына, борчылуына күңеленнән барыбер боз кебек салкын булып калды, һәм күңеленең иң тирән төшендәге бер куркак, мескен нәрсә: «Ярый әле мин дә алар кебек түгел, ярый әле, миңа гомер буе авылда яшәргә, гомер буе печән чабарга туры килмәячәк... Мин, әлбәттә, алардан әллә кайда бәхетлерәк, мин — студент, минем киләчәк — бөек!»— дип шатланды. Әйе, ул алар белән бергә булса да, алардан читтә булган. Аның эшләве дә, аруы-алҗуы да, беләк-кулбашларының сызлавы, хәтта алар алдында политик беседалар үткәрүе дә бары тик аның үзе өчен генә, үзенең күңелен сафландыру, үзенә рухи ләззәт табу өчен генә булган.

Менә әле генә Инсаф белән булган хәл, дөресрәге, Мәрдәншә агайның сүзләре, Мәрдәншә агай үзе аңа бик нык тәэсир итте. Ул, әйтерсең, моңарчы үзенең зиһенен, күңелен басып, томалап торган ниндидер авыр нәрсәдән тәмам айнып китте. Аның күңелендә үз-үзеннән риза булмау кебек бер нәрсә калкып чыкты. Ә бит теге печәнлекне Инсафка ул калдырып китте, дөресрәге, аннан качарга теләп, ташлап чыгып китте. Димәк, ул җирне пычраткан өчен, аның печәнен рәтләп чапмаган өчен таякның юан башы Инсафка түгел, аның үзенә төшә һәм Мәрдәншә агайның Инсафка әйткән сүзләре күпмедер күләмдә аңа да карый.

Ул Мәрдәншә агай турында, үзе турында уйлады. Ул үзен аның алдында бик бәләкәй, бик әһәмиятсез итеп сизде. Мәрдәншә агай аның күз алдында көтмәгәндә бик нык үсеп китте, һәм ул аның зураюын, аның югары

күтәрелүен әле яңа гына күргәндәй булды. Ул, дүрт класслык белеме дә булмаган гади колхозчы, аннан, студент Сәгыйтьтән дә, зур урында утыручы һәм шуңа күрә зур җитәкче булырга тиешле Булатовтан да югарырак, биегрәк иде, аңлырак һәм дөрес, аек фикер йөртүдә сәләтлерәк иде. Ул бөтен кеше эшенә үз эше итеп карый ала, үзенең «кара» уе белән киңрәк, тирәнрәк уйлый ала иде.

Аның күңелендә Мәрдәншә агайга карата элеккегә караганда тагын да ныграк хөрмәт, ихтирам хисе уянды. Ул Булатовның үз-үзеннән канәгать булган, иренчәк, пошмас йөзен күз алдына китерде һәм ачу белән: «Кайчанга кадәр шундый бүкәннәр утырыр икән безнең колхоз башында?— дип уйлады.— Андый эшкә менә кемнәр кирәк анда!.. Мәрдәншә агай кебекләр кирәк, чын-чынлап кайгыра, борчыла белә торган кешеләр кирәк!..»

## VIII

Төш җитте, өмәчеләр иртән килеп туктаган болынга агыла башладылар.

Сәгыйть ирләр белән арттарак калды. Ул үзләреннән алда көлешә-көлешә барган кызлар төркеме арасында Рәшитне күреп алды. Ул аңа бик кылтык булып күренде. Рәшит туктаусыз былагайланды, кызлар белән шаярды, аларның йә чәчләреннән барып тартты, йә арттан килеп берәрсенең муенын печән белән кытыклады. Башына ул яшел печән белән аралаштырып, чалма кебек итеп үрелгән болын чичкәләре бәйләме кигән, аның чалбарына арттан яшел үлән сүле буялып калган иде. Аның өстендә күлмәге-ние юк иде — ян-ягыннан ертылып төшкән аксыл майка гына иде. Зәйтүнә, үзе ише бер яшь кенә кыз белән сөйләшә-сөйләшә, төркемнең икенче ягыннан бара иде.

— Рәшит, кайда умырттың бу майкаңны? Кем белән көрәштең?— диделәр кызлар, көлешеп.

— Карагат ашарга кергәнием әрәмәгә, шунда ботакка эләктердем,— диде Рәшит кычкырып һәм хатыны белән арттанрак атлаучы Инсафлар ягына күз төшереп алды.— Кызлар, энәгез җукмы берәрегезнең? Бирегез әле, тегеп куйыйм... әллә өмәдә исереп сугышкан диерләр...

— Әйт Низамыйга — кантурга нәрәт язып бирсен. Мәчтүрә ямап куяр, бүген дә амбардан тишек-тошык капчыклар күтәреп кайтып барадырые әле...

Кызлар тагын шаулашып көләргә тотындылар, чөнки

Мәчтүрә кышын да, җәен дә колхоз өчен капчык ямый, капчык тегә, һәм ертык, тишек капчык булса, гадәттә: «Мәчтүрәгә бирергә кирәк»,— диләр иде.

Икенче яктан Гөлсемнең ирләрчә калын тавышы ишетелде:

— Читават янына кердем дә, кайчан безнең ише кызлар өчен видымыс чыгарасыз җегетләргә, мин әйтәм, кияү кирәк. Синең кияүгә чыгу-чыкмавың калхузның быелгы буджитенә кермәгән, ди. Кермәсә кермәс, мин әйтәм, үземә эзләргә туры килер, ахры. Ярты ел үтмәде, чыктым Яруллага. Ярулла, мин әйтәм...

Ул арада туарылган арбалар янына да килеп җиттеләр. Учак ягыннан борыннарга аш исе, төтен исе килеп бәрелде.

— Утыра башлагыз, утырыгыз,— диде Хәбирәттәй, төрле яктан килеп-килеп туктаган өмәчеләрне якты йөз белән каршылап.

Шундук ике җирдә ике гармун уйный башлады, табын тирәсе, сабантуйдагы кебек, җыендагы кебек, шаугөр килеп торды. Өмәчеләр, бөтен болынны каплап, ике җиргә түгәрәкләнеп утырдылар.

Аш ашау кызып кына барган чакта, авыл ягыннан колхозның иң яхшы айгыры җигелгән кара, җиңел кәрендәскә утырып, председатель Булатов килеп чыкты. Атын, ашаучылардан ераккарак туктатып, бер агачка бәйләп куйды да, юл килгәндә тузанланган өс киемнәрен каккалап-суккалап, ничектер як-якка чайкалыбрак атлый-атлый, өмәчеләргә таба якынлашты. Аның белән бергә Нәсим дә килгән иде.

— Ничек эшләгәнне карарга килмәсәләр дә, ничек ашаганны карарга киләләр,— диде усал телле Гөлсем, Булатов үзе дә ишетсен дигән шикелле, юри ныграк кычкырып.

Хатын-кызларның кайберләре, шундук ашауларыннан туктап, аларның килеп җиткәнен көтеп тора башладылар, ирләр исә, үз дәрәҗәләрен төшермәскә тырышып, бернигә, беркемгә игътибар итмичә, ашыкмыйча гына ашауларында булдылар.

Булатов, кая килеп чыктым мин, дигән сыман, аптыраулы күз карашы белән беравык ашаучыларга карап торды да, тирләгән, кызарынган битен, шома маңгайларын киң учы белән сыпырып алды, аннан соң кайбер дәрәҗә кешеләренә генә хас булган коры, сүлпән бер тавыш белән:

— Ашлар тәмле булсын,— диде.

Печәнчеләр, шулай ук артык сикереп төшмичә, тые-

лып кына җавап бирделәр. Булатов бүтән сүз әйтмәде, бер читтәрәк утырган Заһирҗан, Мәрдәншә агайлар янына килде дә исәнләшү өчен һәркемгә кул биреп чыкты, Барис белән исәнләшкәндә Сәтыйтьне дә күреп алды: «Ә-ә, Сәгыйть энекәш»,— дигән булды, аңа да тирләгән кулын сузды. Сәгыйтькә аның авызыннан аракы исе килгән кебек булды.

— Утыр әйдә, ашап ал безнең белән.

— Өмә ашын авыз итеп кара,— диештеләр хатын-кызлар.

Хәбирәттәй аштан бушаган ике калай коштабакны сулы чиләккә тыгып, тиз генә юып алды да Булатов белән Нәсим алдына аш китереп куйды. Булатов аштан баш тартты.

— Әле генә ашап чыкканыем, бер кабар җирем дә юк,— диде.

Ә Нәсим, киресенчә, аны-моны уйлап тормыйча, ипиен зур-зур кабып, сүзсез генә ашарга тотынды.

Гадәттә өмәдә сый яхшырак та, тәмлерәк тә була — шуның өчен өмә инде ул. Ләкин ашта бүген бүтән көннәрдәгегә караганда әллә ни үзгәреш булмады. Аш ашаганнан соң көндәгечә Хәбирәттәй калай кружкаларга, тәлинкәләргә чиләктән чәй салып чыкты. Чәй янына бал да, шикәр дә — бернинди тәм-төм дә бирмәделәр. Печәнчеләр бер-берсенә, бигрәк тә Булатов белән Низамый ягына күтәрелеп карамаска тырышып, авызларын пешерә-пешерә, стаканнардан, калай кружкалардан, тәлинкәләрдән кайнар чәй эчтеләр.

Чәй дә эчелеп бетте, ләкин беркем урыныннан кузгалып китмәде. Табын өстендә ниндидер күңелсез, кыен тынлык урнашты. Өмәгә килер алдыннан Низамый колхозчыларга, бал булачак — ачысы да, төчесе дә, дип белдергән иде. Чәй вакытында ул турыда Низамый да, Хәбирәттәй дә бер сүз дә кузгатмады, чөнки өмәчеләр өчен балның «ачысын да, төчесен дә» алып килмәгәннәр иде. Кайберәүләр, бәлки, председатель берәр җылы сүз әйтер, дигән шикелле, әледән-әле Булатов ягына караштырып алдылар. Әмма председатель, әйтерсең, аларны күрмәде дә.

Көтеп тору озакка сузыла башлагач, Рәшит түзмәде, Низамыйга карап:

— Кая, нигә китермисез балыгызны?— диде.— Тамак кычыта башлады.

Тагын да уңайсызрак булып китте. Рәшиткә каршы Гөлсемнең ачулы тавышы ишетелде:

— Бар, яр астына төш тә, чөмер балны! Таштан тамчы

чыкканын каян күргәнең бар?.. Безнең калхузның аның үзенә дә юк, кешегә дә юк.

Булатов, башын калкытмыйча гына, иякләрен, маңгайларын сыпыргалады да:

— Бүгенгә булмады инде,— дип куйды.— Кыладаушик өйдә юк. Иртәгә тагы өмә ясыйбыз, иртәгә әбизәтелне булыр.

Билгеле, мондагыларның берсе дә аракыга, ачы балга «үлеп китә» торган эчкече түгел иде, һәм шулай ук аларның бер-ике кашык бал белән генә чәй эчкәннәре дә бар иде, әмма шуңа да карамастан һәркемнең күңеле кырылды, өмәнең, бергәләп эшләүнең яме югалды. Хатыннар, ризасызлык белдереп, мыгырдана-мыгырдана, урыннарыннан кузгалып китә башладылар. Председательнең коры сүзе генә хәзер аларның күңелен күтәреп җибәрә алмый иде инде.

— Иртәгә!— диде Гөлсем, тагын да ныграк ачу белән.— Иртәгә... Оят та соң, валлаһи! Бал исе белән алдарга маташалар. Кит аннан, җир ярылса, җир тишегенә керерсең. Без бит алданып эшләргә... кем өчен эшлибез соң...

— Ничек эшкә күңелең үсмәк кирәк?!

— Болай булгач, иртәгә ике аякның берсен дә атлау юк инде ул... мичкәсе белән китерәбез дисәләр дә!

— Без мытыес кешесе,— диде Рәшит тә,— иртәгә монда минем койрыкны да күрмәссез!

Өмәнең болай бетүе Сәгыйтьнең эчен пошыра башлады. Ачы бал турында да, төче бал турында да бүген әле бер генә мәртәбә дә исенә кертеп карамаса да, гомуми ризасызлык, гомуми күңелсезлек аңа да тәэсир итте. Аңа хәзер ул төштән соң иртәнге кебек үк дәртләнеп эшли алмас шикелле тоелды.

— Әллә ничек кенә булды бит әле бу,— диде ул Нәсимгә, боларның барысы өчен дә аның алдында бары тик үзен генә гаепле санаган шикелле.

— Ы-ы,— диде тегесе,— ни... болай булгач булмады инде — гәзит укырмын дип килгәнием...

Шул чакны Мәрдәншә агай уртага чыгып басты, кулын болгады да:

— Әй, катыннар, җегетләр!..— дип кычкырды, ыгызыгыны, ризасыз гүелдекне күмеп һәм ни өчендер мыек астыннан гына көлемсерәп куйды.— Туктагыз әле, тукта, кая ашыгасыз? Нәрсә болай борыннарыгызны салындырдыгыз? Менә син, малайкай, нишләтә бал!.. Эчмәсәләр дә исерделәр...

Шуннан соң ул, һаман шундый ук көлемсерәгән төс белән Сәгыйть ягына борылды да ым кагып:

— Сәгыйть,— диде,— башла әйдә даклатыңны!— Кыяфәте шундук кырысланып китте, тавышы кискен булып яңгырады.— Хәзер, иптәшләр, җәмәгать... Сәгыйть безгә теге яклардагы, җәгъни мәсәлән, капиталистически илләрдәге хәлләр турында сөйләячәк. Тавышланмый гына тыңлап утырыгыз.

Нәсим: «Менә ничек икән!»— дигән кебек, гаҗәпләнеп Сәгыйтькә карап алды. Теге уңышсыз «доклад»тан соң аларның әле беркайчан да очрашканнары юк иде, һәм, билгеле, Нәсим моңарчы Сәгыйтьнең печәнгә йөрүен дә, чабучылар белән көн дә төрле темага беседалар үткәрүен дә белми иде.

Мәрдәншә агайның тик торганда, Сәгыйть доклад сөйли, дип белдерүе Сәгыйтьнең үзе өчен дә бөтенләй көтелмәгән нәрсә булды. Ул бүген өмәчеләр алдында нәрсә дә булса сөйләрмен дип уйламаган иде һәм бу турыда алдан беркем белән дә киңәшләшмәгән иде. Нәрсә бу, Мәрдәншә агай, тиеләнгәнме әллә? Бу кадәр халык алдында бернинди әзерлексез доклад сөйләү алты-җиде кеше белән гәпләшеп утыру түгел лә!

Кузгалып киткән кешеләр, теләр-теләмәс кенә, урыннарында тукталып калдылар, кайсылары көттермичә кире килеп утырды, һәм йөзләгән күз карашы шундук Сәгыйтькә борылды. Сәгыйть җиңелчә дулкынланып куйды, ләкин бу элекке кебек каушау түгел иде инде. Мондагы эшчән, тыныч йөзле агайлар, кызыксынучан кыяфәтле хатыннар, елмаеброк карап торган яшьләр, тавыш-тынсыз бала-чагалар — хәзер барысы да аңа таныш, якын иде, алай гына да түгел — ул үзе аларның бер кешесе, бер иптәше иде.

Сәгыйть, элекке гадәте буенча, чәче алынган такыр башын сыйпап куйды һәм сүзне нидән башлап җибәрергә икән дигән сыман, беравык фикерен җыеп торды да:

— Иптәшләр!..— диде.

Аңа тагын да ныграк кыюлык биреп, дәртләндереп, Гөлсем кычкырды:

— Әйдә, җиббәр кичәгене, безгә сөйләгәнне!

Икенче яктан тагын Мәрдәншә агайның тавышы ишетелде:

— Җәгез, җегетләр, шаулашмагыз... Инсаф, Низамый, якынрак килегез. Булатыф иптәш, ашыкмагыз кайтып китәргә, сезгә дә тыңларга була, бик тә файдасы тиюе бар.

## Дүртенче бүлек

### I

Идрис бик яшьтән ятим калды. Әткәсенең дә, әнкәсенең дә кайчан үлүләре турында ул бөтенләй белмәде. Бары тик авылдашлары гына кайчакта шул турыда сүз чыккач: «Әткәң, мәрхүм, бик әйбәт кешеие,— ди торганнар иде.— Нужа җитә кеше башына... Ачлык елны бәхет эзләп читкә киткәние, шул китүдән кайтмады, машина басып үтергән дигән хәбәр килде. Әнкәң дә алай алама заттан түгелие. Урыны оҗмахта булсын бичараның, ачтан үлде...»

Кыш көннәрен ул ничек кирәк алай кешеләрдә үткәрде, җәй җиткәч, көтүче ярдәмчесе булып йөрде. Ул туры килгән бөтенесен дә эшләде, туры килгән бөтенесенә дә хезмәт итте, баш иде. Ул тормышның татып карарга мөмкин булган барлык газапларын, барлык авырлыкларын татыды. Аны яклаучыга караганда — кыйнаучы, юатучыга караганда — тиргәүче, күңелен күтәрүчегә караганда кимсетүче күбрәк булды. Аны тик тырышлыгы, эшкә җәптәшлеге, сүз тыңлаучанлыгы өчен генә «туйдырып», «карап» тордылар, ятимлеге өчен бары тик кактылар-суктылар гына.

Шуңа да карамастан ул елдан-ел үсте, күзгә күренеп, менә дигән булып, таза булып үсте. Бер елны, малайның инде дилбегә тотарлык булуын күреп, авыл мулласы: «Изгелек булсын, савап булсын»,— дигән булып, аны үзенә хезмәтче итеп алды. Мулла абзыйның ул ат караучысы да, җирен сөрүчесе, тырмалаучысы да, кучеры да булды һәм берәр ачуын басарга кирәк булган чакта аның камчы ашаучысы да булды.

Карт мулла тыштан ягымлы, тәмле телле, ләкин эчтән мәкерле, икейөзле бер кеше иде. Шуның өстенә ул кәефе килмәгән чакларда бик холыксыз, бик үз сүзле, кансыз да була торган иде. Ул инде аның йортын бөтенләйгә ташлап та чыгып китмәкче булган иде, ләкин шул вакыт күңелендә туган яңа, сәер бер көчкә, бер яңа хискә буйсынып, һаман тәвәккәлли алмый йөрде.

Мулла абзыйның ап-ак тулы йөзле Мәгъфия исемле бер кызы бар иде. Хәер, аның кызлары бик күп иде, тик нигәдер Идрис күзенә гел Мәгъфия генә күренә торган иде, һәм аңа мулла абзыйның чынлап та аннан башка беркеме дә юктыр шикелле тоела торган иде.

Бервакыт ул аның баскыч алдында шат, көр тавыш белән кычкырып көлгәнен ишетте һәм шуннан соң бөтен тынычлыгын югалтты.

Күп тә үтмәде, дөньялар үзгәреп китте. Көннәрдән бер көнне, бөтен авыл халкын хәйран калдырып: «Ярман сугыш башлаган!» — дигән хәбәр килеп төште. Аны солдатка алдылар, бүтән таза яшь егетләр белән бергә кызыл вагоннарга төяделәр дә каядыр күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга алып та киттеләр. Ул өч мәртәбә сугышка керде, ике мәртәбә яраланып чыкты. Унҗиденче елгы Февраль революциясен Идрис Петроградта каршылады. Бөтен иске дөньяны тетрәтеп, «Аврора»дан туплар аткач та, бөек шәһәрнең асты өскә килә башлагач та, алар үзе шикелле үк сакал-мыек баскан, ябыккан, соры шинельле кешеләр белән бергәләп, бернинди икеләнүсез, бернинди шикләнүсез ак офицерларны штыкка кададылар да большевиклар ягына чыктылар. Ул, винтовкасын кысып тоткан көе: «Яшәсен хезмәт халкы! Бетсен сугыш, бетсен кан эчүчеләр!» — дип кычкырды. Ул яңадан фронтка китте, яңадан «ярманнар»га — немец интервентларына каршы сугышты, Деникин солдатлары белән якалашты һәм, Колчакны куалап, Урал аръягына кадәр барып чыкты.

Сугышны бетереп, туган якларына кире кайтканда, ул яшькә яшь булса да, олыгаерга өлгергән кеше булып, коммунист булып кайтты. Ул туп-туры үзләре авылына кайтып төште һәм беренче көннән үк авылда яңа тормыш кору өчен барган бөек, авыр көрәшкә кушылып китте. Алар ярлы-ябагайдан, элекке фронтовиклардан коммуна төзеделәр. Иптәшләре аны ячейка секретаре итеп сайладылар.

Авылда аклар, кызыллар алмашынып торган чакта, мулла абзый үлеп киткән иде. Мулланың бөтен хуҗалыгы, йорты-җире бары хатын-кыз кулында гына торып калган иде. Ләкин Мәгъфия элеккечә һаман да шаян, һаман да шат күңелле, чибәр иде. Элекке яра тагын кузгалды һәм, бик күп уйлап тормыйча, ул аңа яучы җибәрде. Идрис ул чакта теләсә кайсы кызның йөрәгенә ут салырлык егет иде әле, шуның өстенә авылда аның тоткан урыны да бик бәләкәй түгел иде. Мәгъфия ризалык бирде.

Идриснең мулла кызына өйләнүенә аның кайбер фронтовик дуслары — коммунистлар каршы килеп карадылар. Моның бик үк ярап бетмәгәнлеген ул үзе дә аңлады, әмма аның күзе-башы әйләнгән иде. Аннан соң ул чакта инде Мәгъфия авылның актив яшьләре арасында чуала башлаган иде, спектакльләр куюда, кичәләр оештыруда катнаша башлаган иде, кыскасы, яңалык яклы кеше иде. Ул гына да түгел, Идрискә кияүгә чыккач, аңа сүз бул-

масын өчен, аның исеменә, эшенә тап төшмәсен өчен ул элекке семьясыннан бөтенләй баш тартты, кантондагы алты айлык курсны бетереп кайтты да, авылда балалар укытырга тотынды.

Идрис, тумыштан ук башлы, зирәк булса да, бөтенләй диярлек укымаган иде. Аңа әлифбадан башлап тотынырга туры килде. Аны да төрле курсларга, семинарларга чакырып алдылар, укыттылар, өйрәттеләр. Берничә елдан соң алар, актив белән бергәләп, авылда колхоз төзеп җибәрделәр. Идрис председатель булды, тагын да берничә елдан соң аны, милли кадр дип, төпле, эшлекле, тәҗрибәле кадр дип, югары үрләттеләр — кантон үзәгенә тарттырып алдылар. Мәгъфия тагын мәктәпкә керде, читтән торып техникумда укыды.

Тора-бара тормыш җайга, рәткә салынды, Идрис акчаны ярыйсы гына алды. Кантон үзәгенә килеп бер ел торгач, дөньяга бер кыз бала килде. Ләкин бала озак яшәмәде, үпкәсенә суык тиеп үлде. Күп тә үтмәде, тагын берәү туды. Монысы да кыз бала булды.

Беренчесенең үлеп китүе кайгысыннан әле һаман айный алмаган ата-ана сөенечләреннән нишләргә белмәделәр. Беренче сабыйның үлемен алар үзләренең тәҗрибәсезлекләреннән, саксызлыкларыннан күрделәр һәм шуңа күрә бу баладан да колак какмас өчен, кулларыннан килгәннең барысын да эшләргә тырыштылар.

Кызга нинди исем куштыру турында бераз сүз булып алды. Дөрес, Идрис өчен нинди исем булса да ярый иде — «Кыз булгач кыз, эш исемдәмени!» Ләкин бу мәсьәләдә хатыны бик талымчан булып чыкты. Искелекне җимерү — һәрбер элеккене юк итү, дигән караш бик нык тамыр җәйгән бер вакытта; халык белән, милли традиция белән исәпләшмичә, бөтен нәрсәдә яңа мөгез чыгарырга тырышучылар культуралы кеше, алдынгы, аңлы кеше, дип саналган бервакытта; предмет атамаларын яки анда колакка беренче булып ишетелгән теләсә нинди ят сүзне кеше балаларына исем итеп тагу модада булган бер вакытта укытучы Мәгъфия генә «надан» һәм «искелек яклы» булып кала алмады. Ул гомумән болай да яңалыкка омтылырга, культуралы булырга тырышучы кеше иде.

Кыз балага «Идея» дип исем бирделәр. Ләкин, әйтергә кирәк, әнисе белән әтисеннән башка бүтән беркем дә беркайчан да аңа ул исем белән эндәшмәде. Культурасызрак кешеләр «Идея»не үзләренчә «Һидая» дип, «Идая» дип боздылар, культуралырак дуслары «Ида», «Ид» дип кенә йөрттеләр. «Балакай»га, үзен ничек атасалар да, барыбер иде.

Идадан соң ике игезәк бала, икесе дә ир бала туды. Ата белән ана боларына да чиктән тыш куандылар. Күңеленең иң тирән җирендә һаман да Аллага бер дип инануын, төрле ырым-шырымнарга, теге дөньяга, тәмуг-оҗмахларга ышануын дәвам иткән Мәгъфия, исеме «и»гә башланган икенче баласының сау-сәламәт булуын күреп, игезәкләргә дә шундыйрак исем куштырырга теләде. Малайларның берсен «Икс» дип, икенчесен «Игрик» дип атадылар, әмма нишлисең, Ходай Тәгаләнең әмере шулай булгандыр, «и» барыбер ярдәм итмәде: Икс үлде, Игрик вафат булды. Тагын бүтән балалары булмады. Дөньяда бары Идея генә торып калды.

Аны өрмәгән җиргә дә утыртмадылар. Түпәй итә күрмәсен, үпкәсенә салкын тия күрмәсен, дип куркып, кан калтырап кына тордылар. Бала бик иркә булып, кадерлекәй, алтын-көмешкәй булып, бердәнберкәй булып үсте. Бар тәмле аның авызында булды, бар яхшы аның өстендә булды. Аңа беркайчан бернинди җил-яңгыр тимәде, ул тормышның бары тик матур, ямьле ягын гына, җиңел, рәхәт ягын гына күреп үсте. Хәтта иң авыр елларда, сугыш елларында да ул чын тормышның нәрсә икәнен белмәде, үзе яшендәге кайбер балалар, өсләренә рәтле кием, тамакларына рәтле аш күрмичә, укуларын ташлап, булыр-булмас көчләре белән олылар эшен башкарып йөргән чакта, битләре алсуланып торган бу балакай үз бүлмәсендә песи баласы белән уйнап ятты.

Үзе балалык шатлыгын күрмәгән Идрис бар күңеле белән кызын бәхетле итәргә тырышты. Мәгъфия бигрәк тә.

Идрисне тагын үрләттеләр. Һәм аның эш хакы арткан саен, тормыш тагын да җиңеләебрәк, мулланыбрак китте. Мәгъфиягә хәзер көн дә мәктәпкә бару, класста балалар шау-шуын ишетү, алар белән баш катыру, кочак-кочак дәфтәрләр тикшерү, кыскасы — укытучы булу бик күңелсез, бик кызыксыз эш булып тоела башлады. Бала дигән булып, йорт мәшәкатьләре дигән булып, «чирләде» дә, эшен бөтенләй ташлап чыкты. Начальник хатыны, «иптәш Мәхмүтов» хатыны булгач, таза баштан сырхаулыкка сабышса да — килеште. Мәктәп коллективындагы кайберәүләр генә беренче көннәрне генә пышылдаштылар да, аннан соң аны телгә алучы да булмады. Өйдә дә аның әллә ни мәшәкате юк иде. Өй эшен туган авылларыннан килгән әнкәсе башкарып барды һәм баланы да гел диярлек ул карады. Аңа бары тик аркылы ятканны торкылы алып кую гына, Идеяне киендерү, чишендерү, Идеягә «шулай итмә, болай ит», «монысы яра-

мый, тегесе ярый», «моны ашама, шуны аша» дип, өйрәтеп тору гына кала иде.

Мәгъфия, авылда туып үссә дә, «кара» эшкә, йорт эшенә чиркәнеп карады. Аның бәхете әнкәсе үлеп киткәч тә югалмады. Аларның күршесендәге йортка Рәхимә исемле хатын күченеп килде. Аның ире сугышта яраланып кайткан һәм шуңа күрә, авыр эшкә ярамаганга, кайдадыр төнге каравыл булып тора иде, Рәхимә апа үзе бер конторада идән себерүче, бүлмә җыештыручы булып эшли иде. Аларның өч балалары бар иде. Чисталыкны, пөхтәлекне яратучы һәм теләсә кемгә ярдәм итәргә әзер торучы, чиктән тыш басынкы, сабыр холыклы бу хатын алар йортына бик тиз иялэшеп китте. Зур башлык хатынына «Мәгъфия апа» дигән булып, «үзеңнең вакытың юктыр» дигән булып, суын да кертеп бирде, утынын да яргалап ташлады, сумкасын күтәреп, базарына да чыгып йөгерде, хәтта идәннәрен дә юды, ашларын да пешерде. Тиздән ул алар белән бөтенләй бер семья кешесе кебек булып китте. Тик бу семьяда юан, симез хатын тулы хокуклы хуҗа, гел алҗыган кыяфәтле, эчкә баткан төссез күзле бәләкәй генә, ябык кына хатын тулы хокуклы хезмәтче ролен үтәде. Дөрес, Рәхимә апаның мондый рольдән (бигрәк тә юан хатын кәефсез чакларда) кимсенгән, гарьләнгән чаклары да булды, ире дә үзен чит кеше пычрагын тазартып йөргән өчен еш кына тиргәп алды. Ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар иде — тормышны алып барырга кирәк, балаларны үстерергә кирәк иде, ә килер нәрсә җитәрлек түгел иде, һәм «Мәгъфия апа»сы кулыннан акмаса да, тама торган иде.

Идрис һаман үсте, югары күтәрелде. Аны бер җирдән икенче җиргә күчерделәр. Сугыш вакытында ул районны «үз кулында тота» торган башлыкларның берсе булу дәрәҗәсенә күтәрелде. Элегрәк, яшьрәк чакларда, ул күрше авылларга, хәтта зур җирләргә дә җәяүләп кенә чыгып китә торган иде. Соңга таба ул тимер-күк айгыр җигелгән кәрендәскә утырып йөри башлады, аннары кисәк кенә юл уртасында туктап кала торган иске «газик»ка күчте, сугыштан соңгы елларда исә көл төсендәге елкылдык «Победа» белән генә әйттерә башлады.

Эш дәрәҗәсе күтәрелә барган саен, ул хатыны белән сирәгрәк очраша торган булып китте. Аның гомеренең иң күп өлеше кабинетларда, утырыш, җыелышларда, пленум, сессияләрдә, район колхозларында һәм юлларда үтте. Өй эшләре, семья эшләре белән ул артык кызыксынмады һәм үзенең хатыны, кызы, йорты, хуҗалыгы булуы турында тора-бара бөтенләй диярлек уйламый да башла-

ды. Аның карашынча, яхшы коммунист, яхшы җитәкче үз-үзен бөтенләе белән җәмәгать эшенә, халык эшенә, гомуми эшкә бирергә тиеш иде һәм, аныңча, шәхси интереслардан тулысынча арыну — яхшы, дөрес җитәкче булуның иң югары ноктасы иде. Ул үзен нәкъ шундый яхшы җитәкче дип исәпләде, бар күңеле белән, бар тырышлыгы белән шул яхшылыкны яхшырту буенча эшләде. Һәм күңеленнән ул моның белән горурланмыйча будыра алмады. Мәһабәт, тик бераз җәелә төшкән таза гәүдәле, әкрен кыймылдаучан бу кеше, нинди генә вакыты булмасын, беркемгә бер караңгы чырай күрсәтмәде, беркемгә бер каты орынмады. Өенә ул бары тик ашарэчәр өчен, йоклар өчен генә һәм сөекле кызын сөяр өчен, аңа карап сокланыр өчен генә кайтты. Ул аңа иркәләү, мактау сүзләреннән башка берни әйтмәде.

Шундый шәфкатьле ата иде ул.

Ида әтисен үлеп яратты.

Ида, әтисе кебек, бөтен нәрсәгә, бигрәк тә укуга зирәк булды һәм тормышта аны бары тик укырга гына өйрәттеләр. Өйдәгеләр генә түгел, кызганычка каршы, мәктәп тә анда укудан башка нинди дә булса эшкә, гомумән, хезмәткә карата мәхәббәт тәрбияли алмады. Баладан бары тик дәресләрен яхшы итеп әзерләвен генә, бирелгән мәсьәләләрне вакытында чишүен, шигырьләр ятлавын, кагыйдәләр өйрәнүен генә таләп иттеләр. Әгәр ул берәр фәннән «урта» йә «начар» алса, аңа шелтә белдерделәр, ачуландылар, тиргәделәр һәм ул дөньяда бары тик «начар» алуның, «урта» алуның гына начар, хурлыклы нәрсә булуын аңлап үсте.

Ләкин уку да аңа бүтән балаларга караганда җиңелрәк бирелде. Ул беркайчан да диярлек китаплар белән баш ватып утырмады. Ул укыды, елдан-ел алдынгы булып класстан класска күчә барды, һәм аңа аның бөтен тормышының максаты бары тик уку гынадыр шикелле булып тоелды. Ни өчен уку, кем булу өчен уку, кемгә файда китерү өчен уку — ул болар турында бөтенләй уйламады. Әнисенеке кебек ялкаулык һәм кайбер бүтән нәрсәләр аның күп кенә яхшы якларына ныклап тамыр җәеп китәргә комачау булды. Ул әнисе кебек бик холыксыз, бик үзсүзле булып һәм, гомумән, күп кенә начальник балалары кебек, кылтык, иркә, эшлексез булып үсте.

Үз акылы үзенә җиткәч, әнисен ул яратмый башлады, бераздан бу яратмау аны санга сукмауга әйләнде.

Ана быел кадерле кызкаеның бөтенләй икенчеләнеп кайтканын күрде. Элек әле ул аның белән көлеп сөйләшә, киңәшләшә торган иде, аңа үзенең эч серләрен ача торган

иде. Быел ул аны, әйтерсең, бөтенләй күрмәде дә, белмәде дә. Ул үз кызының үзенә карата салкынлыгын, чит булуын адым саен тойды, бөтен күңеле белән тойды. Аның йөрәге әрнеде, хәтере калды, күңеле тулды, һәм ул үз баласының үзенә карап бер елмайганын күрү өчен генә дә, аның бер яхшы сүз әйткәнен ишетү өчен генә дә үзендә булган барлык мәхәббәт, барлык иркә, яхшылык запасын сарыф итте. Әмма ана кешенең барлык тырышлыгы үсеп җиткән кыз кешенең холыксызлыгына, һавалыгына, боз кебек катылыгына бәрелеп челпәрәмә килә торды. Мәгъфия — бу турыда үз-үзенә таныpга теләмәсә дә,— ни өчендер, кызыннан кан калтырап торды.

## II

Рафига сүзендә торды — бүген ул бер сәгать алданрак килде. Иданың киенгәнен, көзге алдында бик тырышып әйбәтләнгәнен түземлек белән көтеп торды. Аннан соң алар икәүләшеп урамга чыгып киттеләр. Клубта бүген дә шул ук «Тарзан»ны күрсәтәләр иде, шуңа күрә аны тагын бер мәртәбә карауның мәгънәсе юк иде. Кызлар, авыл үзәге булып исәпләнгән һәм ике ягына да тирән канау казылган тар урам буенча бераз култыклашып йөрделәр дә, клуб янындагы бакчага керделәр. Анда бакча уртасына ясалган такта мәйданчыкта гадәттә танцылар була торган иде.

Хәзер җил юк чакта да шаулап, шыштырдап утырган бу биек усаклар, бу нәфис ак каеннар урынында моннан ун еллар элек ташландык кыр иде. Монда әремнән башка берни үсми иде. Иданың әле дә хәтерендә, бу бакчаны авыл яшьләре белән бергәләп аларның мәктәп укучылары утырткан иде.

Ул чакта ул икенчедәме, өченчедәме генә укый иде. Бервакыт ял көнне алар бөтен мәктәпләре белән шушында бакча утыртырга килделәр. Яз көне иде. Зур класс укучылары урманга агачка киттеләр, бәләкәйрәкләр тырма белән чүп-чар җыйдылар, булачак аллеяларны кырып алынган әремнәрдән, үләннәрдән чистарттылар. Иртәгә ял була дигән көнне укытучы апалары аларга үзләре белән тырмадыр, көрәктер алып килергә кушып җибәргән иде. Икенче көнне иртән, ял көнне, аның коры кул белән килүен күреп, апалары: «Һидая, диде, кая синең көрәгең?» Ул, әнисе кушуы буенча, күзен дә чытмыйча: «Көрәкнең сабы сынган»,— диде. «Тырманыкы сынганмы соң?»— диде апалары, елмаеп. Ул тотлыгып калды, әнисе аңа тырма турында берни дә әйтмәгән иде, һәм ул үзе дә

сизмәстән: «Сынмаган»,— дип ычкындырды. Үзләреннән зур көрәк, тырма тотып, тирләп-пешеп шунда эшләп яткан классташлары аннан кычкырып көләргә тотындылар. Хәтта укытучы апалары да аларга кушылды. Ида кып-кызыл булды, ләкин шундук әнисенең бүтән сүзләрен исенә төшерде дә, әтәчләнеп, иптәшләренә. «Тырма сабы тотсаң, кул кабара! Аннан соң бил авырта»,— дип кычкырды. Малайларга тагын җитә калды, алар элеккедән дә арттырыбрак көләргә тотындылар. Әмма укытучы монысында көлмәде. «Кем әйтте сиңа аны?»— диде ул, кырыс кына. «Мин үзем беләм!»— диде Ида, мактанып. Шулай да аның кулына тырма тоттырдылар. Бераздан ул бирелеп, хәтта малайлар белән узышып эшләргә кереште. Кулы да кабармады, биле дә әллә ни авыртмады. Тик бармаклары, уч төбе генә, аннан соң пальтосы, оеклары гына әзрәк пычранды. Бик ашыйсы килеп өйгә кайтып кергәч, әнисе аның өс-башына күз төшереп алды да, гомергә булмаганча, ачулы тавыш белән: «Ю тизрәк кулларыңны, сабынлап ю. Ныгытып ю!»— дип кычкырды. Ул шундый шатланып кайткан иде, әнисенә әллә нәрсәләр сөйләмәкче булып кайткан иде! Аның кәефе кырылды, күзенә яшьләр килде. Ул үзенең ярамаган эш эшләгәнен аңлады, ләкин — ни өчен ярамаган эш — һич кенә дә төшенә алмады. Тик шул көннән соң ул «кул пычрата торган», «бил авырттыра торган» эшләргә кирәкмәгән нәрсә дип карый башлады.

Бакчада танцы башланырга да, яшьләр җыелырга да әле иртәрәк иде. Алар сөйләшә-сөйләшә аллея буенча киттеләр. Рафига сөйләде, Ида, аның сүзенә бик үк колак салмыйча гына, тыңлаган булып барды.

Ул кичәге кич турында, кино турында, клубта очраган кешеләр турында уйлады. «Тарзан»ны карарга кеше бик күп килгән иде, аннан соң алар Рафига белән нәкъ сеанс башланыр алдыннан гына килеп җиткәннәр иде. Аларны кара, матур мыеклы бер егет каршылады. Ул ике билет алып куйган иде, ләкин ул билетлар, билгеле, Ида белән Рафига өчен түгел, Рафига белән аның үзе өчен алынган иде. Кара мыеклы егет Рафиганың кавалеры иде, әлбәттә. Ида моны шундук сизенеп алды. Парлы кешеләр янында аңа кинәт уңайсыз булып китте. «Нәрсә, минем алда үзенең мыегы белән мактаныр өчен алып килде микәнни бу мине?»— дип уйлады ул, Рафигага ачуы килеп. Рафига, аның кыенсынуын аңлаган шикелле, егетнең күзенә тутырып карады да: «Бәхти, тагын бер билет тап инде»,— диде. Бәхти, риза икәнлеген белдергән кыяфәт белән, бик килешле генә итеп баш какты да, тиз генә халык арасына

кереп китте һәм бераздан кулына тагын бер билет тотып килеп тә җитте. Кинодан соң алар Рафига белән икәүләп аны өенә кадәр озатып куйдылар.

Бакча уртасындагы агач төпләрендә, такта скамьяларда берничә парлы күренде, аннан соң малай-шалайлар очрады. Аларның һәрберсе аллея уртасыннан әкрен генә атлап барган ике кызга, дөресрәге, Идага, алай гына да түгел — аның менә дигән ак танкеткаларына, бер чакрымнан яхшы хушбуй исе аңкытып торган киң итәкле, уелган кыска җиңле бик шәп күлмәгенә, шәһәрчә көдрәләткән күперенке чәчләренә карап калды. Кичәгенәк кинода да ул һәркемнең үзенә төбәлгән кызыксынучан күз карашын тойды. Авыл кызларының, авыл егетләренең комсыз карашлары аның күңелендә үз-үзең белән масаю, үзеңнең студент кыз, шәһәр кызы булуың өчен горурлану тойгысы тудырды. Аның бөтенесенә ишетелерлек итеп көләсе, юри кычкырып сөйләшәсе килде. Аның һәркемне үзенә генә каратасы килде.

Бакчаның икенче очына җитәрәк беркем дә очрамады. Алар кире борылдылар. Алар тагын әле генә узып киткән кешеләр яныннан киттеләр. Ләкин урамда халык күбрәк шикелле күренде.

— Әйдә, урамга чыгабыз,— диде Ида.

Ул тагын кичәге кич турында, мыеклы Бәхти турында, Тарзан турында уйлады. Ул Бәхтинең матур булуы, Рафиганың аңа караганда ямьсезрәк булуы турында, аның ул мыеклы егеткә тиң түгеллеге турында уйлады. «Тапкан йөрер кыз!» — диде ул үзалдына, борынын җыерып. Ул Бәхтине Тарзанга охшатты. Ул Рафигадан Бәхти турында, аларның кайчан, ничек очрашулары, ничек дуслашып китүләре турында, Бәхтинең кем булуы турында сораштырып карамакчы булды. Ләкин Рафига тиз генә эч серен ачып сала торган кешеләрдән түгел иде. Ул Иданың сорауларына «әйе, ы-ы» кебек җаваплар гына бирде. Ида аның Бәхти турында бик үк чишелеп китәргә теләмәвен аңлады. «Яңа гына йөри башлаганнардыр инде»,— диде ул күңеленнән. Сәгыйть белән дуслашып китүенең беренче көннәрендә бүлмәдәш кызлары аның турында сораштыра башласалар, үзенең дә кисәк кенә теле тотлыгып калганын исенә төшерде. «Рафига аны ярата, ләкин аның үзен яраталар микән соң — карап карыйк әле»,— диде ул үз-үзенә.

Аңа хәзер авыл урамы да, тәбәнәк йортлар да бик үк күңелсез булып күренмәде.

Алар яңадан бакчага әйләнеп килгәндә, анда радиола уйный башлаган иде. Дүрт-биш егет, такта идәнне шы-

гырдатып, тузан туздырып, үзләре генә танцевать итеп яталар иде. Алар арасында бүтәннәрдән калкурак буйлы, озын ак чалбар, теш порошогы белән агартылган ак туфли кигән Бәхти дә бар иде.

Егетләр, култыклашып килгән кызларны күреп алдылар да, җилләнеп әйләнүләреннән кисәк кенә туктап калдылар һәм, бер-берсен бүлеп, шаярышып кычкырырга тотындылар:

— Кызлар килә, кызлар!

— Әйдәгез, әйдә, кыюрак!

— Тартынмагыз!

Кызлар, алар янына ук килеп җитмичә, танцы мәйданчыгын бүлеп алган агач рәшәткә янында гына туктап калдылар. Шундук Бәхти килеп җитте, исәнләште дә рәшәткә аша кулын сузып:

— Күтәреп алам!— дип кычкырды.

— Нигә үзегез генә танцевать итмисез? Ужасно шәп чыга!— диде Ида, күзен кысып.

Бәхти рәшәткә аша сикереп төште, әдәп саклау йөзеннән дип булса да, рөхсәт-фәлән дә сорап тормыйча, берниндн тартынусыз, күптәнге дуслар сыман, Рафига белән Иданың икесен дә култыклап алды, бер күгәне каерылган рәшәткә капкасыннан аларны такта идән уртасына алып керде. Яңадан радиола уйный башлады. Егетләрнең берсе, зур, кәкре борынлысы, Идалар янына йөгереп килде дә:

— Рафига белән танцевать итәргә рөхсәт итәсеңме?— диде Бәхтигә.

Бәхти, башын иеп, Рафигага карап алды.

— Ун минутка гына була, но, кара аны, бер генә минутка да артык түгел,— диде ул егеткә, бармак янаган булып.

Рафига, үзенең дә каршы түгеллеген белдереп, уң беләген иплэп кенә Бәхти кулыннан ычкындырды. Зур борынлы егет аны шундук җилтерәтеп уртага алып кереп китте.

— Алайса без икәү?— диде Бәхти, Ида белән генә калгач.— Разрешите?

— Что ж поделаешь с вами!— диде Ида, русча. Ул кайчакта, Казанның кайбер татар кызлары кебек, үзенең яхшы тәрбия кешесе икәнлеген күрсәтү өчен, үз туган телен начар белүче булып кылана иде.— Үзегезнең кызыгызны проворонили...

Бәхти бик килешле итеп мыегының бер очын сикертеп куйды.

— Проворонили!— диде ул, Ида сүзен кабатлап, ләкин бөтенләй икенче тонда.

Радиола тавышын ишетеп, бакчага тиздән төркем-төркем яшьләр килә башлады. Танцевать итүче парлылар да, авызын ачып карап торучылар да кинәт күбәеп китте, һәм радиоланың колагын борып утыручы җирән чәчле егет пластинкаларның берсе артыннан берсен алыштырып кына торды.

Ун минут та танцевать иттеләр, унбиш минут та танцевать иттеләр. Бәхти һаман Ида белән булды. Тын алырга туктаган араларда алар янына зур борынлы егет белән Рафига килде. Тегe-бу турында сөйләштеләр, көлештеләр, ләкин яңадан музыка уйный башлагач та, зур борынлы егет беренче булып Рафиганың кулыннан тотып та алды, җилтерәтеп, бөтерелдереп, уртага кереп тә китте.

Ида Бәхти белән калды. Бәхти үзен аның белән бик иркен тотты. Аның кыюлыгы, танцыда бик яхшы йөртә белүе, үз-үзенә ышанып, кулбашларын сикертеп сөйләшүе һәм кара мыегы Идага һаман ошый барды. Ул бик «интересный» булып чыкты, танцевать иткәндә үз-үзен кайбер егетләр кебек бик эре итеп яисә бик җебегән итеп тотмады — әледән-әле сүз башлап җибәрде, сүз арасына төрле мәзәк, кызык нәрсәләр кыстырып җибәрде, хәтта аңа комплиментларга кадәр әйтте. Ул мондагы егетләрдән, гомумән, авыл егетләреннән кайсыдыр ягы белән аерылып, күзгә нык ташланып тора иде.

Ида Рафиганың тынычсызлана башлаганын, минут саен диярлек каш астыннан гына Бәхти ягына караштырып алганын күреп алды. Бу аңа бик кызык тоелды, Рафиганың бик тиз көнләшә башлавыннан көләсе килде. «Бәхти аны яратмый»,— диде ул үз-үзенә, ниһаять, ныклы бер нәтиҗәгә килеп. Һәм бу матур, «интеллигентный», «симпатичный» егетнең үз кызына әйләнеп тә карамыйча, аның белән, Ида белән, танцевать итүе, гел аның тирәсендә булуы анда тагын да үз-үзең белән горурлану тойгысы, үзеңнең матурлыгыңны, бүтәннәрдән өстенлегеңне аңлау тойгысы тудырды.

Ул, бер-берсе белән туктаусыз аралашып торган, чайкалган, кыймылдашкан кешеләр арасында көлке кыяфәтле дус кызын тагын бер очратты да, аннан ераклашкач:

— Сез нишләп үз сүзегезне онытасыз?— диде Бәхтигә. Аннан соң беләгендәге сәгатенә күз төшереп алды.— Ун минут кына түгел, утыз минут прошло инде!

Бәхтинең шундук исенә төште.

— Ах, да!— диде ул.— В самом деле шулай укмыни?— Ләкин шундук яшькелт, зур күзләре белән Идага төбәп карады да, елмаеп: — Әллә минем белән танцевать итәсегез килми?— дигән булды.

Ида уң күзен кысты да, башын чак кына аның ягына борып, теш арасыннан гына көлеп куйды.

Бәхти Рафига янына киткәч, вальсны ул зур борынлы егет белән танцевать итте. Ләкин аңа аның белән танцевать итү бер дә кызык тоелмады. Егет рәтләп йөртә белмәде, еш кына ялгышты, буталды.

— Сез әле яңа гына өйрәнәсез бугай?— диде ул егеткә, салкын гына.

— Юк... әйе... бик үк белмим шул әле,— диде тегесе, уңайсызланып, ләкин шулай да берни сиздермәскә тырышкан шикелле, һаман бөтерелүендә булды.

Кинәт ул үзенең авыр, зур ботинкасы белән Иданың аягына бәрелеп китте. Ида, үз-үзенә ачуланып: «Ниндидер бер күсәк белән танцевать ит, имеш!»— диде күңеленнән. Ул пластинканың тизрәк әйләнеп бетүен теләде. Кеше арасында бик эссе, бөркү була башлады. Кешеләргә бәрелә-сугыла шушылай әйләнеп йөрүгә кинәт аның күңеле сүрелгәндәй булды, нишләптер танкеткасы аягын кысты, тәне авырайды, һәм ул, музыканың беткәнен дә көтмәстән, кулын егетнең иңбашыннан алды да, аны бик кыен хәлдә калдырып, бөтенләй читкә чыгып басты.

Янына Бәхти белән Рафига килгәч, битенә кулъяулыгы белән җилләнә-җилләнә:

— Тирләтте,— диде.— Танцевать итәсе дә килми нигәдер.

— Әйдәгез, бакчада йөреп киләбез!— диде Бәхти.

Караңгы аллея буенча йөргәндә, Бәхти аларга студентлар турында, солдатлар турында бик үк әдәпле дә, шулай ук бик үк әдәпсез дә булмаган бер-ике мәзәк сөйләде. Иданың бу мәзәкләрне кайчандыр, кемнәндер ишеткәне бар иде. Ләкин Бәхтинең сөйләве хәзер аңа бик кызык күренде. Ул эче катып көлде.

Бакчаны бер-ике мәртәбә әйләнделәр дә яңадан танцы барган җиргә килделәр. Алар каршысына тагын каяндыр зур борынлы егет килеп чыкты һәм радиола көй уйный башлагач та, ялт итеп Рафига янына килеп тә җитте. Нигәдер кинәт сүзсезләнеп, тынып калган Рафига аның тәкъдименә каршы:

— Баш әйләнә,— диде, күңелсез генә.

— Алайса, син, Раечка, бераз ял итеп тор,— диде Бәхти, кайгыртучан тонда. Аннан соң тиз генә Идага борылды.— Сезнең дә баш әйләнмидер ич? Ато бөтен кызларның да башы әйләнә башласа, эш харап — бүген минем танцевать итәсе килеп кенә тора.

— Хәзергә юк әле, әйләнми,— диде Ида.

Рафиганың кыяфәте хәзер чын-чынлап кызганыч иде. Идага кинәт бик күңелле булып китте. Аның юри Рафиганың ачуын китерәсе килде. Ул нигәдер кычкырып көлде дә шәрә, ак беләген Бәхтинең биек, киң кулбашына куйды. Ул музыкага колак салмады, үзенең ничек, кая басканын да белмәде, ул бөтенләе белән ак чалбарлы егетнең көчле, нык куллары ихтыярына бирелде.

Аның моңарчы Бәхтине үзләре авылында күргәне юк иде. Алар сөйләшеп киттеләр. Бәхтиләр монда, Идалар авылына, күрше районнан килгәннәр икән. Ул үзе Уралда горный инженер булырга укый икән.

Шул турыда ишеткәч тә, Ида Бәхтигә күтәрелеп карады.

— Шәһәргә өйрәнгән кешегә монда бик күңелсез,— диде Бәхти, үзе турында сөйләвен дәвам итеп.— Барыйм дисәң, барыр җире юк, сөйләшим дисәң, сөйләшер кешесе юк. Притом, без монда күптән түгел генә күченеп килдек. Сезнең белән танышуга мин бик шат, бик доволен, бүген әле миңа беренче мәртәбә шундый күңелле. Мин сезнең белән төне буе танцевать итәргә дә әзер!

— Итәрсез — итмини!— диде Ида.— Кызыгыз әнә тизрәк кайтып китәргә көтеп кенә тора.

Бәхтинең зур күзләре, гаҗәпләнү белдереп, тагын да ныграк ачылды, мыек очлары бөгелеп аска таба сузылды.

— Кем? Кем ул? Раямы? Күрше ич ул минем!

«Вот как!»— дип уйлап алды Ида.

Бәхтинең студент булуын, хәтта үзеннән бер курска югарырак укучы булуын белгәч, аның бу егеткә карата ихтирамы тагын да арта төште. Иң мөһиме — ул аны үзе белән тиң итеп, алай гына да түгел, үзеннән бераз өстенрәк тә итеп исәпли башлады. Аның һәрбер сүзе аңа мәгънәле булып, оста, тапкыр булып, һәрбер кыланышы яхшы, килешле булып тоелды. Мондый егетләр белән ул шушында, авылда, чынлап та таңга кадәр танцевать итәргә әзер иде. Ул моңарчы өйдән чыкмый саргаеп ятуына тагын бер мәртәбә үкенеп куйды.

Аның күз алдына Сәгыйть килде. Ләкин ул озакка бармады, аның образы шундук каядыр югалды, һәм ул, үз-үзен тынычландырып: «Ә нәрсә булган?— диде.— Миңа күңелсез булуын ул бит үзе дә теләми, ул мине ужасно ярата. Пустяки!..»

Танцы бетеп, яшьләр таралыша башлаганда, сәгать төнге бер иде.

— Мин сезне озатып куярмын... әгәр каршы килмәсәгез?— диде Бәхти, бик гади нәрсә турында сөйләгән кебек, тыныч кына һәм Иданың кулыннан алды.

Ида кинәт каушап калды.

— Что сез! Что сез!— диде ул, аңа каршы нәрсә әйтергә дә белмичә, беләген аның кулыннан ычкындырырга тырышып.

Ләкин Бәхти аны ныгытып тоткан иде. Ул, Рафига белән күзгә-күз очрашу турында уйлап, кинәт кып-кызыл булды. Тирә-якта һәркем аңа гына карыйдыр шикелле тоелды. Моны сизү хәзер анда бер дә күңелле тойгы уятмады. Ул тагын егетнең кулыннан ычкынырга тырышып карады, аңа ачуланмакчы булды, ләкин ул, үзенең дус кызы көтеп торырга тиеш булган скамья ягына карамаска тырышып, башын түбән игән көе, күләгәле яктан Бәхти белән бергә баруында булды.

Бәхеткә каршы, Рафига үз урынында юк иде. Күрәсең, көнләшеп кайтып киткәндер инде. Иданың тыны озаеп киткәндәй булды.

— Рафига кая соң?— диде ул, як-ягына каранып.

— Нигә кирәк ул безгә?— диде Бәхти, кычкырып.

— Алай ташлап китәргә ярамый инде...

— Юлны беләдер әле, үзе дә кайтыр!

Урамга чыга торган капка төбендә, ике-өч адым гына читтәрәк, таныш шәүлә күренеп китте. Рафига аларны урам якта көтеп тора иде. Ул Бәхтинең соңгы сүзләрен ишетеп калды. Кинәт аның йөзенә кемдер китереп суккан кебек булды — ул шундый оялды, шундый гарьләнде, нишләргә дә белмичә, тиз генә читкә борылды.

— Ә, Раечка!— диде Бәхти, аны күреп алып, һәм бөтенләй үзгәргән, ягымлы тавыш белән: — Әйдә, киттек!— диде.

Рафига шундук яшьләр арасына кереп югалды.

— Рая! Раечка!— дип кычкырды Бәхти аның артыннан. Аннан соң хәтер калдыргыч салкын көлү белән көлеп куйды да кулын гына селтәде: — Ну, как хочешь...

Рафига, кешеләр арасыннан чыгып, караңгыда берүзе генә калгач, тыела алмыйча елап җибәрде. Бәхти белән алар, егет әйткәнчә, һич тә бер-берсенә күршеләр түгел иде, һәм Бәхти аны инде атнага якын көн саен танцыдан, кинодан соң өйләренә озатып куйган иде һәм аның йөрәгенә шатлык катыш курку салып: «Мин сезгә беренче мәртәбә күргәч тә гашыйк булдым»,— дигән иде.

## III

Сәгыйтьне әкренләп-әкренләп, вакыты-вакыты белән яңадан эч пошу тынычсызлый башлады. Ул, үзенең ни өчен эче пошканын, ни өчен күңеле тырналганын бик

яхшы белсә дә, үз-үзен алдарга теләгәндәй, һаман бернинди хәсрәте булмаган кеше шикелле йөрергә, Ида турында искә төшерерлек барлык нәрсәне вакытлыча онытып торырга тырышты. Һәм шуның өчен ул — бераз үч итеп, ачу итеп тә — Идага, аның үзеннән бернинди җавап алмыйча, берни язмаска булды. Әмма күңел һаман үзенекен итте: әзләнде, борчылды. Әчке тирән сагыш, көндәлек мәшәкатьләрне, бүтән төрле теләкләрне санга сукмыйча, һаман тышка саркып, тамчылап торды.

Беркөнне ул, кичкә таба, бакча киртәсе буендагы бүрәнәләр өстендә китап укып утыра иде. Киртә баганаларыннан яшел чирәмгә озын күләгәләр сузылган, ерактан, авылның икенче башыннан кайтып килүче көтү тавышы килә иде.

Сәгыйть, чишмә ягында ниндидер җыр тавышы ишетеп, кинәт тынып калды һәм китабыннан аерылып тыңларга тотынды. Кисәк кенә кузгалган ниндидер нечкә, үткен хистән күңеле тирбәлеп куйды. Җыр тавышы аңа искиткеч моңлы булып тоелды. Бу таныш тавыш — Зәйтүнә тавышы иде. Ул, бер кулын иңбашындагы көянтәсе өстенә салган көе, икенчесен селти-селти, чишмәгә суга бара, көянтә очындагы калай чиләкләр аяк атлаган саен алмаш-тилмәш чайкалып-чайкалып куялар иде.

Сәгыйть, киртә аша үрелде дә, бөтенләй үз-үзен онытып, чишмә юлына, Зәйтүнә китеп барган якка карап тора башлады. Чиләкле кыз белән аның арасы бик үк якын булмаса да, җыр сүзләрен ул аермачык ишетә алды:

Биек тауның башларында
Каен катылары бар,
Күкрәп үскән күкрәгемдә
Кайгы катулары бар.

«Зәйтүнә үз тавышына үзе гашыйк булып, бирелеп, хисләнеп җырлый, һәм җырның сүзләре һич тә аның, Сәгыйть уйлаганча, күтәренке күңеллелегенә туры килми иде. «Гаҗәп,— дип уйлады ул үзалдына,— аның нинди кайгысы булырга мөмкин?» Ләкин игътибар беләнрәк тыңлый торгач, ул аның тавышында чыннан да ниндидер әчке моң һәм кем өчендер сагышлану кебек нәрсә барлыгын сизеп алды.

Агыйделгә төшә яздым,
Тотмадың беләгемнән.
Тамыр җәйгән гөлләр кебек,
Китмисең җөрәгемнән,—

дип җырлады кыз.

Берничә минуттан ул таллар арасына кереп күмелде. Сыңар чиләк, кояш нурында бер-ике мәртәбә ялт-йолт килде дә, бөтенләй күздән югалды. Бераздан соң калай чиләкнең шалтырап каты җиргә утырганы, тимер башлы көянтәнең әллә шундагы төпкә, әллә ташка бәрелгәне ишетелде, һәм таллар өстендә яшь кызның чиста, яңгыравык авазлары тирбәлде:

Талир тәңкәм суга төште —
Таблыр малларым түгел,
Авызымнан җаным чыкмый,
Онтыр ярларым түгел...

Зәйтүнә, салмак кына атлап, яңадан сукмакка килеп чыкты. Хәзер инде аның чиләкләре дә чыңламый, җыр тавышы да ишетелми иде.

Сәгыйть, урыныннан кузгала алмыйча, һаман аның ягына карап торды.

«Кем өчен шулай моңая икән соң ул?— дип уйлады ул.— Рәшит өчен микәнни?.. Әллә соң яшь йөрәкнең болай гына талпынуымы бу?» Сәгыйть өмәдә, печән чапкан чакта, үзенең Зәйтүнә турында уйлавын, күңелендә ул чакта Рәшиткә карата көнчелек кебек бер нәрсә булганын исенә төшерде. Моны искә төшерү анда үз-үзеннән оялу, үзенең вөҗданы алдында кызару кебек бер тойгы уятты. Үзенең сөйгән кызы була торып, үзенең Идасы була торып, нишләп шулай күңеле чуарланды икән аның? Бернинди хәбәре-хәтере юк дип, бөтенләй азып-тузып китәргәмени монда? Юк инде, булмаса булмас — ул аңа барыбер тырнак карасы кадәр дә хыянәт итәргә тиеш түгел, күңеле белән дә, уе белән дә хыянәт итәргә тиеш түгел! Итмәс! Хәзер нишләп тора соң әле ул монда? Нәрсәгә исе китте соң әле аның?

Ул, яңадан бүрәнә өстенә утырып, баягыча китап укырга тотынмакчы булды. Ләкин, гаҗәп хәл, нишләптер аның кисәк кенә китапка күңеле сүрелде, уку түгел — аны хәтта кулга да аласы килми башлады. Колак төбендә һаман Зәйтүнәнең җыр тавышы яңгырап торды, кичке талгын һавада, бертуктаусыз безелдәшкән черкиләр тавышына, чикерткәләр черелдәвенә һәм морҗадан чыккан әчкелтем, сыек төтенгә кушылып, дәртле, сагышлы авазлар тирбәлде.

Ул тагын чишмә ягына борылып карады — анда беркем дә юк иде. Аңа нигәдер бик күңелсез, бик моңсу булып китте. Аның хәзер үк, шушы минутта ук кайдыр очып китәсе, кемнедер күрәсе, кем беләндер сөйләшәсе килде. Бу «кемдер», әлбәттә, Ида иде.

Сәгыйть, бүрәнәләр өстеннән төште дә, үзенең кая барганын үзе дә белмәстән, әкрен генә атлап, бакча капкасына таба китте. Капканы ачып икенче якка чыкты.

Сукмак таллык артындагы чишмәгә алып бара иде. Сукмакның ике ягында да котырып әрекмән яфрагы, кычыткан үскән иде.

Аның кулы кычытканга тиеп китте, ул берни тоймады. Як-якта яшел яфрак исе, кычыткан исе аңкыды, һәм кырыс, ягымсыз үсемлекләрне үзенчә матурлап утырган төссез, каты чичкәләрдә умарталарына кайтырга соңга калган бал кортлары безелдәште. Ул бик кадерле, бик кирәкле ниндидер нәрсәсен югалткан кеше шикелле, җир өстеннән күзен алмыйча, сукмак буенча барды да барды. Менә таллык та якынайды, ул яктан чылтырап агып яткан чишмә тавышы ишетелде. Ул адымын кызулата төште, таллык арасыннан чыкты да үз алдына бертуктаусыз нидер сөйләнгән чишмә алдында туктап калды. Монда үзенең нигә килгәнен үзе дә белмичә, чишмә суы белән битен юды, башын юды.

Ул эзләгән нәрсә монда чишмә янында да, таллык арасында да юк иде.

Аның кире өйгә кайтасы килмәде. Ул чишмә янындагы калкулык өстенә менеп китте. Туктады да такта түбәле йортлар, биек тупыллар ягына борылып карады. Анда да беркем күренми, анда да тынлык, бушлык иде.

Тагын бераз менгәч, аның алдында җәелеп яткан иркен басулар, ерактагы таулар, урманнар киңлеге ачылды. Ул Ида белән бергә үткәргән элекке вакытларын, аның сүзләрен, аның күз карашын, елмаюларын исенә төшерергә тырышты. Ләкин хәзер аның зиһенендә бер генә нәрсә дә тәртипкә салынмаган иде, бер генә нәрсә дә үз урынында түгел иде, һәм ул хәтта аның кыяфәтен дә тулысынча күз алдына китерә алмады. Аның күңелен хәзер ниндидер тавыш-тынсыз, ниндидер зарланусыз, аңлаешсыз сагыш кына тутырган иде.

Ул үзенең як-ягына күз төшерде. Ул үзенең каршысында гына, калын ботакларын җир өстенә канат кебек җәеп салган тәбәнәк ак чыршы янында, зәңгәрсу кыңгырау чичкәсе күрде. Иелде дә чичкәне өзеп алды һәм аны күзенә якынрак китереп, гаҗәп табышка юлыккан шикелле, игътибар белән карый башлады.

«Чынлап та, нәкъ кыңгырау кебек, уенчык кыңгырау кебек»,— диде ул үз-үзенә. Хәтта телләре дә бар, сабагыннан тотып селкетә башладың исә, шундук нечкә генә тавыш чыгарып чыңларга тотынырлар кебек. Малай чакта алар шушы уенчык кыңгырауларга пешкән

каен җиләге тутырып ашыйлар иде. Ничә җиләк сыйды икән соң моңа? Бер өч-дүрт җиләктер инде... Иданың бер көлмәге нәкъ шушы кыңгырау чичкәсе төсле ич! Ул көлмәге аңа шундый килешә, тәненә шундый сыланып кына тора. Аның күзләре дә шушы кыңгырау чичкәсе төсле!.. Кара, ничек ул моңа элек үк игътибар итмәде икән? Нинди матур, нинди нәфис чичкә!

Ул, тагын кыңгырау чичкәсе күрмәкче булып, як-якка күз йөртеп чыкты. Эзләп торырга да туры килмәде — монда әле печән чабылып алынмаган иде, бөтен болын өсте чуар чичкәгә күмелгән иде. Ул, ниндидер бик әһәмиятле, бик кирәкле бер эш башкарган шикелле, бирелеп, мавыгып, чичкә җыярга тотынды. Аңа аларның берсеннән-берсе матуррак, берсеннән-берсе хуш ислерәк булып тоелды. Ул үзенең ни өчен, кем өчен җыйганын да нык-лап аңламады, анда бары тик шундый бер теләк кенә туды, һәм ул, әлеге теләккә буйсынып, башын да кал-кытмыйча җыйды да җыйды. Бу эш аның күңелендә тынычлану шикелле бер әйбәт хис уятты.

Ул өйгә кайтып кергәндә, күз бәйләнә башлаган иде. Мичтә дөрләп ут яна, мич турысында — идәндә, стенада, сике яңагында мичтән төшкән ут шәүләләре тирбәлә. Әнкәсе мич тирәсендә, Гамбәр Тәлгать янында булаша иде.

Сәгыйть, беркемгә бер сүз әйтмичә, түргә узды, пыяла банка табып, аңа су салды да, алып кайткан чичкәләрен шуңа утыртып куйды. Бөтен өй эченә хуш ис, җәйге болын исе таралды. Бу ис аңа Иданы хәтерләткәндәй булды. Ул урам яктагы тәрәзәне иңеләй ачып җибәрде. Аның битенә төнге дымсу, салкынча һава килеп бәрелде. Урам ягыннан агылган шушы җил аңа үзенең бик кадерле, бик якын кешесе турында нидер пышылдаган шикелле тоелды. Өй эчендә, тышта — бөтен җирдә бары тик ул гына, аның исе, аның рухы гына иде.

## IV

Әз генә дөбердәтү белән, эчтәге өй ишеге ачылып китте һәм чоланда әнисенең үзалдына нидер пышылдавы, лап-лоп басып, ишек ачарга килүе ишетелде. Ул, караңгыда кармаланып, келәне эзләп тапты да, бераз куркынган, ләкин шулай да йомшак тавыш белән:

— Идея, синме, кызым?— диде.

Аның тавышы шундый кызганыч, шундый көчсез булып ишетелде, Иданың күңелендә кинәт әнисенә карата моңа кадәр беркайчан диярлек булмаган ярату, кыз-

гану хисе кебек бер нәрсә уянды. Ул хәзер ни өчендер күтәренке күңелле, шәфкатьле, бәхетле иде, һәм аның үз әнисен иркәлисе, аңа берәр җылы сүз әйтәсе килде.

— Әйе, мин, әнием, ач әле,— диде ул, бала чагындагы кебек иркәләнү тавышы белән.

Аның мондый җавабына күңеле эреп киткән ана шулкадәр соңга калып кайткан кызына шатлыгыннан әз генә булса да ризасызлык белдерергә кирәк тапты.

— Ничек курыкмадың?.. Әтәчләр кычкыра башлады инде... бу төнгә кадәр, кызым...

— Кычкырсын! Андый әтәчләргә мин үзем әтәч!

Ида ачылып киткән ишектән тиз генә эчкә узды һәм әнисенең әле түшәк җылысы да суынып өлгермәгән кайнар, юан гәүдәсеннән ныгытып кочаклап алды, аннан соң аның бит очыннан чутылдатып үпте дә йөгерә-йөгерә баскыч буенча менеп китте.

— Җегетләр барында кызлар куркып торамыни, әнием!— диде ул, кычкырып, беренче мәртәбә әнисе алдында егетләр турында сүз чыгарудан курыкмыйча.

Мәгъфия ни әйтергә дә белмәде. Май баскан карт йөрәге, инде бик күптән булмаганча, шатланып, куанып тибәргә тотынды. Ул, кузгалырга да, ачык калган чолан ишеген бикләп куярга да белмичә, беравык кызы артыннан карап торды. Кызының шундый сөйкемле, шундый якын, ана җанлы булганын аның быел,— хәтта ул шәһәрдән кайтып төшкән көнне дә,— бөтенләй күргәне юк иде әле. «Кара, кулына кош төшкәнмени! Нинди сөенгән...»— дип уйлады ул кызы турында, аптырап. Шуннан соң келәләрне, ишек тоткаларын кулы белән сыйпап куйды, стенага тотына-тотына, сакланып кына баскычтан өскә менде һәм өй ишеген дә яхшылап бикләгәч, авыз эченнән һаман нидер мыгырдана-мыгырдана, үз бүлмәсенә кереп китте.

— Таң ата, әнием!— дип кычкырды Ида икенче бүлмәдән. Шуннан соң аның кабаланып шторны күтәргәне ишетелде.— Ах, нинди красота!..

Мәгъфия тавыш-тынсыз гына үзенең җылы урынына барып ятты да, нииндидер бик зур шатлыгы бар кеше кебек, караңгыда үзалдына елмаеп куйды.

Койка янында гына, идәндә, астына палас җәеп, Рәхимә апа йоклап ята иде. Идрис өйдә юк чакта ул һәрвакыт «Мәгъфия апа»сы янына кереп куна иде. Ул өйдәге тавышка уянып китте.

— Әллә Идрис абый кайттымы, Мәгъфия апа?— диде, пышылдап.

— Юк, Идея.

— Ә-ә... Уф, бастырылып ятам икән!— диде Рәхимә апа, куркынган тавыш белән.— Бер сары эт килеп керде, котың алыныр, Мәгъфия апакаем. Керде дә миңа ташланды бу. Бугазга ябешә, Мәгъфия апакаем. Кычкырырга итәм — кычкырып кына булмый бит. Әй кычкырырга итәм, әй кычкырырга итәм — юк. Шуннан телгә килде бу, Мәгъфия апакаем. «Синиеңме миңа таш бәреп калган?»— ди. Авызына кулымны тыктым да, Мәгъфия апакаем, телен тартып өздем, явызның. «Син икәнсең, дошман»,— мин әйтәм...

Мәгъфия, аның төшен сөйләп бетергәнен бүлдермичә генә тыңлап ятты да, бик белдекле төс белән:

— Колһуаллаһеңне укы, як-ягыңа төкер,— диде. Аннан соң койкасыннан башын калкытып, аска, Рәхимә апа яткан җиргә карап алды.— Урыныңны матча турысына җәйгәнсең ич син. Эстинә буенарак күч. Шуңа бастырылгансың... Минем дә шундук күз алдыма килеп җитәләр... сул якка карап яттым исә, күземне дә ачалмыйм... Беркөнне мәрхүм әткәй булып килгәннәр. Килгән дә яныма, кызым, ди, нишләп болай боексың, ди. Теге мин өйрәткән доганы онытмадыңмы соң? Чәчемнән сыйпый, мәрхүм, урыны оҗмахта булсын. Ун мәртәбә укы да уң ягыңа төкер, ун мәртәбә укы да сул ягыңа төкер...

Рәхимә апа, «Мәгъфия апа»сының сүзенә колак салып, урынын күчереп җәяргә тотынды.

Аңа искечә дә, яңача да уку эләкмәде. Шуңа күрә ул, үзе әйтмешли, ике якка да чи надан булып калды. Ләкин ул, томанлы гына булса да, Аллага да, оҗмахка, тәмугка да ышанды. Дөрес, яшьрәк чакта ул алар турында уйлап та бирмәде, моның өчен аның вакыты булмады. Әмма олыгая барган саен, ул «изге» әбиләр сүзенә ныграк колак салды, үзенең наданлыгы турында, бик зур гөнаһлы булуы турында, Аллаһе Тәгалә каршысына баргач ни дип җавап бирәчәге турында ешрак уйлый башлады. Ә бит ул бер генә җавапны да, бер генә доганы да күңеленнән белми иде! «Мәгъфия апа»сы белән танышып китү, гел аның белән бергә булу бу яктан аның белемен арттыруга бик нык ярдәм итте.

Бүре баласын бүреккә салсаң да урманга карый, дигән кебек, беренче тәрбияне атасы мулла абзыйдан алган Мәгъфия, никадәр генә «культуралы», никадәр генә «аңлы» булып күренергә тырышуына да, кайчандыр балалар укытып йөрүенә дә, район җитәкчесе хатыны булуына да карамастан, күңеленнән барыбер элекке Мәгъфия булып калды.

Буш вакытын кая куярга урын тапмый башлаган саен,

аның динлелеге арта гына төште. Әткәсе өйрәткән догалар да, изге китапларның эчтәлеге дә бик үк онытылып бетмәгән иде, һәм ул аларны тырышып кабатларга тотынды. Әнкәсеннән саргаеп беткән әфтиякләр, догалыклар, фал китаплары калган иде. Алар да бик ярап куйды.

Рәхимә апа белән алар бик тиз уртак тел таптылар. Рәхимә апа, ул сөйләгәннәрне бик үк аңлап җитмәсә дә, шулай да яратып, бирелеп тыңлады. Мәгъфия, үзенең укытучылык сәләтен кулланып, томана хатынны әкренләп-әкренләп «агарту» эшенә керәште. Билгеле, үзенең иренә дә, Идага да ул берни сиздермәскә тырышты.

Ул тагын кызы турында уйларга тотынды. «Нишләп шулай шатлыгы артып кайтты икән?»— диде ул, тиз генә тынычлана алмыйча. Ул күзләре ачык көе бераз тыңлап ятты, Ида бүлмәсендә бернинди тавыш-фәлән ишетелмәгәч, торып тыңлап килмәкче булды.

Мөмкин кадәр ипләп кенә атлый-атлый, Ида бүлмәсе ишегe янына килде дә, эчкә колак салды. Кызының бүлмәсендә кыштырдаган тавыш та ишетелмәде. Кайгыртучан ана кызының ишек тоткасын сыйпаштырып куйды да, күңеле тынычланып, үз ягына чыгып китте. «Йоклый, балакай»,— диде ул, эченнән генә.

Ләкин балакай йокламый иде әле. Ул әнисенең палас җәелгән идәнгә авыр-авыр басып, мышнап, әкрен генә атлап килүен, авыз эченнән нидер пышылдавын ишетеп ятты. Аңа хәтта әнисе ишек төбендә тыңлап та тора шикелле тоелды. Ләкин бүген ул әнисенең коры хәсрәтләнеп, юкка кыбырсып йөрүенә бөтенләй үртәлмәде. «Вот дура, әллә урлап китәрләр дип курка инде!»— диде ул әнисе турында, ачусыз гына.

Аның күңеле җилкенгән, чигә тамырлары дөпелдәп тибә, башы туктаусыз шаулый иде. Аның күңелендә шатлык кебек нindидер бер әйбәт нәрсә бар иде. Аңа бүген бөтенесе дә аны бүтән вакытка караганда да ныграк яраталардыр шикелле тоела иде. Сине һәркем яратканда нинди рәхәт!

Бүген ул үзен үзгәргән, яңарган шикелле хис итте. Ялгызлык, авылда яшәүнең күңелсезлеге, авырлыгы кисәк кенә өстеннән коелып төшкәндәй булды. «Авылда да күңел ачарга була икән»,— диде ул үзенә-үзе, бик зур ачыш ясагандай. Юк, моннан соң инде ул бер генә кичне дә өйдә ятмаячак, кинога... танцыга йөриячәк. Җитәр, хватит! Әтисе кайткач, аның машинасы белән елгага, ерактагы урманнарга барырга була. Менә нинди шәп булачак! Менә бу, ичмасам, шәп булачак!..

Ул юри, аңлы рәвештә, ниндидер эчке бер каушау белән, Бәхти турында уйламаска, аны бөтенләй исеннән чыгарып ташларга тырышты. Ләкин егетнең кара мыегы, авызын матур кыйшайтып сөйләшүләре, туры карый торган зур, матур күзләре, киң балаклы, озын ак чалбары һаман күз алдында торды.

Ул аны озата килде. Алар юл буена Рафиганың үпкәләп кайтып китүе турында сөйләштеләр. Ул көлде, Ида дус кызын яклаган булды, Бәхтине кызларга карата шәфкатьсез, хаксыз, хәтта бераз «жестокий» булуында гаепләде, аңа шелтә сүзләре әйткәләде. Икесе дә аннан котылуларына күңелләреннән бик канәгать булдылар.

Гаҗәп хәл, Бәхтигә ул бик тиз ияләшеп китте. Ул Сәгыйтьне, мин синнән башка чит егетләргә һәрвакыт җирәнеп карыйм, дип ышандыра торган иде. Әмма бүген Бәхти аңа чит тә, ят та булып күренмәде. Әллә соң авыл тынлыгы, элекке ялгызлык аңа мондагы тупас, культурасыз авыл егетләре арасында аны шундый бердәнбер кеше итеп, үзенә тиң кеше итеп күрсәтте микән? Әллә соң моңа аның тышкы күренеше һәм иң мөһиме, аның да студент булуы сәбәпче булды микән? Ни генә булмасын, ул аңа һаман ныграк ошый барды.

Аңа мондагы җанлы, яңа, «интересный» егетнең ачык сурәте ерактагы тонык Сәгыйтьне каплый бара, аны кызыксызга әйләндерә бара шикелле тоелды. Ул, үз-үзенә ачуланып: «Что за ерунда!» — диде, шулай да кара мыек, ак чалбар турында әле бик озак уйланып ятты.

...Бүтән көннәрне дә шулай булды: төшкә кадәр йоклады да, иртән торгач та эшлисе эше, барасы җире булмаганга, иренеп кенә күзен ачты, иренеп кенә урыныннан торды, биш сәгать юынды, биш сәгать киенде, ашыкмыйча гына әзерне ашады һәм күңеленең нигәдер үз урынында түгеллеген, нигәдер тынычлыгы югалганын тойган хәлдә, яңадан үз бүлмәсенә кереп китте, каккан баганадай бер урында басып торды-торды да кулына китап алды. Ләкин китапны өстәлгә ташлап, көзге алдына килде, үз-үзенә сокланды, боргаланды-сыргаланды, йөзенең һәрбер ноктасын, һәрбер сызыгын җентекләп тикшерде.

Төштән соң вакыт бигрәк тә әкрен узды. Теләсә нәрсәгә ачуы килде, юкка-барга әнисенә үртәлде, кычкырды. Кояш сүрелә башлагач, әледән-әле бакчага, урамга чыгып керде, клуб ягына карап тора башлады. Кичке ашны ашагач та, кабаланып, өй киемнәрен өстеннән салып ташлады, анысын анда орды, монысын монда орды, шкафтан яхшы күлмәкләрен актарып алды, бәйрәмгә әзерләнгән

кебек, көзге алдында төзәнергә-бизәнергә, кыйбатлы, яхшы хушбуй белән баштанаяк коенырга тотынды. Хушбуй исе хәтта, парикмахер йортларындагы кебек, ачык тәрәзә аша урамга чыкты, узган-барганнарның борыннарын ярып үтте.

Кич чыгу, танцыга, киногa йөрү һәм булачак «горный инженер» белән очрашу аның өчен хәзер бердәнбер максатка, бердәнбер күңел ачуга, шатлыкка әйләнде.

Рафиганы ул клубта кинода да, бакчада танцыда да бүтән очратмады. Бу аның өчен бик әйбәт булды, хәер, ул аның турында бик үк хафаланмады да, Бәхтинең Рафиганы ташлап, үзе белән — Ида белән — мавыгуы, аңа гына күңел бирүе студент кызга бик табигый булып күренде. Ул монда беркемне дә — үзен дә, Бәхтине дә гаепләмәде, бу турыдагы уй аның башына да килеп карамады. Ул үзен җиңүче итеп кенә сизде. Бары шул гына.

Бәхти аның белән — кирәк вакытта бик ягымлы, бик әдәпле, кайгыртучан, кирәк вакытта — кыю, хәтта чиктән тыш кыю һәм бераз әрсезрәк тә була белде. Ул аның күзенә карап: «Идочка, сез шундый красавица! Валлаһи, торган җиремнән үлеп китим менә!»— диде яисә кичләрен аны клуб алдында, бакчада каршылаган чакларда, кызлар белән сөйләшкәндә үз-үзләрен бик иркен, бик җиңел тота торган шома егетләр кебек, бернинди тартынусыз, бернинди дулкынланусыз: «Бер генә үбеп алыймчы, Идочка, шул алсу битләрегезне!»— дип кычкырды. Билгеле, ул мондый сүзләрне шаярган булып, юри генә кыланган булып әйтте, тик мондый шаян сүзләрдән Ида колак очларына кадәр кызарды, озын керфекләре аска салынып төште, һәм аңа каршы ул рәтле бер генә сүз дә кайтара алмады.

Ул үзенең тынычлыгын көннән-көн җуя барганын, үзе белән Бәхти арасындагы мөнәсәбәтнең хәзер гади танышлык, гади мавыгу, кызыксыну гына булмыйча, әлегә тел белән әйтергә куркыныч булган ниндидер икенче нәрсәгә әйләнә барганын тойды. Ул моңа чик куярга, каршы төшәргә, бөтен нәрсәне өзеп ташларга теләде, әмма моңа аның көче дә, ихтыяры да һәм... теләге дә җитмәде. Һич югында, аның үзенә шулай тоелды.

Тыштан караганда алар арасында, әйтерсең, әлегә берни дә булмады. Алар бергә танцевать иттеләр, бергә кинога кerделәр, бакчада йөрделәр, теге-бу турыда сөйләштеләр, хәтта бәхәсләшеп тә алдылар, тик бәхәсләшкәндә Бәхти аның бер генә сүзенә дә каршы төшмәде, аның һәрбер фикере белән, һәрбер теләге белән килеште. Төнлә ул аны өенә кадәр озатып куйды, төрле мәзәк сүзләр сөйләде.

Ә нигә, моңарчы бер-берсен белмәгән яшь егет белән яшь кыз арасында мондый якын дуслык, мондый ачыктан-ачык дуслык булмаска мөмкинмени? Бик мөмкин! Һәрбер дуслыкның нигезендә, һичшиксез, гыйшык ятарга тиеш дип кем әйтер? Мондый дуслык кына үзең яраткан икенче кешене читкә кага алмый... Ида еш кына шулай уйлады.

Чыннан да бу шундый бер гади дуслык кына иде бугай һәм шул ук вакытта... андый гына дуслык та түгел иде бугай. Ида, куркып, каушап, Бәхтинең беренче сүзне, дуслыктан да артып киткән танышлык вакытында берең икенчеңә беренче булып, үзең башлап әйтүе шундый авыр булган сүзне әйтүен көтте. Ләкин егет ашыкмады: әллә кыюлыгы җитмәде, әллә ышанып җитмәде.

Бер кичне ул, Иданы өенә озата барганда, беразга тынып калды да:

— Идочка,— диде,— сез көндез нишлисез?

— Нигә кирәк ул сезгә?

— Яшел тышлы китапка язып куям,— диде Бәхти.— Чынлап, вакытыгыз бармы көндез? Әйдә, иртәгә мотоцикл белән берәр җиргә барабыз? Просто так. Минем бит мотоцикл бар — әйткәниемме? Минем сезне мотоциклда йөртәсем килә.

Ида тиз генә җавап кайтармады. Киногa, танцыга йөрү ул әле әллә ни түгел, ләкин көпә-көндез... авыл уртасыннан... Аннан соң аңа бит кояшка чыгарга да бик үк ярамый, көз көне шәһәргә чуен китеге кебек караеп бармассың лабаса! Аннан соң... аннан... ну, аннан соң авыл кешеләре, танышлар нәрсә әйтер?

Аңа тиз генә ризалык бирергә ниндидер нәрсә комачаулый кебек иде. Ләкин бу «ниндидер нәрсә» хәзер шундый зәгыйфь, шундый көчсез, ышандыргысыз иде, ул озак икеләнеп тормады. «Пустяки!— диде ул тагын үз-үзенә, күңелендә калкып чыккан әлеге каршы теләкне йомып.— Аннан нәрсә булган? Бик әйбәт булачак даже. Пустяки!..»

— Ә сез мотоцикл йөртә беләсезме соң?— диде ул, аны юри үчекләгән булып.— Белмисездер әле.

— Значит — була? Барабыз? Сәгать ничәдә, кайчан очрашырга?

Ида көлеп җибәрде.

— Сез бик тиз! Мин бит әле согласие бирмәдем. Әгәр мин бармыйбыз, дисәм?

— Ул чакта миңа бик күңелсез булачак.

— Әйдә пристенгә!— диде Ида.

— Була!— диде Бәхти, шатланып.

Икенче көнне билгеләнгән вакытта урамда мотоцикл тавышы ишетелгәч тә, ул тәрәзәгә ташланды. Ак эшләпәсен күзенә төшеребрәк киде дә йөгереп урамга чыкты.

Ул беренче курста укыган чакта алсу төстәге чаңгы костюмы сатып алган иде. Ләкин костюм үтә ачык төстә булганга, бу кием аңа ул вакытта ошамаган иде, аннан соң аны киеп аңа чаңгыда да бик күп йөрергә туры килмәде. Шуңа күрә ул аны икенче җәйне үк авылларына алып кайтып, шунда калдырып китте. Ул инде костюм турында бөтенләй оныткан да иде. Бәхти мотоциклда йөрергә тәкъдим иткәч, ул аны шундук исенә төшерде. Ул костюмның чалбарын гына киде. Җәй көне кышкы, җылы чалбар бик үк килешеп тә бетми иде инде килешүен — ләкин мотоциклда йөрү өчен махсус киемең булмагач, нишлисең!

Ул, күрше-фәләннәр карап тормый микән дигән сыман, үзенең чалбарыннан бераз уңайсызланып, мотоцикл янына якынлашты. Зур пыялалы күзлеген маңгаена күтәреп куйган Бәхти, авызын ерып:

— Ай-яй, кызыл ыштан бик килешә икән үзеңә!— диде.— Болай син настоящий спортсменка. Кая утырасың — алгамы, арткамы?

— Әллә мине артка утыртырыеңмы? Конечно, алга утырам, давай рульне!..

Бәхти, көлүеннән туктамыйча, кесәсеннән үзенеке шикелле үк күзлек чыгарды да, Идага бераз иелергә кушты, иелгәч, күзлекне кидереп, арттан бавын бәйләп куйды.

— Булды,— диде ул шуннан соң һәм рульгә тотынып, Идага утырырга кушты.— Прашу, әйдә...

Бәхти моторны кабызды. Мотоцикл, кисәк кенә каты пытырдап, зәңгәр төтен төчкерергә тотынды, тиз генә урыныннан кузгалып китте дә, капка төпләрендә йокымсырап яткан этләрне өркетеп, үз артыннан куе тузан койрыгы суза-суза, урам уртасыннан басу ягына чапты.

Идалар авылыннан, район үзәгеннән, пристаньга ун чакрым чамасы бар иде. Ком катыш вак таш җәелгән киң юл такыр иде, тигез иде. Бәхти авылны чыккач та, мотоциклын бар көченә җибәрде. Юлда очраган җәяүле кешеләр, атлар, күперләр, ала-кола итеп буялган километр баганалары күзгә чалынып кына калды. Каршыга ыргылган көчле, салкынча җил биткә, күзлек пыялаларына бәрде, култык астыннан кереп, җиң очларын дерелдәтте. Моңарчы мотоциклда йөргәне булмаган Ида, менә урынымнан ычкынып китәм, менә атылып төшеп калам дип, коты алынып барды, чокырлы җирләрне түбән

төшкәндә йөрәге, сикереп чыгар дәрәҗәгә җитеп, куркып кысылды.

Пристаньга, елга яры буена килеп туктагач, күзлеген ул Бәхти кебек үк маңгаена күтәреп куйды. Көннең җилсез, тып-тын булуын күреп, ул аптырап китте. Юлда килгәндә аңа көн чынлап та бик җилледер, бик салкындыр шикелле тоелган иде.

Бәхти мотоциклын аска, сары комлыкка алып төште. Алар кеше әзрәк йөргән җиргәрәк киттеләр дә су керделәр. Ида яшереп кенә Бәхтинең киң, юеш кулбашларына, колаша сыман чокырланып торган калак сөякләре арасына, кара төк каплаган нык балтырларына карап-карап алды. Ул аңа бик көчледер, бик батырдыр шикелле тоелды.

Киенеп яр өстенә менгәч, туктап дебаркадер ягына, елгага карап тордылар: Казаннан зур ак пароход килә иде. Пароход, бер-ике мәртәбә сузып-сузып кычкыртты да, әйләнеп, дебаркадер янына килеп туктады. Бөтен яр буе ямьләнеп, матурланып китте. Дебаркадердан яр читенә сузылган озын такта басмалар буенча кулына чемодан тоткан, аркасына капчык аскан кешеләр йөгерделәр, ашыктылар, кабаландылар. Утырасы утырып, төшәсе төшеп бетте, пароход тагын гудок бирде дә яңадан яр буеннан салмак кына кузгалып китте.

Пристань бер биш чакрым чамасы артта калган иде инде, көтмәгәндә мотоцикл көйсезләнә башлады. Бәхти, йөрешне әкренәйтте дә, кырт кына борылып, канау аша юл читенә чыкты.

— Әйттемме!— диде Ида.— Йөртә белмисең, дип әйттемме! Ну, хәзер как хочешь — теләсәң ничек алып кайт. Мин арыдым, теләсәң ничек алып кайт.

— Кул очына күтәреп тә алып кайтырга риза!— диде Бәхти аңа каршы.

Җир өстенә утырырлык түгел иде, кояш көйдергән чирәмгә бер карыш соргылт тузан кунган иде. Бәхти, Иданың утырыргамы, юкмы дип икеләнеп торганын күреп, кесәсеннән ап-ак кулъяулык чыгарды да тузан өстенә җәеп куйды.

— Утыр шуңа,— диде ул,— синең өчен кулъяулык кына түгел, җан да жәл түгел.

Ида, кояшка аркасын куеп, кулъяулык өстенә җайлап утырды да, уң кулы белән җиргә таянды. Аның хәзер бөтен тәне ватылган, арыган иде, җиңелчә генә башы әйләнә һәм үтереп тә ашыйсы, йоклыйсы килә иде.

Юлда пристаньга баручы бер автомашина күренде. Ида, машина артыннан күтәрелгән тузан эчендә калмас өчен,

юлның икенче ягына йөгереп чыкмакчы булып, шундук урыныннан сикереп торды.

Ул инде канау янына килеп тә җиткән иде, ләкин шул вакыт ул тузанның икенче якка, үзенә каршы якка очканын шәйләп алды. Канау читенә туктады да машинаның узып киткәнен көтеп тора башлады. Бәхти, машинага да, аңа да — бернигә дә игътибар итмичә, иелеп, һаман үзенең мотоциклы белән булашты.

Машина выжылдап килеп тә җитте. Ида, гадәтенчә, башта алгы пыяла аша күренгән шоферга игътибар итте, аннан соң кузовка күз ташлады. Машина элеваторга яңа ашлык алып бара иде. Ак киндер капчыклар өстендә, аркаларын кабинага терәп, өч-дүрт егет утырган иде. Автомашина Ида белән тигезләшкәч тә, егетләр аның ягына борылып карадылар. Берсе кулы белән аның чалбарына күрсәтеп, нәрсәдер кычкырды, һәм кинәт барысы да шаркылдап көләргә тотындылар. Ләкин Ида ягындагысы, иң кырыйдагысы — киң, ачык маңгайлы егет — кинәт көлүеннән туктап калды, йөзе көтмәгәндә җитдиләнеп китте, һәм Идага: ул аңа бик җентекләп карый шикелле тоелды.

Ида аның йөзендәге бу үзгәрешне күрмичә кала алмады — машина аның яныннан шундый якын гына узып китте. Ул хәтта әлеге егетнең аптыраган, гаҗәпсенгән күз карашын да тотып алды. Аның шундук башын түбән иясе, күзен яшерәсе, һич югы, маңгаендагы күзлеген күзенә төшерәсе килде. Ләкин ул берни дә эшли алмады, агарынган, сизелер-сизелмәс кенә калтыранган көе, һаман ераклаша баручы автомашина артыннан аерылмыйча карап торуында булды.

Ул әлеге егетне таныган шикелле булды. Әйе, бу, әлбәттә, ул иде.

## V

Беренче курста Гасыйм Таҗетдинов үз иптәшләреннән артык берние белән дә аерылып тормады. Бүтәннәр кебек үк лекцияләргә йөрде, конспектлар язды, семинарларда катнашты, имтихан, зачетлар тапшырды. Ләкин үз студентларына бәя биргәндә беркайчан да диярлек ялгышмый торган укытучылар аның, гомумән, укуга сәләтле булуы өстенә, бик тырыш, зирәк икәнен бик тиз күреп алдылар.

Тиз арада ул үз группадашлары арасында «башлы» студент булып кына түгел, бәлки, нык характерлы, туры сүзле егет тә, яхшы, ышанычлы иптәш тә булып таныл-

ды һәм үзеннән-үзе бөтен группаның хөрмәтен казанып өлгерде. Икенче курста аны группаның комсомол җитәкчесе итеп сайладылар.

Кайчакта тупаслык булып күренә торган кискенлеге, дөреслекне күзгә туры карап әйтә торган гадәте өчен, билгеле, кайберәүләр аны бик үк яратып та җиткермәделәр.

Бигрәк тә аның Ида белән борчак пешмәде. Ида кечкенә генә нәрсәне дә зурга күтәреп, тик торганда бәхәсләшеп китәргә ярата иде, бер дә юктан аңа бәйләнергә тотына иде. Ул, гадәтенчә, бик белдекле булып исбат итәргә тотына торган иде, ләкин аның «исбат итүе» күп вакытта бернинди нигезсез кычкырынуга, төп мәсьәләне аңламауга кайтып кала торган иде. Гасыйм мондый чакларда ашыкмыйча, кызмыйча, әмма урынлы, дөрес әйтелгән бер-ике сүз белән шундук аның авызын томалый торган иде. Соңыннан Ида еш кына, холыксыз балалар кебек, кинәт үпкәләүгә дә, холыксыз хатыннар кебек, усал, тупас теллелеккә дә барып җитә торган иде һәм аны бәхәсләшә белмәүдә, дорфалыкта гаепләргә тотына торган иде.

Алар, еш кына шулай бәхәсләшсәләр дә, көлешеп сөйләшсәләр дә, беркайчан да бер-берсен яратмадылар. Хәер, Гасыйм яратмады.

Сәгыйтьне ул, киресенчә, якын күрде. Өченче курска күчкәннән соң икесе дә бер бүлмәдә тора башлагач, алар бер-берсенә тагын да ныграк иярләшеп, дуслашып киттеләр. Күп кенә очракта аларның фикерләре, теге-бу нәрсәгә карашлары, хәтта теләкләре дә бер-берсенекенә туры килде. Чын дуслык, чын иптәшлек өчен иң әһәмиятлесе шул түгелмени?

Ләкин соңгы вакытта алар бик сирәк очраша торган булып киттеләр. Сәгыйть кичләрен бик соң кайта башлады, Гасыйм кайчакларда аның кайтканын зарыгып, түземсезлек белән көтеп ятты. Андый вакытларда аның Сәгыйть белән сөйләшәсе, аңа эч серләрен ачасы килә торган иде. Әмма Сәгыйть хәзер элекке Сәгыйть түгел иде инде. Ике арада сүз чыккан чакларда ул Гасыймны хәзер бөтенләй аңламады, йә аңламаганга салышты, яисә «мин моны күптән беләм инде, моның бернинди яңалыгы юк» дигән кыяфәт белән кулларын гына селтәде.

Гасыйм аның һаман салкынаюын, үзеннән читләшүен һәм торган саен үз эченә бикләнүен күрде. Ул гына да түгел, ул үзен бик эре тота башлады, масая, борынын күтәрә башлады. Ул хәзер иптәшләре коллективына караганда Ида коллективын артыграк күрде. Алар хәтта

икәүләшеп лекцияләрне дә ташлап китләли башладылар. Кыскасы, егетнең тәмам күзе тонды, зиһене томаланды. Ул бөтенләе белән гыйшык күленә чумды һәм үз тирәсендәге бер генә нәрсәгә дә диярлек игътибар итми башлады. Билгеле, бу аның укуына да йогынты ясамый калмады. Семинарларда булсын, группа җыелышларында булсын — үзен ул бик сәер тота башлады. Элек һәрбер нәрсә белән кызыксына торган, дәртләнеп, ялкынланып сөйли белә торган, үз фикерләрен яклый белә торган егет тынып, йомылып калды, иптәшләренең сүзенә, бәхәсенә катнашмыйча, олуг галим кыяфәте белән күбрәк вакыт читтә эндәшмичә генә утыра торган булып китте, һәм һәркем хәзер аның бик гади, бик аңлаешлы мәсьәләләрдә дә буталганын, тотлыгып калганын күрде. Дөрес, имтиханнарга, зачетларга ул элеккечә тырышып әзерләнде, сессия вакытларында баш калкытмый китап өстендә утырды, элеккечә һаман яхшы укучылар рәтеннән исәпләнде һәм факультет отличникларының фоторәсемнәре куелган кызыл тактадан узган-барганга һаман элеккечә елмаеп калды. Ләкин, ни генә булмасын, анда күзгә күренеп үзгәреш бара иде, һәм бу үзгәреш бер дә аның алга китүен күрсәтми иде.

Моны бүтәннәргә караганда да яхшырак күргән Гасыйм үзенең иптәше өчен чын-чынлап борчылды. Сәгыйтьне «дөрес» юлга төшерү нияте белән бервакыт ул аңа:

— Беләсеңме нәрсә, ташла син шул... шул ана үрдәгеңне! Юкка үз-үзеңне генә бетерәсең...— диде.

Ләкин ул үз-үзен никадәр хаклы санамасын, иптәшенә яхшылык эшләү теләге белән никадәр рухланмасын, аңа шундук каты стенага барып төртелергә, артык бер сүз дә әйтә алмыйча, телен тешләп туктап калырга, җитмәсә, соңыннан ярыйсы гына үкенергә дә туры килде.

Сәгыйть ап-ак булды, аның каршысына килде дә, гадәттәге тынычлыгын бозмыйча, әмма аңа бер генә каршы сүз дә әйтер урын калдырмый торган тавыш белән, зәһәрле ачу белән, нык кына, салкын гына:

— Сездән акыл сораганым юк, иптәш комсорг... кирәкмәгәнгә кысылмасагыз яхшырак булыр!— диде.

Шуннан соң ул, теше сызлаган кеше кебек, берничә көн чыраен сытып йөрде. Шулай да Сәгыйть башсыз егет түгел, Гасыйм аның белән яңадан сүз башлагач, ул, берни булмаган шикелле, эндәшергә, сөйләшергә тотынды. Ике арадагы киеренкелек, тел яшерү бетте, ләкин күңелсез салкынлык, хәтта яшерен, әчке дошманлык, моңарчы беркайчан булмаган дошманлык барыбер шул көе то-

рып калды, язга, җәйгә кадәр сузылды. Юк, Гасыйм аңа ачу да, үпкә дә сакламады. Колхозда буа буган чакта гына алар яңадан, чын-чынлап якынаеп киттеләр.

Сәгыйть белән ачыктан-ачык сөйләшү яшь комсоргка яхшы сабак булды. Моннан соң ул: дөреслекне теләсә кем белән, теләсә нинди мәсьәлә буенча, теләсә кайчан йөзгә бәреп, күзгә туры карап әйтергә мөмкин түгеллеген, бәлки, аны урынына, вакытына, мәсьәләсенә һәм кешесенә карап — һәркемгә ишетелерлек итеп кычкырып та, шулай ук пышылдап та, сакланып та әйтергә кирәклеген аңлады. Барыннан да бигрәк, кешенең йөрәгенә, күңеленә төшенергә, аның эчке кылларын дөрес чиртә белергә кирәклеген, үзең кебек үк иптәшең белән эш иткәндә ихтирам, әдәп дигән нәрсәләрне аеруча нык истә тотарга кирәклеген борынына киртеп куйды.

Автомашинага утырып пристаньга барган чакта, юл буенда туктап торган Ида белән Бәхтине күргәч, башта ул үз күзенә үзе ышанмады, аптырады да, гаҗәпләнде дә. Башка да китерергә мөмкин булмаган очрашу иде бу. Ул моны нәрсәгә юрарга да белмәде. «Ида әллә Бәхтинең берәр туганы, берәр кардәше микән соң?» — диде ул үз-үзенә, малайларча беркатлылык белән. Ләкин кинәт кашы җыерылып китте, күңеле шундук нәрсәдер сизенеп алды, йөрәге Сәгыйть өчен, үзенең якын дусы өчен әрнеп куйды.

Ләкин моның булуы мөмкинме соң? Бит алар бер-берсен шундый яратышалар! Аның ялгышуы да бар, бәлки, алар бөтенләй Ида белән Бәхти булмаганнардыр, бәлки, алар бөтенләй чит, ят кешеләр булганнардыр?

Ул икеләнде, шикләнде, үз-үзенә ышанмаска тырышты. Әмма ул Иданы да, Бәхтине дә бик яхшы күреп калды. Юк, ул ялгышмады. Әлбәттә, ул — Ида иде. Соң, кул сузып алырлык ераклыкта гына торып калды ич! Аның беренче курста кигән алсу чалбарын, киң читле ак эшләпәсен бер чакрымнан танырга була ич!

Шулай да аңа бик озак икеләнергә туры килмәде. Ул, элеваторга ашлык ташучы машинада грузчик булып эшләгәнгә, һәр көнне икешәр мәртәбә Идалар авылы аша узып китә иде, һәм ул Бәхти белән Иданың икесен бергә тагын бер мәртәбә күрде. Вакыт кичкә таба иде, алар бер урам почмагында, ниндидер киоск каршында көлешә-көлешә сөйләшеп торалар иде. Иданың кулында бәләкәй генә сумка бар иде. Һәм аларның кыланышлары да, оятсызлык нуры белән балкыган йөзләре бер дә аларның бер-берсенә кардәш яисә туган булулары турында сөйләми иде.

Ул Бәхтине Иданы белгән кебек үк белә иде. Бәхти белән ул кайчандыр бер мәктәптә, бер класста укыды. Ул чакта Бәхти мактанчык, бәйләнчек, ләкин бик куркак бер малай иде. Атасы районддагы ниндидер бер база директоры булып эшләгәнгә, аның кесәсендә беркайчан акчадыр, конфет-прәннектер өзелеп тормый торган иде. Ул гел яхшыдан, яңадан гына киенеп йөри торган иде, ләкин аның түшенә һәрвакыт йә аш, йә сөт тамган була, чалбар балагы ләпеккә, ак күлмәге карага буялган була торган иде. Малайлар аны әләкчелеге өчен, селәгәйлеге, мактанчыклыгы өчен яратмый торганнар иде һәм еш кына берәр аулак урында туры китереп, йә туп-туры урам уртасында тәпәләп тә китә торганнар иде. Андый чакта ул бөтен урамны сасытып елый-елый, тизрәк анасы янына йөгерә торган иде, бераздан ямьсез тавыш белән чыелдап, кулына чыбык тотып, анасы килеп чыга, аның артыннан әбиләре, апалары ияртә, этләре өрергә тотына торган иде. Китә торган иде тавыш, кычкырыш — бөтен урам ду селкенеп тора торган иде. Ул вакытта усал малайларның урамда инде эзләре дә калмый торган иде — кайсы кая качышып бетә торганнар иде. Соңыннан Бәхтинең анасы, тиргәшә-тиргәшә, кемгәдер яный-яный, шулай да үз улын да кыйный-кыйный, кире өенә кереп китә торган иде. Икенче көнне ул Бәхтине ияртеп мәктәпкә килеп җитә, директорга керә, укытучылар бүлмәсенә керә, тиргәшә, яный, кычкырыша торган иде. Малайлар исә Бәхтине тагын да ныграк яратмый башлыйлар, күзен дә ачырмыйча үртәргә, үчекләргә тотына торганнар иде.

Идәннән, урамнан төпчек җыеп тәмәке тартырга, тел белән теш арасыннан чыртлатып, бик еракка төкерергә, оятсыз сүзләр белән сүгенергә ул бик иртә өйрәнде. Качып-посып төпчек тартуның ләззәте беткәч, олылар алдында да оялмыйча, беркемнән дә курыкмыйча, хуш исле папирос төтәсли башлады. Бераздан аулак өйләргә йөрүгә бирелеп китте. Монысы инде яшереп тәмәке тартуга караганда да күңеллерәк иде.

Ул укуга бөтенләй күңел салмады, үгет-нәсихәтне дә, киңәшне, куркытуларны да уйлап та бирмәде. Аңа тел белән дә, кул белән дә кермәде. Аны мәктәптә иң тәртипсез, иң хулиган, булдыксыз укучы дип, укудан чыгаруга кадәр барып җиттеләр. Ләкин майга-җайга аптырап тормый торган, район башлыклары каршында үзенә күрә исеме-даны булган ата кеше эшне ничектер рәтләде, һәм, Бәхти тартып-сузып кына булса да, ничек кирәк алай җиденчене бетереп чыкты.

Сугыш елы иде. Атасын әллә ришвәт өчен, әллә өстенә

чыккан өчен биш елга утыртып куйдылар. Бәхтиләр семьясының хәле бик мөшкелләнә башлады. Үз кул көче белән акча табуны моңарчы ни дип тә белмәгән һәм инде ярыйсы гына буйга җитеп килгән Бәхти, тамак туйдыру өчен кемнәргәдер ияреп, алыш-бирешкә бирелеп китте. Авылдан майдыр-күкәйдер, ондыр-фәләндер сатып алды да, пароходка утырып ерак җирләргә китте, бер-ике атнадан тагын әйләнеп кайтты, базарда берничә көн генә күренеп торды да тагын югалды. Кайчан гына булмасын, аның тирәсендә ниндидер спекулянтлар — хатыннар, кызлар чуалды.

Атасы төрмәдән кайтып, яңадан элекке эшенә урнашкач һәм инде дөньялар да рәтләнеп, алыш-бирешнең файдасы бөтенләй диярлек калмый башлагач, Бәхти җиңел кәсепкә кул селтәде дә, кәсепсез генә, әмма барыбер җиңел, барыбер рәхәт тормышка күчте. Бер ел чамасы беркайда да эшләмичә, атасы җилкәсен кимереп яткач, тагын каядыр китеп югалды. Бу вакытта Гасыйм университетның беренче курсы студенты иде инде. Ул Бәхти белән бөтенләй кызыксынмады. Ләкин бервакытны, җәйге каникулга кайткач, ул аны клубта очратып:

— Кайларда йөрисең, укыйсыңмы, эшлисеңме?— дип сораган иде.

Бәхти, эре генә:

— Уралда инженерный техникумда — студент!— дип җавап биргән иде.

Аның җавабы башта бик көлке, бик мәгънәсез тоелса да, Гасыйм соңыннан аның чыннан да Свердловскида ниндидер бер техникумда укуы турында белде. Алар бөтен семьялары белән күрше районга — Идалар районына күченеп киткәч, Гасыйм аның дөньяда барлыгы-юклыгы турында да оныткан иде инде.

Ул көнне Гасыйм үзләренә төнлә генә кайтып төште. Ул юл буена уйланып кайтты. Идага карата булган нәфрәтеннән ул нишләргә дә белмәде. Аның иртәгә элеваторга барганда машинадан төшеп калып, аны эзләп табасы, аны бик яхшылап сүгәсе яисә аңа шундук, кайткач та, бик каты итеп, үтергеч итеп хат язасы килде.

Ләкин иртәгәгә кадәр бик озак көтәсе бар иде. Ул сүрелә төште. Чыннан да, алай тиленәнеп йөрергә аның ни хакы бар соң? Аннан соң аңа хат язып нинди генә эш кырырга мөмкин булыр икән? Һәм нинди максат белән язарга? Читләр белән чуалып, Сәгыйтькә хыянәт итмә, шундый әйбәт мәхәббәтегезгә тап төшермә, дип үгетләргәме соң аны? Үгетләп торырга кирәк микән? Юк, Идага

түгел, киресенчә, Сәгыйтькә язарга кирәк! Белсен бөтенесен дә, йөрмәсен алданып!

Гасыйм, өйдәгеләрнең барысы да йокларга яткач, сеңелесенең дәфтәреннән бер бит кәгазь ертып алды да өстәл янына килеп утырды. Хат башына «Сәгыйть!» дип кенә язып куйган иде, шундук туктап калды. Тагын икеләнә башлады. Ида мәсьәләсендә Сәгыйть белән булган теге сөйләшү исенә килеп төште. «Нишләп гел аның эшенә тыгылам соң әле мин?»— диде ул, үртәлеп, һәм каләмен ачу белән өстәлгә атып бәрде.

Чынлап та, ни дип кычытына соң әле ул? Ни эше бар аның аларда?

Ул, ныклы бер карарга килә алмыйча, озак кына уйланып утырды. Аннан соң каләмен яңадан кулына алды да, нишләгәнен үзе дә рәтләп аңламыйча, «Сәгыйть!» сүзен сызып ташлады һәм аның янына тагын «Сәгыйть!» дип язып куйды. Юк, моны болай гына калдырып булмый иде, Сәгыйтькә барыбер язарга кирәк иде, һәм тырналган, ярсыган күңелне бары тик аңа хат язып кына басарга була иде.

Һәм ул язды. Бер сәгатьтән артык утырып язды.

## VI

Кич чыгуларга, танцы, киноларга хәзер мотоциклда йөрүләр кушылды, һәм хәзер Идага нишләргә, кая барып сугылырга белмичә, бөтен көнне күңелсезләнеп үткәрергә туры килмәде. Дөрес, мотоциклда йөргәндә битен җил кисте, кайчакта кояш кыздырды, ләкин шулай да түзде. Ул үзен бәхетле сизде. Бәхти белән ике арадагы мөнәсәбәт тирәнәйгәннән-тирәнәйде, якынайганнан-якынайды. Ул үзенең Бәхтигә чын-чынлап гашыйк булганлыгын, моңарчы беркайчан да булмаганча, бик нык, бик «серьезно» гашыйк булганлыгын аңлады. Монда хәзер нинди дә булса шикнең булуы да мөмкин түгел иде.

Бәхти һаман элеккечә мәзәкләр сөйләде, үз-үзен аның белән бик иркен тотты, ләкин хәзер еш кына сүзсезләнеп, җитдиләнеп калды. Ида аның күзенә караган чакларда, тәҗрибәсез егетләр кебек күзен читкә борды, хәтта кайчакларда ни өчендер уңайсызланган шикелле күренде. Әлбәттә, ул да аңа гашыйк иде, «серьезно» гашыйк иде! Монда да хәзер бернинди шик-фәлән булырга мөмкин түгел иде. Ләкин егет һаман көттерде.

Йөрәгендә яңа дәрт, яңа ялкын кабынгач та, Ида искесен исенә дә кертеп карамады. Әлегә кадәр — Бәхти

белән, ят егет белән танышлыкның беренче көннәрендә — аның күңелен кайчакларда вөҗдан газабы дигән нәрсә тынычсызлый иде. Теге көнне, пристаньнан кайтканда, автомашинага утырып баручы Гасыймны күргәч, ул хәтта бер-ике көн борчылып, күңелсезләнеп тә йөрде. Тик бу да озакка бармады. «Бәлки, бөтенләй ул да булмагандыр әле!— диде ул үз-үзенә.— Булса соң! Аның миндә ни эше бар!»

Соңгы бер-ике атна эчендә Сәгыйтьтән бернинди хат-хәбәр килмәде. Бу исә аны шатландырды гына, дөресрәге, ул моның өчен кайгырмады. Аннан хат килмәү аңа тәмам тынычланырга, элек шулай да күңеленең бер почмагында эләгеп торган мораль җаваплылыктан тәмам арынырга гына ярдәм итте. «Үпкәләгән, ачуланган! Мин җавап язмаганга язмый — ах, нинди шәп!»— диде ул үз-үзенә. Әйе, үпкәләгән, ачуланган икән — бик шәп! Ичмасам, хәзер борчучы, элеккеләрне искә төшерүче булмас. Аннан соң хәзер бер-береңнән ерак чакта аерылышу да авыр булмас. Инде көз көне очрашкач — очрашырга туры килер микән әле!— көз көне бер-береңә йөз җыерып йөрүләргә, газап, кайгыларга да урын калмас. Хәер, ул инде аның белән үпкәләшеп тә, ачуланышып та йөрмәячәк, шулай ук аңа газапланып йөрергә дә туры килмәячәк. Инде Сәгыйть аны шулай да оныта алмаса, аның икенче кешене сөйгәнен белеп кайгыга сабышса, анда аның ни эше бар?! Әйе шул, үзенә гашыйк булган теләсә нинди егеттә аның ни эше бар! Аңа бары тик кызык кына булачак, күңелле генә булачак. Бәлки, көз көне бөтенләй Казанга да барырга туры килмәс әле. Бәлки... аңа икенче кеше белән икенче җиргә үк китәргә туры килер әле... бөтенләйгә...

Әйе, ул хәзер икенче кешене сөя. Кем моңа каршы килә алыр? Беркем дә! Тормышның бөтен яме, бөтен кызыгы шунда — сөелүдә, бәхетле булуда түгелмени? Әгәр ул тагын да бәхетлерәк булырга, тагын да ныграк сөелергә омтыла икән, әгәр ул тагын да югарырак очарга омтыла икән — кем монда аны гаепли ала? Һичкем дә! Мәхәббәт мәсьәләсендә — бигрәк тә. Мәхәббәт ул шундый нәрсә — аңа бер генә кагыйдә дә, бер генә әхлак, мораль, фәлән-төгән кануннары да ныклы каршылык була алмый. Мәхәббәт — ирекле кош кебек. Ул кош кемгә куна — аңа шул хуҗа. Билгеле, аны кулдан ычкындырмаска, дөресрәге, ул үзе китмәскә тиеш. Әгәр инде аның белән Сәгыйть арасындагы мөнәсәбәт шундый гомерсез булып чыккан икән — нишлисең! Күрәсең, ул мөнәсәбәтнең нигезе дә шуның ише генә булгандыр. Чынлап

та, яратты микән соң ул аны? Хәзер Бәхтине яраткан шикелле чын якрату белән яратты микән? Алар арасында мәхәббәт дигән нәрсәнең үзе үк булды микән әле? Юк, берни булмаган. Булса да, онытылган, югалган, беткән — әнә бара юлы!

Ләкин көтмәгәндә Сәгыйтьтән хат килеп төште.

*«Сагындым, өзелеп, үләрдәй булып сагындым сине,—* дип язган иде Сәгыйть.— *«Кырык гырадыска җитте сагну дәрәҗәләрем»,— дип җырлыйлар бездә. Минем сагыну дәрәҗәм кырык градуска гына түгел — йөз градуска, мең, ун мең градуска җитте! Йөрәгемә градусник куеп караган идем, шартлады, кызуына түзә алмады. Сине шулкадәр яратамдыр дип, моңарчы башыма да китереп карамаган идем. Син минем янда булганда гына бәхетнең кадерен белмәгәнмен икән. Мин һаман синнән берниндли җавап алмыйм. Син миңа язмыйсың. Мин төрлечә уйлап карыйм, газапланам, кайгыдан үләр хәлгә җитәм, шашынам. Минем сиңа бик зур ачуым бар. Шуңа күрә мин дә сиңа бик озак берни язмадым, язмаска үз-үземне мәҗбүр иттем. Күптән инде мин синең белән сөйләшмәдем, сиңа эч серләремне ачмадым. Гаеп миндә. Хәзер мин моны аңладым. Мин — кансыз. Бәлки, синең хәлең бик начардыр, бәлки, сиңа ул-бу булгандыр, син миннән дүрт күз белән хат көтеп ятасыңдыр, үзең яза алмыйсыңдыр. Нинди шәфкатьсез мин! Гафу ит мине, пумала башым, сандугачым-былбылым.*

*Менә мин сиңа хат язарга утырдым. Минем күңел хәзер хис белән, сиңа карата ярату, сөю хисе белән тулган, ташып-артылып тора. Үзем нәрсәдән башлап китәргә аптырап утырам. Мөмкин булса, җырда әйтелгәнчә, шушы хат эченә үзем генә утырып барыр идем синең янга, йә булмаса, йөрәгемне конвертка гына салып җибәрер идем.*

*Беләсеңме, Идеалым, кайчакларда мин синең турында шундый сагышланып, шундый моңсуланып уйларга тотынам — сине шул көе күз алдыма китерә башлыйм, сине үз янымда итеп, җанлы итеп, чын кеше итеп күрә башлыйм. Тирә-якка әйләнеп карадым исә, шундук юк буласың. Шул чакларда миңа ифрат та моңсу, ифрат та күңелсез булып китә.*

*Менә без кулга-кул тотынышып безнең басулар уртасыннан, тузанлы юлдан барабыз. Без икәү генә, безнең янда беркем дә юк. Баш өстендә җәйге кояш кыздыра, эссе. Мин сиңа үзебезнең авыл буйларын, чокыр-чакырларны, басуларны, урманнарны күрсәтәм, синең алда мактанам, горурланам. Синең белән без ерактагы зәңгәр тауларга кадәр барып җитәбез. Мин синең билдән ко-*

*чып алам,— теге, паркларда йөргән чаклардагы кебек,— без синең белән, иске яфракларны шыштырдатып, тын урман эченнән барабыз. Юкәнең чичкә атканын күргәнең бармы синең? Юкә урманында булганың бармы синең? Беләсеңме, дөньяда юкә чичкәсе исеннән дә тәмлерәк бернинди ис юк. Искиткеч ис! Бездә — гел юкә урманы. Ах, кайчан күрсәтермен икән мин сиңа аларны, кайчан син дә безнең юкә урманнарының исен татып карарсың икән! Кайчан безнең юкә балларын ашап карарсың икән! Кайчакта мин синең белән арыш басуларына чыгып китәм. Җилдә чайкалып, кояш нурына коенып, менә-менә саргаям, өлгерәм-җитешәм дип утырган аксыл-яшькелт арыш буеннан бару шундый күңелле, арыш башакларының үзара сөйләшүен, арыш камылларының бер-берсенә тиеп чыңлавын тыңлавы шундый күңелле! Син кайчакта минем белән бергә печән чабасың, синең битләреңнән тир ага, син елмаясың...*

*Мин бераз хыялга бирелеп киттем. Ләкин нишләргә? Үзең шулкадәр яраткан кешегә карата хиссез, тойгысыз булып булмыйдыр, ягъни бераз романтик булмыйча булмыйдыр.*

*Җитте. Артык озын булды бугай. Син инде ялыгып беткәнсеңдер. Ник язмыйсың? Нәрсә булды сиңа, пумала башым? Нигә газаплыйсың мине? Яз. Үләрдәй булып көтәм. Бетте, әнә таң сызылып килә, күзләр йомыла, ә миңа ике-өч сәгатьтән тагын торырга, эшкә китәргә кирәк. Печән бетә инде. Аннан соң — урак. Игеннәр яхшы күренә. Үбәм, кочам.*

*Үлгәнче синеке — Сәгыйть».*

Ида хатны койкада яткан көе генә укып чыкты да, бөкләп, яңадан конверт эченә салып куйды. Өстәлгә ташланган хат шапылдап графинга барып тиде һәм, шулай ук шапылдап, идәнгә барып төште.

Элегрәк күңелдә шатлык хисе уятырдай, серле, көчле мәгънәгә ия булырдай хат аңа хәзер эч пошыргыч булып тоелды. Сәгыйтьнең сүзләре дә, ул үзе дә аңа хәзер бөтенләй аңлашылмады.

Бүлмәгә шыпырт кына атлап, кулына чыра тоткан Рәхимә апа килеп керде. Ида аны күрмәде. Бүген Мәгъфия апасы нишләптер сырхап киткән иде, шуңа күрә ул ашыгып, Ида торуга ашарга әзерләмәкче булып йөри иде.

— Базарга чыкканчы самавыр шаулатып җибәрим дигәнием,— диде ул, Иданың колак төбендә генә пышылдап.

Ида, аның тавышын ишетеп, шундук күтәрелеп ка-

рады. Шушы бәләкәй генә хатынның бер дә юкка гел елмаюы, гел пышылдап сөйләшүе, песи кебек гел әкрен генә басып йөрүе аның ачуын китерде. Хәер, бөтенесенә дә әнисе өйрәтеп бетергән...

Идрис, көндез ашарга кайткач, аштан соң үз бүлмәсенә кереп, бер сәгать, ярты сәгать йоклап алырга гадәтләнгән иде. Ул йоклаганда, аны уятмас өчен, өйдә һәркем аяк очына гына басып йөри, пышылдап кына сөйләшә, сакланып кына тын ала иде. Мәгъфия исә бу тәртипне бик тырышып саклый иде. Бу йорттагы гадәт мескен хатынның канына шулкадәр нык сеңгән иде, ул хәзер, гомумән, теләсә кайда теләсә кем белән, хәтта үз ире, үз балалары белән дә пышылдап сөйләшүгә күчеп бара иде.

— Пышылдамале шулай, Рәхимә апа,— диде Ида, үртәлеп. Аннан соң, ачуланырга бернинди сәбәп юклыгын шәйләп, йомшаграк тавыш белән өстәп куйды: — Әтием өйдә юк ич, кычкырып сөйләшсәгез сезне кем тыя...

Рәхимә апа тагын да ныграк гаепле йөз белән елмайды да тавышын бераз күтәрә төшеп:

— Берәр ташландык кәгазең юкмы дигәнием, Һидая?— диде.— Чырам юешрәк, корысы калмаган... Ут төртеп җибәрергә...

— Әнә ал шуны,— диде Ида, өстәл аягы астында аунап яткан хатка төртеп күрсәтеп.— Ут төрткәнче үк дөрләп китәр, ялкыны кулга бәреп тора.

«Һидая»ның ни сөйләгәнен аңламаган хатын, хатны йомарлап алды да кухняга чыгып китте.

## VII

Хат, элек яраткан кешесенә карата бернинди хис уятмаса да, күңелендә ниндидер юшкын калдырды. Ида, тирән уйга чумган кебек, күзләрен бер ноктага текәп, һаман урынында ята бирде. Ләкин ул уйланмады, башына бер генә фикер дә килмәде, һәм аның уйланасы да килмәде. Ул беркемгә дә ачуланмады, беркемне дә шелтәләмәде, бернигә үкенмәде, кызыкмады. Ул хәзер ниндидер билгесез, кыен бер хәлдә иде.

Рәхимә апа базарга барып кайтты, үзе юк чакта сүнеп утырган самоварны тагын шаулатып җибәрде дә, өстәлгә чәй әзерли башлады. Башын ак яулык белән бәйләгән Мәгъфия тагын бер мәртәбә кызы янына чыгып әйләнде.

— Тор инде, кызым, чәй җитеште,— диде ул бозылган, кызганыч тавыш белән.— Рәхимә апаң җиләк алып кайткан.

Иданың күңеленә шундук: «Җиләк булгач, торырга кирәк»,— дигән уй килде. Ах, җиләк! Тукта, бүген җиләккә барырга кирәк, болынга... Бәхти килсен дә... Вот идея! Менә шәп булачак!

Ләкин ул, ашык-пошык юынып, ашарга гына утырган иде, өч почмаклы ак батист яулыгын ияк астыннан үткәреп бәйләгән яшьрәк кенә бер кыз килеп керде.

— Исәнмесез,— диде кыз, Ида чәй эчеп утырган кухня ягына таба атлап.

Ида җиләк ашавыннан туктамыйча, теләр-теләмәс кенә башын күтәрде һәм керүче кызга игътибарсыз гына бер күз ташлап алды. Кыз аңа таныш түгел иде — күрәсең, әнисенә йә Рәхимә апага килгәндер инде. Әмма кызны каршылап беркем дә урыныннан-кузгалмады, беркем дә аңа урындык тәкъдим итмәде.

— Мин Идая апа янына килгәнием,— диде кыз, беразсүзсез торганнан соң.— Мин райком комсомолдан.

Рәхимә апа, кинәт исенә килгән кебек, шундук икенче якка чыгып китте.

— Утыр, утыр, әйдә, басып торырга-ни алай...— диде ул, кыз алдына урындык китереп куеп.

Кыз урындыкка иплән кенә, җайлап кына утырды да, беравык студент кызның ак, нәфис бармакларына, аның матур чәчләренә, алсу йөзенә карап торгач, туптуры сүзгә башлады:

— Студентлардан агитбригада оештырабыз, урак вакыты бит, үзегез беләсез... Шунда сезне дә...

— Агитбригада?— диде Ида, ашавыннан туктап.— Шунда мин дә катнашырга тиешме?

Бик үк ягымлы тонда әйтелмәгән бу сорауга кыз ничектер каушап калгандай булды.

— Әйе... райком сезне дә исемлеккә кертте. Сезне бик яхшы сөйли дигәннәрие, шигырь сөйли дигәннәрие... биисез дә бугай... Үзегез беләсез, агитбригада булгач, кансиртлар куярга туры киләчәк. Җырчы бар. Беләсездер — Кәримә апа. Казанда, мидицинскида укый. Аннан соң Зыя дигән җегет — анысы Мәскәүдән. Ул биюче. Кеше күп булса, писса да әзерләрбез дибез, ничек булыр тагын... Аларда булдым — ризалар. Тагын менә өч-дүрт кешегә керәсе калды да, аннан соң — сез... Бүген төштән соң сәгать өчләрдә, дүртләрдә җыелабыз...

— Ничек соң... авылларда йөрергәме?

— Соң, ансы шулай инде — үзегез беләсез — урак вакыты бит... Былтыр шулай без чыкканыек. Быел студентлардан оештырырга булдык. Яшьләр... үзебезнең яшьләр дә чыгачак. Бер якта бер бригада, икенче якта —

икенче бригада... Аптырамагыз сез, Идая апа, бик кызык ул авылда, артистлар дип, күтәреп кенә йөртмиләр. Җәяү-ни йөрергә туры килмәс — ат бирәләр, сарык суялар... Киләсез инде алайса?

Иданың йөзе торган саен бозыла барды. Нәрсә соң бүген аңа тынычлап ашарга да ирек бирмиләр?..

— Туктагыз әле,— диде ул, утырган урыныннан кузгалып.— Мин бит... онытып бетергәнмен... шигырь сөйләүне...

— И-и!— диде кыз, аның артык нык каршы тормавына сөенгән кебек.— Онытылса, бик тиз искә төшә ул! Ни тора ул студент кешегә бер-ике шигырь сөйләү!

— Ничек соң... ничә көн йөрергә? Бер атна? Ике?

— Шул чама булыр инде,— диде кыз, һаман ныграк җанлана барып.— Агитбригада булгач, үзегез беләсез, килде-китте генә эшләп булмый. Яхшылап әзерләнеп чыгарга туры килер. Бүген кич райкомга җыелгач сөйләшербез ансын, ансы гына әллә ни түгел... Бәхетегез — җитәкчегә сезгә Асия апаны бирәләр. Беләсездер — мәктәптән, өченче елны институт бетереп килде. Җырлый да, бии дә — барып чыккан инде, шайтан белән бер! Оештырырга, тегесен-монысын рәтләргә — аны гына куш! Үзегезнең арадан да сайларга була... җитәкчене...

Ида мәктәптә укыганда чыннан да концертларга катнаша торган иде, сәхнәгә чыгып шигырьләр сөйли һәм, тавышы бик үк шәптән булмаса да, күмәк җырларга катнашып җырлый да торган иде. Бервакытны ул хәтта, мин артист булам, дип тә котырып алган иде. Ләкин бала чагында кеше ни белән генә мавыкмаган да ни генә эшләмәгән соң! Хәзер ул бала түгел лә!

Шулай да авылдашлар белән, бүтән вуз, бүтән шәһәр студентлары белән бергә булу, яңа танышлар, уен-көлке, атка утырып йөрүләр, авызын ачып, шаккатып утырган авыл халкын шигырь сөйләп (юк, үзеңнең матур буйсының белән) таңга калдыру — барысы да шундук аның күз алдына килде, күңелендә ниндидер яңа уйлар, яңа теләкләр уятты.

«Әллә барыргамы соң?— диде ул, беразга онытылып.— Зыя. Кем соң әле ул Зыя? Быел сабантуйда бөтенесен җиңеп чыкты, патефон алды, дип сөйләгәннәр иде. Шул Зыя ич инде. Спортсмен. Көрәшче. Красавец. Кап-кара чәчле. Тагын кемнәр бар икән соң? Рамазановтыр инде — баянчы... Шәп булыр иде. Зыя... Ләкин... ничек итеп үз өеңне, үзеңнең бүлмәңне, бөтен уңайлыкларны, өстәл тулы шушы әзер ашамлыкларны ташлап китәсең? Анда сиңа кем аш әзерләр, кайда, нинди урында кунарсың?

Өстең-башың пычранып, керләнеп бетәр, кеше йортында чәчеңне дә тарый алмассың, битеңне-кулыңны да юа алмассың. Әгәр берәр шапшак кешедә кунып, бет йә кандала эләктереп чыксаң? Ужас! Авылдан авылга йөрергә, кояшта әлсерәргә, тузанга тончыгырга... юк, аннан булмый бу. Бүтәннәр теләсә нишләсеннәр, для дураков закон не писан... ләкин ул... Юк, юк! Кемнәрнеңдер күңелен табып, бер тиенсезгә интегеп, эттәй азап чигеп йөрергә — бу инде бигрәк, слишком... бигрәк түбәнлек... Матур җәй узып та китәр, күрми дә калырсың... Юк... шулай да... Әллә соң?..»

Урам якта, тәрәзә турысында, кинәт өзек-өзек мотоцикл тавышы ишетелде. Иданың күңеленә шул чакны бер уй килде. Ул, җиңелчә кызарып:

— Теге... өч-дүрт кеше дигәнегез кемнәр алар?— диде.

Кыз, кулына бөкләп тоткан кәгазен ачып карады да, студентлар агитбригадасында катнашырга тиешле кешеләрнең фамилияләрен укып чыкты. Бәхтинең фамилиясе исемлектә юк иде. «Хәерче кебек кеше көлдереп кенә йөрисе калды! Ул да булмагач, юк, бармыйм»,— диде Ида үз-үзенә, күңелендәге икеләнүне җиңеп.

Матур итеп елмайды да, туп-туры кызның күзенә карап:

— Риза. Языгыз,— диде.— Сәгать өчкә алайса?

Түземсез мотоцикл тавышы тагын ишетелде.

## Бишенче бүлек

### I

Миңнисәттәй үз тормышыннан зарланмады.

Нигә, ашарына бар, эчәренә бар дигәндәй, хәзер инде бернинди мохтаҗлык күргәне юк. Балалары үсте, балигъ булдылар, үзләренә үзләре баш. Шулай булгач, тагын ни кирәк? Шулай булгач, бәхетем булмады, дип әйтергә аның ни хакы бар? Балалар рәхәтен күреп, җылы өеңдә тик ят...

Бит, дөнья булгач, төрле вакытлар булды, төрлесен күрергә туры килде. Аларны — хәзер менә бөтенләй икенче кеше булып җиткән, дөнья җимертеп эшләп йөргән, читкә китеп әллә нинди зур җирләрдә укыган шул балаларны аякка бастыру өчен аңа үз вакытында әз чиләнергә, әз азап чигәргә туры килмәде бит!

Әткәләре Сәетгәрәй барында алай кыен булмады булуын. Кит аннан, кая ул кыен булу! Тормыш көтү дигән нәрсә уен гына булган икән ул чакта...

Эшчән кеше иде, тырыш кеше иде, мәрхүм. Кайчакларда кызып китә торган гадәте бар иде, шулай да, мәрхүм, дөнья бәяләре кеше иде — ичмаса, бер генә мәртәбә дә телгә-тешкә килгән чаклары булмады. Колхоз оешкач та икәүләп колхозга керделәр, икәүләп эшләделәр, йорт тергезделәр. Балалар күп булса да, кием-салымына да, барысына да җитте. Мул яшәделәр, иркен яшәделәр. Тик Сәетгәрәй язгы ташуда аты-ние белән суга төшеп үлгәч кенә тормышның авырлыгы сизелә башлады. Нигдидер машина алырга киткән иде ыстансага, мәрхүм. Чанасында тимерләре күп булгандыр инде, боз күтәрмәгәндер...

Балалар әле ныклап эшкә ярамыйлар иде, бары Бибинур гына кул астына керештерә башлаган иде. Яшькә дә, төскә-биткә дә яшь иде әле, үзенә тиң ирләрне каратырлык кына сылулыгы да бар иде. Кодага җибәрүчеләр дә булмады түгел — булды. Әлбәттә, канатың пар булганда, тормыш мәшәкате дә җиңеләер иде. Ләкин үз балаларын кызганды, икенче ирнең алар өчен барыбер икенче ата, чит ата булачагын уйлап кызганды. Аның үз балаларын бүтәннәрдән кактырасы да, суктырасы да килмәде. Һәм ул, шул балаларына карап, шуларга шатланып, куанып, күңелендә гомеренә Сәетгәрәй истәлеген саклады.

Инде Сәетгәрәй өлешен дә эшләргә тиешлеген аңлап, көн дими, төн дими эшләде. Кышларын колхоз ферма-

сында сарык карады, бәрән, бозау карады, җәй җитсә, тагын көзгә кадәр, туң җир өстенә беренче кырпак төшкәнчегә кадәр кырда, басуда булды. Тырышты инде, тырышты.. Бибинурның да, балакайның, бәхете булды, әйбәт җиргә төште. Барисы тагын ел саен бодаен, арышын центнерлап-центнерлап кына алып кайта. Кеше булдылар. Берсе дә китереп биргәнне көтеп ята торганнардан түгел. Эш дигәндә үлеп китәргә торалар, эш дигәндә җаннарын фида кылырга торалар. Ата баласы атага охшый шул — Сәетгәрәй каны аларда. Килене дә беркайчан да кулын кушырып утырмый, кирәк өйдәгесен булсын, кирәк тыштагысын булсын — ялт итеп кенә куя, тегесен тегеләй итә, монысын болай итә. Бер сүз әйтеп булмый, тырыш бала, үзләре ише бала. Сәгыйтенә дә тел-теш тидереп булмый...

Әйе, тагын ни кирәк? Тынычланып, балаларыңның кадерен белеп, рәхәтен күреп, бәләкәч Тәлгатьне карап үз өеңдә тик ят... Барис та шулай ди бит... Шулай куша...

Ләкин соңгы вакытта, бигрәк тә урак вакыты җитә башлагач, Миңнисәттәй ниндидер уйчанлыкка бирелеп китте. Еш кына күңеле талпынды, нәрсәдер эзләнде. Өй эшләреннән, вак-төяк мәшәкатьләрдән арынган араларда «бәпчеген-төпчеген» кулына алды да тар өлгеле кысык тәрәзә каршысына килеп утырды, авыл читендәге саргылт арыш басуының әле бер төшен, әле икенче төшен күзәтте, үзе һаман Тәлгать белән сөйләнде, кайвакытта, күңеле бик тулган чакларда, өйдә үзләреннән башка беркем дә юклыгыннан файдаланып, моңаеп та алды. Шундук күз алдына үткәннәр килеп басты.

Сыерларын, сарыкларын көтүгә җибәргәч тә, уракларын кулбашларына салырлар иде дә, иртәнге салкын белән, үзара сөйләнә-сөйләнә, кызу-кызу атлап, басу ягына чыгып китәрләр иде. Бер капкадан берсе, икенче капкадан икенчесе килеп кушылыр иде, елга аръягына чыккач тагын арттан берәрсе куып җитәр иде. Беләкләрен сызганып ташларлар иде дә, учларына төкереп, уракларына тотынырлар иде. Чатнап, сынып торган камыллы тигез арышны уруы шундый күңелле, шундый җиңел булыр иде — бер эшкә тотындың исә, һич туктыйсы килми торган иде... Җаннарың рәхәтләнә торган иде инде, каннарың язылып китә торган иде, уч төпләрең кыза торган иде. Арыш арасында бертуктаусыз чикерткәләр сайрый, әллә нинди кошлар сайрый торган иде, үзенә бер тавыш чыгарып, әкрен генә, талгын гына башаклар чайкала, кояш кыздыра торган иде, кайчакларда яңгыры да сибәләп китәр иде...

Хәзер күбрәк комбайн белән uralar. Һи-и, урыйм дигән кешегә комбайннан калганы да җитәрлек. Чокыр-чакырларга, кыйтык-мыйтык төшләргә нинди комбайн кереп торсын анда! Комбайнга да җитәр, теләсә кемгә дә җитәр. Быел да шул Таш амбар чокыры янында урырлар инде. Тау кашы бит, иртә өлгерә. Чәен-фәләнен кайнатырга аның чишмәсе әйбәт, ял итәргә урыны яхшы. Кеше йоклаган араларда карагаттыр, шомырттыр җыярга була. Менә тиздән чикләвек җитешә — бала-чага өзә башлаган инде...

Исәпләсәң исең китәр! Шул ничәмә-ничә гектар җирне ялмап кына чыга торганнар иде бит... кул белән, бернинди машинасыз.. Шушы куллар белән, ярылып, катып беткән шушы куллар белән... Бер төннән икенче төнгә кадәр йөрерләр иде, рәтләп тамакларына да ашарга вакыт булмас иде — ул чакта бит синең өчен хәзерге кебек өчәр-дүртәр комбайн эшләми торган иде. Шулай да нинди кайгысыз, нинди хәсрәтсез булган икән ул вакытлар...

Гамбәр-ни, яшь кеше, бала карап ятмас инде. Үзенең чүп чүлмәген әнкәсенә ташлап калдырды да менә, иренең трактырына плугар булды да китте. Ниндидер тик-тормас җан инде үзе дә. Бу чүлмәк-ни бөтенләе белән, башы-аягы белән дүрәнкәсенә торып калды. Шушы сөтлекәй белән булашып уза бөтен гомерең, кайчан кич булганын да, кайчан таң атканын да сизми каласың, кендегең шушы юеш борынга бәйләнгәч. Нишлисең, үз балаң бит, үз каныңның каны бит... Бераз үсә генә төшсен әле, болай иркәләнеп беләктә генә утырмас, кулына талчыбык тоттырып, чирәмдә бәбкә көтәргә җибәрербез әле без аны. Туктале...

Быел тагын чикерткәләр сайрар, кояш кыздырыр, тагын хатыннар кыштырдатып урак урырлар, тагын басу өстендә иртәдән кичкә кадәр кызларның җыр тавышы ишетелеп торыр, төш вакытларында чишмә буенда тагын корымланып беткән кулаказаннарда кара карагат яфрагы салынган тәмле чәйләр ургылып кайнар. Ләкин аңа гына күрергә туры килмәс, ахры, боларның барысын да. Бөтен гомерең узар инде шушы чүп чүлмәге белән, шушы гөл чүлмәге белән...

Шундый чакларда аның күңелләре җирседе, күз кабаклары дымсу томан ярысы белән капланды, шушы тар өйне ташлап, иркенгә чыгып китәсе килде, рәшә белән бергә кушылып тирбәлгән, чайкалган арыш басулары ягына, күк читеннән калкып торган яшькелт-зәңгәр әрәмәләр ягына чыгып китәсе килде. Бит аның быел яздан башлап, хәтта былтыргы көздән башлап беркая

диярлек чыкканы юк... Утауга-фәләнгә, печән җыярга йөрү турында әйтеп тә торасы юк. Алай бик карт та түгел дә бит, бик чуттан төшеп калган кеше дә түгел дә бит, нишлисең, менә шушы ташбаканы, менә шушы чүкечне карыйм дип, бәйләнгән эт кебек гел өйдә купчеп, саргаеп ятырга туры килә. Әнә Бибихәбирәнең дүрт ягы кыйбла, аты юк аранда, кайгысы юк буранда. Ире белән икәүләшеп эш көне сугалар, менә кызы — Зәйтүнәсе кайтты, анысы бер көн калмый печән җыярга йөри, Тәгъзимәсе тагын... Бәхетле дә соң кешеләр!

— Менә шушы сыбызгы борын булмаса, шушы сыбызгы борын...— диде ул, кинәт Тәлгатен исенә төшереп.

Аннан соң, борчулы уйларыннан арыну өчен, аның белән сөйләшергә, аны уч төбенә утыртып сикертергә тотынды.

— Үчтекә! Үчтекә!.. Булмасын дигәч тә, синнән туйган җук, җөзеңне җыерма. Һоп-һоп! Үчтекә!.. Менә минем зур улым, менә минем чүлмәгем, һоп, һоп!..

Малай, югарырак сикергән саен, бәчтек кенә, йомшак кына куллары белән дүрәнкәсенең күлмәк җиңенә чыырдатып ябеште, шундый искиткеч рәхәткә түзә алмыйча, кычкырып-кычкырып көлде. Дүрәнкәсе аның саен сикертте, кайчандыр үзе кыз чакта белгән такмакларын такмаклады:

Сикерсен, сикерсен,
Сиксән ике яшәсен.
Җөгерсен, җөгерсен,
Җөз җегерме яшәсен!

Биесен үк, биесен үк,
Биек таугa менсен үк,
Бияләрен саусын ук,
Кымызларын эчсен үк!

Аннан соң «чүлмәген» күкрәгенә кысып алды да, аның аяк-куллары белән тыпырчынуын, кыбырсуын уйлап та бирмичә, йомшак җиренә иплэп кенә шапылдата-шапылдата, һаман такмаклавында булды, яратып, иркәләп кавыклы башларын үбәргә тотынды.

Үстеби, үстеби,
Бигрәк тәмле кыстыбый:
Сары май белән майлаган,
Туңмай белән катырган —
Шундый тәмле кыстыбый!

Бала белән юанып алгач, күңеле бераз тынычланып киткәндәй булды, тынгысыз уйлар югалып торды, әмма

шулай да йөрәгендә барыбер ниндидер төер утырып калды.

Тәрәзәгә карап тора торгач, урамда бер кеше күренде.

— Сәгыйть абзыкаең түгелме соң?— диде Миңнисәттәй, Тәлгатькә эндәшеп.— Карале, кара, синең күзең яхшырак күрер. Әйе, шул ич. Нишләп бик иртә?

Сәгыйть ишектән үк елмаеп кайтып керде. Бөтен бер бригаданың печәнен чабып бетерүдә үзенең дә әз булса да көче керүен аңлау аңа бик күңелле иде. Бүген ул үзүзеннән бик канәгать иде.

Ул аягындагы туфлиен баскыч төбенә салып ташлады да, өйдән сабын, тастымал алып чыгып, чишмәгә юынырга йөгерде.

Сәгыйть кайтып бераз гына торган иде, басу капкасы ягында, МТС юлында комбайннары-ниләре белән Барислар күренде... Миңнисәттәй, еракта бик үк яхшы күрмәсә дә, Барисның комбайнын шундук аерды. Барислар булмый, кем булсын? Күршеләргә бара торган трактор-комбайннар авыл аша йөрмиләр, авылны читләтеп, басу яктан туры юл белән генә китәләр. Рәшитнекенең артында салам җыя торган арбасы юк, ниндидер сәләмә чүпрәк кенә асылынып тора, аннан соң — тавышы да икенче. Белмәс сиңа Миңнисәттәң! Кирәк булса, кешесенә карап сатып та җибәрер әле ул!..

«ДТ-54» тракторы артына тагылган «Сталинец-6», әкрен генә чайкалып, басу капкасы төбенә — кайчандыр басу капкасы булган төшкә килеп җитте һәм шунда арыш буенда туктап калды. Трактор, авыл белән исәнләшеп: «Менә без дә килеп җиттек, исәнмесез!»— дигән шикелле, күккә кайнар кара төтен кисәкләре бөрки-бөрки, бөтен тирә-якны яңгыратып, бик каты пытырдап алды да тынды. Аннан соң, тракторныкына караганда нечкәрәк, икенче төрлерәк каты тавыш чыгарып, комбайн моторы эшләргә кереште. Ләкин әз генә тырт-пырт килде дә, көтмәгәндә ул да сүнеп китте. Берничә минуттан соң моторның, килеп төшкәч тә оятлы булуына ачуланган шикелле, кичке тын һаваны калтыратып, ярсулы дәрт белән тагын бик шәбәеп җырлаганы ишетелде.

Авылга тракторны, комбайнны килүен бәйрәм каршылаган кебек көтеп алучы бала-чага, арыш басуы ягыннан килгән бу таныш гөрелдәвекне ишетеп, шундук Барислар ягына йөгерде. Сәгыйть тә кулына бер кисәк күмәч кенә тотты да, күңелендә кисәк кенә уянган кызыксыну тойгысын баса алмыйча, ашана-ашана, комбайн карарга китте.

Әнкәсе аның артыннан:

— Киленгә әйт, эше күп булмаса, кайтсын, коймак әзерләгәнием,— дип кычкырып калды.

Барис белән Сәгыйть караңгы төшкәндә генә кайтып керделәр. Барисның өсте-башы гадәттәгегә караганда ныграк пычранган, Сәгыйтьнең кулыннан бензин исе килеп тора иде.

Барисның бүген кәеф бик шәп иде. Ул, киемнәрен алыштырып, чистарынып калгач та, кулына шундук Тәлгатьне алды, аны, ике кулыннан тотып, идән буенча атлатып йөртте, сөйде, яратты, әле муенына атландырды, әле түшәмгә чөйде. Гамбәр, коймак майлаган җиреннән туктап:

— Имгәтерсең, ипләбрәк, җогышсыз!— дип кычкырды.

Өстәлгә тиздән кайнар коймак килеп утырды. Табын янында бүген аеруча шатлык, аеруча куаныч хөкем сөрде. Сәгыйть эшен бетергән иде, Барислар исә яңа гына эшкә башлау алдында торалар иде. Әллә инде әнкәләренең коймагы бик тәмле булды, әллә бик ачыкканнар иде, бер дә кыстатып-нитеп тормадылар, һәркемнең ни дә булса сөйлисе килде. Күңеле күтәренке чакларда Барис бераз мактанырга ярата иде.

— Машина алай начар күренми, быел да сер сынатмас, ахры,— диде ул, үз сүзенең бәясен яхшы белгән кеше сыман, ашыкмыйча гына.— Бер-ике көннән тотынырга була, шулай бит, катын, ә?

— Алла бирсә, урырбыз диген... Алдан кычкырган кәккүкнең башы авырта...— дигән булды Миңнисәттәй.

Барис көлеп куйды.

— Алла бирсә дә урабыз, бирмәсә дә урабыз инде аны, әнкәй. Алладан сорап торасы юк — үз кулыбызда...

— Алладан сорасаң, камбаен белән бөтенләй урдырмас ул, әнкәй,— диде Гамбәр дә, сүзгә кушылып.

Барис белән Сәгыйть, күңелләләнеп, көлеп җибәрделәр, хәтта Миңнисәттәй үзе дә елмаеп куйды. Менә хәзер барысы да өйдә, барысының да күңеле күтәренке — сүз башласаң да була. Ул инде бу вакытны көне буе көтеп йөрде, Бариска да, Гамбәргә дә бик ышандыргыч берәр сүз әйтермен дә, каршы-ни килеп тормаслар, шундук риза булырлар, хәлемә керерләр — үз балаларым бит, дип уйлады. Килене, бәлки, күнәр дә инде, тик менә Барис кына нишләр — холкы атасыныкына охшаган...

Уңай вакыт килеп җиткәч, күңеленә нишләптер кирәкле сүз килмәде, һәм ул беравык нидән башлап җибәрергә кирәклеген уйланып утырды.

— Сезнең үзегез генә — әнкәгезне бер дә исегезгә дә

кертеп чыгармыйсыз...— диде ул, ниһаять, үпкәләгән сыман һәм, бөтенләй кирәкмәгән җирдән тотынуын шәйләп алып, таган ни әйтергә белмичә кинәт туктап калды.

Харап итте, бөтенләй икенче нәрсә әйтмәкче булган иде бит!

Барис, авызына китергән коймагын да капмыйча, гаҗәпләнеп әнкәсенә карады.

— Тора торгач, бер хикмәтле сүз әйттең син, әнкәй. Нәрсә булды сиңа?— диде ул.

Сәгыйть белән Гамбәр дә, аптырап, сүзсез калдылар.

— Нәрсә булсын... берни дә булмаган,— диде Миңнисәттәй, ни булса да булыр дигән кебек, кискен генә.— Җәй буе шулай бала гына карап ятырмын микәнни?

Табын янында кинәт уңайсыз тынлык урнашты. Гамбәр, ялгыш ишетмәдемме, дигән шикелле сагаеп калды, әнкәсенә борылып карарга да батырчылык итә алмыйча, каш астыннан гына аның өстәл читендәге хәрәкәтсез кулларына, агарынган, төссезләнгән йөзенә күз төшереп алды.

— Нәрсә... авырмы әллә бала каравы?— диде Барис.— Авырсынасыңмыни?..

— Менәтерә, каян килеп авыр булсын! Авызыңа ни килде шуны лыгырдап утырасың-ни! Ичмаса, бер донҗа күргән җук, ирек ачкан җук, кеше кебек кайчакта эшкә дә чыгасы килә. Бибихәбирә әнә...

— Нәрсә — Бибихәбирә?— диде Барис, шундук кырт кисеп, әнкәсенә сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмичә.— Печән чабарга җөрисең килмиме? Бар, сине генә көтеп торалар ди!

— Ниндәен печән ди ул?.. Әллә уракка чыгармынмы дигәнием... Яслене ни өчен ачканнар — бер-ике атнага берни дә булмасые әле. Катыннар, авал, бер дә зарланмыйлар, вакытында ашаталар, вакытында җоклаталар, тагын ни кирәк?..

Әллә Сәгыйть барында әнкәсе белән әйткәләшүдән тыелып, әллә болай гомумән әдәп саклап, Гамбәр, һаман авызын ачмыйча, тынсыз, хәрәкәтсез тик утырды.

Әнкәсенең сүзне кая борганы хәзер аңлашылды, һәм Барис яңадан коймакка тотынды да, үз сүзенең хаклыгына тамчы да шикләнмәгән төс белән, баштагы кырыс тонын бераз йомшарта төшеп, җайлабрак, ләкин шул ук вакытта нык кына итеп:

— Әнкәй!— диде.— Эшләр вакытыңда эшләгәнсең, хәзер — безнең чират, минем чират. Өстәлеңдә ни кирәк — шул бар, өстең бөтен — кыбырсымый гына тик ят... Тәлгатьне карап. Менә шул сиңа. Әгәр бала каравы

авыр дисең икән, яслегә бирербез, ләкин, уракка чыгам дип, икенче авызыңны да ачма — менә шул... Хәзер мин карыйм сине, мин туйдырам...

Миңнисәттәйнең кинәт күңеле тулып китте. Аның йортны бөтенләй ташлап китәсе дә килми иде, кая ул — нишләп йорт ташлап йөрсен, андый вакытлар үтте инде — бер-ике атна гына булса да арыш уракка йөрермен, дип кенә уйлаган иде. Ләкин, балаларың кулына калгач, шулай буладыр инде — нишлисең бит... Менә син, теләгән җиреңә дә чыга алма, теләгән эшеңне дә эшли алма икән! Үз-үзенә ул бик кызганыч тоелды, аның елыйсы килде.

— Аллага шөкер, кулымнан эш китмәгән, авызымнан аш китмәгән,— диде ул, башындагы артка шуышкан яулыгын төзәткәләп.— Кеше кулына калганым җук әле... Кешедән ким-хур җирем дә җук, Аллага шөкер, кул-аягым исән... Әллә бераз урак урыштырырмынмы дигәннең эше ие...

Барис һич тә әнкәсенең хәтерен калдырырга теләмәде. Ул үзен йортта хуҗа итеп тотты, мин ни әйтсәм, бүтәннәр шуның белән һичшиксез исәпләшергә, килешергә тиешләр, дип карады һәм, үзенең уйлавынча, бөтен семьяны каравы белән, бигрәк тә әнкәсен тәрбияләве белән күңеленнән мактанмый булдыра алмады. Әнкәсенең тик торганда бер дә юкка «зарлану»ын ул бөтенләй аңламады, ул: мин хаклы, мин аны авыр эш эшләтергә тиеш түгел, дип уйлады.

— Уракка чыгасы килә икән, чыксын... әнкәйне әйтәм,— диде Гамбәр, сак кына, иплəп кенә сүз башлап.— Эшлисе килә икән, тотып тормассың инде. Тәлгатьне-ни, иртән илтер, кич алып кайтыр. Авыр эш түгел.

Хатынының үзенә каршы төшүе Бариска бөтенләй ошамады. Ул, сөйләш инде бу ахмаклар белән, дигән шикелле, энесенә карап алды.

— Менә Сәгыйтькә дә рәтләп ял итәргә кирәк,— диде ул.— Кайтканнан бирле һаман интегеп җөри. Әнкәй дә өйдә тормагач, кем әзерләр аңа ашарга-эчәргә?

— Мин өйдә тормасам?— диде Сәгыйть, урак вакытында үзенең чыннан да нишләячәген әле яхшылап белмәсә дә.

— Әллә син дә әнкәй белән уракка чыкмакчы буласыңмы?— Барис, энесенә түбәнчелек күрсәтеп, көлеп куйган булды.— Чүлмәкчедән күрмәкче, дигәндәй, без камбаен алып кайткач та нишләделәр әле болар, катын, ә?

— Нишләп чүлмәкчедән күрмәкче булсын? Уракка йөрсә, Сәгыйтькә оятмыни?— диде Гамбәр.— Эчендә

җаны бар кеше нишләп ятсын бу вакытта! Чыкмый әллә, чыгарсың, әнкәй, яследә балалар үлә икән дигән сүз ишеткән җук әле.

Гамбәр беркайчан да диярлек Бариска каршы килми торган иде, алар бер-берсен бик тиз аңлый торганнар иде. Нәрсә булган әле аңа? Нигә гел аркылы төшеп утыра әле ул аңа? Әллә алдан сүз берләшеп куйганнармы болар? Әллә соң ул җитәрлек эшләмиме, җитәрлек ашлык алмыймы? Ир кешеме ул, семья башлыгымы, әллә берәр күзсез бүкәнме?

— Нәрсә җитми сезгә?— диде ул кинәт үртәлгән тавыш белән, гәүдәсен турайтып.— Ни җитми, ә? Калхузның гырамына калдыгызмы әллә? Тутырып бирерләр дип белдегезме?— Йодрыкларын кысты да, бәбәкләрен акайтып, хатынына ачулы караш ташлады.— Бик кычытынсаң, үзең дә беркая да чыкмассың! Икәүләп карарсыз баланы, икәүләп өйдә ятарсыз! Менә шул. Үзем эшлим, үзем туйдырам — сезне генә карарлыгым бар әле хәзергә... Җитәр!..

Гамбәр дә кинәт шырпы кебек кабынып китте.

— Җитми-ни, исәр, җитәр! Кара, ничек икән, әлләлә! Ул гына эшли дә, ул гына таба, ул гына туйдыра икән! Бигрәк масая башладың. Җәрингә, күр дә тор менә, үземә бер камбаен алып чыкмасаммы!— исемем Гамбәр булмасын... Син эшләгәнне генә эшли алырбыз, кайгырма!

Шундук Сәгыйтьнең күңеленә келт итеп өмә вакытында Инсаф белән Мәрдәншә агайның әйткәләшүе исенә төште. «Син дә Инсафтан ерак китмәгәнсең икән»,— дип уйлап алды ул абыйсы турында эченнән борчылып һәм бөтенләй көтмәгәндә купкан бу тавышның күңелсез төс ала баруын күреп, Барисның иңбашына тотынды.

— Туктале, тукта, кызма!

Шул чакны тышта, тәрәзә турысында, кемнеңдер койма тактасын шакылдатканы ишетелде. Барысы да кисәк кенә тынып калдылар.

## II

— Кем бар анда?— дип кычкырды Барис, бөтен гәүдәсе белән караңгы тәрәзәгә капланып.

Урам якта ашыгып-кабаланып нидер сөйләгән Низамый тавышы ишетелде. Сүзнең нәрсә турында барганын аңларлык түгел иде. Бераздан тавыш тынды, кинәт кыяфәте үзгәргән Барис өстәл тирәсендәгеләргә борылды да:

— Гамбәр, Сәгыйть!— диде ярым пышылдавык тавыш белән.— Әйдәгез тизрәк... туйдыгызмы? Идарә утыры-

шы булган, шуны әйтеп җөри, чалгылар әзерме?

Аннан артык сүзнең кирәге юк иде инде. Аны шундук аңлап алдылар, барысы да тиз генә урыннарыннан тордылар, ыгы-зыгы килергә, каядыр әзерләнергә тотындылар. Сәгыйть, җиңел бишмәтен элдереп, тышка чыгып йөгерде, Гамбәр мунча чарачасына куйган чалгыларны алырга китте, Барис тиз генә аягына киенә башлады, һәм бераздан идән уртасында Тәлгатьне күтәреп Миңнисәттәй генә торып калды. Сәгыйтьләр, өчесенә өч чалгы күтәргән көе, бакча капкасы аша чыгып, басу ягына йөгерделәр.

Колхоз идарәсе, гомуми хуҗалык өчен печән чабу беткәч, һәр елны диярлек колхозчыларга аерым бер көн бирә иде, һәм бу көнне аларга чабылмый калган чокыр-чакырлардан, әрәмә араларыннан, җир башларыннан үзләре өчен печән чабарга рөхсәт ителә иде. Ләкин бу нәрсә район җитәкчеләреннән яшерен рәвештә эшләнелә иде, чөнки былтырдан элекке елны күрше «Азат» колхозында шундый хәл беленгәч, районның кайбер кешеләре, өй борынча кереп, колхозчыларның үз сыерлары өчен чапкан печәннәрен җыйдырып йөргәннәр иде, председательнең үзен, печән әзерләү планын колхоз артыгы белән тутырса да, җәмәгать милкен әрәм-шәрәм итүдә, законга каршы килүдә гаепләп, судка биргәннәр иде. Дөрес, председательгә берни дә булмады булуын — районда ул алдынгылардан санала иде, аннан соң бу мәсьәләгә райком да катнашкан, председательне яклап чыккан, диделәр. Әмма председательнең котылуына карап кына «Азат» колхозчыларының сыерларына кыш көне барыбер печән эләкмәде. Шушы вакыйгадан соң бүтән җирләрдә дә, шул исәптән «Ялкын» колхозында да, саграк кылана башладылар. Шуңа күрә печән чабарга рөхсәт ителәсе көн турында гадәттә алдан ук, кичтән үк белдерелә иде, һәм сыеры, мал-туары булган һәрбер семья — икешәрләп-өчәрләп тә, хәтта дүртәрләп-бишәрләп тә, кулына чалгы тотып, кичтән үк чокыр-чакыр арасына, әрәмә буйларына сибелә иде. Эшнең күбрәк өлеше гадәттә төнлә башкарыла, иртәнгә инде чабылган печән генә торып кала, чокыр буйлары, куаклык эчләре, әрәмә култыклары — печәне чабып алырга яраклы бөтен җир алдан килеп өлгергән кешеләр тарафыннан бүлгәләнеп беткән була иде.

Караңгыга күзе ияләшмәгәнгә Сәгыйть кая басканын да белмәде. Аягына ниндидер түмгәкләр очрады, озын табаклы үләннәр уралды, ә ул, әкияттәге Камыр батыр кебек, биш атлыйсын бер атлап, үз алдындагы караңгы-

лыкка текәлгән көе, тәненең авырлыгын да тоймыйча, элдерде генә. Бөтен яктан шундый куе, шундый йомшак караңгылык чолгап алганга, биткә җылымса төнге һава бәрелгәнгә, менә шулай җиңеләеп, кызып, каядыр йөгерү әйтеп бетермәслек күңелле иде. Ул үз алдында беркем тарафыннан ачылмаган, серле, тып-тын караңгылык кына күрде, һәрбер адым саен аяк астында чаж-чож килеп шыштырдаган үлән тавышларын гына ишетте. Бара торгач, күзе бераз тирә-якка ияләшә төште. Сыеклана барган караңгылык аша, җир өстендә, төртке-төртке булып анда-монда аксыл чичкәләр күренде, ике якта да кара куак шәүләләре чалынып калды.

Иң алдан кызлар кебек җиңел сөякле Гамбәр йөгерде. Ул кайда яхшы печәнлек барлыгын белә иде. Барис та, Сәгыйть тә, аңа ышанып, аның артыннан ияруделәр. Гамбәр аяк атлаган саен, тыны бетеп, һаман бер үк сүзне кабатлады:

— Чокыр буенда... яшен суккан чыршы янындарак... чапмаган гына булсалар ярарые... Кыш көне утынга барганыек ич...

Бер ярты сәгать чамасы йөгергәч, Гамбәр, туктап, артка калган ире белән Сәгыйтьне көтеп алды.

— Уф-ф!..— диде ул, еш-еш тын алып.— Җөрәккә капты... Әйдәгез тизрәк, менә монда гына... сулга борылгач та...

— Ут капканмыни!— диде Барис, иң соңыннан килеп җитеп.— Ничек чаба — артыннан куян да куып җитәлмәс... Кая болының?

— Чабарсың!.. Сыерыңа печән кирәк булса — чабу түгел, кош булып очарсың... Кыш көне син интекмисең— римунтыңа китәсең дә...

Күрәсең, Гамбәрнең иренә булган баягы ачуы бетеп җитмәгән иде. Барис исә өйдәге тавышны бөтенләй онытукан иде инде.

— Нишләп син җәйдән туп-туры кышка күчтең әле?— диде ул, көлемсерәү сизелеп торган тавыш белән.— Кая болының? Болай телең белән тегермән тартып торсаң, чокырсыз да калырсың. Тукта, кемнәр ул?

Шундук сагаеп, колакларын үрә торгызып тыңларга тотындылар. Әллә уң якта, әллә сул якта — кайдадыр караңгыда ашыгып сөйләшкән тонык, басынкы тавышлар ишетелде. Кемнәрдер, алар кебек үк ашыгып, чокырга таба төшеп баралар иде, ахры.

— Тизрәк!

Киемнәрен ботакларга сыдырттыра-сыдырттыра, ниндидер куаклык арасыннан чыктылар да печән ярып түбәнгә таба төшә башладылар. Астан салкынча, юеш

үлән исе килде, тирә-юньдәге караңгылык тагын да ныграк куергандай, тыгызлангандай булды.

— Менә шушында,— диде Гамбәр, туктап. Аннан соң, өчесе дә бергә җыелгач, пышылдап: — Ишетәсезме?— диде, якыннан гына килгән чалгы тавышлары ягына ымлап.— Белмәс сиңа кеше! Кай арада килеп җиткәннәр диген әле! Әле җөгергән кешеләр түгел алар, күптән килгәннәр... Иң яхшы җиргә төшкәннәр... Әлегеләре икенче якка китте...

Чалгыларын җиргә куеп, әзерләнә башладылар.

— Ярар әйдә!— диде шуннан соң Гамбәр, үзенең дә, бүтәннәрнең дә күңелен күтәрергә тырышкан сымак.— Безгә дә калгандыр әле... Әйдәгез, менә моннан тотыныйк, тагын әз генә сулдарак...

— Әйдә, үгез булмый, чурт булсын — балаларга сөт булсын! Безнең өчен барыбер — сулдамы, уңдамы...— диде Барис, хатынының кабалануын бик кызык күреп.

Һәм әле генә: ниндидер нәрсәне кулдан ычкындырмыйк тагын дигән шикелле, ут чыккан кебек ашыгып, караңгыда абына-сөртенә йөгереп килүләрен исенә төшерде дә, тып-тын яткан чокыр буен яңгыратып, йокымсырап утырган куакларны, төн кошларын сискәндереп, кычкырып көлеп җибәрде:

— Урлашырга килгәннәрмени!

Кемгә кайдан чабарга кирәклеге турында тиз генә киңәшеп алдылар да, өчесе өч җиргә китеп тә бардылар. Күп тә үтмәде, бер-берсеннән еракта өч чалгы тавышы ишетелә башлады.

Юлда йөгереп килгән чакта кузгалган күңел күтәренкелеге тиз генә сүрелмәде. Шушылай, төнлә, бөтен яктан куе караңгылык белән чолганып алынган хәлдә, бирелеп, дәртләнеп эшләве Сәгыйтькә бик күңелле тоелды.

Тиздән ул кыза башлады, көндезге кебек эссе булып китте. Ул өстендәге бишмәтен кайдадыр салып калдырды. Үлән арасы дымлы иде. Чокыр буенда төнлә бигрәк тә нык ис тарата торган ниндидер саз үләннәре исе, яшел печән, дым исе аңкыды. Уң кул яктагы бер тәбәнәк агачка ялгыш кына чалгысы тиеп китте һәм аннан куркынган ниндидер зур, авыр кош очып чыкты. Кошның канат тавышы бер мәлгә куе һавада яңгырап ишетелеп торды да, караңгылык белән бергә болганып, кинәт эреп юк булды. Тагын бөтен нәрсә тынып калды.

Барисның, мондый төнге эшкә бер дә күңеле бармады. Аннан соң ул, көне буе комбайны белән булашып, бик арыган-алҗыган иде. Торган саен аның дәрте сүнә барды, аяккуллары авырайды, күзләрен йокы басты. Ниһаять, аның

артык түзәр хәле калмады, иртәгә дә көн бетмәгән әле дип, кулын гына селтәде дә, иснәнә-иснәнә, энесе янына китте.

— Туктыйк,— диде ул, телен көчкә кыймылдатып. Шаулатып бер иснәп алды да, кесәсеннән папирос чыгарып, ут кабызды.— Җәй бар, кыш бар, ашыгып ни эш бар! Өстеннән очмассың инде, өч кеше ничек тә бер сыерга җитәрлек кенә печән чабарбыз әле.

Сәгыйтьнең әле эшлисе килә иде, ләкин шулай да ул абыйсының сүзенә каршы килмәде.

— Җитәр алайса,— диде.

— Башта сыер пракурорына барырга кирәк,— диде Барис.— Ул ни әйтер бит әле! Әллә ул безне төне буе эшләтергә уйлыйдыр.

Сәгыйть ташлап калдырылган бишмәтен эзләп алып килде, алар ирләрчә ашыкмый гына Гамбәр янына киттеләр. «Сыер пракуроры» башын да калкытмыйча, кызукызу селтәнеп ята иде. Аларның җыенып килүләрен күреп, ул да туктап калды.

— Киттекме кайтып?— диде Барис, аның иңбашына кулын куеп.

— Кайтып?!— Гамбәр гаҗәпләнеп китте.— Кайтып нәрсә бар, пешереп куйганнармы әллә? Иртәгә син җокыңнан торып килгәнче, печәнеңнән җилләр искән булыр. Кунарга кирәк шушында.

— Һы, әнә нәрсә сөйли бит әле ул,— диде Барис, уйланып.

Гамбәрнең тәкъдиме Сәгыйтькә ошады. Ул инде кайтканнан бирле тышта иркендә төн куну турында уйлый иде, тик моңарчы моның өчен бер дә җай гына чыкмый иде.

— Алайса мин дә каршы түгел,— диде Барис, хатыны белән риза булып.

Ләкин өчесенә дә басуда кунарга ярамый иде, чөнки иртәгә иртүк торып эшкә тотынырга кирәк иде, ашарларына алар бернәрсә дә алып килмәгәннәр иде. Кояш чыкканчы ук ашарга бирәр нәрсә алып килергә кушып, Гамбәрне өйгә кайтарып җибәрделәр.

Сәгыйть белән Барис калкурак җиргә менделәр дә, баягынак юлда очраган куаклык арасына кереп, тәбәнәк чыршы астына шалаш сыман бер нәрсә әмәлләделәр. Асларына калын итеп печән җәйделәр, иртән җил өрмәсен, салкын һава кермәсен өчен, баш өстенә сузылып торган чыршы ботакларын түбәнрәк иделәр дә ботакларны печән белән капладылар. Менә дигән булды. Коры да, җылы да булды, аяк сузып ятар өчен уңай да булды.

Сәгыйть, иртән иртүк торырга кирәклеген уйлап, бүтән

көннәрдәге кебек тиз генә йоклап китмәкче булды. Әмма, әллә инде җилкенчәк йөрәге һаман тынычлана алмаганга, әллә төне шундый искиткеч матур, шундый серле, тын булганга — нишләптер аның йокысы килмәде. Аның нәрсә турындадыр уйлыйсы, хыялланасы килде, кабарынкы кара болытлар белән томаланган күк йөзенә, тын гына сулыш алып, тирә-яктагы бөтен нәрсәгә колак салып тыңлаган шикелле күренгән караңгылыкка, ерактагы күк читен дулкынландырып торган таулар шәүләсенә карап ятасы килде.

Абыйсы белән ул әнкәсе турында сөйләшмәкче булган иде бит! Менә хәзер Гамбәр юк, элекке чактагы кебек икәүдән-икәү генә сөйләшергә, эч серләреңне ачып, турыдан-туры сөйләшергә була.

— Абый,— диде ул, әкрен генә, иплəп кенә пышылдап.— Абый...

Ләкин Барис яткач та йокыга киткән иде. Сәгыйть аны уятып тормаска булды, икенче якка борылды да йокы килгәнен көтеп тын гына ята бирде. Күз алдына әнкәсе килде, кайдадыр еракта, томан артында, Барисның ачулы йөзе күренде... Ул, гомумән, әллә нишләгән әле. Элек ул алай түгел иде бугай. Ничек әйтергә — борынын күтәргәнме, бик эреләнә башлаганмы шунда... үзенә каршы бер сүз әйттеләрме, әнкәләренә дә, Гамбәргә дә тизрәк кашын җыера, җөнен кабарта, «үзем беләм», «өйрәтмәгез» дип кенә җибәрә. Хуҗа булган... Юк, бер ныгытып сөйләшергә кирәк әле аның белән...

Аннан соң ул бая очып киткән авыр кош турында, нигәдер Инсаф турында, аның хатыны турында уйлады. Инсаф хатыныннан соң уй җепләре турыдан-туры Идага барып тоташты. Ләкин аның турында уйлау күңелендә хәзер бары авыр газап, икеләнү-шикләнүләр генә уятачак иде, һәм ул, үз-үзен интектермәс өчен, аның турындагы уйны шундук күңеленнән чыгарып ташларга тырышты. Аның бары тик матур, бары тик күңелле, яхшы нәрсәләр турында гына уйлыйсы килде. Гаҗәп хәл, бүтән вакыттагы кебек хәзер аңа Ида турындагы уйны оныту өчен үз-үзе белән озак көрәшергә туры килмәде — игътибарын ул бик тиз икенче нәрсәгә күчерә алды.

Шалаш эчендә аңа нишләптер кызу була башлады, суларга тын, аяк сузарга урын җитмәде. Ул, өстендәге печәннәрен бик үк кузгатмаска тырышып, иплəп кенә тышка чыкты.

Нинди төн, нинди искиткеч төн! Җәйге җылы айларда гына була торган серле-тын, ләкин ниндидер авазлар белән, ниндидер пышылдашулар белән тулы гаҗәп төн!

Баш өстендә, җирнең тыныч йокысын бозудан курык-кан сыман, тавыш-тынсыз гына кара болытлар кыймылдаша, кайдандыр, чокырның теге ягыннан, аксыл томан белән чылатылган куе караңгылык аша бытбылдык тавышы килә, якында гына исә, җир астыннан кычкырган кебек, аңа каршы байгыш тавыш бирә һәм төтен төсле җиңел һавада бертуктаусыз чикерткәләр чыңы — күңелле тормыш җырчыларының дәртле чыңы яңгырап тора. Аннан соң чокыр буенда һаман да баягы чалгылар тавышы ишетелә. Ләкин ул тавыш шундый көчсез, шундый тоныК, аны кайчакта, караңгылыкка ныграк колак салып торсаң, хәтта чикерткәләр сайравы да, төнге бөҗәкләр безелдәве дә күмеп китә. Еракта-еракта, йокыга талган күрше Вәрәш ягында, челт-мелт килеп, электр фонарьлары җемелдәшә. Нинди шәп төн!

Аның, кулларын канат кебек җәеп җибәреп, шул кара болытларга кадәр күтәреләсе, офык читендәге оеп, йокымсырап яткан шул йомшак кара таулар ягына очып китәсе килде. Күңеле ниндидер әйбәт бер хис белән тулды, күзләре, табигатьнең шушы төнге серенә төшенергә теләгән шикелле, комсызланып караңгылыкка текәлде. Ул куаклар арасыннан чыкты да чабылмаган йомшак, җылы печән өстенә сузылып ятты. Кулларын баш астына куйды һәм, бөтен нәрсәгә колак салып, күккә карап, берниндц хәрәкәтсез ята бирде.

Аның шушы кыймылдаучан болытларга караган саен карыйсы килде, җиңел, исерткеч хуш исләр белән тулы шушы саф һаваны сулаган саен сулыйсы килде. Кинәт аңа ул, Сәгыйть, табигатьтәге шушы меңләгән тавышның музыкасын колагы белән генә түгел, бөтен күңеле белән, бөтен җаны-тәне белән тыңлый кебек тоелды, көндез арып ял итәргә туктаган шушы караңгы җир өстенең, еректагы тау карачкыларының, хәрәкәтчән шул болытларның үзара әкрен генә пышылдашуларын, авыр уфылдап тын алуларын ишетә кебек тоелды. Шул вакыт ул шушы табигать белән, туган ягының шушы җирекүге белән үзен бер бөтен итеп, бер җан-тән итеп сизгәндәй булды.

Күңеле аеруча нык дулкынланган чакларда ул бүтән вакытта да шундый ук гаҗәеп бер тойгы кичерә торган иде. Ләкин мондый тойгы аны үзләренең туган ягында, туган авылында булганда гына били торган иде Юк, шәһәрдә дә, бүтән авылларда да аңа әле беркайчан да мондый нәрсә кичерергә, үзе белән табигать арасында мондый якынлык тоярга туры килгәне булмады. Ә бит ул шәһәрдә дә әзме-күпме яшәде, андагы тормышка да

күнегеп өлгерде. Ләкин анда бакчалар да, урамнар да, машина шау-шулары да — барысы да, никадәр генә таныш, никадәр генә гадәтләнгән булмасын, күңеленә барыбер чит булып, ят булып калды.

Нигә соң шулай бик кадерле, сөйкемле һәм җанга якын икән бу туган як, туган җир? Нигә соң туган ил, туган җир төшенчәсе безнең аңда һәрвакыт бала чакның кояшлы көннәре белән, яшенле яңгырлары һәм яшел чирәм чемченеп йөргән йомшак мамыклы каз бәбкәләре белән, яланаякка кадала торган арыш камыллары һәм шаулап аккан язгы ташкыннары, карга боткалары белән шулай тыгыз бәйләнгән икән? Күрәсең, без әле үзебезне чолгап алган шундый гаҗәп, шундый матур дөньяга яңа гына күзебезне ачып карый башлаган чакта, очраган бөтен нәрсәгә исебез китеп куанган чакта, кыскасы, яңа гына тәпи басарга өйрәнгән чакта табигать үзе дә безгә үзенең иксез-чиксез хәзинәләрен ачарга ярдәм итәдер; безне күкрәк сөтен имезеп үстергән әнкәйләр кебек үк, туган җир дә яратып безне үз кочагында иркәлидер, безгә һәрнәрсәдә сиздермичә генә булышлык итәдер. Әгәр шулай икән, сиңа тормыш биргән әнкәңне оныта алмаган кебек, туган җиреңне, туган табигатеңне дә онытырга, чит күрергә, яратмаска мөмкинме соң!

Күккә карап Сәгыйть озак ятты. Түбә өстендә тавышсыз гына аңа нидер сөйли-сөйли, җөн төргәге кебек кабарынкы кара болытлар кыймылдашты, тирә-яктагы һәрбер нәрсәгә аның кебек үк хәйран калып, исе китеп якында гына кара куак утырды, җир астыннан, серле дә, аңлаешлы да тоелган саңгырау аваз биреп, төн ябалагы — байгыш кычкырды, һавада канатлы кортлар белән бергәләп мәтрүшкә исе, яшел үлән исе очып йөрде.

Аһ, нинди гүзәл төн!..

Кинәт ул сагаеп калды: астан — чокыр буеннан — баядан бирле чалгы чыжлавы ишетелеп торган яктан, чыелдык хатын-кызлар тавышы килде. Сәгыйть, шундый матур, шундый күңелле уйларыннан аерылып, төнге тынлыкны, татлы ялгызлыкны бозган шушы тупас тавышны ирексездән тыңларга тотынды. Анда әллә тиргәшәләр, әллә бер-берсенә тавыш биреп кычкыралар иде — ул моны тиз генә аера алмады, тик шунысы ачык иде: хатын-кыз тавышы ачулы, зәһәрле иде. Нәрсә бу? Шушы ягымлы, шушы тату, гүзәл тынлыкны бозарга кемнең хакы бар? Әллә соң шушы киң күңелле, шушы бөек табигатьтән башка тагын берәр начар, ямьсез нәрсә бармы? Тукта! Нинди таныш тавыш бу?

Ул торып утырды. Чыннан да бу таныш тавыш. «Кем-

нәр икән соң алар шулай да?» — диде ул, кемдә шундый холыксыз, зәһәрле тавыш булуын тиз генә хәтерли алмыйча.

Хатын-кыз кычкырудан туктап калды, аңа каршы шундый ук ачулы, йокымсыраган ирләр тавышы җавап бирде. Әһә, менә кемнәр икән! Инсаф белән хатыны ич!

Инсаф әле булса читкә китә алмый йөри, шулай ук колхоз эшенә дә чыкмый — печән чабарга ул өмәдән соң бүтән килмәде. Сәгыйть аны шуннан соң бөтенләй диярлек күрмәде. Тик беркөнне генә, атка утырып эштән кайтып барганда гына, ул аның хатыны белән бергә саклау урман ягыннан кулына балта тотып кайтып барганын күреп калды.

Көн кичкә таба иде, Инсаф изүләрен чишеп җибәргән, бик арыган кыяфәт белән алпан-тилпән атлап бара. Сәгыйть, көндез урманга кергәч, кисеп аударылган юан юкәләр янына барып чыгуын исенә төшереп: «Шулар әрәм иткәннәрдер әле!» — дип уйлаган иде ул чакта, йөрәге әрнеп. Йөрәк әрнемәслек тә түгел. Авыл тирәсендәге әрәмәләр, урманнар хәзер елдан-ел сирәгәя, шәрәләнә бара. Урманны саклау турында беркем дә рәтләп кайгыртмый, каравыл каты булмаганга, Инсаф кебек корткычларның балталары инде саклау урманга кадәр үтеп керә башлаган. Ул чакта алар, печәнчеләр күзенә күренмәскә тырышып, юлдан читкә чыкканнар һәм куаклар арасыннан баралар иде.

Кара син аны, үз сыеры турында онытмаган, бөтен кешедән алда килгән, җитмәсә, төне буе чабарга чамалый, ахры...

Төнге гүзәллек, серле, мәгънәле тынлык шундук юк булды, күңелне ниндидер ямьсез, авыр тойгы биләп алды. Чокыр төбеннән өшеткеч дымлы, юеш һава шуышып менде дә аякларга сырышты, бөтен тәнне чиркәндереп, аркага, күкрәкләргә үрмәләде. Сәгыйть, авыз күтәреп, озак кына бер иснәде дә, шалаш эченә кереп, абыйсы янына сузылып ятты. Чокыр төбендә һаман да тиргәшкән тавыш — әле чыелдык хатын-кыз тавышы, әле ачулы, йокымсыраган ирләр тавышы ишетелеп торды.

Иртән соргылт калкулыклар ягыннан яшь кызлар кебек чын күңелдән елмаеп, күк читен сыек, йомшак нурларга буяп, сызылып кына кояш чыккач та, көн тәмам ачылып, яктырып киткәч тә, йөгерә-йөгерә Гамбәр килеп җитте. Кызу килгәнгә аның бит очлары алсуланган, чәч бөртекләре, яулык читеннән чыгып, маңгаена төшкән иде. Ул, шалаш хезмәтен үтәгән чыршы ботакларын селкетә-селкетә:

— Әй, торыгыз, ялкаулар!— дип кычкырып җибәрде.— Арт саныгызны кояш кыздыра, ялкаулар.

Беренче булып чыршы астыннан өсте-башы тaушалып беткән, йокылы кыяфәтле Сәгыйть килеп чыкты, аннары күзләрен уа-уа, киерелә-сузыла чыгып килгән Барис күренде.

— Каяле, көннекчеләргә нәрсә алып килдең ашарга, бай апа?— диде Барис, Гамбәр кулындагы төенчеккә үрелеп.

Гамбәр бер чикләвек куагы төбенә, җайлы урынга килде дә төргәкне чишеп җибәрде. Барис белән Сәгыйть аның янына утырыштылар. Яшел миски өстенә капланган коштабакны күтәреп алгач та, мискидән җылы бу күтәрелде, тозга ярып пешергән кайнар бәрәңге исе борыннарга килеп бәрелде. Барис авыз чите белән генә энесенә елмаеп-ымлап алды:

— Һы, кара, бәрәңге белән генә эшләтмәкче була бу безне! Эшләтми тор!..

Гамбәр кесәсеннән ак май салынган стакан алып җиргә утыртып куйды да, иренең сүзләрен чынга да, уен-көлкегә дә алырга белмичә:

— Ярар, ваксынма инде,— диде,— хәзергә ярап торыр. Тәлгатьне күтәреп, бераздан әнкәй килеп җитәр, төшкә итле аш пешерәбез... Әнкәй, безгә аш пешерергә бар әле, дигәч, бала-чага кебек сөенә, мескен. Тәлгатьне яслегә бирергә кирәк, читлектәге кош кебек ятмас инде ул анда...

Барис, җавап-ни кайтармыйча, сизелер-сизелмәс кенә кашларын җыерып, мискигә үрелде, кабаланып иң эре бәрәңгене алды да, кулын пешерә-пешерә, ашыгып әрчергә тотынды.

Тәмләп кенә бәрәңге ашап утырганда, якында гына, үзләре артында аяк тавышлары ишетеп, өчесе дә башларын борып карадылар. Уң як кулбашына чалгы салган, авызына тәмәке төреп капкан Мәрдәншә агай, күн итекләрен салмак кына өстерәп, туп-туры аларга таба килә иде. Ул аяк атлаган саен, корыч чалгысы әкрен генә якякка тирбәлә, иртәнге кояш нурларында көмеш кебек ялт-йолт итеп китә һәм аның артыннан чыклы куе үлән өстендә юеш, яшькелт эз сузылып кала иде.

Мәрдәншә агай килеп туктады да, Сәгыйтьләрнең таң тишегеннән шушында килеп ашап утыруларына бик гаҗәпләнгән шикелле, кара, каты төк баскан иякләрен сыпыргалап, беравык карап торды, аннан соң исәнлек-саулык сорашты һәм:

— Ай-яй, малайкай, бик кызу тотынгансыз сез!— диде.

Барис, аның ни турында — әллә бәрәңге, әллә печән турында сөйләгәнлеген аңлап җитмичә, утырган урыныннан читкәрәк кымшанып куйды. Ул аңа урын тәкъдим итте.

— Әйдә, Мәрдәншә агай, тотын безнең белән, җылынып китәрсең... Бәрәңге җитәрлек...

— Әле генә ашап килдем, рәхмәт,— диде Мәрдәншә агай. Шулай да чалгысын җиргә сузып салды да бер читкәрәк тезләнеп утырды.

— Кай арада җитештегез соң әле сез?— диде ул, бераздан тагын сүз башлап, тәмәкесен суыра-суыра. Шуннан соң үкенгән, борчылган тонда: — Бәхетсезгә вахытсыз дигәндәй — мунча кереп калганмын,— диде.— Печәнне бетереп кайткан көн дигән булып, ватылган сөякләрне җомшартып алыйм дигән булып катыннан мунча яктырганыем. Өйдә беркем булмаган Низамый әйтеп җөргәндә, икәүләшеп мунчада торып калганбыз шул, малайкай. Үземнең дә истән чыккан — карга мие эчкән нәрсә... Билгеләп куйган бер җирем барые — очкан, эзе дә юк!

Барис, Мәрдәншә агайга елмаюлы куз карашы ташлап, хәйләкәр генә көлеп алды.

— Ике рәхәт бергә килми шул — нишләтәсең инде аны... Мунчаны аны соңгарак калдырыргае, Мәрдәншә агай.

— Һи-и, Мәрдәншә абзыкаем, донҗада чокыр-чакыр бетмәгәндер әле, тапкансың аптырар нәрсә! Кеше белмәгән әллә нинди җирләр бардыр әле.

— Дөрес анысы, Гамбәр, хак сүз, донҗада чокыр-чакыр күп ул, артыгы белән дә әле ул, шулай да, малайкай, печәнлесе беткәндер инде аның.

— Өскәрәк менеп карале, Мәрдәншә агай,— диде Гамбәр тагын, ничек тә аның күңелен төшермәскә тырышкандай.— Анда, өстәрәк, чикләвек куаклары янында бик шәп җир барые, берәү дә җитешмәгәндер әле.

— Шула-ай... сез якшы җирне эләктергәнсез,— диде Мәрдәншә агай, аның сүзен ишетмәгән кебек, ничектер уңайсызланган һәм шул ук вакытта тагын нидер әйтергә җыенган кыяфәт белән як-ягына каранып.— Минем кебек авыз күтәреп калмагансыз, малайкай. Бер төн эчендә чаптыгызмы аны?

— Кайсы төшне әйтәсең син, Мәрдәншә абзый? Әллә шушыны күп дисеңме? Һи-и, өч чалгы өчен әллә ни түгел инде ул!— диде Гамбәр, чокырның өстеннән астына таба сузылган печән өемнәренә күрсәтеп.

— Нигә, тегендәгесе сезнеке түгелмени?

— Кайда?

— Әнә тегендә, астарак, яшен суккан чыршыдан тегеләйрәк... Мин аны сезнекедер дигәнием.

— Ә-ә!— диде Сәгыйть, аның кай төш турында сөйләгәнен аңлап алып.— Инсафлар чапты аны, хатыны белән... безнеке түгел ул...

Мәрдәншә агайның калын кашлары кисәк кенә югары сикерде.

— Инсаф?— диде ул Сәгыйтькә шундый тон белән, әйтерсең, Инсафның ул җирне чабуында бары тик ул гына гаепле иде.— Калхузда эшләмәгән башына нинди печән аңа?

Барис та аптыраган кыяфәт белән энесенә карап алды.

— Каян белдең Инсаф икәнен?

— Төне буе тиргәшә-тиргәшә чаптылар,— диде Сәгыйть, көлеп.— Син гырылдап җоклаганда тыңлап яттым.

— Ах, төн убыры!.. Шул төшне генә билгеләп куйганыем, малайкай. Сез чапкансыздыр, дип әйтергә генә кыймый утырадырыем,— диде Мәрдәншә агай, ачуын тыялмыйча.— Ах, төн карачкысы!.. Үзе өчен утка-суга керер — сазлыктагы камышларны да кыркып бетергәннәр, чәч алган кебек иткәннәр, малайкай. Менә сиңа, хәзер тагын берәр җирне сыдырып яталардыр инде мыштым гына... Эш түгел бу, булмый бу болай. Син анда кара тиреңне түгеп, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләп җөре, монда җыен ырбач, җыен җык җилкә үзенә рәхәтләнеп печән әзерләсен!.. Ул аны эш көненә бүләргә тиеш, закуны шул аның. Ул тота да — мә сиңа бер көн, теләсәң нишлә шуның белән, чапсаң чабып кал, чапмасаң капчыгыңны тотып кал! Инсаф кебекләре аның аңдышып кына тора, кайчан нәрсә буласын биш көн алдан иснәнеп кенә тора да — әйдә! Төн җокламый чаба...

— Инсафларны читкә китәләр икән, диләрие түгелме соң?— диде Гамбәр.

Мәрдәншә агай, үзенең бер гаепсез кешеләр алдында кызып китүенә уңайсызланган шикелле, шундук Инсафны сүгүдән туктады да кесәсеннән кызыл белән чигелгән кара янчык чыгарып, тәмәке төрергә тотынды һәм, инде бөтенләй тыныч тонга күчеп, әйтеп куйды:

— Китә!.. Абзар артына китсенмени... Китә торган кешеләр китәләр дә эшләп тә яталар. Уңга да юк, сулга да юк аннан, ит тә юк, сөт тә юк. Катыны да үзе кебек... Артыграк та әле...

— Җорт-җирне рәткә салам да, сыер өчен җитәрлек

печән әзерлим дә — көзгә барыбер авылда калмыйм, дип әйтә ди ич.

Мәрдәншә агай урыныннан торды.

— Ярар, китим әле, утырып эш чыкмас,— диде ул, чалгысына тотынып.

Барис та шул вакыт аягына басты.

— Карале, Мәрдәншә агай, тотын әнә теге төштән, булмаса — сиңа да җитәр, безгә дә җитәр...

— Әйе шул, Мәрдәншә абзый... Җитми әллә, әллә кемнәргә дә җитәр әле!— диде Гамбәр дә, көттеребрәк.

Мәрдәншә агай, кичә төнлә Сәгыйтьләр чапкан җиргә караган көе бераз эндәшми торды да, нык кына итеп:

— Җук, Барис, рәхмәт,— диде.— Сезнең дә монда артык җир җук... Китим әле... Рәхмәт.

Ул салмак кына атлап аска таба төшеп китте, күн итекләренә бәрелгән чыклы үләннәр тирбәлеп калды, печән өстендә арттан яшькелт эз сузылды һәм торган саен ныграк дөрләп яна барган иртәнге кояш нурында, күзләрне чагылдырып, корыч чалгы йөзе ялтырады.

## III

Урак башланды.

Көннең-көнозын кояш кыздырган калкулык битендә өй урыны кадәр генә урылган җир һәм аның уртасында бер сослан күренде. Тора-бара урылган җирләр, сосланнар күбәеп китте, һәм берничә көннән соң калкулык өсте бөтенләй кыйтыкланып, бүлгәләнеп бетте. Кыйтыклар да озакка бармады, бер көнне калкулык өсте, чәче алынган татар башы кебек, тәмам ачылып китте, анда бары билләрен бөгеп утырган, чүлмәк шикелле юан корсаклы сосланнар гына тезелеп калды. Күп тә үтмәде, арыш басуының икенче төшендә, тигез җирдә, комбайн тавышы ишетелә башлады. Авыл кешесе өчен кош сайравы яисә бал кортлары безелдәве кебек гадәти тавышка әйләнгән бу гүелдек, күңелләргә яңа хәбәр салып, әле бик якында гына, авыл читендә генә яңгырады, әле бик еракка, куе яшел әрәмәләр ягына китеп, һаман колак төбендә ишетелеп торды. Түбәсе яңа салам белән ябылган иске ындыр табагы җанланып китте. Комбайннар яныннан бербер артлы ашлык төялгән атлар килеп торды. Йөкче малайлар, йөкче егетләр, бестаркаларының капкачларын ачып, ашлыкларны җиргә генә бушаттылар да, арба читенә аякларын аерып баскан көе, атларына сызгыра-сызгыра, тагын тулы бункерлар янына ашыктылар. Җилгәргеч тирәсендә, үлчәү тирәсендә эшлекле кыяфәт белән

кешеләр кайнашты, җилгәрделәр, үлчәделәр, капчыкларга тутырдылар да, капчыкларны, кул очларына гына элдереп, машина кузовына ыргыттылар да станциягә, заготзерного озата тордылар. Шофер Галәү ындыр табагында көненә икешәр-өчәр мәртәбә күренә башлады, машинасы тик торган арада, җилгәрүче, ашлык тутыручы кызлар белән шаярды, арыш сибеште. Камыл уртасыннан юллар салынды. Көндез, төш вакыты җиткәч, ераграк басу якларында, чокыр эчләреннән зәңгәр төтен күтәрелде.

Урак башланды, уттай кызу эш вакыты башланды.

Өченче бригадада ике комбайн — Барис белән Рәшит эшләде. Барис бик зур җир бүлеп алды, шуңа күрә баштарак ул көненә өч-дүрт мәртәбәдән артык әйләнә алмады һәм аның артыннан сузылып барган урылган җир дә бик тар булып күренде. Тора-бара урылган җир тасмасы киңәйде, ташлатып калдырылган салам чүмәләләре күбәйде, комбайн тавышы исә авыл янында ешрак ишетелә башлады.

Барисның үзе яраткан эшкә бөтен күңеле белән бирелә торган гадәте бар иде. Штурвал янына менеп баскач та, борынына яңа арыш исе, киселгән камыл исе кергәч тә, ул бөтен дөньясын онытты, көн-төн комбайны янында булды, хатыны белән бергәләп бер караңгыдан китте, икенче караңгыда кайтты. Сәгыйть аларны хәзер рәтләп күрми дә башлады.

Сәгыйть, үзебезнең печәнне җыеп бетергәч тә, рәхәтләнеп китәрмен, әллә кайларга барырмын, дип уйлаган иде. Аның әз генә ял итеп аласы килә иде.

Эшлисе эш тә бетте, куллары-аяклары бушап калды, ләкин ул үзендә бернинди шатлык, бернинди канәгатьләнү хисе тоймады, киресенчә, бөтен дөнья кинәт бушап, коточкыч күңелсезләнеп калган шикелле булды. Һәм шушы күңел бушлыгын тутыру өчен аңа нәрсә дә булса эшләргә, нәрсә белән булса да мавыгырга кирәк иде. Юк, өйдә тик ятып кына ял итеп булмаячак, бу хәзер бөтенләй мөмкин түгел иде.

Нәрсә, әллә тагын балык каптырырга чыгып китәргәме? Нинди мәгънәсез нәрсә! Әллә соң чынлап та Бибинурларга кунакка барыргамы? Әһә! Әле өченчекөнне генә кемдер берәү артыннан: килсен, килми калмасын, дип әйтеп җибәргәннәр...

Төш вакыты якынлашып кына килә иде әле. Тәвәккәлләде дә, Бибинурларга китеп тә барды. «Берәр атна ятып кайтырмын, аннан соң инде беренче сентябрьгә дә артык күп калмый»,— дип уйлады ул, Карман юлыннан кызу-кызу атлап.

Район үзәгеннән бик еракта булган Карман зур авыл иде. Аның берсеннән-берсе озын, берсеннән-берсе чиста унлап кына урамы бар иде. Йортларның барысы да төзек, барысы да таза, эре. Йорт алларында шомыртлар, миләш, сиреньнәр үсеп утыра, тәрәзә пыялаларын уттай кызыл, алсу чичәкле гөлләр каплап тора һәм һәрбер йортка урамдагы озын баганалардан дүртәр, кайберсенә хәтта бишәр чыбык сузылган. Ак рәшәткә белән уратып алынган алты почмаклы, озынча идарә йорты каршысында, багана башында, кычкырып радио сөйли. Авыл уртасында, базар мәйданы янындарак, ике катлы зур культура сарае салынып ята иде.

Сәгыйть үзе ел ярым укыган урта мәктәп ишегалдына кереп чыкты, яраткан ике укытучысының йортына барып кайтты, кайбер танышларын, дусларын очратты, урманнарга, тауларга чыгып йөрде, бер кичне иске клубта кино карады.

Бер көн кунак булды, ике көн кунак булды, сыйладылар, хөрмәт иттеләр, ләкин өченче көнне аңа монда да бик күңелсез була башлады. Ул әледән-әле үзләре ягына карады, анда аны кемдер, нәрсәдер бик зарыгып көтеп торадыр шикелле тоелды. Үзләреннән ничек кисәк кенә чыгып киткән булса, моннан да шулай кисәк кенә уйлады да, кайтты да китте. Ачуланып та карадылар, ялындылар да — ул берни ишетмәде. Юк, аны өйдә кемдер көтеп тора иде. Күңеле нидер сизенде.

Ул йөгерә-йөгерә кайтты. Ләкин Идадан барыбер берни юк иде. Ул үз-үзен йомшаклыгы өчен, һаман аның турында уйлаганы өчен, өметләнеп кайтканы өчен тиргәде. «Ул миңа язмый икән, мине оныткан икән — мин дә аны бөтенләй истән чыгарып ташларга тиеш!»— диде ул үз-үзенә, ниндидер бер усал кансызлык белән. Бу аңа искиткеч көч бирде, аны канатландырып җибәргәндәй булды. Әйе, көз көне очрашкач та, ул аның ягына борылып та карамаячак, башын горур тотып, аның яныннан юри әкрен генә узып китәчәк.

Ул үзенең аннан шулай итеп үч алачагы турында уйлап ләззәтләнде. Ул аның шул вакыттагы боек, кызганыч йөзен күз алдына китерде. Һәм аның йөрәге тетрәнеп китте. Ул, аны шундый шәфкатьсез уйлары белән генә дә рәнҗеткән кебек, үз-үзен шелтәләргә, аның үз күз алдындагы сурәте алдында тәүбә итәргә, үкенергә тотынды.

Ул, эш юктан эш булсын дип, абыйсы янына басуга китте. Аның җире инде ярыйсы гына тарайган, кыскарган иде. Камыл ярып, ул, урылган җир аша чыкты да,

җир башында туктап, комбайн килеп җиткәнне көтә башлады.

Көн әле яңа гына башланып килә иде. Юл буендагы телефон чыбыклары көмеш җепләр кебек җемелди, аксыл-саргылт арыш камыллары, кылчыклы авыр башларын салындырып, тын гына, шым гына утыралар иде.

Сәгыйть, җылы кояшка битен куеп, җайлап кына камыл өстенә утырды.

Ул үзенең тирә-ягында черт-черт килеп шартлаган ниндидер исәпсез-хисапсыз тавышлар ишетте. Ул игътибар белән тыңларга тотынды. Бу — төнлә дымланган камыллар шулай кояш кызуында кибеп чатный иде. Аның аягына ниндидер вак кына кортлар үрмәләп менде; кулына «Фатыйма» дип аталган, каты, шома канатлы кызыл корт килеп кунды. Җир өстендә, комбайн тәгәрмәчләре, тракторның тимер табаннары куптарган камыл тамырлары арасында, яшел чүп үләннәренең яфракларында йөзләрчә төрдәге, төрле зурлыктагы, төрле төстәге бәләкәч кенә җан ияләре кыймылдашты. Баш очыннан гына шаулашып сыерчыклар очып китте.

Сәгыйтькә җир өсте яңа йокысыннан уянып килә шикелле тоелды һәм андагы бөтен нәрсә җитди бер кабалану белән, тырышлык һәм гомер-гомергә кабатланган бер көчле инстинкт белән эшкә тотына шикелле тоелды. Әйтерсең кемдер аны кисәк кенә кулыннан тартып торгызды. Ул, үзенә яңадан тормыш дәрте кайтканын тойган хәлдә, трактор табаннары бастырып киткән эздән чыкмаска тырышып, комбайн каршысына йөгерде.

Комбайн үзе әле ерак иде, арыш басуының икенче башында аның түбәтәйле озын, нечкә торбасы да, ак киндер чатыры һәм бункерының өске өлеше генә күренә иде.

Комбайн ягыннан килгән тигез ритмлы, эшчән гөрелдек һаман ныграк, һаман ачыграк ишетелде. Сәгыйть тракторчы егетне дә, әкрен генә, эре генә тирбәлеп килгән комбайн өстендәге Барис белән Гамбәрнең йөзләрен дә аермачык күрде.

Ул тракторны үзе яныннан уздырып җибәрде дә йөгереп комбайн артына чыкты. Тар баскычка сикереп менде һәм, өстен-башын тузанга буямаска тырышып, тимер тоткага тотына-тотына, югары күтәрелде.

Штурвалга ике куллап тотынган Барис, күзен бер ноктадан алмыйча, аска, пычкы теше кебек сырлы урак белән арыш сабаклары очрашкан турыга карап бара иде. Ул энесенә әйләнеп карады да, зур күзлек пыялалары ар-

кылы елтырап күренгән күзләре белән ымлап, аңа нәрсәдер әйтте. Комбайн тавышы аша Сәгыйть аның сүзләрен ишетмәде. Сәгыйтькә кинәт ул бөтенләй ишетми башлады шикелле тоелды.

Барис, өстен чишенеп ташлап, гадәтенчә майкадан гына калган иде. Аның юан, кыска беләкләренә, аркасына, муенына, кулбашларына — бөтен җиренә бер карыш тузан утырырга өлгергән һәм ул авызын ачып сөйләшкәндә аның тешләре генә агарып күренә иде. Сәгыйть, тузан каккан булып, абыйсының аркасына шапылдатып алды да:

— Колагың шалкан чәчәрлек булган!— дип кычкырды.

— Шалкан чәчү генә түгел, трактыр белән сөрерлек булды инде!— дип кычкырды тегесе, аңа җавап итеп.

Комбайн, тигезсез юлдан барган арба кебек, як-якка тирбәлде. Егылып китмәс өчен Сәгыйть ике куллап тимер тоткага тотынып барды. Аңа монда бик кызык тоелды. Ул басма уртасында басып торган Гамбәр янына килде, аның кулыннан тимер көрәген алды да өстән, кәкре торбадан агып, тау сыман булып өелә барган арышны бункерның буш почмакларына ишеп җибәрде.

Җир башына килеп җитәрәк, бункер бөтенләй тулды. Барис, паровоз машинисты кебек, бер чыбыкны тартып сигнал бирде. Бөтен агрегат туктап калды. Атларын чаптыра-чаптыра, ашлык ташучы малайлар килеп җитте, комбайн янына ук килеп туктадылар да, ашлыкны автоматик рәвештә бушата торган торбаның киндер җиңен ике куллап тоткан көе, арыш коелганын көтеп тора башладылар. Арба төбенә җиң эченнән шаулап, су кебек авыр арыш агарга тотынды. Ике-өч минут вакыт үтмәде — арба туп-тулы булды. Беренче ат әкрен генә кузгалып китеп барды, аның артыннан җиң астына икенчесе килеп туктады. Сәгыйть бункерны тизрәк бушату өчен, көрәге белән ашлыкны ишеп, көрәп торды.

Барис тагын сигнал бирде. Җиңеләеп калган комбайн яңадан салмак кына кузгалып китте.

Машинаны үз ихтыярына буйсындырып, аны теләсә кая йөртә алган, аның ярдәмендә искиткеч эшләр башкара алган кешеләргә, бигрәк тә шоферларга, тракторчыларга, Сәгыйть малай чагында кызыгып, көнләшеп карый торган иде. Аңа моторның серен биш бармагы кебек белгән кешедән дә башлырак, аннан да белемлерәк беркем дә юктыр шикелле тоела торган иде. Бер үк вакытта очучы да, ерак илләрне гизүче сәяхәтче дә, инженер да, тагын әллә кем дә булырга хыялланган чактагы бу яше-

рен тойгы ул инде үсеп җиткәч тә, студент булгач һәм киләчәк тормыш юлы билгеле бер эзгә төшкәч тә бөтенләй онытылмады. Киресенчә, ул еш кына кайчан да булса бер шоферлыкка өйрәнү яисә үзенә мотоцикл сатып алу турында хыялланды. Әлбәттә, әллә нинди зур омтылыш та, зур идеал да түгел иде бу. Була бит шундый кечкенә, бәләкәй генә хыяллар.

Комбайн өстенә менеп баскач, йөзләгән тимер частьларның, төрле тәгәрмәч, күчәрләрнең, чылбырларның — шушы бөтен бер катлаулы, ләкин төгәл, дөрес механизмның, кеше көченә буйсынып, бернинди каршылыксыз эшләвен күргәч, аның күңелендә күптәнге нәрсә яңадан уянды. Абыйсы Барис та, Гамбәр дә аңа ул белмәгән бик яшерен серне беләләрдер шикелле булып, бик оста, бик галим кешеләр булып күренде. Аның Барис кебек үк штурвал тотып барасы килде.

— Бир әле синең урынга басыйм!— дип кычкырды ул абыйсының колагына.

— Маташма, әйдә, өстеңне пычратасың,— диде Барис, башын күтәреп карамыйча гына.

Ләкин Сәгыйть бик теләнә торгач түзмәде, башы белән генә ымлады да штурвалны энесенә тоттырды.

— Кара аны, карап бар. Арыш калынайса, бераз күтәрә төш, сирәкләнсә, төшерерсең...

Ул кадәресен генә Сәгыйть үзе дә белә иде, әмма шулай да ул абыйсына бер сүз дә кайтармады, штурвалның салкын тимере аша бөтен тәненә бирелгән рәхәт калтырануны тойган хәлдә, кулына ат төшкән бала кебек шатланып, аякларын ныгытып баскан көе, чын комбайнчы төсле бик җитди кыяфәт белән аска, хедер алдына карап баруында булды. Бөтен комбайнга җан биреп, көч биреп, бертуктаусыз мотор эшләде, ашыкмыйча, кабаланмыйча эвернә әйләнде, арыш камыллары, эвернә канатлары астына эләгеп, буйсынучан гына башларын иделәр дә, төптән кыркылып, комбайн корсагына таба йөгереп торган киндер өстенә аудылар, сикергәли-сикергәли, чабалана-чабалана бераз гына килделәр дә, кинәт тыйнакланып калып, эчкә — барабаннар, тешле валлар арасына йотыла тордылар. Сул якта шаулап, калай торба стеналары буенча шуышып, бункерга коры, авыр арыш коелды, һәм хедер артыннан чип-чиста булып кыркылган тигез камыл тырпаеп калды. Шушының бөтенесе белән дә ул...— Сәгыйть җитәкчелек итте.

Кинәт Барис аның колак төбендә генә кычкырып җибәрде. Сәгыйть, миңа кычкыра, ахры, бу, дип, үз урынына басмакчы була торгандыр дип, тиз генә аның ягы-

на карап алды. Барис аңа аркасы белән басып тора иде. Сәгыйть тынычланып яңадан үз алдына борылды.

Шул чакны тузанланып беткән зәңгәр күлмәк кигән, биленә ак алъяпкыч бәйләгән чандыр гына бер кызый, кулындагы кызыл саплы урагын югары тотып, трактор алдына таба йөгерә башлады. Ул, тракторны бер ун-унбиш адым чамасы узып китте дә, үзе буе арышны ярып, туп-туры комбайн алдына килеп, керде һәм, җиләк җыйгандагы шикелле бер иелеп, бер бөгелеп, ашыга-ашыга йөгергәләргә тотынды. Артыннан трактор килеп җиткәч, ялт кына башын күтәрде дә, ачуланган булып, тракторчыга урагы белән янады, нидер кычкырды, трактор исә, бернигә игътибар итмичә, көчле үкереп барды да барды, бөтенләй кызый белән тигезләште. Сәгыйтьнең йөрәге жу итеп китте — кызый әз генә мыштырдаса, аны шундук хедер эләктереп алачак иде. Ләкин кызый, көлә-көлә, кәҗә бәрәне кебек бер-ике генә сикерде дә тракторны узып та китте, башыннан югары тотып, бер кочак әрем күтәргән көе, урылган җиргә килеп чыкты. Сәгыйть аның Зәйтүнә сеңелесе Тәгъзимә икәнен танып алды.

— Дәүләткә илтәсе ашлык бит,— диде Барис, кызның ни өчен әрем урып йөрүен аңлаткан сыман.— Студентлар әремле ипи ашамасыннар дибез, ату башлары эшләмәс.

Трактор түбән, уйсу җиргә килеп керде. Бункерга арыш шәбрәк, күбрәк коела башлады. Барис кулын кәкре торба турысына тотты һәм бер уч арыш алып аны күзенә якынрак китерде дә, ниндидер гаҗәп нәрсә күргән шикелле, җентекләп карарга тотынды.

— Бөтен җире дә шулай куе булсыные аның!— дип кычкырды Сәгыйть.

— Куе!.. Алдыңа кара әнә, ач газны!— дип кычкырды Барис аңа каршы, учындагы арышны кире бункерга ташлап.— Болай куе булса, көненә биш гектар да уралмассың...

Үрне менгәч, арыш тагын сирәгәйде, комбайнга да, тракторга да җиңелрәк булып китте. Ләкин кәкре торбадан арыш бик саранланып кына ага башлады.

Бер дә әйләнделәр җирне, икенче мәртәбә дә әйләнә башладылар. Комбайн бик яхшы эшләде.

Тик бер генә нәрсә Сәгыйтьнең эчен пошырды. Ул уракның һәрвакыт тулы киңлектә урмаганын, хедерның трактор ягындагы очы кайчакта урылмаган арыш читеннән яртышар метрга, берәр метрга кадәр чыгып, киселгән камыл өстеннән барганын күрде. Кайчакта хедер, киресенчә, эчкәрәк кереп китте һәм артта, урылган җир уртасында, озын сызык булып, уракка эләкмәгән биек

арыш утырып калды. Сәгыйть баштарак, мин шулай белми урдырамдыр, дип уйлады һәм: «Абый күрә-нитә күрмәсен»,— дип, гел шүрләп барды. Ләкин соңыннан ул бөтен нәрсәнең бары тик тракторчыга гына бәйләнгән икәнен аңлап алды. Тракторчы комбайнны, дөресрәге, тракторны дөрес алып барса, урак бөтен киңлегенә урды, инде трактор әз генә уңга йә сулга тайпылса һәм урылмаган арыш белән үзе арасындагы билгеле бер арадан чак кына ялгышса, хедер да читкә чыгып барды яисә эчкәрәк керде. Шулай да күбрәк вакыт хедер очы артып калды, һәм арыш мөмкин булган киңлектән яртышар, берәр метрга кадәр кимрәк урылды. Озын, кызыл муенлы тракторчы егет агрегатны дөрес алып бару өчен, башын борып, әледән-әле артка, уракның ничек алдыруына карап барды. Ләкин, әллә гел артка карап бару ялыктырганга, әллә инде игътибарсызлыктан, ул кайчакта онытылып китте һәм хедергә дә, бернигә дә әһәмият итмәде.

— Күңелең булдымы?— дип кычкырды Барис.

Ул, Сәгыйть авызын ачып өлгергәнче, ипләп кенә аны читкә тайпылдырды да яңадан үз урынына басты.

Сәгыйть комбайннан төшеп калды. Каты җиргә баскач та, кинәт аның башы әйләнә, күңеле болгана башлады. Ул торган җирендә чак-чак кына егылып китмәде. Комбайн ераклашкач та, колак төбендә һаман мотор тавышы үкереп торды, борынына арыш, кибәк исе белән бергә бензин исе, кызу газ исе килде, бөтен тәнен кылчык, кибәк кытыклады. Аның күлмәкләре, чалбарлары майлы тузанга буялып беткән иде.

«Менә сиңа комбайн!»— диде ул, нәрсәгәдер үкенгән шикелле, күңел кайту кебек бер нәрсә тоеп һәм алпантилпән атлап, авылга кайтып китте. «Менә сиңа комбайн!— диде ул тагын да, кем беләндер сөйләшкән кебек.— Юк, икенче мин анда ике аягымның берен дә атламыйм!»

Өйдә аны Гасыйм хаты көтеп тора иде. «Нишләп миңа язмакчы булды икән соң бу?— диде Сәгыйть үз-үзенә, гаҗәпсенеп. Аларның әле беркайчан да бер-берсенә хат язышканнары юк иде.— Яңадан дуслык бозылып-нитеп китә күрмәсен дип курыкты микәнни?»

Хат бик озын язылган иде һәм чыннан да бик ягымлы тонда, дуслык, сердәшлек тонында язылган иде. Гасыйм үзенең кайткач та пионер лагеренда вожатый булып эшләве турында, бик әйбәт ял итүе, биш килога артуы, хәзер транспорт бригадасында грузчик булып йөрүе һәм соңгы көннәрдә үзенең ни өчендер тынычсыз булуы турында язган иде. Аннан соң ул Сәгыйтьнең үзе турында,

нишләве, вакытын ничек уздыруы турында төпченеп сораштырган иде.

Хатта Ида турында да, Бәхти турында да бер генә сүз дә юк иде.

«Ярый инде, кызлар язмаса да, егетләр онытмый икән әле»,— диде Сәгыйть үзалдына, күңелсез генә көлемсерәп. Ул шундук аңа җавап язарга утырды һәм Гасыймның үзе кебек үк бик озын итеп, бик киң җәелеп язды. Ида турында, аннан бернинди хәбәр-хәтер булмавы турында бернәрсә дә әйтмәде.

Икенче көнне ул тагын Барислар янына китеп барды.

Барис комбайнында Гөлсем салам ташлатучы булып эшли иде. Сәгыйть өстә тагын әзрәк утырып йөрде дә, комбайн артыннан тагылган салам җыйгыч арбага, Гөлсем янына менеп басты.

Гөлсем, арбаның икенче ягындагы икенче бер кыз кебек үк, озын саплы сәнәге белән арба төбенә җайлап салам түшәп бара иде. Ул противогаздан кисеп алынган күзлек кигән, тузан, кибәк кермәсен өчен авызларын, борыннарын томалап, яулык белән бәйләп бетергән иде.

Сәгыйтьне күргәч тә, Гөлсем, сәнәген селтәп:

— Әллә баедың, ристан?— дип кычкырды.— Кичә борылып та карамады, ыстудин иптәш.— Ул аның кулына сәнәген тоттырды.— Селкенеп җөрмә юкка! Бик тиз койрыкны сыртка салгансың. Тукта, алай ярамый ул...

Сәгыйть, Гөлсемнең үзе кебек үк шундый кырт-мырт сүзләр әйткәләп, сәнәкне җайлап тотты да, арба төбенә коелып барган вак, сары саламны әвеш-түеш китерергә керешге.

Арба бөтенләй салам белән тулгач һәм элек ташлатып калдырылган салам өемнәре турысына килеп җиткәч, Сәгыйтьнең ничек эшләвен көлемсерәп карап барган Гөлсем аягы белән бер тимергә җиңелчә генә басты, һәм арба төбе кинәт ачылып та китте, дүрт почмаклы чүмәлә формасындагы салам өеме сизелмичә генә шуышып төшеп тә калды.

— Ни эшләр җимертәсең хәзер? Ике кулың кесәдә инде-ни синең,— диде Гөлсем, яулыгын чишеп ташлап, күз төпләрендәге тузаннарын яулык очы белән сөртәсөртә.— Донҗада ни хәлләр бар соң? Син булмагач, даклат сөйләүче кеше дә юк, гәзит укучы да юк хәзер...

— Нәрсә?— диде Сәгыйть, ишетмичә, һәм эшеннән туктады да, Гөлсемнең сүзләрен аңламакчы булып, аның янынарак килде. Шул чакны ул аның кулында түгәрәк көзге күреп алды.

— Көзге!— дип кычкырды ул кинәт һәм сорап-нитеп

тормыйча аның кулыннан көзгесен тартып алды да, сәнәген үзенә тоттырып, аска төшеп йөгерде.

Гөлсем башта аптырап калды, аннан соң ачусыз гына кычкырырга тотынды:

— Нишләвең бу, ристан?! Кара, Ярулла абзаңа әйтсәм!

Сәгыйть трактор алдына йөгереп килде. Тракторчы егет, аның кул болгавын күреп, тракторын туктатты һәм Сәгыйть кабинага кереп утыргач, аңа бөтенләй игътибар бирмичә, артына яртылаш борылган көе, һаман комбайнга карап баруында булды.

— Берәр нәрсә күрәсеңме?— диде Сәгыйть, кулындагы түгәрәк көзгене аның каршысына, алгы пыяла турысына якын китереп.

Тракторчы егет башта берни аңламады. Сәгыйть аңа көзге аша комбайн хедерына карарга кушты. Егет, уң кулын рульдән ычкындырмыйча, сул кулына көзгене алды һәм аны җайлап, турылап, үзе каршысында тотып бара башлады. Кинәт аның кырыс йөзе йомшарып китте: көзгедә уракның арыш читеннән чыгып барган өлеше, әвернәнең яртысы, зырылдап әйләнүче тәгәрмәчләр, чылбырлар шул көе күренә иде.

— Автомашинадагы шикелле итеп куйсаң, ә?— диде Сәгыйть.— Сиңа гел артка карап барырга туры килә бит... Тулысынча алдырып та булмый... Муенның авыртып бетә торгандыр әле?

— Авырта инде ул,— диде егет, аның нәрсә эшләмәкче булуын аңлап алып.— Ләкин... беркетер җир юк... Шулай да уйлап карарга була. Барис белән сөйләшеп карарбыз әле.

— Була, ник булмасын!— диде Сәгыйть, куанып.

## IV

Быел җәй бик коры килде. Көне буе туктаусыз кояш кыздырды, бөтен җир куырылды, көйде, янды. Юллар тузан елгасына әйләнде, һәм кызу чабып узган автомашиналар артыннан берәр чакрымга талкан кебек коры, соргылт, җиңел тузан койрыгы сузылып калды. Иген басулары, чокыр-чакырлар, әрәмәләр өстендә ялтырап, дулкынланып, туктаусыз рәшә тирбәлде, эссе, коры һава чыңлап торды, һәм бер шырпы сызып җибәрдең исә, бөтен җир өсте, бөтен күк йөзе гөлт итеп кабынып китәр төсле тоелды. Тамакларга тыгыла торган, күзгә керә торган бу эсселек, бу бөркүлек кичләрен дә кимемәде, киресенчә, кипкән, чатнап ярылган җир өстеннән куе караңгылык белән бергә кайнар бу күтәрелә кебек тоелды.

Бөтен табигатькә җан өреп җибәрү өчен, вакытсыз куырылган бәрәңгеләрне, яшелчәләрне яшелләндерү һәм корый башлаган чишмәләрне гөрләтеп җибәрү өчен, көне буе кызу кояш астында тир түгеп эшләгән, әлсерәгән кешеләрне тын алдыру һәм кибеккән хайваннарга көч бирү өчен яңгыр кирәк иде. Ләкин яңгыр һаман яумады. Дәһшәтле кызулык бик озакка сузылды. Бу хәл һәркемне пошындырды, һәркемне шомландырды.

Барис бөтенләй танымаслык булып үзгәрде: ябыкты, тузанга, майга манчып алган кебек карайды, кояшта янды. Сәгыйть тәкъдим иткәнчә, тракторга автомашиналардагы кебек итеп күзгә кую турындагы уй аңа да ошады. Нәкъ тракторчы алдыннан, алгы тәрәзә янынарак, кабина түбәсен тиштеләр дә, МТС мастерскоенда эшләп алып кайткан махсус сапка ялганган дүрт почмаклы көзгене шунда беркетеп куйдылар. Тракторчы егет комбайнны элеккегә караганда тигезрәк йөртә башлады, урак бөтен киңлегенә урды, Барис хәзер үзенең бүтән көннәргә караганда гектар исәбен дә ярыйсы гына арттыра башлаганын күрде.

Өченче бригаданың арышы бик тиз кимеде. Ләкин арыш артыннан ук арпа җитеште, бодай, солы саргая башлады, борчакны алыр вакыт җитте. Берсе артыннан берсе килеп тыгылды. Пошынырлык, кайгырырлык нәрсә бар иде монда!

Урылган һәрбер сотый, һәрбер гектар алтын хакына бәяләнгән шушындый вакытта, чөй өстенә тукмак дигән шикелле, әледән-әле Рәшитнең комбайны ватылды. Бер сәгать урса, ике сәгать туктап торды, төшкә кадәр урса, төштән соң тагын кырылып ятты. Ләкин шулай булса да урыштыра иде әле, кискән җирдә үсеп калмый, ашлыгы да ындыр табагына китә бара иде. Бүген ул бөтенләй туктап калды. Бүтән чакта йә чылбыры ычкына, йә суккыч аппаратның берәр җире кырыла, салам тыгыла, һәм андый вак-төякне рәтләве дә әллә ни авыр булмый торган иде. Бүген исә аңа бөтен моторны сүтеп ташларга туры килде. Ул ярты көн шуның белән маташты, пычранып бетте, үртәлде, ачуы килде. Ләкин барыбер сернең нәрсәдә икәненә төшенә алмады.

Барыннан да бигрәк, аның МТС башлыкларына, иң элек — директорга ачуы килде. Ничек ачуың килмәсен — бу «Коммунар»ны хәзер чүплеккә генә ташлыйсы бар. Алар аңа шундый гарип-горәбә машина тоттырып чыгардылар. Әнә Барислар, Хәсәннәр заводтан гына килгән, туп-туры вагоннан гына төшкән өр-яңа «Сталинец-6»га гына утырып йөриләр. Алар урмый, кем урсын! Яңа

машинага теләсә кемне утырт — барыбер урыр... Корал эшләр, ир мактаныр, ди! Никадәр сорап йөрде, директорның да, инженерның да ишек төбен таптап бетерде, «Сталинец-6» булмаса булмас, ярар, һич югы, самоходка бирегез, диде. Бирмәделәр.

Рәшит мәсьәләнең монда бары машинада гына түгел икәнен башына да китереп карамады. Ул, машина үзе эшли, мин эшләмим, дип уйлады һәм «Коммунар»ының бик еш ватылуында бары тик машинаны гына гаепләде. Хәер, аның начар эшләве өчен ул күңеленнән хәтта сөенеп тә куйды. «Менә әйттем мин аларга, беткән нәрсә инде бу, дип, аның белән берни эш чыгарып булмас, дип!.. Җәрингә барыбер яңа «Сталинең» алырмын!»— диде ул.

Комбайнда ул нибары икенче генә ел эшли иде, шуңа күрә аның Барисларныкы кебек тәҗрибәсе дә, осталыгы да җитәрлек түгел иде. Аннан соң аны рәтләп укытып, өйрәтеп тә тормадылар. Бер ел ярдәмче булып, комбинезон каралтып, кулын-битен пычратып йөрде дә, икенче елны ук аны, кеше булмаганга, иске «Коммунар»га утыртып чыгардылар.

Комбайнның рәте киткәч тә, аның инде тиз генә кузгалып китмәячәген белеп, трактор шундук икенче як басуга чыгып китте. Рәшит кояш түбәнәя башлаганчы «Коммунар»ы янында булашты да, телефоннан МТСка шалтыратмакчы булып, авылга кайтып китте. «Кирәк чакта аның механиклары-фәләннәре дә килеп чыкмый бит, бүтән вакытта директоры да килә, тегесе дә килә, монысы да килә — теңкәгә тиеп бетәләр»,— дип уйлады ул. Ләкин телефоннан сөйләшкәч тә, бернинди рәт чыкмады — анда, конторада, аңа кирәкле беркем юк иде, барысы да диярлек авылларга, трактор бригадаларына чыгып киткәннәр иде. Бүген, җитмәсә, үзләренең бригадиры да икенче авылда иде. Рәшит, йөреп-йөреп тә юлы уңмагач, бөтенесенә кулын селтәде дә, комбайнның тик утыруына күңелендә аклану кебек бер нәрсә тойган хәлдә, өенә кайтып китте.

Кайткач, бераз йокы симертеп алды, ныгытып юынды, чистарынды да кич чыгып китте. Аның инде күптән Зәйтүнәне күргәне юк иде.

Кичкә таба көнбатыш яктан, түбәннән генә, аскы читләре көмеш кебек ялтырап торган тыгыз, кара болытлар калкып чыкты. Болыт туп-туры авылга таба шуышты, зурайды: төсен, формасын үзгәртте, төрле кисәкләргә бүлгәләнде, ерткаланды да, нindидер дәһшәтле кабалану белән кабаланып, ашыга-ашыга як-якка таралды. Бераз-

дан бөтен түбә өстен бер-берсенә бәрелеп шартларга, очкыннар чәчеп, җир өстенә яшен уклары атарга әзер торган кыймылдаучан кисәк-кисәк кара болытлар каплап алды. Кошлар — сайраудан, этләр өрүдән туктап, тынып калды. Җир өстендәге бөтен җанлы нәрсә, менә хәзер тиздән нәрсә дә булса буласын көтеп, түземсез борчылу белән, тыннарын да алмыйча, сагаеп, югарыдагы ыгы-зыгыны тыңларга тотынды. Кинәт лапас кыегындагы басылган иске саламны куптарып, агач башларын ыжгыртып һәм киртәгә элеп куйган керләрне очыртып, дымлы, көчле җил исеп китте. Җиргә шапылдап каяндыр такта кисәкләре килеп төште; юлда, каз мамыкларын, салам кисәкләрен эләктереп, тузан өермәсе күтәрелде; телефон, электр чыбыклары, ачулы чайкалып, уларга, сызгырырга тотындылар. Җил ачык тәрәзә аша өйгә килеп керде, өстәл өстенә җәелгән ашъяулык итәкләрен тирбәтеп куйды, озын сабаклы гөл яфракларына тиеп үтте дә, өй эченә ниндидер кирәкле, әһәмиятле һәм күптән инде көтелгән нәрсә буласын сиздерүче ис таратып, караңгы почмакларда тынып калды.

— Ай Алла!— диде Миңнисәттәй.— Яңгыр килә түгелме соң? Бәрәкәте белән генә булсынчы... Ай Алла, мендәрләрем чыланадыр инде. Сәгыйть, бүрәнәләр өстенә куйган мендәрләрне генә алып кер әле!

Ләкин үзе, Сәгыйтьнең мендәрләрне алып керүен-кермәвен көтеп тормыйча, елап утырган Тәлгатьне идән уртасында калдырып, шундук тышка чыгып йөгерде. Сәгыйть утынлыкта утын кисә иде.

— Куркытып йөрмәле яңгырны, әнкәй... Яумый ул барыбер.

Яңгыр чынлап та яварлык түгел иде, ниндидер кысыр, ләкин шулай да көчле, тыелгысыз җилләү генә иде бу.

Сәгыйть клубка китте.

Уракның уты чыгып торган чак булса да, авыл яшьләренең күбесенә хәзер иртәнге таңнан кичке караңгыга кадәр эшләргә туры килсә дә, кич клубта беркайчан да кеше өзелеп тормый иде. Бүген дә монда яшьләр күп иде.

Китап алып-биреп утырган Нәсим аның белән исәнләште дә:

— Әһә, җугалган мал! Ташладың син безне. Ни... кайда җөрисең?— диде.

Сәгыйть газета-журнал карарга утыргач, мәгънәле генә итеп әйтеп куйды:

— Мине күрми китә күрмәде, бер сүзем бар сиңа,— диде.

Сәгыйть рәхәтләнеп, онытылып укырга тотынды. Аның инде күптән берни укыганы юк иде. Ул яңа газеталарның берничә номерына күз төшереп алгач та, үзен озак кына күрешми торган якын дусы белән очрашкан кебек итеп, үз алдында ачылган тәрәзә аша якты, киң дөньяга карый башлаган кебек итеп хис итте.

Бер ярты сәгать чамасы утыргач, ул үзенең колак төбендә генә:

— «Тихий Дон» җукмы?— дигән тавыш ишетте һәм тиз генә Нәсим ягына күтәрелеп карады.

Аның «Тихий Дон»ны сораучының кем икәнен беләсе килде. Нәсим алдында ачулы да, артык җитди дә күренгән кыяфәтле бер яшь егет басып тора иде. Аның өсте-башы бик үк шәптән түгел иде, һәм җир сөргәндә еш кына очрый торган яшен ташы кебек кытыршы, каты битен җил кисеп, кояш ашап бетергән иде. Аны студент дип тә, авыл интеллигенты дип тә булмый иде. Сәгыйть элек аны кайдадыр күргәндәй булды, ләкин — кайда?— һич кенә дә хәтерли алмады.

— «Тихий Дон»?— диде ул егеткә, бераз гаҗәпләнгән тонда.— «Тихий Дон»ның татарчасы юк бит әле.

Егет, әллә аның сүзен бөтенләй ишетмәде, әллә сорауның үзенә бирелгәнен аңламады — берни эндәшмичә, өстәл каршысында басып тик торды. Аның өчен Нәсим җавап бирде:

— Безнең Сафа маладис!— диде ул, егетне чын күңелдән мактап.— Урысчаны да, татарчаны да шатырдатып укый. «Тихий Дон» җук — кулда. Шәриф Камал кайтты, кирәкме?.. Бездә иң күп укыган кеше — Сафа. Биримме?

— Ә-ә!— диде Сәгыйть, кинәт исенә төшереп.

Ул аны печәнгә барганда күргән иде. Сафа чикләвек куагы төбендә башын да калкытмыйча, бер калын китап укып утыра иде, аның янында сыерлар ашанып йөри иде. Ул чакта Сәгыйтькә бу күренеш бик гаҗәп, бик сәер тоелган иде. Ни әйтсәң дә, моңарчы аңа беркайчан да көтүчеләрнең китап укып йөргәнен очратырга туры килмәгән иде.

— Теге... синмени әле ул куак төбендә китап укып утыручы?— диде Сәгыйть.

Сафа, телсез кеше кебек, монысында да берни җавап бирмәде. Аңа тагын икенче кеше ярдәмгә килде.

— Безнең Сафа үзе китап укый, сыерларына гәҗит укыта!— диде Рәшит, авызын ерып.

Ул әле генә килеп кергән һәм Сәгыйть белән Сафа арасындагы сүзне ишетеп калган иде.

Өстәл янындагылар Рәшитнең сүзенә шаулашып көләргә тотындылар, чөнки «гәҗит укыта» дигән сүз бу очракта сыерларны бер җиргә җыеп, ашатмый торгыза, ач тота дигән мәгънәне аңлата иде. Сәгыйть тә ирексездән елмаеп куйды. Рәшитнең яшьләрне, бигрәк тә үзенә каршы гына утырган Зәйтүнәне көлдерә алуына бик кәефе килде. Ул тагын көлә-көлә нидер әйтте — Сәгыйть анысын ишетмәде. Көлү тавышы басыла төшкәч, Сафа, ирләрчә калын тавыш белән кырт кисеп:

— Синең камбаеның журналга тотынган бугай,— диде,— бер әйләнә дә көне буе утыра.

Бүлмә эчен яңгыратып тагын көләргә тотындылар. Хәзер инде шаян күз караշлары Рәшит ягына борылды. Көтмәгәндә авызы йомылган Рәшит телсез-өнсез калды, як-ягына каранды, тик шулай да елмаюыннан туктамады. Ләкин бу инде тантаналы, батыр елмаю түгел иде.

— Нәрсә, нәрсә?— диде ул, кисәк кенә исенә килеп, кызарынып.

Аннан тагын алып-биреп көләргә тотындылар.

— Бир кирәген шуның, Рәшит!

— Нәрсә мытыес кешеләрен мыскыллый ул!

— Нәрсә икәнен каян белим мин аның!— диде көтүче егет җиңүче төс белән.— Бар, эстинә гәзитәсеннән сора — ул әйтер. Яхшы чәпегәннәр үзеңне.

— Нинди гәзит? Нәрсә лыгырдыйсың, бүтәкә?

Оятыннан, ачуыннан хәзер дөрләп китәргә әзер торган Рәшитнең кинәт кашлары җыерылды. Кемдер тиз генә аның костюм итәгеннән тартты, икенчесе көлә-көлә беләгеннән тотып алды, һәм, көчләп диярлек өстерәп, аны стена газетасы кадакланып куелган почмакка алып киттеләр.

— Син әле күрмәдеңмени? Әйдәле, әйдә...

— Кая, кая?— дигән булды Рәшит, газета каршысына килеп туктагач, ясалма көр, шат тавыш белән.

Газета әле бүген генә, кич кенә чыгарылган иде, һәм Рәшит аны чыннан да күрергә өлгермәгән иде. Газетаның соңгы баганасына, аска, зур тәгәрмәче төшеп калган комбайн өстендә аякларын күккә күтәреп ятучы Рәшит карикатурасы төшерелгән иде, аның авызыннан тәмәке төтене шикелле булып чыккан куык эченә: «Тәгәрмәч табылса, мин дә урыр идем дә бит!»— дигән сүзләр язып куелган иде.

Рәшитне уратып алган егетләр, малай-шалайлар, тегене үртәп, юри ачуын китерергә тырышып, газетага төртеп күрсәтә-күрсәтә, кычкырып көлешергә тотындылар.

— Илла да шәп ясаган соң!
— Кешесен әйт әле син, кешесен — нәкъ үзе!
— Тәгәрмәчең табылдымы соң әле синең, яшьтәш?
Рәшит үзенең карикатурасына үзгәргән, кызганыч йөз белән карап торды торды да, һаман көчәнеп елмайган көе:
— Абзаңның... даны таралды!.. Шәп...— диде, тотлыга-тотлыга.
Шуның белән котылып та калды — көлешү әкренләп басыла төште, аның тирәсендәгеләр таралып бетте. Рәшит кинәт басылып, тынып калды. Ул куркып кына, сиздермичә генә Зәйтүнә ягына карап алды. Зәйтүнә аңа арты белән тора иде. Шулай да бүген аны күрергә, бернигә карамыйча тәвәккәлләргә һәм аңа һич югы бер генә сүз булса да әйтергә кирәк иде.

## V

— Нинди яңалыгың бар тагы?— диде Сәгыйть.
Нәсим, урыныннан кузгалмыйча гына, тәрәзә төбенә үрелеп, аннан Сәгыйтькә «Комсомольская правда»ның бер номерын алып бирде. Өченче биттәге бер кыска гына мәкаләгә төртеп күрсәтте дә:
— Укы!— диде.
Сәгыйтьнең йөзендә кинәт куаныч һәм шул ук вакытта кызыксыну билгесе күренде. Ул, үз күзенә үзе ышанмыйча, мәкаләне ике-өч кат укып чыкты. Көтелмәгән бу шатлыктан аның йөрәге кисәк кенә туктап калган шикелле булды. Мәкаләдә Идалар районы турында, җәйге каникулга кайткан студентларның агитбригада оештырулары, урак вакытында авылларда концертлар куеп йөрүләре турында язылган иде! Мәкалә бик кыска булганга, анда беркемнең дә исем-фамилиясе телгә алынмаган иде. Ләкин Сәгыйть Иданың да шул ук агитбригадада булуына һич тә шикләнмәде. Менә кайда икән ул, менә нишләп йөри икән ул!.. Аларның районы, студентлар агитбригадасы — ул да булмагач анда, кем булсын!..
Ул аның белән очрашкан, сөйләшкән кебек булды. Ул шатлыгыннан хәзер бөтен кеше алдына чыгып,— белсә дә, белмәсә дә,— дөнья җимертеп биергә, әллә нәрсәләр эшләп ташларга әзер иде.
— Син... син... каян белдең аны?— диде ул, сизелерсизелмәс кенә кызарынып. Аңа, Нәсим Ида турында да, Иданың һаман аңа хат язмавы һәм үзенең гел аның хакында гына уйлавы турында да — барысын да беләдер шикелле тоелды. Ләкин ул үзенең ялган куркаклыгын,

оялчанлыгын шундук җиңде; аның күңелен үзенең шундый кызы булган өчен һәм бу турыда инде авылдашларының да белеп алуы өчен горурлану тойгысы биләп алды. Аның хәзер Ида турында һәркемгә кычкырып сөйлисе килде.

— Ни... нәрсәсен беләсең инде аның?— диде Нәсим.— Укып чыктыңмы соң?

— Ә?! Белмисең алайса?

— Әллә тагы... Укыдыңмы соң? Мин әйтәм, әллә без дә шулар кебек итәбезме, дим... Студентлар безнең авылда да җитәрлек, син хәзер даклат сөйли беләсең... Ни... кирәк икән, үзебезнең яшьләрне дә алырбыз...

— Доклад?— диде Сәгыйть, Нәсимнең сүзен бөтенләй аңламаган кебек.— Доклад сөйләргәме? Була ул! Сөйлибез! Әзерлибез! Оештырабыз!

Ул хәзер теләсә нәрсәгә риза була ала, теләсә кем белән килешә ала, теләсә кемнең сүзен тыңлый ала иде.

— Мин кирәкле кешеләргә әйттем,— диде Нәсим.— Соңыннан монда бер ярты сәгатькә калып сөйләшик әле. Ни... китмә инде син...

Ишек төбенә якын гына куелган бер скамьяда, кызлар арасында Зәйтүнә утыра иде. Ул инде баядан бирле үзе иптәшләре белән сөйләшкән була, үзе һаман, ачыктан-ачык сиздереп, күршесе студент ягына караштырып ала иде.

Сәгыйть тә аны күреп алды. Кызлар янына килде дә барысы белән дә кычкырып исәнләште. Зәйтүнә шундук күзен түбән иде. Сәгыйть, кыю гына кыланып, кызлар уртасына утырды. Аның кем белән булса да сөйләшәсе, эчендәге шундый күп, шундый зур шатлыгын кемгә булса да түгәсе килә иде.

Зәйтүнәнең кара, матур күз керфекләре сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп куйды. Аның болай да кара-кучкыл бите, көне буе кояшта йөргәнгә, тагын да ныграк янып, шоколад төсенә кергән, тагын да ныграк нәфисләнгән, чистарган иде, һәм Сәгыйтькә аның яшь йөзеннән, гәүдәсенә бик килешеп торган ак, чиста күлмәгеннән, ачык түгәрәк муеныннан көндезге кояш ялкыны бәреп тора, яңа арыш, камыл исе килә шикелле тоелды.

— Кая медалең?— диде ул, күршесенең түшенә карап.

Зәйтүнәнең унынчы классны бик әйбәт бетерүен һәм көмеш медаль алуга кандидат булуын ул күптән белә иде. Унынчы класс укучылары имтиханнарын тапшырып бетергәнче үк, имтиханнарның тулы нәтиҗәсе бил-

геле булганчы ук инде авыл халкы Зәйтүнә турында шаулаша башлаган иде.

Зәйтүнә аның күз карашыннан тагын да ныграк уңайсызлангандай булды, шулай да башын югары күтәрде дә, көлеп:

— Миңа дигән медаль эшләнмәгән әле,— диде.

— Нәрсә, әллә бирмәделәр? Бирми генә карасыннар, үземә генә әйт...

— Аттестаты килде, медале генә юк...

— Ә! Алай дисәң генә! Котны алдың, күрше, бөтен авылга бердәнбер кеше бит син безнең. Юк, чынлап. Авылда гына түгел, бөтен районда... Котлыйм, алайса, көмеш медаль кавалеры!— Ләкин кинәт тукталып калды да, үз сүзенең дөреслегенә үзе үк шикләнгән шикелле, әйтеп куйды: — Кавалеры? Кызлар кавалер буламыни? Күрше кавалер буламыни? Кит аннан, минем күрше нишләп кавалер булсын! Алайса, көмеш медаль барышнясы, котлыйм сезне!..

Зәйтүнә, ак, тигез тешләрен күрсәтеп, шундый эчкерсез, шундый чын көлү белән көлеп җибәрде, һәм көлгән чакта аның сизелер-сизелмәс кенә булып кулбашлары селкенде, ак якалары тирбәлеп куйды.

— Нишләп мин барышня булыйм!

— Нигә, ярамыймыни? Алайса — көмеш медаль туташы! Ярыймы?

— Уф, үләм!.. Әллә нинди барышнялар, туташлар...

— Ах, сезгә туташ та ошамый?! Юк, туташ та түгел, барышня да түгел, алайса көмеш медальле Зәйтүнә! Әллә монысы да ярамый?

Сәгыйть үзенең ни сәбәптән куана башлаганын да онытты. Кызлар янында аңа бик күңелле иде.

Яшьләр таралыша башладылар. Нәсим калырга кушкан кешеләр өстәл тирәсенә җыелдылар.

Сүзнең нәрсә турында барасын һәркем алдан белә иде, шулай да Нәсим, учына йөткерә-йөткерә, үзенең тәкъдимен тагын бер кат сөйләп чыкты. Аңа беркем дә каршы килмәде, киресенчә, аның тәкъдимен бик хуплап, бик яратып каршы алдылар.

Монда барлыгы биш студент бар иде. Шуларның икесе мех техникумы студентлары, Сәгыйтьтән кала икесе — педагогия һәм технология институтларыннан иде. Билгеле, авылда студентлар алар гына түгел иде, алардан башка тагын бүтән вузларда, бүтән техникумнарда укучылар да җитәрлек иде. Ләкин болары — студентларның да җырларга, биергә иң һәвәсләре һәм шуның өстенә — шушы ук клубның элекке активистлары иде.

Алар кайчан, ничек әзерләнү, нинди номерлар әзерләү турында бик җанланып сөйләштеләр, киңәштеләр. Ләкин биш кешедән генә тулы бер бригада оештырып булмаячак иде. Шуңа күрә авыл яшьләреннән тагын өч кешене өстәделәр. Аларның берсе — Зәйтүнә, калган икесе колхоз яшьләре иде. Җитәкче ролен Нәсим үз өстенә алды. Сәгыйтькә берәр темага лекция әзерләргә куштылар. Концертны кайда кую мәсьәләсендә әз генә сүз булып алды. Кайберәүләр әйтте, хәзер колхозда кызу эш вакыты, чит авылларга чыгып йөреп булмас, үзебездә генә бер-ике концерт куярбыз да, шуның белән җитеп торыр, диделәр. Ләкин Нәсимнең ничек тә бүтән авылларга да чыгасы килде. «Студентлар агитбригадасы! Исеме ни тора!— диде ул һәм оялчан гына өстәп куйды,— мин дә бит студент буласы кеше».

Иң соңыннан шуңа килештеләр: башта үзебездә генә куярбыз, мөмкин булса, көндез кырга, колхозчылар янына да барырбыз, диделәр, әгәр инде концерт шәп чыга икән, ул чакта, җитәкчеләрдән рөхсәт сорап, күршеләргә дә барып кайтырга булыр, диделәр.

Сәгыйть бәхәскә бик үк катнашмады, аның өчен хәзер бөтен нәрсә хәл кылынган иде, бер генә нәрсәне дә тикшереп, төпченеп торасы юк иде.

Ул Ида турында уйлады. Ул аның сәхнәгә чыгып җырлавын йә биюен күз алдына китерергә тырышты. Ләкин биегәндә ул мондагы авыл кызларының берсе булып, җырлаганда Зәйтүнә булып күренде, чөнки аның беркайчан да Иданың җырлаганын да, биегәнен дә күргәне юк иде. Ул аның тавышын ишеткәндәй булды, ләкин бу тавыш аның тавышына охшамаганниндидер чит тавыш иде. Шуннан соң аның күз алдыннан экранда бер-бер артлы алмашынып торган кадрлар сыман, Кабан күлендә көймәдә йөрү күренешләре, Иданың ак эшләпәсе, Идел өстендәге ямьсез болытлар узды.

Кинәт ул, кемдер арттан килеп куркыткан кебек, дерт итеп китте. Аның күңеленә бер коточкыч уй килде. Ул Иданың ни өчен берninди җавап бирмәвенең серенә төшенгәндәй булды.

Студентлар агитбригадасы, димәк, анда егетләр дә бар дигән сүз! Ул анда үзләренең берәр авылдашы белән, берәр «артист» студент белән мавыга, шуның белән күңел ача! Алар бергәләп концерт куеп йөриләр, алар икәүләшеп бииләр, берсе гашыйк егет, икенчесе гашыйк кыз булып, сәхнәдә бер-берсен үбешәләр! Бер-берсен кочаклыйлар! Әһә, менә ни өчен язмый ул! Менә ни өчен аның вакыты юк!..

Сәгыйть катты да калды. Бу инде элекке вакытлардагы кебек билгесез, газаплы шикләнүләр дә, вак-төяк икеләнүләр дә түгел, бу инде аның өчен хәзер исбат ителгән, ачыкланган хакыйкать, бернинди шик, икеләнү катышмаган хакыйкать иде. Мондый ачыш алдында ул сукыраеп, миңгерәүләнеп калгандай булды. Аның хәзер үк чыгып китәсе килде, хәзер үк аның янына барасы, йөгереп, очып барасы килде, ул ниндидер «артист» белән биегән чакта, алар бер-берсен үпкән чакта аны үз куллары белән буып үтерәсе килде. Аның бөтен дөньяның астын-өскә әйләндерәсе, тау-ташлар җимерәсе, бөтен кешене, бөтен авыл-шәһәрләрне кырып, сыпырып ташлыйсы килде. Аның мондый хыянәте белән дөньяда бер генә нәрсә дә тиңләшә алмый кебек иде. Аның тыны кысылды — ул болай да яртылаш ачык изүен бөтенләй ычкындырып җибәрде.

— ...Алайса иртәгә беребез дә соңга калмый җыелабыз,— диде Нәсим, сөйләшү-киңәшүне беткәнгә санап.— Мин сиңа, Сәгыйть, даклат өчен тема әзерләрмен... Бәлки, үзең дә табарсың... Ни телисең... Булды алайса?

Сәгыйть аны аңламады. Ул, бүтәннәр кузгала башлагач, башын түбән иеп, кешеләр артыннан ишеккә юнәлде. Баскыч төбендә, караңгыда, ул үзе янында гына:

— Сәгыйть абый...— дигән кыюсыз тавыш ишетеп, туктап калды.

— Ә?.. Зәйтүнә...

— Үзегез... күрше дә күрше дигән буласыз... үзегез көтми дә кайтып барасыз...

Сәгыйть кинәт ниндидер куркыныч нәрсәдән айный башлаган кебек булды һәм, үзенең нишләгәнен үзе дә сизмәстән, ипләп кенә кызны култыклап алды.

— Җитәкләмәгез, мин сукыр түгел, Сәгыйть абый,— диде Зәйтүнә, көлеп, ләкин үзе һич тә беләген ычкындырырга ашыкмады.

— Кара... Әле генә Сәгыйть абыйсыннан башка кайталмыйдырые... Нинди батырайган...— диде Сәгыйть көчәнеп кенә, шаяртмакчы булып.

— Сезнең белән кайткач... батыраймый ни!

Алар урамга чыктылар. Сәгыйть, үз янында хатын-кыз барлыгын, үзенең шундый әйбәт, шундый яшь, сылу күршесе барлыгын тоеп, әкренләп тынычлана барды. Аңа аек фикер йөртә алу сәләте кайтты.

Бәлки, алай да түгелдер әле, бәлки, бу да — көнләшү, сагыш нәтиҗәсендә туган гадәттәге ялган шикләнү генәдер. Аһ, шулай гына булсачы!

Ул үз-үзен шуңа ышандырырга тырыша башлады. Ул

үзе уйлап тапкан шикләнүне шулай ук үзе уйлап тапкан икенче шикләнү белән беренчесенә капма-каршы булган шикләнү белән юкка чыгарырга тырышты. Ул инде аны хыянәте өчен кичерергә дә, теләсә нәрсә уйлаганы өчен үз-үзен тиргәргә дә әзер иде, әмма аның күз алдына шундук бүген укыган мәкалә килеп басты, баштагы «исбатланган хакыйкать»— шикләнү шундый аермачык булып, шундый аяусыз булып яңадан күңелен телгәләргә керешге. Аның хәзер Идага нинди дә булса начарлык эшлисе, аннан коточкыч үч аласы килде. «Бик әйбәт! Шулай кирәк сиңа!»— диде ул күңеленнән, Идага эндәшкән кебек һәм Зәйтүнәнең беләген үзенә якынрак кысты, әйтерсең аның шулай икенче кыз белән култыклашып кайтып баруын Ида караңгылык аша күреп тора һәм аларны шулай күрү аңа бик авыр, ифрат та авыр иде. Сәгыйть тантана итте: «Бик шәп! Бик шәп!»

Төн бик караңгы иде. Яңгыр яумаган иде. Ләкин һавада һаман яңгыр исе килде, тупылларның эре яфракларын шаулатып, басу ягыннан дымсу, җылымса җил исте. Еракгагы болыт читләрен елтыр-кызгылт ялкын белән көйдереп, яшен уты ялтырап китте. Кайдадыр күк читендә, күңелгә шомлы сер салып күк күкрәде. Күкрәү тавышы, гөрелдәп тәгәри-тәгәри, бераздан караңгы бушлыкка кереп югалды. Аннан соң бөтенләй икенче якта тагын яктырып-яктырып алды. Тирә-якның шулай тавыш-тынсыз ялт-йолт килүендә, бөтен күкнең шулай әледән-әле гөрселдәп торуында ниндидер яшерен мәгънә бар иде, һәм җир өстендәгеләргә ул нәрсә турындадыр хәбәр итә иде, тик әлегә аның нәрсә турында сөйләгәнен генә белеп булмый кебек иде.

Алар, күк күкрәвенә колак салып, һәрберсе үз уена бирелгән хәлдә, бераз җир сүзсез генә атладылар. Беренче булып Сәгыйть башлады.

— Уракка йөрисеңме, күрше?— диде ул, тыныч булырга тырышып.

— Әйе...— Зәйтүнә тамагын кырып куйды.— Уракта... әнкәй белән... Сез дә бит бүтән җылларны урак урадырыегыз кайткач...

— Быел да урам мин,— диде Сәгыйть, юри мактанган төсле итеп.— Камбаен белән!

— Тәгъзимә әйткәние шул, камбаенга авыр итеп Сәгыйть абый да утырып җөри, дип!— Зәйтүнә яңадан күңелләләнеп китте.

— Алай гайбәт сатып йөрсә, барсын әле, колагын борырмын әле мин аның!

— Мин әйтте дип кенә әйтмәгез...

Бераз тын гына бардылар. Сәгыйть җитди тонда сорап куйды:

— Мин бит инде синең белән күптән сөйләшергә дип йөрим. Мәктәпне бетердең бетерүен, медаль дә булды — укырга кая китәргә уйлыйсың соң син?

— Ныклап уйлаган җук әле,— диде Зәйтүнә, бераз көттереп.

— Ничек инде — ныклап уйлаган юк! Дакументларың әзерме соң?

— Әзер... Барысы да әзер.

— Сорап торам тагын: кая китәсең! Консерваториягәдер инде, артист булыргадыр. Шулаймы?

— Артист?— диде Зәйтүнә, бу сүзне беренче мәртәбә ишеткән кебек, гаҗәпләнеп.— Безнең Фәүзи генә ул, артист булам, ди. Казанга кайчан китәсең дә, кайчан китәсең, ди, теңкәгә тиеп бетте. Үзең белән мине дә алып барырсың, ди, әткәйләргә генә әйтмә, ди, көләм, ярар, әйтмәм, мин әйтәм. Мич артында чикерткә сайрарга тотынды исә, бармагын авызына каба да тыңларга тотына. Мин Казаннан гармун уйнармын, әнкәйләр монда тыңлар, ди. Бик җылак — алып бармыйм, диең исә, хәзер балавыз сыгарга керешә...

Әледән-әле күк күкрәде, әле бер якта, әле икенче якта алмаш-тилмәш яшен яшьнәде, куе караңгылыкны урталай ярып төшкән зәңгәрсу яктылык эчендә берничә секундка кап-кара биек агачлар, йорт кыеклары, морҗалар, җир өсте, бакча киртәләре күренеп-күренеп калды. Гөрселдәү тавышы һаман көчлерәк, һаман ешрак ишетелә башлады. Еракта — хәзер бигрәк тә ерак булып тоелган офык читендә — төн карасы белән дәһшәтле кызгылт-сары яктылык көрәште. Анда нәрсәләрдер кыймылдашты, нәрсәләрдер бер-берсенә бәрелештеләр, очкыннар чәчрәтеп, төтен ургытып шартлап җимерелделәр, биек кыялардан аска убылып, ишелеп төштеләр.

Тын алуы һаман авырлашты, һаман көчле җил иste, бикләнми калган капкалар, морҗа калайлары шакылдадады, киртә агачындагы яртылаш куптарылган берәр коры кабык очы җилгә сызгырып утырды. Сәгыйть Зәйтүнәне үзенә табарак елыштырды.

— Курыкмыйсыңмы?— диде ул, аның хәленә керергә теләгән шикелле.

— Нәрсәдән куркырга?.. Икәү булгач... Мондый төндә генә куркып торалармыни?

— Безнең университетка дисең алайса? Химфакка? Бик әйбәт булачак,— диде Сәгыйть, яңадан баягы темага кире кайтып.

Шул вакыт ул Иданың да беренче курста башта химфакта укуын, бер айдан соң, өстәмә фәннәрдән имтихан биреп, үзләренең факультетына күчүен исенә төшерде. Нигә күчтем, дигән иде соң әле ул химфактан? Укуы авыр, формула да формула, дигән иде бугай. Әгәр Зәйтүнә дә шулай, укуы авыр, дип ташлап чыкса?

— Нигә химфакка?— диде ул, сакланып кына.

— Нигә дип... Химияне яратам мин. Мәктәптә безнең укытучы бик яхшые...

— Ә формулалар?

— Нәрсә «формулалар»?

— Кайберәүләр, мин әйтәм, формулаларны яратып бетермиләр.— Сәгыйтькә ул хәзер Идадан көләдер шикелле тоелды. «Шулай кирәк сиңа!»

— Формулаларны яратмагач, химияне ничек яратасың!— диде Зәйтүнә шундый гади итеп, үз-үзенә шундый нык ышанып. Сәгыйтьнең күңеленә шундук: «Ә шулай да ул Ида кебек түгел»,— дигән уй килде.

Күзләрне чагылдырып яшен яшьнәде. Кисәк кенә югарыда, түбә өстендә генә, күк төбе коточкыч чатнап, чытырдап китте. Күкрәү тавышы, кыялар җимерелгәндә як-якка сибелгән чуер ташлар кебек дөбер-шатыр килеп, вак кисәкләргә бүлгәләнеп, каядыр аска, караңгылык эченә тәгәрәде. Сәгыйть Зәйтүнәнең зәңгәрсу-ак йөзен, алга төбәлгән елтыр-кара күзләрен, күлмәк изүендәге бәләкәй генә сәдәфләрен күреп калды. Алар күптән инде зарыгып яңгыр көткән тузанлы юл читеннән чыктылар да йомшак чирәм буенча бара башладылар.

— Явамы инде бу, юкмы?— диде Сәгыйть, ургылган, дөбер-шатыр килгән күккә карап.

— Нишләп яумас икән?.. Яусыные инде,— диде аңа каршы Зәйтүнә, эчке бер өмет, ышану белән.

Авыл урамын аркылы кисеп үткән чишмә күпере аша чыккач, Сәгыйть, Зәйтүнә янында үзен олы кеше шикелле тотарга тырышып, өйрәтү, киңәш итү тонында:

— Дакуминтларыңны җибәр тизрәк,— диде,— иртәгә үк җибәр.— Шуннан соң Зәйтүнәне җиңелчә генә шелтәләп алган булды: — Менә җүләр! Алай беренче сентябрьне көтеп ятсаң, торып та калырсың. Уйлагансыңдыр инде: кулда медаль бар... булачак... шулай булгач, теләсә кайчан алырлар әле, дигәнсеңдер инде. Ярый, соң түгел әле. Яшь чакта була инде ул. Алырлар, ник алмасыннар! Әгәр кирәк икән, гаризаңа өстәп тә куй, мин — сезнең студент Сәгыйть абыйның авылдашы, диген. Мине анда белмәгән кеше юк!

— Бер-беребезгә күрше генә, дип тә әйтмимме соң?

— Була, алай дисәң дә ярый!

Җил басылды, такта кебек каты сукмакка шапылдап бер эре тамчы килеп төште. Бөтен җир өсте, өй артларындагы өянке яфраклары, караңгыдан тырпаеп чыгып торган көнбагыш сабаклары — бар нәрсә, бу гаҗәп тавышны ялгыш ишетмәдекме, дигән шикелле, курку катыш сөенеп, тынсыз калды. Икенче тамчы Сәгыйтьнең маңгаена килеп бәрелде һәм маңгай тиресен рәхәт кытыклап, борыны буенча аска агып төште. Кипкән җир өстенә, өянке яфракларына бераздан шап-шоп тамчылар бәрелә башлады, әйтерсең караңгыда ниндидер шук малайлар бер-берсенә борчак атышалар иде. Авыр, кысынкы төн шундук иркенәеп, җиңеләеп киткәндәй булды.

— Их, яңгыркай!— диде Зәйтүнә, балаларча куанып, һәм учына яңгыр тамчысы тотып алмакчы булып, кулын алга сузды. Шуннан соң эчке бер сөенеч белән такмакларга тотынды: — Яңгыр, яу, яу, майлы ботка бирермен, көмеш кашык бирермен!..

Сәгыйть шундук элеп алды:

— ...Майлы ботка казанда, көмеш кашык базарда!

Ләкин яңгыр яумады, әз генә шыбыр-шыбыр килде дә шундук тынды. Шулай да һавада яңгыр исе, көчле яңгыр алдыннан гына була торган серле киеренке тынлык торып калды.

## VI

Өйдә инде беркем калмаган иде, барысы да кояш белән бергә торып, эшкә китеп беткәннәр иде. Миңнисәттәй тәрәзәләрне ачып, өй эчен җилләтеп ята иде, каяндыр исә шунда Низамые килеп чыкты. Атын, өйгә кертерлек итеп, тәрәзә каршысына ук китереп туктатты да, тирләгән чәчле башын кашый-кашый:

— Исәнме, Миңнисәттәй,— диде. Аннан соң, җавап кайтарганны да көтмәстән, уенын-чынын бергә кушып, әйтеп куйды: — Бик картаеп киттең әле син, Миңнисәттәй.

— Ай Алла, Низаметдин,— диде Миңнисәттәй, яулык читен төзәткәләп,— нишләп алай бик тиз картайтасың әле син мине?

— Нишләп мин картайтыйм сине, үзең картаясың ич!— диде тагын Низамый, авызын ерган булып. Җитмәсә, салпы якка салам кыстырырга тотынды: — Бүтән җылларны бик актиф күренәдериең, әйтеп торганны да көтмидериең... Быел әллә нишләдең, өянәгең суктымы шунда — яздан бирле пассифланып ятасың.

Миңнисәттәй Низамыйның тел төбе кая барганын бик тиз сизенеп алды. Моңа чаклы әле быел бригадирның аңа эшкә әйтергә кыйганы юк иде. Миңнисәттәйнең йөрәге тынычсызланып тибәргә тотынды. Шулай да ул бик тиз генә сикереп төшәргә ашыкмады.

— Бала бар бит, Низаметтин, яшь бала,— диде ул, ипләп кенә, артык нык карышмаганын сиздереп.

— Бала дип-ни, бала кемдә дә бар инде ул, Миңнисәттәй. Бер-ике көлтә урсаң да... ясле сиңа җырак түгел, ике атлап бер сикерден исә, Тәлгатеңне илтеп тә куясың. Хәбирәттәйгә ияр дә кит, ашарыңа алып торма — бүген анда өмә... аш пешерәләр...

Шулай диде дә китеп тә барды. Барис белән булган теге вакыттагы ачуланышудан соң Миңнисәттәй быел уракка чыгудан бөтенләй үк өметен өзә башлаган иде инде. Дөрес, килене әйткән иде, бар, әнкәй, Бариска карама, эшлисең килә икән, бар, дигән иде. Ләкин шулай да башбаштакланып чыгып китәргә кыюлыгы җитми торган иде, тагын тавыш чыгар, тагын тәмсезләнергә туры килер, дип уйлаган иде, инде Барис алдында яңадан да шул турыда сүз чыгарасы килмәгән иде.

«Туктале,— диде Миңнисәттәй үз-үзенә,— тәрәзәләремне ябып куйыйм да, өйне дә җыештырып тормыйм — калсын бөтенесе шул көе. Бибихәбирәләр җитешкәнче Тәлгатемне илтеп куйсам... Нәрсәдән куркып торырга соң шулкадәр!» Йоклап яткан Тәлгатьне иплэп кенә уятты да, аны ашатып-нитеп тә тормыйча, гомердә булмаганча җиңел-җиңел атлап, яслегә чыгып чапты.

Юл буенча күңеленнән Барис белән бәхәсләшеп барды. «Синдә генә түгел бала, кеше баласы торган җирдә синеке дә торыр, берни булмас чүлмәгеңә,— диде ул, үзенең кыюлыгына үзе исе китеп.— Бала-бала дип, шушы яшемнән йөз суымны корытыр хәлем юк әле, сезне карап үстергәнем дә җитәр!.. Син эшләп табасың, улым, анысына бер сүзем дә юк, рәхмәт, ярый, картаймыш көнемдә игелегеңне күрәм, рәхмәт анысына... Шулай да, улым, басу эше белән күзе чыккан әнкәң өчен шушы яшьтән өйгә бәйләнеп, балага бәйләнеп яту һич тә генә килешкән эш түгел. Мин әле, Алла бирсә, җимертеп эшләр кеше!..»

Яследә баланы ике куллап алып калдылар. Миңнисәттәй тәмам җиңеләеп, яшәреп, ашыга-кабалана өенә кайтып китте. Юл уңаенда Хәбирәттәйләргә кагылып узды: «Мине дә көтегез, бергә барырбыз!» — диде. Өенә кереп, сабантуйга, җыенга әзерләнгән шикелле, әйбәт күлмәкләрен киде дә, әйбәт яулыкларын бәйләде дә,

каядыр шунда чолан почмагына кыстырып куйган урагын эзләп тапты, бакча, лапас капкаларын юкә бау белән бәйләп куйды һәм ишеген зур йозак белән бикләде дә, үз алдына сөйләнә-сөйләнә, урамга килеп чыкты.

Күршесе аны үзләренең капка төпләрендә көтеп тора иде. Миңнисәттәй килеп җитмәс борын ук ул аны кычкырып каршы алды.

— Бер ирек ачып, тын алып кайтырсың, ичмаса,— диде.— Балаң белән булашып, быел басуны да күргәнең җук бугай әле.

— Үзем дә шулай дидем, Бибихәбирә. Җәмне җәйләр узып бара, мин әйтәм, арышкайларны күреп, каннарны таратып кайтыйм әле, мин әйтәм. Гомерлеккә килгәнмени донҗага — бикләнеп ятырга әллә!..

Алар шулай үзара сөйләшеп, гөрләшеп, арыш басуы ягына алып чыга торган тыкрыкка кереп киттеләр. Бара торгач, Миңнисәттәй сорап куйды:

— Кара, Зәйтүнәне әйтәм, Казанга киттеме әллә?

— Җук, ыстансага китте әле бүген. Кылуптан кайтып бер-ике сәгать кенә җоклады да, таң атмас борын чыгып җөгерде, гөнаһшымнык. Куркабыз, җулда ул-бу, булуы бар... Кыз кеше бит — җөрәгем уч төбендә генә, исән-сау әйләнеп кайтса ярарые инде. Тыңламады — кая ул! Дүкәмитләрне, мидалларны Казанга җибәрергә кирәк, ди. Сәгыйть әйткән, дүкәмитләреңне тизрәк җибәрмәсәң, укырга алмаслар, дип әйтте, ди.

— Алай икән, ыы...— диде Миңнисәттәй һәм, бераз сүзсез барганнан соң үзалдына сөйләнгән кебек, әйтеп куйды: — Кай арада күргән соң әле ул аны... Зәйтүнәне? Барислар янында пычранып җөри ләбаса — киеменең карар җирен дә калдырмаган, мөрҗәдән төшкән кебек булып беткән...

— Күргәндер инде, Миңниса, аларны каян белеп бетерәсең. Бәхете генә булсын инде, бәхете... Кыз бала оясыннан бер очып чыгып китте исә, кайтыр дип уйлама. Бәхете генә булсын...

Урылган арыш җире өстенә килеп җиткәнче үк Миңнисәттәйнең борынына таныш ис килеп бәрелде.

— Һай, арышкайлар, һай, басукайлар!— диде ул тәэсирләнеп, күңеле нечкәреп һәм, кулын маңгаена куйган көе, эчкә баткан тонык күзләрен кысыштырып, каядыр еракка — бала чагыннан ук һәрбер калкулыгы, һәрбер куагы-әрәмәсе, чокыры-чакыры таныш булган кырларга текәлде.

Хәбирәттәй үзенең күршесен Рәшит комбайны ура-

тып алган җир башына алып китте. Арыш буенда әле беркем дә күренми иде.

— Менә шушыннан урырга кушты кичә Низаметтин,— диде Хәбирәттәй, чәбәләнә башлаган калын арышка күрсәтеп.— Рәшит бер дә уралмый лабаса, гөнаһшымнык. Низаметдин әйтә, ул утырып калыр, сез ялт итеп ялмап та алырсыз, ди. Шулай инде ансы, ул гөнаһшымнык кузгалып киткәнче көтәм дип монда... арышың коелып беткәнен карап торып булмый инде. Җә, тотындык, Миңниса.

...Яңа гына таң беленеп килә иде. Кичтән бөтен күк йөзен каплап алган болытлар каядыр юк булган иде, тышта искиткеч тынлык урнашкан иде. Рәшит, комбинезон төймәсен каптыра-каптыра, карачкы кебек тавыш-тынсыз гына баскычтан төште дә, үз артыннан чолан ишегенең ябылуына-ябылмавына да игътибар итмичә, урам як капкага таба атлады.

Ул әлерәк кенә кич йөреп кайтты, ләкин йокларга яткач бер генә минут та черем итә алмады.

Кемнеңдер коймасы буенда ямьсез тавыш белән ата песи мыраулады. Караңгыда күн итеге ниндидер ташландык калай чиләккә барып төртелде, аннан соң күрмичә бер аягы белән ялгыш канауга китереп басты — чак-чак кына егылмый калды. Ул барды да барды. Ул нишләптер басу ягына килеп чыкты. Бераздан ул еракта, сыекланган кара күк фонында үзенең комбайнын күрде. Комбайннан якын гына бер арыш саламы өемен актарып керде дә шунда бөгәрләнеп ятты.

Аның инде күптән Зәйтүнәгә күзе төшеп йөрде. Кич клубта вакыттамы, урамдамы, эштәме — кайда гына булмасын, гел аның тирәсендә булырга тырышты. Зәйтүнә елмаеп аңа бер сүз әйтсә, балалар кебек шатланды. Ул аның өчен утка, суга керергә әзер торды. Ләкин ул аңа үзенең хисләре турында әйтергә яисә, һич югы, шул турыда читләтеп кенә булса да белдерергә ни өчендер беркайчан да батырчылык итмәде. Үзенең мондый йомшаклыгына ул үзе дә бик аптырады. Аның аңа бөтенесен дә сөйләп бирәсе килде, йөрәген ачып саласы килде, тик ул моның өчен беркайчан да уңайлы вакыт кына туры китерә алмады. Көтте. Аның алдында ул кайчакларда бик кыюланып китте, кайчакта бөтенләй каушап калды, кызарды, бер дә юкка теле көрмәлде. Ул Зәйтүнәнең быел унынчы классны бетерүе, үзенең бары җиде класс белән генә утырып калуы турында, көз җиткәч тә аның Казанга китәчәге турында уйлады. Ләкин аңа нишләптер Зәйтүнә беркая да китмәс, авылда, аның янында торып

калыр һәм, билгеле, кайчан да булса бер аңа борылып карар кебек тоелды. Ул бөтен күңеле белән моның шулай булуын теләде.

Кичәгенәк ул клубка барганда: «Беткән баш беткән! Бөтенесен дә әйтәм дә бирәм, җитәр инде җебеп йөрергә!» — дип барган иде. Аның хәзер артык көтәргә тәкате калмаган иде.

Ул аның һәрбер күз карашын сагалап торды, аның бер генә сүзен дә колагыннан ычкындырмады, бер генә хәрәкәтен дә күзеннән читкә җибәрмәде. Ул аны ни генә булса да өенә кадәр озатып куярга карар итте. Ул, аның чыкканын көтеп, ике сәгатькә якын тышта ишегалдында таптанды. Ләкин аның Сәгыйть белән култыклашып китеп барганын күргәч, акылдан шашкан кебек булды. Ул моңа һич тә ышанырга теләмәде. Коточкыч нәрсә иде бу, дөньяда булуы мөмкин булмаган нәрсә иде бу.

Ул, көчле магнит белән тарттырылган кебек, моның ни өчен кирәклеген үзе дә аңлап җитмичә, алар артыннан атлап китте. Ул аларның сөйләшүләрен, көлешүләрен ишетеп барды, аның аяк буыннары хәлсезләнде, иреннәре кипте. Шәһәрдә укып кайттым дигәч тә, әллә кем булып борынын күтәреп йөргән шул студентны ул бөтен йөрәге белән дошман күрде, аның яныннан ихахай да михахай килеп барган Зәйтүнә аңа коточкыч шәфкатьсез, коточкыч кансыз булып, кыланчык, җилбәзәк булып тоелды. Ул инде элек тә алар арасында нәрсәдер барын сизенә иде, Зәйтүнә өчен һаман шикләнеп, һаман куркып йөри иде. Ләкин шулай да моңарчы аның аларның шулкадәр явызлыгын исбат итәрлек бернинди дәлиле юк иде. Кичә ул бөтенесен аңлады.

Аның Зәйтүнәне каядыр читкә китүдән тотып каласы килде, аның алдына барып ялынасы, ялварасы килде. Ләкин моның өчен ул үзен бик көчсез итеп, булдыксыз итеп сизде. Һәм үзенең көчсезлеген, үзенең бәхетсезлеген ныграк аңлаган саен, аның искиткеч батыр, искиткеч гайрәтле кеше буласы килде. Аның Зәйтүнәне шаккатырырлык, шул тәкәббер кызның йөрәген тетрәндерерлек берәр күз күрмәгән, колак ишетмәгән эш эшлисе килде, шуның белән аны үзенә каратасы, үзен яраттырасы килде,— юк, яраттыру ук түгел,— аннан үзенә берәр ягымлы сүз генә булса да әйттерәсе килде.

«Әгәр үлсәм?!» — диде ул үз-үзенә. Зәйтүнә өчен эшләнергә тиешле иң бөек һәм искиткеч нәрсә булыр иде бу, батырлыкның да, гайрәтлекнең дә, аны ярату көченең дә иң югары ноктасы булыр иде. Менә ул чакта исенә төшәр иде аның! Нигә минем үземне генә калдырдың,

нигә үлдең, нигә, ичмасам, бер генә сүз дә әйтмичә үлдең, дип елар иде, Рәшит бәгырем, күз нурым, кадерлем, дип, дөньяда мин бары сине генә яратам, синнән башка миңа беркем дә кирәкми, дип елар иде, аның үле гәүдәсе өстенә иелеп, күз яшьләрен түгеп елар иде. Мин бит сине яратканымны әйтергә генә кыймый йөрдем, дип елар иде.

Үзе уйлап тапкан мондый ярату, кызгану сүзләреннән аның күңеле тулды, ул үзен чыннан да бәхетле итеп сизә башлады. Ул шушы татлы хыял белән ләззәтләнеп, беркадәр берни турында уйламыйча тын гына ятты.

Ләкин ул үлгәч дөньяның ни кызыгы калыр икән соң? Ул үләр, череп туфрак булыр, аның шушы куллары, шушы яшь куллары, хәтта күкрәгендә хәзер сызланып типкән шушы йөрәге дә, йомшак, озын чәчләре дә — барлык тере, сизгер әгъзалары череп бетәр, иеп төшәр, югалыр; тора-бара аның җир йөзендә булуы-булмавын да, хәтта аның исемен дә онытырлар, гомумән, һәрбер үлгән кеше җирдә ничек онытылса, аны да шундый ук шәфкатьсезлек белән, шундый ук кансызлык белән онытырлар; яңа яшь егетләр, яшь кызлар үсеп җитәр; Зәйтүнә җыерчыклы йөзле, бөкрәеп беткән, тешләре төшеп беткән бер корткага әйләнер, һәр елны яз көне юл буйларында яшел чирәм тишелеп чыгар, җир өстендә вак кына кортлар мыжлап торыр, күктә кояш якты нур сибәр, түбә өстендә җиңел ак болытлар йөзеп йөрер. Тик... ул гына булмас.

Үз-үзенә ул бик кызганыч, ифрат та кызганыч булып тоелды, бөтен тәне чымырдап китте, күз төпләреннән ирексездән яшь бөртекләре сытылып чыкты.

Юк, үләргә кирәкми! Үлү — коточкыч, мәгънәсез. Аның әле яшисе килә, аның әле дөньяда бик күп нәрсә күрәсе килә! Аның әле бик-бик бәхетле буласы килә, сөеләсе, сөясе килә! Нинди дә булса бүтән нәрсә эшләргә кирәк, Зәйтүнәнең генә түгел, «бөтен авылның, бөтен авыл халкының, бөтен җир йөзенең исен китәрерлек нәрсә эшләргә кирәк. Ләкин менә хәзер генә, шушылай бөгәрләнеп яткан җирдән генә нинди зур эш, нинди бөек эш эшләргә соң, һәркемне таң калдырырлык нинди гаҗәп эш эшләргә соң?

Ул стена газетасындагы үзенең карикатурасын, Сафаның чәнечкеле сүзләрен исенә төшерде. Оят, гарьлек тойгысы аның колак очларын уттай көйдереп алды. Ул уку өендәге яшьләрнең, Зәйтүнәнең, Сәгыйтьнең авызларын күтәреп шаркылдап көлүләрен тагын бер кат ишеткәндәй булды, аларның шундый ачу китергеч мыскыллы йөзләрен яңадан күргәндәй булды.

Кинәт ул, ычкынып киткән пружина кебек, яткан урыныннан атылып торды — як-якка арыш саламнары сибелде.

Ул, яка арасына, колак артларына тулган салам кисәкләренә, кибәк, кылчыкка да игътибар итмичә, ныклы адымнар белән туп-туры үзенең комбайны янына, моторы сүтеп ташланган ватык комбайны янына китте. «Менә нәрсә эшләргә кирәк икән миңа!» — диде ул, исенә килеп. Һәм ул үзенең шушы комбайнын эшләтә башламыйча торып, бүлеп алган шушы арышын урып бетермичә торып, бөтен дөньяны хәйран калдырырлык бернинди бөек нәрсә дә, бернинди гаҗәп нәрсә дә эшли алмаячагын аңлады.

Инде таң атып килә иде. Иртәнге һава чиста, тын иде, һәм бөтен җир өсте уч төбендәге кебек күренеп ята иде.

Рәшит үзенең моңаеп утырган ватык «Коммунар»ы янына килгәч тә, әле генә йөрәген телгәләгән хәсрәтле уйлардан шундук арынгандай булды. Хәзер үз алдында торган бурыч — моторны төзәтү, аны эшләтә башлау бурычы аңа гыйшык газапларыннан да авыррак булып күренде.

Кайсы башыннан тотынырга соң моның? Нишләргә? Нәрсә, әллә соң яңадан авылга кайтып, тегендә, МТС конторында эш сәгате башланганны көтеп утырырга да, ярдәм җибәрүләрен сорап, телефоннан шалтыратыргамы? Әллә соң ат җигеп МТСның үзенә үк китеп барыргамы? Юк, алай да ярамый, болай да ярамый. Ничек кенә итсәң дә, бөтен көнең бушка узачак. Шулай да комбайн бүген урырга тиеш, аның ялкау түгеллеген, булдыксыз, эшлексез түгеллеген бөтен кеше күрергә тиеш!

Ул «Коммунар» өстенә менеп басты. Еракта, бодай басуы читендә, Барис комбайны караеп күренде. Ул кичә арышны бетереп бодайга күчкән. Нәрсә ул бодай!— йөгертә дә чыга инде ул аны. Тукта, кешеләр күренә түгелме соң анда? Кара, ничек төн тишегеннән килеп тотынган! Менә син карунны, өстеннән очмакчы була микәнни, бүтәннәр җитешкәнче, бодайны тизрәк үзем генә урып бетерим, ди микәнни?! Комсыз... Юк, дөрес итә ул — төне буе урса да кулыннан килә, аннан соң ашлыгы да син йоклап ятканны көтеп тормый, коела, иелә... Туктале, әллә соң аның янына барыргамы? Барырга да, шулай-шулай, Барис абзыкай, диергә... Барис яшьтәш, диергә, барып кына карыйк әле, диергә, син бит машинаны кайбер механиклардан да остарак беләсең, диергә, минем дә бер кирәгем төшеп куяр, белеп булмый дөнья хәлләрен, диергә... Юк, килмәс... Ма-

шинасы гөрләп эшләп торганда, нишләп ул аны ташлап йөрсен, нишләп синең өчен алтындай вакытын әрәм итсен! Булмый шул, энекәем, диер, син лутчы МТСка бар, ватык комбайнны төзәтү алар эше, диер, җитмәсә, үз-үзеңне белмәгәч, нигә машинага утырып чыктың, диер... Әллә соң килер микән? Гамбәре бар, аннан соң... болай сүз тыңлый торган кеше үзе. Барырга кирәк.

Ул аска төшә башлады. Ләкин шундук баскыч уртасында туктап калды. Аның күз алдына төнге вакыйга килде, бөтен тәне буенча кайнар дулкын йөгерде, куллары салкын тимер тотканы ныграк кысып тотты. Ничек итеп алар күзенә күренергә? Теге студент һәр көнне шунда чуалып йөри. Көләрләр: «Әнә Зәйтүнә кияве килгән!» — диерләр. Юк, аның алдында ялынып, зарланып торганчы, җир тишегенә кереп киткәнең мең артык! Юк, аягы да, күңеле дә тартмый. Булмый. Менә хәзер ярдәмче килер, эшчеләр килер, трактор килер. Тагын бер мәртәбә бергәләп карарга да, булмый икән, күп уйланып тормыйча, МТСка китәргә...

Әмма егетнең күңеле барыбер бер урынга утырмады. Ул тагын Барис комбайны ягына карый башлады, икеләнде, үз-үзен тиргәде, Сәгыйтьне тиргәде һәм, ниһаять, тиз генә җиргә төште.

Барислар иртәнге заправканы бетереп, моторларына ут кабызырга җыенып яталар иде. Рәшит Сәгыйтьне ерактан ук күреп алды. Ул ирексездән адымнарын әкренәйтә төште һәм, аны бөтенләй күрмәмешкә салынып, әвернә белән булашкан Барис янына килде. Гадәтенчә, киң итеп елмайды да:

— Исәнме, яшьтәш,— диде.

Барисның бик җитез хәрәкәтләнеп, ләкин ашыкмыйча, кабаланмыйча гайка борганын күзәтеп торды-торды да, үзенең ни өчен килгәнен җайлап кына, ипләп кенә сөйләп бирде. Барис, эшен бетереп, билен турайтты, үз алдына, җиргә текәлеп, бераз гына сүзсез торды. Шуннан соң ышанычлы итеп, нык итеп:

— Ярар, яшьтәш, була, хәзер барырбыз,— диде.

Рәшитнең өстеннән тау-таш ишелеп төшкәндәй булды — ул шундый җиңеләеп, шундый күңелләләнеп китте.

— Килегез әле монда!— дип кычкырды Барис, Гамбәр белән Сәгыйтьне үз янына чакырып.

Комбайнның икенче ягыннан Сәгыйть килеп чыккач, Рәшит баскан урынында таптанып куйды, ләкин шулай да читкә борылмады, аны үз гомерендә беренче мәртәбә күргән кебек, аның ягына карап тик торды. Ул нишләптер Сәгыйтькә карата үзендә баягы кебек дошманлык

тойгысы сизмәде — студентның йөзе тыныч, эшчән иде, ул аннан һич тә көләргә дә уйламый иде бугай. Ул аңа хәтта бик гади, бик зарарсыз һәм әйбәт кеше булып күренде.

Беренче булып Сәгыйть исәнләште.

— Рәшит килгән икән!— диде ул, дусларча.— Ни эшләр уңдарып йөрисең, Рәшит?

— Уңдарган эш җук әле хәзергә,— диде Рәшит, шулай да әз генә булса да елмаюдан тыела алмыйча.— Менә уңдарырга җөрибез.

— Сез үзегез кузгалып китәрсез,— диде Барис энесенә, майлы кулын салам белән сөртә-сөртә.— Менә Рәшитнең чирле айгыры янына барып килергә кирәк. Җиңел дип бик кумагыз. Гамбәр, син теге иләкне караштырып бар.

Барисның «чирле айгыр»ны карарга китүенә Сәгыйть Рәшиттән ким куанмады. Менә хәзер ул беренче мәртәбә үзе генә урачак, беркемнең карап, күзәтеп торуыннан башка урачак! Шулай да ул, эчке шатлыгын белдермәскә тырышкан кебек, күптән өйрәнелгән, гадәтләнгән нәрсә турында сөйләгән кебек, ис китмәү тонында әйтеп куйды:

— Кайгырма. Берни булмас.

Барис берсүзсез барырга риза булгач, Рәшит үз комбайны өчен кинәт бөтенләй кайгырмый, борчылмый башлады, әйтерсең аның бер күз каравы гына да моторны терелтеп җибәрә алачак иде — шундый нык ышанды ул аңа.

«Коммунар»га якыная башлаганда, Рәшит кисәк кенә туктап, Барисның кулыннан тотты.

— Карале, кемнәр ул анда? Нишлиләр алар?— диде ул, үз җиренең аргы башында кыймылдашкан ике карачкыга төртеп күрсәтеп.

Барис та туктап шул якка карарга тотынды.

— Җиреңә уракчылар төшкән ич!— диде ул, аларның нишләгәнен юрап-нитеп тормыйча.

Рәшит тә аларның уракчылар икәнен башта ук шәйләп алды, тик аның моңа ышанасы гына килмәде. Аның йөзе кырысланып китте. Кем кушкан аларга комбайн алдына кереп урырга? Күзләре чыкканмы әллә!

— Туктале, порхылдатып килим әле мин аларны!— диде ул, гайрәтләнеп.

— Берсе минем әнкәй түгелме соң, әнә теге зәңгәр күлмәклесе?..— диде Барис та, кашларын җыерып.— Кем кушкан аңа!

— Әйе шул, мин дә шуны әйтәм бит, кем кушкан аларга!

— Анық янындагысы Хәбирәттәй ич...

— Әйе, шулар,— диде Рәшит, Барисның сүзен дөресләп.

Зәйтүнәнең әнкәсен танып алу белән, анық гайрәте дә шундук шиңде, ул аларны «порхылдатып килү» уеннан кире кайтты. Шулай да бик гаҗәп иде бу. Нишләп алар күрәләтә аның җиренә килеп керештеләр икән? Низамый Ала карга эшедер әле, бер дә бүтәннеке булмас... Комбайны барыбер тик тора, кызык итим әле моны, бөтенесе алдында хур итим әле, дигәндер. Ах, Ала карга! Кичәгенәк бәйләнеп маташа иде шул, алай гел утыра башласаң, төп башына да утырып калырсың әле, дигән иде шул...

Ачудан Рәшитнең йөзе тагын да ныграк җитди-кырыс төс алды. «Ярар, карап карарбыз әле!»— диде ул күңеленнән һәм ныгытып йодрыкларын кысып куйды.

Кояш инде көндезгечә аркаларны, битләрне рәхимсез кыздыра башлагач, беләкләр, иңбашлар язылып, уракның инде рәтенә, җаена гына төшкәч һәм эчкә таба урып керелгән җир өстендә юан-юан көлтәләр тәгәрәшеп калгач, якында гына комбайн моторы пырылдарга керешге.

Миңнисәттәй билен язып, урагын кулбашына салды да баядан бирле тавыш-тынсыз утырган «Коммунар» ягына карарга тотынды. Комбайн җирен кырмыска кебек төрле яктан сырып алган өмәчеләр дә, учмаларын, ураклы беләкләрен маңгайлары турысына күтәргән көе, аптырап, гаҗәпләнеп, тавыш килгән якка борылдылар. «Коммунар» чын-чынлап телгә килгән иде, һәм аның күккә сузылган нечкә торбасыннан ачуланып-ачуланып зәңгәрсу төтен атыла иде.

— Ай Алла, туктаган камбаенызбыз пытырдый түгелме соң?— диде Миңнисәттәй, күршесе ягына карап.

— Шул шул, гөнаһшымнык.

Бүтән уракчылар да кисәк кенә бер-берсенә эндәшергә, кычкырып сөйләшергә тотындылар.

— Өмә бетте алайса! Вәссәлам!

— Низамыен әйт тә куй — камбаен алдына китереп кушалармыни!

— Һей, исегез киткән икән — урыныннан да кузгалалмас әле, сүнәр...

Ләкин, үч иткәндәй, сүнмәде. Менә кояшта ялт-йолт килеп, яңа такта белән ямалган әвернә әйләнә башлады, бер биш-ун минуттан тракторын да кабыздылар, һәм комбайн, бөтен басуны үзенә бер шау-шу белән күмеп, әкрен генә урыныннан кузгалып китте.

Уракчылар, нишләргә дә белмичә, аптырап тик тор-

дылар. Ә комбайн һаман туктамады, үзенең гадәттәге эзе белән килде дә килде, аның өстеннән бөркелеп тузан, кибәк өермәсе күтәрелде, артыннан вак кына чүмәлә кебек салам өеме төшеп калды. Трактор кемнеңдер кыйтыклап урып кергән җире турысына җитте. Хатыннар, бер-берсенә кул болгашып, көлешә-көлешә йә ачуланып кычкыра-кычкыра, әрле-бирле йөгеренергә, җир өстенә ташлап калдырылган көлтәләрен җыярга тотындылар.

Трактор шулай да туктап калды, тракторчы, кабинадан ярты гәүдәсен чыгарып, Рәшиткә нидер әйтте, тегесе исә, әйдә, кит туп-турыга! дигән шикелле, авызын ерып, кулын гына болгады. Трактор тагын кузгалып китте. Хатын-кызлар, уракларын селтәп, комбайн каршысына йөгерделәр. Рәшит, әйтерсең аларны бөтенләй күрмәде дә — үзүзеннән канәгать йөз, горур кыяфәт белән, штурвалга тотынган көе, тирбәлеп, чайкалып тик килде.

Ярый әле, көтмәгәндә Низамый килеп чыкты. Тиз генә кәрендәсеннән төшеп, тракторчыга туктарга кушты да Рәшит янына менеп китте.

Бүген уракка бик күп кеше чыккан иде, комбайн эшли башлаган өчен генә ул кадәр халыкны кире кайтарып җибәрергә яисә аларны икенче басудагы бодай җиренә алып барып кушарга һич тә ярамый иде. Бу — кадерле вакытның әрәм булуына, өмәнең өзелүенә генә сәбәп булачак иде. Шулай ук Рәшит участогын ике өлешкә бүлеп, бер өлешенә уракчыларны, икенчесенә — комбайнны кушу да мәгънәсезлек булыр иде. Күрәсең, бригадир моны шундук искәреп алды. Рәшиткә ул:

— Әйдә, син бодайга кит!— диде.

Рәшит, бераз көттереп торды да, җиңел, тигез җиргә китәргә күңеленнән бик риза булса да, эре генә:

— Сез гел шулай инде,— диде,— эшкә аяк чалырга гына торасыз...

## VII

Билгеләнгән көнне клубта концерт булды. Артистлары студентлар икән, дигәч, халык гадәттәгегә караганда да күбрәк килде, залда аяк очына басып торыр урын да булмады. Сәгыйть тынычлыкны яклау хәрәкәте турында, тынычлык өчен җирдә барган бөек көрәш турында лекция сөйләде һәм ачык итеп, аңлаешлы итеп, чын ораторлар кебек сөйләде. Халык тын да алмыйча тыңлап утырды, соңыннан хәтта сораулар да бирделәр.

Сәгыйть үз-үзеннән, үзенең лекциясеннән, концерттан — бөтен нәрсәдән ул көнне бик канәгать калды.

Бүтәннәр дә, ахры, үзләрен шулай тойдылар, һәм беренче чыгышта ук уңышка очрау агитбригада членнарын канатландырып җибәрде. Икенче көнне кич алар, колхоз ат биргәнне дә көтеп тормастан, җәяүләп күрше авылга киттеләр. Студентларны анда да яратып каршыладылар, концерт төн уртасына кадәр барды.

Кичәгенәк агитбригада Вәрәшкә барып өченче концерт биреп кайтты. «Безгә хәзер район буенча гастрольгә чыгып китсәң дә була!» — диде Нәсим, кәефләнеп.

Якын тирәдә кичтән җәяүләп барып, төнлә тагын җәяүләп кенә кайтырлык бүтән күрше авыллар юк иде. Шуңа күрә артистлар бер-ике көн ял итәргә һәм шуннан соң ераграк авылларга чыгып китәргә, моның өчен кирәк кешеләр белән сөйләшеп, килешеп куярга, кайбер нәрсәләрне яңадан әзерләргә, тикшерергә булдылар.

Янтыкка алар кичә таң алдыннан гына кайтып керделәр. Каникулга кайтканнан бирле Сәгыйть беренче мәртәбә төшкә кадәр йоклады. Әнкәсе өйдә юк иде, уракка киткән иде. Ул, өстәл янына утырып, үзе өчен калдырылган сөт өсте белән суынган бәрәңге ашады. Ул кичәге концерт турында, караңгы төндә урман аша шаулаша-шаулаша кайтулары турында уйлады.

Вәрәшнең клубы бик бәләкәй иде, алтмыш-җитмеш кешедән артык сыешлы түгел иде. Бер агай, урыныннан тормыйча гына: «Кытайда ничә мильярт халык бар?» — дип сорады. Ул: «Миллиард ук юк, шулай да биш йөз миллион чамасы бар, дип исәплиләр», — дип җавап биргәч, агай бөтен залга ишетелерлек итеп телен шартлатып куйды: «Ах, абзыкай! — диде. — Мин тагын мильярт дип утырган булам! Безгә тагын шулкадәр көч өстәлгәч, каян килеп җиңмәк кирәк безне даллес-маллесларга!» Аннан соң урта яшьләрдәге бер хатын кычкырды: «Ул Әмрикәдә соң безнең кебек катыннар җук микәнни?» Бу, ахры, берәр мәзәк нәрсә әйтмәкче була торгандыр инде, дигән шикелле, залдагылар аның сүзеннән кычкырып көләргә тотындылар. Ләкин хатынның йөзе бик җитди иде. Тавыш басылганны да көтмичә, ул тагын да ныграк итеп кычкырды: «Авызыгызны ыржайтмагыз әле айгыр кебек! Бер дә көлә торган җире юк... Нишләп чыдап торалар икән шул ыштыр битләргә... аларның катыннары нишләп шул котырганнарны буйлаталар икән? Аларны бик иреккә куйсаң, бөтен җиреңне-суыңны җотып бетерерләр алар!..»

Аннан соң Сәгыйть Нәсим турында уйлады. Нәсим аңа кичәгенәк: «Иртәгә кил әле безгә... эшең булмаса, бер җиргә барырбыз», — дигән иде. Ул шулай гел серле

итеп сөйләшергә ярата — кая бармакчы булуы турында никадәр сораса да, барыбер әйтмәде, «Кил әле, кил!» генә дип куйды.

Ашагач ул Нәсимнәргә китте.

— Миңгали карт чакырганые күптән,— диде Нәсим, аны каршы алып,— онытып җибәргәнмен. Ни... ул персидәтелдән зарлана да персидәтелдән зарлана. Гәзиткә язаргае, ди. Әйдә, барабыз, бәлки, икәүләп берәр нәрсә язып ташларбыз... Синең белән әйбәтрәк чыгар, ә?

Миңгали картның бакчасы бөтен районда дан казанган бакча иде. Бакчачы Миңгали карт турында райондагы һәркем диярлек белә иде. Аның җимеш бакчасын карарга, аннан өйрәнергә, киңәш сорарга чит авыллардан экскурсантлар да, болай кызыксынучылар да, бакчачылар да, мәктәп балалары да килә, аның турында еш кына район, хәтта республика газеталарына да язалар, җыелыш, күргәзмә, конференцияләрдә бүтәннәргә үрнәк итеп һәрвакыт аның исемен телгә алалар. Район базарында аның үзенә бер кибете бар, һәм ул шунда җәй башыннан алып көз ахырларына кадәр җиләктер, алмадыр сата.

Миңгали карт эзләнүчән, яңага омтылучан, тынгысыз кешеләрнең берсе иде. Шуның өстенә ул бар күңеле белән яшеллекне ярата иде. Яратып кына да калмый, шуның өчен хезмәт итә, шуның өчен бөтен көчен, бөтен вакытын бирә иде.

Янтыкның озын урамын берничә җирдән аркылы кисеп чыккан чишмә буйларындагы биек таллар, идарә йорты каршындагы сирень куаклары, клуб бакчасы, мәктәпне тирәли әйләндереп алган яшел тупыллар — барысы да аның исеме белән бәйләнгән иде. Аларны ул үз кулы белән утырткан, кемнәрдер «боерык» язып биргән өчен түгел, кемнәрдер кушкан, мәҗбүр иткән өчен түгел — үз теләге белән утырткан иде.

Ул һәр елны яз башында яисә көз җиткәч өй борынча һәркемгә бушлай алмагач үсентеләре таратып йөри, аны ничек утыртырга, кайда утыртырга, ничек итеп тәрбияләргә кирәклеген өйрәтә, кайчакта мондый «юк эш» белән «пычранасы» килмәгән берәр агай белән хәтта кычкыргалашып та ала. Бу якта, җәй бик кыска килгәнгә, алмагач бик үк яхшы үсми, үссә дә рәтләп алма бирми, һәм халык, гомер-гомергә килгән ныклы бер караш буенча, гомумән, алмагач үстерүгә кул селтәп, ышанмыйча карый. Ләкин Миңгали карт үзенең бакчасындагы алмалары белән, үзенең эше, тәҗрибәсе белән моның дөрес түгеллеген ел саен исбат итә, һәм ул чын күңеленнән шуны авыл халкына да аңлатырга тырыша.

Ул үзенең бакчасына килгән теләсә кемне, татарның яхшы бер гадәте буенча, һәрвакыт сыйлап, кунак итеп җибәрә. Янтыкның бер генә кешесе дә диярлек — олысы, кечесе — җимеш-фәлән җитешкән вакытта Миңгали карт бакчасының хәлен белүдән файдаланмыйча калмый. Тик Сәгыйтьнең генә инде дүрт-биш елдан бирле анда булганы юк иде.

Нәсим белән алар икәүләшеп Миңгали карт бакчасына киттеләр.

Бакчага килеп җитәрәк, юлда, кулларын аркаларына куеп, башларын бик түбән игән көе, әкрен генә лыстырдап килүче ике карт очрады. Сәгыйть аларны яннарына килеп җитмичә тиз генә таный да алмады — алар шундый нык картайганнар иде. Картларның берсе — кыска гына, юантык кына Әхмәтҗан бабай — аягына ак җон оек белән тирән галош, өстенә кыска сырма кигән, икенчесе — калку яңаклы, яшь коя торган, кызарынган күзле, ябык, бөкре Салих бабай — башына җирән киез эшләпә, өстенә озын бишмәт кигән иде. Алар, үз алларына туптуры карап, авылга таба кайтып баралар иде. Күрәсең, Миңгали кордашлары янына барганнардыр инде: берсенең мыек очына, икенчесенең авыз читенә кызыл җиләк буялып калган иде.

Сәгыйть белән Нәсим, картлар турысына җиткәч тә, кычкырып сәлам бирделәр, ләкин тегеләр әллә танымадылар, әллә инде сүзләреннән аерыласылары килмәде — туктап-нитеп тормыйча, башларын гына борып, чит авыл кешеләре кебек: «Бик исәнбез әле, Аллага шөкер»,— диделәр дә үз юлларында булдылар.

— Әхмәтҗан бабай белән мин кайчандыр көлтә ташырга йөргәниием,— диде Сәгыйть, алардан ераклашкач.— Ялкау да карт соң! Эшкә йөриме әле ул?

— Җөри! Инде өч-дүрт җыл мич башыннан төшкәннәре юк икесенең дә,— диде Нәсим. Аннан соң өстәп куйды: — Яшь чагында аны ат карагы булган диләр... Әхмәтҗан картны...

— Нәрсә, чирлеләрмени?

— Җук, картлык баскан...

Аста, тау бите буенда, Миңгали карт бакчасы күренде. Сәгыйть, исе китеп, сокланып, кинәт туктап калды. Ул үзен нindидер икенче дөньяга, нindидер әкият патшалыгына килеп чыккан кебек хис итте. Бакча хәзер элеккегә караганда тагын да ныграк зурайган, үзгәргән, матурланган иде. Бакча чыннан да сокланырлык, искитәрлек иде.

Алды белән көньякка караган, уртасыннан төньякка-

рак кереп, бөгелеп торган һәм шул рәвешчә дуга кебек булып күренгән бер зур тау итәгендә Миңгали карт бакчасы җәелеп ята иде. Монда беркайчан да салкын төньяк җилләре үтеп керә алмый, шул ук вакытта көне буе кояш нуры төшә иде. Җимеш бакчасы өчен менә дигән урын иде бу.

Бакчаның ярты өлеше, көнбатыш ягы, астан алып өскә кадәр тубал-тубал булып утырган алмагачлар белән, икенче өлеше, көнчыгыш ягындагы тау бите, кура җиләк рәтләре белән капланган иде. Бакчаны буйдан-буйга аркылы-торкылы ике киң аллея кисеп үтә иде. Тау өстендә, бакчаның чит-читләренә тигез итеп яшь ак чыршылар утыртып чыгылган; чыршылар рәтеннән бераз гына эчтәрәк, бер-берсеннән бер илле метрлар ара калдырып, шалаш сыман нәрсәләр корып куелган; шалашлар янына озын таяклар утыртылган; таяклар очына кош-корт куркыту өчен бау белән калай кисәкләре, карчыга үләксәләре эленгән. Шунда ук утырып ял итү өчен җайлы скамьялар куелган. Тауның көнчыгыш як итәгендә, калкурак җирдә ак койма белән әйләндереп алынган җыйнак кына, матур гына йорт утыра; йортның көньяктагы стенасына терәтеп веранда кебек нәрсә корылган; анда ачык һавада җиләк киптерәләр. Веранда артында тагын җимеш куаклары сузылган, анда картның тәҗрибә участогы иде. Тәҗрибә участогыннан да, йорттан да арырак — тау астында — ерактагы әрәмәләргә кадәр сузылган тигез кара җирдә питомник күренә. Кеше кулы белән утыртылган, кеше тарафыннан тәрбияләнеп, саклап үстерелгән шушы гүзәл яшеллек, шушы ясалма урман җылы, йомшак кояш нурында балкып ята; ботакларын иеп төшкән эре, ак алмалар ерактан ук ялтырап, күзнең явын алып тора. Бөтен нәрсә тәртипле, матур, мәһабәт. Куаклар арасында анда бер, монда бер ак күлмәкле хатын-кызлар күренә иде.

— Нәрсә шаккаттың?— диде Нәсим.— Әллә Миңгали бакчасын күргәнең җукмы? Моннан ул әллә ни кызык түгел, әйдә, аска төшәбез...

Алар туп-туры йортка алып бара торган киң, тигез юлга килеп чыктылар. Юлның да ике як читеннән очлы башлы ак чыршылар тезелеп киткән, чыршылардан кояшта кызган ылыс исе, пешек исе аңкый, юл читенә кыйгачлап сырлы күләгәләр төшкән иде.

Якыннан гына, алмагачлар арасыннан, яфрак шыштырдаган тавыш килде. Нәсим туктап калды, аннан соң юл читенә чыкты да, чыршы ботакларын кулы белән ике якка аерып, бакча эченә карады.

— Карт үзе,— диде ул, пышылдап.— Әйдә, янына барабыз.

Алар яхшы итеп йомшартылган, бернинди чүп үләне күренмәгән кара җир өстенә килеп керделәр. Сәгыйтьнең аягы баскан саен шаталак сөягенә кадәр батып-батып китте. Ул, шүрләгәндәй итеп, туктап калды.

— Тукта,— диде ул, Нәсимнең җиңеннән тотып,— без аның берәр нәрсә утыртылган түтәлен таптыйбыз бугай.

— Бернинди түтәл түгел — үзе шулай. Алмагач төбен шулай җомшарткан...

Аларның чыш-пыш килүләрен Миңгали карт шундук ишетеп алды, ахрысы, кинәт куаклар артыннан аның ачулы тавышы ишетелде:

— Кем ул анда?!

— Бу — без, Миңгали бабай!— диде Нәсим, кычкырып.

— Сез булсагыз ни, нишләп җөрисез анда?

Агачлар артыннан, ике кулына да алмагач ботакларыннан сыдырып алынган яшел яфраклар тотып, малайлар кебек кенә, бәләкәй генә Миңгали карт килеп чыкты. Аның башында колакчынсыз иске бүрек, өстендә аркасына кадәр уратып алган озын итәкле ак эш халаты иде. Ул килүче кешеләргә бер сүз дә әйтмичә җентекләп карап торды да яңадан куаклар артына кереп китте.

— Әллә танымадың, бабай?— диде Нәсим, карт янына килеп туктагач, аның белән дусларча булырга тырышып.

Бакчачының болай бик кыты гына каршылавына Нәсимнең бераз кәефе киткән иде бугай.

— Таныса ни,— диде Миңгали карт, шулай ук кискен генә, ләкин монысында инде йомшаграк тавыш белән. Ул, ботак очларына үрелеп, һаман яфрак сыдырды.

— Ни... нигә кирәк соң ул, бабай, нигә өзәсең аларны?— диде Нәсим, яңадан сүзгә башлап.

Миңгали карт, эшеннән туктап, кулындагы яфракларын җиргә ташлады да:

— Кортларын чүпләргә кирәк,— дип куйды. Аннан соң кулларын халат итәгенә сөрткәләп, Сәгыйть белән Нәсимгә ялт кына карап алды да: — Әйдәгез алайса, әйләнеп килик,— диде, ниндидер алдан килешеп куелган нәрсә турында сөйләгән кебек.

Яшьләр кебек җиңел-җиңел атлап, аларны ул алмагачлар арасына алып кереп китте. Ул барыннан да бигрәк үзеннән алмагачлар, җимешләр турында сораштырганнарын, үзенең бакчасы, үзенең эше белән кызыксынганнарын ярата иде. Нәсимнең кортлы яфраклар турында сорап куюына ул шулай йомшарып китте дә.

Миңгали карт озын, каты ботакларын сузып, җәелеп утырган әле бер, әле икенче алмагач янына килде, куллары белән яшел, эре яфракларга кагылып-кагылып куйды һәм тәҗрибәле экскурсоводлар кебек, бер генә артык сүз дә кыстырмыйча, бер генә артык хәрәкәт тә ясамыйча, монсы Хурашафка, монсы Вәнис, дип, монсы Кытайка, монсы Дики, дип, алмагачларның сортларын, яшьләрен, кайчан алма бирә башлауларын, нинди алма бирүләрен, күпме бирүләрен — барысын да бер-бер артлы аңлатып барды. Бу алмагачлар яныннан ул инде йөзәр, меңәр мәртәбә узып киткән, сәгатьләр буенча алар белән сүзсез генә сөйләшеп торган, аларның шатлыгын, кайгысын бергә уртаклашкан, һәм шуңа күрә дә ул аларның сортларын-фәләннәрен генә дә түгел, хәтта аларның гадәтләрен дә, һәрберсендә ничә ботак, ничә яфрак булуын да биш бармагы кебек белә иде бугай.

Картның баштагы кырыслыгы тәмам юк булды, йөзе һаман ачыла, яктыра барды. Аның гадәтен бик яхшы белгән Нәсим аңа әледән-әле сораулар бирде, ә ул эчке бер горурлык, эчке бер куаныч сиздереп торган тыныч һәм картларча әкрен тавыш белән, бер дә түбәнсенмичә, бер дә иренмичә, барысын да сөйләп барды, үзе һаман ботаклардан күзенә күренгән кортлы яфракларны сыдырып-сыдырып алды. Аннан соң ул аларны икенче җиргә алып китте. Алмагачларның ике сортны бергә ялгап үстергәнен дә, кыш көне салкында туңмасын өчен ботакларын җир өстеннән генә, түбәннән генә җибәртеп үстергәнен дә күрсәтеп йөрде.

Бер ярты сәгатьтән соң алар өйгә керделәр.

Стеналары бакчачылык турындагы плакатлар белән, авыл хуҗалыгы журналларыннан, газеталардан кисеп алынган төрле рәсемнәр белән тулы бәләкәй генә, тәбәнәк кенә өй эченә кояш нуры тулган иде, бөтен нәрсәдә җинелчә җиләк исе, яшеллек исе аңкып тора иде.

Миңгали карт такта белән бүленеп алынган икенче як бүлмәгә чыкты да кулына папка хезмәтен үтәгән китап тышы тотып өстәл янына, Сәгыйтьләр каршысына килеп утырды. Китап тышының ике ягындагы бавын чишеп җибәргәч, аннан зәңгәр тышлы дәфтәр килеп чыкты.

— Менә пылан,— диде бакчачы, шакмаклы дәфтәр битендәге ниндидер сызыклар, түгәрәкләр өстеннән юан бармагын шудырып.— Безнең бакча пыланы. Яңа җорт салырга кирәк, тау башына мендереп. Бөтен бакча күренеп торырлык булсын, хәзер унбиш гиктарга җитте, каян барысын да күреп бетермәк кирәк. Менә монда тагын

алма утыртабыз, мондагы кура җиләкне күчерәбез. Җегерме гиктар итәргә исәп. Унлап баш корт кирәк, серкәләндерү өчен. Бар да бар хәзер — җорты гына кирәк. Бардым Булатыйфка: шулай-шулай, мин әйтәм, иптәш Булатыф, бакчаны зурайтырга кирәк. «Һәй, бабай, болай да зур ич бакчаң, кая тагын зурайтмакчы буласың аны!» Урак җитте дип, кешеләремнең яртысын алып бетерделәр, җиләк коела. Базарда сатып кайтсаң, акчасын: «Давай!» «Сиңа нигә кеше кирәк — син үзең биш кешегә торырлык!» Көлә. Төнге каравылны да алдылар, каравылчы да үзем, сатучы да үзем, эшче дә үзем... Биш кеше... Бардым бервакыт: «Булатыф иптәш, бакчаны коймалап алырга кирәк». Җыл да: «Ярар, ярар, барысы да булыр!» Алма җитте, бала-чага киләчәк. Кыш көне куян кимерә. Ул аны белми. «Бала-чагалар керә бакчага, берәрсен шәпләп кенә кыздырып алсаң ярарые, иптәш Булатыф». «Ашасыннар!— ди.— Сиңа гына алма ашап ятырга димәгән!» Сөйләш син аның белән!..

— Әйбәт ат бирделәрме соң, бабай?— диде Сәгыйть, аны идарә йортында очратуын хәтерләп.— Председатель соң, бирербез, дигәние ич.

— Бирделәр,— диде Миңгали карт ниндидер билгесез тонда.— Аның сүзе үзе яныннан киткәнче генә. Хәзер әйтә, хәзер оныта. «Өч йөз җөк тирес түгәргә кирәк»,— дидем. «Ярар, синең бакчаңнан башка да эш муеннан!» Җаны җук безнең калхуз башлыкларының. Аңа эчке булсын — шул җиткән.— Бакчачы карт Нәсимгә күтәрелеп карап алды.— Барысын да яз, берсен дә төшереп калдырма. Кая, кәгазең, каләмең җукмыни?

Бакчачының сүзләре белән мавыгып, Нәсим монда үзенең ни өчен килгәнен дә онытып җибәргән иде бугай.

— Ә-ә... ни... бабай, без икәүләп язабыз,— диде ул, Сәгыйтькә күрсәтеп.— Менә дигән итеп язарбыз!

— Шунсын да төртеп куегыз: бакчаны утыртканга быел унсигезенче җыл. Алты йөз меңнән артык дахут алган, диген. Яз көне питумниктан суртлы кыржауник алып кайтыйк, дидем, акча бирмәде, ат бирмәде. Шунсын да әйт.

— Бабай, синең соң районга барганың юкмыни?— диде Сәгыйть.— Калхуз ярдәм итми икән, район ярдәм итәргә тиеш ич!

— Алар ярдәм итә. Агранум килә, өйрәтә, китаптан укып күрсәтә. Бүтәне килә дә: «О-о, бабай, нинди әйбәт, нинди шәп бакча!» Утыра да китә.

Бакчачы карт кунаклар алдына зур тәлинкәгә өеп, изелеп пешкән, бераз гына ачы тәм кергән кура җиләк

кертеп куйды. Аның күңеле тагын да йомшарыбрак китте, теле тагын да ныграк чишелде, һәм ул, бакча турында, үткәннәр турында искә төшерүдән җиләк ашауга караганда да күбрәк ләззәт табып, ашыкмыйча гына һаман сөйләвендә булды.

— Менә барые ул персидәтел!— диде ул, истәлекләргә бирелеп.— Хаҗиеф барые бер заман. Аның тырышлыгы белән утырттык шушы бакчаны. Якшы кеше күп торамы соң ул — шундук раюнга тарттырып алдылар. Аннан китте тагын югарыга. Хәзер бик зур начанник, ди. Ни сорап барсаң да: «Бабай, эшләрбез! Булыр, бабай!» И булдырды да. Үзе килеп, үзе карап, тикшереп җөрерие. «Бабай, укырга өйрән, китап буенча эшлә». «Бабай, мин сине бер Мәскәүгә алып барырмын әле». Өйрәнеп булмады укырга. Бераз сукалыйм — хәзер соң инде, җитмешнең теге ягына чыгып барам.

Миңгали карт, әллә үзенең үткән гомере турында, әллә яхшы председатель Хаҗиев турында уйланып, беравык сүзсез генә, тын гына утырды.

— Хәзер дә бар ул андыйлар,— дип башлады ул тагын.— Былтыр Карманнан килгәннәр.— Сәгыйть урынында кымырҗып куйды.— Пар ат җиккән, баскан урынында тотып торырлык түгел. «Әйдәле, бабай, безгә барыйк, күрсәтерсең, өйрәтерсең. Без дә синеке кебек бакча утыртабыз». Киттек. Персидәтелләре Арманшин Хәлиулла, исәнләште, кул бирде: «Исәнме, бабай».— «Бик исән әле».— «Бабайны әйбәт алып килдегезме? Җулда ул-бу булмадымы?»— «Җук, берни булмады,— мин әйтәм,— күперегезнең бүрәнәләре генә селкенеп калды чыкканда». Шундук, сыразы: «Барыгыз, төзәтеп кайтыгыз!» И чәй эчкәнче төзәтеп тә кайттылар. Киттек бакчаларына. Бакча — җук. Урман эче, тигез җир.— «Җуук,— мин әйтәм,— кояш төшми. Тау кашы кирәк. Кырым, Капказ түгел монда». Киттек, көне буе җөрдек эзләп. Безнең белән Арманшин да җөри. Таптык, әйбәт җир, чишмәсе дә бар. Кичтән җыелыш җыйды бу бакча утырту турында. «Бабай, кил безнең калхузга, без сине күтәреп кенә җөртербез».— «Җу-ук, рәхмәт чакыруыгызга». Кая ташлап китмәк кирәк боларны? Гомереңнең күңелле чагы шушында узган. Сүз тыңлый торган кеше Арманшин. Бар ул андый персидәтелләр, Хаҗиеф кебекләр. Бар... Кулыңнан килсә, бөтен җиргә бакча утыртырыең да бит — җук...

Ул тагын тынып калды. Сәгыйть аның көне буе кояшта янган һәм җиләк суы белән юылган шикелле булып күренгән картларча нәфис, шома тиреле, сөякчел яңак-

ларына, галимнәрнеке кебек ялтырап торган киң маңгаена һәм ап-ак, чиста мыекларына, сирәк сакал төкләренә — бөтен өс-башына, кыяфәтенә гаҗәпләнеп карап торды. Бу минутта аның йөзе аңа ниндидер гүзәллек белән, акыллылык нуры белән яктыртылган шикелле тоелды; эчкә баткан, әмма терелеген, яшьлек дәртен югалтмаган елтыр күзләрендә үзенә бер төрле җылылык, ягымлылык сизелде. Аның тышкы кыяфәте генә карт иде, чынында ул үз яшеннән әллә кайда яшьрәк иде, хәтта кайбер яшь булып исәпләнгән кешеләрдән дә яшьрәк иде.

«Әгәр шушы бакчасы булмаса, әгәр кырыс табигатькә яраклаштырылган, йомшартылган, буйсындырылган шушы алмагачлары, шушы җиләкләре булмаса, ничек яшәр, нәрсә белән, нинди омтылыш белән яшәр иде икән ул?— дип уйлады Сәгыйть күңеленнән.— Гел саф һавада булу, күбрәк җиләк ашау гына аны шулай яшь итеп күрсәтәме соң әллә? Кая!.. Шушы бакчасы яшәртә аны, үзе җаны-тәне белән яраткан тынгысыз эше, гүзәл шигъриятле, мәгънәле эше яшәртә аны!»

Сәгыйть күңеленнән аны әле килгән чакта юлда очраган Әхмәтҗан картлар белән чагыштырып карады, алар арасында ул җир белән күк аермасы күрде. Әхмәтҗаннар, Салих картлар күптән инде теге дөньяга китәргә аяк киенә башлаганнар, мич башына, җылыга менгәннәр, бу карт исә кашлары, керфекләре кар кебек агарган җитмеш-сиксән яшьлек карт — авылдагы барлык картлардан да картрак карт — тагын да яңа бакчалар үстерү турында, кеше тормышын тагын да ныграк бизәү, аны тагын да күңеллерәк итү турында хыяллана!

...Бакчачы аларны озата чыкты.

— Җиләк ашый-ашый китегез,— диде ул, юл өстендәге кура җиләк куакларына күрсәтеп.

— Рәхмәт, бабай, сыйландык бит инде!

Нәсим, тау өстенә менгәч:

— Шулай да алма ашатмады, саран,— дип куйды.

Сәгыйть эндәшмәде. Аның хәзер бакчачы турында беркемнән дә, хәтта Нәсимнән дә начар сүз әйттерәсе килмәде. Избач үзе дә хаксызлыгын шундук шәйләп алды, ахры, баштагы сүзләренә каршы килеп:

— Ярар әйдә,— диде, бераз баргач,— тагын берәр килербез әле. Өлгермичә ул бернәрсәсен дә өздерми.

«Менә нинди алтын кешеләр бар бездә!— диде Сәгыйть, баштагы уен дәвам итеп. Ул бригадир Низамыйның печән чабарга барган чакта, кеше юк бит, эшләр кеше юк, дип зарланган сүзләрен исенә төшерде.— Юк, кеше юк түгел, чын кешеләрне күрә белүчеләр, аларны

дөрес аңлый белүчеләр юк, аларны дөрес оештыра белүчеләр юк! Менә кемнәр җитешми хәзер колхозда! Мәрдәншә агайлар, Гөлсемнәр, Заһирҗан агайлар, Миңгали кебек картлар, Хәбирәттәй кебек хатыннар — кемнәр соң алар? Шулар лабаса инде чын колхоз кешеләре! Шулар лабаса инде чын эш кешеләре!»

## VIII

Миңгали карт бакчасыннан ераклашып, олы юлга килеп чыккач, артта күккә бөркелеп күтәрелгән тузан өермәсе күренде.

Станция ягыннан, бер-бер артлы тезелеп, бик кызу тизлек белән авылга таба әллә өч, әллә дүрт автомашина чаптырып килә иде. Станция белән берничә авылны тоташтырган бу юлда машиналар бик еш йөреп торалар иде, һәм хәзер дә аларның тузан туздырып килүендә әллә ни гаҗәпләнерлек нәрсә дә булмас иде — элеваторга ашлык ташый торган чак. Ләкин хәзер, каядыр тизрәк барып җитәргә тырышкан кебек, бик нык ашыгып, пыр туздырып килүче бу автомашиналарның бу якныкы түгел икәнлекләре ерактан ук күренеп тора иде.

Сәгыйть белән Нәсим туктап көтәргә булдылар. Машиналар якынайганнан-якынайды. Алдагы биек, озын кузовлы, өр-яңа яшел машина, аларны бер ун метр чамасы узып китте дә кинәт туктап калды. Шофер кабинасы ачылып та китте, кабинадан Мәрдәншә агай килеп тә чыкты.

— Ә-әй, җегетләр! Әйдәгез, утырыгыз!— дип кычкырды ул, аларны үз янына чакырып.

Машина «Ялкын» колхозыныкы түгел иде һәм шоферы да бөтенләй ят кеше, рус кешесе иде. Каян килеп утырган соң анда Мәрдәншә агай?

Күп уйланып торырга вакыт юк иде — Сәгыйтьләр машина янына йөгереп килделәр дә, ашыгып кузовка менеп утырдылар. Ул арада арттагы машиналар да куалап җитте.

Кабина ишеге шапылдап ябылды, һәм алар кисәк кенә кузгалып киттеләр.

— Безгә баралар түгелме соң болар?— диде Сәгыйть, машинаның туп-туры ындыр табагына алып бара торган юлга борылганын күреп.

Арттагы өч машина да алар артыннан борылды. Күз ачып йомганчы ындыр табагына килеп тә җиттеләр.

Өстәл өсте кебек тигез ындыр табагында бөтен җирне тутырып, таудай булып, чистартылган аксыл-саргылт бо-

дай өелеп ята иде. Дәүләткә ашлык тапшыру буенча колхоз районда иң арттагылардан исәпләнә иде.

Машина туктау белән кабинадан Мәрдәншә агай килеп чыкты. Аның йөзе сизелерлек булып дулкынланган, үз-үзен тотышында, күз карашында ниндидер серле, тантаналы нәрсә сизелә иде. Ул Сәгыйть белән Нәсимне үз янына чакырып алды да, тыны кысылган кеше кебек, ничектер кабаланып:

— Җегетләр...— диде.— Әйдәгез, хатыннарга капчык тутырырга булышыгыз... Тизрәк... хәзер бөтен ашлыкны ташып бетерәчәкләр... Әнә никадәр машина килде! Бөтенесе дә безгә...— Һәм ашыгып лапаска, җилгәрүчеләр янына кереп китте.

Тутырып куелган капчыклар бер генә машинага җитәрлек иде, шуның өстенә төньяктан яңгыр болыты ябышып килә иде. Шуңа күрә авторота машиналарын көттермичә тизрәк төяп озатырга кирәк иде.

Җилгәрүчеләр, капчык тутырырга чакыргач, ындыр табагы башлыгы Мәрдәншә агайга каршы килеп карадылар: «Безнең эш түгел, үзләре тутырсын»,— диделәр. Ләкин хәзер алар белән сатулашып торып булмый иде.— Мәрдәншә агай, һич тә кызмаска тырышып, әмма шулай да каты гына итеп:

— Ярар, телегезгә күп салынмагыз!— диде.— Кулыгыз калмас, әйдә тизрәк!

Сукрана-сукрана җилгәрүчеләр дә килеп чыкты, тиздән ындыр табагындагы бөтен кеше бодай өеме тирәсендә кайнашырга тотынды. Мәрдәншә агай хәтта шоферлар кулына да тимер соскылар, чиләкләр тоттырды.

Яңгыр болыты һаман якынлашты. Кисәк кенә хатын-кызларның итәкләрен тарткалап, ындыр табагы читенә китереп аударылган салам өемен шаулатып җил исеп китте һәм шуннан соң кинәт бөтен нәрсә тынып калды. Кешеләргә бу ничектер шомлы да, дәртләндергеч тә тәэсир итте.

Бер машинаны төяп тә бетерделәр, аның урынына, үлчәү янына, икенчесе килеп туктады. Бер төркем хатын-кызлар ындыр табагының икенче башында тарау яткан ашлыкны көшелләргә өяргә керештеләр, Мәрдәншә агай белән ике-өч ир кеше көшелне икенче баштан салам белән яба бардылар.

Икенче машинаны да төяп бетереп, бортларны ябарга тотынгач, Мәрдәншә агай халык күбрәк җыелган җиргә килде дә, башындагы кепкасын салып, тирләгән чәчләрен сыпырып куйды.

— Эх!— диде, елмаеп.— Төяп бетермичә әйтмәм дигәнием, булмас, ахры, малайкай! Әй, катыннар... кемнәр

бар анда, килегез әле мондарак, бер хәбәр әйтәм... Әле генә радиодан бер әйбәт хәбәр ишетеп кайттым загатзирна алдында...

Барысы да эшләреннән туктап калдылар.

— Иптәш Зверев[1] даклатын сөйләделәр!— диде Мәрдәншә агай, күтәренке тавыш белән.— Налукны кимету турында яңа закун чыккан, иптәшләр-җәмәгать!.. Менә сезгә хәбәр шул... Барысын да истә калдырып булмады... Заһирҗанны әйтәм, белеп чәйнәгән икән, малайкай! Налук хәзер сутый исәбеннән генә алыначак, элекке кебек сыер, сарык налуклары бетә... Шулай, җәмәгать-иптәшләр... Боларның барысы да керестиәнгә, җәгъни сезнең белән безгә, бөтен кешегә җиңеллек булсын өчен эшләнә. Мәгънәсе шул аның... Яртылаш киметелә налук хәзер. Әле монсы башы гына, ди, калхуз турында, безнең турыда тагын да яңа закуннар булачак, ди... Эх, гәҗит җук бит, Сәгыйть, малайкай, мин-ни рәтләп аңлата да белмим... Анда баганага радио куйганнар. Халык җыелган, авызларын күтәреп тыңлап торалар. «Нәрсә бар да нәрсә бар? Әллә тагы сугыш башланганмы?» Кеше арасыннан тыгылып кердем дә тыңлыйм... Кайтып җиткәнче җөрәк үз урынында түгел... Анда тагын үзебезнең Булатыфны очраттым, менә, ди, безгә машиналар бирәләр, алып кайт, ди. Әле яңа гына шәһәрдән килгәннәр, җулны белмиләр, ди...

Чыннан да шатлыклы, чыннан да куанычлы хәбәр иде бу. Кешеләрнең йөзе кинәт балкып китте, ирексездән һәркем елмаеп җибәрде, һәм барысы да, бер-берсен бүлеп, берьюлы сөйләргә, шаулашырга тотындылар.

— Якшы хәбәрең өчен авызыңа бал да май!

— Кит аннан, Мәрдәншә абзыкаем, чынлап укмы?

— Ай, рәхмәт яугыры!

— Болай булгач, тормышлар якшыра дигән сүз!..

Сәгыйть, гомумән, нинди дә булса көтелмәгән яңалык ишеткән чактагы кебек, беразга аптырап калгандай булды, кинәт төшкән көчле яктылыктан күзе, зиһене чагылган шикелле, тиз генә фикерен җыя алмый торды. Аның күкрәге кем өчендер горурлану хисе белән, сөенеч, шатлык хисе белән тулды. Ул шушы гади кешеләр күңеленә, үзенең күңеленә шундый якын, аңлаешлы булган яңа карарны чыгаручы зур кешеләр белән, Партия башында торган кешеләр белән үзе арасында ниндидер бәйләнеш барлыгын, күзгә күренеп торган туганлык җебе барлыгын, ышанычлы якынлык җебе барлыгын тойган кебек булды. Һәм аңа мондагы һәркем шундый ук тойгы кичерә кебек тоелды.

[1] Зверев А.Г. — ул елларда СССР финанс министры.

— Шулай да машиналарны тутырмыйча булмас. Әйдәгез, тизрәк... яңгыр килгәнче...— диде Мәрдәншә агай, исенә килеп.

Кешеләр, әйтерсең аның әйтүенә генә түгел, бәлки, икенче нәрсәгә, үзләренең күңелләрен канатландырган яңа хискә буйсынып, шундук кыймылдашып куйдылар, җилләнеп, дәртләнеп эшкә тотындылар. Куллар тизрәк, җитезрәк хәрәкәтләнде, тимер соскылар, зур-зур чиләкләр шаулап, күңеллеләнеп, бодай көшеле кимерде, юан-юан капчыклар тулып, авыраеп, үлчәү янына тезелә бардылар.

Ләкин машинаның дүртесен дә төяп бетереп булмады. Яңгыр болыты бөтенләй якынлашты. Берән-сәрән тамчылар төшә башлады. Бодайны, чыланмасын өчен, калын итеп салам белән каплап бетерделәр.

Якындагы куак яфракларын шаулатып, беренче яңгыр йөгереп узды. Хатын-кызлар, ирләр, кычкырышып, лапас эченә йөгерделәр.

Кара болыт баш өстенә үк килеп җитте, һәм шул вакыт томалап, коеп яңгыр яварга тотынды. Мич төбе кебек булып кипкән, каткан җир өстенә шап-шоп яңгыр тамчылары бәрелде. Гәрәбәдәй эре тамчылар тузан туздырып як-якка чәчрәделәр, шаянланып, шатланып сикерделәр, биештеләр. Ындыр табагы читендәге яшел үлән яфраклары, тамчылар килеп тигән саен кинәт башларын иеп, сөрлегеп-сөрлегеп киттеләр, ләкин калкынырга да өлгермәделәр, тагын бер-бер артлы атынырга, селкенергә тотындылар. Лапас түбәсеннән асылынып торган салам очларыннан шыбырдап су коелды. Кипкән, кибеккән җир өсте, рәхәт ләззәткә бирелеп, тыныч кына чыланып, ялтырап ятты.

Мәрдәншә агай, лапас алдында чүгәләп утырган көе, кесәсеннән ашыкмыйча гына тәмәке янчыгы чыгарды. Лапас баганасына сөялеп, тыштагы ургылып яуган яңгырга карап торучы Сәгыйть ягына башын борды да:

— Гырушчикка кеше юк бит, малайкай,— диде.— Яңгыр туктагач та икегезгә дә утырып китәргә туры килмәгәе.

Сәгыйть Нәсимгә күз төшереп алды. Ул үзе риза иде.

— Барабыз, ник бармаска!— диде Нәсим дә, аның күз карашын аңлап.

Мәрдәншә агай тәмәкесен тәмләп кенә суырды да, эчке бер канәгатьләнү белдергән тавыш белән, әллә яңгыр турында, әллә үзе алып кайткан зур хәбәр турында:

— Бик вакытлы булды бу,— диде, юеш җир өстеннән күзен алмыйча,— ай-яй вакытлы булды!

## Алтынчы бүлек

### I

Әле һаман чикерткәләр сайрый, көн урталарында кызу кояш нуры маңгайларны, аркаларны пешерә, кырлар-басулар өстендә күккә элеп куйган чиксез зур пыяла җәймә кебек, ялтыравык рәшә тирбәлә, ерактагы тау сикәлтәләре, урманнар зәңгәрсу томанга төренеп күренә. Әйтерсең берни үзгәрмәгән, әйтерсең яшеллек белән капланган җир өсте гомергә шулай кояш нуры астында шатлыклы елмаеп, җемелдәп ятыр. Ләкин бу беренче карашка гына шулай. Бу инде җәйге чикерткәләр түгел, бу инде җәйге рәшә дә түгел, гөр килеп, күкрәп утырган җәйге яшеллек тә түгел. Табигатьнең яшел бизәге хәзер күзгә күренеп уңа бара, һәм сиздермичә генә килеп урманнарга, үлән-чәчәкләргә, тау итәкләренә һәм таллыкларга кунган сары сырхауны яшереп калырга инде бер генә нәрсәнең дә — рәшәләрнең дә, чикерткәләр сайравының да көченнән килми. Бәрәңге бакчаларында кызгылт тутыклар күренә; көнбагыш сабаклары, түгәрәк зур башларын күтәрә алмыйча, моңаеп, салынып утыралар; бушап, тынып калган басуларда көтү йөри; ындыр табагы урыннарында төркем-төркем күгәрченнәр, боҗыр, көртлекләр туена; олы юлны аркылы кисеп, бөтен басу буенча, трактор көннең-көнозын аксыл-саргылт камыл өстеннән киң кара эз суза. Түбә өстен әлегә юеш болытлар да капламаган, җанга тия торган, кием аша иңбашларга үтеп төшә торган салкын, бәйләнчек яңгырлар да яумый, юллар да ләпеккә батмаган.

Әмма бөтен нәрсәдә көз исе килә, көз...

Кайчакларда бөтен тирә-як тынып кала. Шундый чакларда зәп-зәңгәр күк биеклеген моңлы бер чың белән чыңлатып торналар очканы күренә һәм яшь, яңгыравык тавыш белән кыйгаклый-кыйгаклый, җәй буе күзгә-башка күренмәгән кыр казлары төркеме узып китә; биек тупыл башларыннан ботакларга бәрелә-сугыла, шыштырдап, дәфтәр бите кебек киң, яшькелт-сары яфраклар өзелеп төшә; җил аларны лапас түбәләренә, өй кыекларына китереп утырта, такыр сукмакларга, баскыч төпләренә җәеп ташлый.

Көз исе килә, көз...

Шушындый вакытта — уйсу-җыпты җирләрдә сарык җөне кебек куе, беренче суган кыягы кебек ямь-яшел, йомшак курпы калкып чыкканда, нәфис юкә яфракларына төртке-төртке каралҗым таплар төшкәндә — күңел

ниндидер әчке сагыш-моң белән, тынгысыз, борчулы хәсрәт белән тула. Үзең өчен бик кадерле, бик кирәкле ниндидер нәрсә сиздермичә генә кулыңнан ычкына бара шикелле тоела. Нигә алай икән соң ул? Яз башында иске яфраклар арасыннан беренче үләннәр күтәрелеп чыккан чакта, җылы бу бөркеп яткан җир өстендә беренче тургайлар сайраган чакта без тагын да яшәреп киткәндәй булабыз икән, күңелләрне тормыш дәрте, илһам, омтылыш җилкендерә икән, безнең алда бөтенләй башланмаган бөтен бер бәхет-шатлык тулып ята шикелле тоела икән — көзге сарылык, көзге өнсез тынлык безгә, киресенчә, яшьлекнең һәм... моңарчы барлыгы-юклыгы әллә ни беленмәгән бәхетнең, ваемсыз шатлыкның артта кала баруы турында сиздерми микән?

Сәгыйть чабылган, көтү таптап, ашап бетергән болын аша урманнан кайтып барганда шундый бер тойгы кичерде.

Аның күкрәге тараеп, кысылып калган шикелле булды, тын алырга һава җитми кебек иде, юк, һава гына түгел, тагын да ниндидер бик әһәмиятле, бик кирәкле ниндидер нәрсә җитми кебек иде. Нәрсә икән соң ул? Һы, нәрсә! Билгеле — ул... ул...

Сәгыйть инде соңгы вакытта аның турында бөтенләй диярлек уйламый башлаган иде. «Күрәсең, безнең арада хәзер берни дә калмагандыр инде. Калмасын әйдә!» дигән уй белән килешергә тырышкан иде. Ул хәтта кайчакларда, сөенеп: «Нинди шәп булды! Нинди җиңел котылдым!»— дип тә куя торган иде.

Менә бүген аның шундый зур авырлык белән, шундый әрнеткеч сыкрану белән басылырга, тынарга мәҗбүр булган күңеле тагын бер мәртәбә канат җилпергә тотынды. «Шулай ук бөтенесе дә бетте микәнни?— диде ул, әле кайчан гына аны шулай мәңгегә онытырга ныклы сүз бирүенә үкенеп.— Шулай ук минем бәхет тә шушы яшел җәй кебек кыска гомерле булыр микәнни?.. Көз... Аһ, нинди шәфкатьсез көз! Нигә гомергә гел җәй генә булып тормый икән?!»

Сәгыйть аны бөтенләйгә йөрәгеннән йолкып ташларга тырышуының бары тик бер көчәнү генә, бары тик үз-үзеңне алдау гына булганлыгын һәм, һич югы, андый шәфкатьсезлекне, андый батырлыкны беркайчан да беренче булып үзе эшли алмаячагын аңлады. Боларның барысы да тынгысыз, ялгыз күңелнең бер шашынуы гына, вакытлыча үз-үзеңне юатырга тырышу гына булган икән. Аннан башка дөньяның яме дә булмаячак һәм канәгатьсез йөрәк беркайчан тынычлык таба алмаячак икән.

Юк, тизрәк Казанга китәргә кирәк, Казанга!..

Беренче сентябрьгә кадәр төп-төгәл унике көн бар иде әле, һәм бу вакытта студентлар әле җыела да башламыйлар иде. Ләкин аңа ни өчендер Ида хәзер Казандадыр шикелле тоелды. Аның тизрәк аны күрәсе килде.

Ул өйгә тыны бетеп, ашыгып кайтып керде.

— Әнкәй, мин китәм!— диде кычкырып, ниндидер сөенечле хәбәр алып кайткан шикелле.

— Китәсең? Кая китәсең, тагын Бибинурларгамы?— диде Миңнисәттәй, улының очкынланган күзләренә карап.

— Китәм, әнкәй!.. Укырга китәм — әзерләнергә кирәк...

— Укырга?!— Миңнисәттәй кинәт каушап төште, ялгыш ишетмәдемме дигәндәй, тагын кайтарып сорады: — Укырга китәм, дисеңме? Ай Алла, менәтерә, ниндәен укуга?.. Әле соң кая — беркем дә кузгалмый лабаса.

— Кузгалмасын — мин китәм! Җитте, ял иттем! Иртәгә китәм!

— Күргәндәй дә булмадым,— диде Миңнисәттәй. Лып итеп урындыкка утырды да кулларын тезенә куеп, хәрәкәтсез калды.— Сезнең икегез дә бер калыптан сугылган: исләренә төште исә исләре китә, тоткан җирдән генә сындырырга булсын... Әнкәгез дә кирәкми, ай Алла... беркем дә кирәкми... Ана күңеле балада, бала күңеле далада — менә шул инде...

Сәгыйтьнең әнкәсен барып кочаклыйсы, аның сирәгәйгән кыска, йомшак чәчләреннән иркәләп сыйпыйсы килде. Ләкин бу минутта ул моның өчен үзендә көч тә, кыюлык та тапмады. Уллык хисенә караганда, анда хәзер гашыйк егет хисе көчлерәк иде.

— Соң, бүген үк димим бит мин, әнкәй!— диде ул, аны юатырга тырышып.— Минем анда эшлисе эш бар, доклад язасы бар.

Сәгыйть, үз-үзен ялган сөйләүдә тотып, кызарынып китте. Хәер, бу бик үк ялган да түгел иде, фәнни түгәрәктә тикшерелүгә куелачак докладны аңа барыбер язып бетерергә һәм, һичшиксез, Казанга баргач язып бетерергә кирәк иде. Уку башланганчыга кадәр калган вакытны, әлбәттә, шуның өчен файдаланырга туры киләчәк иде. Тик бу турыда ул ныклап уйлап кына җиткермәгән иде.

Ни булса булды, мәсьәлә хәл ителде! Китәргә булгач китәргә!

— Кайчан китәсең соң? Иртәгә үкмени? Ай Алла, нәрсәләр әзерләргә соң — берни җитеш түгел...

— Иртәгә китәм! Иртәгә кич!— дип кычкырды Сәгыйть, ишеккә ташланып.

Ул, авыз эченнән ниндидер марш көйли-көйли, Зәйтүнәләргә йөгерде. Зәйтүнәгә аның беренче курска алынуы турында язу килгән иде, һәм ул хәзер, түземсезлек белән, Сәгыйтьнең кайчан Казанга кузгаласын гына көтеп тора иде.

Сәгыйть ишегалдына йөгереп кергәндә, Зәйтүнә, яңа бәрәңге тутырылган зур яшел табак тоткан көе, бакча капкасыннан чыгып килә иде. Аның өстендә кыска җиңле, төсе уңган алсу ситсы күлмәктән башка берни юк иде. Сәгыйтькә ул бу кыска күлмәктән бөтенләй балачага булып күренде. Аның бармаклары, кара-кучкыл матур беләкләре йомшак кара туфракка буялган иде. Туфрак аның хәтта күлмәк итәгенә дә, шәрә тез капкачларына да сыланып калган иде.

Күршесен күргәч тә ул кызарып китте, уңайсызланып күзләрен түбән иде һәм, нишләргә дә белмичә, бераз аңа карап торгач, бәрәңгеле табагын җиргә утыртып куйды да чәнти бармагы белән ачык изүен каплаштырырга тотынды.

— Исәнме, күрше!— диде Сәгыйть, кызны оялтмас өчен аның ягына бөтенләй карамаска тырышып.— Китәбез! Иртәгә китәм! Әзерләнденме?

— Китәбез?! Китәсез?!

— Әйе, китәбез! Әзерләнеп беттеңме?

— Мин инде күптән әзер!

Зәйтүнә бүтән бер нәрсә турында да сораштырып тормады, җирдәге бәрәңгесен дә, хәтта студент егетнең үзен дә онытып, тиз генә өйләренә йөгереп кереп китте. Өй эчендә аның кемгәдер шатланып: «Китәбез! Иртәгә!»— дип кычкырганы ишетелде.

Сәгыйть, үзенең бурычы үтәлгәнгә санап, кире үзләренә кайтты да җәй буена шүрлектә ял итеп яткан китап-дәфтәрләренең тузаннарын каккаларга, юлга алып чыгасы әйберләрен караштырырга тотынды.

Өйдәге һәрбер нәрсә аның өчен кинәт бөтен мәгънәсен, бөтен кызыгын югалтты. Аның тизрәк төнне уздырып җибәрәсе, тизрәк таң аттырасы килде.

Бераздан соң, аның артыннан ук диярлек, кызулап Хәбирәттәй кереп җитте, исәнлек-саулык та сорашып тормады, туп-туры сүзгә башлады.

— Ниятләгәнсең икән алайса? Син инде, Сәгыйтькәем, безнең Зәйтүнәне ташлап-нитеп китә күрмә инде, бар ышаныч синдә... Бала-чага дисәң, бала-чага, бер дә акыл кермәгән, Ходаем. Берәр мич булса да сохарый киптерик-

ме, дигәнием, мин анда салдатка китмим бит капчыклап сохарый алып чыгарга, ди. Сөйләшеп кара син аның белән, гөнаһшымнык! Җул азабы — гүр газабы... Ни булмас дисең җулда! Элеккедән әйтәм, элек сохарыйсыз чыгарырсың кешене җулга! Маен, балын салырсың инде, акчасы да кирәк булыр... Кыз бала бит, Миңниса... Донҗа күргәне бармы әле аның, гөнаһшымнык! Безнең Бикбулат кына ул яшьтән үк читендә дә, кырында да булды дигәндәй... Кара син, Сәгыйть, хәлен белебрәк тор инде Казанга баргач... Өйрәтәсен өйрәт, күрсәтәсен күрсәт, кирәк икән — әйткәләп тә, тиргәп тә ал, сиңа килешә ул...

Хәбирәттәй бер тотынса, сөйләргә һич иренми иде инде ул. Кайчан юлга чыгу, юлга нәрсәләр әзерләү турындагы сүзләре беткәч тә, үзе дә сизмәстән, Бикбулаты турында, Тәгъзимәсе турында, ниһаять, «музыкан» Фәүзие турында тотынды, аннан соң яңадан Зәйтүнәсенә әйләнеп кайтты, балаларының һаман яхшылыкларын, уңганлыкларын мактады.

Кайбер аналар үз балаларын гел хурлап кына торган кебек, кайберләре, киресенчә, алар турында мактаудан башка бүтән берни дә сөйләмиләр. Заһирҗан агай балаларының берсен дә хурлап телгә алырлык булмаса да, Сәгыйть шулай да Хәбирәттәйнең «безнең Фәүзи», «безнең Бикбулат» дип, уллары-кызлары турында артык киң җәелеп китүен бик үк яратып бетерми иде. Ләкин хәзер ул аның сүзендә бернинди мактану да, масаю да сизмәде. Киресенчә, ул аңа үзенең балалары белән, бигрәк тә... Зәйтүнәсе белән бик хаклы рәвештә горурлана ала шикелле тоелды. Нигә, Бикбулаты начармыни? Лейтенант, армиядә хезмәт итә, ай саен йортларына акча салып тора. Аннан соң мондагы балаларының кай җире белән горурланмаслык? Тәгъзимәсе гел отличнога укый, Фәүзие — «музыкан»... Зәйтүнәсен инде әйтеп тә торасы юк...

Хәбирәттәй, чыгып китмәкче булып, әле ишек соткасына тотынды, әле яңадан күршесе янына килеп утырды, һаман теленә баш була алмыйча, тегесен искә алды, монысын искә алды, әледән-әле Сәгыйтькә эндәште — бер ел күрми торган диярсең!

Шулай да ул чыгып киткәч, Сәгыйтькә өй эче тагын да ныграк бушап калган шикелле тоелды.

... Заһирҗан агай, арбага яңа арыш саламы салып, ат җигеп алып кайтты. Өй эчендәгеләр студентны озата чыктылар.

— Хат яз, кара аны!— диде Гамбәр.

— Мин сораган китапларны җибәрергә онытма,— диде Барис, соңгы мәртәбә энесенең кулын кысып.

— Сау бул, сау бул, абзыкай!— диде Гамбәр, Тәлгать булып, үзе белән алып чыккан малаеның нәни кулларын болгап.

Менә Зәйтүнәнең дә калын тактадан ясалган, куе кара буяуга буялган чемоданын арбага чыгарып салдылар. Улын озатырга станциягә кадәр баручы Миңнисәттәй арба эченә үк кереп, аякларын бөкләп утырды, Заһирҗан агай, салмак кына кыймылдап, киртәгә бәйләп куйган дилбегәне чишеп алды. Яхшы итеп майланган тимер күчәрле арба кузгалып китте.

Шул чакны кычкырып елаган балалар тавышы ишетеп, барысы да артларына борылып карадылар. Урамның икенче ягыннан, бар көченә акырып елый-елый, Фәүзи йөгереп килә иде. Гамбәр, аның тузанга буялып беткән борынын, кызарынган, җимерелгән кыяфәтен күреп, тыела алмыйча көләргә кереште. Хәбирәттәй исә: «Җул чыкканда җылап калалармыни!»— дип, малаен тиргәргә тотынды.

— Мин дә бара-ам, мин дә-ә!.. Калдырып китә-ә!— дип кычкырды Фәүзи яшь аралаш һәм томырылып арба артыннан ташланды.

Ләкин Хәбирәттәй аны шундук эләктереп алды, малай исә аның саен тыпырчынды, аның саен ярсыбрак елады.

— Үзе алып барам диде-е!.. Мин дә бара-ам... Казанга-а!..

Заһирҗан агай атын туктатты да, чыбыркысын күрсәтеп:

— Җылале, җыла тагы!— диде, ачуланмакчы булып.— Бар, кереп кит өйгә!

Фәүзи барыбер туктамады. Зәйтүнә, арбадан тиз генә сикереп төште дә, көлә-көлә энесе янына килде, чүгәләгән көе, аның ике кулыннан тотып алды, яратып, иркәләп, аны күкрәгенә кысты, бит очларыннан үпте.

— Җылама, җүләр, син бит инде зур кеше!— диде ул, Фәүзине юатып.— Мин әле тагын кайтам, көтеп кенә тор. Менә үзем барып урнашыйм да, укый башлыйм да сине кайтып алып китәрмен. Менә күрерсең, чынлап.

— Китәрсең, алдакчы!— диде бала, күз яшенә тыгылып, ләкин инде бөтенләй тынычлана башлаган тавыш белән.

— Кыш көне мин сиңа менә дигән гармун алып кайтырмын!— дип кычкырды Зәйтүнә, яңадан арбага утыргач.

Ат кузгалып китте.

Фәүзи — бала, аның әле бөтен киләчәге алда, ул әле

үсәр, зур булыр, теләгән җиренә барыр, теләгән нәрсәләрен күрер һәм, һичшиксез, сабый күңелен хыялландырган бөек теләгенә дә ирешер. Хәзергә аны юатып кына калдырдылар, битеннән үптеләр, күкрәкләренә кыстылар.

Рәшитне дә аның кебек үк калдырып киттеләр. Ул да елады, күз яше белән түгел — йөрәге белән, күңеле белән елады, нишләргә белмичә елады. Аңа беркем бернинди вәгъдә бирмәде, беркем юатмады, битеннән дә үпмәде, күкрәгенә дә кысмады. Мөгаен, инде беркайчан да үпмәсләр дә, күкрәкләренә дә кысмаслар...

Ул аның кайчан китәсен алдан ук белеп торды. Кайчан китәсен генә түгел, кайсы атка утырып китәсен дә, кемнәр белән китәсен дә белеп торды. Һәм ул, ындыр табагы читендә утырган үзенең «Коммунар»ына сөялгән көе, олы юл буенча китеп барган җигүле атка, арбадагы ак яулыкка бик озак карап торды. Күңелен коточкыч сагыш биләп алды. «Әллә мине укымас дисеңме?! Мин әле... мин... барыбер сездән калышмам! Нәсим абый укыганны... Мин дә укырмын...» — диде ул, үз-үзенә ант биргән кебек, кискен бер ярсу һәм өметсезлек белән.

Шулай да аның Фәүзи кебек күз яшьләре белән елыйсы килде, үзен ташлап китеп барган бердәнбер, кадерле шул кансыз кыз ишетерлек итеп елыйсы килде.

Ләкин ул — җегет кеше иде.

## II

Поезд Казанга якынлашып килгәндә, караңгы төшә башлады. Вагон артыннан йөгереп барган тигезле-тигезсез кырлар, кызыл ярлар, калкулык буена сыенып утырган тавыш-тынсыз авыллар тоташ бер болганчык караңгылыкка әйләнә бардылар һәм минут саен поездга якынайганнан-якынайдылар. Соргылт караңгылык һаман куера төште. Телеграф баганалары, юл читенә тезелеп утырган агачлар, әледән-әле күренеп калган тәбәнәк йортлар, күзләрен чекерәйтеп, туп-туры вагон тәрәзәсенә карап бара башладылар. Еракта, авыл юлларында тирбәлүче автомашина утлары күренде, кисәк кенә тәбәнәк ярлар эчендә йокымсырап яткан буалар, елга өсләре ялтырап китте. Кайчакларда поезд кара урман эченә килеп керде, һәм тәрәзә алды кинәт бөтенләй капланып калды. Паровоз, караңгыда үзе генә калганга, курыкмас өчен үз-үзен дәртләндерергә тырышкан сыман, тирә-якны тынычсыз, яңгыравык тавыш белән күмеп кычкыра-кычкыра, һаман алга ыргылды. Алда көтмәгәндә бер күзле яшел утлар калкып чыктылар, бераз гына урыннарында

басып тордылар да, үзләренә якынлашып килгән таныш дөбердекне ишетеп, кинәт кенә ычкынып киттеләр һәм, елмаеша-елмаеша, күз иярмәслек тизлек белән каршыга чабарга тотындылар. Аста шпаллар тирбәлде, рельслар шакылдады, иң койрыкта, соңгы вагоннан бер адым да калмыйча, караңгылык куалап барды.

Менә кемдер:

— Казан!— диде.

Вагон эче шундук аякка басты, пассажирлар тәрәзәләргә ябырылдылар. Кайдадыр еракта, төн караңгылыгы эчендә тирбәлеп, кыймылдашып торган меңнәрчә ут төрткеләре күренде.

Ул утлар шундый күп иде, шундый якты иде — анда, шәһәр өстендә, бернинди караңгылык та, бернинди төн дә юктыр шикелле иде. Ул якта бөтенләй икенче дөнья, икенче тормыш иде, һәм акыл җитмәслек шундый серле, шундый мәһабәт ул дөнья үзенең яңалыгы белән дә, үзенең гүзәллеге белән дә яшь кызның бөтен зиһенен томалап алды, аның йөрәген ашкынып тибәргә мәҗбүр итте. Зәйтүнә үзе күргән нәрсәгә ышанырга да, ышанмаска да белмәде һәм шул ук вакытта һаман зурая, һаман ачыклана барган якты утлардан күзен ала алмыйча, тылсымланган, сихерләнгән шикелле тәрәзәгә капланып тик торды. «Казан!..— диде ул күңеленнән.— Казан!..» Шул вакыт аның күз алдына бала чактан ук таныш күренешләр — данлы шәһәрне бөтен җир йөзендә шул көчле утлар диңгезе кебек бизәп, яктыртып торган бөек юлбашчы, бөек Горькийлар, Тукайлар килде.

Шәһәрнең үзенә кердек дигәч тә бик озак бардылар. Менә бик күп тәрәзәләрендә электр нурлары балкыган йортлар күренде, вагон стенасы аша, тәрәзә пыяласы аша ниндидер ят тавышлар үтеп керде, урамнардан бер-бер артлы тезелешеп чапкан машиналар күренеп калды.

Күптән инде аягүрә басып килгән ирләр, хатын-кызлар, яшьләр, картлар — барысы да чемоданнарын, капчыкларын, төенчекләрен кулларына алдылар һәм вагон, тормозларын шыгырдатып, коточкыч зур тәрәзәле вокзал каршысына җитеп туктагач та, кинәт кенә тынып калып, ишеккә таба ябырылдылар.

Сәгыйть үз чемоданын уң кулына алды, сулы белән, егет кеше буларак, Зәйтүнәнең авыр сандыгына тотынды.

— Әйдә, син алдан атла, үзем алып чыгармын,— диде ул авылдашына.

Ләкин әле моңарчы беркемнән дә мондый яхшылык күрмәгән һәм, гомумән, иркәләнүне, кешегә салгашуны

ни дип тә белмичә, барысын да үзе эшләргә, үзе башкарырга гадәтләнгән гади авыл кызы, гаепле кеше шикелле елмаеп, үз чемоданына ныгытып тотынды.

— Җук, җук!.. Мин үзем... авыр түгел ул!

Алар шаярышып бәхәсләшкән, тарткалашкан арада, арттан пассажирлар килеп өелде, юл өстендә тоткарлык барлыкка килде.

— Әйдәгез, тизрәк! Туктама!— дип кычкырган тавышлар ишетелде.

Сәгыйтькә баштагы теләгеннән кире кайтырга туры килде. Алар биек тимер капка аша вокзал мәйданына килеп чыктылар.

Шәһәрдә әлерәк кенә яңгыр явып узган иде, һава саф, салкынча иде. Аяк астында юеш асфальт шыштырдады, әле анда, әле монда, көзге кебек ялтырап, җыелып яткан су күренде, як-якка алтын нурлар сибеп, су өстендә, тигез асфальтта электр шәүләләре җемелдәште. Бертуктаусыз автомобиль гудоклары, трамвай звонклары, каядыр ашыгучы, тыз-быз килүче кешеләрнең кычкырып сөйләшүләре ишетелде һәм боларның барысы да бергә кушылып, буталып, колак төбендә үзенә бер төрле гүелдәү булып яңгырап торды.

— Менә сиңа шәһәр!— диде Сәгыйть, үзе янынннан атлап барган Зәйтүнәгә карап.— И Казан! Нурлы Казан, ямьле Казан!..

— И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!— диде Зәйтүнә, аны төзәтеп.

— Нәрсә, нәрсә? Кара, син әле студентны өйрәтмәкче буласыңмы? Карап-карап торам да, тагын бер карап куям — бик үзсүзле күренәсең әле син, күрше, гел миңа каршы төшәсең! Кара аны, бик тиз колагыңны борырмын!.. «Әнкәй сиңа ни әйтте — тик толылга булмыйммы»— оныттың дамы? Әһә, әнә безнең трамвай килә — киттек!

Корыч рельслар буенча күңелле шыгырдап, яртысы кызылга, яртысы сарыга буялган матур трамвай вагоны килеп җитте. Аның тар рамлы тәрәзәләрендә күңелле ут балкый, бераз гына артка ташланып утырган матур кешеләрнең башлары күренә иде. Вагон туктады, тоткасыз ишекләр шундук үзләреннән-үзләре ачылып китте, матур, яхшы киемнәр кигән яшь егетләр, кызлар, алтын погонлы хәрбиләр ашыкмыйча гына бер-бер артлы җиргә коелыша башладылар.

— Әйдә, әнә теге ишеккә!— дип кычкырды Сәгыйть, Зәйтүнәне җитәкләгән шикелле, үз артыннан ияртеп.

Тәрәзә аша һаман шул ук исәпсез-хисапсыз электр

фонарьлары, теләсә кайда эленеп торган якты, тонык утлар күренеп калды, әкрен генә йомшак утыргычлар тирбәлде һәм аста һаман рельслар шыгырдады. Зәйтүнәгә ул әле булса поездда утырып бара шикелле тоелды, тик монда вагон гына икенчерәк иде: таррак, кыскарак иде дә кешеләрнең күбесе аягүрә басып бара иде.

Сәгыйть Зәйтүнәне үзләренең гомуми торагына алып китте. Трамвайга утыргач, аны бер уй борчый башлады.

«Әгәр Ида килгән булса?»— диде ул, аның алдында курку кебек бер нәрсә тоеп.

Әгәр килгән булса, әгәр аның чит кыз белән икәүдән-икәү генә утырып баруын күрсә? Нәрсә дияр ул? Ул бит кайчакта тузандайны тубалдай итеп күрергә ярата. Туктале, нәрсәсе бар соң моның? Үз авылдашыңны, тәҗрибәсез авылдашыңны укырга алып килүдән ни була?

Шулаен шулай да, Зәйтүнәне кайда урнаштырырга икән? Торакта әле кызлардан беркем юктыр. Студентлар килә башлаганчы дип, аны, үз бүлмәңдә торгызып торыргамыни? Әллә соң берүзен бер бүлмәгә урнаштырыргамы? Юк, берничек тә булмый, ярамый... Әгәр берәр бүлмәдә ялгыш кына таныш кызлар очраса гына инде... Ләкин тагын — ул таныш кызлар, бәлки, группадашлары — нәрсә диярләр? Ида нәрсә дияр?..

Кем булсын соң анда, алардан башка бу вакытта кем килсен!.. Ул шәһәр урамына да чыга алмас, адашыр, куркыр, аннан соң аның үзен генә калдыру, гомумән, бик зур игелексезлек булачак. Ни генә булмасын, башта аңа барыбер аның белән бергә йөрергә, шәһәрне дә, университетны да күрсәтергә, кинога-фәләнгә дә алып барырга туры киләчәк...

Трамвайда алар берни сөйләшмәделәр. Әле генә ачык йөзле Сәгыйть кинәт җитдиләнеп, уйчанланып китте. Зәйтүнә моны шундук күреп алды.

«Юк, туктале,— диде Сәгыйть, үз-үзе белән бәхәсләшкән шикелле.— Нәрсәдән куркам, шүрлим соң әле мин? Менә җүләр! Нигә кирәге бар боларның?..» Ләкин шундук аңа бер тавыш, тирәндәге эчке бер тавыш каршы төште. Әгәр ул аның белән бергә иптәшләре алдында күренергә курка икән, димәк, монда берни дә юк түгел! Димәк, ул уйлаганча, бу кыз бик үк ятим, бик үк мескен, көчсез түгел, димәк, анда егетләр күңелен тынычсызландыра ала торган көч тә, матурлык та бар...

Шул чакны аның күз алдына печән чабу, өмә һәм яшенле караңгы төн күренешләре килеп басты, һәм кичәгенәк кенә булган шикелле якын тоелган, ләкин инде узган, төрле истәлекләр арасында күмелеп калган ул

көннәр аңа бик кызганыч кебек булды. Йөрәге яшереп кенә, азгынланып, сагышланып тибеп куйды.

Барысы да көтелмәгәнчә килеп чыкты. Сәгыйтьләр белән бер бүлмәдә торучы Павел — физмат студенты инде әллә кайчан Казанга килгән, бүлмә ачык, җитмәсә, почмакта буш койка да тора иде. Зәйтүнәне урнаштыру мәсьәләсе тагын да җиңелрәк булды. Коридорның икенче башындагы бер бүлмәдә быел беренче курска керүче өч кыз тора иде. Алар әле күптән түгел генә имтиханнар тапшырганнар, укырга кабул ителгәннәр, ләкин туган яклары ерак булганга, өйләренә кайтып тормыйча, беренче сентябрьне көтеп, бүлмәдә торып калганнар иде. Араларында ике татар кызы да бар иде. Хәтта аларның берсе Зәйтүнә кебек үк химфакка кергән иде.

Кызлар белән Зәйтүнә бик тиз уртак тел тапты, Сәгыйть исә мәсьәләнең болай тиз, җиңел чишелүенә чын күңеленнән сөенде. Ул Зәйтүнә өчен шундук урын әзерләп бирде: коридордан койка кертте, койканы әйбәтләп урнаштырды да:

— Менә сиңа студент түшәге!— диде, койканың тимер пружинасына сугып.— Кулыңны баш астыңа куй да рәхәтләнеп йокла! Астыңа җәяргә берәр нәрсәң бармы? Булмаса, сырманы бирәм.

Зәйтүнә, әйтерсең, әле булса исенә килергә өлгермәгән иде. Ул ап-ак итеп буялган стеналарга, түшәмнәргә, җыйнак, күңелле бүлмә эченә, ягымлы ят кызларга, үзе өчен әзерләнгән зәңгәр койкага сокланып карап торды-торды да, шәһәргә килеп төшкәч әле беренче мәртәбә көлеп җибәрде.

— Бер кичкә — кер мичкә! Казанда булгач, как идәнгә дә ятып җокларга риза!

Ят кызларның кайсы аңа үзенең артык мендәрен, кайсы одеялын тәкъдим итте.

— Җук, җук, минем барысы да бар!— диде куанычы эченә сыймаган Зәйтүнә.

— Хәерле төн!— диде Сәгыйть, саубуллашып.

Павел йоклаган иде инде, Сәгыйть аны уятып тормады. Ачык тәрәзә каршысына килде дә беравык төнге шәһәр өстенә карап торды.

Монда хәзер бөтен нәрсә аңа Иданы хәтерләтте. Ул хәзер аның янында, якында гына. Иртәгә ул аны күрәчәк, аның үзен күрәчәк. Ул моңа нигәдер һич тә шикләнмәде. Ул моны шундый нык тели иде, һәм моның шулай булыры аның өчен һич тә мөмкин булмаслык нәрсә булып тоелмады.

Бүген үк барып торырга вакыт соң иде инде. «Ул хәзер ятып йоклагандыр»,— дип уйлады Сәгыйть.

Ул икенче көнне күзен ачып җибәргәндә, Павел инде торып каядыр чыгып киткән иде. Сәгыйть тиз генә юынып керде, ашады да өстенә яхшы киемнәрен киенә башлады. Зәйтүнәне исенә төшереп, киенүеннән туктап калды. Күңелендә тагын каршылыклы сораулар туды. Нәрсә, аны шул көе калдырып китәргәмени? Юк, болай килешми, һич тә, һич тә килешми. Ярамый.

Ул, өстәлне койка янына ук тартып китереп, авылга исәнлеге-саулыгы турында, бик яхшы килеп җитүе турында хат язды да, бүлмәне бикләп, Зәйтүнә янына керен китте. Кызлар, каядыр барырга әзерләнеп, этажеркага куелган бер бәләкәй генә көзге алдында төзәнеп-бизәнеп яталар иде. Югары курс студентына хөрмәт күрсәтеп, алар шундук аның алдына урындык китереп куйдылар. Сәгыйть утырып тормады.

— Нинди төшләр күрдең Казанда?— диде ул авылдашына.

Зәйтүнә елмаеп җибәрде.

— Бернинди төш күрмәдем. Мин төш күрмим,— диде ул, балаларча беркатлылык белән.

— Шулай да кая барырга җыенасыз әле сез?

— Университетка. Шәһәр күрергә,— диделәр кызлар.

«Менә нинди яхшы!— диде Сәгыйть күңеленнән.— Җил безгә уңайдан гына исеп тора...»

Алар җыйнаулашып урамга чыктылар.

Шәһәр инде күптән уянган, халык аякка баскан иде. Алар трамвайга-фәләнгә утырып тормадылар. Юлда базардан помидор, бәрәңге алып кайтып баручы шәһәр хатыннары очрады, базарга көянтәләп сөттер, майдыр алып баручы, маңгайларын ике-өч кат яулык белән урап бетергән, күлмәк итәкләрен билләреннән аскарак кыстырып куйган татар хатыннары очрады. Урамнардан ялтыравык, нәфис «Победа»лар, озынча кара «ЗИМ»нар, бәләкәч кенә «Москвич»лар узып китте. Тротуарларның күләгә төшкән ягында тыз-быз килгән халык очрады. Өрсәң очып китәрлек җиңел, үтә күренмәле яхшы материялләрдән тегелгән күлмәкләр кигән, шәрә беләкле, ачык муенлы, эшләпәле-эшләпәсез хатыннар, кызлар; башларына йә түбәтәй, йә киң читле салам эшләпә кигән, әлсерәгән кыяфәтле ирләр; аналарының кулларына асылынып барган һәм тезләренә дә җитмәгән кыска күлмәкләренә караганда, кызмы, малаймы икәнен аерып булмаслык алсу битле балалар очрады.

Урам почмакларында чиста ак халат кигән хатыннар кәгазьгә төргән мороженыйлар, чыжлап торган газлы сулар саталар. Киосклар, магазиннар ачык. Йорт буйла-

рында бер-берсеннән тигез ераклыкта яшь юкәләр утыра. Бакчаларда, агач күләгәләрендә күзлекле картлар газета укый; такта белән уратып алынган ком өстендә ялангач балалар уйный. Газоннарда үтә ачык төстәге ал, зәңгәр, ак чәчәкләр елмаеша. Күк йөзе чиста, тыныч. Асфальт урамнар тигез, төз. Өчәр, дүртәр катлы таш йортлардан, урамнан, челтәрле тимер коймалардан, ачык ишекләрдән, зур тәрәзәләрдән — бөтен нәрсәдән күңелле эсселек бәрә, борыннарны рәхәтләндереп кытыклый торган буяу исе, тәмле ашамлык исе килә.

Сәгыйтькә шәһәр бик чиста, бик төзек булып, хатынкызлар искиткеч матур, гүзәл булып күренде.

Сәгыйть Зәйтүнәгә урамнарның, бакчаларның исемнәрен әйтеп барды, ерактан ук күренгән ап-ак Спасс башнясы, Кремль, Сөембикә манарасы турында сөйләде; шәһәрнең тарихи урыннары турында, берничә елдан Казанны әйләндереп алачак биек дамбалар турында сөйләде.

Алар опера театрының яңа, зур бинасы яныннан узып киттеләр, Ленин исемендәге бакчада булдылар да тар гына, кыска гына урамнан югары күтәрелеп, өч почмаклы бер бакча алдына килеп чыктылар. Куе агачлар артында төз колонналы матур, мәһабәт йорт агарып күренде. Ул йорт шундый озын, шундый зур иде, аны баштарак урамның яртысын биләп торадыр дип уйларга мөмкин иде.

— Менә ул — безнең университет!— диде Сәгыйть, кулы белән алга күрсәтеп.

Алар биек ак колонналар астында, тигез таш идәндә туктап калдылар. Аяк асты шундый шома, шундый ялтыравык иде, Зәйтүнә, ялгыш таеп китүдән курыккан шикелле, шундук кулы белән юан колоннага тотынды.

— Университетта үзегез генә адашмассыз бит?— диде Сәгыйть Зәйтүнәнең иптәш кызларына.— Минем тиз генә бер җиргә барасым бар. Карагыз аны, минем авылдашны адаштыра күрмәгез! Килеп җитсәм, бергә кайтырбыз...

— Юк, юк! Барыгыз, Зәйтүнәгә берни булмас!— диештеләр кызлар.

Өч катлы ишек аша салкынча, коры һавалы иркен вестибюльгә килеп кергәч, Зәйтүнә каушагандай итеп туктап калды, гаҗәпләнеп, исе китеп як-ягына каранды, үзе дә сизмәстән, нишләптер иптәш кызларының кулына тотынды. Аны ниндидер тантаналы соклану, изге бер тетрәнү биләп алды. Шул чакны ул үз каршында биек таныш һәйкәл күрде.

— Ленин!— диде ул, пышылдап.

Уң кулын алга сузып, аягүрә тынып калган юлбашчы сыны, аның кыюсызлыгын күреп, аңа дәрт, көч би-

рергә теләгәндәй, әйтерсең: «Әйдә, әйдә, түрдән уз! Ныграк бас!»— диде.

Зәйтүнә кыюланып алга атлады.

Кызлар ишектән кереп киткәч тә, Сәгыйть Чернышевский урамы буенча, Кремль ягына, Идалар торагына китте.

Ничек килеп җиткәнен дә сизмәде.

Гомуми торакта, һәр елны кабатлана торган гадәт буенча, ремонт эшләре әле һаман бетмәгән иде. Ишек төбендә вахтер-фәлән юк иде. Сәгыйть, идәнгә утыртып куелган известьле мичкәләр, шунда ук аунап яткан киң, калын такталар, ком өемнәре яныннан үтеп, аягының кая басканын да тоймыйча, озын баскычтан югарыга менеп китте.

Кинәт ул үзендә шүрләү кебек ниндидер бер нәрсә сизде. Бөтен тәне буенча тыелгысыз эсселек йөгерде. Аның бүлмәсе янына килеп җитте дә, тын алырга да, кыймылдарга да куркып, үзалдына елмайган көе, ипләп кенә ишек шакыды. Эчтән җавап биргән тавыш ишетелмәде. Ул, анда чыннан да беркем дә юклыгына ышанасы килмичә, ишекне кисәк кенә тартып җибәрде. Бүлмә эче буп-буш иде, тып-тын иде. Известьле киң табан эзләре белән чуарланган тузанлы идәндә кәгазь кисәкләре, буш шешәләр аунап ята, бер почмакта тимер койкалар, икенче почмакта, бер-берсенә сыенып, тумбочкалар өелешеп тора иде.

Сәгыйть тынсыз калды. «Килмәгән!»— диде ул үз-үзенә. Килмәгән. Әйе, килмәгән... Димәк, киләчәк! Әле бит вакыт та түгел...

Шулай да ул ишекне кире ябып куйды да, песи кебек сак кына атлап, күрше бүлмәнең дә ишеген тартып карады. «Белмәссең, үзләренеке әзер булмагач, күршеләренә күчеп торуы бар»,— диде ул. Күршеләрнең ишеге бикле иде. Ул өченче бүлмә ишеге янына китте, ансында кычкырып сөйләшкән егетләр тавышы ишетелде, дүртенче бүлмәдә ремонт бара, бишенчесе буш иде. Ул шулай барлык бүлмәләрнең дә диярлек ишеген тартып карады — берән-сәрән ишетелеп куйган кызлар тавышына колак салды — юк, ул чыннан да килмәгән иде әле.

Сәгыйть, инде хәзер нишләргә соң, дигән сыман, бер минут чамасы коридор уртасында басып торды да, ни өчендер чит кеше күзенә күренүдән куркып, тиз генә аска төште. Ишек төбендә баягыча беркем юк иде. «Әллә вахтерны көтеп торып сораргамы соң — кем килгәнен, кем киткәнен ул белми калмас»,— диде ул күңеленнән. Ләкин бу уеннан шундук кире кайтты. Шушы вакыттан монда килеп, кызын эзләп йөргән өчен вахтер хатын ан-

нан көләр, җитмәсә, йөрәгенә кадый торган берәр тупас сүз дә әйтеп ташлар төсле тоелды.

Ул урамга чыкты, йорт тәрәзәләрен калтыратып, колакларны тондырып, коточкыч тавыш белән мотоцикллар чабып узды; иләмсез үкереп, бөтен һаваны сасы газ исе белән пычратып, килбәтсез «МАЗ»лар узды.

Бөтен нәрсә аңа күңелсез, ямьсез булып күренде. Урамда ачу китергеч эссе, тузан, шау-шу иде; кешеләр, бигрәк тә хатын-кызлар, барысы да кыланчык, ахмак, мактанчык иде; урам читеннән төрткәләшеп, акырышып, тәмәке тартып барган малай-шалайлар явыз, хулиган иде.

«Тукта, бәлки, ул хәзер пароходта килә торгандыр!» — диде кинәт Сәгыйть үз-үзенә. Әйе шул, бәлки, ул аны пароходтан төшкән чагында очратыр, әгәр алар ягыннан пароход килеп җитмәгән булса, көтеп торыр.

Ул яңадан күңелләләнеп китте, аның белән булачак очрашу турында хыялланырга тотынды, беренче күргәч тә аңа нинди сүзләр әйтәчәге турында, халык күп булса, аны кочаклап алып булмаячагы, бары тик кул биреп кенә исәнләшергә туры киләчәге турында уйлады. Тиз-тиз атлап, аска, Бауман урамына төште дә, Болак күпере аша чыгып, беренче трамвай туктый торган урынга килеп җитте һәм, трамвайга утырып, дөресрәге, ишек тоткасына асылынып (эчтә кеше бик күп иде), Устьега төшеп китте.

Башта ул пароход килгәнме-юкмы икәнен белергә йөгерде. Дебаркадер кырында бернинди пароход юк иде. Тимер капка янында, пароход килгәнне көтеп, кешеләр өелешеп тора иде, ул алардан пароходның кайсы яктан киләсен сорады — алар бөтенләй икенче яктан киләсе пароходны көтәләр иде. Ул расписание янына барды, тар гына тәрәзә каршысына килеп, белешмә бюросыннан сорады — расписание язылган кара такта да, ак чырайлы хатын да бер үк нәрсәне сөйләде: Идалар ягыннан иртән-иртүк ике пароход килгән дә киткән һәм бүген аннан бүтән бернинди пароход булмаячак икән.

Икенче мәртәбә алдану бигрәк тә кыен булды. Кулларын кесәсенә тыкты да, үз алдында беркемне дә, бер генә нәрсәне дә күрмичә, тәмәкече кеше кебек төкеренә-төкеренә, порт буенча китте. Идел ярына чыгып, чуерташ өстенә утырды.

Елгадан әкрен генә дымсу җил исте, колак очларын, битләрен үбеп алды, борыннарын кытыклап китте. Су өстендә кояш нурлары тирбәлде — күзне чагылдырды. Артларыннан тирән су буразнасы калдырып, моторлы көймәләр узып китте; ялкау гына, юаш кына чайпалып,

ярларына тулып, җәелеп аккан Идел буйларын яңгыраткан моңсу гудок тавышлары ишетелде; авыр пошкырып, ухылдап, зур тәгәрмәчле буксир пароходлары, корыч троска тагылган җансыз баржалар, буын-буын итеп сузып салган саргылт озын саллар шуышты; яр буеннан көймәчеләрнең бер-берсенә эндәшүләре, палубаларда чылбыр чылтыравы ишетелде; еракта зәңгәрсу күк пәрдәсенә ак төтен төсле куш эз сызып, реактив самолет очты.

Сәгыйть үз тирәсендә шушы шау-шу килгән, кайнашкан, хәрәкәтләнгән бөтен нәрсәгә игътибарсыз гына колак салып, бөтен нәрсәне күзәтеп утыра торгач, Иданы да, үзенең монда ни өчен килгәнен дә оныта башлады. Тынычланды. Ул үзенең бик нык ашыйсы килгәнен сизде. Яңадан трамвайга утырды да шәһәргә кайтып китте.

Бүлмәдә Павел үзе генә, күлмәкләрен салып ташлап, биленә кадәр шәрә көе, калай кружкасына өрә-өрә, кайнар чәй эчеп утыра иде. Алар кул биреп исәнләштеләр.

— Нишләп бик иртә килдең?— диде Павел.

— Эш бар. Ә син?

— Минем дә эш бар,— диде Павел.

Павелның ата-анасы да, туганнары да — беркеме дә юк иде, барысы да сугыш вакытында үлеп беткәннәр иде. Ул үзе балалар йортында тәрбияләнгән, соңыннан заводта эшләгән, шул ук вакытта кичке мәктәпне бетергән һәм былтыр университетка укырга кергән иде. Яшенә караганда, төскә-биткә бик олы күренгән, буйга — үз группадашлары арасында иң озыннардан, иң көчлеләрдән саналган Павел чиктән тыш гади, тыйнак холыклы һәм һәркем белән дуслаша ала торган әйбәт, кечелекле бер егет иде. Каникул вакытында кайтыр җире булмаганга, ул җәйнең яртысын төрле походларда, экскурсияләрдә, яртысын — шәһәрдә, гомуми торакта үткәрә иде. Бары тик стипендия акчасына гына киенеп тә, туенып та булмаганга, ул үзенә өс киеме һәм бүтән кирәк-ярак алу өчен буш вакытларында акча эшли иде. Тырыш, эшчән һәм шул ук вакытта бик нык сәләтле булган бу рус егетен Сәгыйть беренче мәртәбә очрашкач та күңеленә якын күрде һәм алар арасында тиздән яхшы дуслык урнашты.

— Әйдә, утыр, чәй эчәбез,— диде Павел, үз яныннан урын күрсәтеп.

Сәгыйть өйдән алып килгән тәм-төмнәрен — бал-май банкаларын өстәлгә өеп ташлады.

— Менә сиңа күчтәнәч! Монысы авыл күмәче, монысы чәкчәк, менә монысы бал, җүкә балы — әйдә, сыйлан.

Павел кыстатып тормады. Алар бер-берсен күрми тор-

ган вакытта кайларда булулары, ниләр эшләүләре турында сөйләшә-сөйләшә тәмләп чәй эчәргә керештеләр. Бераздан Павел сорап куйды:

— Шулай да нинди эшең бар?

— Доклад язарга кирәк. Авылда тотынып карарга итеп караганыем — әле кирәк китабы юк, әле ансы, әле монсы юк. Менә тоттым да килдем, ныклап тотынырга кирәк.

— Син язма хәзер,— диде Павел.— Павловтан үрнәк ал.

Сәгыйть көлеп куйды.

— Павелдан үрнәк ал димәкче буласыңмы әллә син?

— Павелдан үрнәк алсаң да зыян итмәс!— диде тегесе.— Беләсеңме, Павловны, физиолог Иван Петровичны — ял вакытында ул беркайчан эшләмәгән... фәнни эш белән шөгыльләнмәгән.

— Әһә, син әйтмәкче буласың инде, фәнни хезмәт белән юкка башыңны авырттырып утырма, ял вакытында ял ит, димәкче буласың инде, ә?

— Эзенә генә бастың!— диде Павел.— Балың бик әйбәт икән... Әйдә, иртәгә минем белән Идел буена, ике баржа утын килә — бушатабыз. Эше авыр, алдан ук әйтәм, ләкин син чыдарсың, җилкәң нык күренә.

Сәгыйть эндәшмичәрәк торды.

— Ярар, була, барабыз,— диде ул, ниһаять.

«Барыбер көне буе доклад язып утырып булмаячак, языйм дисәң, эштән соң да язарга була,— дип уйлады ул күңеленнән.— Берничә көн шулай узар, ул вакытта Ида да килеп җиткән булыр».

Ләкин Ида килеп җиткән иде инде.

## III

Ул бүген иртән иртүк килеп төште. Кояш әле чыкмаган, шулай да яктыра башлаган иде. Җиңел такси аны биш минут эчендә студентлар торагына китереп куйды. Үзләренең бүлмәсендә әле беркем дә булмаганга һәм анда әле берни дә җыештырылмаганга, рәтләнмәгәнгә, ул, вахтер хатын тәкъдиме буенча, кешеләр уяна башлаганчы бераз көтеп торды, шуннан соң күршедәге бүлмә кызларын уятып керде дә шунда урнашты. Пароходның беренче, икенче классларында урын булмады — өченче класста килергә туры килде. Анда кеше бигрәк тә күп иде, һәм Ида юл буе утырып кына килде, рәтләп күзен дә йома алмады.

Бүлмәдә матрацлы бер буш койка бар иде, өеннән алып килгән йомшак мендәрләрен салды да, ак, чиста җәймә-

ләрен җәйде дә, өстен-башын чишенеп тә тормыйча, шундук ауды. Ул берни белмичә йоклады.

Бүлмәдәге дүрт кыз, йокыдан торгач, бергәләшеп базарга чыгып киттеләр. Бер сәгатьтән соң сумкаларын алма белән, кишер, кыяр белән тутырып яңадан кайтып керделәр. Көлешә-көлешә, бер-берсенә теләсә ни әйтешеп, бик озак ашап утырдылар. Ида һаман уянмады. Кызларның берсе, аяк очларына гына басып, аның койкасы янына килде, йөзенә иелеп, бераз тыңлап торды.

— Әллә үлгән инде?— диде, иптәшләренә карап.

— Үлсә, күмәрбез,— диде кызларның берсе, һәм дүртесе дә кинәт пырхылдап көлеп җибәрделәр.

Ида барыбер уянмады. Кызлар, Иданың үзен генә калдырып, бүлмәне өстеннән бикләп чыгып киттеләр.

Ида йокы аралаш йөзенә кояш нуры төшкәнен сизгәндәй булды һәм коты алынып уянып китте. Ул, берни аңламыйча, озак кына түшәмгә карап ятты. Йөрәге еш-еш типте, аркасына тир бәреп чыкты. Ул тәрәзәнең пәрдәсе юклыгын күреп алды һәм, инстинктив бер көчкә буйсынып, тиз генә сикереп торды да, кояш нурын одеялы белән каплап куймакчы булып, тәрәзәгә таба атлады.

Кинәт аның йөзе агарынып китте, күзләре зуррак ачылды, иңбашлары сизелер-сизелмәс кенә калтырарга тотынды һәм ул бөрешеп калды, әйтерсең тәрәзәдән кисәк кенә кышкы җил бәреп керде. Ләкин куркуга караганда кызыксыну көчлерәк булып чыкты. Битләренә туптуры кояш нуры төшүенә дә игътибар итмичә ул, тагын бераз алгарак килде һәм, тын алырга да, кузгалырга да куркып, баскан урынында катты да калды.

Тротуар буенча ашыга-ашыга Сәгыйть килә иде.

Ида тизрәк койкасына ташланды, одеялын башына каплады да, коты алынып, дер-дер калтыранып, аның бүлмәгә килеп кергәнен көтә башлады. Үз йөрәгенең тибүе аңа тротуардан атлап килгән Сәгыйтьнең аяк тавышы шикелле булып яңгырады. Аның ничек итеп урам як ишектән керүен, ничек итеп баскычтан йөгерә-йөгерә менүен ул күңеле белән күреп ятты. Шул вакыт аңа торырга да, ишекне бикләп куярга кирәк дигән уй килде, ләкин аңа ул хәзер урыныннан тору түгел, хәтта телен дә, бармагын да кыймылдата алмас кебек тоелды. Ул һаман шул көе ята бирде. Бер минут үтте, ике минут үтте, менә коридорда аяк тавышлары ишетелде. Ул аның аяк тавышын шундук таныды. Шуннан соң әкрен генә күрше бүлмә ишеген шакыган тавыш ишетелде. Тагын коточкыч берничә минут узды. Сәгыйть ул яткан бүлмә ишегенә якынлашты. Тоткага тотынды. Ида тетрәнеп

китте. Аңа хәзер менә стеналар, түшәмнәр ишелеп төшәр, аның өстенә тау-таш җимерелер, ул исә койкасы-ние белән коточкыч упкынга ыргытылыр шикелле тоелды.

Ләкин ишек бикле булып чыкты.

...Ул көн гомергә онытылмаслык булып аның хәтерендә утырып калды. Агитбригадага катнашырга димләп кергән кызның башыннан сыйпап чыгарып җибәрүенә, аның тәкъдименә чын күңелдән риза булмавына ул соңыннан үкенеп бетә алмады. «Әгәр көне буе өйдә утырган булсам, әгәр сәгать өчкә кадәр беркая да чыкмаган булсам... Ужас!»— диде ул, еш кына уфтанып. Ләкин эш узган иде инде, никадәр генә үкенсәң дә, никадәр генә уфтансаң да, хәзер барыбер терсәкне тешләп булмый иде.

Бәхти, ул урамга килеп чыккач та, кояш кебек елмайды да, уң кулын, терсәк турысыннан бөгә төшеп, артистларча алга сузды, сул кулын күкрәгенә куеп, аның алдында баш иде һәм:

— Пажалыста! Тройка җигелгән — килергә дә утырырга,— диде.— Безне анда урман кошлары көтә. Урманга барабыз бүген, шулай бит?

— Синең кебек урман кошларын көтәрләр дә шул!— диде ул, башын бер якка кыйшайткан көе, шаян елмаеп һәм Бәхтинең күзлеген аска басып куйды да, кычкырып көлә-көлә, кире өйләренә йөгереп кереп китте.

— Тиз бул!— дип кычкырып калды Бәхти аның артыннан.

Ул киң итәкле көрән юбкасын, озын җиңле, саргылт-кызыл бизәкле кофтасын киеп, матурланып, елмаеп чыкты. Аның нигәдер гел көләсе, шаярасы килде. Ул көнне аның күңеле бик күтәренке булды.

Җәйге урман шундый күңелле, шундый матур иде, агач ботакларында күзгә күренмәгән ниндидер кошлар сайрый, куе яфраклар арасыннан тасма-тасма кояш нурлары сузылып төшкән иде.

Мотоцикл ярым караңгы урман юлыннан һаман эчкәрәк керде. Юл өстендә тәгәрмәч астында изелеп, кабыклары суелып беткән ботаклар, агач тамырлары, таяклар очрады, кулбашларга яфраклар ышкылып-ышкылып китте.

Печәне чабылып алынган якты бер болында Бәхти туктап калды.

— Ах, нинди шәп! Нишләп җиләге юк соң моның? Минем җиләк ашыйсы килә!..— диде ул.

Бәхти мотоциклын сүндереп куйды да, аның янына килеп, җир өстеннән җиләк эзләгән булып кыланды.

— Монда нинди җиләк булсын!— диде Бәхти, көлеп.

— Нишләп булмасын — була!— диде ул, бәхәсләшергә әзерләнеп.— Беләм — була! Вот! Үлән арасында була! Менә бер җиләк!

— Син үзең җиләк!— диде Бәхти һәм уң кулын аның иңбашына салды.— Шундый тәмле җиләк — кап та йот!

Ул аның кулын ычкындырды да торып йөгереп китте.

— Ку мотоциклың белән!

Бәхти аның артыннан йөгерде.

Болын читендә, урманнан аерым бер җирдә, карт бер каен үсеп утыра иде. Ул ачык урынга, кояшлы якка янтайган һәм исерек кеше шикелле менә-менә җиргә сузылып барып төшәм дигәндә генә, кинәт яшел чәч толымнарын таратып җибәреп, башын югары күтәргән дә шул көе кыен бер рәвештә гомергә бөкрәеп калган иде.

Ул туп-туры шул каенга таба йөгерде, артыннан Бәхти килеп җиткәнче, каен кәүсәсен кочаклап алды да аның өстенә үрмәләп менәргә тырышкан булып кыланырга тотынды.

— Кара... кара... нинди каен!

Аның артыннан ук килеп җиткән Бәхти ике куллап аның биленнән тотты, ул авызын ачып берәр сүз әйтеп өлгергәнче, аны җиңел генә күтәреп алды да каен өстенә утыртып куйды. Йөгерми йөгергәнгә ул тирләп төште, йөрәгенә капты. Ул бер якка шуып төшкән эшләпәсен рәтләштерде дә, ачуланган булып, искәрмәстән Бәхтинең чигәсенә чабып җибәрде.

— Менә сиңа!— Бәхти, авызын ерып, икенче чигәсен куйды.— Менә тагын! Менә!.. Икенче мәртәбә сораусыз тотынмассың!

Кинәт ул утырган җиреннән сикереп торды, кытыршы кабыклы каенга җайлап басты да кулларын ике якка канат кебек җәеп җибәрде һәм бер адым алга — агач башына таба атлады.

— Очына кадәр менәм!— дип кычкырды ул, тиләләнеп.— Тот! Тотмасаң, менәм, все равно менәм!

Ләкин шул вакыт әллә башы әйләнеп китте, әллә аягы тайды — тигезлеген саклап калмакчы булып, куллары белән бик нык селтәнде дә бер якка чайкалып китте. Ярый әле, Бәхти шунда гына иде — Ида егылып киткәнче, көчле куллары белән ул аны шундук тотып та алды, җиргә-нигә төшермичә, ныгытып күкрәгенә кысып та алды.

— Менә җүләр! Башың белән барып төшкәниең бит!— диде ул, куркып.

Шуннан соң нәрсә булганын Ида рәтләп хәтерләмәде

дә. Алар каен төбенә җиргә утырдылар. Бәхти һаман аны кочагыннан ычкындырмады. Аның башы әйләнде, йөрәге сикереп-сикереп типте. Бәхти тотлыга-тотлыга, агарынган йөз белән, аңа нәрсәдер пышылдарга тотынды.

— Ида... Идочка...

Ул аның уттай янган, дер-дер калтыранган тәнен тимер кыршау белән кыскан кебек һаман ныграк кысты, ниндидер рәхимсезлек белән, ниндидер хайванлык белән кысты.

Ул аның мыек очларының кызган энә кебек бит тиресенә чәнчеп кергәнен тойды, аның йотлыга-йотлыга пышылдаган бәйләнешсез, ясалма сүзләрен ишетте...

Яңадан кайтырга җыенганда, бер-берсенә әйтер сүз табылмады, күзләрен күтәреп карарга кыюлыклары җитмәде. Һәм ул гомерендә беренче мәртәбә үзен беркемгә дә кирәксез итеп, коточкыч ялгыз, көчсез итеп сизде. Дөньядагы бөтен нәрсә аңа пычрак булып, оятсыз, кабахәт булып күренде. Бәхтинең көчәнеп аны юатырга тырышуы аның җенен котыртты, косасын китерде. Аның тавышы, хәрәкәтләре, мыеклары — бөтен нәрсәсе шундый ачык, аермачык рәвештә ят, чит булып тоелды. Ул, үз-үзен кызганып, тыела алмыйча кинәт елап җибәрде, тилереп, үксеп-үксеп елады һәм, күз яше аралаш, ямьсезләнгән, шашынган тавыш белән:

— Кит! Кит!.. Күземә күренмә!.. Кит! Кит!..— дип кычкырды.

Соңыннан... икенче көнне ул тагын килде, тагын тәрәзә турысында мотоцикл тавышы ишетелде, ләкин хәзер ул элеккечә түземсез булып, дәртле булып яңгырамады. Алар тагын урманга бардылар. Бәхти ант итте, вәгъдәләр бирде, һәм ул аңа ышанды. Ул үзен бөтенләе белән аныкы итеп хис итте, һәм бу аңа бер дә оят нәрсә булып, ярамаган нәрсә булып тоелмады, киресенчә, ул үзенең инде хәзер чын-чынлап аныкы булуы белән горурлана башлады. Ул үзен бөтенләй яңарып, үзгәреп, икенчеләнеп киткән шикелле сизде. Аңа хәзер бөтенләй бүтән төрле тормыш, искиткеч яңа, гүзәл тормыш башланды шикелле тоелды.

Бәхти өч көн рәттән килде. Дүртенче көнне ул килмәде. Ул аны дүрт күз белән көтте, сагынып-саргаеп көтте. Ләкин Бәхти барыбер килмәде. Аның коты алынды. Кич клубка чыгарга оялды.

Тагын бер көн узды, өметләнеп ул һаман көтте, икенче көн дә узды, һәм шул вакыт ул, куркуыннан нишләргә белмичә, аның вәгъдәләренең, матур сүзләренең бары тик оятсыз ялган гына, күз буяу гына булганлыгын, аның

кыюлыгының, матурлыгының һәм ул үзе уйлап тапкан әллә нинди яхшы сыйфатларының бары тик мираж гына, декорация генә булганлыгын аңлады. Ул үзенең алданганлыгын, мәсхәрәле рәвештә алданганлыгын аңлады. Хурланган күңеле һич тә ышанырга теләмәде, ләкин булган нәрсә, аның килмәве һәм аяусыз акыл шул турыда сөйләде. Шикләнеп, икеләнеп торырга, тагын нәрсәгәдер өметләнеп торырга бернинди нигез калмады. Бәхти качты, каракларча, куркакларча качты... югалды.

«Какие мерзавцы бу җегетләр! Аларның барысы да шундый оятсыз, шундый сволочь, нахал!..» — дип уйлады ул көчсез бер ярсу белән, ир җенесендәге һәркемгә карата чын-чынлап нәфрәт, җирәнү хисе тоеп.

Ул атна буе өйдән чыкмый ятты, хәтта рәтләп урыныннан да тормады, каралай көйде, ябыкты, саргайды, сүзсезләнде, үлек кебек, берни сизми, берни тоймый башлады. Көн төнгә әйләнде, төн газапка әйләнде.

Эшнең нәрсәдә икәнен сизенеп алган әнисе бер дә кызыннан ким көймәде. Ләкин сораштырырга, төпченергә кыюлыгы җитмәде. Әтисенә берни дә сиздермәделәр.

Беркөнне бер таныш колхоз председателе кунарга кергәч, әнисе сөйләшәсен сөйләште, рәтлисен рәтләде дә иртән, аны машинага утыртып, шул агайның авылына җибәрде.

Авыл бик матур урынга, урманлы-сулы җиргә утырган иде. Ул анда ярты айдан артык торды, председатель агайның бәләкәй кызлары белән урманга йөрде, су керде, яңа сауган сөт эчте, тазарды, тулыланды. Элеккеләр әкренләп онытыла, төссезләнә барды. Бәхти турында ул бөтенләй уйламаска, аны бөтенләе белән җиргә күмеп куярга тырышты. Әмма болын читендәге кәкре, юан каен, чабылган печән исе, бәйләнчек усал черкиләр барыбер күңелендә җуелмас тирән эз булып калды.

Утырмадан кире үзләренә кайткач, өйдә бер ике-өч көн генә торды да, авылдан артык ямь таба алмыйча, Казанга җыена башлады. Аның тизрәк авылдан, караңгы, котсыз авылдан китәсе килде. Шәһәрдә вакытны да күңелле итеп үткәрергә мөмкин булачак иде, һәм анда аның турында берни дә белмиләр дә иде. Аның болай бик иртә кузгалуына өйдә бик үк каршы килмәделәр. Төнге пароходка утырды да Казанга юл тотты.

Көн артыннан көн узып, күңеле гаҗәп бер җиңеллек, гаҗәп бер тизлек белән яңадан тынычлана төшкәч һәм бөтен нәрсә яңадан элекке хәленә кайткач, ул, дөньяда тормышка ашуы бик шикле нәрсә турында хыялланган кебек... Сәгыйть турында хыяллана башлады.

## IV

Әйе, үз-үзен бәхетсез, ялгыз сизә башлагач, аңа яңадан Сәгыйть кирәк булды. Аның карашынча, моның бернинди начарлыгы юк иде. Ул үзен Сәгыйть алдында бөтенләй диярлек гаепсез санады, аңа тик бер генә мәртәбә җавап язуын да, хәтта аннан зуррагын да онытты, дөресрәге, онытырга тырышты. Ул гомумән беркайчан да, бер генә нәрсәдә дә үзенең гаебен танырга гадәтләнмәгән иде.

Ул аңа берни дә әйтмәс — бары шул гына. Ул турыда аның белән «теге»ннән башка кем белә?! Аннан соң Сәгыйть бит аны ужасно ярата! Ул аның һәрбер сүзенә ышана; аның күңеле йомшак; аңа аның бер елмаеп каравы да, бер иркәләнүе дә җитәр, һәм ул яңадан аның табанын ялый башлар, элек ничек үләрдәй булып яратса, хәзер дә һаман шулай ук яратыр, һәм тормыш, берни булмаган кебек, һаман элеккечә барыр.

Ул шулай уйлады, шулай булуын теләде, шуны өмет итте. Сәгыйть аңа һаман да элекке Сәгыйть булып тоелды. Ул, анда бернинди үзгәреш юктыр, дип уйлады.

Әйе, аңа бөтенесе дә җиңел генә, шома гына үтәр шикелле тоелды. Әмма тәрәзә аша Сәгыйтьнең үзен күргәч, моңа кадәр кайдадыр яшеренеп яткан вөҗдан кинәт башын калкытты, аны тетрәнергә, кан калтырарга мәҗбүр итте.

Билгеле, әле баштан аны монда, Казанда, күрермен дип өмет итмәгән иде ул. Ә ул килгән һәм килде. Каян белгән ул аның монда икәнен? Әллә соң белмичә генә килгәнме?

Яңадан тынычсыз тормыш, авылдагыга караганда да газаплырак, авыррак тормыш башланды. Иртән йокыдан, ишекне шакымыйлармы, дип куркып уянды; коридорга-фәләнгә чыгарга туры килсә, бүлмә ишеген ачкач та, күңеле белән иң элек аны эзләде, як-ягына каранды, аяк тавышы ишетелмиме дип, сагаеп тыңлап торды, әледән-әле артына борылды; урамга, магазинга чыгарга туры килсә, кеше күзенә күренмәстәй җирләрдән, өй артларыннан, аулак урыннардан йөрде, курыкты-өректе, йөрәге дерт-мерт килде; кичләрен сирәк кенә кинога барырга туры килсә, залда юри иелеп, битен яшереп утырырга тырышты; кайчакларда аңа кемдер арттан аның тавышы белән, «Ида!» дип кычкыра шикелле тоелды. Ул үзен бер генә җирдә дә тыныч, иркен сизмәде, теләсә кайда аны кемдер эзәрлекләде, кемдер артыннан күзәтеп торды.

Берничә көннән студентлар килә башлады. Буш ко-

ридорлар, вестибюльләр, бүлмәләр җанланып китте. Ишекләр көне буе диярлек шап-шоп ачылып-ябылып торды; идәннән түшәмгә кадәр студентларның чемоданнары, төргәкләре, китап салып кадакланган әрҗәләре белән дыңгычлап тутырылган бүлмә ишеге алдында чиратлар барлыкка килде; хуҗалар расписка буенча үзләренең әйберләрен алдылар; буфет эшли башлады; көн дә иртә-кич плитага яктылар; коридорлар буенча матрацлар, койка, урындыклар, чемоданнар сәяхәт итә башлады; уңган, җитез кызлар, юл киемнәрен алыштырып, кулларына тоткалы таба, савыт-саба тотып, эшлекле кыяфәт белән бүлмәдән кухняга, кухнядан бүлмәгә таба йөгергәләргә тотындылар; юылган, агартылган чиста, якты бүлмәләргә яңадан өстәл-урындыклар, койкалар, тумбочкалар кереп урнашты; әле буяу исе дә очып бетмәгән тигез, ап-ак стеналарга расписаниеләр, табель-календарьлар, открыткалар кадакланды; тумбочкалар өстенә, этажеркаларга китаплар тезеп куелды; тәрәзәләргә коменданттан кул куеп, язу белән алынган пәрдәләр эленде; көзгеләр куелды. Китте студент тормышы тагын җанланып, шаулап-гөрләп!

Ачык калдырылган бүлмә ишекләре аша кычкырып көлешүләр, кызып-кызып сөйләшүләр, бәхәсләр ишетелде. Кичләрен урам якка караган ачык тәрәзәләрдән электр яктысы белән бергә кушылып музыка моңнары, яшьләрнең җыр тавышлары агылды. Бал кәрәзе кебек вак-вак бүлмәләргә бүлгәләнеп беткән студент умарталары, беренче сентябрь якынлашу белән, һаман ныграк кайный, гүли башлады. Алар, үзләре белән туган якларның яшел кырлары, урманнары, болын чәчкәләре исен һәм таза, сау тәннәрендә эссе кояш нурларын алып килгән студентлар, һәрбер хәрәкәтләрендә, үз-үзләрен тотышларында, тавышларында яшьлек, көч, энергия ташып торган кайгысыз студентлар — көләч йөзле, бәхетле, горур, гүзәл егетләр, кызлар — тротуарларны иңләп йөрделәр, трамвай, троллейбус вагоннарын, театр, кино вестибюльләрен, бакча-паркларны, мәйданнарны тутырдылар, һәм җәй буена бөркүлектән әлсерәгән, тыны кысылган карт шәһәр тагын да яшәреп, тагын да сылуланып китте, көлде, елмайды, шатлыктан нурлар сирпеде.

Ида иптәшләренә кызыгып, көнләшеп карады.

Сәгыйть белән очрашу сәгатен ул ничек тә кичектерергә теләде. Ләкин алар барыбер очраштылар.

Сәгыйть алты көн рәттән Павел белән бергәләп баржадан утын бушатырга йөрде. Авылдагы кебек иртәниртүк тордылар да тизрәк Идел буена ашыктылар. Эш

чынлап та бик җиңел булмады. Сәгыйть кичләрен ярыйсы гына арып-алҗып кайтты. Шулай да колхоз эшендә чыныккан организм артык бирешмәде, һәм ул кайтып бераз гына ял итте дә, Павелның әйбәт киңәшенә дә карамыйча, докладына тотынды. Беренче көнне ике-өч юл да яза алмады — башы берни уйламады, күзен шундук йокы басты. Икенче, өченче көннәрне эш бераз алга киткәндәй булды — көчәнеп кенә булса да, башы да эшли башлады, күңеленә матур, дөрес фикерләр дә килде. Ул кичләрен икешәр сәгать урыныннан да кузгалмыйча утырды.

Бер мәртәбә Зәйтүнә керде. Авылдан хат алуы турында, бүлмәдәш кызлары турында, университет турында нәрсәләрдер сөйләргә тотынды, ләкин Сәгыйтьнең китап-дәфтәрдән аерылырга теләмәвен күреп, аның эшен бүлдерүдән уңайсызланган шикелле, кызарынды да, ничектер ы-мы итте дә шундук чыгып та китте. Сәгыйть кинәт үзенең төзәтеп булмаслык ниндидер хата эшләгәнен, авылдашының хәтерен калдырганын аңлап алды.

Аның бу арада Зәйтүнә янына бөтенләй кергәне юк иде. Үзенең корылыгына, начар, тупас кеше булуына ачуы килеп, китапларын тиз генә җыештырып куйды да Зәйтүнә артыннан кереп китте.

Зәйтүнә торган бүлмәдә аның баштагы иптәш кызларыннан беркем дә юк иде, бүлмәдә беренче курс студентларыннан бары ул гына торып калган иде.

— Кая иптәшләрең?— диде Сәгыйть.

— Алар икенче бүлмәгә күчтеләр. Койканың хуҗасы килгәч, мине дә моннан куалап чыгарачаклар,— диде Зәйтүнә, еларга җитешеп.

— Соң нигә син дә иптәшләрең белән бергә күчмәдең?

— Анда аларның буш урыннары юк...

«Валлаһи, бала!— диде Сәгыйть күңеленнән, көлеп.— Тапкан кайгырыр нәрсә! Чакырсалар — утыр, кусалар — кит дигәндәй, хуҗасы килгәнче торып тик ят...»

Шулай да ул уйга калды. Аны бүлмәгә ныгытып урнаштырырга кирәк иде, һәм монда аның ярдәменнән башка берни дә барып чыкмаячак иде, ахры.

— Торып тор хәзергә,— диде ул аңа, бер үк вакытта юату да, киңәш тә итү тонында.— Кайгырма юкка!.. Баш тишелеп күз чыкмаган әле! Иртәгә университетка барырбыз, бәлки, ордер да бирә башлаганнардыр инде.

Икенче көнне алар икәүләшеп университетка бардылар, хуҗалык бүлегенә керделәр. Гомуми торакта урын бирелергә тиешле беренче курс студентлары исемлегендә нишләптер Зәйтүнәнең фамилиясе юк иде. Медаль белән

кабул ителгән студент буларак, аңа, әлбәттә, ордер беренче чиратта бирелергә тиеш иде. Тикшерә торгач, Зәйтүнәнең фамилиясе исемлеккә машинистка хатасы белән генә кертелмәгәне беленде. Зәйтүнәнең шундук күңеле күтәрелеп китте.

Аңа да, Сәгыйтьнең үзенә дә ордер алып, бүлмәгә төпләп урнашканчы, тагын берничә көн узып китте. Ул арада беренче сентябрь дә якынлашты.

Пристаньга төшеп тә, кызын очратмый кайткан теге көннән соң Сәгыйть Идалар торагына бөтенләй аяк та атламады. Ул аның турында вакытлыча онытып торырга тырышты. Беркөнне ике мәртәбә алдангач, аның тагын өченче мәртәбә алданасы килмәде, дөресрәге, алданудан курыкты. Үзенчә акыллылык, саклык күрсәтеп, ул хәтта уку башланганчыга кадәр көтәргә булды.

Әмма беркөнне, университетка баргач, коридорда ул Степканы очратты. Степка өстенә кара төстәге өр-яңа шевиот костюм кигән, галстуклар тагып җибәргән, һәм шуңа күрә ул аңа бик нык үсеп киткән, зурайган шикелле күренде.

— О-о, Степка!— диде Степка, Сәгыйтькә кул сузып.

— О-о, Сәгыйть!— диде Сәгыйть, аның кулын кысып.

Степка, кайбер рус егетләре кебек, Сәгыйтьне «Саша» дип йөрткәнгә, Сәгыйть тә аны, шаярып, «Сәгыйть» дип атый иде. Алар бер-берсенә карата аеруча дуслык тойгылары кичергән чакларда, бер-берсенә еш кына шулай исемнәрен алмашып эндәшәләр иде.

— Кайчан килдең, Степан Иванович? О-о, син бигрәк карайгансың! Чәчең кая, сатып эчтеңмени?— диде Степка.

— Костюмың бик шәп икән... Кайчан алдың, күпмегә?— диде аңа каршы Сәгыйть һәм костюм материясен капшап караган булып, Степканың беләгеннән чеметеп алды.

Степка тыелып кына кычкырып җибәрде, ләкин шулай да сер бирмәде һәм иптәшенең мондый астыртынлыгына, җавап итеп, аның кыска чәч бөртекләрен тартып карау нияте белән башына үрелде. Әмма буе җитмәде, һәм алар, мәктәп балалары кебек шулай шаярыша-шаярыша, урамга чыктылар.

— Син нишләп үзең генә? Кая бер як канатың?— диде Степка, университет каршындагы бакчага килеп кергәч.

— Килмәгән әле ул,— диде Сәгыйть тыныч кына, әйтерсең Иданың үзе янында булуы-булмавы аның өчен барыбер иде.

— Килмәгән?!— диде Степка.— Аның Казанга килгәненә инде бер атна бардыр!

Степка Идалар белән бер торакта яши иде. Сәгыйть агарынып китте. Ул, тез буыннарының хәлсезләнгәнен тойган хәлдә, кинәт туктап калды.

— Килгән? Кем әйтте сиңа аны? Кайчан килгән?

Аның бөтен тәне буенча кайнар кан йөгерде. Аңа бик эссе булып китте. Күңеле шундук монда нинди дер ярамаган, начар нәрсә барлыгын сизенеп алды. Килгән? Нигә бу вакытка кадәр бу турыда берни белдермәгән? Нигә, ичмасам, бер генә мәртәбә булса да аның бүлмәсенә килеп китмәгән? Кайнарланган миендә мең төрле сорау туды. Аңа аның җәй буена, дөньядан бөтенләй югалган кеше кебек, бернинди хәбәр-хәтер бирмәве белән хәзер, Казанга килеп тә, шул турыда берни белдермәве арасында нинди дер дәһшәтле, серле бәйләнеш бар төсле тоелды.

Степка, Сәгыйтьнең кинәт үзгәрүенә бөтенләй игътибар итмәгән кебек, һаман сөйләнеп сөйләнде:

— Степан Ивановичка сәлам тапшырыйммы?— мин әйтәм. «Әллә сәлам тапшырырга ялландыңмы?»— ди. Ялланмаса-ни, мин әйтәм, барыбер буш барам ич, салып җибәр кесәгә сәламеңне, очратсам, бирермен. Нәрсәдер кычкырды да, йөгереп кереп тә китте — ишетмәдем...

— Кайтасыңмы? Юк? Ну, мин киттем!— диде Сәгыйть, ашыгып, һәм тиз генә борылды да бакчадан чыгып та китте...

Ул ишеккә бер-ике мәртәбә бармак сырты белән шакылдатып алды, эчтәгеләрнең җавап бирүләрен дә көтмичә, үз-үзен көчкә тыеп, бүлмәгә атылып килеп керде. Ида, өстенә йомшак соры одеял ябынып, койкасында сузылып ята иде.

— Менә син кайда икән!— диде Сәгыйть, кычкырып, һәм бүтән кызлар белән ашык-пошык кына исәнләште дә туп-туры аның урыны янына килде.

Ида башын калкытып кыймылдап куйды һәм, өстеннән одеялын алып ташламыйча гына, койкасыннан яртылаш торып утырды. Аның әзрәк кенә ябыккан шикелле күренгән бит очлары сизелерлек булып кызарынды. «Иптәш кызлары алдында уңайсызлана!— дип уйлады Сәгыйть.— Алар булмаса, мин сине алай кызарындырып тормас идем дә бит, одеялың-ниең белән, койкаң белән бергә алып кочар идем!»

Алар тел белән дә, кул белән дә күрешмәделәр, моның кирәге дә булмады, күрешү — чиктән тыш коры, салкын булыр иде. Алар бер-берсенең күзләренә, йөрәкләренә генә карадылар, дөресрәге, Сәгыйть карады, Ида, аркасын койкасына терәгән көе, һаман шулай ук оялып, кызарынып, күзен читкә борып тик утырды.

Сәгыйть өстәл янындагы буш урындыкны алды да аның каршысына килеп утырды. Аның Ида өстендәге одеялны алып ташлыйсы, аны ныгытып күкрәгенә кысасы, аңа карата әллә нинди матур сүзләр әйтәсе килде. Ләкин ул, үзе артында чит кешеләр барлыгын тойган хәлдә, теле-кулы бәйләнгән кебек, аннан күзен ала алмыйча карап утыруында булды.

— Мин әле тормадым,— диде Ида, гадәтенчә тавышына иркәләнү тоны бирергә тырышып һәм авыртынган кеше шикелле, көчәнеп кенә елмаеп куйды.

— Тормадың? Иртәннән бирлеме?

— Юк. Төштән соң.

Тагын, кирәкле сүз таба алмыйча, тынып калдылар. Ида Сәгыйтькә әз генә, бәчтек кенә үзгәргән шикелле тоелды. Аның күз төпләрендә сизелер-сизелмәс кенә ниндидер ят күләгә уйный кебек иде, аннан соң ул ничектер басылып, олыгаепмы, җитдиләнепме калган шикелле күренә иде. Ләкин, ни генә булмасын, ул барыбер Ида, аның Идасы иде.

— Нәрсә, чирләдең әллә?— диде Сәгыйть, иплэп кенә. Ида сискәнеп киткән шикелле булды.

— Чирләдең? Әллә шулай күренә?

— Юк, төштән соң тормадым, дисең ич.

— Баш авырта шул,— диде ул, елмаеп.— Белмим — нигәдер. Әллә салкын тидердем инде пароходта килгәндә...

— Ах, качкы!— диде Сәгыйть, аның сүзен тыңламыйча.

Ул, бүлмәдәге бүтән кызларга күрсәтмәскә тырышып, одеял астына кулын тыкты да аның йомшак, кайнар бармакларын эзләп тапты.

— Кайчан килдең?— диде ул, рәхәт җылылык бәрелгәнен тоеп.— Кайчан килдең? Нигә берни белдермәдең? Мин сине шундый сагындым, шундый күрәсе килде.

Ида исен, акылын җыя башлады, үз-үзен әкренләп-әкренләп кулга алды. Гыйшык нуры чәчеп торган күзләре белән киң итеп елмаеп, аңа бер карап алды да, ачыктан-ачык үпкәләү сиздереп торган тавыш белән:

— Син соң... син үзең?— диде.— Үзең кайчан килдең? Берәр килеп хәлне белдеңме? Сагынгансың! Нигә әйтмисең — кайчан килдең?

— Җегермесендә.

— Ну во-от! Мин алайса синнән дүрт көн соң килгәнмен! Минем баш авыртты, салкын тигән бугай пароходта килгәндә...

— Салкын тигән? Ну-у сине! Нишләтергә инде моның

өчен? Врачка бардыңмы соң? Аптекадан берәр нәрсә алып кайттыңмы?

— Ю-ук, бетте дияргә була инде...— диде Ида, зәгыйфь кенә елмаеп.

Сәгыйтькә бик күңелле булып китте. Әһә, менә ни өчен килә алмаган икән ул аның янына! Ну ахмак та соң ул! Бер генә мәртәбә килде дә бүтән вакытта аның турында уйлап та бирмәде. Нәрсә соң бу? Аңа бер генә мәртәбә килергә түгел, көн дә килергә, иртән дә, кич тә килеп әйләнергә кирәк булган. Ә ул монда аны көтеп яткандыр, аның үзенә генә, билгеле, бик күңелсез булгандыр... Житмәсә, ачуланып тор, имеш!

— Сиңа минем турыда кем әйтте?— диде Ида.

— Степканы күрдем,— диде Сәгыйть һәм аның белән булган очрашу турында сөйләп бирде.

Алар икесе дә Степканың сүзләреннән, кыланышларыннан көләргә тотындылар.

— Кара, нишләп ятасың әле син? Әйдә урамга чыгабыз!— диде Сәгыйть.

Ида үрелеп тәрәзәгә карап алды. Тышта караңгы төшә башлаган иде.

— Әйдә!— диде ул, кузгалып.— Только син чыгып кит хәзер. Марш!

Ида киенгәнче аңа тагын коридорда көтеп торырга туры килде. Ида аңа бик озак маташа шикелле тоелды. Ул, сабырсызланып, әледән-әле ишек янына килде, аның аяк тавышын ишетмәкче булып, иелеп, бүлмә эченә колак салды; мондый ярамаган эш белән шөгыльләнгәндә чит кеше күрүдән куркып, кинәт читкә тайпылды да тагын идән такталарын санарга тотынды, тагын туктады, тагын тыңлады.

Менә ул, ниһаять, өстенә озын итәкле яхшы костюмын, аякларына пыяла сыман үтә күренмәле капрон оек белән биек үкчәле, ялтыравык лаклы бик шәп танкеткасын киеп, бармак очларына бәләкәй генә, нәфис кенә сумкасын элдереп килеп чыкты. Аннан шундый көчле, шундый җиңел хуш ис аңкыды. Әллә шул истән, әллә аның белән яңадан бергә булу бәхетеннән Сәгыйтьнең бераз гына башы әйләнгәндәй булды. Ида сумкасын аңа тоттырды.

Тышта инде күз бәйләнә башлаган иде, ләкин фонарьларга, магазин витриналарындагы лампочкаларга ут алынмаган иде. Кич бик матур иде, бик җылы иде.

— Кая барабыз?— диде Сәгыйть, тротуар буенча берничә адым киткәч.

— Әйдә кинога? Ах, кинога!— диде Ида, кая барырга

кирәген уйлап табуына бик нык сөенгән шикелле.— Күптән кино караган юк.

Сәгыйть бик үк мондый тәкъдим көтмәгән иде, аның Ида белән бергә аулакта буласы килә иде, аның белән сөйләшәсе, бик күп нәрсә турында сөйләшәсе-аңлашасы килә иде. Хәзер аңа ике сәгать буе бер-береңә эндәшми утырудан да газаплырак бернәрсә дә булмас шикелле тоелды.

— Әгәр паркка барсак?— диде ул, иплән кенә, ничек тә аңа каршы килмәскә тырышып.

— Ю-ук, кинога барабыз! Кинога!

Сәгыйть, аның шулкадәр кино карарга атлыгып торуының сәбәбен аңлап җиткермәсә дә, бүген барлык кинотеатрларда да диярлек инде кайчандыр каралган иске картина күрсәтелсә дә, аның да, үзенең дә кәефен бозмас өчен, риза булды.

— Булды, булды! Киттек кинога! Ах, кинога!— диде ул, көлеп.

Ике арада сүз әлегә юл хәлләре, кайчан килү, ничек килү, килгәч нишләү кебек вак-төяк нәрсәләр турында гына барды. Зуррак, җитдирәк сөйләшү алда иде әле, һәм икесе дә, алдан килешеп куйган шикелле, җәй көнен ничек үткәрүләре турында да, Идел буенда бирешкән вәгъдәләре турында да хәзергә ләм-мим бер сүз кузгатмадылар, ул тирәдән сакланып кына читләтеп үтә тордылар. Шулай да икесенең дә күңелләрен бары шул гына тынычсызлады.

Очрашу шатлыгыннан, очрашу бәхетеннән исерү торабара әкренләп сүрелә башлады. Сәгыйть, экранда хәрәкәтләнгән кадрларга бөтенләй игътибар итмичә, бөтен сеанс дәвамында уйланып, булачак аңлашу турында баш ватып утырды. Ул мәсьәләнең кайсы очыннан тотынырга да белмәде, буталды, аптырап бетте, үз-үзенә, үзенең элекке шикләнүләренә икеләнеп карый башлады.

Ул хәзер шундый якын, шундый аңлаешлы — ничек итеп аның күңелен рәнҗетмәк кирәк, ничек итеп аның хәтерен калдырмак кирәк? Ничек итеп аңа бернинди дәлилсез, бернинди нигезсез гаеп ташларга кирәк? Нигезсез?.. Аның үз сүзендә тормавы шул үзе генә дә җитди сөйләшү өчен нигез түгелмени? Никадәр газапланды ул шуның аркасында! Газапланса соң? Яраткач, газапланмыйча гына буламыни? Чын ярату — үзе шул ук газап түгелме соң? Шуның өчен ачуланып торыргамы? Ул үзе монда, аның янында! Алар тагын очраштылар, берберсен күрделәр. Соң, шулай булгач, тагын ни кирәк! Ул аңа карата тамчы да үзгәрмәгән. Юк! Кирәге юк!..

Сәгыйть Идага күз төшереп алды. Ул экранда барган вакыйгаларны бөтен күңеле белән бирелеп, йөрәгеннән кичереп карый, дөньясын онытып карый иде — ул бик тыныч иде. Ул да үзалдына борылды да, аның кебек үк тыныч булырга тырышып, ак киндер өстендә кыймылдашкан кешеләрне күзәтергә тотынды. Ләкин аның түземлеге озакка бармады, күңеле белән яңадан ул кайдадыр читтә йөри башлады.

Юк, бүген барыбер сөйләшмичә, аңлашмыйча булмас, ахрысы.

Кинодан чыккач, алар электр утлары белән яктыртылган шау-шулы урам буенча киттеләр. Гашыйк кешеләр өчен вакыт бик соң түгел иде әле, уникеләргә, берләргә кадәр урамда йөрергә яисә берәр бакчага кереп утырырга була иде. Сәгыйть, Иданы култыклап, Черек күл бакчасына таба юнәлде.

Кинәт Ида бизгәк тоткан кеше кебек сизелер-сизелмәс кенә дерелди, калтырый башлады.

## V

— Нәрсә булды?— диде Сәгыйть.

Ида, аның ни турында сораганын аңламаган кебек, тиз генә җавап бирмәде.

— Берни булмады,— диде ул бераздан. Үзе тагын да ныграк дерелдәргә тотынды.

— Нигә калтырыйсың?

— Калтырыйм? Что син!

— Әйе, беләгең калтырый,— диде Сәгыйть, аның берни белмәмешкә салынуына үртәлә башлап.

— Өшетә башлады бугай,— диде Ида, аның белән килешергә мәҗбүр булып.

— Өшетә?! Төн бик җылы, аннан соң синең өстә костюм. Мин күлмәкчән — шулай да өшемим.

— Сиңа җылыдыр да соң, миңа — суык, менә шуул...— диде Ида ниндидер ят, сәер тавыш белән.

Ул туктап калды һәм көчәнеп кенә елмайды да Сәгыйтьнең күзенә туры карамаска тырышып, тотлыга-тотлыга:

— Йөрмик бүген... Вакыт та соң... Сәгыйть...— диде.— Кайтарып куй мине! Суык тию бетеп җитмәгән, ахры...

— Баягынак кына бетте дигәниең бит әле!— диде Сәгыйть, аның ялганын тотып.

— Аннан соң минем иртәгә иртүк торасы бар,— диде Ида, аның сүзләрен ишетмәгән шикелле.

— Нишлисең?

— Кер юарга кирәк,— диде Ида, кулбашларын җыергалый-җыергалый, ияге белән күлмәк якасын ышкып.

Сәгыйть аның беркайчан да кер-фәлән юмаганын, үз керләрен гел кешегә биреп юдырганын бик яхшы белә иде. Ул, аның сүзенә риза булырга да, аңа каршы төшәргә дә белмичә, аптырап, сәерсенеп китте. Ул ике мәртәбә аның ялганын ачты. Бу аны сагаерга мәҗбүр итте. Ул аның ни өчен үзеннән тизрәк аерылырга теләвен, җәй буена бер-берсен күрергә шундый интизар булып торганнан соң да һәм менә яңадан күрешкәч тә, беренче көнне үк, бернинди сөйләр сүзе юк кеше кебек, тизрәк качарга теләвен аңламады. Аның күңелендә ниндидер сукыр ачу, ярсу кабара башлады. Ул аның нидер яшергәнен сизенеп алгандай булды. Аның күз аллары яктыра башлагандай булды.

Әйе, ни дә булса бар монда! Нигә ул үзе шундый, яраткан кеше булып күренергә тырыша, шул ук вакытта үзе аның белән иркенләп сөйләшергә дә теләми, нигә әллә нинди ялганнар, нигезсез сәбәпләр эзләп таба? Нинди салкын тию ул, нинди кер юу ул? Юк! Чынлап яраткан кешегә сөйләшү өчен бернинди салкын тиюләр дә, бернинди керләр дә каршылык була алмый. Элек аның белән төннәр буе тротуар таптап йөрергә, ашавын да, төн йокыларын да онытып, шәһәрнең иң кырый урамнарына барырга да берсүзсез риза булган Ида, ни өчен хәзер шундый көтеп алынган көнне дә, шундый кадерле көнне дә тизрәк үз бүлмәсенә кайтып ятарга ашыга?

Сәгыйть, шундый күңелсез уйларга бирелеп, аның яныннан тын гына атлап барды.

— Гүр суыгы кергән, ахры, синең эчеңә,— диде ул, Иданың тагын калтырана башлавын сизеп.

Бу сүзләрне ул тыныч кына әйтергә тырышты, ләкин аның тавышы зәһәрле булып, тупас булып чыкты. Ида әйтерсең тагын берни ишетмәде.

Алар тимер рәшәткәле койма янына килеп җиттеләр. Җиргә багана башындагы фонарьлардан, йорт почмакларындагы лампочкалардан электр яктысы төшә иде.

Ида, калтыранган кулы белән Сәгыйтьнең битеннән, чәчләреннән сыйпый-сыйпый, иркәләнергә тырышып:

— Сәгыйть,— диде,— бар, син шушыннан гына кайтып кит, яме? Иртәгә йөрербез...

Аның гаепле тавышын ишеткәч тә, аның шәрә, салкын бармакларының үз тәненә тигәнен тойгач та, әйтерсең моңарчы Сәгыйтьнең ярсуын тотып торган богаулар шартлап өзелеп китте. Коточкыч көч белән тышка чыгарга омтылган ачуын тыярга тырышып, ул еш-еш сулыш ал-

ган көе, усал елтыраган күзләрен Иданың агарынган йөзенә кадады.

— Нигә?..— диде ул карлыккан, калтыравык тавыш белән.— Нигә куасың? Нигә баядан бирле качасың миннән? Нигә күзеңне читкә яшерәсең, нәрсә яшерәсең? Күрми-сизми дисеңме әллә?

Сәгыйть ягымлы, яхшы күңелле булганда, түбәсе күккә тиеп, берни уйламыйча куанган вакытта Ида үзен аның янында бик кыен сизде, гаепле итеп, мескен итеп сизде, хәтта аннан шүрләде дә, оялды да. Ул аның берни белмәгәнен, аның үзен һаман элеккечә яратканын, барыбер һаман шул ук Сәгыйть булып калганын күрде. Бу аны сөендерде дә, газаплады да. Шул вакыт ул үзенең аңа тиң түгеллеген, үзенең аннан бик түбән төшкәнлеген аңлады. Аның кайнарланып пышылдаган гыйшык сүзләре аның йөрәгенә очлы пычак булып кадалды, аның елыйсы килде, Сәгыйтьнең аяк астына егылып, аннан гафу үтенәсе, аңа барысын да сөйләп бирәсе килде. Шул ук вакытта ул, кан калтырап, булачак аңлашу минутын көтте һәм бу минутның ничек тә бүген, мөмкин икән — гомергә дә килеп җитмәвен теләде. Аның күңелендә бер-берсенә капма-каршы теләкләр, хисләр көрәште. Инде Сәгыйтьнең көтмәгәндә дулый башлавы аңа көч кертеп җибәрде, билгеле бер карарга килергә мөмкинлек бирде.

— Что с тобой, Сәгыйть?— диде ул бөтенләй тыныч, нык тавыш белән һәм кычкырып көләргә тотынды.— Ужас!.. Көзге кирәкме? Карале йөзеңә — нинди усал син!

Ида сумкасыннан хушбуй исе аңкытып торган дүрт почмаклы бәләкәй генә көзге чыгарды һәм сумкасының каптырмасын шартлатып бикләп куйды да көзгене Сәгыйтькә сузды. «Мине һаман тилегә саный бу!»— дип уйлады Сәгыйть, ярсып.

— Мин сине көзгесез дә яхшы күрәм... Күңелеңдә нәрсәләр барын уч төбендәге кебек күреп торам!

Ида, аның үртәлүенә һич тә игътибар итмәгән шикелле, тагын көләргә керешге.

— Ну, нәрсәләр бар минем күңелдә — әйт, әйт!

— Шулаймы? Әйтимме?— Иданың үз-үзен тыныч тотуын күреп, Сәгыйть кинәт сүрелә төште, гайрәте кимеде, тавышы әкренәйде, көчсезләнде.— Син... син нигә сүзеңдә тормадың?.. Нигә вәгъдәңдә тормадың? Нигә җәй буена рәтләп җавап та бирмәдең?— диде ул, хәлсез кеше кебек пышылдавык тавыш белән, ашыга-ашыга. Аңа сөйләве бик авыр, бик кыен иде.— Әгәр... әгәр бетте дисең икән... булмый дисең икән — нигә яшерергә аны?

— Кем әйтте сиңа, бетте, дип? Мин әле сиңа берни әйтмәдем,— диде Ида, җитди итеп.

— Менә шул-шул: берни дә әйтмәдең!

— Минем... синнән башка кемем булсын? Нинди вздор сөйлисең, син, Сәгыйть! Син бит мине прекрасно беләсең — мин синнән башка беркемне дә ярата алмыйм... гомергә дә, үлгәнче дә!..

Сәгыйтьнең йөрәге тагын дерт итеп китте: юк, һаман бүтән нәрсә, чит нәрсә турында сөйли, юри бутый, юри икенче якка каера!

— Беләсең, беләсең!— диде ул, тагын үртәлә башлап.

Алар, караңгы бакчага кереп, бер буш скамьяга утырдылар.

— Белмим шул менә,— диде Сәгыйть, ярсу да, газап та, өмет катыш икеләнү дә сиздергән кайнар пышылдау белән.— Белмим шул менә: әллә яратасың, әллә... Син минем сорауга җавап бирмәдең — нигә хат язмадың?

— Язмадым?— диде Ида, бик нык гаҗәпләнеп.

— Әйе, язмадың. Минекеләрне алдыңмы соң?

— Әллә син миңа хат яздың?— диде Ида, тагын да ныграк гаҗәпләнеп.

Сәгыйтьнең күңеленә шундук: «Нәрсә бу? Әллә тагын шаяртамы? Әллә соң чынлап та?..»— дигән уй килде.

— Алайса син минем хатларымны алмадың?— дип кычкырды ул, үзе дә сизмәстән урыныннан сикереп торып.

— Язган булсаң, алырыем,— диде Ида, коры гына.

— Алмадың? Берсен дә алмадың алайса? Берсен дә!— дип кычкырды Сәгыйть, тыела алмыйча.

— Юк, баштагы икесен алдым, үзеңә дә яздым ич.

Әйтерсең башына күсәк белән китереп суктылар — шундый көтелмәгән, шундый коточкыч яңалык иде бу. Ачуы-ярсуы — бөтенесе дә төкерек кебек эчкә йотылды, үзеннән-үзе йомарланган йодрыклары язылып китте. Ул кинәт үзенең гаепле икәнен, коточкыч гаепле икәнен күрде, аның шундук гафу үтенәсе, аны күккә чөясе килде, һәм ул шатлыктан, бәхеттән тилереп, шашынып, комсызланып аны күкрәгенә кысты, аның битеннән, колагыннан, борын очларыннан үпте.

— Алайса мин сине нахакка рәнҗеткәнмен, тукран башым, былбылым?!— диде ул, үзенең ялгышуына шундый нык сөенеп.— Гафу ит, гафу ит. Мин дурак, мин дурак! Алайса син минем хатларны алмадың? Аңлашыла, аңлашыла... барысы да аңлашыла! Ул мине ташлаган, ул мине оныткан, ул — кансыз, ул сүзендә тормый, хат язмый, мине исенә дә кертеп чыгармый, дидең инде син.

Аңлашыла! Шуңа күрә дә бүген миңа гел кире ягың белән тордың инде, иеме? Соң сине ташларга мөмкинме соң?! Әйт, мөмкинме? Син булмасаң, үләм бит мин!.. Мин — дурак!

— Канишно, син дурак,— диде Ида, ачусыз гына, һәм, тагын да ныграк иркәләнеп, аның күкрәгенә сыенды.

— Синең турыда нәрсәләр генә уйлап бетермәдем мин!— диде Сәгыйть, һаман тынычлана алмыйча, дәртле, ашкынулы тавыш белән.— Мин инде сине бөтенләй минеке түгелдер дип уйлый башлаганыем. Мең кисәккә теткәләп ташлардай була торганыем сине шундый чакларда — менә ничек яратам мин сине! Чын-чынлап көнчел рыцарь — дуэльгә генә чыгасы калганые.

— Дура-ак...— дип пышылдады Ида, аңа тагын да ныграк сырылып.

Алар, янып сөюнең изге серенә яңа гына төшенгән тәҗрибәсез яшь гашыйклар кебек, бер-берсенең йөрәк тибешенә, бер-берсенең кайнар сулышына колак салып, бер-берсе алдында изрәп, мәмрәп тынып калдылар. Дөньяда хәзер алардан башка тагын кемнең дә булса булуы мөмкин дә түгел иде.

Бакчадагы соңгы кешеләр дә таралышып бетте, урам шау-шуы басыла төште, автомобиль гудоклары сирәгәйде, тимер юл вокзалы ягыннан йокымсыраган паровоз тавышлары ишетелде. Төнге һава сизелеп үк салкыная башлады. Сәгыйть берни тоймады.

— Нишләп барып җитмәде икән соң минем хатлар?— диде ул бераздан, үзалдына сөйләнгән шикелле.

— Минекеләр дә!— диде Ида.

— Синекеләр дә!..

Ида бераз гына сүзсез утырды да, ниндидер яшерен нәрсәнең эзенә баскан шикелле, шатланып кычкырып җибәрде:

— Белдем! Ах, белдем! Менә хәзер белде-ем... Только ачуланмассыңмы, Сәгыйть, бернәрсә әйтсәм, ачуланмассыңмы?— Ул аның каты, юан бармакларын ныгытып кысты, хәзер менә бөтен эч серен ачып салырга әзер торган кеше сыман, тутырып аның күзләренә карады.

Егетнең колак үрә торды. Шулай да ул йомшак кына итеп:

— Әйтеп кара,— диде.

— Юк, син ачуланма только!

— Ачуланмам...

— Кайткач... миңа бер типус бәйләнеп йөрде...— диде Ида, һәм шул вакыт аның күз алдыннан Бәхти чагылып үтте. Ул — үзенең ялган сөйләвеннән түгел, бәлки, үзе-

нең алдануын исенә төшереп, кинәт сүзеннән туктап калды, кызарынды, уңайсызланды. Ләкин бу бик тиз узып китте.— Шундый бер ужасный тип... ефрейтормы, капитанмы булган шунда... Кайдадыр инспектор булып эшли. Ну, син ачуланмыйсыңмы? Ну, бер невежа инде... авылда, беләсең ич, күсәк, дубина... Бер кичне танцевать итте бу минем белән — иптәш кызым белән кинодан соң танцыга калганыек. Ну, без икенче көнне дә бардык, өйдә страшно күңелсез. Бу тагын минем тирәдә крутится-вертится. Тоттым да мин моңа грубить иттем. Өченче көнне беркая бармадым. Өйдә утырдым. Бер кыз артыннан записка җибәргән бу миңа. Ну, просто нахальство! Күз алдына китерәсең инде: яратам-фәлән, то да се... Запискасын утка ташладым да теге кыз артыннан җавап җибәрдем...

— Шуннан, шуннан?

— Туктале, тукта... җавап хаты бик интересный чыкты: «Студенткаларга любовный запискалар язып интеккәнче, башта буеңны үстер әле бер ун сантиметр булса да»,— дидем тегеңә.

Сәгыйть утырган урынында кымшанып куйды.

— Ансын бераз арттыргансың,— диде ул ачулану да, көнләшү дә белдермәгән җитди тонда.— Ансы бераз артык. Ансы инде кешенең физик ягы. Шулай бик кыска буйлымыни соң ул?

— Ужасный карлик! Минем кулбаштан да юк, кәкре аяклы... Исеме әллә Рим, әллә Неаполь...— Аларның авылларында чыннан да шундыйрак бер кеше бар иде.

— Синең исем кебегрәк икән,— дип куйды Сәгыйть, көлемсерәп.

— Ну, дальше... Аның сеңелесе почтада эшли. Аңлашыламы хәзер? Ясно? Вот карлик! Аның эше булмый — кемнеке дисең?

— Сиңа аны судка бирергә кирәк, судка!— дип кычкырды Сәгыйть, үзендә кинәт «ефрейтор»га карата туган ачуына чыдый алмыйча.— Аның ни хакы бар? Мин сиңа анда ниләр генә язмадым! Укыганнардыр да көлгәннәрдер! У-у, кабахәтләр!..

— Хәзер соң шул инде,— диде Ида, үкенечле тавыш белән, авыр сулап.— Аннан соң — к чему? Аңлаштык — шул җитмәгәнмени? Син булгач, хәзер миңа берни кирәкми — хат та, суд та, чорт та!..

— Шулай булгач, без икебез дә гаепле, беребез дә гаепле түгел!— диде Сәгыйть, тәэсирләнеп.

Бары да аңлашылды, бары да ачык. Ничек итеп ул аны бернинди сәбәпсез әллә нәрсәләрдә гаепләргә батыр-

чылык итте икән? Әллә кемнәрнең оятсызлыгы, наданлыгы, кабахәтлеге аркасында шулкадәр газап кичер, имеш, нахакка бер гаепсез, саф, намуслы кызыңны рәнҗет, имеш! Коточкыч нәрсә бит бу! Шулай да күп нәрсәдә ул үзе гаепле. Ул әле һаман үз-үзен чын-чынлап ирләрчә тота белми, чын-чынлап ирләрчә төпле, дөрес фикер йөртә белми. Шуңа да ул аның алдында гел көлкегә кала да! Көлке булмыйча, көлке, әлбәттә! Аның хыянәт итүе, вәгъдәсен бозуы мөмкинме соң! Һичкайчан да! Әйе, алар арасына җил дә үтәрлек түгел.

Ләкин шул вакыт ул үзенең авылда чакта Ида агитбригадага катнашкандыр, анда егетләр белән йөргәндер, дип күңеленнән котыруын исенә төшерде. Бу да хәзер аның өчен аңлашылмаган, куркыныч нәрсә түгел иде. Әмма шулай да ул, үз-үзен тәмам тынычландырырга теләп, аннан шул турыда сорамакчы булды.

— Син барыбер җегетләр белән йөрдең... агитбригадада,— диде ул, әкрен генә.

— Нәрсә, нәрсә?

Сәгыйть аңа «Комсомольская правда»да укыган мәкалә турында, шуннан соң үзенең әллә нәрсәләр уйлап бетерүе турында сөйләп бирде.

— Син ул агитбригадада катнаштыңмы соң шулай да?— диде ул соңыннан.

— Минем ул турыда ишеткәнем дә юк! Кызык син, Сәгыйть, әллә нәрсәләр китереп чыгарасың. Шунда җегетләр белән гүләйт ит, имеш! Син әле читтә булсаң да ул агитбригада турында беләсең — минем, әйтәм бит, ишеткәнем дә юк. Гәзит укырга бик үк әвәс түгеллегемне син бит яхшы беләсең... Ну, Сәгыйть, син миңа икенче мәртәбә мондый чепухалар белән бәйләнмә!.. Обидно... Ату, үпкәләрмен, яме?

— Бетте, бетте! Моннан соң — беркайчан да!— диде Сәгыйть, тагын икенче мәртәбә ялгышуына нишләргә белмичә сөенеп.

Алар аерылышканда сәгать иртәнге өченчегә китеп бара иде инде. Караңгы тын урамнар буенча Сәгыйть, канаты яңадан төзәлгән кош кебек, очынып, җилкенеп кайтты.

...Икенче көнне иртән күзләрен ачып җибәргәч тә ул, кулларын баш астына куйды да, түшәмгә текәлгән көе, гадәтенчә, фантазиягә бай художникларга һәм гашыйкларга гына хас төгәллек, ачыклык белән кичәге кичне күз алдыннан үткәрергә, күңеленнән кичерергә тотынды. Ул бер-бер артлы Иданың кыяфәтләрен, сүзләрен, тавыш тоннарын һәм үзенең нәрсәләр уйла-

вын, нәрсәләр кичерүен — барысын да исенә төшерде. Әле кызарды, әле агарды, кашларын җыерды, кинәт кенә үзалдына елмаеп җибәрде. Ул үзен бәхетле тойды. Ләкин, гаҗәп хәл, бу бәхет аның күңелендә бернинди шатлык хисе уятмады. Йөрәге, никадәр генә дулкынланса да, барыбер тыныч көе калды. Ул Иданың ярату сүзләрен, иркәләнүләрен, күз карашларын, үзенең аны ничек итеп кочуын, ничек итеп үбүен яңадан бер кат тыңлап, тоеп, сизеп карады, әмма үзе көткән дәрәҗәдә ләззәт тә, канәгатьләнү дә таба алмады. Киресенчә, беренче очрашу кичәсенең һәрбер детален тыныч күңел, аек баш белән яңадан хәтер иләге аша үткәрә башлагач, күп кенә нәрсә аның өчен аңлаешсыз булып калды.

Шулай да, кинодан чыккач та, нигә ул аннан качарга тырышты икән? Бүлмәдә чакта бит анда берни дә сизелми иде, ул шундый киң күңелле, шундый ачык, ягымлы иде. Әгәр ул аңа башта ук ачуланмаган икән, аңа карата үпкә-фәлән сакламаган икән, урамда да ул үзен шулай тотарга тиеш иде, ягъни элеккечә икәүдән-икәү генә калырга, бернинди киноларга бармаска, ул әйткәнчә, йә паркка, йә берәр бакчага китәргә риза булырга тиеш иде, һич югы, аның теләгенә каршы килмәскә тиеш иде. Чынлап та, бер-береңне шулкадәр сагынып тор да, бер-береңә сөйлисе сүзләрең шулкадәр күп булсын да — тот та киного кит, җитмәсә, соңыннан тизрәк кайтып китәргә, урыныңа кайтып ятарга ашык!

Ярар, кинога баруда берни юк, ди, аның чыннан да кинога барасы килгән, ди. Ярар. Ләкин, әгәр ул аны берәр нәрсәдә гаепле дип уйлый икән, ул миңа нигәдер хат язмады, сүзендә, вәгъдәсендә тормады, дип уйлый икән — нигә соң ул алайса беренче булып үзе аңлашырга, мәсьәләне ачыкларга тырышмады? Нигә ул аңа ачуланмады да, үпкәләмәде дә, нигә ул аны: вәгъдәсез дип, фәлән-төгән дип атамады? Нигә, ниһаять, үзе гаепле кеше шикелле, бер дә юкка дерелдәргә тотынды, тизрәк аның яныннан китү, ычкыну ягын гына карады?!

Юк, монда тагын нәрсә дә булса бар. Валлаһи, бар! Чын күңеленнән сөйгән кеше мәсьәләне ачыктан-ачык куяр иде, шулай-шулай, Сәгыйть, диер иде, күрәсең, син мине ташлагансыңдыр, юри генә йөрисеңдер, чөнки син җәй көне минем хәлне дә белергә теләмәдең, диер иде; әгәр шулай икән, турысын гына әйт: яратасыңмы әле син мине һаман да, юкмы?— диер иде. Ул нәрсә әйтте? Берни әйтмәде! Кичә ул, үз егетен өзелеп сөйгән кызга караганда, бигрәк тә үзенә җәза бирүләрен көтеп торган мәктәп баласына охшый иде. Ни дигән сүз бу?

Ул моңа ачык җавап таба алмады, ул әле бер генә нәрсәне дә ачыклый алмады, бер генә нәрсәнең дә рәтенә ныклап төшенмәде, ләкин шул ук вакытта күңелендә нәрсәдер кинәт кителеп төшкәндәй булды, ниндидер үзгәреш барлыкка килгәндәй булды. Ул хәзер бер генә нәрсәне — үзенең «идеалы»на элеккечә ялкынлы дәрт белән сукырларча табына алмаячагын гына, аны инде сөттән аграк, судан пакьрак итеп, бөтен кешедән изгерәк, гүзәлрәк итеп исәпли алмаячагын гына аңлады. Анда Идага карата ышаныч кими төште. Шундый аңлаешлы, шундый ачык тоелган бу яңалык аның котын алды, аны тетрәнергә мәҗбүр итте.

Әйе, аны нәкъ шушы рәхимсез хакыйкать куркытты, һәм ул кайчандыр керсез, саф булып тоелган Иданың үзеннән әкренләп-әкренләп ераклаша барганын тойды. Менә аның шунысы да коточкыч иде инде. Ул нишләргә дә белмәде, нинди фикергә килергә дә, үз-үзен киләчәктә аның белән ничек тотарга да белмәде.

Доклады белән бер ярты сәгать чамасы гына утырды да ашыгып Ида янына китте.

Ида аңа бүген кичәгегә караганда да ягымлырак, сылурак булып күренде. Ул бертуктаусыз көлде, иркәләнде, аңа әледән-әле ярату, чиксез бирелгәнлек белдергән күз карашлары ташлады, аның һәрбер теләген үтәргә тырышты, бер генә сүзенә дә, бер генә ымына да аркылы төшмәде. Бу минутта аннан да яхшырак, аннан да гүзәлрәк кешенең булуы да мөмкин түгел иде. Сәгыйть үз йөрәгенең яңадан рәхәт дулкынланып тибүен тойды, эчкерсез ягымлылык, мәхәббәт, хөрмәт алдында тез чүкте. Иртәнге күңелсез уйлар, начар төш кебек, каядыр таралып бетте.

Алар урамнар буйлап йөрделәр, борынгы Кремль стеналары ягына барып чыктылар, Казанка елгасы буенда җәелгән зур төзелешкә, җирне ашый-ашый, үзе артыннан тирән күл ясап, болын уртасына кереп утырган земснарядларга, Казанның Ленин районы ягына сузылган туры дамба читендәге биек ком тауларына, шунда кайнашкан кешеләргә, машиналарга карап тордылар. Сәгыйть җәй көне үзенең печән чабуы турында, Барис белән комбайнда эшләве турында сөйләде, Ида тагын үзенең бала чакларын исенә төшерде, элекке дус кызларыннан көлде. Аннан соң алар Сөембикә манарасына менделәр. Манара эчендәге агач баскыч тоткаларына, басма такталарына, өрлекләргә, стеналарга меңнәрчә кешеләр язып, сызып, чокып калдырган исемнәрне, хәрефләрне, саннарны укыдылар. Манараның иң биек җиренә менеп

җиткәнче Ида әледән-әле туктап ял итте, Сәгыйтьнең беләгенә асылынды. Аның битләре кызарды, ул бер-ике мәртәбә, еш-еш тын алып: «Тагын менәсе бармыни әле?» — дип сорады. Алар, тәрәзәдән башларын тыгып, аска карадылар. Кызыл, соргылт, яшел түбәләр; күккә сузылып утырган завод морҗалары; Идел аръягындагы Югары Ослан тавы; шәһәр читендәге саргылт-яшел урманнар; Казанка буендагы калкулык өстендә кызыл кирпечтән салынган зур йорт; озын вышка — бөтен нәрсә фотодагы кебек бәләкәй генә булып, вак кына булып күренде. Шәһәр өстенә кечке кызгылт кояш нуры сибелгән иде, шакмак-шакмак йортлар, тигез урамнар арасында күләгә белән яктылык аралашкан иде.

Ида аска, ниндидер кыска кешеләр, җәенке машиналар кыймылдашкан урам өстенә карады да, коты алынып:

— Ох, шушыннан җыгылып төшсәң!..— диде. Аннан соң Сәгыйтькә борылды да, көлеп: — Мин кушсам, шушыннан сикерериеңме?— диде.

— Юк!— диде Сәгыйть.

— Алайса син мине яратмыйсың!

— Анда сикереп, ит кисәгенә әйләнгәч — яратсам ни, яратмасам ни сине, барыбер түгелмени? Икәү сикерсәк — анысы менә ярый, ичмаса!

Ул аның биленнән кочаклап алды. Ида куркып кычкырып җибәрде, әйтерсең Сәгыйть чыннан да аның белән манарадан җиргә сикермәкче иде.

## VI

Сәгать төнге уникенче. Бүлмә эче тып-тын, өстен ачып ташлаган Павелның мышнап сулыш алганы гына ишетелә. Бүген Сахалиннан килеп төшкән Андрей вокзалга әйберләрен алырга китте, Венгрия егете Миклош икенче бүлмәдә, үзенең дуслары-ватандашлары янында. Алар анда татар көйләрен өйрәнәләр. Миклош скрипкада бик яхшы уйный. Лампочка сүндерелгән, ләкин бүлмә эче караңгы түгел — тәрәзә аша ак стеналарга тыштан ут шәүләсе төшә. Коридорда сирәк-мирәк аяк тавышлары, ишек ачып япкан тавышлар ишетелә.

Сәгыйть әле һаман юк. Хәер, көн дә шулай инде. Юк, бүген аны, һичшиксез, көтәргә кирәк. Ух, нинди авыр сөйләшү булачак аның белән!..

Гасыйм өстендәге одеялын читкә алып ташлады да тиз генә урыныннан торып утырды һәм, юан балтырлы шәрә аякларын койка читеннән салындырып, нәрсәдер уйлаган сыман тынып калды. Аннан соң, идәнгә басып,

тәрәзә янына килде, тышка карады, анда беркем дә күренмәгәч, яланөс көе, идән буенча әрле-бирле йөренергә тотынды.

Җәй көне ул үзләре авылында Бәхти белән очрашты. Бу очрашу автомашинада узып киткән чактагы очрашуга караганда да көтелмәгәнрәк булып чыкты.

Ул урам читендә басып тора иде. Бәхти, аның турысына җиткәч, мотоциклын кисәк кенә туктатты да, озын, киң беләзекле күн перчаткасын салып, кесәсеннән папирос чыгарды.

— Утыгыз юкмы?— диде ул, аның йөзенә карамыйча гына.

Аннан соң, күзлеген маңгаена күтәреп куйгач, аны танып алды, көн дә күреп гадәтләнгән кешесенә эндәшкән кебек, бер дә ис китмәгән, салкын тонда, эре генә:

— А-а, Гасыйм?.. Привет...— диде һәм күрешер өчен иренеп кенә перчаткалы сул кулын сузды.

Гасыйм да аның белән очрашуына әллә ни артык куаныч белдермәде. Алар арасындагы мөнәсәбәт, гомумән, мәктәп елларыннан калган тутык истәлекләрдән, очрашкан чакларда әйтелә торган «исәнме-саумы» кебек сүзләрдән ары узмый иде.

Бәхти хәзер аңа тагын да озыная, киңәя төшкән шикелле күренде. Тик аның кешегә туп-туры карый ала торган шардай күзләре генә элеккечә яшькелт боз кисәкләре кебек җансыз салкынлык бөркеп тора иде, аннан соң, йөзе, яшьтән үк аракы белән, тәмәке белән мавыга башлаган кайбер егетләрнеке шикелле, бик иртә картайган, төссезләнгән, нурсызланган иде.

Алар, тиз генә аерылышып китүне ничектер уңайсызга санап, теләр-теләмәс кенә, көчәнеп кенә бер-берсенең хәлләрен сораштырырга тотындылар. Бәхти папирос тәкъдим итте, ул алмады.

Бәхти кинәт перчаткаларын бер-берсенә шапылдатып куйды.

— Ә-ә! Беләсеңме, мин бит синең асыл кошың белән типтердем!— диде ул, тешләрен ыржайтып.

— Нинди минем «асыл кош»?— диде ул, чыраен сытып, аның кем турында сөйләгәнен шәйләмичә.

— Һа! Нинди асыл кош! Ике аяклы, ике куллы. Син дә Казанда, университетта укыйсың түгелме соң?

Аның йөзе тартышып куйды. Күз алдына шундук яшен тизлеге белән алсу чалбар, ак эшләпә һәм бармак очында селкенеп торган бәләкәй сумка килеп басты.

— Шуннан?.. Укыса ни булган?— диде ул теш арасыннан, аның оятсыз йөзенә карарга җирәнеп.

— Шуннанмы? Менә шул...

Һәм үзенең гыйшык маҗаралары, хатын-кыз күңелен яулап алуда күрсәткән «батырлык»лары белән теләсә кем алдында шапырынырга ярата торган Бәхти Ида белән булган нәрсә турында, бер генә детален дә төшереп калдырмыйча, барысын да сөйләде дә бирде. Ул Иданы нигәдер аның сөйгән кызы дип исәпли иде бугай. Шуңа күрә ул, аның ачуын китерү, йөрәгенә тоз салу нияте белән, юри бераз арттырып та җибәрде, әледән-әле аның күзенә карап, шаркылдап көлеп алды. Ә соңыннан:

— Жалкы, тагын бераз гүләйт итеп булмады, китәм,— диде.— Әйтәсе дә түгел, шәп синең кыз!

Шуннан соң аның үзгәргән йөзен күреп алды да, тупас ягымлылык, оятсызлык белән сорап куйды:

— Нигә, әллә синеке түгел?.. Исеме Идея. Идочка дисәң дә була. Тәне җоп-җомшак, мендәр кебек. Может син аны белмисең дәдер?

— Юк... мин андый кызны белмим...— диде ул. Аның йодрыклары торган саен ныграк кысылды.— Безнең кызлар андый түгел... Ул кыз минем танышым гына булса да... мин синең хәзер... тешеңне кесәңә тутырып җибәргән булырыем!..

Барыбер үз-үзен тыеп кала алмады. Кисәк кенә аның беләгеннән шундый ныгытып тотып алды, тегесе тартылып китте һәм чак-чак кына мотоциклыннан ычкынып, тузанга барып төшмәде. Бәхти кинәт каушап калды, кәефле төс белән ерылган иреннәре шундук йомылды, йөзе ап-ак булды.

— Ычкын моннан, шакшы мыек!— дип кычкырды Гасыйм бар көченә.— Икенче күземә күренәсе булма!.. Авызыңны канга батырып җибәрермен... малай чактагы кебек...

Бәхти дә исенә килеп өлгерде, беләген тартып алды да, һөҗүмгә ташланырга әзерләнгән ерткыч кебек, гәүдәсен бераз артка кыйшайтты һәм:

— Но... но... көдрәймә! Үзеңә эләкмәсен!— диде дошманлык сиздереп торган явыз, әмма шулай да куркак тавыш белән.— Прашу, таптала күрмә!

Моторына ут кабызды да, мотоциклын ачулы пытырдатып, урыныннан кузгалып та китте.

Бәхти белән булган шушы бәрелешне Гасыйм соңыннан еш кына исенә төшерде һәм һәрвакыт аның ачу, нәфрәт белән йодрыклары кысылды, йөрәге, тышка атылып чыгарга теләгәндәй, ярсып-ярсып типте. Шул чакта Бәхтине яхшылап тукмап җибәрмәгәненә ул соңыннан чын-чынлап үкенде.

Ида мәсьәләсенә килгәндә, гаҗәп хәл, нишләптер ул аптырамады да, шак та катмады. Әйтерсең шулай булырга тиеш тә иде. Ул башта аңа карата чиркәнү, нәфрәт кебек бер нәрсә тойды. Ләкин шулай да бу хис бик үк көчле түгел иде.

Барыннан да бигрәк, ул үзенең дусы өчен, үзе яхшы белгән, күңелен яхшы аңлаган дусы өчен борчылды, аның турында кайгырды.

Бәхтинең сүзләренә ышанмаска аның нигезе юк иде. Бүтән вакытта ялганласа да, мондый нәрсәдә ул ялганламас, юк — ялганламас! Мактану өчен, масаю өчен бераз шыттырса шыттырыр, куертыр, әмма ялганламас! Аннан соң ул бит аларны үз күзе белән күрде. Бәхти кызлар белән йөри икән, ул инде беркайчан яхшылык өчен йөрмәс! Аның өчен бу — элек-электән билгеле нәрсә.

Тик менә нишләргә — әйтергәме, юкмы Сәгыйтькә бу турыда? Әйтсәң ни файда да, әйтмәсәң ни файда?

Казанга килгәннән бирле, Сәгыйть белән күрешкәннән бирле шушы уй аны торган саен ныграк борчыды, торган саен ныграк эзәрлекләде.

Сәгыйтьнең ул кичләрен һаман гел соңга калып кайтуын, аның һаман берни сизмичә алданып йөрүен күрде. Кайчакларда ул аңа шундый кызганыч булып, шундый сукыр, ахмакларча сукыр булып тоелды. Аның аңа бөтен дөреслекне әйтеп бирәсе, күзен ачасы килде. Ләкин эчке бер көч аны бу ниятеннән һаман тыеп, туктатып килде. Әмма шулай да моны күңелдә озак саклап йөртеп булмый иде, эчне бушатырга, җиңеләеп, иркенәеп калырга кирәк иде.

Менә бүген тагын аны авылда чакта Сәгыйтькә хат язу алдыннан булган икеләнүгә караганда да көчлерәк, каршылыклырак бер икеләнү-газап биләп алды. «Әйтергәме, юкмы? Әйтергәме, юкмы?» — диде ул, инде кырыкмаса кырык мәртәбә үз-үзенә сорау биреп. Мондый коточкыч, мондый көтелмәгән яңалыкны әйтеп, Сәгыйтькә ул нинди генә яхшылык эшли алыр икән соң?

Бәлки, Сәгыйть бу турыда үзе дә белә торгандыр, бәлки, Ида бөтенесен дә сөйләп биргәндер, гафу үтенгәндер, аклангандыр, Сәгыйть барысын да кичергәндер дә, эшләре һаман бернинди үзгәрешсез, майланган арба кебек тәгәриләр туп-турыга — бит мәхәббәт бөтенесен дә булдыра ала! Әгәр шулай булса, ул аңа бернинди яңалык ачмаячак, берничек тә аның күзен ачарга ярдәм итмәячәк, бары тик аның күңел ярасын гына кузгатачак һәм яңадан ике арада салкынлык, дошманлык тууына гына сәбәпче булачак.

Юк, мөмкин түгел!— шундый эшне ничек кичермәк кирәк?! Мең гашыйк арасыннан шундый кеше бирәү генә табылса да, ул барыбер Сәгыйть булмас. Ида нигә сөйләп торсын? Ни өчен? Таптың сөйләр кеше! Юк, Сәгыйть берни белми — күренеп тора, белми.

Ярый, бу турыда бөтенләй белмәгән очракта да, әйткәч, ул аны аңлармы соң? Бәлки, ул аңа бөтенләй ышанмас, мөмкин түгел, фәлән-төгән, дияргә тотыныр? Эченнән, җитмәсә, уйлап куяр, көнләшә, ничек тә мине Идадан аерырга тели, дияр. Бит шундыйрак нәрсә сизелә иде ич анда элегрәк. Ул чакта инде алар арасында тагын да атлап та, сикереп тә чыгып булмаслык упкын барлыкка килер.

Әгәр бөтенләй әйтмәсәң? Йөриләр икән, йөри бирсеннәр — аларда кемнең ни эше бар? Бер-берсен шулкадәр нык яратышалар икән, ни генә булса да, үзләре хәл итәрләр әле. Ат дагалаганда бака ботын кыстырмый дигәндәй, аларга вәгазь укырга, аларны тәртипкә өндәргә, әдәпкә өйрәтергә аның ни хакы бар? Бала-чага түгелләр, үз акыллары үзләренә җиткән... Тормышта андый нәрсәләр генә булмыймыни — аңа карап кына чын мәхәббәт бозыламыни?

Чын мәхәббәт?.. Кая, нинди чын мәхәббәт бар монда? Юк! Йөз мәртәбә, мең мәртәбә юк! Чепуха! Ерунда!

Нәрсә, әллә соң Ида ялгышканмы, нахакка алданганмы, бөтенләй уйламаган җирдән Бәхти корбанына әйләнгәнме? Булмый торсын! Сөйгән егете, менә дигән егете була торып, ни өчен «ялгышкан» ул, ни өчен Бәхтинең кара мыегына, шардай күзләренә «алданган» ул? Кем аны моңа мәҗбүр иткән? Ләкин әз генә үз башы белән уйлый белә торган, үзенең намусын, үзенең кызлык хисен бар нәрсәдән өстен итеп карый торган теләсә нинди кыз аның буш кеше икәнен, шомарган таш икәнен беренче караштан ук күрергә тиеш иде бит! Әгәр Бәхти белән аның арасында җитди бер нәрсә дә булмаган булса да, Сәгыйтькә ул барыбер хыянәт итмәгәнмени инде? Ничек кенә иткән әле!

Бәлки, ул Сәгыйтьне элек чынлап яратмагандыр? Әйе шул, шулай да булуы мөмкин түгелмени? Яратмагандыр да, ташлагандыр, шуннан соң инде бөтен күңеле белән Бәхтигә бирелгәндер... Тагын ерунда! Тагын чепуха!.. Әгәр чын күңеленнән яратмаган икән, ни өчен хәзер ул... тагын аның белән йөри? Ни өчен ул аңа турысын гына әйтми? Юк! Киресенчә түгел микән әле, читтән караганда ул Сәгыйтьне ныграк ярата булып күренми микән әле!

Әйе, шулай, һәм, шулай булгач, һичшиксез, әйтергә кирәк! Ул моны һич тә яшереп, эчендә саклап кала алмый.

Әйтергә булгач әйтергә! Комсорг булып кына түгел, аның чын дусы булып та, группадашы, бүлмәдәше булып та, кирәк икән — болай намуслы егет кеше булып та сөйләшергә тиеш ул аның белән.

Тик монда белеп, бөтенесен дә исәпләп, үлчәп эшләргә кирәк булачак, иптәш комсорг! Теге вакыттагы кебек тагын авызың пешә күрмәсен...

Шул чакны кисәк кенә ишек ачылып китте, һәм, җилләнеп, Сәгыйть кайтып керде.

## VII

Ул шундук ут кабызды. Бүлмә эче гөлт итеп китте. Миклош тумбочкасы янында басып торган шәрә Гасыймны күреп алды да:

— Се́рвус ток![1] — дип кычкырды мадьярча.— Миклош, мин хәзер мадьярча өйрәнә башлыйм... Гасыйм? Мин сине тагын Миклош дип торам, чак-чак кына яшерен серләрне әйттермәдең...

Гасыйм аңа бөтен гәүдәсе белән борылып карады. Сәгыйть үз койкасы янына узды да кинәт борынын җыерды.

— Фу-у!— диде ул.— Кем тәмәке тартты?

Шул вакыт ул ниндидер серле кыяфәт белән үзенә таба карап торган Гасыймның кулында утлы папирос күреп алды.

— Гасыйм?! Әһә, шулаймы әле син! Берсе дә юк чакта гына папирос суырабыз дисең, ә? Кайчан гына бөтен бүлмә алдында тартмаска сүз биргәниең әле?!

— Тәмәке?— Гасыйм кинәт бөтен тәне белән калтыранып китте, әйтерсең кемдер сизмәгәндә аның колак төбенә килеп кычкырып җибәрде. Шундук кулындагы папирос төпчегенә күз төшереп алды, аның утлы башын бармаклары белән кысып сүндерде дә тәрәзәне ачып тышка ыргытты. Гафу үтенгән сыман, ниндидер үзгәргән тавыш белән: — Ә!.. Мин болай гына... берне генә...— диде.

Сәгыйть, аның йөзенә күтәрелеп карамыйча, чын күңелдән көлеп җибәрде. Бөтен өстәл өсте, бөтен идән һәм Павелның тумбочкасы папирос төпчеге белән тулган иде, Павелның, күрәсең, әле күптән түгел генә башланган «Беломор»ы бушап калган, ачык тәрәзәдән, морҗадан чыккан кебек, тышка куе зәңгәр төтен агыла иде.

— Шаяртма, дус кеше! Белдем эшеңне, кырырмын тешеңне! Бетте, җегетләр җыелгач та әйтәм, һа-һа!..

---

[1] Сервус ток — исәнмесез.

«Күптән инде аның мондый күтәренке күңел белән кайтканы юк иде!»— дип уйлап алды Гасыйм үзалдына, Сәгыйтьнең нәрсә сөйләгәнен бик үк төшенмичә. Ул үз койкасына барып утырды да аның нишләгәнен күзәтә башлады.

— Оныта язганмын!— диде кинәт Сәгыйть, тумбочка актарып яткан җиреннән башын күтәреп.— Мин бит сиңа сөенче әйтергә дип ашыгып кайттым.

— Сөенче? Нинди сөенче?

— Нинди сөенче! Сөенче булгач сөенче инде. Син башта шуны әйт — нәрсә бирәсең?

Сәгыйтьнең шат күңеллелеге Гасыймга да йота башлады.

— Әтәч салгач, бер күкәй!— диде ул, авыз чите белән генә елмаеп.

— Юк, әтәч күкәенә генә риза түгел! Булмый! Бер кружка сыра куясыңмы?

— Туктале, син нәрсә хәерче кебек теләнәсең әле? Кем өчен сөенче: минем өченме, синең өченме? Идаң үбеп кайтарган саен берәр кружка сорый башласаң син!..

— Менә җүләр!— диде Сәгыйть, өстәл өстенә ак май, бал салынган пыяла банка белән күмәч куеп.

Аннан соң графиннан калай кружкага шыбырдатып салкын су агызды да йотлыга-йотлыга «чәй» эчәргә тотынды.

— Менә җүләр!— диде ул тагын да дусларча.— Синнән сөенче сорыйлар икән, сөенече дә синең өчен инде... Бик шәп хәбәр. Ну, әйт, куясыңмы бер кружка, ату сөенечеңне бал белән кабып җотам!

— Җотсаң җотарсың инде, мине генә кабып җотма,— диде Гасыйм, аның ничек зур-зур кабып, кабаланып ашавын күзәтеп. Аннан соң урындык алды да Сәгыйть каршысына килеп утырды.— Ләкин син эчмисең бит... Кызык — нәрсә икән соң ул? Ярар, була — куям. Молотов стипендиясе бирделәр исә...

— Ә?!— диде кинәт Сәгыйть, ашавыннан туктап.

— ...Молотов стипендиясе бирделәр исә, бер кружка сыра гына түгел, телисең икән, ярты литр кызылны куям.

— Син... кем әйтте сиңа?— диде Сәгыйть, күзләрен зур ачып.— Мин тагын ашыга-ашыга кайтам, туктале, мин әйтәм, сөенче алыйм беренче булып. Аена бишәр йөз алырга булгач, бер кружкага гына саранланып тормас, мин әйтәм. Син каян белдең? Утырыш әлерәк кенә бетте ләбаса...

— Беләм инде мин... барысын да беләм,— диде Га-

сыйм, ничектер серле генә көлемсерәп.— Шулай да син борыныңны төшермә — ярты литр синеке... икебезнеке... Хәзер үк алып кайтырыем — кибетләр ябылып беткәндер. Ярар, хәзергә син үзеңне ак аракы эчә дип хис ит. Кирәксә, чиләге белән кертеп бирәм.

Алар икесе дә шаркылдап көлешергә тотындылар. Павел йокы аралаш нидер мыгырданды да, бөтен койкаларын селкетеп, икенче ягына әйләнеп ятты.

— Юк, акны мин беркайчан да эчмәячәкмен,— диде Сәгыйть, чыраен сытып, шул вакыт ул үзенең авылга кайткач эчеп исерүен исенә төшерде.— Юк, агын да, кызылын да эчмим. К чорту! Син мине, булмаса, берәр балетка алып барырсың... телисең икән, шунда сыйларга да була!— Ул, үзенең хәйләсенә кәефе килеп, тагын көлеп куйды.

— Балетка? Сине генәме, сезне дәме?

Сәгыйть тотлыгып калды.

— Ә!— диде ул.— Шулайрак икән шул. Ярый, монда гына сыйларсың алайса. Әйдә, ашыйсың килмимени? Ату балны бетерәм, соңыннан авыз суыңны агызып йөрмә...

— Юк, миңа хәзер бал түгел, ачы нәрсә кирәк...

— Кара ничек: безнең группадан ике Молотов стипендиаты!— диде Сәгыйть, аның сүзләренең мәгънәсенә игътибар итмичә, күтәренке тавыш белән.— Шуларның берсе — минем белән бергә тора... мин ашаганга авызын күтәреп карап утыра, һа-һа-һа!.. Син яткан почмакка хәзер мәрмәр такта кагып куярга кирәк, тактага: «Монда фәләнфәләненче елда, шушы шыгырдавык койкада, дүртенче курс студенты, Молотов стипендиаты, булачак профессор, булачак академик Гасыйм Таҗетдинов йоклады»,— дип язып куярга кирәк. Шунда ук өстәп куярга була: «Бу урынга яткан кешенең бәхете булачак — үзе якты, үзе җылы, радиатор янында гына. Кем дә кем стипендиат булырга тели — шушы урынны алсын!» Нәрсә, әллә ошамый? Риза түгелсеңмени? Менә күрерсең, иртәгә бөтен группадан утызар тиен җыябыз да гроббюрога мемориаль такта ясатырга заказ бирәбез. Теге зыяраттагы кабер ташларын алар ясый торганнардыр ич? Бер тактаны гына ясап бирәләр дә бирәләр инде алар. Мәрмәрләре булмаса, балчыктан да ярар. Акча мәсьәләсендә дә кайгырмаска була — утыз тиен малмыни ул! Бер мәртәбә трамвай билеты алмый качып бардың исә, шундук утыз тиен янга кала... «Студентта акча күп була, ун тиенгә илтсәң, барабыз!»...

Сәгыйтьнең авызына ни туры килде, шуны сөйләнеп

утыруына Гасыйм әйтерсең бөтенләй игътибар итмәде. Ләкин ул һаман аны күзәтте һәм: «Нәрсәдер бар монда,— дип уйлады күңеленнән.— Группа... акча җыю... Күптән инде аның мондый булганы юк иде...»

— Син бүген нишләптер шат күренәсең,— диде ул бераздан сакланып кына.

— Нигә, минем шат булуым сиңа ошамыймы әллә?

— Юк, ошый, бик ошый,— диде Гасыйм, ашыгып.— Болай гына әйтәм. Ида белән эшләр шәп бара, ахры, синең. Шуңа да, мин әйтәм, бүген шулай канатланып кайткан инде бу...

Сәгыйть, нидәндер уңайсызланган шикелле, күзен тиз генә читкә борды, сөйләнүеннән туктап калды да, үзалдына бер ноктага текәлгән көе, уйланып, әкрен генә чәйнәвендә булды.

— Нәрсә, чәең беттеме әллә?— диде Гасыйм, урыныннан торып.— Бир кружкаңны, алып керәм — мин бит сине сыйларга тиеш.

Ләкин иптәшенең ярым шаярту, ярым кайгырту тонында әйтелгән бу сүзләре Сәгыйтькә бөтенләй тәэсир итмәде. Әйтергә теләгән нindидер нәрсәсен кисәк кенә исеннән чыгарып җибәргән һәм хәзер шуны ничек тә хәтеренә төшерергә тырышкан кеше кебек, беравык тын гына утырды да уң кулы белән иягенә таянды.

— Беләсеңме, Гасыйм,— диде ул, авыр көрсенеп,— кайчакларда менә үзеңә генә шундый авыр, шундый кыен булган вакытлар була, бөтен күңелеңне, бөтен җөрәгеңне, башыңны-миеңне нindидер авыр уй баса, кайгы кебек нәрсә баса. Шул уйларны күтәреп арып-алҗып, интегеп җөрисең-җөрисең дә, шуларның барысын да кемгә дә булса берәрсенә барып түгәсең килә башлый, җиңеләеп каласың килә башлый... Кемгә сөйлисең, кем аңлый синең уйларны? Тукта, тукта, беләм нәрсә әйтереңне! Мин сине аңлыйм. Әйе, син генә аңлыйсың дадыр мине... Ләкин кешенең күңелендә беркайчан да беркемгә әйтелми торган, әйтергә мөмкин булмаган нәрсәләр була. Аны теләсә кемгә ачып салып булмый... Чобан тулмый тишелми дигәндәй, тулганчы газапланып җөрисең... Юк, ничек кенә авыр булмасын, ничек кенә әйтергә ярамасын — булмый! Менә минем тулды хәзер, тулды, малай! Ида белән эшләрең шәп барадыр, дисең син, юк, бармый, бармый, Гасыйм... Мин бит беркемгә берни әйтмим — үзем генә беләм барысын да. Аннан соң, әйтәм бит, әйтеп тә булмый теләсә нәрсәне... Менә мин хәзер әйтәм сиңа, әйтәм, әйтмичә түзәлмим!.. Син җокларга ашыкмыйсыңмы? Иртәгә беренче лекция уннан бугай?

Гасыйм бүлмә буенча йөренүеннән кинәт туктап калды, чиктән тыш кызыксыну белән, эчке бер куаныч һәм гаҗәпләнү белән иптәшенә төбәп карады. «Бигрәк тә яхшы!»— дип уйлап алды ул шундук. Яңадан урындыгына килеп утырды да, Сәгыйтьнең авызыннан чыгарга торган һәрбер сүзне тартып алырга теләгәндәй, тиз генә:

— Юк, юк! Сөйлә, әйдә, сөйлә!— диде.

— Менә шул, Гасыйм, сөйлисе килә, бары сиңа гына сөйлисе килә... Мин хәзер кисәү кебек — җә дөрләп, ялкынланып янарга тотынам, җә кисәк кенә сүнәм дә пыскый башлыйм, көйрим... утсыз янам... Идага карата, дим... Нәрсәдер сынды, өзелде. Барыннан да бигрәк ышаныч югалды.

— Шулай укмы?!

— Күреп торам — күзгә карап алдый,— дип, сүзен дәвам итте Сәгыйть, ниндидер эчке бер әрнү, үртәлү белән.— Әйе, алдый! Беркөнне бертөрле сөйли, икенче көнне икенче төрле сөйли, бутала, йә бөтенләй эндәшми. Менә инде бер атнадан бирле гел шулай. Нәрсәдер бар... дөресен генә әйтми. Мин сизгер — ничек итеп каравыннан да, ничек итеп елмаюыннан да, нинди тонда сөйләвеннән дә мин аның күңелен шундук аңлыйм. Ялганлый, нидер яшерә, белмим...

Сәгыйть урыныннан торды да, кулларын кесәсенә тыккан көе, башын иеп, тәрәзә каршысына килде, тумбочка өстендәге папирос төпчекләрен сыпырып төшерде һәм үз-үзе белән, үз вөҗданы, үз йөрәге белән сөйләшкән кебек тыныч, ләкин тирән бер дулкынлану, эчке бер тәэсирләнү белән яңадан сүзгә керешге. Быел Казанга килгәч очрашулары турында да, үзенең авылдагы шикләнүләре турында да — берсен дә яшермичә, тартынмыйча, курыкмыйча сөйләде. Торган саен ул үзенә җиңелрәк була барганын тойды.

— Менә бүген ниндидер тоткыннан котылгандай булдым,— диде ул, сүзен бетереп һәм өстәл янында иякләренә ике куллап таянып утырган Гасыймга карап алды да, авыр сулап, елмаеп куйды.— Шула-ай, малай... Син аптырыйсың минем күтәренке күңел белән кайтканга... Бүген миңа Ида турындагы уйлар, газаплар, мәхәббәтфәләннәр беренче мәртәбә шундый чүп булып, шундый вак нәрсә, мәгънәсез нәрсә булып тоелды. Кайбер исәрлекләрне искә төшереп үземнән-үзем оялдым, җир тишегенә керердәй булдым, валлаһи! Бит мин үземнең кайда басып җөргәнемне дә, кайда утырганымны да, кемнәр белән укыганымны бөтенләй онытканбулганмын, Гасыйм!

— Кызык, бик кызык!— диде Гасыйм, башын күтәреп.— Син хакыйкатькә үз башың белән, үз җөрәгең белән барып җитәсең — синең шул ягың миңа бик ошый. Уйланасың, эзләнәсең син... Инде мәхәббәтне чүп диюең — ерунда! Чепуха! Чын мәхәббәт беркайчан да чүп тә түгел, вак нәрсә дә түгел — син инде аны миңа караганда мең мәртәбә яхшырак беләсең, өйрәтеп торуның кирәге юк. Синең Иданы чын күңелдән яратуың да, минемчә, бер дә чүп түгел. Тик менә... Ничек әйтергә? Арттырып җибәрәсең бугай... арттырып җибәрдең бугай... Ну, ерунда! Бик кызык бу, әйе... Нигә туктадың әле син? Әйдә, сөйләп бетер инде бер тотынгач.

— Тагын нәрсә сөйләргә? Менә шул...— Сәгыйть беравык уйланып торды. Аның йөзе тагын уйчанланып калды.— Белмим, малай, кайсы юлдан китәр бу безнең мәхәббәт дигән нәрсә... Бөтенләй аерылышу мөмкин микән ул?.. Ләкин мин бүген кайтканда аның турында уйлап та карамадым.

Коридорда кычкырып сөйләшә-сөйләшә егетләр, кызлар узып китте. Сәгыйть тә, Гасыйм да, аларның ни сөйләгәннәрен аңларга теләгән шикелле, андагы тавышка колак салып, ләкин чынында икесе дә үз уйларыннан арына алмыйча, беразга тынып тордылар. Павел йокы аралаш нәрсәдер мыгырданып куйды да тагын икенче ягына әйләнеп ятты.

— Алайса ул җәй буе сиңа берни дә язмады? Җитмәсә, почта кешеләрен гаепли?..— диде Гасыйм, Сәгыйть белән сөйләшүгә караганда, бигрәк тә үз-үзенә эндәшкән кебек, әкрен генә.— Менә нәрсә, Сәгыйть!.. Ида турында менә нәрсә...— Ләкин ул кинәт туктап калды. Гадәттәге кыюлыгы каядыр юк булды, әмма аның сүзләре шундый яшерен, шундый тирән мәгънәле булып ишетелде — инде бөтенләй тынычландым, җиңеләеп калдым, Идага кагылышлы бер генә нәрсә дә мине борчый алмас, дип уйлаган Сәгыйть шундук сагаерга мәҗбүр булды.

— Нәрсә?.. Аның турында нәрсә беләсең?— диде ул, шулай да берни дә сизенмәгән булып күренергә тырышып.

— Мәхәббәт буенча гына түгел... сиңа карата гына түгел — комсомол линиясе буенча да аның эш хөрти,— диде Гасыйм, бераз көттереп, бөтенләй икенче тонда.

— Нишләп?

— Буа буудa булмады — монысы бер. Справка алып килмәгән — ике. Нәрсә, әллә оныттың дамы? Буа бууда булмаучылар җәй көне доклад-фәлән сөйләргә тиешләр, шул турыда справка алып килергә тиешләр, дип, карар чыгарганыек ич!

Нишләп онытсын! Сәгыйть Иданың ни өчен буа буарга бармавының сәбәбен аңлатып язган сүзләрен исенә төшерде. Кашларын җыерып куйды. Ләкин Гасыймга бу турыда берни әйтмәде — кыюлыгы җитмәде, ни әйтсәң дә, ул барыбер аның Идасы иде һәм бер кичне генә аның турында уйламау — бу әле аның турында уйлап та карамау, аннан бөтенләй читләшү дигән сүз түгел иде... Ул күңеленнән аны Гасыйм алдында хәтта якларга да әзер иде. «Шул агитбригадаларында катнашса ни булган инде аңа!» — диде ул үз-үзенә, аны шелтәләгән шикелле һәм үзенең әле кайчан гына аны анда егетләр белән биеп йөридер, дип уйлавын бөтенләй онытып. Гасыймга ул аларның агитбригадасы турында да, «Комсомольская правда»дагы мәкалә турында да бер генә сүз дә ычкындырмады.

— Бөтен группадан ул гына үзенең вәгъдәсен... үзенең бурычын үтәмәгән,— диде Гасыйм, Сәгыйтьнең ни уйлаганын белергә теләгән сыман, һаман аннан күзен алмыйча.— Справка алып килдеңме, дигәч, көлә, күзләрен кыса, сүзне уенга борып җибәрмәкче була. Аны комсомол җыелышында тикшерергә туры киләчәк... бераз кыздырырга, кызартырга туры киләчәк. Ну, синеңчә ничек?— Гасыймның тавышы әкренәя төште, дусының күзләренә ул сынап, җентекләп карады. Һәм һәрбер сүзенә басым ясап: — Әгәр син каршы килсәң... бәлки, группа алдында кызартып та тормабыз?— диде.— Бәлки, үзара гына, бюрода гына тикшерербез? Син болай... гашыйк булып түгел, комсомол булып, Иданың группадашы булып әйт...

Сәгыйть дулкынланып тагын урыныннан сикереп торды, графиннан кружкага су агызып алды, бик нык кибеккән кеше шикелле, кружканы күтәреп эчеп бетерде дә, авызын кулы белән сөртә-сөртә:

— Юк, Гасыйм, юк!— дип кычкырды.— Син миңа башта әйтәсе сүзеңне әйт! Тыңлап-тыңлап торам да... койрык болгый башладың! Син дә миннән нәрсәдер яшерәсең, валлаһи, яшерәсең! Күзләреңнән үк күреп торам! Нәрсә беләсең Ида турында? Нигә турысын гына әйтмисең? Бүтән вакытта бит уйлап та бирмисең. Курыкма, теге чактагы кебек ачуланмам да, үпкәләмәм дә... Андый чак узды. Җыелышка кую мәсьәләсе...— аны миннән сорап тормыйлар: тикшерергә икән, тикшерергә, анда минем катнашым юк.

Беркайчан да ялгышмыйча дөреслекне сизеп алырга ярдәм итә торган нечкә бер тойгы аша ул Гасыймның баядан бирле нәрсәдер әйтергә теләгәнен, хәтта ул «нәрсә»нең нәрсә икәнен дә шәйләп алды. Ләкин аның аны үз колагы белән ишетәсе килде, үзенең күңелендәге «нәрсә»сенең дөресме, түгелме икәнлеген беләсе килде.

— Дөресен әйтергәме? Ярар, тыңла!— Йөзеннән кан качкан Гасыйм сизелер-сизелмәс кенә калтыранган бармаклары белән тумбочка өстендәге папирос кабын капшап алды, ләкин шундук исенә килде дә папиросны кире урынына ташлады, үзенең мондый йомшаклыгына ачуы килгән кебек, кулын селтәп, кисәк кенә урыныннан торды.— Турысы гына шул: ул сине алдый! Ул сине алдаган! Җәй көне алдаган... Сине генә алдамаган, үзе дә алданган! Мин үз күзем белән күрдем, үз колакларым белән ишеттем! Синең кисеп ташлаган тырнагыңа да тормый ул! Менә кем ул синең идеаль Идаң!

Аның тавышына Павел тагын уянды, күзләрен бер ачып, бер йомып, бераз гына каранып ятты да яңадан икенче ягына әйләнде. Әгәр коридорда берәрсе булса, бу бүлмәдә егетләр тиргәшәләрдер, дип уйлар иде.

— ...Алай гына да түгел: тотнаксыз, вәгъдәсез, оятсыз ул!— диде Гасыйм әкренрәк тавыш белән.

Урындык аркасын ике куллап кысып тоткан көе, башын күтәреп карарга да батырчылыгы җитмичә, бер кызарып, бер агарынып утырган Сәгыйть коточкыч тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Берни дә аңламыйм! Аңламыйм! Аңларга да теләмим!

— Тукта, хәзер бөтенесен дә аңларсың...

Гасыйм сөйләгәндә Сәгыйть аны бер генә сүз белән дә бүлдермәде, сорау да бирмәде, нәфрәтен, ачуын да белдермәде, кымшанмады да, ичмасам, керфек тә селкетмәде. Әйтерсең ул утырган җирендә җансыз катып калган, урындыгына берегеп калган иде. Гасыйм, сүзен бетереп, башын күтәреп караса, шаккатты: аның йөзе электр яктысында ак стенадан да аграк булып күренде.

Алар, икесе дә әле генә ызгышып, кыйнашып туктагач, хәзер бер-берсенең күзенә карарга оялган кешеләр шикелле, бер-берсеннән уңайсызланып, шул ук вакытта бу кадәр коточкыч яңалыкның авырлыгына, аяусызлыгына түзә алмаган кебек, күпмедер вакытка өнсез-тынсыз калдылар.

Беренче булып Сәгыйть кузгалды. Көтмәгәндә өстенә коелган пычрак, әшәке нәрсәдән арынырга теләгән кебек, кулбашларын авырлык белән генә кыймылдатып, алпан-тилпән атлап, үзенең урыны янына килде, койка астыннан чемоданын тартып чыгарды, китаплар, дәфтәрләр арасыннан фотоальбомын эзләп тапты, альбомнан Иданың рәсемен алды.

Ида күперенке чәчләрен юри туздырып, иреннәрен юешләтеп һәм кино артисткаларына охшатырга тырыш-

кан сыман, башын бераз кыңгыр салып төшкән. Ул елмая. Ләкин аның елмаюы чын елмаю түгел — ялган, ясалма, алдакчы елмаю. Чәнечке кебек як-якка тырпаеп торган озын керфекләре дә ялган, ясалма. Рәсем артындагы: «Мәңге синең Идеалың»,— дигән сүзләр дә ялган, ясалма. Монда бөтен нәрсә ялган белән, икейөзлелек белән тулган. Аның хәтта кылтаеп күз кысуы да, түшендәге алтын суы йөгерткән тимер... чуен медальоны да, күлмәгенең кабарынкы иңсәләре дә — берсе дә чын түгел, барысы да — ялган, ясалма.

Сәгыйть рәсемгә күз кырые белән генә карап алды да аны урталайга ертты, вак кисәкләргә ваклап бетерде һәм идәндә яткан тәмәке төпчекләре кебек итеп, чүп савытына ташлады. Шуннан соң, бик озак чирләп ятканнан соң әле яңа гына аягына басып килә торган сырхау кебек, ниндидер бер авырлык, кыенлык белән яңадан чемоданына иелде, аны аска этеп куйды һәм шулай ук авыр хәрәкәтләнеп, әкрен генә, сүзсез генә костюмын кия башлады. Аның күзләре тонган, нурсызланып калган иде, кансыз иреннәре ныгытып кысылган, бөтен кыяфәтендә тел белән әйтеп бирә алмаслык коточкыч газап, кайгы һәм әчке бер сызлану күренә иде.

Үзенең кайда икәнен дә, нишләгәнен дә рәтләп аңлап җитмәгән шикелле, ышанычсыз, исерек адымнар белән ул ишеккә юнәлде.

— Сәгыйть! Кая барасың?— дип кычкырып җибәрде Гасыйм.

Ул туктап калды.

— Тын җитми... Буылам... Тын җитми миңа, Гасыйм... Булмый...— диде ул күз яше сизелеп торган ниндидер көчсез, кызганыч, әрнүле тавыш белән.

Ишектә аңа каршы ак чырайлы Миклош очрады. Сәгыйтьнең каядыр барырга җыенганын күреп:

— Ка́я ба́ра?— диде татарча.

— Аһ, сервус, сервус, Миклош...— диде Сәгыйть һәм, алдын-артын карамыйча, баскыч буйлап аска төшеп китте.

Ул чыгып берничә секунд торгач та, Гасыйм да ашык-пошык киенә башлады. «Артыннан китәргә кирәк!»— диде ул үз-үзенә, дусы өчен чын-чынлап борчылуга төшеп.

## VIII

Нинди матур, нинди күңелле иде бу дөнья! Көн шундый якты, шундый аяз иде, урамнарда матур киенгән, ягымлы, әйбәт кешеләр йөри иде, күңел шундый шат, шундый бәхетле, тыныч иде.

Нигә соң әле бу бөтен җир йөзен кара сөрем каплады, нигә бер генә нәрсә дә ачык булып, ялтырап, җемелдәп күренми? Кая булып беткән бу кешеләр, аһ, кая соң чын кешеләр? Йортлар да юк, урамнар да, бакчалар да юк. Нишләп болай соң бу?! Нигә соң беркем дә аны кызганмый, нигә беркем дә аны юатмый? Нәрсә булды соң әле бу? Әһә! Гасыйм әйтте! Әйе, кичә Гасыйм әйтте бит әле моны, Гасыйм... Ул һәрвакыт шундый — кешенең йөрәгенә агу салырга гына тора. Кансыз кеше ул! Юк, мөмкин түгел бу! Һичкайчан да! Ул андый түгел, ул — аныкы! Ул шундый саф, ул шундый изге, шундый әйбәт! Юри әйтте ул аны, Иданы үзе яратмаганга күрә әйтте, дошманлаштырыр өчен әйтте, бәхетсез итәр өчен әйтте... Нинди эчкерле бу Гасыйм!..

Ах, җ-җылан! Ах, юха җылан, кара җылан! Черек күлдә ничек куенга керде, ничек сырпаланды! Борынын тарта-тарта, изге булып, унбиш яшьлек алсу кыз булып иркәләнеп утырды! Нигә җир күтәрә икән шундый кешеләрне?

Тукта, Гасыйм нигә әйтте соң әле боларны? Нигә шулай аның бөтен нәрсәсен астын өскә китерде икән? Әйтмәсә генә ни булган! Үзендә генә сакласа, берни дә бозылмас иде, берни дә үзгәрмәс иде, ул һаман да елмая алыр иде, шатлана, сөйләшә алыр иде, элеккечә һаман урам гөрелтесе, җыр-музыка ишетелеп торыр иде! Хәзер ул беркайчан да аның йөзенә карый алмаячак, беркайчан да аның ягымлы, кадерле тавышын ишетә алмаячак! Беркайчан да!.. Нинди коточкыч! Әйе, мәңге аны күрәлмәячәк. Бетте, өзелде, киселде — үлем дә моннан авыррак түгелдер...

Юк, булмый, ярамый болай! Тизрәк аның янына барырга кирәк, барысын да сөйләп бирергә кирәк. Ул барысын да кичерәчәк!.. Кичерәчәк, бары ул гына ташламасын!.. Ул аны гына ярата, әйе, аны гына — бүтән беркем кирәкми! Кирәкми! Ул аны җибәрмәскә, кулыннан ычкындырмаска тиеш, ычкындырмаска тиеш!.. Андый кызны дөнья бетереп эзләсәң дә табып булмаячак, андый алтын кызны, андый...

Юк шул — соң инде... соң... Бетте. Бөтен нәрсә җимерелде, пыран-заран килде, булмый... Нинди оят!

Җ-җылан! Нишләтергә аны? Үтерергәме? Өзгәләп ташларгамы, чәйнәп бөркергәме?.. Алар анда аның хатын укып икәүләшеп көлгәннәрдер... Нинди оят!..

Әйтерсең, барысы да инстинкт буенча, нык урнашкан бер гадәт буенча эшләнде. Лекциядән чыккач, ул урамнар буенча йөрде, бакчаларга кереп чыкты, скамьяларда бераз гына утырып торды да, күңеленә тынычлык таба

алмыйча, тагын торып китте. Ул үзенең кая барганын да, кемнәр белән очрашканын да, кемнәр белән сөйләшкәнен дә рәтләп аңламады. Тротуарларда кемнәргәдер барып бәрелде, кемнәрнеңдер үкчәләренә басты, кешеләр аннан гафу үтенделәр, ул аларга күтәрелеп тә карамыйча, ашыкмыйча гына читкә тайпылды. Урам аша чыкканда аның яныннан гына, арткы тәгәрмәчләре белән ачы шыгырдап, «Победа» туктап калды — тагын бер адым атласа, машина астына эләккән булыр иде. Шофер, йодрыгы белән янап, аңа нәрсәдер кычкырды, сүгенде — ул аны күрмәде дә. Ул әледән-әле магазиннарга керде, шүрлекләргә тезеп куйган ялтыравык ботинкаларга, курчакларга, костюмнарга, төрле бизәктәге материя төргәкләренә карап торды. Бара торгач, кинәт тротуар уртасында, берәр ишегалдында туктап калды, аптырап як-ягына каранды.

Гасыйм әйткән коточкыч сүзләр, утлы тимер китеге кебек очлы сүзләр һаман йөрәгендә утырды, һаман тирәнрәк яндырып төште, бөтен нәрсәсен өтеп, көйдереп, җанын, күңелен газаплап торды.

Кайчакта аңа боларның барысы да күзне ыграк ачып җибәрдең исә, иртәнге томан кебек таралып бетә торган куркыныч төш кенәдер шикелле тоелды. Мондый чакларда аның йөрәге өметләнеп тибәргә тотынды, аның булган бөтен нәрсәне онытасы килде. Ләкин мондый теләк артыннан ук язгы ташкын шикелле ургылып килгән икенче төрле аяусыз, коточкыч уйлар дулкыны черек нигезле бу хыялларны, зәгыйфь өметләрне шундук юып ташлады.

Ул, үз-үзенә җиңелрәк булсын өчен, аның турында гел начар гына уйларга тырышты, бүтәннәрнең аның турында кимсетеп әйткән сүзләрен, элек үзенең ачуын китергән аның кыланышларын исенә төшерде. Ләкин аның ул начарлыкларына караганда үзенең хәзерге кайгысы, хәзерге газабы мең мәртәбә көчлерәк тоелды, шунлыктан ул берничек тә җиңеллек таба алмады. Аның каядыр еракка китәсе килде, күз күрмәгән, колак ишетмәгән җиргә олагасы килде, бөтенләй кечерәеп, яланаяклы малай гына булып каласы килде, кайчандыр Барис белән печән кибәне төбендә йоклап утырган чактагы бәләкәй Сәгыйть буласы килде. Ул чактагы алҗулар, ачыгулар — барысы да искиткеч матур, күңелле хыял гына булып тоелды. Аның үләсе килде, бөтенләй каядыр югаласы килде, әмма дөньяда барыбер яшәргә, хәрәкәтләнергә кирәк иде, нәрсәләрдер уйларга, нәрсәләр өчендер газапланырга кирәк иде. Иң авыры да шул иде.

Кайчакта аның күңелендә Идага карата ихлас, көчле кызгану хисе уянды. Ул аны шундый түбәнлеккә төшкәне өчен кызганды, аны хәзер шул түбәнлектән тартып алырга үзенең көчсез булуы өчен, үзенең аңа инде берничек тә ярдәм итә алмаячагы өчен кызганды.

Беренче мәртәбә кайда очраткан иде соң әле ул аны? Алар инде бер ай чамасы укыганнар иде. Дүшәмбе көн иртән гадәттәгечә үз урынына килеп утырды, звонок булды. Караса, алдында — ниндидер ят кыз. «Кем ул?»— диде, янындагы Гасыймга пышылдап. «Белмим»,— диде Гасыйм, башын чайкап — кызларга аның бик исе китми иде. Ул аңа беренче карашта ук ямьсез булып күренде, аның муены, чигәләре уңып пешкән калач кебек ап-ак иде, өстендә бәйләнгән зәңгәр кофта иде. Группадагы һәркем турында инде барысын да белеп өлгергән кызыксынучан Муся аларның кем турында пышылдашканнарын ишетеп алды да, арттан муенын сузып: «Безгә күчте. Исеме — Идея!»— диде. Ул, мондый сәер исемне ишетеп, пырхылдап көлеп җибәрде. «Реакцион идеяме, прогрессив идеяме?»— диде ул, бер ай эчендә шундый катлаулы фәнни терминнарны белеп өлгерүе белән мактанган сыманрак. Ят кыз, үзе турында сөйләшкәннәрен ишетеп, урынында кыймылдап куйды. Аннан соң...

Кара, ничек көлешеп баралар! Кызы култыклаган... Нинди бәхетледер ул егет! Коточкыч бәхетледер... Алдашмый торган, турылыклы кызы булган һәркем бәхетле...

Таш капка төбендә караңгы иде, вакыт төнге бер тирәсе иде. Беренче мәртәбә ул аны шунда үпте. Дөресрәге, башта ул үпте. Шундый җебегән иде ул — әллә никадәр батырлыгы җитмичә куркып, кан калтырап йөрде! Аны юкка рәнҗетермен, ачуландырырмын дип курыкты. Ә ул — тотты да үпте. Бөтен тәнен рәхәт ялкын чорнап алды — шундый авыр, шундый ләззәтле иде ул беренче үбешү...

Кызык бу шәһәр халкы — картларына тикле култыклашып йөри. Бит авылда алай түгел. Кая ул аларга култыклашып тору! Тизрәк сыер саварга, аш салырга кирәк, бәрәңге юарга, тегесен-монысын эшләргә кирәк. Хәбирәттәй белән Заһирҗан агай урамда култыклашып йөрсәләр — кызык та булыр иде соң... Инсафлар йөри ич...

Көтмәгәндә таныш дворник килеп чыкты да, аларның үбешеп торуын күрмәмешкә салынып, озын саплы себеркесе белән тырышып-тырышып урам себерергә тотынды. Ул әйтте: «Харап булдык — Фәйзи абый!»— диде.

Аның чәч бөртекләре күзенә, битенә төшкән иде. Алар аерылышып китә башлагач, дворник, хәйләкәрләнеп: «Каяле, шул тирәне дә себереп җибәрим»,— диде...

Доцент Захаров ич! «Исәнмесез!» Кайчан карама — гел берүзе. Күрәсең, аның турындагы имеш-мимешләр дөрестер. Әнә бит, кара сакал үстерә башлаган. Хатын-кыздан качу өчендер инде. Нинди ямьсез сакаллы яшь кеше! Хатын-кызга шул ошый. Аларга кәҗә койрыгы тагып куйсаң да ошар — соңгы мода буенча гына булсын да, оригинально булсын! Кызы алдап качкач, ул да шулай газапланды микән? Ул бит аны үләрдәй булып яраткан. Хәзер монах кебек яши, диләр. Бөек җанлы, саф күңелле кеше... Ләкин — нәрсәсе белән бөек җанлы соң ул? Бүтән бер генә хатын-кызны да яратмаган өченме? Ләкин андый кешеләргә барыбер тиле дип кенә карыйлар. Алар үзләре өчен генә батыр, үзләре өчен генә искиткеч кеше, чынында алар — буш кешеләрдер, бәхетсез кешеләрдер... Кирәкми монахлар!.. Һы, үзең нишләрсең бит әле...

Ул инде аны ике көн күрмәде. Сизенгән, ахры, лекциядән соң аның янына килмәде... Кара, таныш бакча лабаса. Кайчан утырганнар иде соң әле алар монда?

Ул бакчага кереп утырды. Башында, бер генә секундка да тынгы белмичә, һаман бер үк уйлар кайнады, күкрәген кысып, авырттырып, әрнү һәм сызлану белән, әкрен генә йөрәге типте, күрмәс күзләре каядыр бушлыкка текәлде.

Көчсез генә җил исеп китте, агач башыннан тирбәлә-тирбәлә бер яфрак очып төште. Төште дә аның тезенә кунды. Ул яфракны кулына алды. «Яфрак коела, чаган яфрагы...— диде ул, үзалдына сөйләнеп.— Түгәрәк тә түгел, озынча да түгел — чит-читләре телгәләнеп беткән, юри шулай кискәләгәннәр диярсең...»

Нечкә, каты сабагыннан тотып, яфракны ул бармаклары белән әйләндерергә тотынды... Болай караганда, үзе чын яфрак кебек, шоп-шома, ямь-яшел, ләкин... барыбер өзелгән яфрак. Әйе, өзелгән, җиргә төшкән яфрак!..

Яфракны комлы аллеяга ташлады да кисәк кенә урыныннан торды.

Урамда, бакча буеннан, култыклашып нindидер кызлар китеп бара иде. Алар арасында берсе аңа Зәйтүнә сыман күренде. Кинәт ул, бөтен бакчаны яңгыратып:

— Зәйтүнә!— дип кычкырып җибәрде.

Аның урманда адашкан кеше кебек тамак ярып кычкыруы монда, шәһәр уртасындагы бакчада, агач төбендәге һәрбер скамьяда кешеләр утырган бакчада, шундый

гаҗәп булып яңгырады, һәм бу вакытта аның кыяфәте шундый сәер иде — барысы да аптырап аның ягына борылып карады. Сәгыйть исә, аларның барын-югын да белмичә, исәр кеше шикелле аллея буенча йөгерергә тотынды, скамьяга утырган ниндидер картның ялгыш аягына басты, юл өстендәге бер баланы чак-чак кына бәреп екмады. Карт бөтен бакчаны шаулатып тиргәшергә тотынды, «Хулиган!» диде, «Бешеный!», «Нахал!» диде. Бу тавышка аның янындагы дамалар да кушылды, Сәгыйть артыннан ачулы сүзләр яуды. Студентлар, яшьләр көлешергә тотындылар. Сәгыйть аларның берсен дә ишетмәде. Иптәш кызларыннан ике-өч адым артка калып туктап торган Зәйтүнә янына атылып килде дә, елмаерга тырышып, сусаган кеше шикелле йотлыга-йотлыга:

— Зәйтүнә!.. Зәйтүнә!..— диде.

Ике куллап ул аның бәләкәй, кайнар кулын тотып алды. Үзенең авылдашын беркайчан да мондый итеп күрмәгән Зәйтүнә, каушаган хәлдә, ни әйтергә белми басып тик торды.

— Кая барасың? Кая киттең?— диде Сәгыйть, һаман еш-еш тын алып.— Нишләп ябыктың болай? Әллә чирләдең? Шәһәр һавасы килешмиме?

Зәйтүнә чыннан да күзгә күренерлек булып суырыла төшкән иде. Бу минутта ул Сәгыйтькә ниндидер җылы сүзгә, ниндидер юату сүзенә мохтаҗ булып күренде. Уку башланганнан бирле аның аны бөтенләй диярлек күргәне юк иде, очрашканда да, алар гел читтән генә исәнләшеп китәләр иде.

— Җук, чирләмәдем. Миңа бик әйбәт!— диде Зәйтүнә.

Аның шундый матур кара күзләрендә шатлык чаткысы елтырап китте, йөзендәге беренче карауга ук күзгә ташланып торган ниндидер сагыш күләгәсе шундук юк булды. Ул, кыюланып, Сәгыйтькә текәп карады һәм бөтен нәрсәне — урамнарны, бакчаларны, егетнең күңелен искиткеч куаныч белән тутырып, йомшак, ак тешләрен күрсәтеп, ирексездән елмаеп җибәрде.

— Сез үзегез соң, үзегез! Төнлә күрсәң куркып качарсың!

Сәгыйть, бераз җир киткәч, витрина пыяласы каршысына туктап, үзенең кыяфәтенә күз төшерде. Аның кыска чәчләре ачулы тырпайган, галстугы бер якка авышкан, күлмәк якасының бер очы бөгелеп калган, сулъяк җиңенә исә каяндыр тузан буялган иде. Ул, үзен шундый кыяфәттә күреп, үз-үзеннән көләргә, Зәйтүнә белән икәүләшеп көләргә тотынды. Аңа нишләптер бик җиңел, бик күңелле була башлады. Ул үзенең Зәйтүнәне әле бер

генә мәртәбә дә кинога да, театрга да алып бармаганлыгын исенә төшерде. «Менә сиңа авылдаш!— диде ул күңеленнән.— Әйтәсе дә түгел, шәп авылдаш... кереп хәлен дә белгән юк!..»

— Кая барадырыең,— диде ул, өстен-башын төзәтеп.

— Беркая да бармыйдырыем.

— Кая барабыз соң?

— Белмим,— диде Зәйтүнә, әкрен генә, күзләрен читкә борып.

— Белмәсәң шул, әйдә, операга! Операда булганың бармы соң әле синең? Юк шул! Бик шәп! Анда гел музыка уйный, кешеләр бер-берсенә гел җыр белән генә эндәшәләр. Атаклы җырчыларны, артистларны күрерсең... Юк, син үзең атаклы җырчы, әйе, менә дигән җырчы син — артист булмасаң да.. Искиткеч җырчы син, Зәйтүнәм... авылдашым... сылу күршем!..

## IX

Иртән авылдан хат килеп төште. Хатны Барис язган. Өй эчендәге һәркемнән сәлам әйткәч, йорт хәлләрен берәм-берәм санап чыккач, үзенең эше турында да, колхоздагы хәлләр турында да искә алган.

*«Колхозлар турындагы яңа карарларны укыгансыңдыр,*— дип язган Барис энесенә.— *Без бик сөендек, клубта җыелыш булды. Хаҗиевны беләсеңдер инде, юк, син аны белмисеңдер, мин дә чак-чак кына беләм әле. Министерствода зур агроном булып эшли икән. Шул язып җибәргән, әгәр Янтык халкы каршы килмәсә, колхозга персидәтел булып кайтыр идем үземнең элекке урынга, дигән. Халык риза. Кем риза булмасын инде, Булатов кына бу арада карасына орынып йөри. Өченчекөн кантурга баргач, исәнме, Булатов абый, дигән идем, әйләнеп тә карамады. Хәзер аның көне кыскарды, тиздән тибеп төшерәбез без аны урыныннан, көн-төн эчә. Беркөнне Инсаф кереп чыкты, ул беркая да китмәде. Калхузда калам инде, ди, аларның хатыны белән эшләре хөрти, аерылышыргарак йөриләр. Әнкәй сиңа җылы оек бәйлим, ди, киткән чакта оныткан мын, ди. Мәрдәнша агай сине гел телгә ала, хат язганда, миннән сәлам әйт, ди. Нәсим дә, Гөлсем дә».*

Хатны укыгач та, Сәгыйтьнең әллә ничек күңеле нечкәреп китте. Шул вакыт ул үзенең, үзе уйлаганча, бер дә ялгыз түгеллеген, бәхетсез түгеллеген, бәлки, еракта-гы туган авылы белән, аның кешеләре белән — туганнары белән генә түгел!— һәрбер кешесе белән бергә икәнле-

ген һәм алар өчен куаныч булган нәрсәнең үз күңеленә дә бик якын, аңлаешлы икәнлеген аңлады. Мәрдәншә агайларның, Нәсимнәрнең үзе белән кызыксынуларын, үзен онытмауларын белү аны дәртләндереп җибәрде. Көне буе ул үз күкрәгендә әлеге хат тудырган әйбәт бер җылылык тоеп йөрде.

Төштән соң, лекция беткәч, группаның комсомол җыелышы башланды.

Көн тәртибендә торган беренче, икенче мәсьәләләрне тикшереп бетергәч тә, Гасыйм аудиториягә бераз тынычсыз, җитди күз карашы ташлап алды һәм шундук Сәгыйтьне, Иданы эзләп тапты. Хәер, эзләп тә тормады — ул аларны инде баядан бирле күреп, күзәтеп утырды.

Сәгыйть тәрәзә янында, Степкалар, Хәмитләр беләнрәк. Бер карауда бик тыныч, бер карауда боек, хәсрәтле булып тоелган ап-ак йөзе тартылып, кысылып калган шикелле күренә. Хәрәкәтсез, җансыз күзләре тәрәзәгә төбәлгән. Ул аудиториядә түгел, ул — бөтен күңеле белән кайдадыр еракта, икенче дөньяда. Ида, гадәтенчә, артка, Муся янына утырган. Аның беркайчан җыелыш вакытында рәтләп тыңлаганы юк — көлешә, пышылдаша. Ләкин ул да бүген тынып, йомылып калган; күршесенә теләр-теләмәс кенә җавап бирә, көчәнеп кенә елмаеп куйган була. Күренеп тора, күңеле тырнала... Ярый, бик әйбәт, күңеле тырнала икән, димәк, уйлый дигән сүз, инде кеше уйлана икән — аның уйлануы һәрвакытта да начар нәрсә турында гына булмаска мөмкин. Әйе, аларның икесенең дә күңелләре тыныч түгел. Соң, аның үзенә рәхәтме әллә? Юк, аларның хәзер өчесенә дә бик кыен, аларның өчесе дә тыныч түгел, ләкин өчесе өч төрле тынычсызлана.

— Хәзер,— диде Гасыйм, эчке бер дулкынлану белән,— көн тәртибендә соңгы мәсьәлә — комсомолка Идея Мәхмүтованың персональ эше...

Әкрен искән җилгә шаулап торган урман кебек басынкы гына гөрелдәп утырган аудитория кинәт тынып калды. Колаклар үрә торды. Кайберәүләр Ида утырган якка, кайберәүләр Сәгыйть ягына борылып карадылар, кайберсенең йөзенә аптырау, гаҗәпләнү билгесе чыкты, кайсылары серле генә елмаеп куйды. Моңарчы комсомол эше буенча да, бүтән яктан да бернинди табы булмаган, җитмәсә, бер-берсенә шундый нык гашыйк парның бер сыңары Иданың «персональ эш»кә эләгүе күпләр ичен көтелмәгән нәрсә иде. Һәм бу әле быел беренче «персональ эш» иде.

Степка Сәгыйтькә карап алды да, гомуми тынлыктан файдаланып, хәйләкәр-җитди төс белән сорап куйды:

— Әллә сине рәнҗеттеме, Бикчурин?

Алар тирәсендәге студентлар тыелып кына көлешеп алдылар. «Андый рәнҗетүләр өчен, кызганычка каршы, персональ эштә тикшермиләр шул!» — диде Гасыйм күңеленнән, Степкага җавап биргән шикелле. Ул кыска гына итеп, бер-ике сүз белән, Иданың бүгенге җыелышта тикшереләчәк персональ эшенең нидән гыйбарәт икәнен сөйләп бирде. Аннан соң туп-туры Идага текәп карады да, бераз кискенрәк, яңгыравык тавыш белән:

— Иптәш Мәхмүтова!— диде.— Чыгыгыз монда, сөйләгез җыелыш алдында: ни өчен справка алып килмәдегез? Ни өчен үзегезгә төшкән комсомол бурычын үтәмәдегез?

Арткы рәтләрдә урындык кузгаткан тавыш ишетелде. Ида урыныннан кузгалды да, ачык-соргылт материядән тегелгән яңа, матур күлмәгенең мамык кыстырылган ясалма иңсәләрен төзәткәләп, өстәлләр арасыннан алга узды. Аның артыннан салмак кына күлмәк итәге тирбәлеп барды, кыйбатлы хушбуй исе таралып калды. Барысы да, тыннарын кысып, аның үзләре каршысына, Гасыйм өстәле янына җитеп туктаганын көтеп тордылар. Бернинди көлешү-пышылдашу ишетелмәде, бары тик аның киң үкчәле көзге туфлиләренең ялтырап торган тигез паркет идәнгә шак-шок басканы гына ишетелде.

Ул Гасыйм утырган өстәл янына килеп җитте дә комсоргтан бераз гына читкәрәк туктап калды, группага йөзе белән борылды, үзенең дулкынлануын, тынычсызлануын сиздермәскә, гадәтенчә, шаян, илтифатсыз булырга тырышып, бер дә юктан ireннәрен җәеп җибәрде. Ләкин аның битендәге алсулык шулай да каядыр качкан иде, ирен читләре, борын яфраклары шулай да сизелер-сизелмәс кенә дерелди, күз карашы, мәҗбүр ителгән кебек, үзеннән-үзе идәнгә төбәлә иде.

— Менә — мин, алдыгызда торам! Ни әйтерсез?— диде ул, һаман көлемсерәвен дәвам итеп.

Ләкин үзенә таба карап торган иптәшләренә бер күтәрелеп күз ташлаган иде, кинәт дерт итеп китте, йөзендәге ясалма, уңайсыз елмаю, ваемсыз булып күренергә тырышу билгесе кул белән алгандай юк булды. Ул бер генә кешенең күз карашында да үзенә карата теләктәшлек нуры, дәртләндерү билгесе күрмәде. Барысының да кыяфәте җитди, игътибарлы иде, беркем дә көләргә, шаярырга җыенмый, һәркемнең күзе җавап көтеп аңа төбәлгән, бары тик аңа гына төбәлгән иде. Тик Муся гына кашлары, бармаклары белән аңа нәрсәдер ымлый, нәрсәдер аңлатырга тырыша, ләкин аның ул кыланышы гына аңа ярдәм итәрлек түгел иде.

Ул күз кырые белән генә Сәгыйть ягына карап алды. Аның бөтен игътибары бөтенләй икенче нәрсәдә иде, ул чит, ул дошман иде. Монда утырганнарның барысы да чит, барысы да ят иде. Аның шушы җитди күз карашларыннан, шушы кырыс кешеләрдән качасы килде, тизрәк ишеккә ташланасы, алдын-артын карамыйча, каядыр йөгерәсе килде, берәр җиргә посып, яшеренеп елыйсы, барын да онытасы килде. Ул үзенең алар алдында ниндидер ярамаган эш эшләвен, алар алдында ни өчендер гаепле икәнен аңлады. Ләкин — нинди ярамаган эш, нинди гаеп эш эшләгәнен һич кенә дә башына китерә алмады. Ул, дөресен генә әйткәндә, ниндидер буалар буып йөрү, халык алдында ниндидер лекцияләр, докладлар сөйләү, дигән сүзләргә бөтенләй диярлек игътибар итмәде. Ул аларның төп мәгънәсенә төшенә алмады. Боларның барысы да аңа тик җыелышларда сөйләнелә торган формаль, буш, коры сүзләр генә булып яңгырады. Бүген иртән Гасыйм, комсомол җыелышында персональ эшең каралачак, дигәч тә, ул моңа көлеп кенә карады, тапкан куркытыр нәрсә, ничек тә койрык болгарбыз әле, дип уйлады.

Юк, чынында ул персональ эштән дә — бернәрсәдән дә курыкмады, аны Сәгыйтьнең кисәк кенә салкынаюы, аннан читләшүе һәм очрашкан чакларда бөтенләй күрмәмешкә салышып, исәнләшмичә дә китеп баруы үтерде. Ул моның сәбәбен дә сизенеп алды, кайгырды, борчылды. Ул аның гел Гасыйм белән бергә булуын, аннан бер адым да калмый ияреп йөрүен күрде. Ул, Гасыйм аңа теге автомашинада утырып барганда күргәннәрен сөйләгәндер, Сәгыйть бөтенесен дә белгәндер, шуңа күрә сөйләшмидер, шуңа күрә качадыр, дип уйлады. Ул аклану өчен төрле сәбәпләр эзләде, ничек тә аның белән очрашырга, аңлашырга теләде һәм аның белән күзгә-күз карап сөйләшсә, уңышка ирешәчәгенә әз генә дә шикләнмәде. Ләкин Сәгыйть хәзер бүлмәгә үзе килмәде, монда — аудиториядә очратып булмады, Гасыйм комачаулады.

Менә хәзер ул бөтен группа каршысында басып тора. Сәгыйть аңа борылып та карамый. Нинди таш йөрәк! Аның әле беркайчан да бу кадәр күп кеше алдында шундый гаепле йөз белән басып торганы юк иде. Аның гайрәте, кыюлыгы һаман шиңә төште, әле бер як бите, әле икенче як бите йә кызарды, йә агарды, тамак төбенә сусыз борчак боткасы кебек ниндидер коры төер килеп тыгылды. Ул үзен тагын шундый бәләкәй, шундый көчсез, бәхетсез итеп сизде.

— Кайгырма, без әйтербез!— диде Гасыйм, аның боргаланырга тырышуын күреп, кискен генә.— Хәзер сезгә сүз бирелгән — сөйләгез!

Үзенә куркыныч килгәндә ул керпе кебек энәләрен кабартырга гадәтләнгән иде. Гасыймның кискен тавышы аңа тагын, Сәгыйть белән быел күз беренче очрашу вакытындагы кебек, үз-үзен кулга алырга ярдәм итте. Ул тиз генә Гасыймга борылып карады.

— Нәрсә сөйләргә?— диде ул, сүзнең ни турыда барганын аңламаган сыман. Аннан соң коры гына итеп: — Мин сезгә әйттем, иптәш комсорг, справка алып килмәдем. Андый формальность өчен үземне гаепле саный алмыйм,— диде.

— Сез миңа сөйләмәгез — группага сөйләгез!

Арттан Муся тавышы ишетелде:

— Чынлап та! Ни гаебе бар аның? Подумаешь, справка алып килмәгән! Стипендиядән төшермәсләр әле. Взнос түләмәсә йә анда комсомол билетын югалтса...

Үзен яклау тавышын ишетеп, Ида аягына ныграк басты, башын югарырак күтәрде, аңа яңадан элекке кыюлыгы кайтты. Ләкин Мусяның сүзләре бүтәннәрнең хәзер Идага карата булган кире тойгыларын гына көчәйтә төште. Шундук Степка торып кычкырды:

— Справка алып килмәгән — факт! Нигә ул группа карарына формальность дип карый?

Аңа тагын бүтәннәр кушылды:

— Комсомол билеты югалту гына гаеп түгел.

— Җитәр сиңа, Муся, яклашма юкка!

— Дәвам ит, Гасыйм!

Тавыш басыла төшкәч, Гасыйм урыныннан торды да карандаш белән өстәлгә шакылдатып алды.

— Менә нәрсә: без монда Мәхмүтованың персональ эшен тикшерергә мөмкинме, юкмы, дигән мәсьәләне карамыйбыз. Карарны кабул иткәнбез икән, ул безнең өчен формальность түгел! Безнең группаның карары — безнең һәрберебез үтәргә мәҗбүр булган документ ул!.. Әгәр сез, иптәш Мәхмүтова, аңа бары формальность кына дип карыйсыз икән — моның белән сез үзегезнең аңсызлыгыгызны гына яисә комсомол бурычын үтәүгә төкереп каравыгызны гына күрсәтәсез. Ни өчен һәркем үзенең эше турында справка алып килгән дә, ни өчен бары сез генә үзегезне әллә кем итеп санийсыз? Җавап бирегез! Боргаланып торуның барыбер файдасы тимәс.

Ида тагын аудиториягә күз төшереп алды, үзен тагын уңайсыз сизә башлады. Шул вакыт ул үз иптәшләренең, коллективның бердәм ихтыярын, берни белән дә

җиңеп булмастай көчен, ныклыгын тойды. Һәм теләсәң дә, теләмәсәң дә, шушы көчкә буйсынырга кирәк иде. Аның бу газапны тизрәк бетерәсе, тәэсирле, ышандырырлык итеп гафу үтенәсе, «чын комсомол сүзе» биреп, тизрәк үз урынына барып утырасы килде.

— Мәхмүтова үзенең җәй көне нишләгәнен белмәсә, Бикчуриннан сорарга кирәк. Ул белми калмас!— дип сүз кыстырып куйды Степка.

Кызлар көлешеп алдылар, Сәгыйть Степка тавышын ишетеп сискәнеп китте, ләкин аңа борылып та карамады — таштан коеп куйган сын шикелле һаман шул көе тәрәзәгә, тышка — каядыр еракка карап утыруында булды.

Түземсез, киеренке тынлык озакка сузыла башлаган шикелле булды. Кинәт Иданың зиһене яктырып китте. Ул үзен агитбригадада катнашырга чакырып килгән теге райком кызын, Сәгыйтьнең «Комсомольская правда»га басылган мәкалә турындагы сүзләрен исенә төшерде. Ул шундук кискен бер карарга килде һәм гаепле, әмма шулай да акланыр өчен күңелендә ниндидер дәлиле булган кеше тоны белән сөйләргә керешге.

— Дөрес, иптәшләр...— диде ул, көрсенеп.— Мин справка алып килмәдем. Үземнең гаепне таныйм. Үз бурычыма мин, иптәшләр, җиңел караганмын... Миңа каты җәза бирсәң дә әз... Мин...

Аңа яңадан сөйләү куәте кайтты. Үз күңеленнән чыкмаган нәрсә турында ул һәрвакыт матур итеп, шома итеп сөйли ала иде. Ул, үз-үзен тәнкыйтьләп, бер чиктән икенче чиккә ташланды, үзенә карата кискен сүзләр куллanudан да курыкмады. Киеренке атмосфера бераз бушый, йомшый төште. Кайберәүләрнең, аңа теләктәшлек белдереп, ачусыз гына:

— Күптән шулай кирәк аны!

— Монсы инде икенче нәрсә!— дигән сүзләре ишетелде.

Идага аның саен көч, дәрт керде. Үз-үзен котылганга, җиңгәнгә санап ул торган саен кыюланып дәвам итте.

— ...Ләкин,— диде ул, кисәк кенә тавышын үзгәртеп,— бу әле минем авылга кайткач халык алдында бер нәрсә дә эшләмәвем турында сөйләми... минем тик ятуым турында сөйләми! Мин агитбригадада катнаштым, концертларда катнаштым, иптәш комсорг!— Ул тантаналы йөз белән Гасыймга карап алды.

Ул, теләсә кайчан ялганларга гадәтләнгән кешеләргә генә хас җиңеллек белән, ичмасам, әз генә дә кызармыйча, тартынмыйча, үзенең каникулга кайткач, урак вакытында район студентлары белән бергәләп авыл-

дан авылга йөрүе, халык алдында шигырьләр укуы, биюе, хәтта җырлавы һәм ике мәртәбә дин һәм фән турында лекция сөйләве турында шыттырырга тотынды.

Группа хәзер һаман аның ягына авыша башлады, «персональ эш»нең чыннан да бик үк нигезле түгел икәнлеге, монда әллә ни авыз күтәреп сөйләшеп утырырлык сүз юк икәнлеге ныграк ачыклана барды. Иданың сүзләренә ышанмаска беркемнең дә башына килмәде — ул шундый төпле итеп, үз-үзенә нык ышанып сөйләде. Ул бөтенләй күңелләләнеп китте. Бер дә юкка кыерсытылган бала шикелле, елмаю катыш үпкә белдергән караш белән иптәшләренә, Гасыймга күтәрелеп карады да, үзе ясаган тәэсирдән ләззәтләнеп:

— Пичәт сугылган, штамп басылган справка алып килмәсәң дә, үз бурычыңны үтәргә була, минемчә,— диде.— Иптәш Таҗетдинов әйтте: «Справка алып килдеңме?»— Мин әйттем: «Юк!»

Муся барысына да ишетелерлек итеп пырхылдап көлеп җибәрде:

— Подумаешь, бик зур нәрсә!

Гасыйм үзенә нишләптер бик кызу була башлаганын тойды. «Чынлап та, тапкан бернәрсә: справка да справка!»— диде ул, үз-үзенә ачуланып. Менә ничек бәйләнә! И бик оста бәйләнә! Бәлки, ул чынлап та ялганламыйдыр? «Комсомольская правда»га язганнар иде бит аларның район студентлары турында. Дөрес, анда Иданың фамилиясе телгә алынмаган иде, ләкин һәркемнең фамилиясен язу мәҗбүри дә түгел андый кыска мәкалә өчен. Менә сиңа кирәк булса! Хәзер бөтен группаны үз ягына аударды, инде «справка» дип авызыңны ачсаң, көлке генә килеп чыкмасмы? Нинди формалист, нинди канцелярист булдың, димәсләрме?.. Шелтә-фәлән биреп кара син аңа хәзер, гаебен исбат итеп кара син аның хәзер!.. Юк, шулай да койрык болгый, валлаһи, койрык болгый бу! Беренчедән, агитбригадада чынлап та катнашкан булса, справка алып килергә кирәклеге турында да онытмас иде; икенчедән, ни өчен бу турыда ул башта ук әйтмәде? Нигә җырлаулары, биюләре хәзер генә исенә төште? Бу турыда ул, мәсьәләне катлауландырып тормас өчен, менә шулай бөтенесе алдында оятка калмас өчен, группа алдында кызарынып басып тормас өчен алдан ук әйтергә тиеш иде ләбаса! Шулай да ботка килеп чыкты бу, ботка, иптәш комсорг!..

Ида үзенең эшен беткәнгә санады, иптәшләрендә үзе әйткәннәргә бернинди шик калмасын өчен, тыныч, ләкин шулай да Гасыймнан мыскыллап көлү сиздереп торган тавыш белән:

— Ышанмыйсыз икән, иптәш Таҗетдинов, «Комсомольская правда»ны алып карарга була,— диде.— Анда безнең агитбригада турында язылган...— Ул хәтта газетаның номерын да әйтте.

Мәсьәлә хәл ителде. Ул теләгенә иреште. Аудитория, бушанып, җиңеләеп, әкрен генә гөрләшергә, шаулашырга тотынды. Гасыйм, Идадан да газетадагы мәкалә турында ишеткәч, нәрсә уйларга да белмичә, тәмам аптырап калды, күңелендә кинәт үз-үзенә карата шикләнү туды.

Ләкин шул вакыт бөтен аудиторияне яңгыратып кычкырган көчле тавыш яңгырап китте:

— Ялган!

Барысы да тавыш килгән якка, Сәгыйть ягына борылып карадылар. Кайберәүләр, үз колакларына үзләре ышанмыйча, аның әлеге сүзен яңадан кабатлавын көттеләр, кайберәүләр, булачак кызык тамашадан алдан ук ләззәт табып, елмаешып куйдылар; Ида күзен шундук идәнгә төшерде, йөзе кинәт коточкыч агарынып китте; Гасыймның күз карашында чиктән тыш гаҗәпләнү, кызыксыну билгесе күренде.

Сәгыйть үз-үзе белән бик озак көрәште. Ул Иданың персональ эше тикшерелгәндә бернигә дә катнашмаска, читтә калырга тырышты. Шулай да ул һәркемнең сүзен ишетеп, тыңлап утырды, Идага карата әйтелгән катыкаты сүзләр аның да йөрәгенә барып тиде. Ул әле һаман да «аныкы» иде һәм аның персональ эше кайсыдыр ягы белән аның үзенә дә, Сәгыйтькә дә кагыла иде. Ул, инде беркайчан да аңа әйләнеп тә карамаска дип, аның турында инде беркайчан да исенә дә кертеп чыгармаска дип, үз-үзенә мең мәртәбә антлар итсә дә, күңеленең иң тирән җирендә аны барыбер якын күрде, ниндидер акылсыз, ахмак бер өмет белән яшәде, нәрсәгәдер ышанды, нәрсәдер теләде. Аның Идага ташланган гаепләрнең бер өлешен үз өстенә аударасы килде. Мондый минутларда ул хәзер ике арада бернинди якынлык та, бернинди җылылык та калмавын, үзенең аның тарафыннан алданган булуын да һәм горур күңеленең моны беркайчан кичерә алмаячагын да — барысын да онытты, аның өчен дөнья тагын яктылык белән, ямь, матурлык белән тулды, һәм ул үзен яңадан бәхетле итеп сизә башлады.

Ләкин мондый онытылу озакка бармады. Ул Иданың сөйләү тонында, үз-үзен тотышында, күз карашында үзенә шундый нык таныш булган нәрсәне — аның ялганын тотып алды. Шундук аның күз алдына коточкыч хакыйкать килеп басты. Ул барысын да күз алдына китерде,

барысын да ачык күз белән, рәхимсез, шәфкатьсез күз белән күрә башлады. Аның бу күрәләтә ялганны, көлеп, елмаеп торган шәрә ялганны фаш итәсе, сытасы, шартлатасы килде. Әмма аның ялганын фаш итү, аны бөтенесе алдында фаш итү — бу инде ике араны бөтенләйгә, мәңгегә өзү дигән сүз булачак иде. Ул әле һаман моннан курка иде, аның әле һаман моңа кыюлыгы җитми иде. Әгәр бернәрсә дә әйтмәсәң, әгәр бернигә дә катышмыйча утырсаң, Ида ак-пакь булып калачак, аның өстенә тырнак карасы кадәр дә кер төшмәячәк һәм «эш» тә шуның белән бетәчәк иде. Ләкин, икенче яктан, аны яклап, берни әйтми калу, аның бөтен группаны, бөтен иптәшләреңне алдаганын, шундый оста итеп ялганлаганын әйтми калу — бу инде үз вөҗданыңа үзең хыянәт итү, үзең дә шул ук ялган юлына басу булыр иде, яхшылыкка лаек булмаган кешегә яхшылык күрсәтү һәм, алай гына да түгел, үз иптәшләреңне, үз группадашларыңны, җыелышны алдау булыр иде. Юк, мондый батырлыкка, мондый шәфкатькә, дөресрәге,— мондый түбәнлеккә бару өчен аның, күңеле никадәр генә каршылыклы булмасын, хәзер инде бернинди сәләте дә, бернинди көче дә, ихтыяры да юк иде.

Ул ут белән су арасында утырды, астына без кадалган кебек утырды, бер кузгалды, бер басылды, икеләнде, нишләргә дә белмәде. Иданың агитбригада турында шундый оятсыз рәвештә ялганлавын ишетеп ул, моңарчы үзендә беркайчан булмаган кыюлык белән, бөтен икелемикеле уйларын бер читкә сыпырып ташлады да урыныннан сикереп торды.

— Ялган!— диде ул тагын да һәм бернинди кызгану, бернинди шәфкать, өмет сиздермәгән күзләрен Идага төбәде.— Сезнең монда сөйләгән һәрбер сүзегез башыннан азагына кадәр ялган! Сезнең агитбригадада катнашуыгыз турындагы җырлавыгыз, биюегез турындагы сүзләр барысы да ялган! Сез җырладыгыз, биедегез — ләкин калхузчылар алдында түгел! Сезнең бөтен эчегез ялган белән тулган — мин хәзер моны бөтен күңелем белән аңладым. Моның шулай түгел икәнен миңа хәзер дөньяда беркем дә исбат итә алмас... Мин сезнең аннан да зуррак ялганнарыгызны беләм... Мин хәзер группа алдында, иптәшләр алдында сезнең ни өчен буа буарга бармавыгызны әйтеп бирергә тиешмен. Мин әйтмичә булдыралмыйм, миңа вөҗдан шулай куша, намусым шулай куша... Чөнки... сезнең шундый ялганнарыгызда... минем дә гаеп бар... мин дә гаепле...

Ул калтыранган куллары белән костюм кесәсеннән

таушалып беткән сыек зәңгәр төстәге конверт чыгарды. Конверт эченнән Иданың хатын алды да, аннан аның ни өчен эшкә бармавының сәбәбен аңлаткан сүзләрен бөтен аудитория ишетерлек итеп кычкырып укып чыкты.

Ичмасам, тын алган тавыш та, кымшанган тавыш та ишетелмәде. Бөтенләй уйламаган, бөтенләй көтелмәгән ачыш иде бу, чиктән тыш гаҗәп ачыш иде бу. Сәгыйть, мондый нәрсәдән үзе дә тиз генә исенә килә алмаган кебек, беразга сүзсез калды. Шул чакны Иданың елак тавыш белән:

— Нечестно... Намуссыз!..— дигән сүзләре ишетелде.

Ул, кызарынган йөзен түбән иеп, тиз генә шундагы, алдагы бер урынга килеп утырды. Хәзер аңа беркем дә карамады, беркем дә игътибар итмәде, әйтерсең аның аудиториядә барлыгы-юклыгы турында да оныттылар.

Сәгыйть бер киң итеп сулыш алды да күтәрелеп Гасыйм ягына карап алды. Аларның күзләре бергә очрашты. «Менә монысы ярый!»— диде Гасыймның акыллы, нык карашлы күзләре. Сәгыйтьне бу дәртләндереп җибәрде.

— Кем намуслы, кем намуссыз — иптәшләр әйтерләр,— диде Сәгыйть, яңадан сүзгә башлап.— Дөрес, үзеңә язылган хатны бүтәннәр алдында, җитмәсә, шушы кадәр кеше алдында уку бик үк яхшы нәрсә түгел... Ләкин сез хәзер минем дөресен сөйләгәнемне, иптәш Мәхмүтовага ялган гаеп ташламаганымны күрәсез. Мин моны сезгә әйтергә тиеш... Тагын... бетмәде әле. Мин сезнең турыда барысын да әйтергә тиешмен... Чөнки сезне мин бүтәннәргә караганда яхшырак беләм, чөнки сез... безнең группа кешесе... Мин әйтмичә булдыралмыйм... Иптәшләр... сез дә минем кебек яшь кешеләр... җегетләр, кызлар, намуслы, турылыклы кешеләр — аңларсыз... мин әйткәннәрне аңларсыз...

Аның тавышы карлыкты, бик көчсез булып, хәтта пышылдавык булып ишетелде.

— ...Мин иптәш Мәхмүтованы яраттым... Сез моны беләсез... Яшь җегет белән яшь кызның бер-берсен яратуы бер дә гаҗәп нәрсә түгел. Моның бернинди яшерер нәрсәсе юк... Ләкин мин ялгышканмын, аның белән дуслашып ялгышканмын. Менә нәрсә турында әйтәсем килде минем! Иптәш Мәхмүтова чын дуслыкка да, чын мәхәббәткә дә лаек түгел... Менә нәрсә әйтәсем килде минем... Аның өчен чын дуслык та, чын мәхәббәт тә берни түгел... Менә монда безнең алга чыгып ул комедия күрсәтеп торды... Комедия!.. Үз хатагызны танырга сезгә

кыюлык кына түгел, теләк тә җитмәде. Мин боларны иптәш Мәхмүтовадан үч алу өчен дә, аны сезнең алда мәсхәрәләү, кимсетү өчен дә әйтмим. Мин боларны дөреслекне сөйлисем килгән өчен әйтәм... Сезнең турыда мин хәзер барысын да беләм... Сез миңа, юк — безнең мәхәббәткә хыянәт иткәнсез, ул гына да түгел — сез үзегез дә алдангансыз... Монда килгәч сез, берни әйтмичә... берни булмаган кебек, яңадан миңа сырпалана башладыгыз. Менә ул кайда намуссызлык!..

Ул утырды. Аның сүзләрен ишетеп хәйран калган, гаҗәпләнгән аудитория җансыз-тынсыз торды. Беркем бер урыныннан кузгалмады, беркем бер авызын ачмады. Хәтта Степка да, исе китеп, күзлекләрен ялтыратып, әле Сәгыйтькә, әле Идага карап-карап алды. Тагын Мусяның гына бәйләнчек тавышы ишетелде:

— Комсомол җыелышымы бу — нәрсә бу? Кешенең алданган мәхәббәтендә безнең ни эшебез бар?!

Гасыйм шундук башын күтәрде.

— Юк — бар!— диде ул Мусяга җавап биргән кебек, ләкин бөтен аудиториягә карап, нык, кискен тавыш белән.— Иптәшебезнең алданган мәхәббәтендә дә, чын мәхәббәт дигән бөек, изге хисне пычратучы вак җанлы кешеләрдә дә безнең эшебез бар! Мин иптәш Бикчуринның бер генә сүзенә дә шикләнмим. Алай гына да түгел — ул сөйләгәннәргә өстәп, Мәхмүтова турында тагын күп кенә нәрсә әйтә алам. Ләкин мәсьәлә бер Бикчурин белән бер Мәхмүтовада гына түгел, иптәшләр. Мәсьәлә безнең бөтенебездә дә, иптәшләр, мәсьәлә хәзер тирәнәя, киңәя төште, иптәшләр! Сүз хәзер бер справка турында гына, бер алданган мәхәббәт турында гына бармый. Сүз безнең, совет яшьләренең, совет студентларының, хезмәткә, мәхәббәткә карашыбыз турында, үз-үзебезне тотышыбыз турында, дуслык-иптәшлек турында бара! Сүз, иптәшләр, коммунистик мораль турында, әйе, коммунистик мораль, чын мораль, чын әхлак турында бара!— Тәэсирләнгән, дулкынланган Гасыйм үз алдындагы егетләргә, кызларга игътибарлы, сынаулы күз карашы йөртеп чыкты, һәркемгә мөрәҗәгать итеп: — Кем сүз алырга тели, иптәшләр?— диде.

*1952—1954*
*Казан—Чистай—Казан*

# МӨДИР САҖИДӘ

*Повесть*

## Беренче бүлек

### I

31 июль көне, гомергә онытылмаслык булып, минем хәтеремдә калды. Ул көнне мин иртәрәк тордым. Тиз-тиз генә ашадым-эчтем дә көзгегә карандым. Көзге белән эшемне бетергәч, китап-дәфтәр арасыннан дипломымны алдым. Ике битлек катыргы кисәген кул очына тоттым да урамга чыгып киттем.

Райздравка барып кергәндә, мин бөтенләй дулкынланмадым. Райздрав мөдире әле килмәгән иде. Секретарь миңа утырырга, көтеп торырга кушты. Утырдым да көтә башладым. Көткән арада, секретарь хатынның ничек итеп машинкада басуына, көдрәләтелгән кыска чәченең селкенеп-селкенеп куюына карап тордым.

Шулай утыра торгач, бүлмәгә кыюсыз гына атлап бер кыз килеп керде. «Бу да минем кебек техникум бетергән кешедер инде»,— дип уйлап алдым. Кыз исәнләште: исәнмесез, диде. Секретарь да исәнмесез, диде. Мин эндәшмәдем, эре генә утыра бирдем. Мин кызның өс-башына игътибар иттем. Әллә ни түгел. Ярым авылча, ярым шәһәрчә. Техникум бетергән кеше нинди булыр дисең инде... Нәрсә ул техникум бетергән кеше? Надан дисәң, надан түгел, белемле дисәң, белемле түгел. Институт белән мәктәп арасында буталып калган. Урта кул. Мин, билгеле, үземне әйтмим. Мин — башка. Мин... Ярар инде, калып торсын.

Беркадәр вакыттан соң, тагын бер кыз килеп керде. Аннары бер кыз белән бер егет керде, ике кыз керде. Бүлмәдә утырыр урын да калмады. Чыш-пыш сөйләшкән, тыелып кына көлешкән тавышлар ишетелә башлады.

Мин берсе белән дә сөйләшмәдем. Үзләрен тиешенчә тота белмәгәннәре өчен, кызларга эчтән генә ачуланып та куйдым. Теләсә кем алдында, теләсә кайда ихахай да михахай килеп йөрсәң, булырсың фельдшер! Безгә бит

укыганда юкка гына әйтмәделәр, фельдшер кеше кайда да үз-үзен тота белергә тиеш, дип...

Менә бервакыт тышкы ишек ачылып китте. Бүлмәгә җилләнеп, ашыгып бер агай килеп керде. Агай да түгел, абый. Япь-яшь. Үзе чибәр, озын буйлы, зур кара күзле, куе кара чәчле. Кулына сары күн портфель тоткан. Өстендә вак шакмаклы җәйге пинжәк. Ап-ак, чип-чиста күлмәк. Чалбары тар балаклы, яшькелт-зәңгәр төстә.

Ялт итеп торган бу чибәр кеше безнең белән елмаеп исәнләште дә түргә узды. Мин шундук аның райздрав мөдире икәнлеген аңлап алдым. Мөдирне мин бик җитди кыяфәтле, күзлекле, бөкрәйгән карт кеше итеп күз алдына китергән идем. Хәзер мин чак-чак кына каушап калгандай булдым. Күңелемнән, аптырап: «Шундый япь-яшь начальниклар да була икән дөньяда!»— дип уйлап алдым.

Соломон Моисеевич, ягъни әлеге райздрав мөдире, портфелен шап итеп өстәлгә ташлады, ак эшләпәсен, пинжәген чөйгә элеп куйды, елкылдап торган чәчләрен тарады да күтәрелеп безгә карады.

— Сөйләгез, коллегалар, мин тыңлыйм,— диде.

Шулай дигәндә үзе ап-ак тешләрен күрсәтеп елмайды, никтер өстәл тартмасын ачып җибәрде. Без аңа үзебезнең йомышны әйтеп бирдек, менә без — яшь белгечләр, медицина техникумы бетергән кешеләр, сезнең карамакка килдек, дидек. Кая булса да эшкә билгеләвегезне телибез, дидек. Без дигәч тә, мин түгел. Мин берни эндәшмәдем, сихерләнгән кебек Соломон Моисеевичның күзләренә карап тик утырдым.

Соломон Моисеевич безнең һәрберебезне сораштырып чыкты, кайдан килдегез, кайда укыдыгыз, диде. Аннары безнең дипломнар белән танышты. Украинадан килгән берике кешене исәпләмәгәндә, без барыбыз да Башкортстанныкылар булып чыктык. Ләкин мин аларның берсен дә белмим. Мин алар белән укымадым. Мин Уфада укыдым. Алар Бөредә, Стәрлетамакта, тагын шуның ише вак-төяк шәһәрләрдә укыштырганнар. Шул турыда белгәч, мин үземне тагын да эрерәк, дәрәҗәлерәк тотарга тырыштым. Бигрәк тә, Украинадан килгәннәр генә бераз шиккә төшергән иде. Мин аларны Киевтандыр дип уйлаган идем. Түгел икән. Нindидер Винницаданмы, Конницаданмы. Минем андый Конница-Винницаларны ишеткәнем дә юк.

## II

Беренче танышудан соң, эш урыны билгеләү башланды. Миннән соң килгән кыюсыз гына кыз үзләренең

туган авылында калдыруны сорады. Украинадан килгәннәр берәр культуралырак, зуррак авылга китәргә теләделәр. Егет белән кыз исә икесен дә бер пунктка җибәрүне үтенделәр.

Соломон Моисеевич елмаеп кына тыңлап утырды да, шулай бит, болай бит, дип, үз фикерен аңлатырга тотынды. Кызлар шаулаштылар, урыннарыннан кузгалыштылар, өстәл янына җыелдылар. Барысы да өстәл янына баргач, миңа утырган җирдән Соломон Моисеевич күренми башлады. Шулай да мин урынымнан кузгалмадым, кулларымны тез өстенә салып, башымны югары тотып, әдәпле генә утырып тордым.

Бер заман Соломон Моисеевич миңа төбәп карады да:

— Ә син, сылукай, кайсы авылга китәргә телисең?— диде.

Кисәк кенә бирелгән сораудан мин каушап калдым. Сораудан да түгел, ахрысы. «Сылукай» сүзеннән. Шундый матур, ягымлы күз карашыннан... Йөземә кызыллык йөгерде, башым түбән иелде. Утырам берни эндәшмичә. Үзем Соломон Моисеевичның соравын аңларга тырышам, үземнең никтер йөрәк суга. Шулай да бераздан исемне җыйдым да, җитди булырга тырышып:

— Мине район больницасында гына калдырырга мөмкин булмасмы?— дидем.

— Ник? Авылга китәсегез килмимени?— диде Соломон Моисеевич.

— Килми шул,— дидем мин.

Бүлмәдәге шау-шу тынып калды. Барысы да минем якка борылдылар, барысы да кызыксынып карап торалар. Мин тагын да ныграк кызарындым.

— Әти-әниләр...— дидем, нәрсәдер ялганларга чамалап.

— Нәрсә, картлармыни? Сездән башка торалмыйлармыни?— диде Соломон Моисеевич.

— Юк та соң...

— Шулай булгач?

Ул тагын миңа төбәп, сынап карады. Минем үзеннән-үзе телем чишелеп китте. Көндәлдәге яшерен серләрне ачарга ярамаганлыгын белсәм дә, барысын да сөйләдем дә бирдем.

Авылга киту-китмәү мәсьәләсендә минем үз исәбем бар. Исәпнең хисабы шул: мин — Яңавыл кешесе. Яңавылда безнең үз йортыбыз бар, әти-әни, эне-сеңел бар. Яңавыл минем өчен теләсә нинди «культуралы» авыллардан артыграк. Яңавыл ул минем башкалам, минем республикам. Якында гына Бүә суы. Көн дә мин Бүәгә су

керергә барам. Аннары... бигрәк тә шул: Яңавылда мин кичке мәктәпкә йөри алачакмын. Унынчы класска. Кабатлау өчен. Институтка керү өчен. Шулай булгач, нишләп әле мин авылга китеп мүкләнергә тиеш?

Райздрав мөдиренә мин шулайрак дидем. Бары тик авылда мүкләнәсем килмәгәнне генә әйтмәдем дә көн саен Бүәгә су керергә барырга кирәклеген генә әйтмәдем. Алары үземә дә нигезсез булып тоелды. Кичке мәктәпкә йөрү, институтка әзерләнү — болары инде, уйлавымча, теләсә кемне ышандырырга тиеш.

Ләкин Соломон Моисеевич ышанмады. Ышануын, бәлки, ышангандыр да — тыңламады.

— Юк, кадерлем,— диде.

«Кадерлем» сүзен ишетеп, мин тагын тынычсызланып куйдым. Тагын бер дә юктан башымны түбән идем.

— Беренчедән, район больницасында буш урын юк,— диде райздрав мөдире, миннән күзен алмыйча.— Икенчедән, авылда кадрлар җитми. Мин сезне иң артта калган авылга җибәрәм, медицина ярдәменә иң мохтаҗ пунктка... Барып төшәрсез, җиң сызганып эшкә тотынырсыз, бөтенесен юлга салырсыз. Килештекме?

— Ә уку?— дидем мин, әле һаман бирешергә теләмичә.

— Уку? Бик укыйсыгыз киләмени?— диде Соломон Моисеевич, көлемсерәп.

— Килә шул!— дидем мин.

— Менә нәрсә, сылукай,— диде Соломон Моисеевич,— мин сезне күчерермен район больницасына. Тик хәзер түгел. Соңыннан. Җай чыккач. Килештекме?

— Килештек!— дидем мин, елмаеп.

## III

Мине Яңавыл районының Мәсәгут дигән авылына билгеләделәр. Кулыма приказ тоттырдылар да хәерле юл теләп озатып калдылар.

Мин юл буена Соломон Моисеевич турында уйлап кайттым. «Әллә гашыйк булдым инде?»— дидем үземә-үзем. Шулай дип уйлагач, миңа бик-бик рәхәт булып китте. Кичтән йокларга яткач та бары шул турыда гына уйладым.

Мәхәббәт уйлары белән булашып, йокыга бик соң киткәнмен. Иртән әни көчкә уятты. Тордым да сәгатькә күз төшереп алдым. Мәсәгут ягына йөрүче автобус китәргә ярты сәгать чамасы вакыт калган. Ашык-пошык юындым, тышка чыгып кердем, көзге янына килдем.

— Нәрсә кадалдың тагын шул көзгеңә? Тиз бул!— дип кычкырды әни.

Кичтән тутырып куйган кечкенә чемодан белән студентлар сумкасын кул очына гына элдердем дә ишеккә юнәлдем.

— Ярый, хушыгыз,— дидем.

— Нинди хушыгыз ул?— диде әни.— Сау бул, диген. Әллә кая китмисең. Кайтырсың әле, машина йөреп тора.

Шулай сөйләнгәләп, ул мине озата чыкты. Мин җәяүләп автовокзалга киттем. Үземчә, бик кызу бардым. Барып җиткәнче тирләп төштем. Шулай да соңга калганмын. «Ашыгуым әрәмгә китте»,— дип уйладым, үкенеп.

Аптырап тордым-тордым да Мәсәгут ягына бара торган таш юлга чыктым, Җобанай күпер төбенә туктадым да көтә башладым. Әледән-әле машиналар, атлар узып китә. Күбесе мин барасы яктан киләләр. Мәсәгут ягына да киткәләделәр. Буш кабиналы машина килгәнен күрдемме, шундук кулымны күтәрәм. Тик нишләптер беркем дә туктамый.

Бер сәгать чамасы көттем. Эч поша башлады. Менә борылмадан Ходайбирдин урамыннан бер машина килеп чыкты. Күпер турысына җитте дә минем каршыда туктап калды.

— Кая барасың?— диде шофер.

— Мәсәгуткә,— дидем мин.

— Әйдә, Ямадыга кадәр утыр. Аннан Мәсәгуткә күп калмый.

Минем моңа бик үк утырасы да килмәде. Беренчедән, кабинасы буш түгел, аннары кузовының да рәте юк — кырыйлары аркылы-торкылы сугылган такталар белән киртәләп алынган. Киртә эчендә ике-өч агай күренә. Шунда ук бер ала сыер басып тора.

Берни эшләр хәл юк. Чемодан белән сумканы кузовтагы бер агайга суздым да, тәгәрмәчкә басып, әйберләр артыннан үрмәләдем. Агайлар миңа игътибар итмәделәр, кычкырып сөйләшүләрендә булдылар. Ала сыер гына миңа моңсу күзләрен тутырып карады да тыйнак кына мөгрәп куйды.

Машина кузгалып китте. Мин, такта киртәгә тотынып, тирә-якны күзәтә башладым. Кая карама — дулкын-дулкын басулар, калкулыклар, түбәнлекләр. Калкулык араларында авыллар күренгәли. Анда — биек тупыллар, тирәкләр, ак такта түбәләр өелешеп утырган җирләрдә — бик күңелледер, рәхәттер кебек. Еракта, күк читендә, болыт кисәкләре кабарып тора. Басулар өстендә елкылдап

рәшә тирбәлә. Күңел шул болытлар ягына, зәңгәрсу калкулыклар арасында кысылып утырган сихри авыллар, сирәк-мирәк әрәмәләр ягына омтыла. Тирә-якта шундый иркенлек, кояш. Каршыга салкынча җил исә. Шундый күңелле, шундый рәхәт!

Ямады авылына барып җиткәнче, минем күңел шулай бик күтәренке булды. Утыз чакрым араны ничек үткәнебезне дә сизмәдем.

Машина кибет каршында туктап калды. Мин җиргә төштем, рәхмәт әйттем. Әйберләрне кибет баскычына куйдым да өс-башны каккалап алдым.

— Менә шушы юл бара инде Мәсәгуткә, сеңлекәш,— диде шофер, каядыр авыл артына күрсәтеп.— Китә торсаң да ярый, берәр нәрсә туры килер әле шунда.

Машина кузгалды. Миңа карап сыер тагын мөгрәп куйды. Кибет алдында мин берүзем торып калдым. Кинәт кенә моңсу булып китте. Як-ягыма каранып алдым. Менә ул авыл. «Культуралы» зур авыл! Нишләргә хәзер — җәяүләп китәргәме, әллә «берәр нәрсә» көтеп торыргамы?

## IV

Шулай тора торгач, мин кибеткә кереп чыкмакчы булдым. Кергәндә, кинәт, үземнең фельдшер кеше, мөдир кеше икәнлегемне исемә төшердем — юлда килгәндә, ул турыда онытып җибәргәнмен. Башны югары күтәрдем, эре генә түргәрәк уздым, киштәләрдәге товарларны күздән кичердем. Карасам, үлчәү янындагы киң тактада кып-кызыл кура җиләк өелеп тора. Сатучыдан ярты кило җиләк үлчәттем дә баскычка чыктым. Торам шулай җиләк ашый-ашый. Яннан гына бер бабай китеп бара.

— Бабай, Мәсәгуткә ничә чакрым?— дидем.

Бабай туктады, башындагы түбәтәен арткарак чөеп:

— Җәяү барсаң — биш чакрым, ат белән барсаң — өч чакрым, машинага утырып барсаң — бер чакрым да булмас,— диде.

Мин көлеп куйдым. Бабай белән сөйләшеп торган арада, кибет янына җигүле бер ат килеп туктады. Арбадан яшьрәк кенә бер егет төште, аксаклап аты янына килде, дилбегәсен тәртә башына чалып куйды да баскычка менде.

— Исәнме, апасы?— диде бу кинәт.

Мин җавап бирмәдем. Теләсә нинди авыл малае белән сөйләнеп тормассың бит монда!

— Җиләк тәмлеме, юанкай?— диде бу тагын, авызын ерып.

Юанлык минем иң нечкә җирем. Кем дә кем миңа юан дип, симез дип әйттеме, шартлар дәрәҗәгә җитәм инде. Аксак егетне күрмәмешкә салынып, аңа бөтенләй артым белән борылдым.

— Ачуланма-а!— диде бу, юаткан сыман.— Кая барасың?

— Сезнең өчен барыбер түгелмени?— дидем мин.

— Барыберен барыбер дә, минем ат бар бит!— диде бу, минем әйберләрне караштырып.— Мужыт, юллар бер яккадыр.

— Мужыт, түгелдер,— дидем мин, үчекләшеп.

— Шулай да, кая барасың?

— Мәсәгуткә.

— Мәсәгуткә?! Булды алайса! Хәзер папирос кына алып чыгам да...

Аксаклап, ул тиз генә кибеткә кереп чыкты. Аты янына барышлый миңа карап елмаеп алды: «Әйдә, утыр, алып кайтам Мәсәгуткә»— диде.

Мин алай эчкерле түгел. Утыр дигәч, шундук йомшарып киттем. Әйберләрне алдым да җиргә төштем. Егет арбаның бер ягыннан миңа урын әзерләде, чемоданны алга җайлап куйды да, үзе икенче якка аякларын салындырып утырды.

Без кузгалып киттек. Таш юлда тәгәрмәчләр дыңгырдый. Арба артына бәйләнми салынган буш мичкә сикергәли. Койрыгын күтәреп, бөтен гәүдәсе белән селкенеп, лыс-лыс ат чаба. Ат селкенгән җайга, тәртә башындагы дуга селкенә, тимер аеллар чылтырый.

Минем инде күптән, бик күптән атка утырганым юк. Кайчаннан бирле икәнен дә белмим. Арбада утырып бару миңа искиткеч рәхәт. Никтер көләсе килә. Шулай да көлмәскә тырышам. Бөтен гәүдәм белән селкенгәләп, йомшак печән өстендә тик барам.

— Мәсәгуткә кемнәргә барасың?— дип кычкыра егет, сүз башлап.

Сөйләшкән сүз ныграк ишетелсен өчен, ул дилбегәне тарта төшә.

— Беркемгә дә түгел,— димен мин.

— Кунаккамыни?— ди егет.

— Юк, кунакка да түгел,— димен.— Эшкә барам. Эшләргә.

Шулай дип әйткәндә, күкрәгем шатлык, горурлык хисе белән тула. Мин үсеп киткәндәй булам. Авыз ерылып китә. Эшкә! Нинди зур сүз, мәгънәле сүз! Эшләргә... барлык кешеләр кебек эшләргә... үз көнеңне үзең күргә...

— Укытучымыни?— ди егет.

Бу сүзләрне ул миңа бик гаҗәпләнеп әйтә кебек.

— Түгел... фельдшер...— димен мин.

— О, врач икән!— ди егет, миңа карата ачыктан-ачык хөрмәт белән.

«Врач» сүзенә минем түбәм күккә тия. Без беразга тынып калабыз. Үземнең «врач» икәнлегемне белдергәч, минем хәзер ныклап торып сөйләшәсем килә. Мин, каерылып, егетнең какча йөзенә, киң чандыр җилкәсенә карап алам.

— Аягың нишләде?— димен.

— Комбайнда эшләгәндә трактор астында калдым,— ди егет.

Шуннан соң тагын сүз бетә. Бу минутта минем аяк турында, авырулар турында бөтенләй сөйләшәсем килми. Мин егетнең үзенең сораштыруын телим. Минем күңелне аңлагандай, бераздан бу шаян гына сорап куя:

— Апасы, исемең ничек?— ди.

— Саҗидә,— димен мин.

— Мин — Равил,— ди егет.

Беркадәр баргач, тагын сорый бу:

— Безнең авылга ничә көнгә барасың?— ди.

— Ничек инде ничә көнгә?— димен.— Эшкә барам димен ич. Медпунктка мөдир булып.

— Һи, безнең авылда врачлар озак яшәмиләр!— ди Равил.

— Ник?

— Белмим. Әллә авылның суы килешми. Мин белгәндә генә дә, инде ничә кеше алышынды! Шагапов абый эшләде — Яңавылга күчте. Вәзилә исемлесе барые — ире белән читкә китте. Юнысова Фәһимә дигән бер чибәркәй эшләде, анысы укырга китте. Зөбәйдә исемле бер башкорт кызы барые — анысы үзләре ягына кайтып китте. Әле күптән түгел Зина апа эшләде, Ермакова, ул да хәзер Яңавылда. Син кайсы якныкы соң?

— Яңавыл.

— Һи, әйттем бит! Күз җиткәнче таясың инде син бездән!

— Белмим...— димен мин.

Мин чыннан да ни әйтергә белмим. Күңелгә шом төште. Нишләп беркем дә тормый икән ул Мәсәгуттә? Бик алама авыл микәнни?

Равил атына бер кизәнеп алды да, минем барлыкны-юклыкны да онытып, кычкырып җырлап җибәрде.

Арба дыңгырдыгы, җыр тавышы миңа үткән бала вакытларны искә төшерде. Бәләкәй чакта, Эткенавылда

картәтәй мине, арбага утыртып, үзе белән көлтә ташырга алып барган иде. Биектә, көлтә төялгән йөк өстендә утырып бару рәхәт тә, куркыныч та. Минем аста — картәтәйнең бишмәте, тирә-ягымда — кылчыклы көлтәләр. Урылган арыш исе, камыл исе килә. Күктә тургай сайрый. Без басу юлыннан барабыз. Арба янтайгандай итteме, куркып, мин юан бастырыкка тотынам, чыркылдап кычкырып җибәрәм. Картәтәй уйламый да,— авыз эченнән әкрен генә көйләп тик бара.

Менә миңа хәзер дә бераз гына куркыныч та, күңелле дә. Әшли алырмынмы мин анда, әллә чынлап та, Равил әйтмешли, көз җиткәнче үк таярга туры килерме?

Берарада Равил җырыннан туктады да:

— Ничәнче елгы син?— диде.

— Утыз җиденче,— димен.

— Унтугызда алайса. Мин дә унтугызда.

— Шулаймыни?

— Шулайрак шул, апасы. Җегетең бармы?

— Ник кирәк ул сиңа?

— Яшел тышлы китапка язып куям,— дигән була Равил.

— Яза бир!— димен.

— Һо, безнең авылда җегетләр җитәрлек! Үзем берәрсе белән таныштырырмын әле.

— Мин егетләр эзләп бармыйм,— димен мин, кырт кисеп.— Мин — укырга китәсе кеше.

— Әйттем бит!— ди Равил, куанып.— Алайса, уку башланганчы гына эшлисең?

— Кем әйтте алай дип?

— Үзең.

— Мин алай димәдем. Миңа егетләр кирәкми генә дидем.

— Ха-ха-ха! Ансыз буламыни?!— ди Равил.— Унны бетергәнсең, техникум бетергәнсең. Нинди бетмәс уку инде ул?

— Ул гына аз. Мин институтка китәчәкмен,— димен мин.

— Ничә ел укыдың барысы?

— Унике.

— Мин менә җидене генә бетердем. Укып мулла булмассың дигәндәй...

— Дөрес түгел, Равил,— димен мин, белдекле генә.

— Һи, ник дөрес булмасын! Менә син унике ел укыгансың, мин — җиде... Икебез дә бер арбага утырып барабыз, бер үк юлдан. Ха-ха! На, малкай!

## V

Мин бәхәскә кереп тормадым. Авыл егетләренең шулайрак фикер йөрткәнлекләрен мин бик яхшы беләм. Шуңа күрә мин Равилнең сүзләренә бик үк гаҗәпләнмәдем дә. Тик менә шундый егетләр алдында каушап төшмәскә генә кирәк. Аларча фикер йөртә башласаң, бик тиз тәгәрәрсең мещанлык баткагына! Аннары инде егетләр белән йөри башларсың...

Юк инде, анысы булмас! Минем үз-үземә биргән сүзем бар: авылда мин егетләр белән йөрмәячәкмен! Мин — институтка китәсе кеше, мин югары белем аласы кеше. Төп максатың тормышка ашмый торып, нинди егетләр белән йөрү ди ул?! Минем әле барысы да алда, барысы да киләчәктә.

Мин шулай уйланып барганда, Равил кинәт кычкырып җибәрде:

— Менә болары безнең басулар инде!— диде.— Әнә, Фатыйма-тау астында безнең авыл.

— Бернәрсә күрмим,— дидем мин.

— Күрерсең әле! Ә ул басуларның начальнигы — мин!

— Кемнәрнең начальнигы?— димен, берни аңламыйча.

— Басуларның.

— Басуның начальнигы буламыни?

— Булмыйча! Мин — басу каравылчысы. Басудагы бөтен нәрсә миңа буйсына, ха-ха!

«Без икебез дә начальник икән»,— дип әйтмәкче булдым мин, шулай да тыелып калдым.

— Матурмы безнең яклар?— ди Равил.

— Матур,— дигән булдым мин.

Үзем исә бернинди матурлык күрмим. Бөтен җир шәпшәрә. Бернинди урман юк. Як-якта иген кырлары.

Фатыйма-тауның өстенә үк менеп җиткәч, чыннан да алда матур күренеш ачылды. Калкулык астында, уч төбендәге кебек булып, Мәсәгут авылы күренде. Тип-тигез ике урам. Урамнар яшеллеккә күмелгән. Авыл яныннан ук бормаланып елга ага. Авыл артында, елга буенда кечкенә әрәмәлек. Тагын да арырак, зәңгәрсу томан эчендә, ниндидер башка авыллар...

Таудан чаптырып төштек тә елга аша салынган күперне дөбер-шатыр чыгып киттек. «Олы урам» дип аталган урамга килеп кердек. Урамга килеп керүебез булды, Равил, тиле кебек, очраган бер кешегә:

— Менә яңа врач алып кайтам!— дип кычкырып бара башлады.

Мин моңа ачуланырга да, көләргә дә белмим. Ипләп

кенә: кычкырма алай, димен. Равил ишетми дә. Аннары ишетерлек тә түгел. Ат чаба, буш мичкә дыңгырдый, өрә-өрә арттан ниндидер эт йөгерә.

Бер заман Равил атын алты почмаклы яңа гына бер йорт алдына туктатты да:

— Менә килеп тә җиттек, апасы,— диде.— Шушы була инде безнең митпункт.

— Ярар, рәхмәт алып килүегезгә,— дидем мин.

— Кич клубка чык. Бүген үк!— диде Равил, кузгалып киткәндә.

Мин аңа җавап кайтарып тормадым.

Менә мин килеп җиттем. Шатланырга да, кайгырырга да белмим. Берни уйлый белмим. Арбадан шулай тиз генә төшкәнгә, шалтыравык Равил белән шулай тиз генә аерылышканга бераз моңсу да, авыр да кебек. Шул ук вакытта күңел нәрсәгәдер очына да шикелле.

Әкрен генә як-якка — урамга, йортларга күз йөртеп чыктым. Урам тигез, чиста. Яшел чирәм. Ятып ауныйсы килә. Каршыда гына, урамның икенче ягында, алты почмаклы зур йорт тора. Йортның бер почмагына «Марс» колхозы идарәсе» дип язылган такта беркетелгән. Колхоз идарәсеннән арырак, сулга таба, тыкрыкның икенче ягында, искерәк кенә клуб күренә. Клуб тирәсендә биек тупыллар үсеп утыра. Урамның пункт урнашкан ягында, бер йорт аша, тагын бер алты почмаклы йорт. Анысы авыл Советы булырга тиеш кебек.

Барысы да якын. Мәсәгутнең үзәгендә торачакмын икән. Һы.

Чемодан белән сумканың икесен ике кул очына элдердем дә капка ягына борылдым.

## VI

Ишегалга керү белән беренче булып күзгә ташланган нәрсә шул булды: ишек төбенә үк диярлек киселмәгән утын аударып ташлаганнар. Шунда юан гына бер агачта тәмәке көйрәтеп бер агай утыра. Уртача яшьләрдә. Озынча ябык битле, төскә ямьсез. Өстенә ак буй төшкән яшел штапель күлмәк кигән. Чалбары кара, таушалып беткән. Яланбаш. Аягында сандали.

Мин капкадан килеп кергәч тә, бу мине җентекләп күздән кичерде. Күзен дә алмыйча, минем үзе янына килеп җиткәнне көтеп тора башлады. Аның шулай текәп каравын сизгәнгә күрә, үземне бераз уңайсыз тоеп, әкрен генә ишек төбенә якынлаштым. Килеп җиттем, әйберләрне җиргә куйдым да, елмаерга тырышып:

— Исәнмесез,— дидем.

— Исән генә,— диде агай.

Шулай диде дә буылып ютәлләргә тотынды. Ютәлләп туктагач, яңадан тәмәкесен суыра башлады.

— Эчләрне актара инде, дошман,— диде.— Чистый теңкәне корытты.

— Салкын тидердегезмени?— дидем мин, кызганган булып.

— Күптән инде... тарта башладыммы, өзгәли генә...

— Ташлап булмыймыни?

— Булмый шул. Ташлыйсы да килми. Тартсаң, кайгылар басылып китә.

Минем сүз озайтып торасым килмәде. Шундый фикердәге кеше белән ничек сөйләшәсең? Файдалы дип уйлый икән, тарта бирсен! Тартуны гына түгел, эчүне дә файдалы дип уйлый, ахрысы, ул. Йөзе таушалган, күз төпләре күгәргән, бит очлары ямьсез булып кызарып тора...

Мин ишеккә карап алдым. Ишектә — йозак.

— Болар юклар икән,— дидем, үзалдыма сөйләнеп.

— Нәрсә, эшкәме?— диде агай, аз гына да гаҗәпләнү белдермичә.

— Әйе, эшкә,— дидем мин, елмаеп.

— Алай икән.

— Пункт мөдире итеп җибәрделәр,— дидем.— Әле генә Равил дигән егет китереп куйды... ат белән...

Бу турыда әйткәч, агайда миңа карата хөрмәт хисе уяныр дип көткән идем, ләкин минем мөдир булуыма аның әз генә дә исе китмәде. Ашыкмыйча гына тәмәкесен сүндерде дә чалбар балагындагы мамык кисәкләрен сыпыргалап төшерде.

— Һе, алай икән, алайса,— дигән булды.— Түлке, авылы начар шул, сеңнекәш. Авылыннан бигрәк, начальствосы яман.

— Сез шушы авылныкымы?— дидем мин.

— Юк, мин читтән килгән кеше. Укытучы мин.

— Укытучы?— дидем мин, исем китеп.

Шундый кыяфәттәге укытучы була алуына минем никтер ышанасым килмәде.

— Бу авылда өч ел эшләдем инде,— диде агай.— Менә быел эшләмәячәкмен. Кампликтавание вакытында исемлектән төшереп калдырганнар.

— Ни өчен?

— Мин дөреслекне сүләргә яратам — шуның өчен,— диде агай, үртәлеп.— Дөресен сүләгән кешегә монда тынгы юк. Ялагайлансаң, ярарга тырышсаң, майда йөзәсең.

Мин андай түгел. Директор белән тыныша алмадык. Булмады. Турысын әйткән — туганына ярамаган. Шулай. Авыр булыр сиңа монда. Кырыкка бөгәрләр. Кәтлит ясарлар.

— Мин бит мәктәп директорына буйсынмыйм,— дигән булдым.— Авыл Советына буйсынам.

— Алары мәктәп директорыннан да яманрак. Әнә пунктның сарае буш тора. Шунда сыер кышлатканыем, җанымны ашадылар шуның өчен.

— Сез кайда торасыз соң?— дидем мин.

— Менә... пунктның икенче ягында,— диде агай, теләр-теләмәс кенә.— Аннан кысрыклап чыгармакчы булдылар — чыкмадым. Мин андай түгел. Кая чыгаем мин аннан? Бала-чага, катын... Катын эшләмәй. Берүзең тырышкан буласың, дөнья артыннан куган буласың. Ул синең якаңнан эләктерә дә ала. Да, сеңнекәш. Мин әле аннан чыкмаймын! Мин әле Уфага барам. Яңавылда да ышаныч юк. Сине инде акыртып җылатачаклар алар.

Ул шулай зарланган саен, минем эч поша, күңел төшә бара. «Ник килдем мин монда?»— дип үкенеп тә куям. Тизрәк бу агайдан аерылып та китәсе килә, йозакны ачтырасы, эчкә керәсе, үзеңне эш урынында итеп күрәсе килә.

Агай белән шулай күңелсез темага гәп сатып торганда, урам якта пункт турысына ниндидер ат килеп туктады. Икебез дә шул якка борылып карадык.

## VII

Капкадан унөч-ундүрт яшьләрдәге бер малай килеп керде. Йөзе борчулы. Ашыкканлыгы, курыкканлыгы әллә каян күренеп тора. Мөгаен, бер-бер хәл булгандыр.

Безнең янга килеп җитте дә бу, башта бикле ишеккә, аннары безгә карады.

— Бырачлар кая икән?— диде.

Мин, җавап көткән сыман, агайга карадым.

— Ник кирәк бырач?— диде агай, ашыкмыйча гына.

— Җиңгәй бәбәйгә чирләде,— диде малай, еларга җитешеп.— Тиз генә кушарка алып килергә куштылар. Кайда торалар алар? Өйләре кайда? Пунктта булмаса, өенә барып ал, дип җибәрделәр.

— Алар юк, энекәш,— диде укытучы, кемнеңдер бәбәйгә чирләвенә әз генә дә исе китмичә.— Кушарка бүгеннән башлап эшләмәй. Иртәгә эшен тапшырачак. Менә монда берәү бар да...

Ниндидер җансыз әйбергә күрсәткән сыман, ул миңа төртеп күрсәтте.

— Апа, әйдә тизрәк!— диде малай.

Мин, билгеле, «кушарка» түгел, мин — мөдир. Белемем буенча мин — фельдшер, ягъни мин — терапевт, хирург, невропатолог, күз-колак-борын авырулары белгече. Мин — универсаль. Авылда нинди чирле бар, барысын да мин карарга тиеш. Ләкин килмәгән «кушарка»ны көтеп торып булмый бит инде! Тиз дигәннәр, хәзер үк алып кил, дигәннәр...

Тик мин әле пунктка аяк та басмаганмын! Мин әле эшне дә кабул итмәгән, кемгә дә булса күренмәгән дә. Нишләргә?

Шушы минутта мин үз гомеремдә беренче мәртәбә чын-чынлап җаваплылык дигән нәрсә тойдым. Кеше өчен, кешенең язмышы өчен җаваплылык тойдым. Ни генә булмасын, малайны кире борып җибәрергә минем хакым юк. Димәк, эш сәгате минем шушы минуттан башлана.

— Ярар, барырбыз,— дидем малайга. Аннары агайга борылдым да:

— Пунктның ачкычы кемдә икән?— дидем.

— Минем катынга әйт,— диде агай, пунктның үзләре тора торган ягына ымлап.

Мин, ашыгып, урынымнан кузгалдым. Ишектән миңа каршы тәбәнәк буйлы, юан гына, түгәрәк кенә бер хатын килеп чыкты. Ул, ахрысы, безнең сөйләшүне ишетеп торган. Хатын миңа бүрәнә ярыгыннан ачкыч алып бирде.

Ишекне ачтым, эчкә кердем. Килеп керү белән, борынга дару исе бәрелде. Бүлмә эче салкынча гына, тыныч. Бөтен җир ялт итеп тора. Чебен юк, ни юк. Идән ап-ак итеп юылган. Тиешле җиһазлар барысы да үз урынында.

Монысы — кабул итү бүлмәсе.

Ишек төбендә тагын көтеп тору бүлмәсе бар. Такта стена артында — өченче бүлмә. Анда ике тимер карават тора. Караватлар арасында — кечкенә өстәл. Урындыклар. Ишек төбендә мич, юынгыч...

Монысы минем тора торган бүлмәм булачак. Тимер караватка чемоданымны куйдым да чемоданнан үземнең студент чакта киеп йөргән ак халатымны алдым. Аны кечкенә сумкага салдым. Аннары, икенче якка чыгып, тумбочка өстендә торган чирек литрлы шешә белән йод алдым. Шунда ук бинт кисәге белән кайчы да табылды.

Ишекне бикләп, ачкычны билгеле ярыкка куйгач, арбага чыгып утырдым. Юл мине тагын каядыр алып китте.

## VIII

Колхоз идарәсе янындагы тыкрыктан бәләкәй урамга чыктык. Малай атны туктаусыз куып бара. Менә соңгы

йортлар да артта калды. Мин яңадан кырда-яланда. Якякта кукуруз басуы. Миңа әле булса мин Равил белән барам кебек.

— Без кая барабыз соң?— дип сорыйм шулай да бераздан.

— Тау-авылга,— ди малай.

Андый авылны мин беренче мәртәбә ишетәм.

— Еракмы соң ул?— димен.

— Моннан өч-дүрт чакрым,— ди малай.

«Минем өчен ат җибәргәннәр бит әле!»— дип уйлап алам, шатлык хисе тоеп. Шул ук вакытта шүрләгәндәй дә булам. Ышанырлармы, артык яшь димәсләрме? Ярый әле, мин Галия кебек кечкенә гәүдәле түгел.

Галия... Ниләр генә эшләп ята икән инде минем Галиякәем? Ахирәтем. Күптән инде аннан хат алган юк. Вакыты юктыр. Нинди бәхетле ул! Минем менә шулай арбага утырып барганны күрсә, нәрсә дип әйтер иде икән?

Ара никадәр ерак, шулай да мин аны үз янымда итеп тоям. Аның җанга үтеп керә торган ачулы күз карашын тоям, аның шелтәле сүзләрен ишетәм. Аның ачулы йөзен күз алдына китерү дә мине тетрәнергә мәҗбүр итә. Менә кем булырга кирәк миңа! Галия кебек. Какшамас, буйсынмас Галия кебек. Тимер рухлы, чыдам Галия кебек...

Иң авыр минутларымда, мин һәрвакыт аны искә төшерәм, аңа охшарга тырышам. Тик менә шунысы яман — үземә авыр булмаган чакларда, мин аның турында уйламыйм да. Мин, күрәсең, бик начар кешедер. Минем әле һаман да үземдәге алама якларны тулысынча бетерә алганым юк. Күрәсең, капитализм калдыгы миндә ныграк сакланадыр. Ник? Каян белим мин аны?!

«Туктале, ник шүрлим соң әле мин? Чыннан да, батыр булырга кирәк! Батыр булырга!..»— дип уйлыйм үзем, күңелне күтәрмәкче булып.

Күп тә үтмәде, Тау-авылга барып та җиткәнбез. Безнең килгәнне ерактан ук күреп торганнар, ахрысы. Каршыдагы бер йорттан шунда бер апа килеп чыкты.

— Килдегезме? Әйдәгез, әйдә, бик вакытлы килеп җиттегез,— диде апа, безне каршылап.— Син, Фәрит, ерак китмә. Йомышка кирәк булырсың.

Мин апа белән исәнләштем дә ишегалга уздым, ниндидер иске галошлар янында тузанлы танкеткамны салып, өйгә кердем. Мин килеп кергәндә, йөкле хатын куллары белән эчен тотып, ух-вах килеп, ишекле-түрле йөренеп тора иде. Агарынган, ябыккан булса да, үзе болай яшь, таза күренә. Шунда ук сандык өстендә, озын күлмәге-

нең җиңнәрен сызганып, үзенчә бик эшчән кыяфәттә, мөлаем гына бер әби утыра.

— Исәнмесез, апа. Хәлегез ничек?— дидем мин.

Авыру хатын урынына әби җавап бирде.

— Әйбәт бара, балакаем, Аллага шөкер, дөрес бара,— диде.

Кирәк булса миңа булышмакчы булып, әби җитез генә урыныннан торды. Мин сумкадан халатны алып кидем. Күңелемнән үзем шунда уйлап куйдым: мөгаен, бу карчык кендек-әбидер, дидем.

— Авыр шул, апай... Кайчаннар гына котылырмын инде,— диде йөкле хатын, көрсенеп.

Мин аңа караватка ятарга куштым. Яткач, колагымны куеп, баланың йөрәк тибешен тыңладым. Шуннан соң апаның исем-фамилиясен сорадым, тегесен-монысын сораштым. Исеме Рәмзия икән, утыз өч яшьтә. Тракторчы булып эшли икән. Ике баласы бар икән. Балаларының икесен дә өйдә тапкан. Җиңел тапкан. Тапкач тиз савыккан, озакламый тракторда эшли башлаган.

Йөкле хатынны караштырган-сораштырган арада, өйгә теге безне каршы алган апа килеп керде. Керде дә, миңа карап:

— Ничегрәк, апай?— диде.— Монда гына котылыр микән, әллә Йөгәмәшкә алып барырбыз микән?

— Дивана булдыңмы әллә?!— диде кендек әби, ачуланып.— Шушы хәлендә кешене юлга алып чыгалармыни!

Аның шулай миннән узып, минем өчен җавап бирүенә, минем эшемә кысылуына үртәлеп куйдым. Техникумда укыганда безгә әйттеләр, им-томчылар сезнең дошманнарыгыз, диделәр, аларга каршы авылда көрәш алып барыгыз, авырулар янына аларны якын да китермәгез, диделәр.

— Әби, кысылмагыз әле! Чыгып торыгыз моннан!— дидем мин, тупас кына.

Ул вакытта мин үземне әллә кем итеп исәпләдем. Укытучыларым әйткән сүзләргә сукырларча ышануны изгелек, патриотлык дип белдем. Ул вакытта мин карт кешенең хәтерен калдыру мөмкинлеген дә, үземнең яшьлегем, тәҗрибәсезлегем турында да уйлый алмадым. Мин, медиклар кендек-әбиләргә табынырга тиеш, дип әйтергә җыенмыйм. Медик буларак, мин беркайчан да андый сүзне әйтмәм. Ләкин шунысы да хак: кендек-әбиләр гасырлар буена изге эш эшләгәннәр — йөкле хатыннарга булышлык күрсәтә килгәннәр. Аларның да, билгеле, төрлесе булган. Яхшысы, яманы дигәндәй... Әлеге кендек-әби нинди белгеч булгандыр — әйтә алмыйм. Тик

шулай да әзме-күпме теоретик белем үзләштереп, ак халат киеп кайткан унтугыз яшьлек кызыйдан ул, һичшиксез, тәҗрибәлерәк булгандыр.

Моны мин бары соңыннан гына, эш узгач кына аңладым.

## IX

— Арбага яхшылап урын әзерләгез!— дидем мин.— Йөгәмәшкә больницага алып барабыз. Монда бернинди шартлар юк. Дару юк, шприцлар юк, стерильность турында әйтеп тә тормыйм...

Барысы да аптырап калдылар. Өйдә тынлык урнашты.

— И, балакаем, котылыр вакыты җитә хәзер,— ди әби, сукранып.— Юлга чыгарга ярамас, әллә ни булуы бар.

— Үзем озата барырмын,— дидем мин.

Мин моны нык итеп, үз-үземә ышанып әйттем. Минем үзсүзлелек йөкле хатынга да, аның каенанасына да тиешенчә тәэсир итте.

— Ярар, барыйм әйдә, Сәлимәттәй. Бырач кеше белми әйтмидер әле,— диде Рәмзия апа.

— Беләдер дә соң, балакаем,— диде кендек-әби күңелсез генә.— Барасы җире бигрәк ерак шул.

Мин, тиз генә халатны чишеп, сумкага салып куйдым. Аннары мендәрләр алып чыгарга куштым.

Мендәрләрне җайлап арбага салдык та йөкле хатынга арбага утырырга булыштык. Хатын, ыңгырашмаска тырышып, йөзен чытып, иплэп кенә сузылып ятты. Хәерле юл теләп, капка төбендә безне хуҗа хатын белән кендекәби озатып калдылар.

Инде төш ауган. Көн шулай да кызу. Безгә унике чакрым юл барырга кирәк. Бер-ике чакрым арба юлы белән баргач та, таш юлга чыктык. Мин Фәриткә атны кызуларга куштым.

Ат юрта башлагач, моңарчы тыныч кына яткан хатын ухылдарга тотынды.

— Фәрит, әкренрәк алып барчы атны, селкетә,— диде бу, еламсырап.

Ул шулай дигәч, Фәрит атны әкренәйтә төште. Хатын беразга тынычланып калды. Ат әкренләгәч, минем эч поша. Болай атлатып кына барсак, кичкә дә барып җитә алмабыз, чыннан да юлда ул-бу булыр кебек.

— Фәрит, чаптыр атны, йоклама!— димен малайга.

Беркадәр вакыт кызу гына бардык та, хатын тагын ухылдарга тотынды.

— Фәрит, туктат атны! Үләм... әкренрәк...— ди.

Әле әкренләп, әле кызулап бара торгач, бервакытны Йөгәмәшкә керә торган юл чатына килеп җиттек. Фәрит атны читкә борды.

Ат юлы тузанлы, ләкин таш юлга караганда тигезрәк. Арба хәзер бөтенләй диярлек дыңгырдамый, тузан өстеннән йомшак кына селкенеп тик бара. Ике якта да урылган арыш басуы. Арырак, чокыр-чакырлы урыннарда, биш-алты уракчы күренә. Алар комбайн керә алмаган кыйтыкларны урып яталар.

Беркем сөйләшми. Бары тик хатынның әледән-әле ухылдап куйганы гына ишетелә. Әлеге дә баягы, атның коры җиргә дөп-дөп басканы, камыт-ыңгырчак селкенгәне ишетелә, ара-тирә мае беткән арба тәгәрмәче шыңшып ала.

Йөгәмәшкә тикле, күп булса, ике-өч чакрым ара калды. Еракта биек агач башлары күренде.

— Җитәбез, апа, җитәбез!

Бу сүзләрне мин, йөкле хатынны тынычландырудан бигрәк, үземне тынычландыру өчен әйтәм. Миңа чыннан да күңеллерәк була башлый. Ләкин авырлы хатын көтмәгәндә көйсезләнергә тотынды. Кинәт каты гына итеп:

— Фәрит, туктат атны!— диде.

Фәрит дилбегәне тартып җибәрде. Ат туктады. Күз ачып йомган арада, хатын урыныннан торды, арбадан төште. Төште дә, шунда юл буена, арба янына чүгәләде.

— Фәрит, артың белән борыл!— дип кычкырды каенесенә.

Мин аптырап калдым. Аягыма бастым да, торам нишләргә белмичә. Шулай да телгә килдем.

— Апа, нишлисез! Ярамый!— димен.— Хәзер үк арбага ятыгыз. Ярамый, рөхсәт итмим!

Минем кисәтү хатынга чебен безелдәгән кебек тә тәэсир итмәде, ахрысы. Ике куллап арба читенә тотынган көе, бу һаман көчәнүендә булды, ух-вах килде. Бар көченә ах! дип бер кычкырып җибәрде дә кинәт тынып калды.

Мин тетрәнеп киттем. Иелдем, чүгәләгәндәй иттем. Берни эшли алмаганга, үгетләп, шелтәләп, тагын нидер сөйләнгән булдым.

Искәрмәстән, хатын ачу белән миңа кычкырып җибәрде:

— Тот баланы! Нәрсә каттың?!— диде.

Күп тә үтмәде, дөньяга бер бала туды. Теп-тере, шәпшәрә бер бала туды. Мин кабаланып аны кулыма алдым. Кендекне кистем. Баланың кызыл, җылы тәпиләре бе-

раз гына җиргә тиде, тузанга буялды. Әллә басарга ирек бирмәгәнгә үпкә белдереп, әллә дөньяга чыгуына шатланып, үзенең уймак чаклы гына авызы белән бала кычкырып елап җибәрде. Чын кеше тавышы белән, чын хистойгылар белән елап җибәрде.

Мин Фәриткә сумкадан ак халатны алып бирергә куштым. Халатны алдыма җәйдем дә баланы шуңа төрдем, аннары мендәр өстенә салдым. Бала белән эшне бетергәч, ана кешегә булышыйм гына дигән идем... хатын, берни булмагандай, җитез генә кыланып, арбага менеп тик бара! Менде дә бу арбага, баласы янына чалкан сузылып ятты.

Мин баланы яңадан кулыма алдым, хатынның баш астындагы мендәрен җайладым, күлмәк итәген каплаттырып куйдым.

— Кем?— диде ана бераздан, хәлсез генә.

Баланы карарга да онытканмын икән. Халатны сүтеп карадым да, күңелсез генә:

— Мала-ай...— дидем.

Хатын тынып калды, күзләрен йомды.

Ул арада мин дә бераз айныгандай булдым. Як-ягыма күз төшереп алдым. Күктә кояш кыздыра. Баш очында гына тургайлар сайрый. Юл буенда үләндә, камыл, арасында, бер-берсен узышып, чикерткәләр чекелдәшә. Исе китеп, хәйран калып, Фәрит тын гына арба янында басып тора. Кара бия, тынычсызланып, койрыгын селтәштереп куя, башын борып әледән-әле безнең якка күз ташлап ала. Бездән арырак, урылмаган арышлар янында, кайсы кулын маңгаена куеп, кайсы биленә таянып, безгә таба уракчылар карап тора.

Уракчыларны күрү белән, мине оят-хурлык хисе көйдереп алды. Менә сиңа врач! Менә сиңа мөдир! Эшкә башлавыңның беренче адымыннан ук хурга кал, имеш! Бөтен халык алдында! Бөтен дөнья алдында!..

— Әйдә... Фәрит...— дидем төшенке генә.— Кузгал.

Баланы җайлап тоттым да арбага менеп утырдым.

Берничә минуттан, без больницага барып җиттек.

## X

Мәсәгуткә без Фәрит белән икәү генә кайттык.

Инде кич булып килә. Урамда бала-чагадан башка беркем күренми. Фәрит мине капка төбенә кадәр китереп куйды. Мин ишегалга уздым, бүрәнәдәге ярыктан ачкычны алдым да, ишекне ачып, өйгә кердем.

Бүлмәләр әйтеп бетергесез дәрәҗәдә ят булып, чит булып тоелды. Стеналардагы плакатлар да, тәрәзә

пәрдәләре дә, ак җәймә җәелгән сәке дә — барысы да миңа шелтәләп, ачуланып карыйлар шикелле тоелды.

Чемоданнан Галиянең фотосын эзләп таптым да өстәлдәге графинга сөяп куйдым. Озак кына аның күзләренә карап тордым. Күңелемнән: «Нишләргә? Нишләргә?»,— дип, үз-үземә сорау бирдем. Дус кызымның бераз гына кысылган очкынлы күзләренә, нечкә иреннәренә карап торгач, күңелгә ял булып киткәндәй булды. Өйдән алып килгән суык бәрәңге белән бер телем икмәкне алдым да, иренеп кенә, теләр-теләмәс кенә ашарга керештем.

Карама коелып утырам шулай тимер караватта. Инде бөтен авыл белгәндер. Сөйлиләрдер, гайбәт саталардыр...

Шулай нишләргә белми утырганда, кемдер бүлмә ишеген ачты да:

— Мөмкинме?— диде.

Мин ишеккә борылып карадым. Минем «мөмкин» дигәнне дә көтмәстән, бүлмәгә чая гына бер кыз килеп керде. Керде дә бу, елмаеп, туп-туры минем янга узды.

— Исән-имин килдегезме?— диде.— Сез инде өлгергәнсез дә... Фәритне очраттым. Тау-авылга баргансыз икән.

Авыздагы бәрәңгене чәйнәмичә йотып җибәрдем. Кып-кызыл булдым. Ишеткән! Барысын да белә! Кем соң бу? Ник килгән? Җитмәсә, үзен шундый иркен тота.

Яшькә дә, буйга да ул минем чама. Ләкин, миңа капма-каршы буларак, искиткеч җиңел сөякле. Нечкә билле. Төскә-биткә матур, бик матур. Нәфис кара кашлар, кыю кара күзләр. Җыйнак кына, матур гына борын. Иреннәр дә җыйнак, матур. Чокырланып торган ирен асты, түгәрәк кенә ияк. Маңгае гына бераз тәбәнәк сыман. Аннары калку, тулы күкрәк. Кашлары, күзләре аеруча матур. Шәрә беләкләре кояшта янган. Тулып, күзгә бәреләп тора.

Өстенә авылчарак тегелгән алсу штапель кофта кигән. Җиңе, кыска булса да, терсәккә җитеп тора. Анысы бик үк килешле түгел. Аннары — кара трико юбка. Юбкасы нечкә билен тагын да нечкәртеп күрсәтә. Аягында биек үкчәле кара туфли. Чәче кистерелгән, шпилькалар белән тоттырып, артка җыеп куелган.

Әллә минем Тау-авылга барганны белгәнгә күрә, әллә үз-үзен чамадан тыш кыю тотканга, беренче караштан ук ул миңа ошамады. Кем белә, бәлки, бераз гына көнләшү дә булгандыр.

— Сез кем буласыз соң?— дидем мин, ашавымнан туктап.

— Мин Зөһрә булам,— диде кыз, җиңел генә.— Мин

пунктта санитарка булып эшлим. Әле әйтмәдем дәмени? Менә мин инде ул Зөһрә... сезнең санитарка!

Без сөйләшеп киттек. Мин аннан пункт хәлләре турында, минем киләчәк эшемә кагылышлы кайбер нәрсәләр турында сораштырдым. Зөһрә әйтте, мин инде монда дүртенче ел эшлим, диде, шушы дәвер эчендә, өч фельдшер алышынды, менә сез дүртенчесе, диде. Баштарак ул шулай «сез» дип эндәште, аннары, ияләшә төшкәч, «син»гә күчте.

Минем белән ул бер дә санитарка булып, миңа буйсынган кеше булып сөйләшмәде. Үз-үзен ул миннән зуррак, өстенрәк итеп тотты. Ничәнче елгысың, диде, кайдан килдең, кайда укыдың, диде, әтиең-әниең бармы, Яңавылда йортыгыз кайсы урамда, ничәнче номер, диде. Шуннан соң Уфа турында, шәһәр тормышы турында сораштыра башлады.

Баштарак аның өстенлегенә эчем пошса да, Уфа турында сорагач, шундук ачылып киттем. Зөһрә дә күз алдында үзгәрде. Йотлыгып, авызга керердәй булып тыңлый!

— Эх, ятабыз инде шушында әрәм булып!— диде бу, көрсенеп.— Кеше кебек, ичмасам, читкә дә китеп булмады.

«Чынлап та, авылда әрәм булып ята шундый чибәрлеге белән»,— дип уйлап куйдым.

— Ничә класс бетердең соң?— дидем.

— Кая инде ул!— диде Зөһрә, кулын селтәп.— Җиде... Аның белән кая барасың? Авыл капкасыннан чыгарга да ярамый.

— Әзрәк шул,— дидем мин.— Ник, шулай да техникумга керергә тырышып карарга була.

— И, уку белән дә берни кырып булмый инде хәзер,— диде Зөһрә, үзенә үзе каршы килеп.— Әнә бездә әле унны бетергәннәр дә беркая китә алмый йөриләр... чабата киеп... тирес түгеп...

— Сездә әле дә чабата кияләрмени?— дидем мин.

— Кимиләр дә соң. Итек кисә дә чабата кебек инде ул. Кайсы тракторда эшли, кайсы фермада. Берсе — бригадир ярдәмчесе. Көтүче кебек. Белемем булса, шушында чиләнеп ятырыеммы соң мин!

«Минемчә уйлый бу!»— дидем мин үз-үземә. Ә мин барыбер монда чиләнеп ятмаячакмын. Җай чыгу белән, Яңавылга сыпыртачакмын. Инде икеле-микеле уйланып торасы юк. Яңавылда больницада эшләрмен дә тагын Уфага, йә Казанга юл тотармын. Монысында инде институтка. Туп-туры институтка!

Зөһрә чыгып китәргә ашыкмады. Минем янда эше булмаса да, тәрәзә пәрдәләрен сыпырыштыргалап, өстәл-

дәге графинны бер урыннан икенче урынга күчергәләп, тегесен-монысын сөйләнгәләп, һаман минем янда булды. Мин ашамлык төрелгән кәгазьне читкәрәк алып куйдым. Үзеңнең санитаркаң алдында, ярлы кеше кебек, суык бәрәңге ашап утырмассың лабаса!

Шуннан соң чемоданнан үземнең китап-дәфтәрләрне, бер-ике күлмәгемне алдым. Әйберләремне тәртипкә китерә башладым.

— Их, карыйм әле!— диде Зөһрә.

Күлмәкләрнең берсен минем кулдан тартып диярлек алды да, сүтеп яктыда карарга да тотынды. Аның нинди материядән тегелүенә игътибар итте, ничә метр китүен, ничә сумга төшүен сорады. Тегелешендәге кайбер яңалыкларны күреп алды. Берсен карап бетерде дә, икенчесенә тотынды. Анысын да җәеп җибәрде, үзенә үлчәп карады. Метрлар, сумнар турында сорашты. Уфада хәзер ничегрәк киенәләр, диде. Фәлән апа Чиләбедән кайткан, аның күлмәге фәләнчә тегелгән, дип такылдап алды.

Күлмәк турында аның шулкадәр фәлсәфә сатуы миңа бер дә ошамады. Кием-салым, мода турында сөйләшү ул, минемчә, наданлык, мещанлык. Мәктәптә безне шулай өйрәттеләр. Мода турында, киенү-ясану турында элек бай хатыннары, бай кызлары гына сөйләшкәннәр. Чөнки аларның башка эшләре булмаган. Аларга менә минем кебек фельдшер булырга да туры килмәгән, башка төрле мәктәптә укырга да туры килмәгән. Чын кеше, алдынгы карашлы совет кешесе, минемчә, бары тик уку турында гына, илгә, халыкка хезмәт итү турында гына уйларга тиеш.

Күлмәкләр турында сүз булып алгач, Зөһрәне ошатмау тойгысы яратмауга әйләнде. Аның белән бөтенләй сөйләшәсе килми башлады.

— Берәрсендә үтүк юк микән?— дидем шулай да.

— Ярар, хәзер,— диде Зөһрә.

Күз ачып йомганчы, ул кемнәрдәндер үтүк алып чыкты. Кайдан күмер алырга, кайда кыздырырга, ничегрәк үтүкләргә кирәклеген аңлатты да:

— Мин киттем. Клубны җыештырасым бар. Мин бит клубта да эшлим. Заф булып,— диде.

Ничек килеп кергән булса, шулай ук ялт кына чыгып та китте.

## XI

Икенче көнне Зөһрә килеп ишек шакыганда, әле бик иртә иде. Мин тиз генә сикереп тордым, ишекне барып ачтым. Бүген Зөһрә кызыл бизәкле ситсы күлмәк кигән.

Бөтенләй икенчеләнеп калган. Тагын да нечкәргән, җыйнакланган. Мин аңа сокланып, көнләшеп карадым. Кичәге яратмау тойгысы каядыр юк булды. Үзләреннән алып килгән калай чәйгүн белән бу миңа чәй кайнатырга куйгач, бөтенләй күңел эреп китте.

Мин тора торган бүлмәдәге плитәгә ягып җибәргәч, Зөһрә, җитез генә кыланып, юеш чүпрәк белән өстәл өсләрен, шкафларны, тумбочкаларны сөртеп чыкты, тәрәзә пәрдәләрен караштырды, урындык-өстәлләрне кузгаткалап алды. Ул бик тиз эшләде, ялт-йолт кына эшләде. Эшкә уңганлыгы, булдыклылыгы аның әллә каян күренеп тора иде.

Бүген мин анда тагын бер яңалык күреп алдым. Эшләгән арада, ул әледән-әле минем белән сөйләшкәли, сөйләшмәгәндә, җырлап-җырлап ала. Тавышы шундый матур. Искиткеч матур! Юеш чүпрәк белән өстәл-шкаф сөрткән кебек җиңел генә, көчәнмичә генә җырлый.

«Нинди бәхетледер бу!» — дип уйладым үзалдыма. Егетләр үлеп яраталардыр моны. Ләкин егетләр турындагы уйны мин шундук куалап җибәрергә тырыштым. Үзем дә сизмәстән, көрсенеп куйдым. Бит әле миңа бер генә егетнең дә чын-чынлап гашыйк булганы юк! Кайбер килде-киттеләрне исәпләмәгәндә...

Минем өчен бу бик зур нәрсә. Серле, тирән нәрсә. Мин моны кузгатырга да куркам. Котым алына.

Юындым да сүзсез генә чәч тарарга тотындым. Кинәт кузгалган күңел үз урынына утыргач, ачыктан-ачык мактау белдереп:

— Тавышың бик матур икән синең, Зөһрә,— дидем.

Зөһрә көлде, юеш чүпрәген карават башына куйды. Аннары, бернинди тартынусыз, минем чәчләрне тоткаларга керешеп китте.

— Синең чәчең матур,— диде, үзен мактаганга әз генә дә исе китмичә.

Миңа ничектер җылы булып, рәхәт булып китте.

— Чәч белән генә нишлисең,— дигән булдым мин.— Мин бит юан... күәс кебек...

— Һи, кияүгә чыксаң әле, бал корты кебек кенә калырсың,— диде Зөһрә.

Чәчне тарап бетергәч, чәй эчтем. Чәй эчкәндә, утыз яшьләр чамасындагы, ягымлы гына бер хатын килеп керде. Бу акушерка булып чыкты. Моңа кадәр ул пунктның мөдире дә булып торган. Бөтен эшне берүзе алып барган. Хәзер ул пунктны миңа тапшырырга килгән.

Танышкач-белешкәч, мин аңа кичә Тау-авылга барганда юлда булган күңелсезлек турында сөйләп бирдем.

Анын моңа бер дә исе китмәде. «Дөнья булгач, булыр инде»,— диде дә куйды. Тәҗрибәле кеше авызыннан мондый сүз ишеткәч, минем өстән тау-таш ишелеп төшкәндәй булды. Хәзер шул турыда ныграк, тәфсилләбрәк сөйлисем килеп китте. Ләкин хатынның тыңлап торасы килмәде. Шуннан без икәүләп авыл Советына киттек.

## XII

Авыл Советында эш сәгате башланган иде. Председатель дә, секретарь да шунда. Бер хатын белән бер ир кеше дә бар.

Без исәнләштек, түргә уздык.

— Менә, Галим абый, минем урынга килгән,— диде акушерка хатын, миңа күрсәтеп.

Калын иренле, тәбәнәгрәк буйлы, тыныч кыяфәтле Галим абый (күрәсең, авыл Советы председателе) өстәлдәге салам эшләпәсен кулына алды да:

— Һо, яңа фельдшермыни?— диде.— Бик шәп, сеңлем. Бик кирәк кеше син безгә. Кайчан килдең?

Мин, үз-үземне кыю тотарга тырышып:

— Кичәгенәк,— дидем.— Менә пунктны кабул итәргә кирәк... сез кирәк.

Кулына кәгазь кисәге тоткан бер хатын шунда сүзгә катышып:

— Алар халкына тынычлык бармыни,— дип куйды.— Кичәгенәк килеп төшү белән, мескенкәемне алып та киттеләр.

— Каян килеп алдылар?— диде председатель, кызыксынып.

— Тау-авылга, бер хатын янына,— дидем мин, теләмичә генә.

— Бик яхшы булган,— диде Галим абый.— Килгән дә, китеп тә барган. Эшне кабул итәсем бар дип көтеп ятмаган.

— Әйтмә инде, мескенкәемне,— дип куйды тагын да әлеге хатын, мине кызганып.

— Нишләп мескен булсын?— диде Галим абый.— Яшь кеше, көче ташып тора. Белеме бар. Дөрес эшләгән!

Бу турыда сөйләшәсе килмичә, мин сүзне тизрәк икенчегә борып җибәрергә ашыктым.

— Нишләрбез икән, Галим абый?— дидем.

Галим абый авыл Советы секретарена безнең белән пунктка барырга кушты. Җәенке борынлы, ямьсез генә бер агай шомарып беткән өстәле яныннан торды да безнең янга килде. Без өчәүләшеп пунктка киттек.

Пунктны тапшыру, кабул итү ике-өч сәгать эчендә тәмам булды. Кирәкле кәгазьләргә кул куйгач та, элекке мөдир белән авыл Советы секретаре, миңа эшемдә уңышлар теләп, саубуллашып чыгып та киттеләр.

Мин кабул итү өстәле янына килеп утырдым. Халат төймәләрен барлап чыккан булдым, чәч тузгымаганмы дип, халат якасы үз урынындамы, кием-салымда андыймондый кимчелек юкмы дип, шкаф пыяласына карап алдым. Өстәлдәге кара савытына, журналга, дару шешәләренә кагылгалап алдым. Никтер кисәк кенә шүрли башладым. Гомергә калтыранмаган кул калтырый, тез буыннары калтырый. Үземнең бер дә юктан авыз ерыла.

— Керсеннәрме?— ди Зөһрә.— Эшкә барасы бар диләр, ашыктыралар.

Ашыктырганнарын мин үзем дә ишетеп торам. Ашыктырмыйлар да. Берәү генә ашыктыра.

— Керсеннәр... берәмләп...— димен.

Тавышым әллә нинди ят булып, ямьсез булып чыга. Авырулар белән сөйләшкәндә дә тавышым шулай бозылып чыкмасын дип, тамак кыргалыйм. Шул вакыт, авыр кирза итекләре белән шак-шок басып, ашыктырган егет килеп керә. Таза. Юан. Кызгылт йөзле. Киемнәре каралып беткән. Күренеп тора — йә тракторчы, йә комбайнчы. Сул кулын күтәрә төшкән. Кул аркасында җәрәхәт күренә.

— Илла да, апасы, көттерергә яратасың икән!— ди бу, бөтен бүлмәгә шаулап.— Кайчан килгәнием инде — эшкә китәргә кирәк. Шуның өчен никадәр вакытны әрәм итәргә туры килә.

— Утырыгыз,— димен мин.

Тавышым җитди, тыныч чыкты.

— Исемегез, фамилиягез ничек?

## XIII

Ул көнне мин биш-алты кеше генә кабул иттем. Авыруларны бик җентекләп, озаклап карадым. Үземчә, диагнозлар куйдым, рецептлар яздым.

Кулына ялгыш чүкеч белән суккан тракторчы егетнең ярасын бәйләдем дә, аңа тагын икенче көнне дә килергә куштым. Аның артыннан урта яшьләрдәге бер апа керде. Моның тамагы авырта булып чыкты. Эштән тирләп кайткач, кое суы эчкән. Ападан соң, корык-корык йөткергәләп, саргылт йөзле, ябык кына бер агай керде. Үпкәсе авырта икән. Аңа Яңавылда күренергә язу бирдем, чөнки диагноз куя алмадым. Йөрәге авырткан яшь кенә бер хатынга икенче көнне килергә куштым.

Зөһрә авыруларны берәм-берәм кертеп торды. Чираттагы авыруны керткәч тә, ишекне ябып куйды. Шуннан соң минем янга килде, мин әйткәнне дә көтмәстән, миңа ярдәм итеп, кайберсенең кулын тотып торды, кайберсенә сәкегә ятарга булышты.

Бер малайның чалгыга киселгән аягын бәйләп ятканда, кемдер ишекне ачты да, башын тыгып:

— Мөмкинме?— диде русча.

Мин, башымны калкытмыйча гына:

— Сабыр итегез,— дидем.

Малай соңгы кеше иде. Таягына таянып ул ишеккә юнәлде.

— Кем бар анда — керсен,— дидем Зөһрәгә.

Зөһрә ишекне ачты да, икенче як бүлмәгә кычкырып:

— Керегез!— диде.

Бүлмәгә озын гына, чандыр гына бер кыз килеп керде. Өстенә зәңгәр бизәкле чуар ситсы күлмәк кигән. Күлмәгенең зур ак якасы әллә каян күзгә ташланып тора. Нечкә биленә ак пластмасса каеш буып куйган.

— Утырыгыз. Фамилиягез ничек?— дидем русча.

Кыз утырды.

— Бородуля,— диде.

— Ничә яшьтә?

— Унсигездә.

— Кайда торасыз?

— Мәсәгуттә.

— Кай җирегез авырта?

Кыз елмаеп җибәрде.

— Мин авыру түгел,— диде.— Мине монда акушерка итеп җибәрделәр. Менә приказ.

Кыз миңа бер кәгазь кисәге тоттырды. Чыннан да шулай, акушерка итеп җибәргәннәр.

Шуннан без ныклабрак таныштык. Мин бераз гына авырулар белән сөйләшкәндәге шикелле сөйләштем. Кызның исеме Таня икән. Украинадан килгән. Иптәшләреннән бераз соңга калган булган. Мин теге Соломон Моисеевич бүлмәсендә очраткан украин кызлары аның иптәшләре булган икән. Фельдшерлык-акушерлык мәктәбен быел гына тәмамлаган. Дипломына теркәлгән кәгазьгә караганда, мәктәпне бик яхшы бетергән. Менә дигән итеп бетергән! Бер генә «яхшы»сы да юк, барысы да «отлично»!

«Оһо!» дип куйдым үзалдыма. Ләкин нишләп соң ул монда эшкә килгән? Аңа бит турыдан-туры институтка керергә мөмкин булган. Бернинди имтихан тапшырмыйча! Кем бу, нинди ахмак бу?

Үзем турында мин аңа кыска гына итеп сөйләдем.

Менә мин дә бүген генә кабул иттем әле, дидем, килүегез бик яхшы булган, дидем. Аннары өстәп куйдым, үзегезне өегездәге кебек хис итегез, дидем, юлдан соң арыгансыздыр, хәзер менә урнашырсыз, ял итәрсез, дидем.

Таня тыйнак кына тыңлап торды. Сөйләшү-аңлашу тәмам булгач, көтеп тору бүлмәсенә чыктык. Анда Таняның чемоданы белән зур гына төенчеге тора. Чемоданны мин алдым, төенчекне Зөһрәгә күтәрергә куштым. Таняны мин үзем төн кунган арткы бүлмәгә алып кердем.

Шулай итеп, минем штатта тагын бер кеше артты.

## XIV

Мәсәгут фельдшерлык-акушерлык пунктына барлыгы җиде авыл карый. Бу — күп, бик күп. Мәсәгуткә иң якын авыл — Алдар. Еракльгы бер чакрым. Иң ерак авыл — Куштирәк. Анысы унике чакрым. Аннары Кызыл Яр, Тау-авыл, Түбән Чат, Югары Чат.

Менә шушы авыллардан безгә таң ату белән авырулар килә. Җәяүләп киләләр, атка утырып, машинага утырып киләләр. Бер авылдан берәр авыру булганда да, көненә җиде кеше. Гадәттә, җиде генә булмый, унҗиде, егерме җиде була. Зөһрәнең әйтүенә караганда, миңа кадәр бер дә болай күп кеше килгәне булмаган. «Зина апа» дигән фельдшер эштән киткәч тә, пунктның эшләре таркала башлаган. Бөтен пунктка баш булып калган теге акушерка хатын авыруларга кул селтәгән. Рәтләп карамаган, кычкырынган, авыруларны бер дә юкка тиргәп чыгарган чаклары да булган. Аның үзенең тормышы рәтле булмаган — ире белән начар торган, аерылышып йөргән. Шуңа күрә үзенең төп эшен тиешенчә алып бара алмаган. Аннары аның вакыты да булмаган. Бер үк вакытта аңа фельдшерлык эшен дә, акушерлык эшен дә башкарырга туры килгән.

Ә без — Таня белән икәү. Ул яктан караганда, безнең эшләр җайлы. Шулай ук безнең ирләребез белән талашып торасыбыз да юк, балалар турында, йорт-җир турында да кайгыртасы юк. Безнең бөтен кайгы-мәшәкать — эш. Шуның өстенә без яшь, без әле каешланмаган, шомармаган. Эш — безнең өчен яңа нәрсә, тансык нәрсә. Шуңа да без җилләнеп, дәртләнеп эшлибез.

Авыруларны кабул итүдә Таня сирәк була. Аның үз эше бар. Ул авырлы хатыннарны исәпкә ала, аларның хәлләрен белешеп тора, бала табуда булыша, яшь балаларны тикшерә — патронаж сестра ролен дә үти.

Менә шулай көннәр безнең бик киеренке үтә, буш

вакыт бөтенләй диярлек калмый. Кичләрен, караватка яту белән, йокыга китәбез. Ә кайчакта бик озак кына сөйләшеп, серләшеп ятабыз. Таня үзенең Украинасы турында, әнисе, әбисе турында сөйли.

Кичләрен, йокларга ятыр алдыннан, кайчагында баскычка чыгып утырабыз, китап укыйбыз. Караңгы төшә башлагач, аяк очтагы, елга буендагы бакалар тавышын тыңлыйбыз. Алар, бер-берсен уздырып, кычкыралар, сайрыйлар... Берсе бер көйгә сайрый, икенчесе икенче көйгә сайрый. Бөтенесе бергә кушылгач, нииндидер оркестрны, музыканы хәтерләтә. Чынлап, музыканы.

Аннары бака сайравыннан башка, кичләрен тагын икенче төрле тавышлар да ишетелә. Караңгы төштеме, яшьләр клубка җыела. Алар безнең яннан гына үтеп китәләр. Төн уртасына кадәр клуб ягында сөйләшкән, көлешкән тавышлар яңгырап тора. Андый чакларда бигрәк тә моңсу була. Күңел тынычсызлана башлый. Нидер җитми кебек, кемнедер көтәсең кебек. Бер сәбәпсез елыйсы килеп куя. Авыр гына көрсенәсең дә тып-тын, буп-буш бүлмәгә кереп ятасың. Башта бераз йоклый алмый азапланасың, аннары кинәт кенә онытылып китәсең. Берничә сәгатькә чынбарлыктан юкка чыгасың.

Иртән-иртүк тагын Зөһрә килеп җитә. Тагын эш көне башлана.

## XV

Унынчы классны бетергәч, мин Башкортстан медицина институтына укырга кермәкче булдым. Гариза бирдем, имтиханнар тапшырып йөрдем. Ләкин конкурстан үтмәдем. «Балл» җитмәде. Җиңелеп, хур булып, кире Яңавылга кайтуны күз алдыма да китерә алмадым. Мин Уфада торып калдым. Шәһәрдә берәр эшкә кереп, бераз чарланырга, ныклап торып имтиханга әзерләнергә, икенче елны тагын бәхетне сынап карарга булдым.

Шуларның барысын да әйтеп әтигә хат яздым. Озакламый җавап хаты да килеп төште. Әти миңа киңәш биргән, син, кызым, дигән, бер дә алай бетеренмә — дөньяның кендеге институт түгел, дигән, алай чынлап медик буласың килгәч, тот та фельдшерлар мәктәбенә укырга кер, дигән, үзеңә бер һөнәр булыр, телисең икән, соңыннан институтка да керерсең, бәлки, дигән.

Мин әтинең сүзен тотарга булдым. Өйдә чакта да ул миңа нәкъ шунда керергә киңәш иткән иде, институтка керә алмассың, азапланма юкка, дигән иде.

Техникумга мине бернинди имтихансыз алдылар. Туп-

туры өченче курска. Анда барлыгы ике ел укыдым. Үземне язмыш тарафыннан рәнҗетелгән итеп хис иткәнгә, теләмичә генә укыдым. Шуңа күрә минем теоретик белем сай булды. Практикасы да инде...

Танянык эшләр башкача. Фельдшерлык-акушерлык мәктәбендә ул дүрт ел укыган, ягъни җидене бетергәч тә кергән. Үзенең әйтүенә караганда, ул институт турында уйламаган да. Ул чеп-чи авыл кызы. Тормышка ул ачыграк күз белән карый, авылчарак, практик буларак карый. Ул гомере буена «кушарка» булып эшләү өчен укыган. Мин моны эшли башлауның беренче көннәреннән үк аңлап алдым.

Шулай беркөнне сорый бу миннән:

— Нәрсә ул аорта?— ди.

Мин көлеп куйдым.

— Китаптан карарга кирәк булыр,— дигән булдым.

— Ю-ук. Андый аорта түгел,— ди бу, сузып.— Татарча «аорта» нәрсә?

— Ә-ә! Авырта?— димен мин.

— Әйе, аворта!— ди Таня, татарча әйтергә тырышып.

Мин аңа «авырта»ның нәрсә икәнлеген аңлатып бирдем. Чемоданыннан тиз генә бу башланмаган калын дәфтәр алды да беренче биткә «авырта — болит» дип язып куйды. Бер тотынгач, тагын сораштыра башлады. Үзе мин әйткән бер сүзне дәфтәренә теркәп бара. Мин аңа авырулар белән сөйләшкәндә еш кулланыла торган сүзләрне, «Кай җирегез авырта?», «Кайчаннан бирле авырта?» кебек җөмләләрне яздырдым.

Буш вакыты булдымы, Таня дәфтәрендәге сүзләрне, җөмләләрне ятларга тотына. Тапкырлау таблицасы ятлаган кебек ятлый. Бирелеп, тырышып өйрәнә. Ул, гомумән, тырыш, карусыз.

Беркөнне, кичке ашны ашагач, Таня белән икәүләп татар теле өйрәнеп утырганда, тышта ишек ачылган тавыш ишетелде. Дөбер-шатыр килеп, кемдер кереп ята. Без тынып калдык, көтә башладык.

— Мөмкинме, апалары?— дип кычкыра Равил, такта ишекне ачкандай итеп.

— Кер әйдә, кер, Равил!— дип кычкырдым мин, куанып.

Теге көннән соң Равил пунктка бер-ике мәртәбә кереп чыккан иде. Болай гына, хәл-әхвәл сораштырыр өчен генә. Ничек урнаштың, диде, ошыймы, диде. Аннары клубка чакырды. Икенчесендә чирле булып, аягым сызлый дип керде. Ике керүендә дә, мин аны дусларча каршыладым, иркенләп сөйләшеп утырдым.

Бүген дә мин Равилне түргә чакырдым, утырырга

урын тәкъдим иттем. Равил алай кыстатып тормады, лап-лоп атлап, туп-туры өстәл янына килде, утырды да елмаеп миңа карады, Таняга карады.

— Тавык кебек әллә кунакларга да җыендыгыз?— дигән булды.— Бүген клубта кино була.

Таня аның нәрсә сөйләгәнен бик үк аңлап җитми. Шулай да нидер чамалый, сораулы караш белән әле миңа, әле Равилгә карый.

Шунда минем күңелгә бер уй килде.

— Равил,— димен, елмаеп.— Безгә укытучы кирәк әле.

— Кирәк булса, каян алыйм мин аны?— ди Равил.

— Үзең бул.

Равил аңламады. Йөзенә аптырау билгесе чыкты.

— Кем булырга? Укытучымы?

— Укытучы... профессор,— димен мин, көлеп.— Менә Таня татарча өйрәнмәкче була. Шуңа укытучы кирәк.

Үзе турында сөйләгәнне сизеп торган Таня, ачуланган булып, мине шелтәләп алды, нәрсә син анда «Таня» дип лыгырдыйсың, дигән булды.

Равил, ниһаять, аңлап алды. Күңелләнеп елмаеп җибәрде. Таняга борылды да, татарча:

— Шулаймыни, апасы?— диде.

— Нярся-а?— диде Таня, сузып.

Равил белән без көлеп җибәрдек. Мин Таняга аңлатып бирдем.

— Була ул, апасы!— диде Равил, урыныннан торып.— Әйдә, кинога барасыңмы минем белән? Барганда өйрәтермен.

Мин тәрҗемә итеп бирдем. Таняга җитә калды. Ул инде моңарчы да кино турында, клубка чыгу турында сүз кузгаткалап караган иде. Мин каршы килдем. Клублар, кинолар турында минем ишетәсем дә килми. Ләкин бүген мин Равил белән клубка барырга Таняга үзем әйттем. Таня шундук әзерләнергә тотынды.

Алар мине дә өндәп карадылар. Мин риза булмадым. Шуннан соң болар икәүләп кенә чыгып киттеләр. Буш, тын бүлмәдә мин берүзем торып калдым. Миңа никтер ямансу булып китте. Галиягә хат язарга утырдым.

## XVI

Хатымны язып та бетермәдем, тышта тагын кемнеңдер кергәне ишетелде. Мин тын калып көтә башладым.

Соңгы вакытта мин әллә нишләдем. Бигрәк тә кичкә таба. Урамда сөйләшеп узган кешеләрне ишеттемме, шундук тәрәзәгә капланам, узып баручыларның йөзләрен күрергә тырышам. Тышта, ишегалда кыштырдык ишет-

темме, тагын колак үрә тора, күңел никтер тынычсызлана башлый. Кемнедер көтәсең, кемнедер күрмәкче буласың. Соңыннан беркем юклыгын аңлагач, тирә-якта бушлык, моңсулык барлыкка килә. Кайчагында төннәрен сискәнеп уянам. Үземчә, мин моны күп эшләгәнгәдер дип уйлыйм, әллә чирләдем инде дип тә куям.

Чынын гына әйткәндә, үземнең ни өчен үзгәргәнемне мин бик яхшы сизенәм. Шуны да сизенмәгәч! Тик менә үз-үзеңне алдыйсың килә. Чын сәбәпне юри оныткан буласың, бөтенләй булмаган сәбәпләр эзләгән буласың. Миндә, гомумән, үз-үзеңне алдарга тырышу гадәте бар бугай. Миндә, Такташ әйтмешли, ике «мин». Шул ике «мин» арасында һәрвакыт каршылык чыгып тора. Бер «мин» дөреслекне сөйләргә тели, икенче «мин» нәрсәдәндер курка. Әллә кеше сүзеннән курка...

Эшли башлавымның беренче атнасында ук, миңа Яңавылга райздравка барырга туры килде. Дару, марлябинт алырга. Анда баргач, билгеле, Соломон Моисеевич янына керми булмый. Соломон Моисеевич минем белән елмаеп кына сөйләште, эшләп буламы, коллега, диде, иптәш начальник, диде.

Мин аңа нәрсә дип җавап биргәнмендер, хәтерләмим. Бары шуны гына хәтерлим: аның алдында мин никтер оялдым, кызарындым. Аның янып торган зур кара күзләренә карадыммы, ни хикмәттер — коелам да төшәм. Телем көрмәлә, күзем күрми башлый.

Тагын шуны хәтерлим: аның яныннан чыккач, мин үземне исерек кебек хис иттем. Өйгә кайткач, әти әйтә, әллә, кызым, начальнигың тиргәдеме — бик кызарынгансың, ди. Булыр, булыр, аны бер дә рәтле кеше түгел дип сөйлиләр, ди. Минем әти белән бәхәсләшәсем, Соломон Моисеевичны яклыйсым килде. Ләкин аны яклап берни әйтә алмадым. Бары, тиргәмәде, дип кенә куйдым.

Мәсәгуткә кайткач, атна буена Соломон Моисеевич турында уйланып йөрдем. Яңавылдан әллә кайда читтә яткан бер караңгы авылга, шушындый бер вакытта аның килеп чыгуы мөмкин түгеллеген аңласам да, аннары, урамда берминди машина тавышы ишетелмәсә дә, тиле бер өмет белән, мин хәзер аның бүлмәгә килеп керүен көтә башладым.

Ниндидер кеше чолан ишеген ачты, тамак кырды, безнең бүлмә ишегенә таба килә башлады. Ишек шакыган тавыш ишетелде.

— Керегез!— дип кычкырдым мин.

Бүлмәгә кояшта янган таза яшь бер егет килеп керде.

Мин аны танып алдым. Тимерҗан дигән егет.

Үзеннән бигрәк, исеме истә калган. Бераз гына искечәрәк булса да, колакка ягымлы исем. Кешесе яшь булгач, искечәрәк икәнлеге дә сизелми.

Мин аның белән комсомол учетына кергәндә таныштым. Танышмадым, күрдем генә. Шунда аның бригадир ярдәмчесе булып эшләвен белдем. Никтер колакка чалынып калды. Бары шул.

Язылып бетмәгән хатны читкә этәреп куйдым да керүчегә күтәрелеп карадым. «Әллә мине дә кинога алырга килгәннәрме?»— дип уйладым, үзалдыма елмаеп. Тик нишләптер бу кинога алырга кергән төсле күренми. Йөзе җитди, киеме дә — эш киеме. Кырынрак салынган кепкасы астыннан тотам-тотам чәче күренеп тора.

— Вакыт соң булса да, килдем әле,— диде бу.— Әнинең хәле начар. Барып карамассыз микән?

— Нәрсә булды?— дидем мин.

— Лапас түбәсеннән егылып төшкән,— диде бу.— Эштән кайтып ашарга гына утырганыем, кычкырган тавыш ишетелде. Чыксам, егылып төшкән... «Ай, аягым!»— дип, бер генә ыңгырашты да, тыны да бетте. Өйгә дә алып кермәдем, менә монда сезгә йөгердем.

— Хәзер!— дидем мин, тиз генә урынымнан торып.

Без Тимерҗаннарга барып җиткәндә, аның әнисен инде өйгә алып кергәннәр иде. Ул инде һушына килгән. Караватта чалкан сузылып ята. Шунда ук ике-өч хатын кайнаша. Алар аңа су бөркегәннәр, киемнәрен чылатып бетергәннәр. Кемдер башына юеш сөлге бәйләп куйган, кемдер аягы астына мендәр кыстырган.

— Аягы тайган, аягы!— диештеләр хатыннар, мин килеп кергәч тә.

— Аны бырачлар берни эшләтә алмайлар. Хәбирәттәйне алып килергә кирәк,— дип куйды шунда олы авызлы бер хатын.

Үземнең алда минем дәрәҗәне төшереп торган хатынга ачуым килеп куйды.

— Ышанмагач, чакырмаска кирәгие!— дидем, каты гына.

— Ышанам, балакаем, ышанам.— диде Тимерҗанның әнисе, ыңгырашып.— Ышанмаска менә! Шул да булдымы сүз, Маһирә җиңгәй... кешенең хәтерен калдырып...

— Минем хәтер калмый,— дигән булдым мин.

Аннары ыгы-зыгы килгән хатын-кызга борылдым да, кырыс кына:

— Тавышланмагыз әле,— дидем.— Авыру яныннан чыгып торсагыз да ярар.

Хатыннар мыштым гына чыгып киттеләр. Мин шун-

дук эшкә керештем. Апаның аягыннан ипләп кенә оекларын салдырып алдым. Җентекләп капшап карадым. Аяк таймаган да, сынмаган да. Күрәсең, сеңере тартылган, кан сауган.

Карап бетергәч, артыма борылдым да Тимерҗанга табак белән салкын су китерергә куштым.

— Аягыгызны хәзер салкын суга, бераздан җылы суга тыгып утырырсыз,— дидем апага.— Хәзергә йөрмәскә кирәк булыр.

— Йөрүләр юк инде ул!— диде апа.— Котым алынды. Сынгандыр дип торам. Мондый көнне кеше күзенә карап яту күңелле эш түгел, балакаем, Аллам сакласын.

— Курыкмагыз, ике-өч көннән төзәлер, бернәрсәсе калмас,— дидем мин.

— Шулай булсын, Алла бирсә, шулай булсын, балакаем,— диде апа, сүзчәнләнеп.— Имгәк аяк астында. Карап йөрмәсәң, Аллам сакласын, вакыт җиткәнне сизми дә калырсың.

— Әйттем мин сиңа!— диде Тимерҗан, әнисен шелтәләп.

— Әйткәч тә бит, балакаем,— диде әнисе.— Син эштә, атаңнан булмай, ул печәнне өяргә кирәк ләбаса. Тараудa яткырып булмай ич инде.

— Үзем өярмен дип әйттем ич!— диде Тимерҗан, үртәлеп.— Биек җирдә башың әйләнгәнне үзең дә беләсең. Кем кушкан сиңа анда менәргә?

— Казалгыры диген, ялгыш басканмын, сизми дә калдым,— дигән булды апа, акланырга тырышып.

Минем алда алар шулай җиңелчә генә әйткәләшеп алдылар. Мин кулыма сумкамны эләктердем дә чыгып китәргә җиендым.

— Балакаем, бырачны озатып куй, куркыр,— диде Тимерҗанның әнисе.

— Юк, юк, мәшәкатьләнмәгез! Курыкмыйм,— дидем мин, ишек тоткасына тотынып.

— Мин шул якка барам. Клубка,— диде Тимерҗан.

Бу сүзләрне ул болай гына сөйләнгән кебек әйтте. Үзең кара, миңа барыбер дигән сымаграк итеп кенә. Мин апаны караган арада, ул инде юынып, өстен-башын алыштырып өлгергән иде.

Без ишектән икәү бергә чыктык.

## XVII

Без Тимерҗан белән сөйләшми генә барабыз. Икәүдән-икәү генә булганда, җитмәсә, әле бер-берең белән тие-

шенчә таныш та булмаганда, нәрсә турында гына сөйләшәсең? Каян сүз табарга да, каян кыюлык табарга?

Барабыз әкрен генә атлап. Кайбер йортларда ут алганнар. Шулай да күпчелек өйләрдә бернинди җан әсәре күренми — әллә ятып беткәннәр, әллә үлеп беткәннәр. Бары тик оныткanda бер анда-санда эт өргән тавыш ишетелеп куя да, басынкы гына сөйләшкән, капка шыгырдаткан тавышлар ишетелгәли.

Чыш-пыш көлешеп, кызулап безнең яннан гына ниндидер кызлар узып китте. Бераз киткәч, берсе артына борылып карады, иптәшләренә нидер әйтеп алды. Кызлар, ераклашып, караңгыда юк булдылар. Берсенең ак күлмәк итәге озак кына күренеп барды.

Алар узып киткәч, мин, тагын берәрсе килмиме дигән сыман, артыма әйләнеп караган булдым, аннары күккә карап алдым. Күктә — йолдызлар. Шундый зур булып, якты булып күренәләр. Әллә соң ул төнне йолдызлар бөтенләй юк иде микән? Менә хәзер инде истән дә чыккан!

— Ник сез бер дә клубка чыкмыйсыз?— диде Тимерҗан, сүз башлап.

— Анда мин нишлим?— дидем мин.

— Нишлим дип инде...

— Мин бит клуб мөдире түгел, пункт мөдире,— дигән булдым мин, шаяртып.

— Клубта күңел ачарга була,— диде Тимерҗан.

— Минем күңел болай да ачык,— дидем мин.

Тимерҗанның шундук сүзе бетте. Сизеп барам: аның сөйләшәсе килә, ләкин минем тиз генә ачылып китмәвем эчен пошыра.

— Буш вакытларыгызны ничек уздырасыз соң?— дип куйды бу, тагын да бераз баргач.— Иртә йоклыйсыз, ахрысы. Тәрәзәгездә ут күренми.

— Тәрәзәләрне без мендәр белән томалыйбыз,— дигән булдым мин.

— Мәдрәсәләрдәге кебекме?

Аның бу сүзе миңа бик тапкыр булып тоелды. Мин нәрсә әйтергә дә белми калдым.

— Кичләрен без баскычка чыгабыз, бака тавышы тыңлыйбыз,— дидем, соңлап булса да.

— Бака тавышы гармун тавышына караганда күңеллерәктер ул?— диде Тимерҗан, көлемсерәп.

— Әйе, күңелле!— дидем мин.

Тимерҗан көлеп җибәрде.

— Тагынниләр эшлисез?— диде бу, башланган сүзгә өзелергә ирек бирмичә.

— Тагынмы? Китап укыйбыз. Таня татарча өйрәнә. Мин аны өйрәтәм, укытам.

— Кызык. Китаптан карапмы?

— Татарча мин китапка карамыйча да беләм,— димен мин.

Хәзер инде минем үз сүзләрем миңа бик тапкыр булып тоела.

— Сез унны кайда бетердегез?— ди Тимерҗан.— Татарчамы, русчамы?

Уку темасы — минем иң яраткан темам. Бу турыда мин сәгатьләр буе сөйләшә алам, үз-үземне, дөньямны онытып сөйләшә алам.

Ул төнне без чыннан да дөньяны онытып сөйләштек.

Безнең арада искәрмәстән нинди дер уртаклык барлыкка килде. Мин аңа үземнең моннан ике ел элек Яңавыл татар урта мәктәбен бетерүем, шуннан соң Уфага баруым, конкурстан үтмәвем турында сөйләдем.

Тимерҗанның да язмышы бөтенләй минеке төсле булып чыкты. Ул да моннан ике ел элек урта мәктәп тәмамлаган. Яңавылда түгел, Ямадыда. Ул да минем кебек үк институтка кермәкче булган. Бер үк елны! Ихтимал, Уфага без аның белән бер үк автобуска утырып баргандыздыр әле! Тимерҗан авыл хуҗалыгы институтына керергә исәпләгән. Беренче имтиханда ук «икеле» алган да, кайткан да киткән. Баштарак ул да минем кебек кайтмаска уйлаган. Ләкин аңа кайтмыйча ярамаган. Әтиәниләрен үзләрен генә калдырырга батырчылык итмәгән. Әнисе карт, әтисе аннан да картрак. Җитмәсә, гарип икән, авыр эшкә ярамый икән. Шуның аркасында Тимерҗанны армиягә дә алмаганнар.

Шулай итеп, кайткан да киткән. Кайткач, колхозга эшкә йөри башлаган. Нинди эш кушсалар, шуңа йөргән. Механизаторлар курсына җибәрмәкче булганнар — бармаган. Һаман институтка керү турында хыялланган. Кыш көннәрендә имтиханга әзерләнгән. Икенче елны тагын шул ук институтка барып караган. Тагын керә алмаган. Тагын Мәсәгуткә кайтып килгән. Икенче мәртәбә уңышсызлыкка очрау моның барлык хыялларын юкка чыгарган. Шуннан соң бөтенләйгә авылда торып калырга уйлаган. Былтыр көз аны бригадир ярдәмчесе итеп куйганнар.

Сөйләшә-сөйләшә, без клубны да, пунктны да узып киттек. Урам уртасында өелешеп йоклап утырган казларны уята-уята, авыл башына кадәр барып җиттек. Алдан килешеп куйган кебек, бер сүз әйтмичә, күперне чыктык та, басу юлы белән китеп бардык. Бераздан алда,

уң яктарак, караеп ферма каралтылары күренде. Фермага чаклы барып тормадык, кире борылдык.

— Инде бөтенләй укырга исәп юкмы?— дидем мин, әкрен генә.

Мин бу сүзләрне эчке бер киеренкелек белән, сагаюшомлану белән әйттем. Әйтерсең, әгәр дә мәгәр ул киләчәктә минем кебек институтта укырга уйламаса, ниндидер начарлык булырга мөмкин иде.

Тимерҗан эндәшмичәрәк барды.

— Юк дип әйтеп булмый,— диде ул, икеләнгәндәй итеп.— Синең кебек укыган кешеләрне күрсәм, авылга иптәшләр кайтса, студентлар... күңел тузына башлый. Кыен була, көнләшәсең, кызыгасың. Эшкә чыктың исә, онытыла.

— Гомергә шушында, шушы авылда калырга уйлыйсыңмы?— дидем мин, котым алынып.

Үзебез дә сизмәстән, без бер-беребезгә «син» дип эндәшә башладык. «Сез»не мин бөтенләй яратмыйм. Элекке байларны хәтерләтә. Аристократияне. «Син» ул шундый якын. Туганың кебек, әтиең-әниең кебек.

— Ник, калса ни булган? Мин шушы авылда туган кеше,— диде бу, тыныч кына.— Бөтен кеше шәһәргә китеп бетсә, авылда кем калыр?

Мондый сүзләрне мин кайдадыр ишеткән идемме, укыган идемме — хәтерләмим. Шулай да бу миңа чын күңелдән әйтелгән шикелле тоелды.

— Юк!— дидем мин, һөҗүмгә ташланган сыман.— Дөрес түгел, дөрес түгел! Ун класс бетер дә бригадир ярдәмчесе булып йөре, имеш! Ярый, бригадир да булдың ди, хәтта колхоз председателе де булдың ди. Шуннан соң нишләргә? Гомергә катып калыргамы? Авыл кешесе булып?.. Ышанмыйм. Шундый япь-яшь кеше...

Мин дәртләнеп, ялкынланып сөйләдем. Чын күңелдән сөйләдем. Үз сүзләремә үзем нык ышанганга күрә, Тимерҗан да ышаныр дип уйладым. Тимерҗан исә, бераз тын гына барды да, үзсүзләнеп:

— Алай түгел ул,— дип куйды.

Ул да моны үз-үзенә ышанып әйтте. Нык итеп әйтте.

— Мин дә баштарак шулай дип уйладым,— диде аннары.— Укырга, укырга, дидем! Безне бит шулай тәрбияләделәр. Ни өчен укырга, кем өчен укырга — рәтләп әйтүче булмады. Без уку өчен укыдык. Үзебез өчен. Укыган кеше шәһәрдә генә түгел, авылда да кирәк. Шуны безгә аңлатучы булмады. Хәзер әнә әйтеп карыйлар да, бер дә тәэсир итми. Әзме-күпме укырга-язарга өйрәндеме, шәһәргә таю ягын карый. Институткамы анда, техникумгамы...

Шулчак минем йөрәк сугып куйды. Тимерҗанга берәр усалрак сүз әйтәсем килеп китте. Ләкин тел очына бер генә усал сүз дә килмәде.

— ... институтка, техникумга эләгә алмый икән, һөнәрчеләр мәктәбенә керә, слесарьлыкка, токарьлыкка керә,— диде Тимерҗан.— Анысы да булмый икән, урам себереп йөрергә дә риза. Бары шәһәрдә генә булсын! Мин алай булдыра алмыйм. Шәһәрдә урам себереп йөрүгә караганда, авылда көтүче булу мең артык миңа.

— Кеше көтүчесе булып!— дидем мин һәм, искәрмәстән, пырхылдап көлеп җибәрдем.

Тимерҗан туктап калды. Миңа карап алды да бөтенләй үзгәргән чит бер тавыш белән:

— Көтүче дә кеше,— диде.— Менә... килеп җиттек. Хәзер инде курыкмассыз. Хушыгыз.

Кинәт каушап калдым. Үземнең ни дәрәҗәдә ахмаклык эшләгәнлегемне әле тулысынча аңлап та җитмәдем, шулай да сер сынатасы килмичә, тыныч булырга тырышып:

— Хушыгыз. Рәхмәт... китереп куюыгыз өчен,— дидем.

Тимерҗан, иңбашларын кызу селкетеп, ашыгып китеп барды.

## XVIII

Мин дә үзебезгә кереп киттем. Таня чыгып ишек ачты. Ул әлерәк кенә кинодан кайткан. Йокламыйча мине көтеп тора.

— Кайда йөрдең?— диде бу, гаҗәпләнеп.

Күңеле күтәренке. Күрәсең, кино ошаган.

— Чакырдылар. Бер авыру хатын янына бардым,— дидем, сүлпән генә.

Таня минем күңелсезлекне сизеп алды, борчылгандай итеп:

— Нәрсә, хәле бик авырмыни?— диде.

— Авыр,— дидем мин.

Шулай бер-ике сүз сөйләшкәләп, үз бүлмәбезгә кердек. Минем эч поша. Елыйсы килә. Үкенү тойгысы бөтен нәрсәнең астын өскә китерә. Нәрсә булды соң әле бу? Шундый күңелле башланган сөйләшү нишләп шулай күңелсез бетте соң әле?

Чишендем дә урынга яттым. Түшәмгә карап ятам. Күзгә йокы керми. Йокларга тырышмыйм да. Уйланам. Юк, уйланмыйм да. Ниндидер билгесезлек. Бүлмә эче кап-караңгы, тып-тын. Теге якта бүрәнә аша тонык кына

булып бала елаган тавыш ишетелә. Уй җепләре шул якка юнәлә. Дөнья кайгысы баскан укытучы агайны, аның йомры, бәләкәй хатынын кызганып куям. Миңа аларны еш күрергә туры килә. Йорттагы бар эшләрен хатыны эшли. Көн-төн печән ташый, сыер сава, бәрәңге бакчасында булаша, ашарга пешерә, балаларын карый. Эшли дә эшли, һич тик торганы юк. Агай шушы арада Яңавылда югалып торды. Аны Тау-авылга башлангыч мәктәпкә укытырга куйганнар. Өч чакрым җиргә ул җәяүләп йөриячәк. Ничек йөрер ул анда? Әллә күченеп китәрләр микән? Менә шәп булыр иде! Авыл Советы секретаре инде мине ике мәртәбә котыртып алды. Чыгыгыз дип әйт син аларга, ди. Мин, тиле, чыннан да әйттем, апа, кайчан чыгасыз инде, безгә бүлмә кирәк, дидем, без анда бала табу бүлеге ачарга уйлыйбыз, дидем. Апаның кәефе кырылды. Шуннан алар безгә рәтләп эндәшмәс булдылар. Өч балалары белән кая китсеннәр инде алар? Минем өчен барыбер түгелмени? Торалар икән, тора бирсеннәр.. Бала табу бүлеге ачу турында уйлап та карамыйлар алар... авыл Советында... Юри генә сөйләнәләр. Безнең тилелектән файдаланалар. Ул секретарь чыннан да бик алама кеше. Утыз яшькә кадәр өйләнмәгән. Авылда аны беркем яратмый, диләр. Мәкерле, эчкерле, диләр. Торсалар ни, тора бирсеннәр! Шул балаларны кызганмый ничек куалап чыгармак кирәк! Агай да кызганыч, хатыны да, балалары да кызганыч.

— Сиңа нәрсә булды?— ди Таня кинәт, мине уйларымнан бүлеп.

— Бернәрсә дә булмады,— димен.

— Юк, нидер булган сиңа.

— Кино күңелле булдымы соң?— дигән булам, сүзне икенчегә борып.

— Бик күңелле булды!— ди Таня.

— Клублары ошадымы соң?

— Ошады. Бик ошады!

— Нәрсәсе ошады соң?

— Бөтенесе дә. Халкы да, клубы да.

— Равил ошадымы соң?

— Ул да ошады,— диде Таня, көттеребрәк.

Аннары, никтер Равилне яклыйсы килеп, әйтеп куйды:

— Аксаклыгы гына бар,— диде.— Нәрсәсе ошамаслык? Син теләсә нәрсә диген, ләкин ул миңа ошый. Үзе кыю, шаян.

Мин эндәшмәдем.

— Миңа аның аксаклыгы бөтенләй сизелми,— диде бу, яңадан сүзгә башлап.

Күрәсең, шулай да күңелен тырныйдыр. Тырнамый ни, шәп нәрсә түгел инде ул аксаклык.

Мин тагын берни эндәшмим. Минем тын гына ятуны Таня хупламау дип уйлады, ахрысы.

— Мин үзем дә әллә ниткән чибәр түгел лә!— диде бу бераздан, үз-үзен кимсетеп.

— Син ябык, мин симез,— дидем мин, уфтанып.

— Шулай шул,— диде Таня, сөенеп.

— Юанлыкның беразын гына сиңа биреп булсыные ул!— дидем мин, буш хыялга бирелеп.

— Үзебез медик, үзебез берни булдыра алмыйбыз,— диде Таня.

— Шуның өчен укырга кирәк!

— Нәрсә-ә?

— Бер кешедәге юанлыкны икенче кешегә күчерү өчен!

Мин моны чынлап әйтәм. Бернинди шаярусыз. Таняга бу, күрәсең, кызык тоелды. Миннән көләргә тотынды.

— Ник көләсең?— дидем, тупас кына.

— Уку дип саташкансың инде син,— диде Таня, бераз тын ятканнан соң, җиңелчә шелтә белән.

— Нәрсә, әллә син дә шушы авылда торып калыреңмы?— димен, әтәчләнеп.

Мин моны тиргәшкәндәге кебек усалланып әйттем.

— Чынлап, тилергәнсең син,— ди Таня.

— Тилерсә тилерер, әйт, гомергә шушында торып калырыеңмы?— дип кычкырам мин.— Шулкадәр белемең була торып, сәләтең була торып, шушы караңгы авылда калырыеңмы?

— Ник калмаска, туры килә икән... кирәк икән, ник калмаска?— ди Таня, уйланып.

— Ә уку?

— Мин инде үземә кирәген укыган. Миңа җиткән.

— Ничек оялмыйсың шулай дип әйтергә?!— димен мин, кызганнан-кыза барып.— Япь-яшь көеңә! Шундый дипломың була торып!

— Нәрсәсеннән оялырга аның?

— Киләчәктә нишләргә уйлыйсың соң син?

Шулай димен дә, нәрсә әйтер икән бу дип, тынып калам. Мин моны үземчә бик авыр сорау дип, бик туры куелган сорау дип исәплим. Ләкин Таня һич тә аптырап тормый, гап-гади нәрсә турында сөйләгән кебек, тыныч кына:

— Бернәрсә дә эшләргә уйламыйм,— ди.— Үз эшемне тиешенчә эшли алсам, миңа шул җиткән.

— Юк, ул гына җитмәгән! Син дә укырга тиеш, институтка керергә тиеш! Ничек кенә авыр булмасын, барыбер керергә тиеш!

— Кирәге барые!— ди Таня, киреләнеп.— Унбер ел укыдым, җитәр. Тагын биш-алты ел ач торып туберкулез аласым юк.

Мондый сүз ишетеп, мин ни әйтергә дә белми аптырап калдым. Минем җен ачуларым килде. Аның шундый аңсыз булуына, шундый кире булуына, үземнең берни аңлата алмавыма ачуым килде.

— Укыйсым килми, кияүгә чыгасым килә!— дидем, мыскыллап.— Грибоедовның теге Митрофанушкасы кебек...

— Фонвизин...— ди Таня, төзәтеп.

— Ярый, Фонвизин да булсын,— димен, кинәт сүрелә төшеп.

Уй җепләре өзелеп тынып калдым. Шул вакыт мин тагын да Танының миннән белемлерәк икәнлеген аңлап алдым. Аннан наданрак була торып та, тилереп-тилереп аны укырга өндәвем үземә дә мәгънәсезлек булып тоелды. Шулай да мин үземнең хаклы икәнлегемне бик яхшы аңлыйм. Укырга, укырга кирәк! Бу мәсьәләдә минем карашны беркем дә, берни дә үзгәртә алмаячак!

— Әйт, кияүгә чыгасың киләме?— димен, Танының эндәшми ятуын күреп.

Мондый туры куелган сорауга Таня ничек җавап бирергә дә белми.

— Син уку турында хыялланасың, мин хыялланмыйм,— ди.— Нәрсә тагын ми черетергә? Миңа җиткән. Минем үз эшем бар. Бөтен кеше врач булып бетсә, кем акушер булыр? Алты ел буена мине кем туйдырыр?

— Үзеңне-үзең туйдырырсың!

— Стипендиягәме? Рәхмәт!

— Дүрт ел торгансың бит әле.

— Тордым. Әни ярдәм итте. Кайчанга чаклы ярдәм итәр ул? Юк, хәзер, киресенчә, мин аңа ярдәм итәргә тиеш.

Мин аңа каршы берни әйтә алмыйм. Билгеле, ул хаклы. Әти-әниләргә ярдәм итәргә кирәк. Ярый әле, минем әти эшли. Ул миннән бернинди ярдәм өмет итми. Үзеңне-үзең карый алсаң, безгә шул җиткән, кызым, ди. Күңеленнән, бәлки, аның да миннән ярдәм өмет иткән чаклары буладыр. Әйтми генәдер. Нәрсә алып кайтырга икән киләсе атнада? Әти белән әнигә генәме, әллә барысына дамы? Алар бит дүртәү. Өмет итсәләр, барысы да өмет итәдер. Танының рәхәт — әнисе дә әбисе.

Күңелгә шундыйрак уйлар килә. Минем инде бәхәсләшәсем дә килми. Барысы да надан, барысы да туң баш. Ничек аңламыйлар алар?!

Күңелдә шулай да бернәрсә калган икән әле.

— Бүгеннән кияүгә чыгарыеңмы, Таня?— димен, әкрен генә.

— Чыгарыем,— ди Таня.— Яраткан кешем булса... Ул мине яратса, мин — аны... Тотарыем да чыгарыем!

— Равилгә дә?

— Ә ник «дә»?— ди Таня, хәтере калып.— Әллә ул кеше түгел?

Мин телемне тешләп тынып калдым. Шул чакны кемдер колак төбендә генә: «Көтүче дә кеше!»— дигән кебек булды.

## XIX

Икенче көнне без соңгарак калып тордык. Нишләптер Зөһрә дә соңга калган. Минем кәеф кырылды. Көндәгечә иртәрәк килеп уятмаган өчен, Зөһрәгә ачуланмакчы да булып карадым, ачулана алмадым. Зөһрәнең дә йөзе чытык. Килеп керде, эндәшмәде-нитмәде, дөбершатыр килеп плитәгә ягарга кереште.

— Сиңа тагын нәрсә булды?— дидем, аптырап.

Зөһрә җавап кайтармады, ишетмәгән кеше шикелле кыланып, тышка чыгып китте. Чыккач авыруларга кычкырынып алды. «Нәрсә булган аңа? Кем кушкан аңа кешеләргә кычкырырга?»— дип уйладым ачу белән. Кергәч тә шул турыда үзенә әйтергә дип күңелемә салып куйдым. Ләкин эш сәгате башланганчы, Зөһрә бүтән күренмәде.

Юындым да, ашап-эчеп тә тормыйча, кабул итү бүлмәсенә чыктым. Таня бүген Кызыл Ярга, яңа туган бала янына барырга тиеш иде. Татарча әле яхшы аңламаганга, үзе белән Зөһрәне алып барыр дип сөйләшкән идек. Мин беренче авыруны кабул иткәндә, каяндыр ашыгып Зөһрә кайтып керде. Минем янда тукталып тормыйча, бу безнең бүлмәгә, Таня янына кереп әйләнде.

— Кызыл Ярга Таня хәзер үк бармакчы була,— диде, миңа каш астыннан карап.

Сөйләшү буенча Кызыл Ярга алар авыруларны карап бетергәч китәргә тиешләр иде. Мин аңлап алдым: Таня түгел, Зөһрә үзе китмәкче була хәзер үк. Берәр ашыгыч йомышы бар микәнни Кызыл Ярда? Дөресен генә әйтсә, ни булган инде!

— Ярый, барыгыз,— дидем, рөхсәт итеп.

Авыруларны мин үзем генә карадым. Үзем кешеләрне сораштырам, үзем әледән-әле тәрәзәгә карап алам, көтеп тору бүлмәсендә ишетелгән тавышларга колак салам. Кемнедер көтәм. Мин аны көтәм.

Мин аны көне буе көттем. Кичкә таба бу көтү газап-

лы бер тынычсызлыкка әйләнде. Күңелемнән әллә нәрсәләр уйлап бетердем. Ныклап торып уйлап карагач, мин үземнең бик нык гаепле икәнлегемне, бер дә юкка аның хәтерен калдырганлыгымны аңладым. Мин аңа «көтүче» дидем. Дөресен әйткәндә, мин аны үзем дә уйлап тапмадым. Мин аны, ахрысы, Зөһрәдән отып калганмын. Шулай да беренче мәртәбә диярлек күргән кешегә шулай дип әйтергә минем ни хакым бар? Мин кем аңа? Беркем түгел. Мин бары Саҗидә генә, пункт мөдире генә...

Уйлана торгач, үзем дә сизмәстән, шүрләп куйдым.

«Көтүче» дигән өчен әгәр дә мәгәр комсомол җыелышына куеп тикшертсә? Менә аннан булыр!.. Бик мөмкин. Персональ эш дип. Совет яшьләренә хас булмаган караш дип. Мещанлык, капитализм калдыгы дип... Шуннан торып сөйләрләр, кыздырырлар. Безнең Тимерҗанны көтүче дип атаган, диярләр. Ул көтүче булгач, без, алайса, көтүмени, диярләр. Сезне әллә Уфада шуңа өйрәтеп кайтардылар, иптәш Фәррахова, диярләр. Сез аксөяк, диярләр, безнең комсомоллар арасында андый мораль яктан череп таркалган кешеләр булмаска тиеш, диярләр.

Әйтмәгән кая ул — барысын да әйтерләр! Җитмәсә, «личное дело»га каты шелтә чәпеп куярлар.

Мин чын-чынлап куркуга төштем. Тотып кына күрсәтерлек бернинди гаебем булмаса да, үземне мин ниндидер җинаятьче итеп сизә башладым. Баскычка чыгып утыргач та, әле озак кына баш ваттым. Бары тик яныма Таня килгәч кенә, курку-өркү кимегәндәй булды. Аның чандыр гәүдәсеннән кочаклап алдым да, үз итеп, якын итеп, аны үземә табарак тарттым. Кызыл Ярда күргәннәре турында сораштырдым. Татарча өйрәнгән яңа сүзләрен әйттереп карадым. Шуннан соң Фатыйма-тау ягына, сүнеп барган кызгылт офыкка текәлдек тә, тынып калдык. Таняга да күңелсез, миңа да күңелсез. Икебезгә дә ямансу, бик ямансу.

## Икенче бүлек

Зөһрә белән безнең ара көтмәгәндә бозыла башлады. Минем моңа күңелем тырналды. Төрлечә уйлап карыйм: әллә соң хәтерен калдырдыммы, әллә бик тупас кыланаммы? Алай тупас та кыланмыйм шикелле, хәтер калырдай усаллык та эшләмәдем шикелле. Безнең эштә усалланырлык нәрсә дә юк. Бөтенебез өч бөртек кеше. Эш зур түгел, катлаулы түгел. Бер-береңне бер сүздән аңлыйсың. Көн дә бер үк төрле дип әйтерлек нәрсә башкарасың.

Гомумән, Зөһрәгә минем бер генә мәртәбә дә бәйләнгәнем юк. Мин кеше үзенә тиешлесен үзе аңлап эшләргә тиеш дип исәплим. Зөһрә шулай эшли дә. Аның бөтен җире ялт итеп тора. Идәндә беркайчан тузан, пычрак булмый, тәрәзә пәрдәләре, халатлар, сөлгеләр, җәймәләр беркайчан керле булмый. Үз эшен ул бернинди авырлыксыз башкара. Шулай булгач, аңа ничек бәйләнеп торасың? Аннары, ул үзе дә миңа беркайчан каршы сүз әйтми.

Шулай да ул үзен әллә ничек тота. Әйтерсең монда ул мөдир дә, мин аңа буйсынган кеше. Тик бу турыда ул әйтергә генә кыймый сыман. Башта ук ул үзен шулай тотты. Хәзер аның бу сәер кыланышы көчәйгәннән-көчәя бара. Элегрәк ул ике сүзнең берендә, Зина апа шулай итә торган иде дип, миңа үзенчә киңәшләр биргәләде, мине үзенчә тәнкыйтьләп алгалады. Аның киңәшләре еш кына урынсыз булды, шулай да мин ачуланмадым, берәр файдалы сүз ишетермен, бәлки, дип, еш кына аның сүзләренә дә колак салгаладым.

Хәзер ул әнә алай да сөйләнми. Минем белән бөтенләй диярлек сөйләшми. Сораган нәрсәгә бер-ике сүз белән генә җавап бирә дә тынып кала. Кайчагында, матур иреннәрен кысып, синең ишеләрне генә күргән бар инде дигән кебек, җилләнеп минем яннан узып китте.

Аннары, элегрәк ул кичләрен безнең белән утыра, чигү чигә, ләчтит сата иде. Хәзер инде эш сәгате беткәч, пунктта аны бер минут тотып булмый. Шундый төгәл — нәкъ вакытында килә, нәкъ вакытында кайтып китә. Эш сәгате булмаганда берәр эш кушып кара — һич тыңлата алмассың! Турыдан-туры каршы да килми, берәр төрле сәбәп кенә таба, шулай ди, болай ди... Ни әйтсә дә әйтә,— барыбер үзенекен итә.

Минем өчен бу чүп өстенә чүмәлә булды. Димәк, мине яратмый. Шулай да, нигә мине генә яратмыйлар икән болар? Барысы да... Юан булган өчен генәме, әллә холкым өчен дәме? Ниндирәк холыклы икән соң мин? Нинди генә

булмасын, мин бит барыбер усал түгел, мәкерле, эчкерле түгел. Мин бик йомшак бугай, тиз ышанучан, авырлыклар алдында тиз бөгелеп төшүчән бугай. Ләкин мин әле барыбер үз дигәнемне итәрмен! Мин әле барыбер үз-үземне яраттырырмын! Институтка керсәм, чын врач булып чыксам, минем алда әле Зөһрә ишеләр биеп кенә торырлар.

Мин шулайрак фикер йөрттем. Мин көлмәс, елмаймас булдым. Хәтта Таня белән дә элеккечә иркенләп сөйләшми башладым. Мин үземне ниндидер кысынкылыкта, ниндидер чик эчендә итеп сиздем. Әгәр дә мәгәр шул чикне үтеп чыктым исә, тагын берәрсенең хәтерен калдырырмын, ачуын китерермен шикелле тоелды.

Озакламый минем тормышта тагын да күңелсезрәк хәлләр килеп чыкты.

## II

Беркөнне кич, гадәттәгечә, баскычта моңаеп утырам — капка ачылган тавыш ишетелде. Мин дерт итеп киттем. Кемдер килә. Кем икән? Равилме, Тимерҗанмы?

Таня белән кинога барган теге кичтән соң, Равил тагын бер мәртәбә килде. Безнең белән юк-бар лыгырдап утырды. Ул көнне алар беркая бармадылар. Таняны ул бары татарча өйрәтте. Бәлки, тагын улдыр?

Әйе, ул. Мине күргәч тә елмаеп җибәрде, кычкырып сәлам бирде, үзенчә шаяртып алган булды.

— Бакалар бүген исерешеп беткәннәр, ахрысы, акыралар да бакыралар,— диде.

Ул инде минем бака тавышы тыңларга яратуымны белә. Үзенчә шуңа ишарәли.

— Шауламале,— дигән булам мин, кулымны селтәп.

Равил шаркылдап көләргә тотынды.

— Бака тавышын бик яхшы аңлыйсың, әллә үзең дә бака нәселеннән микән?— диде.

Безнең якта юан кешене «бака» дип үртиләр. Равил шулай күзгә карап «бака» дигәч, бик-бик кыен булып китте. Шулай да берни сиздермәдем, эчкә йоттым. Җитмәсә, үземне үзем тәнкыйтьләп алдым.

— Шулай шул, Равил, бака нәселеннән мин,— дигән булдым.

— Сиңа колхоз эшенә чыгарга кирәк, апасы,— ди Равил, киңәш итеп.— Синең эшең җиңел. Көч чыгарып эшли торган түгел. Кара әнә, авылда берәр юан кеше бармы? Барысы да чыра кебек, ха-ха-ха!

«Чынлап та, мин бит бер дә авыр эш эшләмим»,— дип уйлап алдым мин. Дөрес, мин һәр көнне гимнастика

ясыйм — сикерәм, бөгеләм-сыгылам. Уфада чакта паркка барып, йөгереп кайта торган идем. Монда алай йөгереп булмый. Йөгерер җир юк. Халык алдында уңайсыз да. Ләкин нәрсә ул гимнастика? Әти әйтмешли, үлмәс җанга бер сәбәп. Мин аның бернинди файдасын күрмим. Ягъни ябыгу буенча. Туктале, ял көннәрендә Яңавылга кайтмаска, колхоз эшенә чыгарга кирәк. Аннары менә бу өелеп яткан утынны да кисәсе бар. Кем киссен аны? Зөһрә барыбер үзе генә кисеп бетерә алмаячак. Иртәгәдән тотынырга кирәк.

Равил минем каршыда туктады да папирос көйрәтеп җибәрде. Бер-ике суыргач, ишеккә ымлады, тавышын әкренәйтә төшеп:

— Марҗа кызы өйдәме?— диде.

— Өйдә,— дидем мин.— Ул сине көтте. Укытучы шулай соңлап йөрми инде.

— Укытучы шулайдыр да, мин бит профессор!— диде Равил.

Күңеле күтәрелеп, ул тагын көләргә керешеп китте.

— Тизрәк өйрәт,— дидем мин.— Син өйрәткәнне ул ныграк исендә калдыра.

— Үрәтәм мин аны, апасы, үрәтәм!— диде Равил.

Сизелер-сизелмәс кенә аксаклап, кызулап, ул өйгә кереп китте. Баскычта мин үзем генә торып калдым. Үземнең иртәгәдән авыр эшкә тотыначагым турында, бер-ике ай эчендә ябыгып-нечкәреп калачагым турында хыяллана башладым. Моңарчы ничек мин бу турыда уйлый алмадым икән? Бит чыннан да, авылда минем кебек юан кешене сирәк очратасың. Очратасың да — авыру була. Минем бит бөтен җир таза. Менә дигән! Хикмәт нәрсәдә соң? Белмим. Институтта укыган булсам, билгеле, белгән булыр идем. Юк, болай да беләм бугай. Тән төзелешем шулай.

Утырам шулай юк-бар хыялга бирелеп. Искәрмәстән тагын капка шыгырдап куйды. Мин тынып калдым. Сагаеп бер йодрыкка йомарланып калдым. Монысы кем икән?

Тимерҗан! Кепкасын кырын салган. Нәкъ шәһәрдәгечә. Каян өйрәнгән ул аңа? Уфада өйрәнеп кайтты микәнни? Кыска җиңле ак ефәк күлмәк кигән. Кара чалбар. Монысы әле авылча — киң балаклы. Күкрәге киң, кулбашлары сөякчел. Гәүдәсе төз, матур. Биле нечкә. Битемуены, беләкләре кояшта янган. Башы чак-чак кына түбән иелгән. Күзләре, кемнәндер качкан кебек, әледән-әле читкә карый. Йөзе кыюсыз, адымнары ышанычсыз.

Атлар-атламас кына килде дә, минем танкеткаларыма карап:

— Исәнмесез, Саҗидә,— диде.

Мин күлмәк итәген тартыбрак куйдым. Үз-үземне кочаклап утырган көе, чак-чак кына башны калкытып:

— Исәнмесез,— дидем.

Шулай дидек тә, икебез дә сүзсез калдык.

## III

Тора торгач, ул да, Равил кебек, папирос кабызып җибәрде.

— Тәмәке тарту өчен монда җайлырак, ахрысы?— дидем мин.

— Нәрсә, әллә ярамый?— диде Тимерҗан, папиросын кулына алып.

— Ярый. Сезнең үпкә бит, минеке түгел,— дигән булдым мин.

— Үпкә генә түгел, йөрәк тә минеке!— диде Тимерҗан.

— Башыгыз кемнеке соң?— дидем мин.

Күңелем күтәрелеп, кисәк кенә көлеп җибәрдем. Тимерҗан да көлеп куйды.

— Анысы да әлегә үземнеке,— диде.

Без шулай көлештек тә тынып калдык. Беравык утыргач, мин җитди генә сорап куйдым:

— Әниегезнең хәле ничек?— дидем.

— Йөри, сезнең дәва килеште,— диде Тимерҗан.

Тагын сүзсез калдык. Күреп торам: аның нидер әйтәсе килә, тик әйтә генә алмый. Як-ягына карана, папиросын чәйни, иңбашларын җыера.

— Таня өйдәме?— диде бу бераздан, сүз югында сүз булсын өчен генә.

— Ул кирәкмени?— дидем мин.

— Кирәкми дә...— диде бу, ы-мы итеп.

— Кирәк булса, чакырып чыгарам.

— Болай гына...

— Алай икән.

Тагын сүз бетте.

— Нишләп алай ятим бала кебек басып торасың, утырып тор,— дигән булдым мин бераздан.

— Багана авып китәр дип куркам,— диде бу.

— Әллә үзең авып китүдән куркасыңмы соң?

— Үзең дә аварсың... син әнә нинди усал!

— Бик куркынычмыни?— дидем мин, көлеп.

Миңа ияреп бу да көлде. Икебезгә дә яңадан күңелле булып китте.

— Медиклар усал була икән дип ишеткәнием, шулай икән,— дигән булды бу.

— Минем бригадирлар турында ишеткәнем бар,— дидем мин.

— Бригадир ярдәмчеләре усал булмый,— диде бу, юаш кына.

Шулчакны Равилнең сүзләрен искә төшердем.

— Тимерҗан,— дидем,— миңа да колхоз эшенә әйт әле!

— Пунктта әллә эш юк?— диде Тимерҗан, сүзне уенга борып. Күрәсең, мине шаярта дип уйлады.

— Пунктта да эш җитәрлек,— дидем мин.— Ял көнне... Минем дә эшләп карыйсым килә.

— Чынлап әйтәсеңме?— диде бу.

Шундук җанланып китте, сөялгән баганасыннан купты да бер-ике адым миңа таба атлап куйды.

— Хәзер кеше бик кирәк. Чынлап әйтсәң, мин сезнең өчегезгә дә эш табам.

— Әйе, өчебезгә дә!

— Элек сезнекеләр чыга торганые. Кеше тапмадык исә, шушында килә торганыек. Аннан соң — укытучыларга әйтәсең. Алайса, чынлап?

— Чынлап, чынлап!— дидем мим.— Берәр авыррак эшкә... көч чыгарып эшләрдәй эшкә...

«Кара, мин нинди таза!»— дип шаяртмакчы булдым, шулай да тыелып калдым.

— Мин сезне, алайса, капчык ташырга куярмын,— диде Тимерҗан, көлеп.

— Була, теләсәң нинди эшкә куй.

— Юк, чынлапмы?— диде бу тагын да.— Амбар алдында таудай бодай өелеп ята. Кыза. Әйләндерергә, җилләтергә кеше кирәк.

— Бүген җомга, иртәгә шимбә,— дидем мин, көннәрне санап.

— Теләсәгез, үз эшегез беткәч, төштән соң да барырга була,— диде бригадир ярдәмчесе, әрсезләнеп.

— Төштән соң булмый. Авылларга чыгарга кирәк. Иртәгә Түбән Чатка барабыз.

— Ник?

Мин «ник» икәнлеген аңлатырга өлгерә алмый калдым. Шулчакны капкадан тагын кемнеңдер килеп кергәне күренде.

## IV

Зөһрә икән. Никтер җилләнеп килә. Җилләнеп кенә дә түгел, тузынып килә! Йөзе җимерелгән, кыска чәчләре тузгыган. Үзе әле генә мунча кереп чыккан шикелле. Кып-кызыл. Әллә чынлап та мунча кергән.

Ниндидер күңелсез сөйләшү буласын сизенеп, шып булдым. Пунктта эшләүче кешенең, үземә буйсынган кешенең шулай тилереп йөрүе өчен Тимерҗан алдында миңа оят булып китте.

— Ни булды, Зөһрә?— дидем, тыелып кына.

— Булмады,— диде бу.— Таня кирәк.

Шулай тупас кына җавап кайтарды да йөгереп баскычтан менде, җилләнеп, тузынып чоланга кереп китте. Тимерҗан да, мин дә сүзсез калдык. Зөһрә чын-чынлап минем котны алды. «Тагын нәрсә булган инде моңа?» — дип уйладым, тынычсызланып. Ник шулай тупас кылана ул? Ярамый болай, ярамый! Ныгытып әйтергә кирәк. Кем мин аңа?!

Мин аның артыннан кермәкче булдым, кереп сораштырмакчы яисә, аңлашып булмаса, тиешенчә үзен кыздырып алмакчы булдым. Ләкин аның кыяфәтен исемә төшердем дә тыелып калырга мәҗбүр булдым. Аннан соң өйдә бит Равил бар! Чит кеше алдында аның минем белән тагын да тупасрак сөйләшүе мөмкин.

— Шундыйрак кеше инде ул Зөһрә,— дип куйды Тимерҗан, бер дә юктан көрсенеп.

Ул чакта мин аның бу сүзләрне ничек әйтүенә дә, кыяфәтенә дә игътибар итмәдем. Мин бары үз уйларым белән генә мавыктым. Соңгы көннәрдә Зөһрә белән икебезнең арада барлыкка килгән салкынлык тагын эчне тырнап куйды. «Ничек яраргa да белмәссең боларга!» — дидем үз-үземә, ачынып.

Шул вакыт дымлы җил исеп куйды. Һавада инде баядан бирле яңгыр исе килә иде. Көнне караңгылатып җибәрде. Күршеләрнең биек тупыллары сызланып-сыкранып шауларга тотынды. Ашыгып, астан гына ниндидер кошлар очты.

Мин аягүрә бастым. Түбә астынарак елыштым.

Без Тимерҗан белән сөйләшмәдек тә, аерылышып та китмәдек. Нидер көткән сыман, бер-беребезгә карашып тик тордык. Минем хәзер Зөһрә янына керәсем килмәде. Тимерҗанның да тиз генә кайтып китү исәбе юк иде, ахрысы.

Шапылдап такта түбәгә берән-сәрән яңгыр тамчылары килеп төште.

— Бер дә вакытсыз булды әле бу,— диде Тимерҗан.— Эх, харап итә инде, чылата инде!

— Нәрсәне чылата?— дидем мин.

— Нәрсәне! Ашлыкны. Ындыр табак тулы бодай!

— Өстен ябып куеп булмыймыни?— дидем мин.

— Кая инде хәзер!— диде Тимерҗан, кулын селтәп.

— Алайса, йөгер тизрәк!— дидем мин, ашыктырып.

Еракта агач яфракларына, өй түбәләренә, киртә-коймаларга каты бәреп, чыбыклап явып килгән яңгыр тавышы ишетелде.

— Юк, булмады инде!— диде Тимерҗан.— Кешеләр бар да соң анда. Япсалар ярый да...

— Син үзең бар! Йөгер тизрәк!— дидем мин, кыстап.— Өлгерерсең әле, йөгер!

Күреп торам, аның үзенең дә йөгерәсе килә. Тик әйтәсе ниндидер сүзе булгангамы, ничектер, тәвәкәлли алмый тора.

— Алайса, кер, чыланасың бит,— дидем мин.

— Юк!— диде Тимерҗан кинәт.— Киттем! Соңыннан... Хуш. Сау бул!

Шулай диде дә капкага йөгерде. Менә шыгырдап капка ачылды, шапылдап ябылды. Шул ук вакытта диярлек бөтен дөньяны томалап яңгыр да килеп җитте.

Тимерҗан китеп бер-ике минут узмады, ишекләрне шап-шоп бәреп, Зөһрә килеп чыкты. Эндәшмәде-нитмәде, биек үкчәле туфлиләре белән такта басмаларны дөбердәтеп җиргә төште. Төште дә, коя башлаган яңгырга да карамастан, капкага ташланды.

«Аңламассың бу халыкны!»— дидем, аптырап. Чолан ишеген бикләдем дә өйгә кердем.

## V

Равил әле китмәгән. Таня белән икесе, көлешеп-шаулашып, ярым русча-украинча, ярым татарча нидер гәпләшеп утыралар.

— Яңгыр ява,— дидем мин.

— Нарся?— диде Таня.

— Яңгыр йа-ва,— диде Равил, минем сүзләрне кабатлап. Аннары шул ук сүзләрне русчага тәрҗемә итте: — Дож... дож... Ничек әле, апасы?

— Идет,— дидем мин.

— Дож идйот!— диде Равил, сөенеп.— Яле, кабатла татарча: яңгыр йа-ва...

— Ян-гр я-вы,— диде Таня, аның артыннан кабатлап.

Үзе никтер көләргә кереште.

— Зөһрә ник килгән?— дидем мин Таняга, русчалап.

— Татарча скажи!— диде Таня, үзенең татарча бик яхшы белгәнлеген күрсәтмәкче булып.

— Зөһ-ра ник кил-гән?— диде Равил, минем сорауны кабатлап.

— Зохра зачем... идет?— диде Таня, аңламыйча.

Равил аңа төшендереп бирде.

— Нинди Зөһрә?— диде Таня, миңа карап, гаҗәпләнеп.— Кайчан килде?

— Әле генә.

— Безнең янга беркем кермәде,— диде Таня.

— Кермәде?

— Юк, кермәде,— диде Равил дә.

— Ник кермәсен! Синдә йомышым бар диде ич!

— Кермәде, апасы, кермәде. Ни пришол!— диде Равил, кычкырып.

— Конечно, «ни пришол»,— диде Таня, көлә-көлә.

Мин уйга калдым. Димәк, ул мине алдаган! Холыксызлыгы өстенә, аның әле алдаша торган гадәте дә бар икән! Ник килгән соң ул шулай да? Нинди йомыш белән? Теге якта булды микәнни?

Мин кабул итү бүлмәсенә чыктым. Андагы әйберләрне караштырдым. Бөтен нәрсә үз урынында. Әллә соң көндез онытып калдырган берәр нәрсәсен алырга килгәнме? Алай дисәң, чыгып киткәндә кулында бернәрсә дә юк иде шикелле.

Мин яңадан үзебезнең бүлмәгә чыктым. Тәрәзә каршысына килдем дә пыяла аша урамга, коеп яуган яңгырга карап тора башладым. Минем әллә ничек эчем пошты. Шулай да күңелдә эч пошуга караганда да зуррак бер хис бар, җылылык, өмет-куаныч бар.

Ә бит ул килде! Димәк, ярата! Чынлап та... ярата микәнни?..

Минем йөрәк дәртләнеп, ашкынып типте. Соломон Моисеевич онытылды. Ни әйтсәң дә, ул ерак. Күктәге йолдызлар кебек ерак. Аның турында бары хыялланырга гына була. Тимерҗан турында хыялланырга да, нык-лап торып уйланырга да була. Ул монда гына, якында гына. Аны күрәсең, тоясың. Аның белән сөйләшәсең. Ул йолдыз да түгел, ай да түгел. Ул — кеше. Күптән инде мин теләгән, мин күңелемдә йөрткән кеше...

Чынлап та, миңа әллә нәрсә булды. Әллә ничек җиңеләеп калдым дип әйтимме... кинәт кенә дөнья үзгәрде дип әйтимме... Шундый якты, җиңел, рәхәт!

Шул ук вакытта нидер куркытып, котны алып тора. Нәрсә соң әле бу? Тукта, нәрсә булды әле миңа?

Мин, әйтерсең, бар көчемә чабып барганда, искәрмәстән абынып киттем. Абынмадым да, маңгаем белән ташка, баганага... стенага бәрелдем. Күземнән утлар күренде. Йөрәгем жу итеп китте. Мин Зөһрәнең ни өчен тузынып йөрүен аңлап алдым! Ни өчен моңарчы миңа карата салкын булуын, ни өчен мине яратмавын, күралмавын аңлап алдым!

## VI

Иртән безне Зөһрәнең җиңгәсе Рафика апа килеп уятты. Аның безгә элек тә килгәне бар. Ул әле күптән түгел генә баладан котылды. Өйдә бала карап ята. Ул — башкорт. Безнең якта әйтелгәнчә, чи башкорт, ягъни кара башкорт. Зөһрәнең абыйсы Хисам абый аны былтыр Учалы ягыннан алып кайткан.

Рафика апа бик матур. Минем аңа караган саен карыйсым килә. Кайчагында мин аңа гашыйк булам шикелле. Чынлап. Анда бернинди усаллык, бернинди эчкерлелек юк кебек. Ул юаш, тыйнак. Шулай да ул җебегән түгел. Ул теләсә кемне үзенә карата ала торган тыйнаклык белән тыйнак. Ул, чын башкортларның күпчелеге төсле, кап-кара. Чәчләре кара, кашлары кара. Кайсыдыр ягы белән ул Зөһрәгә дә охшаган сыман. Ләкин Зөһрә тере, елгыр, җитез. Рафика апа — салмак, йомшак һәм бераз гына моңсу, боек. Бәлки, ул тумыштан шулай моңсудыр, бәлки, туган якларыннан читтә-еракта яшәү аны шундый иткәндер — әйтеп булмый. Ни генә булмасын, моңсулык аңа бик килешеп тора. Ә хәзер ул бераз гына сулыга, ябыга төшкән.

Ишек төбендә Рафика апаны күргәч, мин елмаеп җибәрдем, ишекне ныграк ачтым да:

— Исәнмесез, Рафика апа, керегез,— дидем.

— Исәнме, Саҗидә,— диде Рафика апа.— Зөһрә урынына килдем әле. Нимә әйтерһең тагы.

Зөһрә исемен ишетү белән, чыраем бозылып китте. Күз алдына кичәге кыланышы килеп басты.

— Зөһрәгә ни булган?— дидем, сагаеп.

— Авырып тора. Соланды юасы бар тигәйне ул.

«Авырган, пычагым!»— дидем үзалдыма. Шулай да Рафика ападан сораган булдым:

— Нәрсә булган? Кай җире авырта?— дидем.

— Кисә ямгырга эләккән. Башы авырта,— диде Рафика апа.

— Алай икән,— дидем мин.

— Һин борсылма, Саҗидә,— диде Рафика апа, юатып.— Бетәр әле. Иртәгә ял. Һин әйт тә нимә кәрәген, үз эшеңдә бул.

— Ярар, алайса, Рафика апа,— дидем мин.— Мичкә ягып, шприцларны кайнатырбыз да, шуның белән эш бетәр.

Мин аңа кайдан нәрсә алырга, шприцларны ничегрәк кайнатырга кирәклеген әйттем дә, сабын, сөлге алып, тышка юынырга чыктым.

«Борчылам! Зөһрә өчен борчылам!»— дип уйладым, күңелемнән Рафика апа белән бәхәсләшеп. Бөтенләй килмәсә дә исем китми. Чыннан да, килмәсә нинди шәп булыр иде! Аның урынына Рафика апа калса... Тимерҗан бит аның янына килмәгән, минем янга килгән! Үзе килгән. Мин гаепле түгел. Зөһрә теләсә нишләсен. Минем анда эшем юк. Теләсә нишләсен...

Ә тышта шундый күңелле! Җир әле кичәге яңгырдан соң кибеп тә өлгермәгән. Үләннәр юеш, сукмак юеш. Киртәләр, өй түбәләре юеш. Шатланып кояш елмая, шатланып кошлар сайрый! Чиләкләрен сайратып, кемдер тыкрыктан аяк очка суга төшеп бара. Минем турыдан узганда, киртә аша миңа карап алды. Ә мин, авыз читләрен акка буяп, тырышып-тырышып щетка белән теш чистартам.

Тимерҗан кичәгенәк амбарга барып җитә алды микән? Юктыр. Кая ул анда барып җиткү! Ашлыклары чыланды микән? Бит без иртәгә эшкә чыгачакбыз. Чыланса яхшы булыр иде. Мин бер минут туктамый эшләр идем. Тимерҗан шунда булыр. Минем ничек эшләгәнне күреп, сокланып карап торыр. Ул болай да миңа сокланып карый. Чынлап. Валлаһи менә! Кояштыр!

Туктале, алайса, мин Зөһрәдән дә матуррак булам түгелме соң? Булмас ла! Ник булмас икән соң? Төскәбиткә алай котсыз түгелмен лә. Түгәрәк бит, кара куе чәч. Минем күзләр матур, тешләр, иреннәр... Үзем дә беләм, әйткәннәре дә бар. Тик менә шул әлеге дә баягы... юанлык кына...

Һы... бәлки, ул мине яратмый дадыр. Әйе шул. Зөһрәнең көнләшеп йөрүе генә аның мине яратуы була алмый бит әле. Да-а... Менә сиңа кирәк булса! Мин, тиле, тагын әллә нәрсәләр уйлаган булам. Менә сиңа кирәк булса!

## VII

Таня иртән беркая бармады. Икәүләп авыруларны кабул итеп бетердек тә, көндезгегә күкәй тәбәсе куырып ашадык. Аннары юлга әзерләнә башладык: кечкенә сумкаларга кирәкле даруларны, коралларны салдык, халатларны салдык. Тик менә бинтны гына бик аз алырга туры килде.

Бинт дигәннән, бинт бик күп бетә. Һәрбер яраны медицина кушканча бәйли башласаң, безнең айлык запас бер атнага да җитмәс. Ә җәй көне яралану аеруча күп була.

Юл уңаенда без авыл Советына да кереп чыкмакчы булдык. Акча сорап карарга кирәк. Бинтсыз бернәрсә эшләп булмаячак.

Авыл Советында көндез кеше булмый. Бүген дә шулай. Председатель өйдә юк, каядыр киткән. Үз бүлмәсендә секретарь гына утыра. Кайчан кермә, һәрвакыт бер урында. Нидер язган була, сызган була. Язмасасызмаса, газета караштырган була. Дөресен әйткәндә, мин аны яратып җиткермим. Алай гына да түгел, бөтенләй яратмыйм! Шулай ук ул да мине яратмый, ахрысы. Ул надан. Нибары җиде класс бетергән, шулай да үзен белдекле итеп, зур кеше итеп тотарга тырыша. Бер кереп утырган да, утыра да утыра. Эшнең җаена төшенеп алган — берничек кузгата алмассың! Күрәсең, шуңа күрә дә өйләнә алмый торгандыр, бичара. Урынын ташлап китәргә куркадыр. Кызлар артыннан йөрергә вакыты юктыр. Шулай да аны Зөһрәнең апасы Фәгыйлә апа белән йөри дип сөйлиләр.

Фәгыйлә апа Зөһрәдән дә матуррак. Исең китәр, аларда гына булыр икән бар матурлар! Фәгыйлә апа сыер фермасында эшли. Бозау карый. Алдынгы. Иң алдынгы. Аны инде, мин монда эшли башлаганнан бирле генә дә, ике мәртәбә район газетасына мактап язып чыктылар. Гаҗәп, чынлап та йөриләр микәнни? Никтер ышанасы килми.

Без Таня белән килеп кергәч, секретарь өстәленнән башын калкытты да коры гына сәлам алды. Нурсыз күзләрен чекрәйтеп, безгә төбәлеп калды.

— Вәзир абый, бинт бетте,— дидем мин, үпкәләгән сыман.

— Бинт бетте?— диде секретарь.— Бетсә ни, миндә бинт фабригы юк ла!

И ачуым да килә шулай кыланып сөйләшкән кешегә!

— Акча кирәк бинт алырга,— дидем мин, катырак булырга тырышып.

— Квартал бетми торып, кәпикә дә юк.

— Нишләргә соң алайса? Бинт бетте бит!

— Саклабрак тотыгыз.

— Саклап тотыйм дисәң дә булмый.

— Юк. Смитада күпме каралган, барысын да алгансыз.

— Сметада минем эшем юк,— дидем мин.

— Сезнең эшегез булмаса, минем эшем бар. Смита — минем өчен закун,— диде секретарь, коры гына.

— Миңа бинт кирәк — теләсә каян табыгыз,— дидем мин, киреләнеп.— Инфекция булса, үзегез җавап бирерсез.

— Карале, сеңлекәем,— диде секретарь, тыныч кына. Аның бу тынычлыгында миңа карата үтергеч өстенлек сизелде.— Нәрсә, син монда миңа акыл өйрәтергә кердеңмени?

— Теләсәгез нишләгез — инфекция булса, үзегез җавап бирерсез!— дидем мин тагын да.

Шулай дидем дә, кызып-кайнарланып, ишеккә ташландым. Ләкин болай гына да күңел басылмады. Кырт кына борылып яңадан өстәл янына килдем, яңадан үземнекен тукырга тотындым: медицина бу, дидем, монда кешенең язмышы хәл ителә, дидем, берничә метр чүпрәк аркасында, кешеләр гомергә гарип калырга, уларга мөмкин, дидем. Секретарь эндәшмәде, ике кулын иягенә таянып, әллә кем булып, сүзсез генә утыруында булды.

— Әйдә инде киттек,— диде Таня, күлмәк итәгеннән тартып.

Ул мине, көчләп диярлек, ишеккә таба алып китте.

## VIII

— Туктагыз әле!— диде кинәт секретарь, нидер исенә төшеп.

Без туктадык, кире килдек.

— Сез нәрсә анда пунктта егетләр җыеп ятасыз?— диде бу, нурсыз күзләрен миңа төбәп.

— Нинди егетләр?— дидем мин, берни аңламыйча.

— Нинди егетләр икәнлеген үзегез беләсездер инде,— диде секретарь, мыскыллы көлемсерәп.— Соңгысы булсын. Беренчелеккә гафу итәм.

Ул шулай диде: «Беренчелеккә гафу итәм»,— диде. Шундый гарьләндем, шундый хурландым, кинәт бөтен эчем-тышым ургып кайный башлады.

— Кем әйтте, кем әйтте?— дидем.

— Сүз иясе белән йөрми,— диде секретарь.

— Дөрес түгел!— дип кычкырдым мин, әллә нинди чәрелдек тавыш белән.

Борылдым да, ярсуымны баса алмыйча, Таняга тәрҗемә итеп бирдем. Таняның да йөзе үзгәреп китте.

— Пунктта кеше җыеп ятырга рөхсәт ителми,— диде секретарь, русчалап.— Пункт — медицина учреждениесе. Егетләр белән йөрисегез килә икән, клубка барыгыз. Аулагөй ясап ятырга анда!

— Кем әйтте, кем әйтте?!— димен мин, бер үк сүзне кабатлап.

— Сез нәрсә, сахрада яшибез дип белдегезме әллә?— диде секретарь.— Кем әйтсә дә барыбер түгелмени? Сез-

нең тирә-ягыгызда кешеләр. Күршедә дә кешеләр, стена аша да кешеләр...

— Ә-ә!— дидем мин, искәреп.— Стена ашамы? Күршеләрме? Ярый, сорыйбыз хәзер!

— Сорыйсы юк,— диде секретарь.— Әйттем бит: беренчелеккә гафу итәм, икенче кабатланса...

— Юк дип әйттем бит, юк!— дип кычкырам мин, еларга җитешеп.

— Нәрсә, әллә безгә кеше дә килмәсме?!— диде Таня да, сүзгә катышып.— Без төрмәдә түгел.

— Пунктта не положено. Ярамагач ярамый. Пункт — совет учреждениесе...

— Юк дип әйттем бит, юк!— дип кычкырам мин, борып куелган машина кебек.

«Егетләр җыеп яту» дигәнне мин бөтенләй начар, әдәпсез мәгънәдә аңлыйм. Равилнең, Тимерҗанның килүен исемә дә кертеп чыгармыйм. Шуңа күрә миңа монда коточкыч гаделсезлек, мәкер һәм яла бар кебек тоела. Секретарьга минем нәкъ менә шуны аңлатасым килә. Ләкин ул мине тыңламый да. Күрәсең, аның тыңлыйсы да, аңлыйсы да килми. Аның үз сүзе сүз. Ул кире. Кире генә дә түгел, ул агач, таш! Аңа әйтсәң ни дә, әйтмәсәң ни. Безне егетләр җыеп ята дип әйткән икән, аның өчен ул — закон, смета кебек үк закон.

Мин кычкырындым, кычкырындым да тыела алмыйча елап җибәрдем. Ике күздән кайнар яшь атылып чыкты. Борылдым да, борын суын тарта-тарта, йөгердем урамга. Елый-елый пунктка кайттым. Күңелемнән күршеләрнең тетмәсен тетмәкче булам. Капканы ачу белән, иң әүвәл тәрәзәләренә карадым, аннары сыер абзарлары ягына карадым. Бәләкәй, йомры хатын абзар тирәсендә печән өеп ята. Туп-туры шунда киттем.

Өсте-башы начар гына. Күлмәге арка турысыннан тишелеп чыккан. Башына бәйләгән яулыгы тузган. Бөтен киемендә, бөтен кыяфәтендә ярлылык, мескенлек күзгә ташланып тора. Йөзе ябык, күзләре генә утырып калган. Каршысына барып бастым да, күз яшьләремне йота-йота:

— Нәрсә дигән сүз бу, Заһидә апа?!— дидем.— Бездә ни эшегез бар сезнең? Минем нинди начарлыгым тигәне бар сезгә? Йомшак дигәч тә, басмакчы буласызмы...

Күрше хатыны эшеннән туктады, алъяпкыч итәге белән тирләгән битен сөртте, берни аңлатмый торган күз карашы белән миңа күтәрелеп карады.

— Туктале, тукта, Сәҗидә,— диде, каушап.— Аңлатып сөйлә: ник алай бер дә юктан тузынасың?

— Тузынмассың! Бер дә аңлатасы юк! Вәзиргә барып

безне әләкләп йөрмәсәгез, эчегез күбәме әллә?! Аулагөй ясап яталар дип... Кайчан күрдегез бездә аулагөй?

— Берни әйткәнем юк, Саҗидә!— диде күрше хатыны.

— Бүлмәдән чыгыгыз дигәнмен икән дә, шул ошамаган,— димен мин, аны тыңламыйча.— Әллә мин әйткәнме аны? Секретарь куша ич! Миңа димәгәе!..

— Бөтенесе дә шул корыган бугаз аркасында!— диде күрше хатыны, борынын тартып.

Мин тагын нидер такылдарга тотындым. Ләкин Таня шунда кулдан тотып алды.

— Җитәр! Киттек, соңга калабыз,— диде.

Мин үзебезнең кая барырга җыенганлыгыбызны исемә төшергәндәй иттем, Таняга буйсынып, урынымнан кузгалып киттем.

Түбән Чатка без җәяүләп бардык. Дүрт чакрым араны күз ачып йомганчы үттек.

## IX

Түбән Чатта без көтү кайтканчы булдык. Авылны бөтенләй йөреп чыга алмадык — иллеләп йортта гына булдык та кайту ягына борылдык.

Мәсәгуткә без караңгы төшкәндә кайтып кердек. Эттәй арып-алҗып кайттык. Шыгырдатып капканы ачтык, ишекне ачтык та, тып-тын чоланда тавыш ясап, өйгә кердек.

Бүлмәләрдә шомлы тынлык. Тынлык кына да түгел, тарлык, кысынкылык. Давыл инде басылган, тик шулай да күңел әле тулысынча тынычланып җитмәгән. Өйдә дә торасы килми, тышка да чыгасы килми.

Бик нык ашыйсы килә. Ашарга әзерләргә кирәк. Ашыкмыйча гына, теләмичә генә, Таня белән икәүләп, плитә янында кайнаша башладык.

Шул чакны әкрен генә теге якның ишеге ачылды. Серле генә, мыштым гына атлап, кемдер безгә таба килә. Икебез дә тынып калдык. Тыңлап торабыз. Мин инде андагыларның аяк тавышларын таныйм. Безгә керүче кеше укытучы агай булырга тиеш. Кәрим абый.

Менә ул ишеккә килде, ишек шакыды.

— Керергә буламы?— диде.

— Керегез,— дидем мин.

Керде дә, анда-монда сөрлегеп, түргәрәк узды. Өстәл янына ук барып җитмәде, туктап калды. Кулында тәмәке. Үзе белмәгәч, мин инде монда тартырга ярамый дип тормадым. Тешне кысып, аның сүз башлавын көтәм. «Мине сүгәр өчен килгәндер инде»,— дип уйлыйм.

— Сеңнекәш,— диде бу, миңа эндәшеп.

Карлыккан эчке бер тавыш белән, әрнеп, газапланып әйтте.

— Заһидә апаңны юкка рәнҗеткәнсең,— диде әкрен генә, серле бер тантана белән.— Юкка, сеңнем. Без андай кеше түгел. Син алай яңгышма. Вәзирне мин синнән күбрәк беләм. И әйтәм, син әле яшь. Кеше сүзе буенча харап була күрмә. Дөнья иркен — сиңа да җитәр, безгә дә.

— Сез миңа шуны әйтергә кердегезме?— дидем мин, кызарынып.— Рәхмәт киңәшегезгә. Мин инде ишеткәнем бар.

Шулай дидем дә, эре генә атлап, өстәл янына килдем, өстәлдән, китаплар арасыннан нәрсәдер эзләгән булдым, актарган булдым. Күршенең болай да ябык, нурсыз йөзе тагын да агарынып китте. Куллары калтырана башлады.

— Сеңнем,— диде бу.— Рәнҗемә. Нахакка... Без андай кеше түгел. Син безгә кысык итмәйсең, без — сиңа... Заһидә апаң белән икенче тавышланасы булма! Ишетсен колагың! Әйтәсе сүзең булса, үземә әйт. Аның нирбы начар... башы... йөрәге...

Алпан-тилпән атлап, калтыранып бу урынынннан кузгалып китте.

— Куркытмагыз,— дидем мин.

— Юк, куркытмыйм,— диде агай.— Әнә... аяктан җыгылды... ята. Өч бала белән торып каласым килми минем.

— Егылды?!— дидем мин, котым алынып.

— Ышанмасаң, кереп кара. Авырсынсаң, иртәгә Йөгәмәштән бырач чакыртам.

Йөрәккә ут салып, шом салып, ул чыгып китте. Бүлмәдә әчкелтем тәмәке төтене исе торып калды. Чоланда агайның өстерәлеп атлаган аяк тавышы, тишек комганнан идәндәге чиләккә тамган тамчы тавышы ишетелеп торды.

— Нәрсә булган?— диде Таня, каушап.

Сүзнең нәрсә турында барганлыгын чамаласа да, ул, күрәсең, ныгытып аңлап җитмәгән иде.

— Егылган... Күрше хатыны аяктан егылган!— дидем мин, пышылдап.

## X

Кинәт кенә исемә-акылыма килдем дә кабул итү бүлмәсенә йөгереп чыктым. Әлбәттә, керергә кирәк! Нинди авырсыну ди ул! Нинди генә шартларда булсам да, мин — фельдшер, мин — медик. Аяктан егылган. Нервысы на-

чар, башы... йөрәге... Аңа беренче ярдәм кирәк. Күршеңдәге авыруны кереп карамау ул үзе бер җинаять булыр иде!

Минем арттан шундук Таня килеп керде.

— Сиңа ярамый, Саҗидә!— диде, юлыма аркылы төшеп.

— Ник? Дөрес! Бар, син кер. Бар, тизрәк!

Таня тиз генә халатын киде, фонендоскоп алды, кан басымын үлчи торган аппарат алды. Ашыгып кереп тә китте. Мин баскан урынымда тордым да калдым.

Шулай торганда, тәрәзәгә күзем төште. Карасам, ак ефәк күлмәген киеп, ашыга-ашыга, безгә Тимерҗан килә!

Күрдем дә моны, тиле кебек ярсып, ишеккә ташландым.

Тагын! Кара, нинди шәп егет! Алар аркасында сүз ишетү җитмәгән... тагын килә! Кирәге юк берсенең дә! Мин егетләр белән очрашмый да тора беләм. Аулагөй түгел монда. Йөрсеннәр әнә үзләренең клубларына.

Секунд эчендә күңелдән шундый усал уйлар үтте. Йөгереп чыктым да, чолан ишеген ачып җибәрдем дә бастым тегенең каршысына.

— Исәнме, Саҗидә!— диде бу, авызын ерып.

— Исән булмасам, мин үзем фельдшер,— дидем, коры гына.

— Саҗидә!

— Нәрсә? Ник килдегез монда?

— Карале, туктале...

Тавышы да үзгәрде моның, йөзе дә үзгәрде. Таза беләкләремне күкрәк турысында кушырдым да, ниндидер кинодагы уңай геройны хәтерләткән бер кыяфәттә, башымны горур гына югары күтәреп:

— Безнең пунктка икенче аяк басасы булмагыз!— дидем.— Бетмәгән әнә... клублар... аулагөйләр... Равилгә дә әйтегез, эзе булмасын.

Шәп егетнең борын төбендә генә ишекне шап иттереп яптым да, кердем дә киттем. Юк, кереп китмәдем, ишекнең келәсен элдерергә азаплана башладым. Нишләптер кул калтырана. Һич кенә дә элдерә алмыйм. Шул ук вакытта аяк буыннары да хәлсезләнеп китте. Каяндыр курку, шүрләү калкып чыкты.

Келәне каптырып тормадым, өйгә кереп киттем. Аяктан егылмас өчен, тәрәзә янгагына барып сөялдем. Берни тоймыйм, берни сизмим. Уйламыйм да, кайгырмыйм да. Бары тик хәлсезлек кенә җанга тия. Аннары никтер калтырата-дерелдәтә.

Ара-тирә үзем тәрәзәгә карап алам. Китәрме? Киттеме? Ничек китте?

Мenə капкадан чыкты. Башын иеп, әкрен генә урам буйлап китеп барды. Туктады, уйга калды. Тагын кузгалды, тагын туктады. Аның шулай китеп баруын күргәч, үземнең тагын бер кирәкмәгән дуамаллык эшләгәнлегемне аңлагандай булдым. Бөтен тәнемне, үткер скальпель булып, үкенү тойгысы ярып үтте.

Кисәк кенә бу кире борылды. Ниндидер кискен, ныклы бер карарга килеп, яңадан безнең капкага килә башлады. Ни кирәк аңа? Ни кирәк? Кире килә! Җибәрмәскә кирәк! Керсен! Кеше сүзеннән куркып монда... Кемдә кемнең эше бар?! Миндә беркемнең эше юк!

Күп тә үтмәде, бик каты ишек шакыган тавыш ишетелде. Мин яңадан чоланга чыктым.

— Кем бар? Нәрсә кирәк?— дидем ишек аша, дер-дер калтыранып.

— Мин бу, мин — бригадир ярдәмчесе!— дип кычкыра бу тиле кеше сыман.— Иртәгә амбарга барасызмы?.. барасызмы? Ашлык яна, кеше юк. Барасызмы? Икенче килмәм, курыкма! Әйт, барасызмы? Барыгыз... өчәүләп!

Бөтенләй чит кеше булып, бригадир булып кычкыра. Кычкырды-кычкырды да йөгереп баскычтан төште, йөгереп ишегалдан чыгып китте.

Ул кычкырганда, мин тагын келәгә килеп тотындым, ишекне ачаргамы, бикләргәме азапланам — үзем дә аңламыйм. Келә нишләптер күтәрелмәде. Ишек ачылмады. Ул баскычтан төшеп киткәч кенә, мин ишекнең бикләнмәгәнлеген аңлап алдым. Ишекне төртеп җибәрдем дә шунда бусагага утырдым. Утырмадым да. Егылып төштем. Кинәт елыйсым килде. Мыштым гына үксергә тотындым.

## XI

Бер заман артымда Таня басып торганлыгын шәйләп алдым.

— Ни булды тагын?— ди бу.

— Булмады,— дигән булам.— Айлы төн, матур...

— Нинди айлы төн?!— ди Таня, исе китеп.— Әйдә, керәбез. Тилереп беттегез инде барыгыз да.

— Хәле ничек?— димен, күршеләр ягына ымлап.

Ул миңа күрше хатын турында сөйләргә тотына. Фәлән төрле дару бармы, ди, тынычланса бетәр, ди, нервы, баш, йөрәк, ди... Без өйгә керәбез, шкафны ачып, кирәкле даруларны алабыз да, Таня яңадан теге якка кереп китә.

Мин үзебезнең якка чыгам. Чыксам, калай капкачын сикерткәләп, дөбер-шатыр чәйгүн кайнап утыра.

Таня чыккач, сөйләшми генә чәй эчтек. Ашагач-эчкәч, көрсенеп куйдым. «Шул кирәк сиңа!— диде графинга сөяп куелган «Галия», утлы күмердәй күзләрен очкынландырып.— Җебегән кеше син, җебегән, булдыксыз. Сүзеңдә тора белмисең, антыңны бозасың, егетләр турында уйлыйсың. Уйлау гына түгел, очрашасың, сөйләшәсең! Физика, химия дәреслекләрен ай буена кулыңа да алып карамадың. Нинди кеше син? Әйт әле, нинди бәндә син?! Синең белән дуслашкан мин җүләр! Мин сөйләгән сүзләр барысы да бушка китте. Юкка төкерекләремне чәчеп, мин сине укырга, укырга дип өндәгәнмен! Булмый синнән, берни булмый...»

Мин тагын көрсенеп куйдым. Үзем белән үртәшеп утырган Галияне графин яныннан алдым да йөзе белән өстәлгә капладым. Ләкин алай да күз алдыннан китмәде, мине һаман үчекләвендә булды. Алдым да, ачуланып, «Нервы авырулары» китабына тыгып куйдым.

Күз алдыма Уфа килә, мин кайчандыр кызыгып караган шат йөзле студентлар килә. Ә бит Галия бер-ике көннән институтка барачак! Нинди бәхетле ул! Нинди бәхетле!..

Аның сүзен тотканда, бөтенесен аныңча эшләгәндә, мин дә аның белән бергә була ала идем бит! Ләкин булмады. Көч җитмәде, тырышлык, чыдамлык җитмәде. Нинди чыдамлык ди ул?! Чыдам булган кеше секретарь белән тиргәшеп йөримени, авыру хатын белән әйтешәмени?! Әллә нинди кеше мин. Алама кеше мин. Нинди икәнлегемне үзем дә юньләп аңламыйм.

Галия нинди соң? Галия ул кеше генә дә түгел,— фәрештә! Үзе бәләкәй генә, чандыр гына. Өрсәң җаны чыгарга тора, үзендә никадәр көч, никадәр энергия! Ул төннәр буе укып утыра ала. Тели икән, тәүлекләр буе черем дә итми. Имтиханнарга әзерләнгәндә, ул атналар буе кинога бармый, мунчага бармый. Ашавын оныта, эчүен оныта, хәлсезләнеп аяктан егыла, шулай да кулыннан китабын төшерми. Аның белмәгәне юк. Китаптагыны ул биш бармагы кебек белә, кайсы биттә нинди хәрефнең кыек басылганына кадәр белә. Шуңа да ул отличница. Ул — баштанаяк укучы. Ул — чын совет студенты.

## XII

— Нәрсә кайгыга баттың, әйдә ятабыз,— диде Таня.

— Ятабыз?! Нинди яту әле бу вакытта?

— Нишләмәкче буласың? Кайгыдан суга ташланырга уйламыйсыңдыр ич?

— Көлмә,— дидем мин, ачусыз гына.

— Көлми ни! Синең йөзеңә карасаң, көлү түгел, әллә нишләрсең.

— Син карама!

Шулай бер-ике сүз әйтештек тә тынып калдык.

— Әйдә, алайса, клубка?— диде Таня.

— Клубка?!— дидем мин, шаккатып. Бераз тынып тордым да, тыныч булырга тырышып: — Син теләсәң нишлә,— дидем.— Мин анда беркайчан да бармаячакмын! Менә шул. Ә син бар. Мин сине тотмыйм.

— Синең белән саргаеп үләрсең,— диде Таня, үпкәләп.

— Синең тормышта максатың юк, шуңа күрә күңелсез сиңа,— дидем мин.

— Харап инде, синең генә максатың бар!

Мин аңа каты бәрелгәнлегемне аңлап алдым, телемне тешләп тынып калдым. Ләкин күңел барыбер тыныч түгел, һаман кытыклана, һаман кымырҗып тора.

— Бәхетле кешеләр озакламый укырга барачаклар!— дидем, Галия турындагы уйларымны дәвам итеп.— Ә без утырабыз менә монда канаты сынган кошлар кебек.

— Барсыннар, минем өчен барыбер!— ди Таня, каты гына.

Бүген ул да минем белән әллә ничек сөйләшә. Бүтән чакта ул бер дә алай түгел. Хәзер әнә бер сүз әйтеп булмый, кытыгына тия. Күрәсең, Равилне күрәсе киләдер.

— Башкача нәрсә дисең... минем өчен барыбер дисең инде,— дидем мин, үзалдыма сөйләнеп.— Галия әнә алай дип уйламый торгандыр әле.

— Ошамый миңа синең Галияң!— ди Таня, тагын да ныграк үртәлеп.

— Ник ошамый? Ник?

— Отличница андый булмый.

— Нинди була соң?

— Кеше төсле... Китап корты, китап колы ул синең Галияң! Алай кем дә укый ала. Күрерсең әле, бер-ике елдан туберкулез алыр.

— Синең бар курыкканың туберкулез икән. Медицина хәзер туберкулезны тулысынча дәвалый.

Шуннан башка мин аңа бер сүз дә әйтә алмыйм. Галияне никадәр яратсам да, никадәр аңа табынсам да, бу минутта мин аны яклардай берни таба алмыйм. Дөресен әйткәндә, Галиянең күп кенә гадәтләрен мин үзем дә ошатып бетермим, тик ул турыда танырга гына куркам. Аннары аның ошаган яклары ошамаган якларына караганда күбрәк тә, көчлерәк тә. Аның менә шул көчле яклары мине үзенә буйсындырып тора да.

— Минем яшисем килә!— ди Таня.— Кешеләрчә, яшьләрчә яшисем килә. Тагын кайчан яшәргә? Миңа унсигез яшь. Сиксән түгел, унсигез! Нәрсә миңа монда уку дип, институт дип, үз-үземне төрмәгә бикләргә?! Үлгәч — мәңгелек төрмә...

«Надан!»— дип уйлап алдым. Үлгәч төрмә буламыни? Үлгәч анда төрмә дә юк! Никтер хәзер минем Таня белән сатулашып торасым килми. Мин инде бүген җитәрлек сатулаштым. Кычкырып, кайгырып арып беттем.

— Әйдә, алайса, ятабыз,— дидем.

— Хәзер минем ятасым килми,— ди Таня.

— Теләсәң нишлә, мин ятам.

Шулай дидем дә, урын-җир әзерли башладым. «Иртәгә эшкә барасы бар бит әле»,— дип уйладым үзалдыма. Барыргамы, бармаскамы? Нишләп йөрергә икән соң анда адәм мәсхәрәсе булып? Болай да бөтен авыл көләдер әле.

Түзмәдем, эшкә бару турында Таняга да әйттем.

— Барабыз!— диде Таня, бернинди икеләнүсез.

— Әйдә, алайса, тегеләргә барып кайтыйк,— дидем мин.— Баргач-баргач, өчәүләшеп барырга кирәк. Кем ул анда ялкауланып ятырга?!

— Әйдә!— диде Таня, сөенеп.

Тиз-тиз генә җыендык та Зөһрәләргә китеп бардык.

## XIII

Ишекне бикләп, ачкычны үзебез белән алдык. Капкадан чыкканда, ипләбрәк, тавышланмыйчарак чыгарга тырыштык.

Урамда инде караңгы. Колхоз идарәсе йортында ут яна. Клубта да ут күренә, берән-сәрән тавышлар ишетелә. Икебез дә шул якка карадык, тавышларга колак салгандай итеп тордык. Аннары чирәм өстеннән әкрен генә китеп бардык.

Зөһрәләрнең өе, авылдагы барлык өйләр кебек, гади генә. Өй эчендә бүлмә-фәлән юк. Ишектән кергәч тә уң якта зур ак мич, каршында караватъ. Караватъ өстенә чаршау эленгән. Почмакта мендәр өеме. Аш-су исе, яшь бала исе. Түшәмгә асылынган сиртмәле бишек...

Без килеп кергәндә, хуҗалар инде ятырга өлгергәннәр иде. Өстәлдә лампа янып утыра. Лампаны кысып куйганнар, шуңа күрә өйдә бик үк якты дип әйтерлек түгел. Күрәсең, яшь балага салкын тимәсен дип, ишекләрен ачмаганнар. Һава бөркү. Түшәмдә, казан тирәсендә, чебеннәр безелди. Тәрәзәгә бәргәләнеп бал корты безелди.

Алар безелдәгәнгә, лампа филтәсе тавыш чыгарып янганга, аннары, бишектә яшь бала йоклап ятканга, өй эче бик тын булып тоела.

Без кергәч, Хисам абый да, Рафика апа да уянды. Рафика апа чаршау астыннан чыгып идәнгә төште дә, эчке күлмәгенең изүләрен тотыштырып, өстәлдәге лампага үрелде, утны күтәрде.

— Кызлар килгәнмени? Исәнмесез, кызлар,— дип кычкырды Хисам абый чаршау артыннан.

Без аңа:

— Исәнбез,— дип җавап бирдек. Тәрәзә янындагы утыргычка парлап утырдык та, сүзсез генә, хуҗаларны күзәтәбез. Безне ишек ачып керткән Нәсимә апа — Зөһрәнең әнисе самовар куярга кереште.

— Мәшәкатьләнмәгез, Нәсимә апа,— дидем мин.— Без ашап кына килдек, рәхмәт.

— Ашасагыз ни... менә...— диде Нәсимә апа.— Аштан олы кеше буламыни? Менә хәзер кайнап чыгар.

Рафика апа бертуктаусыз сөйләнә дә сөйләнә. Чебеннәрне тирги, өйдәге бөркүлекне тирги, аннары малае Азатны мактап ала, Түбән Чатка бардыгызмы, мин кирәк булмадыммы, ди. Мин аңа бер-ике сүз белән генә җавап бирдем дә, кулларны тез өстенә салып, шулай утыра бирәм. Нәсимә апаның сүзләренә, кыланышларына карап, мин үземчә бер фикергә килдем: күрәсең, минем тиргәшкәнне болар да ишеткәннәрдер, дидем.

— Фәгыйлә апа өйдә юкмыни?— дидем, тыелып кына.

— Фермада,— диде Нәсимә апа.

— Ул, бахыр, көн-төн шунда, бозаулары менән,— дип куйды Рафика апа.

— Зөһрәләр кая соң?

Зөһрәнең өйдә юклыгын мин кергәч тә сизеп алган идем. Кайда булыр ул? Билгеле, клубындадыр!

— Ул кирәк булдымыни?— диде Нәсимә апа, пышылдап, нindидер яшерен нәрсә турында сөйләшкән сыман.

— Терелдемени?— дигән булдым мин.

— Кайчан чирләде соң әле ул?— диде Хисам абый.

— Чирләп торды бүген, башы авыртты,— диде Нәсимә апа.

— Баш авырту да булдымы чир!— диде Хисам абый чаршау артыннан.

Нәсимә апа эндәшмәде, битләрен сыйпаштырып, чәчләрен яулык астына яшергәләп, чоланга чыгып китте.

— Яшьтәр өйдә ятмай инде. Алар клубта,— диде Рафика апа, моңсу гына елмаеп.

Мин Рафика апага карап утырдым-утырдым да кисәк кенә урынымнан тордым. Таня да кузгалды.

— Сезне юкка борчыдык,— дидем.

— Берәр йомышыгыз барыемыни?— диде Нәсимә апа, ишектән керешли.

— Иртәгә амбар алдына эшкә барырга әйттеләр. Ашлык җилгәрергә. Иртән иртүк Зөһрә амбар алдына барсын.

— Ярар, әйтербез,— диде Рафика апа.

— Әйтербез, әйтербез,— диде Хисам абый да.

Рафика апа өтәләнергә тотынды: ник утырмадыгыз әле, диде, хәзер сәй кайнай, диде. Нәсимә апа да, Хисам абый да шул ук сүзләрне кабатладылар.

— Рәхмәт, эчкән чаклар да булыр әле,— дидем мин.

Саубуллаштык та чыгып киттек.

## XIV

Иртән без Зөһрә килгәнне көтеп тормадык. Ашадык-эчтек тә, искерәк киемнәрне киенеп, амбар алдына киттек. Вакыт әле иртәрәк кебек. Көтү яңа чыгып килә. Чыннан да, без амбар янына барып җиткәндә, анда әле беркем юк иде.

Амбар алдына ашлык китереп өйгәннәр. Таудай булып ята. Өстенә салам ташлаганнар. Түбәсе ябык ындыр табагында да күлдәй булып ашлык җәелеп ята. Анысына салам капланмаган. Бодай. Сап-сары. Карар күзгә күңелле. Шунда ук җилгәргечләр, мичкә, әрҗә ише нәрсәләр. Бер почмакта капчыкка тутырылган ашлык өеп куйганнар. Анысы Яңавылга озатыргадыр инде.

Без амбарга якынлашу белән, шул капчыклар арасыннан каравылчы карт килеп чыкты. Озын буйлы, төз, туры гәүдәле. Табак битле, кысыграк күзле. Чал кергән кыска мыегы, сакалы бар. Башында иске бүрек, өстендә — кыска сырма.

Кулындагы таягын алгарак сузып басты да, бер сүз әйтмичә, безне көтеп алды.

— Исәнме, бабай,— дидем мин.

— Исәнме, кызым. Исәнмесез,— диде карт, безнең икебезне дә күздән кичереп.

Сүзләрне бик үк ачык әйтми, авыз эчендә лыбырдатыбрак сөйли. Шулай да тавышы көр, көчле. Каяндыр тирәннән, күкрәктән чыга.

— Нишләп йөреш?— диде бу.— Яңавылгамыни?

Кысык күзләрен елтыратып, әле миңа, әле Таняга карап алды, мыегын сыпыргалады, таягы белән җиргә төрткәләп куйды.

— Яңавылга түгел, эшкә, бабай,— дидем мин.— Эшкә килдек. Ашлык җилгәрергә җибәрделәр.

— Эшкә?— диде бабай, ышанмагандай итеп.

Бер сүзне әйтә дә туктап кала, ни әйтерләр болар дигән сыман, көтеп тора. Үзе һаман безгә карый.

— Иртә бит әле. Иртәрәк кузгалгансыз.

— Нишләп иртә булсын? Без инде бу вакытта эшли башлыйбыз,— дидем мин.

— Кемнәр соң әле сез?— диде бабай.— Үзебезнең авылмы дигәндәй...

— Үзебезнең авыл,— дидем мин, елмаеп.— Әллә танымыйсың?

— Яшьләрне каян танып бетерәсең инде.

— Фельдшер Саҗидә бит мин. Сезнең «бырач».

— Ә, бырач!— диде бабай, җанланып.

Шулай дигәч, бу тагын мыегын сыпырып алды, кызулап, таягын җиргә төрткәләргә тотынды.

— Ник килдегез соң монда? Мине тикшерергәмени?

— Юк,— дидем мин, көлеп.— Эшкә җибәрделәр, эшкә! Ашлык җилгәрергә. Кешеләр җитми, ди...

— Ә-ә,— диде бабай, төшенеп.— Ашлык җилләтергәмени? Бик хуп. Иртәрәк бит әле, кызларым.

— Булсын, көтәрбез,— дидем мин.

— Утырып торыгыз алайса,— диде бабай, капчыклар ягына күрсәтеп.

— Әйдә,— дидем мин Таняга.

Әле көн җылынмаган, салкынча. Мин юка киенеп килдем. Таня бәйләгән кофта кигән. Аңа рәхәт. Капчыклар янына килдек тә, бер-беребезгә сыенып, тыгыз капчыклар өстенә утырдык.

Бабай, таягын төрткәләп, бер урындарак басып торды да шулай ук капчыклар янына килде. Килде дә утырып тормады — читкәрәк басып, безнең каршыда туктап калды.

— Каян килдең соң безгә?— диде, миңа карап.

— Яңавылдан. Яңавылныкы мин.

— Бу кызым каян?

— Ул бик ерактан. Украинадан.

— Булган бар,— диде бабай.— Кәк булмаска! Гирман сугышында... мимечләрне куганда... Хураша хохол!

Соңгы сүзләрен ул Таняга карап әйтте. Без Таня белән көлеп җибәрдек. Бабайның кысык күзләре очкынланып китте. Безгә кушылып ул да елмайды.

— Утыр, бабай,— дидем мин, аңа урын күрсәтеп.

Бабай ялындырып тормады — капчыкның буш башына җайлап кына утырды да, шома таягын тезләре арасына куеп, әйләндерергә тотынды.

— Бырач дисең, алайса?— диде, миңа карап.
— Әйе, бабай, фельдшер Сәҗидә. Ә бу — Таня.
— Тәнә?
— Таня!
— Ярар, Тәнәме, Танамы... Безнеңчә беләме?
— Бераз сукалый.
— Сукалагач ярай. Аннан тырмалай башлар, чәчә башлар.

Таня, сүзнең үзе турында барганлыгын шәйләп, миңа карап-карап ала. Мин аңа кайбер сүзләрне әйләндереп бирәм.

— Бырач халкы белән дуслык юк минем,— дип куйды бабай, бер дә юктан.
— Әллә яратмыйсың безне?— дигән булдым.
— Яратмаудан түгел — йомыш төшмәй. Шулай да бер йөрәкне барып тикшертергә дип йөрим. Вакыт юк.
— Йөрәгең нишләгән?
— Эшләмәгән. Болай гына. Тикшерү өчен генә.
— Кил, бабай, кил,— дидем мин.
— Вакыт юк шул,— диде бабай, зарлангандай итеп.— Төннә менә каравылда торам. Көндез печән әзерләргә кирәк. Йоклап ята торган чак түгел.
— Әллә бөтенләй йокламыйсың?
— Кайчакта черем итеп аласың инде,— диде бабай, тыйнак кына.
— Каравылда торгандамы?— дигән булдым мин, шаяртмакчы булып.
— Каравылда торганда йокламасаң, кайчан йоклайсың?— диде бабай, бер дә исе китмичә.

Мин аны, юк, йокламыйм, дип әйтер дип уйлаган идем. Аның мондый эчкерсезлеге миңа кызык кына тоелды. Авыл кешесе шулайрак инде ул. Ачыктан-ачык. Ялганлап, күз буяп тормый. Барысы дамы? Юктыр, барысы да түгел. Кайберәүләр генә. Чын авыл кешеләре генә.

— Әллә хәзер генә карайсыңмы соң, кызым?— диде кинәт бабай.
— Нәрсәне?
— Йөрәкне, кызым.
— Йөрәкне?! Ничек карыйсың аны монда?— дидем мин.— Монда булмый. Пунктка кил, бабай. Монда бит бернәрсә дә юк безнең.
— Торба кирәкмени?
— Кирәк шул.
— Шулайдыр инде,— диде бабай, килешеп.— Барырмын әле бер. Түлке, син мине чиратсыз кертерсең, кызым, яме?

— Ярар,— дигән булдым мин.— Исемең ничек соң синең, бабай? Нишләптер мин дә сине белмим.

— Мине дә белмәгән кеше булыр икән!— диде бабай.— Шәйхаттәр мин, Шәйхаттәр карт.

— Ә, шулаймыни...

Күңелемнән уйлап куйдым: «Нәрсәсе белән атаклы икән соң бу Шәйхаттәр карт?»— дидем.

— Ничә яшьтә соң син, бабай?— дидем, беравык тынып утыргач.

Карт сакал-мыегын сыпырды да тамак кырып куйган булды, таягын биетеп алды.

— Тугызынчы унны куып барабыз, кызым,— диде.

— Туксанны?!— дидем мин, исем китеп.

Таняга да тәрҗемә итеп бирдем. Аның да күзе дүрт булды, гаҗәпләнеп Шәйхаттәр бабайга карап алды.

— Сез күпме дигәниегез?— диде бабай, горур гына.

— Минем әти илле биштә. Сиңа, күп булса, алтмыш бишне бирергә була,— дидем мин.

Шәйхаттәр бабай күңелле генә кеткелдәп алды.

— Менә шул була инде ул Шәйхаттәр бабагыз!— диде аннары, ачыктан-ачык бер масаю белән.

— Шулай да ничә яшьтә соң син, бабай?— дидем мин.

— Быел көз кырпак төшкәч сиксән икене тутырам, балалар,— диде бабай.

— Күз ничек күрә, күз?— дидем мин, Шәйхаттәр бабайның кысык күзләренә җентекләбрәк карап.

— Аллага шөкер, күрә. Көн яктысында хәреф таныйм.

— Колак ничек?

— Аллага шөкер, ишетмәгән нәрсәм юк,— диде карт. Үзе тагын кеткелдәп көлеп куйды.

— Ашау ничек? Тешләр?

Шәйхаттәр бабай авызын ачты да саргайган эре тешләрен күрсәтте. Аның алгы тешләре, азау тешләре — асты да, өсте дә — барысы да исән иде, тап-таза иде. Минем гаҗәпләнүем соңгы чиккә җитте.

— Шул көе!— дидем мин, шаккатып.— Карале, Таня!

Таня да бабайның авызына карады. Исе китте.

— Чирләгәнең булдымы, бабай?— дидем мин.

— Аллага шөкер, булмады. Бала вакытта чирләгәнмен. Әнкәй мәрхүмә әйтерие, бик чирләш булганмын. Иллә мәгәр, үзем белгәндә хәтерләмәймен. Аякка тырма теше кадалгач, аксап бераз йөрдем. Анысы да күпкә бармады, бетте.

— Аракы эчтеңме? Яшь чагында...

— Аракы безгә хәрам,— диде бабай, җитди итеп, эчке бер тантана белән.— Тәмәке дә хәрам. Дин кушмай.

— Без дә кушмыйбыз,— дидем мин.

— Дөрес, сез дә кушмайсыз. Бырачлар дин яклы.

— Алай түгел дә инде ул,— дидем мин, аның сүзләрендә политик хата күреп.

— Сез аны икенче төрле аңлаткан буласыз. Динчә булмасын дип...

Шулай диде дә кинәт сүзсез калды. Аңа хөрмәт йөзеннән, без дә тынып калдык.

## XV

— Эшкә соң чыгалар икән,— дип куйдым мин, яңадан сүз башлап.

— Хәзер эшләмәйләр, кызым,— диде Шәйхаттәр бабай, тыныч кына.— Хәзер көн уздыралар. Менә никадәр ашлык исраф булып ята. Ярай әле, монда кайтып җиткән. Әпекәйнең кадере китте. Чүп урынына да күрмәйләр.

— Кем күрми инде аны чүп урынына да?— дидем мин.

— Кем дип... барысы да, кем ашлыкта эшләй. Ныгымас борын, яшел көе урдыралар. Анда үреп ята. Аннары икенче кат җыеп йөриләр. Суктыралар чи көе. Яртысы башакта кала. Калган яртысын илебатырга озаталар. Анда кыза, монда кыза. Коела, түгелә-чәчелә. Кадере юк ашлыкның. Элекке белән исәпләгәндә, ниндәй уңа хәзер! Бер чүбе юк. Карап торсаң, исең китәр. Сабакта чагында гына күреп каласың да.

Мондый сүзләрне тыңлавы миңа күңелсез. Мин аның дөресме, түгелме икәнлеген бик үк аермыйм. Шулай да сизенәм — сиксән ике яшәр карт юкны сөйләп утырмас. Чынлап сөйлидер, эче пошканга сөйлидер. Картлар алар тынгысыз булалар, хәзергене яратып та җиткермиләр, гел элеккене мактау ягын карыйлар. Ләкин Шәйхаттәр бабай элеккене дә мактамый, зарлана, пошына гына.

Таня белән без бер-беребезгә сыенып утырабыз шулай. Бабай, сүзнең ялганып китмәвен күреп, тагын тынып калды, «Йа Алла!»— дип, бер көрсенеп куйды да таягын тукылдатырга тотынды.

— Алайса сез бырачлар буласыз?— диде, кабатлап.

— Шулай,— дидем мин.

— Кичәгенәк нәрсә бүлештегез соң?— диде бу, миңа карап.

Миңа кинәт бик кыен булып китте.

— Булды инде, бабай,— дигән булдым, тыныч күренергә тырышып.

— Ипле йөрегез, балалар,— диде бабай, йомшак кына

итеп.— Тәүфикълы булыгыз. Әйтүче юк сезгә, үрәтүче юк. Мин менә әйтәм дә малайларга — тыңнамайлар. Әркем оста, белекле. Кайчагында олылар сүзен дә тоту кирәк.

— Шулайрак булды инде, бабай,— дигән булдым мин, үз-үземне шелтәләп.

— Ярар, яшь чакта була инде ул,— дип куйды бабай да.— Яңгышып куясың шулай. Сиңа чаклы берсе дә, рәтләп карамады, диләр. Барганым булмагач, әйтәлмәймен. Кеше сүләй. Әйбәт эшләргә кирәк, кызым, тел-теш тиярлек булмасын. Хураша рабутайт нады!

Таняга карап алды да кысык күзләре белән генә елмаеп куйды. Таягын шакылдатты, тамак кырды, сакалмыегын сыпырды.

— Бик чибәр күренәсез,— диде, мактап.— Менә үзегезне кияүгә бирербез. Мәсәгут киленнәре булырсыз.

— Безгә дигән кияүләр мич алдында көл ашый!— дигән булдым мин, остарып.

— Көл ашап туйганнардыр инде,— диде бабай, икебезгә дә мут күзләре белән караштыргалап.

Күз алдына шундук «көл ашап туйган кияү» килде. Бүген бит аның белән очрашасы да бар әле! Нишләргә аны күргәч? Ничек карар ул миңа?

Кыска гына вакыт эчендә, күңелне шундыйрак сораулар тынычсызлап алды. Тынычсызлап кына түгел, үзәкләрне өзеп алды.

— Ярар, балалар,— диде Шәйхаттәр бабай, урынынан торып.— Мин кайтаем. Сез, алайса, эшкә килдегез?

— Эшкә, эшкә!

— Катыннар кузгалып килгәнче, төш җитәр. Сез яшь кеше. Әнә анда салам астында көрәкләр, сәнәкләр бар. Кул кушырып утырганчы, тотыныгыз, алайса. Бодайны ачыгыз. Саламын читән буена ташып куегыз. Ындыр табакны себерә торырга да була. Бодайны шул якка тараталар.

Ул безгә кайдан себерергә кирәклеген күрсәтте. Саубуллашты да, гәүдәсен төз тотып, әкрен генә авылга таба китеп барды.

Таня белән без саламны актарып ташладык. Кочаклап күтәреп читән буена ташырга тотындык.

Бодай өемен ачып бетергәндә, авылдан амбарга таба килүче берничә җан иясе күренде.

## XVI

Болар бер ир кеше белән бер-ике хатын-кыз булып чыкты. Хатыннарның икесе миңа таныш. Берсе — шофер Мәгъсүм абый хатыны, икенчесе — толхатын Ка-

милә. Иңбашына калын сумка аскан, юан гына, таза гына абзый миңа таныш түгел. Аның пунктта булганы юк. Минем танышларның барысы да диярлек чирле-мырлы кешеләр. Шулай булгач, аның миңа таныш булмавы бер дә гаҗәп түгел.

Килделәр болар, исәнләштеләр дә төрле якка таралдылар. Сумкалы агай үлчәү янына килде. Сумкасыннан, вак-төяк таш шикелле итеп, кечкенә герләр алып куйды, үлчәүгә сөяп калдырылган сәнәкне бер читкә алып ташлады. Мин аның монда ниндидер баш кеше икәнлеген аңлап алдым.

Хатыннарның берсе әйтте: «Килдегезме?»— диде, икенчесе: «Кызлар бездән иртәрәк кузгалганнар»,— диде.

— Килдек,— дидем мин.— Иртә торып өйрәнгәч, ашыгыбрак килгәнбез.

— Зарар юк,— дип куйды тол хатын.

— Әндәр бичәсен көтеп торабызмы, тотынабызмы, Камиләттәй?— диде шофер хатыны.

— Ниндәй көтү ул?— диде сумкалы агай.— Ашлыкның Әндәр бичәсендә эше юк. Тиз кыланыгыз.

— Безнең Зөһрә дә килмәгән әле,— дип куйдым мин.

— Зөһрә койрыкны тоттырмас!— диде Камиләттәй.

Сумкалы агай безнең янга килде.

— Сеңелләр барында тырышып эшләгез,— диде хатыннарга.— Сынатмагыз.

— Әйдә, сынатса-сынатмаса, алар яшь кеше — эшләй торган чаклары,— диде Камиләттәй.

— Саламны үзегез ачтыгызмы?— диде агай безгә.— Шәйхаттәр карт әйттеме? Әйбәт булган. Әнә шул төшне себереп ташлагыз да таратыгыз. Көн явымга китте. Кичкә кадәр яхшы гына җилли әле ул.

Сумкалы агай безгә шулай тегесен-монысын әйткәләде дә амбар ягына китеп барды.

— Тотындык алайса, кызлар,— диде Камиләттәй.

Без башта себерке белән киң генә такыр урынны себереп куйдык. Аннары кулларга агач көрәкләр алдык та өелгән бодайны шул такыр җиргә сибәргә тотындык.

Башта ук мин чын күңелдән бирелеп эшләдем, хатыннар алдында оятка калмаска тырышып эшләдем. Мондый эш миңа таныш. Агач көрәк белән мин элегрәк кар көри торган идем. Аннары, Уфада укыганда, безне ике ел колхозга алып бардылар. Анда да шундыйрак эшләр эшләргә туры килде.

Берничә минут чамасы, без баш та калкытмадык. Бераздан, хәл алмакчы булып, барыбыз да билләрне турайттык, берьюлы бер-беребезгә карап алдык, елмаешып куй-

дык. Һәркемнең йөзе алсуланган, һәркем еш-еш тын ала. Бары Камиләттәй генә шул көе диярлек — йөзендә әз генә дә кан әсәре юк.

Авыл ягында тузан туздырып килүче бер машина күренде. Машинаның килеп җитүен көтеп тормастан, яңадан эшкә тотындык.

Машина килеп җитте, түбә алдында туктап калды. Шаулашып җиргә малай-шалайлар төште. Шап-шоп кабина ишеге ачып-япкан тавышлар ишетелде. Иелгән башны калкытмый гына, шул якка күз төшереп алдым.

Юк, беркем күренми. Ягъни мин күрергә теләгән кеше күренми. Башымны калкыткандай иттем дә машина ягына озаклабрак карарга тотындым. Юк, килмәгән. Әллә кемнәр шунда. Яңавылга алып китәргә ашлык төйиләр бугай.

Күреп торам, Таня да астыртын гына шул якны күзәтә.

— Беркем юк,— дидем аңа русча.

— Юк шул,— дигән булды Таня.

Икебез дә көлешеп куйдык.

— Әнә, шытты!— диде шофер хатыны, авыл ягына ымлап.

Барыбыз да күтәрелеп шул якка карадык. Болай таба ашыгып, ниндидер хатын-кыз килә. Күрәсең, Әндәр бичәсе дигәннәре шулдыр.

Кабаланып килеп җитте дә тиз генә кулына көрәк алды. Шуннан соң исәнләште, сөйләшеп тә тормастан, эшкә керeште.

Хатын бик таза күренә. Эре сөякле, юан гына гәүдәле. Җилләнеп, пыр тузып эшли. Сибеп җибәргән бодае ындыр табакның икенче башына барып төшә. «Менә көч монда!»— дип уйлап алдым мин, кызыгып.

Ярар, болар барысы да килеп беттеләр, ахрысы. Безнең Зөһрә нишләп килми соң һаман да? Әллә бөтенләй килмәскә итәме? Мин чын-чынлап тынычсызлана башладым. Баштарак, килсә ярый, килмәсә ярый, диебрәк уйлаган идем. Ләкин мөдирлек тойгысы көнләшү, яратмау тойгысыннан шулай да өскә чыкты. Ни әйтсәң дә, ул бит минем кеше! Аның өчен мин җаваплы!

## XVII

Бер заман мин онытылып киттем. Эшнең җаена яттым да, эшлим дә эшлим. Килеп тотынгач та шундый авыр булып тоелган эш җиңеләеп китте. Тыным озайды, куллар ныгыды, агач көрәк җиңел, ышанычлы йөри башлады. Без тездән бодайга батып эшлибез. Аста бодай җылы, аякка рәхәт. Үзеңнән үзең онытылырсың.

Кемдер колак төбендә генә:

— Исәнмесез,— дип кычкырып җибәрде.

Бәлки, ул алай кычкырмагандыр да, миңа гына шулай тоелгандыр. Мин сискәнеп киттем, билне яздым. Карасам, Тимерҗан басып тора! Безнең эшне күзәтә, йөзе җитди, иреннәре кысылган, күзләре каядыр каш астына кереп яшеренгән. Өстендә эш киеме — иске генә кыска бишмәт, тапланган яшел фуражка. Минем әтинеке кебек. Аның да сугыштан алып кайткан шундый ук яшел фуражкасы ишек башында чөйдә эленеп тора. Аягында күн итек. Бишмәтенең түш кесәсеннән авторучка белән куен дәфтәре күренеп тора.

Хатын-кызлар бер-бер артлы аңа җавап кайтардылар: исәнме, Тимерҗан, диделәр, бик исән әле, диделәр. Мин бернәрсә дә әйтмәдем. Телем тотлыкты. Уңайсызлануымны сиздермәс өчен, яңадан көрәгемә тотынган булдым.

Безнең янда бу озак тормады, кызулап машина янына китеп барды.

— Зөһрә юк бит, Зөһрә!— диде аның артыннан шофер хатыны.

Тимерҗан җавап кайтармады. Хатыннар үзара мәгънәле генә елмаешып алдылар.

— Чирләп тора бугай ул,— дидем мин, никтер Зөһрәне якларга чамалап.

Нәкъ шул чакта, бөтенләй көтмәгәндә, Зөһрә күренде.

Килеп җитте. Башкалар кебек исәнләште дә, безнең эшләгәнгә карап, туктап калды. Барыннан да элек, өс-башы күзгә ташланды. Клубка баргандагы кебек киенгән! Мин беренче мәртәбә күргәндәге кебек. Ал кофта, тар кара юбка, биек үкчәле туфли. Чәче матур итеп таралган. Битенә, җитмәсә, кершән яккан. Чынлап. Бүтән киеме беткәндер. Авыл кызы, имеш. Фу, тора лабаса кыланып, кулларын биленә таянып. Йөзенә карамаска әллә ни бирерсең.

— Әйдә, көрәк ал, Зөһрә, эшкә тотын,— дидем мин.

Кузгалмады бу. Шунда безнең янга башлык агай килеп җитте.

— Эшкә болай соңлап йөрмәйләр, сеңлем,— диде, усал гына.— Үзеңнән олы кешеләрдән оялырга кирәк. Әнә алар күпме эшләделәр, син әле яңа күзеңне җырткансың. Мин бит сиңа аерым язмам!

Зөһрә каршы сүз әйтмәде, җирдә яткан көрәкләр янына килде дә үзенә яраклысын сайлап алды, бодай өеменә керде.

Ул болай кәефле генә күренә. Теге яңгыр яуган кичтәге шикелле түгел. Аңлашканнар, ахрысы. Әйе шул, Тимерҗан миңа күтәрелеп тә карамады ич!

## XVIII

Бөтенләй кирәкмәгәндә күңел кырылды. Эш тә әллә ни мавыктырмый башлады.

Тимерҗан һаман машина тирәсендә булаша. Ә бит ул дөрес эшләмәде! Без аңа ярдәмгә килдек. Без монда чит кешеләр. Безгә килмәсәк тә булыр иде. Шулай булгач, безгә алай ук караңгы чырай күрсәтергә тиеш түгел иде. Миннән башка монда бит Таня да бар әле. Мине күрәсе килмәсә, аның белән сөйләшергә була иде. Унны бетергән, имеш. Унны түгел, әллә нәрсә бетерсә дә, барыбер шул Тимерҗан булып калыр.

Калса әллә! Минем өчен барыбер түгелмени?!

Төрлесен уйлангалап, мин әкрен генә кыймылдыйм шулай. Беркем белән сөйләшмим. Хатыннар да, Таня да сөйләшми. Төшкә кадәр беребез дә ачылып китмәдек. Баш калкытмый эшлибез. Бодай өемен бөтен ындыр табагына җәеп ташладык. Шуннан соң беркадәр ял итеп алдык. Ял иткәндә дә рәтләп сөйләшмәдек. Ял иткәч, тагын бодай актарырга керештек. Бер үк бодайны әвештүеш китерәбез, җилләтәбез, киптерәбез.

Сәгать уникe тулу белән, өйгә кайтып киттек. Таня белән бәрәңге пешереп ашадык. Ашадык та амбар янына киттек. Никтер тизрәк барып та җитәсе килә, барасы да килми кебек. Шулай да тагын беренче булып килгәнбез. Хатыннар да, Зөһрә дә юк. Ындыр табак башлыгы хатыннардан да соңгарак калып килде. Ул килгәнче эшкә тотынмадык. Хатыннар белән гәпләшеп утырдык. Алар үзләренең авырулары турында сөйлиләр, миннән киңәшмазар көтәләр. Мин белгән кадәр җавап бирәм, теге-бу чирнең кайчан, ничек булуы турында сөйлим. Хатыннар тын гына тыңлап утыралар. Миңа рәхәт, күңелле.

Шулай сөйләнеп утырганда, башлык агайның килгәнен күреп алдык. Өсләрне каккалап аягүрә бастык та иренеп кенә көрәкләргә тотындык.

Кояш кыздыра. Дымсу бодай чыннан да җилләгән сыман. Көрәккә дә җиңелрәк, аякка да артык кызу түгел. Җәелеп ташланган бодайны бер кат әйләндердек тә комбайннан килгән икенче өемне таратырга керештек. Аннан соң җилләгән, җилгәрелгән бодайны капчыкларга тутырыштык.

Капчык тутырып ятканда, искәрмәстән Равил килеп чыкты. Атка утырган, арбасына мичкә салган. Өстендәге киеме майга, тузанга буялып беткән. Кайдадыр амбар ягында ягулык склады бар икән. Бензин, керосин ише нәрсәләр саклый торган урын. Шунда китеп бара. Безне

күреп алды да, ерактан ук кычкырып исәнләште. Балкып-елмаеп, бераз гына аксаклап, безнең янга килде. Апалары, дигән булды, кулларыгыз кабара күрмәсен, шприц тота алмассыз, дигән булды. Кычкырып сөйләнә-сөйләнә, яңадан арбасына утырды да саубуллашып китеп тә барды. Комбайннарга «гәрүчи» илтәсем бар, диде. Складтан борылып кайтканда да безгә нәрсәдер кычкырып китте. Без аңа кул болгадык, елмайган булдык. Таняны инде әйтәсе дә түгел — кояштай балкый.

Равил китеп күп тә үтмәде, басу ягыннан Тимерҗан килеп чыкты. Мин тагын сискәнеп киттем. Ул икәнен белдем дә, артыма борылып карадым. Авызымны ачып тик торам! Мине хатыннар күреп алдылар. Зөһрә дә, Таня да күрде. Кып-кызыл булдым. Башымны идем дә яңадан кулыма көрәк алган булдым.

Тимерҗан эндәшмәде, сумкалы агай янына китеп барды.

Һай Аллам, егылып үләрсең кешеләрнең кыланышына!

## XIX

Дүшәмбе көн бик күңелсез башланды. Күңелсез башланды, күңелсез бетте. Көне генә түгел, атнасы да авыр, күңелсез узды. Ул атнада бер-бер артлы көтелмәгән хәлләр булып алды.

Шулай бервакыт кабул итү бүлмәсенә олы гына яшьтәге бер хатын килеп керде. Күреп торам, Мәсәгутнеке түгел. Шулай ук тирә-як авыллардан да түгел. Ник дисәң — удмурт хатыны. Минем авылларда удмуртлар юк. Кара күлмәгенең итәгенә буй-буй итеп ал, сары, зәңгәр тасмалар тегеп чыккан. Күлмәк изүендә төрле төстәге чигүләр. Аягында ялт итеп торган резин итекләр. Кулында — кечкенә төенчек.

Килде дә бу, исәнләште, күрсәтелгән урынга утырды.

— Юаны син буласыңмы, апа-ай?— диде.

Татарча бозып сөйли. Сүзләрнең соңгы иҗекләрен сузып әйтә.

— Нинди «юаны», нәрсәнең?— димен, берни аңламыйча.

— Юаны баш тиганнарые,— ди бу.— Миңа юаны кирагые.

Әллә минем сорауны аңламый, әллә колагы ишетми. Чынлап та ишетми, ахрысы.

— Нинди «юаны»? Аңлатып сөйләгез,— димен, кычкырып.

— Ничкасына күренма, юанына курен тиганнарые,— ди хатын, бер үк сүзләрне кабатлап.

Безне тыңлап торган Зөһрә шунда пырхылдап җибә-

рде. Анның шундый әдәпсезлегенә, оятсызлыгына ачуым килеп куйды. Шундук мин моңа мәгънәле күз карашы ташлап алдым. Бу минем ачуланганны күрмәмешкә салынды, каядыр читкә карап, көлгәләгән булып:

— Сине халыкта Юаны дип, Таняны Нечкәсе дип йөртәләр,— диде.

Әһә, менә нәрсәдә икән хикмәт! Ярсудан агарынып киттем. Кемгә ачуланырга да белмим — авызын ерып, мыскыллап торган Зөһрәгәме, үчекләшкән шикелле сөйләнеп утырган удмурт хатынынамы.

— Мин Юаны түгел, мин — Саҗидә!— димен хатынга, кычкырып.

— Нарса? Ничкасымыни?— ди хатын.

— Сөйләгез, кай җирегез авырта?— димен, бар тавышыма кычкырып.

— Кулак ишытмай бит але минем, апаем,— ди хатын. Бармагы белән үзе колагына күрсәтә.

— Күптәнме?— димен, колагына кычкырып.

— Нарса?

— Кайчаннан бирле авырта?

— Ученчы кон мунча кырдем. Тумаланды. Бырни ишитмай, апаем.

— Аңа кадәр яхшы ишеттеңме?

— Мунчада су кыргәндыр димын шул. Бырни ишытмаем, бутынләй тумаланды.

— Акмыймы?

— Калтасу раюныннан мин, апаем. Сине мунда яхшы карай тиганнарые.

— Акмыймы, дим?

— Бигрәк яман икән ул кулагың ишытмагач, апаем.

Моңа кадәр әле миңа чит районнан килгәннәре юк иде. Бу хатынның күрше районнан булуы күңелне җилкетеп куйды. Мин моны бик әйбәтләп, җентекләп карамакчы булдым. Карасам, колагы тулы сагыз!

Такта стенага шакып, теге якта утырган Таняны чакырдым. Ул да карады. Шуннан без икәүләп киңәштек тә колакны юарга булдык. Мин Зөһрәгә күп итеп җылы су әзерләргә куштым. Су әзер булгач, Таня белән икәүләп, удмурт хатынының колагын махсус шприц ярдәмендә юдыра башладык. Шактый озак азапландык. Алмаш-тилмәш юдык. Су түгеп хатынның күлмәкләрен чылатып бетердек. Колакларның икесе дә юылып беткән кебек булгач:

— Хәзер ишетәме?— дидем.

— Тунды. Бутынлай тунды,— ди бу.

— Су кергәнгә тонган,— дидем мин.— Бетәр әле. Иртәгә әйбәтрәк ишетә башларсың.

Шулай юатып моны чыгарып җибәрдем.

Икенче көнне бу тагын иртән-иртүк килеп җиткән. Ишекне ипләп кенә ачты да килеп керде кабул итү бүлмәсенә. Өстендә шул ук киемнәр, кулында кара сумка.

— Колак ничек, апа, ишетәме?— дип кычкырам мин моңа, килеп утырмас борын.

— Ишыта, апаем, айбат буген!— ди бу шатланып, елмаеп.

Никтер бу өстәл янына ук килми, идән уртасындарак туктап тора. Күзләрен мәгънәле генә җемелдәтеп, кил әле дигән сыман, үзе миңа нәрсәдер ымлап ала. Нәрсә булган тагын? Зөһрәдән шикләнә микәнни? Ник шикләнә?

Моның ымлавына буйсынып, шулай да урынымнан тордым. Янына барып җиткәнемне көтмичә, хатын икенче якка ук чыгып китте. Көтеп тору бүлмәсенә. Анда өч-дүрт кеше чират җиткәнне көтеп утыра. Чыктым мин моның артыннан.

— Нәрсә бар?— димен.

— Ишыта, апаем, ишыта!— ди, кычкырып.

— Нәрсә бар, әйтегез шушында гына,— димен.

Хатын эндәшми. Чоланга ук чыгып китте бу. Як-ягына күз төшереп алды да кулындагы сумканы ачып җибәрде. Карасам, ак дәфтәр битенә төрелгән ике йомарлам май. Берсе-берсе берәр кадак булыр.

— Сиңа бу, апаем, сыңныкаш. Кучтанач,— ди бу.— Кулагым бик яхшы ишыта. Рахмат яусын, апаем. Халал ризык, шикланма. Кича гына яздым.

— Юк, юк! Үзеңә булсын, апа!— дидем мин, кул селтәп.

Без шулай сатулашып ятканда, чоланга Зөһрә килеп чыкты. Чиләк күтәреп суга китте. Мине шунда ямьсез бер сизенү өтеп алды. Күңелгә шундук: «Кара, иснәнеп, каранып йөри!»— дигән бер уй килде. Көтеп тору бүлмәсенең ишеге ябылып бетми калган иде. Авырулар ишетеп торсын дигән кебек, юри ныграк кычкырып:

— Юк, апа,— дидем хатынга.— Безгә күчтәнәч кирәкми. Ярамый. Зурлавың өчен рәхмәт. Сезне дәвалаган өчен безгә акча түлиләр.

Шулай дидем дә, хатынны аптырашта калдырып кердем дә киттем. Өстәл янында язып утырганда күреп торам: хатын, сумкасын кул очына тотып, әкрен генә урам буйлап китеп бара.

## XX

Зөһрәнең иртән мыскыллап көлүен дә, минем арттан шымчыланып йөрүен дә нишләптер бик тиз оныттым. Көне буе мин сөенечле бер уй белән йөрдем. «Миңа хәзер

чит районнардан да киләләр!»— дип уйладым, масаеп. Бәлки ул масаю да булмагандыр. Эчкерсез бер шатлык кына булгандыр. Үз эшенең нәтиҗәсен күреп кем генә шатланмас икән?! Әнә... колагым ишетә, ди. Мин дәваладым бит аны. Мин!

Шулай да миңа озак шатланырга туры килмәде. Икенче көнне үк минем кикрик шиңде. Канат сынды. Дөнья ямьсез булып, кап-кара булып калды. Ул көнне Таня өйдә юк иде. Авыруларны мин үзем генә кабул иттем.

Икенчеме, өченчеме кеше булып, кабул итү бүлмәсенә бер агай килеп керде. Озын буйлы, киң күкрәкле. Таза. Бик таза. Мондый кеше турында: басса бакыр өзәрлек, типсә тимер өзәрлек, диләр. Кырык яшьләр чамасы. Битен сакал-мыек баскан. Күрәсең, кырынырга чамасы юк — кулы бәйләүле.

Утырды. Урындык шыгырдап, ыңгырашып куйды. Исемен-фамилиясен, кайсы авылдан булуын сорадым. Алдар авылыннан икән.

— Ни булды, кай җирегез авырта?— дидем.

— Менә, сеңелкәш, үтерә шушы бармак,— ди агай.— Бәйләп кенә җибәрче.

Шулай сөйләнгәләп ул бәйне чиште, кулын миңа табарак сузды. Баш бармагы кып-кызыл булып шешкән, юанайган. Шешү, кызгылт юл булып, беләккә таба сузылган. Шешкән бармакның тиресе юкарган, ялтырап тора.

Шешкән бармакка иплән кенә кулымны тидереп карамакчы булдым. Минем кагылуым булды, агай, коты алынып, ай! дип кычкырып җибәрде. Шундук кулын тартып алды.

— Сез бик әбәләк икәнсез,— дидем, шелтә белән.

— Булмассың әбәләк!— ди агай.— Җылан карагы диләр аны! Бер атна инде күземә йокы кергәне юк. Дошманыңа күрсәтмәсен мондый чирне.

— Ник соң баштарак килмәдегез?— дидем мин.

— И, сеңлем,— ди агай, гаепле төс белән.— Әйтми булмый инде, карчыклардан имнәткәнием. Файдасы тимәде. Имсез китми дигәннәрие.

— Әнә шулай карчыкларга ышанасыз да, атналар буе йоклый алмый җәфаланасыз,— димен, ачуланып.— Ник утыртып куйганнар безне монда?! Ник пункт ачканнар?! Сез имче карчыкларга йөрсеннәр өченмени?

— И, сеңелкәем, әйтмә инде. Наданлык, томаналык,— ди агай, үз-үзен гаепләп.

Диагноз мәсьәләсендә баш ватып торасы булмады. Халык телендә бу «җылан карагы», фән телендә — панариций. Укыган чакта безгә аны берничә мәртәбә күрсәткәннәр иде.

— Ярырга туры килер,— дидем, шундук бер карарга килеп.

— Юк, юк, ярдырмыйм! Дару гына сөрт,— ди агай, чыраен сытып.

— Сез инде бала түгел. Шуннан да куркып торгач!— димен, җиңелчә мыскыл белән.

Шул арада үзем тиз генә кулны юдым, тырнакка, бармак битләренә йод сөрттем. Шул эшләрне бетергәч, агайның авырткан кулын нык кына итеп тотып алдым да, аның ай-ваена карамыйча, шешкән бармакны дезинфекцияли башладым.

— Имче янына барырга курыкмаган, фельдшер янында курка! Әзрәк оялырга кирәк,— дип сөйләнәм үзем, бала-чаганы юаткан сыман.— Курыксагыз — карамагыз. Берни булмас, черки тешләгән кебек кенә. Черкидән дә куркып торгач...

Тиз-тиз генә эшемне бетердем дә күз ачып йомган арада скальпельне алдым. Агай исенә-акылына килергә өлгергәнче, шешне буйга ярып та җибәрдем. Минем ярып җибәрүем булды, яшелле-зәңгәрле тавышлар белән агай, дөнья бетереп, акырып та җибәрде. Кычкырмады — акырып, чинап җибәрде!

Зөһрә көтеп тору бүлмәсендә иде. Пыш-пыш килеп аның анда кем беләндер «суган» сатканы ишетелә иде. Шундук ишектән атылып килеп керде. Ачык ишектә куркынган йөзләр чалынып калды. Башкасын күрә алмадым. Шул ук секундта бармактан шыбырдап кан атылып чыкты. Кан күргәч, агайның, күрәсең, башы әйләнеп китте. Искәрмәстән капчыктай идәнгә ауды да төште.

Тотып кала алмадым. Көчем җитмәде. Аннан соң мин аны һуштан язар дип башыма да китереп карамадым. Минем өчен бу аяз көнне яшен суккан кебек булды.

Зөһрәгә шкафтан нашатырь спирты алырга куштым. Ул агайның борын төбенә нашатырь спиртына манчылган мамык тидерде. Идәндә хәрәкәтсез яткан агай бераздан әкрен генә тын алды, төчкереп җибәрде, кыймылдап куйды, күзләрен ачты. Бичараның маңгаеннан салкын тирләр бәреп чыкты.

Мин тиз генә тәрәзәне барып ачтым, барлык ишекләрне ачып җибәрдем. Бүлмәгә саф һава бөркелеп керде. Агай торырга азаплана башлады. Зөһрә белән без аңа ярдәм итмәкче булдык. Ләкин ул бик авыр булып чыкты. Шунда безгә көтеп тору бүлмәсеннән бер егет кереп булышты. Өчәүләп моны яңадан урындыкка утырттык. Тиз-тиз кыланып, мин ярылган бармакны бәйләп куйдым, агайның кулындагы кан тапларын сөртеп алдым.

— Менә бүген инде рәхәтләнеп йокларсыз,— дигән булдым, юатып.— Иртәгә бәйләтергә килерсез.

— Ярма дип әйттем мин сиңа,— диде агай, ыңгырашып.

— Ярмыйча ярамый,— дидем мин.— Ярмасаң, азуы мөмкин.

Минем сүзләремә агай ышангандырмы, юктырмы — әйтә алмыйм. Шулай да аның ачуы, кәефсезлеге миңа да тәэсир итте. Үземнең дөрес эшләгән булуыма никадәр нык ышанган булмыйм, барыбер күңел тиешенчә тынычлана алмады. Мин үземне гаепле итеп сизә башладым. Агайдан соң кергән авырулар хәзер миңа шикләнеп карыйлар шикелле тоелды.

Кикрик шиңү менә шуннан башланды.

Авыруларны карап бетергәч, үзебезнең якка чыктым. Кулыма «Хирургия» китабын алып, «Панариций» темасын укып караган идем, телсез-өнсез калдым. «Ах, туң баш!»— дидем үземә-үзем. Үкенүдән, йөрәк әрнүдән күзгә яшьләр килде.

Бармакны мин иртә ярганмын. Шеш тулып җитмичә. Бармак авырткан чакта, бик нык авырткан чакта ярганмын!

Икенче көнне агай килмәде. Минем хәсрәтне көчәйтеп җибәрергә бу тагын бер сәбәп булды. Эштән соң мин аның өенә дә бармакчы булдым. Ләкин икеләндем. Ни булса да булыр дидем дә бармадым. Соңыннан мин аны шулай да очраттым. Бармагы инде төзәлгән иде. Ул миңа бернинди шелтә белдермәде. Көлеп кенә куйды. Җитмәсә, рәхмәт тә әйтте. Сүзең дөрес булды, сеңелкәш, ул көнне тынычлап йокладым, диде.

Безнең очрашу бер-ике айдан соң гына булды. Ә ул чакта чыбыксыз телефон аша миңа бик үк күңелле булмаган сүзләр ишетелде. Үземә генә дә ишетелеп калмады. Түгәрәк дулкыннар булып, минем турыдагы имешмимеш бөтен авылга таралды. Көннәрдән бер көнне мине авыл Советына чакыртып алдылар.

## XXI

Авыл Советында Галим абый белән Вәзирдән башка кеше юк иде. Мин Галим абый кабинетына кердем. Галим абый утырырга кушты. Утыргач, кырыс кына бер карап алды.

— Беләсеңме, нәрсәгә чакырттым мин сине, сеңлем?— диде.

— Белмим шул, Галим абый,— дидем мин.

Ни өчен чакыртканлыгын белмәсәм дә, яхшыга түгеллеген алдан ук сизенеп алдым. Нинди гаебем бар икән

дип, шундук үткән көннәрне күз алдына китердем, тегенди-мондый нәрсәләрне искә төшердем. «Күрәсең, Вәзир әләкләшкәндер, пунктта аулагөй ясап яталар дип әйткәндер»,— дип уйладым. Үземә калса, минем иң зур «гаебем» бары шул гына иде. Күңелгә тиз арада әзер сораулар, җаваплар килде. Ләкин сөйләшә башлагач, минем бу сорау-җавапларның берсенә дә кирәге калмады.

— Белмәсәң, менә шул, сеңлем: синең турыда начар сөйлиләр,— диде Галим абый.— Күңелеңә авыр алма. Сөйләшми ярамый.

Мин дерт итеп киттем. Кая инде ул авыр алмаган! Йөзеңә карап: «Син начар!»— дип әйтсеннәр әле! Кем моңа тыныч карый алыр икән? Мин кып-кызыл булдым, Галим абый, җаныңны суырып алырдай булып, бертуктаусыз күзгә карап тора. Күрәсең, йөзгә карап дөресен белмәкче була.

— Нинди начар сүз, Галим абый?— дидем, ипләп кенә, юаш кына.

— Ниндиме? Бәлки, син үзең дә беләсеңдер — сөйләп бир... нинди гөнаһларың бар?

— Ишеттем...— дидем мин.

— Нәрсәне ишеттең?

— Нәрсәне дип... Бармак ярганны сөйлиләр. Аннары юлда бала таптырганны...

— Нинди бала тагын?

— Теге Тау-авылныкы соң. Беренче көнне. Рәмзия исемле хатын... Баласы әйбәт үсә. Берни булмаган.

— Ярар, анысы да булды. Тагын?

— Тагын дип... Тагын шул инде: бер картның тешен суырганда сынып калганые. Анысы да беренче көннәрдә. Безне теш суырырга өйрәтмәделәр. Мин инде үзлегемнән. Китаптан карап. Үзе сорады бит, авыртса да түзәрмен, теләсә ничек суырып ал, диде. Мин әле аның сынып калган тешен дә алдым.

— Ярар, монысы да булды,— диде Галим абый, тыныч кына.— Тагын?

— Тагын дип... тагын шул, әнә Вәзир абый белән әйткәләштек. Бинт юк. Акча бирми. Хәзер әнә тәрәзәгә элгән марляларны кисеп бинт ясадык. Минем өстә лә алар барысы да, Галим абый! Мин бит яраны бәйләми җибәрә алмыйм. Инфекция булырга мөмкин, азарга... Аннары кем җавап бирә?

— Ярый... Тагын!— диде Галим абый, сабырлыгын җуя башлап.

— Тагын... ни... шул... Заһидә апа белән әйткәләштек. Үзе әнә әләкләшеп йөргән юк-барны... Вәзир абыйга.

Авыргач, без аның баш очыннан да китмәдек. Таня гел кереп торды. Хәзер әнә йөри. Берни юк. Безгә әллә кеше дә керми торырмы?

Шул чакны үз бүлмәсенең ачык ишегеннән секретарь кычкырды:

— Мин сезгә кеше кермәскә тиеш димәдем,— диде.

Мин аның Галим абый алдында ялагайлануын сизеп алдым да, батыраеп:

— Вәзир абый олы кеше, үзе әнә төрле гайбәт сүзләргә колак сала,— дидем.— Безнең сүзгә ышанмый. Нәрсә... кем дип җибәргәннәр безне монда? Ышанмасалар, җибәрмәсләрие. Минем әле беркемгә дә ялган сөйләгәнем юк.

— Ярар, сеңелкәем,— диде Галим абый.— Вәзир абыең белән нәрсә турында сөйләшкәнсездер — анысы миңа караңгы. Бинт турында ул дөрес әйткән. Сметадан узып без бернәрсә дә эшли алмыйбыз. Киләчәктә бинтларыңны саклабрак тотарга тырышырсың.

— Шулай итәрмен, Галим абый,— дидем мин, тиз генә килешеп.

— Заһидә апаң белән тиргәшүең әйбәт булмаган, сеңлем. Бик ямьсез булган.

— Шулай шул,— дидем мин.

— Дөрес, алар пункт йортында торырга тиеш түгелләр. Аларга инде яхшылап әйтелде. Шулай да без аларны урамга куалап чыгара алмыйбыз. Шуның өчен аларны кыерсыту... фельдшер кешегә килешеп бетми. Син бит интеллигенция! Ярамый, икенче кабатланмасын! Колагыңа киртеп куй моны.

— Ярар, Галим абый, киртеп куярмын,— дидем мин.

Шуннан Галим абый эндәшмичәрәк торды, минем йөзгә тагын бер төбәлебрәк карады да:

— Удмурт хатыныннан май алдыңмы?— диде.

— Юк, алмадым,— дидем мин, каушап, аптырап.

— Чынмы?

— Чын, Галим абый.

— Ник халык сөйли соң? Миңа килеп әйтәләр... фельдшер Саҗидә авырулардан май, күкәй алып ята, диләр, үзен майлаган-җайлаган кешене генә яхшы карый, шундыйларга гына яхшы дарулар бирә, диләр. Дөресме шул?

— Дөрес түгел, Галим абый!— дидем, калтырана башлап.— Мин беркемнән май да, күкәй дә алмадым. Майны мин үзебездән алып килдем, Яңавылдан. Күкәйне дә. Ышанмасагыз, әнә Танядан сорагыз.

— Мин сиңа ышанам, сеңлем,— диде Галим абый.— Ләкин мин ышану гына җитми. Җилсез агач шауламый. Димәк, шулай да нидер булган? Ни булды?

Ни булганын мин сөйләп бирдем.

— Мин сиңа ышанам,— диде Галим абый, кабатлап.— Ярар, сүзне шуның белән бетерик. Борчылма... күңелеңә авыр алма. Кыен булса, андый-мондый йомышың булса, икенче туп-туры үземә кил — ничек тә уртак тел табарбыз.

— Килермен, Галим абый,— дидем мин, җиңеләеп.

Авыл Советы председателе бүлмәсендә шундыйрак сөйләшү булды. Галим абый яныннан мин тынычланып, яңарып, үз-үземә тулы ышаныч белән чыгып киттем. Мин нишләптер беркемгә дә ачуланмадым. Бары гаҗәпләндем генә: кем сөйли алыр икән шундый чеп-чи ялганны? Удмурт хатыны булмас. Ул әйтер иде, күчтәнәчкә май алып килгән идем, алмады, дияр иде. Алмады дигәч, алмаган дип сөйләрләр иде. Кем соң алайса? Шул көнне минем кабул итүне көтеп утырган авыруларның берәрсеме? Әллә соң Зөһрәме?

Мөгаен, шулдыр! Нишләтергә аны? Нишләргә аның белән? Әллә кайтып пыр туздырып ташларгамы? Куалап чыгарырга?! Ничек эшләргә, ничек яшәргә киләчәктә аның белән? Каян килеп чыкты соң бу Тимерҗаны да?

Минем күңелдә төрле уйлар буталды. Мин әлегә нишләргә дә белмәдем. Тик шулай да минем өчен бернәрсә ачык: моннан соң миңа ничек тә акыллы, сабыр булырга кирәк. Түзәргә кирәк, барысын да уйлап эшләргә кирәк. Мин бит сүз бирдем!

Ләкин күп тә үтмәде, минем барлык уйларны, барлык хис-тойгыны икенче якка борып җибәргән кайбер вакыйгалар булып алды.

## Өченче бүлек

### I

Беркөнне мине Куштирәк авылыннан килеп алдылар. Биш-алты яшьләрдәге бер малай чирләгән. Сөйләүләренә караганда, хәле бик яманга охшый. Башы, тәне уттай яна, ди, коса, саташа, ди. Кайчагында аңын югалтып куйгалый, ди.

Бардым, карадым. Малай агач сәкедә ята. Нәкъ үлем түшәгендә яткан кебек. Астында иске тун, баш очында кызыл тышлы мендәр. Тирә-ягын чатыр кебек итеп кызыл чаршау белән әйләндереп алганнар. Йөзе кып-кызыл, күзләре ярым йомык. Градусник куеп караган идем, температурасы 39 чамасы.

— Нәрсә?— ди яшь кенә ана, эчке бер каушау белән.

— Хәзергә берни әйтеп булмый,— димен.— Әллә ни куркыныч нәрсә юк. Шулай да баланы өйдә калдырырга ярамый. Яңавылга хәбәр итәргә туры килер. Бәлки, больницага салырлар.

— Бүлнискә?!— ди хатын, коты алынып.— Юк, туганкаем, теләсәң нәрсә әйт, анда илтеп бала үтертер хәлем юк! Үлсә өйдә үләр.

— Сезгә кем әйтте үләр дип?!— димен, кырыс кына.— Әллә бала чирләми торамы?

— Әйтмә! Анда гына бала, аңа гына кадерле!— ди абый кеше, хатынына ачуланып.

— Әллә мине күрми дисең?— ди хатын, еламсырап.— Бырачның әйтәсе килми. Бирмим баламны, үлсә өйдә үләр.

Белмим, әллә инде аны мин килгәнче берәрсе куркытып куйган, әллә чынлап та ул вакытта минем кыяфәтем бик шикле булган,— апа кеше тикмәгә генә сөйләнми иде, ахрысы. Бәлки, аның күңеле сизенгәндер?

Мин аны үземчә юатырга тырышам, берни юк, берни булмас, димен. Күңелемнән үзем һич тә алай уйламыйм. Минемчә, бу полиомиелит дигән авыру булырга тиеш.

Полиомиелит — йогышлы авыру. Күбесенчә ул яшь балаларда була. Полиомиелит белән авырганда, баланың арка мие зарарлана. Еш кына паралич суга. Тап-таза аяклар, куллар җансыз әйбер кебек салынып кала. Кеше гомер буена шулай хәрәкәтләнми торган, үсми торган аяк-куллар белән гарип калырга мөмкин.

Ул елларда Яңавыл районының кайбер авылларында менә шул куркыныч авыру күренә башлаган иде. Шуңа күрә, полиомиелит районндагы медицина халкының ко-

тын алган иде. Әгәр дә мәгәр берәр авылда шуңа охшаш берәр авыру булса, шундук районга хәбәр итәргә дип, безгә алдан ук кисәтү ясап куелган иде.

Мин үземнең дөрес диагноз куюыма әз генә шикләнмәдем. Полиомиелит турында мин әле шушы арада гына китаптан укыган идем. Райздрав биргән күрсәтмәләрне истә тотып, мин, Мәсәгуткә кайткач та, Яңавылдагы тиешле урыннарга шалтыраттым.

Икенче көнне төшкә таба, «ашыгыч ярдәм» машинасына төялеп, Яңавылдан биш-алты кеше килеп төште. Алар арасында Соломон Моисеевич та бар иде.

## II

Алар башта безнең пунктка тукталдылар. Машинадан төштеләр дә, җыйнаулашып, тәрәзәләргә карана-карана, капкага юнәлделәр, капка алдында бераз җыелып торгач, ишегалга керделәр.

Мин әле авыруларны кабул итеп бетермәгән идем. Көтеп тору бүлмәсендә ике-өч кеше бар. Минем бүлмәдә, өстәл янында, шулай ук бер авыру утыра. Соломон Моисеевичны күреп алдым да куанычымнан елмаеп җибәрдем. Соңгы атнада бу минем беренче елмаюым булды, ахрысы. Көн ямьсез иде, болытлы иде. Иртәдән башлап яңгыр яварга җыена иде. Миңа кинәт кояш чыгып киткән төсле булды. Авыру янында Зөһрәне генә калдырдым да, ашыгып, ишекләрне орып-бәреп, кунакларны каршыларга чыгып киттем.

Мин аларны кайгырган-борчылган итеп күз алдына китергән идем. Беркемнең йөзендә борчылу билгесе күренми. Барысы да шат, көләч. Бигрәк тә Соломон Моисеевич. Аннары санэпидстанциянең баш врачы Ульяна Архипова.

Соломон Моисеевич, мине күргәч, юлдашларына нәрсәдер әйтеп алды. Барысы да шаркылдап көләргә тотындылар. Миңа карап көләләр. Мыскыл итеп көлмәгәнлекләрен күреп торам. Яратып, шаяртып көләләр. Ни өчен көлгәнлекләрен аңламасам да, мин дә көлгән булам, исәнмесез, димен, әйдәгез, түрдән узыгыз, димен.

Алар шулай шаулашып, көлешеп баскычтан менделәр, өйгә керделәр. Авырулар яныннан узганда, артык шаулашмадылар. Безнең торак бүлмәгә кереп тулдылар да, кем каян урын таба, шунда урнаштылар.

Мин аларны озата кердем, аннары, гафу үтенгәндәй:

— Мине авырулар көтеп тора бит әле,— дидем.

— Барыгыз, бар, карагыз,— диде Соломон Моисеевич.

Кая басканымны да белмичә, тулган ай кебек балкып, мин икенче якка килеп чыктым. Нишләптер кисәк кенә зиһенем чуалып китте. Өстәл янына утырдым да каршымдагы бабайга:

— Исемегез, фамилиягез?— димен.

— Яздың бит инде, кызым,— ди бабай, хәлсез генә.

— Яздым? Ә, язганмын икән! Кайсы авылдан?

— Кызыл Ярдан. Анысын да яздың, кызым.

— Язганмын икән шул,— дигән булам мин, тынычланмакчы булып.

Үзем һаман теге якка колак салам. Өзек-өзек булып Соломон Моисеевичның сүзләре ишетелеп китә. Аңа каршы тагын тыелып кына көлешеп куялар, пыш-пыш киләләр. Юлда, күрәсең, берәр кызык нәрсә турында сөйләшеп килгәннәр дә, әле булса шуның тәэсиреннән котыла алмыйлар.

— Кай җирең авырта, бабай?— димен, соравымны дәвам итеп.

— Сорадың бит инде, кызым,— ди бабай тагын да, ризасызлык белән.

— Сорадыммыни?— дигән булам, исем китеп.— Кайчан сорадым? Сорадым бугай шул. Ничек әле?

— Тамактан үтмәй, кызым. Аш үтмәй. Әпине дә сөттә җебетеп кенә ашаймын. Әзрәк сөт эчәм дә чәй эчәм. Тамактан үтмәй. Ашамагач, хәл юк. Шушы атна төшендә генә дә күзгә күренеп ябыктым. Куәт юк, кызым.

Ул әкрен генә сөйли, хәлсез тавыш белән генә. Мин аның йөзенә игътибар беләнрәк карап алам. Чыннан да, бик ябык. Яңак сөякләре, тиресен тишеп чыгардай булып, төртелеп тора. Күзләре эчкә баткан, нурсызланган. Чырае агарып-саргаеп калган.

— Җен кору зәхмәте диләр, кызым. Белмәм тагын. Менә сиңа килдем. Син ни әйтерсең. Кортка да, малайлар да сиңа күренеп карарга куштылар. Тамактан үтсә, башкасына кайгырмасыең. Тамактан үтмәй. Ни хикмәттер инде, кызым.

Мин бабайны бүлдерми генә тыңлап торам. Бичара, бу минутта ул мине Алладан да артык күрәдер, бәлки. Аның ялварулы нурсыз күзләре, ябык чырае — бөтен кыяфәте шул турыда сөйли. Ләкин нишли алам мин? Нәрсә әйтергә аңа? Рентгеннан карамыйча, кирәкле анализлар алмыйча, каян беләсең аның нәрсә икәнлеген?!

Минем шунда күңелгә бер уй килде.

— Яңавылдан әнә олы докторлар килде,— димен бабайга.— Күрсәтеп карыйк әле сине шуларга.

— Бик әйбәт булыр, кызым,— ди бабай.— Үзем дә әйтмәкче булганыем, кыймадым.

## III

Кунаклар арасында «олы докторлар»дан ике генә кеше. Беренчесе, билгеле, Соломон Моисеевич. Медицина институтын ул Мәскәүдә бетергән. Моннан ике ел элек. Укуын бетергәч, аны Уфага җибәргәннәр. Уфа безгә җибәргән. Әйтүләренә караганда, укуын ул бик яхшы тәмамлаган. Килгәч тә аны район сәламәтлек саклау бүлеге мөдире итеп билгеләгәннәр.

Икенче «олы доктор»— Ульяна Архипова. Институтны ул Казанда бетергән. Кайберәүләр әйтә, имеш, алар Соломон Моисеевич белән йөриләр икән, ди. Ләкин мин моңа ышанмыйм. Тамчы да ышанмыйм. Булуы мөмкин түгел. Ульяна Архипова ямьсез. Үзе сары, үзе килбәтсез. Күзләре зәңгәрме, яшелме — аңламассың. Борыны зур. Бите бит түгел — кытыршы, тупас. Исең китәр, институт бетергән кеше дә шундый ямьсез булыр икән!

Югары белемле кешеләрдән бары шулар гына. Алар белән тагын дезинфектор Мәдинә апа килгән. Арада ул иң олысы. Яше буенча. Аңа кырык-кырык бишләр чамасы булыр. Ул башкалар кебек юкка-барга көлми дә, шауламый да. Аннары санитария фельдшеры Соня. Япьяшь. Нечкә билле. Шәһәрчә матур. Тик тавышы гына тупасрак. Алардан кала тагын бер фельдшер кыз.

Шушы көннәрдә генә Мәсәгут пунктына керә торган авылларны икегә бүлеп, яңа пункт ачу турында сүз булган иде. Яңа пунктка өч авыл керәчәк: Куштирәк, Түбән Чат, Югары Чат. Медпункты Түбән Чатта булачак. Минем карамакта бары дүрт кенә авыл калачак: Мәсәгут, Алдар, Тау-авыл, Кызыл Яр.

Мин танымаган кызны менә шул яңа оештырылган пунктка мөдир итеп алып килгәннәр икән. Анысын соңыннан белдем.

Чыктым теге якка. Туп-туры Соломон Моисеевичка мөрәҗәгать итәргә ничектер кыюлык җитмәде. Санитария врачына ялынырга туры килде.

— Иптәш Архипова,— димен,— анда бер авыру бар. Чыгып кына карамассыз микән?

Архипова карышып тормады. Юл чемоданын ачып, чиста ак халатын киде дә минем белән кабул итү бүлмәсенә керде. Мин аңа бабай турында белгәннәремне кыскача гына тәрҗемә итеп бирдем. «Олы доктор», уйлангандай итеп торды да, бабайга күлмәген салып сәкегә ятырга кушты. Эчен капшап карады, суккалап карады. Капшаган саен, суккалаган саен, Таня кебегрәк итеп:

— Аорта? Аорта?— дип сорады.

Кай төше турында сорасаң да, бабай, авырта, кызым, авырта, ди. Кай җиренең авыртканын ул үзе дә ныклап аермый, күрәсең.

— Соломон Моисеевичка әйтеп карарга кирәк,— диде «олы доктор» бераздан, әкрен генә.

Бабайга без киенми торырга куштык. Архипова теге якка чыгып китте. Койрык булып, мин дә аның артыннан тагылдым. Архипова түрдә өстәл янындагы урындыкта кырын-ярын утырып торган Соломон Моисеевич янына барды, бүтәннәр ишетмәсен дигән сыман, ипләп кенә үзенең йомышын әйтте.

— Ничего! Үзегез карагыз!— диде Соломон Моисеевич, кычкырып.— Мин сезгә ышанам.

Ул моны ничектер җиңел генә әйтте, шаярып, көлешеп сөйләшкәндәге кебек кенә итеп әйтте. Аннары, Ульяна Архипованы да, аның йомышын да онытып, Соняга нәрсәдер эндәшеп куйды.

Бу миңа бераз гына гаҗәбрәк тоелды. Шулай да күңелемнән сөенеп куйдым. Димәк, Ульяна Архипованы ярата икән дигән сүзләр дөрес түгел! Яратса, билгеле, ул аның сүзләрен тыңлаган булыр иде.

— Саша, бәлки, карарсың, ә?— диде Архипова тагын да.

Монысында ул бик йомшак итеп, үзенчә бик ягымлы итеп эндәште.

— Улечка, мин бит сиңа тулысынча ышанам!— диде Соломон Моисеевич, елмаеп.

Аның бу елмаюында күрәләтә санга сукмау сизелде. Күңелемнән мин пырхылдап җибәрдем: «Улечка! Шәп булды Улечкага!»— дидем.

Улечканың кәефе кырылгандай булды. Шулай да ул кеше алдында үзенең кәефсезләнгәнлеген күрсәтмәскә тырышты. Ясалма бер елмаю белән елмайгандай итте дә без тагын кабул итү бүлмәсенә чыктык.

Бабайга мин киенергә куштым. Бабай киенде, яңадан үз урынына утырды. Без әкрен генә Улечка белән үзара сөйләшеп алдык, бабайга: «Яңавылга барырга, рентгенда каралырга, хирургка күренергә кирәк»,— дидек. Аннары, врач әйтүе буенча, мин рецепт яздым, Яңавыл поликлиникасына кәгазь яздым.

## IV

Авыруларны карап бетергәч, яңадан үзебезнең бүлмәгә чыктым. Анда инде күптән мине көтеп утыралар.

Бүген төнлә яңгыр яуды. Яңгырлар бу арада ешаеп китте. Юллар пычрак, авыр. «Ашыгыч ярдәм» машинасы

Ямадыдан Мәсәгуткә бик авырлык белән килгән. Шофер Куштирәккә барудан баш тарткан. Машинаның болай да рәте юк, батып ятсак, бөтенләй Яңавылга кайта алмабыз, дигән. Минем анда барганым бар, юл начар, дигән. Кунаклар аптырабрак калганнар, нишләргә дә белмиләр.

— Тизрәк барып җитәсе иде,— ди Улечка, Соломон Моисеевичка караштырып.— Никтер күңел үз урынында түгел.

— Моңарчы нәрсә карадыгыз? Бирермен мин сезгә кирәгегезне! Минем районда — инфекция!— ди Соломон Моисеевич, шаяртып, кычкырынгалап.

Шуннан соң бу миңа борылды да, елмаеп:

— Менә иптәш Фәррахова ни әйтер бит әле!— диде.— Без аның карамагында. Теләсә нишләтсен.

Кызлар көлешеп миңа карыйлар. Аларга ияреп, мин дә көлгән булам. Үзем көләм, үзем кызарам.

— Нишләргә? Ат сорарга кирәк!— димен, җиңел генә.

— Әлбәттә, ат сорарга!— ди Соломон Моисеевич.— Безнең машинаны тартып алып барырдаен, көчлерәген...

— Чынлап та!— ди Улечка, сөенеп.— Акыллым, бар син сора. Тизрәк барып җитәргә кирәк. Ике ат сора. Икене, яхшыны!

Улечканың йомыш кушуы миңа бик үк ошап җитмәде. Шулай да ы-мы итеп тормадым, тиз генә икенче якка чыктым. Зөһрә шприцлар сөртеп маташа.

— Бар әле, колхоз идарәсенә кереп ат сора. Куштирәккә барырга. Ике ат,— димен.

Зөһрәнең болай да чытык йөзе тагын да ныграк бозылып китте.

— Миңа бирәләрмени алар?— ди бу.— Үзең сора!

Сатулашып тормадым. Чыннан да, аңа бирмәүләре мөмкин. Тоттым да үзем чыгып йөгердем.

Колхоз идарәсендә бухгалтердан башка беркем юк. Ат турында сүз чыгаргач: «Мин белмим»,— дип кенә җавап бирде. Күп уйлап тормадым, туры председатель өенә йөгердем.

Мин барып кергәндә, председатель яңарак кына басудан кайтып кергән иде, ахрысы. Кәефе юк. Булмас та шул — колхозның эшләре шәптән түгел. Басуда җыелмый калган бик күп ашлык ята. Амбар алдында ашлык кыза. Киптереп өлгерә алмыйлар. Дәүләткә ашлык тапшыру буенча да колхоз артта бара.

Колхоз председателе белән без бик үк дус түгел. Ул безне күрми дә, белми дә. Беркадәр дәрәҗәдә ул безне әрәм тамаклар дип, эшлексезләр дип исәпли. Ул болай да тупас, кире кеше.

— Мирсәет абый, безгә яхшы гына ике ат бир әле... Тизрәк кирәк,— дидем мин килеп кергәч тә, тыным бетеп.

Мирсәет абый, аптырап, кашларын җыерып карады да:

— Кыз да булсын, буаз да булсын,— дип куйды.— Нәрсәгә? Кая барасыз?

Мин моңа аңлатып бирдем. Тизрәк кирәк, димен, район здрав мөдире көтеп тора, димен. Мин инде ничек тә Соломон Моисеевич исеме белән алдырмакчы булам. Үземчә, бу кирәгенчә тәэсир итәр дип уйлыйм, район начальнигы кушкач, берсүзсез ике атны безнең капка төбенә китереп туктатырга кушар дип уйлыйм.

Мирсәет абый эндәшмәде, тузгыган каты чәчләрен артка сыпырып куйды да тәрәзә аша тышка, ялтырап яткан пычрак урамга карады.

— Ат юк. Ялга туктатылды барысы да,— диде.

— Минем үземә түгел бит, Мирсәет абый!— димен мин, мондый җавапка нәрсә әйтергә дә белмичә.

— Минем эшемә йөрмиләр әле,— ди председатель, тупас кына.— Әнә Ходайбирдин калхузыннан сорагыз.

Ачудан, гарьләнүдән кып-кызыл булдым. Менә сөйләшеп кара син аның белән! Шундый да надан, шундый да аңсыз кеше булыр икән!

— Алар да үз эшләре белән йөрмиләр,— димен мин, кыза башлап.— Кеше анда үләргә ята, монда сезгә ике атыгыз да җәл.

— Ике? Ике түгел, берсе дә юк, сеңлем. Башымны катырма. Кирәк икән, җәяү барырлар. Тик ятып симереп беткәннәр, дуңгыз кебекләр. Бар, шулай дип әйтте, диген.

Мин шаккаттым! Минем котым алынды! Ничек теле бара аның? Ничек теле әйләнә? Ничек оялмый ул?!

Мин аңа каршы бер генә сүз дә әйтә алмадым. Минем авызым йомылды, телем тотлыкты. Кырт кына борылдым да, үземчә бик усал итеп:

— Хушыгыз!— дидем.

Ишекләрен шапылдатып яптым да, чыктым да киттем.

## V

Мин авыл Советына киттем. Бәхеткә каршы, Галим абый шунда булып чыкты. Мин аңа үземнең хәлне сөйләп бирдем. Соломон Моисеевич турында тагын начар сүз ишетүдән куркып, монысында аны бөтенләй телгә дә алмадым. Күбрәк авыру балага, инфекция таралу куркынычына басым ясадым.

Галим абый сүзсез генә тыңлап торды да өстәл читенә суккалап алды, беравык уйланып утыргандай итте.

— Ярар, минем атны алырсыз,— диде.— Алмаштилмәш утырып барырсыз. Сез яшьләр җәяү тәпиләсәгез дә таманга килер.

— Минем үземә ничек тә ярый, Галим абый!— димен, куанып.— Мин җәяү йөреп өйрәнгән.

— Шулайдыр, шулайдыр,— ди Галим абый.— Хәзер җигеп китерерләр. Әзерләнеп торыгыз.

Мин йөгереп пунктка кайттым. Кайтсам, чоланда Улечка көтеп тора.

— Менә нәрсә, акыллым,— ди бу миңа.— Хәзер төш җитә. Без барыбер төшкә кадәр барып җитә алмыйбыз. Аннан тагын кире әйләнеп тә кайтасы бар. Соломон Моисеевич төшке ашны ашамый булдыра алмый. Мин үзебез белән коры-сары алып чыктым чыгуын. Шулай да Соломон Моисеевич аңа гына канәгать булмас.

— Аш пешерербез!— димен мин.— Безнең зур чуен бар. Тутырабыз да шуны, пешерәбез. Итле аш!

— Тиз өлгермәс шул инде ул,— ди Улечка, үз-үзенә каршы килеп.

— Өлгерә, өлгерә!— димен мин.

— Ярар алайса. Күп булса, ике сәгать көтәргә туры килер. Анда инде көнне дә ачып җибәрер, бәлки,— ди Улечка.

Менә бәхет! Мин Соломон Моисеевичны кунак итәм! Дөнья кинәт үзгәреп китте. Ямьсез Улечка искиткеч матур булып күренде. Әлерәк кенә көлке ишетелгән «Улечка» сүзе ягымлы булып тоелды.

Шулай да бераздан мине борчу биләп алды. Борчу да түгел инде, болай гына, уйлану гына... Зур чуенда итле аш пешерергә ризалык биргәндә, мин кайбер нәрсәләрне уйлап җиткермәгәнмен. Алар бит биш-алты кеше, Таня белән мин генә түгел. Таня дигәннән, иртүк ул авылларга чыгып киткән иде. Төш вакытларына аның да кайтып җитүе мөмкин. Шулай булгач, ашны биш-алты кешегә генә дә түгел, алты-җиде кешегә пешерергә туры киләчәк. Каян җиткермәк кирәк аларга азыкны? Икмәк инде җитәр. Җитмәсә, күршеләрдән алып торырга була. Ә ит? Бозыла дип мин итне өйдән күп алып килмәдем. Авылда мал-туар суючы бөтенләй диярлек юк. Суйсалар да, авылда сатмыйлар, Яңавылга алып китәләр. Анда кыйбатрак. Нишләргә? Тагын колхоз председателенә барыргамыни? Әллә Галим абыйгамы?

Улечка шунда миңа күпмедер акча сузды. Мин, хурланып, акчаны кире кактым. Шушы арада гына айлык эш хакы алган идем. Мин әле аны тотарга да кызгана идем. Үземә берәр яхшырак күлмәк алырмын дип саклый идем.

Бүлмәгә кердем дә чемодан төбеннән шул акчаны алдым. Аннары икенче якка чыктым. Зөһрә әле кайтып китмәгән. Әллә ни эше булмаса да, эшем кешесе булып, һаман шул шприцлары белән, шкаф пыяласының тузанын сөртү белән булаша.

— Зөһрә!— димен мин моңа.— Хәзер үк безгә биш кило ит табарга кирәк. Хәзер үк!

Тегенең ике күзе дүрт булды.

— Биш кило!— ди бу, кычкырып.

— Кычкырма шулкадәр,— димен мин.— Хәзер үк аш пешерергә кирәк. Әйт, кемдә ит бар?

— Белмим,— ди бу, сүлпән генә.— Шулкадәр мәшәкатьләнеп торганчы, чәй генә кайнатырга да бирергә.

— Син нәрсә!— димен.— Соломон Моисеевич чәй эчәмени? Ул бит синең белән мин түгел.

— Әллә кем дә түгел!— ди бу, кашларын җыерып.— Берәр дистә йомырка пешерергә була...

— Ничек инде ул әллә кем булмасын?!— димен мин.— Кыскасы, сатулашып тормыйбыз. Әйт, каян ит табарга?

— Каян табасың авылда юк итне?— ди бу.

— Ике бәясенә алабыз. Күпмегә булса да алабыз!— димен мин, йодрыктагы акчаны күрсәтеп.

— Туктале, алай булгач,— ди бу, уйланып.— Әллә колхоздан сорап карыйсыңмы? Аларның булмый булмас. Тракторчыларга суялар алар.

— Юк, булмый!— димен, кырт кисеп.— Әле генә председательдә булдым. Бирмәс.

— Гайшә апаларга кереп карале, ул белми микән,— ди бу.

## VI

Гайшә апалар безгә күрше йортта гына торалар. Без аларга әледән-әле йомыш белән кергәләп йөрибез. Кайчакларда Гайшә апа үзе дә керә. Кулы киселсә-нитсә йод сөрттерә, күзем кычыта дип, күзенә дару салдыра.

Кердем дә Гайшә апага бер-ике сүз белән үземнең йомышымны сөйләп бирдем.

— Ит булмас ул хәзер авылда,— ди Гайшә апа.— Йөрүең генә калыр. Үзем берәр тавыгымны суйдырып бирерием дә, барысы да күкәй сала. Җәлрәк шул, апай. Быел тавык утыртмадым. Җәлрәк шул. Биш тавыкның берсен суйсаң, дүрт кала, дүртнең берсен суйсаң, өч кала.

— Бер тавык кына җитмәс,— димен мин.— Болай булгач, кимендә ике тавык кирәк. Минем акча бар. Артыгы белән түлим.

— Берсе дә җитеп торырые әле аның,— ди Гайшә апа.— Син инде ачуланма. Кара, ник Зөһрәләрнең үзләреннән сорап карамайсың? Аларның тавыклары күптер. Нык тормышлы кешеләр бит алар.

Гайшә апаның сүзләре миңа бик дөрес булып тоела. Чыннан да, ник баш ватарга? Күптән шулай итәсе калган!

Гайшә апалардан чыктым да, пунктка кереп тә тормастан, чаптым Нәсимә апаларга. Чаптым дигәч тә, кая ул чабу! Аяк асты пычрак. Аякта тишек-мишек танкетка. Әледән-әле таеп китәм, егылмас өчен берәрсенең урам ягындагы бакча коймасына тотынып-тотынып алам. Үземнең күзгә ак-кара күренми: кем белән очрашканымны да, кая барганымны да рәтләп белмим. Барам да барам.

Нәсимә апаларга барып кердем. Хисам абыйдан, Зөһрә белән сеңелесе Сәлимәдән башкалары барысы да өйдә. Нәрсә булды икән дигән сыман, аптырашып карап торалар миңа. Мин еш-еш тын алам, тиз генә аңлатып сөйләп бирергә тырышам.

— Тавык кирәк, Нәсимә апа,— димен.— Итле аш пешерәбез, Нәсимә апа. Күпме сорасагыз да бирәм!

Шулай дигән булам да көлеп җибәргән булам, борынны тартып алам, маңгай чәчләрен төзәткәлим.

— Нинди тавык?— ди Нәсимә апа.— Зөһрә нишләп ята анда? Эшегез беткәндер ич?

— Райздрав килде, врачлар килде. Яңавылдан,— димен.

Мәсьәләне аңлап алгач, Нәсимә апа кисәк кенә тынып калды. Күреп торам, бик үк риза буласы килми.

— Ярамаган кайнар су!— ди.— Кайнатыгыз да бирегез. Юкка мәшәкатьләнеп... Бетмәс андай килүче-китүче...

— Начальникка һыу эсерергә ярамас,— дигән була Рафика апа, юаш кына елмаеп.

— Үзем өчен түгел бит, Нәсимә апа,— димен, ялварып.

Минем кинәт үз-үземне кызгандырасым килеп китте, тыным кысылгандай булды. Шул ук вакытта котым алынып уйлап куйдым: «Болар да бирмәсә, кемгә барырмын? Берни барып чыкмаса, нинди хурлык!»— димен.

— Бер тавыктан ни булган да ни калган,— диде шул чакны Фәгыйлә апа, сүзгә кушылып.— Суйдырып бирергә кирәк, әнкәй.

— Минем тавыкларым симез,— ди Нәсимә апа, миңа карамыйча гына.

Фәгыйлә апа белән Рафика апа икесе берьюлы көлеп җибәрделәр. Мин, Нәсимә апаның ачуын китерүдән куркып, тыелып калдым.

— Күрше тавыгы гына симез була торганые,— ди Фәгыйлә апа, көлә-көлә.

— Ярар, авызыгызны җырмагыз!— ди Нәсимә апа, ачуланып.— Сезгә көлке. Карарга дигәндә, берсенең дә кузгаласы килми. Теге койрыкның өйгә кайтып кергәне дә юк.

Кем турында сүз барганын мин шундук аңлап алдым. Билгеле, Зөһрә турында. Сәлимәне әле телгә алмыйлар. Ул — укучы.

— Үзең өйрәтәсең,— ди Фәгыйлә апа.— Ул бит безне тыңламый, сине генә тыңлый.

— Тыңлайсыз сез!— ди Нәсимә апа, пыранлап.— Минем күзем йомылса, иркенләп калырыегыз да, күзем генә йомылмай.

— Миңа болай да иркен,— ди Фәгыйлә апа.

Ул моны тиргәшмичә генә әйтә. Җиңелчә шаяртып кына. Үзе шунда Рафика апага күз кысып ала.

— Әсәй, кешене көттермә инде,— ди Рафика апа каенанасына, юаш кына.

— Үзем өчен булса... миңа барыбер дә соң...— дигән булам мин, үзалдыма сөйләнеп.

Нәсимә апа кирелеген җиңде, өстенә иске бишмәтен киде дә тышка чыгарга җыена башлады.

— Аны әле тотасы да бар,— диде, сукранып.

— Әйдәгез әле, тотып бирик шул мур кыргырыны!— диде Фәгыйлә апа, күңелләләнеп.

Без шаулашып тавык тотарга чыгып киттек.

## VII

Кычкыртып бер симез тавыкны тотып та алдык. Нәсимә апа тавыкның ике канатын каерып кулына тотты да, зур галошларын өстерәп, күрше картларга кереп китте. Бераздан күрше карты белән аллы-артлы лапаска китеп барганнары күренде. Күп тә үтмәде, анда, лапас астында ак тавыкның тамак ярып бар көченә кычкырганы ишетелде. Озак кычкыра алмады — тавышы өзелеп, кисәк кенә тынып калды.

Нәсимә апа тавыкны эштер-өштер генә йолкып бирде. Кул очына гына тоттым да чаптым тагын да урам буйлап. Күңел шат, горур. Кайтам лабаса тар урамны киң итеп.

Мин кайтып кергәндә, сәгать унике тулган, беренче китеп бара. Соломон Моисеевич белән хатын-кызлар һаман безнең бүлмәдә утыралар. Өстәл тирәсен әйләндереп алганнар да, дөньяларын онытып, рәхәтләнеп кәрт сугалар. Минем тавык күтәреп кайтып кергәнне күрделәр дә, дәррәү кубып шаулашырга, ура кычкырырга тотындылар.

— Молодец, Саҗидә!— ди Соломон Моисеевич, барысын да уздырып.

Мондый мактау сүзенә минем түбәм күккә тиде. Кыюланып, Соломон Моисеевичның матур кара күзләренә карыйм, көләм, елмаям.

Чуендагы су инде кайнап чыккан. Тавыкны бер кат пешекләдек тә шул көе чуенга салдык. Аннары тегесенмонысын әзерләргә тотындык. Бәрәңге әрчедек, Гайшә апалардан куна тактасы, уклау алып чыгып, камыр җәйдек. Без дигәч тә, Зөһрә белән икәү эшлибез. Кунаклар һаман кәрт сугалар, көлешәләр, шаулашалар. Бары Мәдинә апа гына шауламый, уенга да катышмый. Безнең янга килеп булышкандай итә, тегесен-монсын сораштыра.

Шулай әзерләнеп ятканда, минем янга тагын Улечка килеп җиткән. Серле генә итеп бу мине икенче якка чакырып чыгарды да:

— Акыллым,— ди, пышылдап,— булгач булсын инде, тавык янына бер ярты куймый ярамас. Соломон Моисеевич кайчагында салырга ярата.

Нәрсә әйтәсең инде моңа? Мин бик шат. Соломон Моисеевич өчен булгач, икеләтә, өчләтә шат.

Тагын бу миңа акча сузды, бар әле, тиз генә кибеткә барып кил, ди.

— Сез минем кунаклар, мин — хуҗа,— дидем мин эре генә, акчаны кире кагып.

Онга-камырга буялган кулларымны юдым да, кечкенә сумканы кулга элдердем дә, чыгып киттем кибеткә. Аракы сорагач, сатучы миңа сәерсенеп карады.

— Начальство өчен. Яңавылдан килделәр,— дигән булам, никтер акланган сыман.

— Ярый торган эш,— ди сатучы.— Алар майлаганны ярата.

Ярты литр ак белән ярты литр кызылны алдым да, кайтып та киттем.

Тиздән аш җитеште. Аш җитешүгә генә диярлек Таня кайтып керде. Аны шаулашып каршы алдык. Шуннан соң Гайшә апалардан барыбызга да җитәрлек табак-савыт алып чыктык, бердәнбер өстәлне җайлап бордык та кунакларга ике яклап утырырга куштык. Мин Таня белән аш бүлдем, табын әзерләдем, Улечка стаканнарга, йомыларга аракы агызды.

— Хуҗаны — түргә! Соломон Моисеевич янына!— диделәр кызлар, чыркылдап.

— Кил, кил монда!— ди Соломон Моисеевич, өстәл аша миңа кулын сузып.

Шатлыктан, дулкынланудан кисәк кенә башым әйләнеп китте. Үзем карышкан булам, ник карышамдыр — үзем дә аңламыйм. Мин карышкан саен, кызлар ныграк

кычкыралар, кыстыйлар. Кулдан тарткалап диярлек, мине шулай да Соломон Моисеевич янына утырттылар. Улечка һәркемгә үз алдындагы стаканын, йомырысын алырга кушты. Соломон Моисеевич ниндидер тост әйтте, кызлар тагын көлештеләр. Улечка эчәргә кыстады.

Соломон Моисеевич яртылаш аракы салынган стаканны җитез генә күтәрде дә авызына каплады. Эчкәндә аның ефәк галстук төене кыймылдап-кыймылдап куйды.

— Эч, Саҗидә, берни булмас!— диде бу, минем аркадан сөеп.— Мин монда. Үзем рөхсәт итәм.

## VIII

Мәҗлес бик күңелле узды. Барысы да бик канәгать булдылар, көлделәр, шаян сүзләр әйтештеләр. Күбрәк Соломон Моисеевич көлдерде. Без барыбыз да аның авызына гына карап утырабыз. Берәр сүз әйттеме, аны-моны карамыйча, шыркылдашырга гына торабыз.

Мин бөтенләй диярлек эчмәдем. Шулай да нишләптер исергәндәй булдым. Миңа кинәт бик кызык була башлады. «Соломон Моисеевич мине Улечкага караганда ныграк ярата»,— дип уйладым мин күңелемнән. Ул вакытта мин үземне әйтеп бетергесез дәрәҗәдә бәхетле итеп сиздем.

Ашап туяр алдыннан гына, кемдер шоферны исенә төшерде.

— Их, алданрак әйтмәгәнсез!— дидем, өтәләнеп.

Плитә өстендә утырган зур чуенны аударып караган идем — ашның тамчысы да калмаган! Миннән шаулашып көләргә тотындылар.

— Улечка, берәр йөз грамм чыгарып бир, җылынсын,— диде Соломон Моисеевич.

Улечка урыныннан торды, стаканга яртыдан күбрәк аракы агызды. Бер кулына бер телем икмәк, икенче кулына стаканын тотып, тышка чыгып китте. Без, тын калып, кызыксынып, Улечканың кергәнен көтә башладык.

— Йоклап киткән,— диде Улечка кергәч, буш стаканын өстәлгә куеп.— Тагын яварга тора, нишләрбез икән, Саша?

— Икенче тавык суярга кушарбыз!— ди Соломон Моисеевич.

— Икенче тавык пешкәнче әллә барып кайтасызмы соң?— ди Улечка.— Сәгать өч тула. Бүген өлгермәвебез мөмкин.

— Мин һәрвакыт әзер!— ди Соломон Моисеевич.

Шулай диде дә бу, миңа карап алды. Мин аның нәрсә

әйтергә теләгәнлегеп сүзсез дә аңлап алдым. Табак-савытны Зөһрә белән Таняга юарга куштым да авыл Советына кереп киттем.

Ат туарып куелган. Кештерт-кештерт китереп утлыктан печән ашап тора. Авыл Советы дежуры миңа мыгырданып алды: Куштирәккә барасы кеше шушы вакытка каламыни, диде, аннан әле әйләнеп тә кайтасы бар, диде. Шулай да атны җикте, дилбегәне миңа тоттырды да, фәлән вакыттан да соңга калмагыз дип, капка төбенә чаклы озата килде.

Минем ат тотып кайтканны күреп, пункттан бер-бер артлы кунаклар чыкты. Мин, өйгә кереп, аягыма бота, өстемә плащ кидем.

Чыксам, тарантасны уратып алганнар да нәрсә турындадыр сүз көрәштерәләр. Кемнәр иң әүвәл утырып барырга тиеш дигән мәсьәләне хәл итәләр икән.

Ат яхшы булса да, тарантас бәләкәй — алты кешене күтәрерлек түгел. Аннары тарантаска алай төялеп тә йөрмиләр ләбаса.

Кызлар үзара сүз озайткан арада, Соломон Моисеевич беренче булып менеп тә утырды.

— Ярый, кызлар, сез сатулаша торыгыз, мин китә торыйм,— диде. Дилбегәне алды да, атка кагып та җибәрде.— Кем утырырга тиешлеген килеп әйтерсез! На-а!

Ат кузгалып китү белән, Соня бер яктан, Улечка икенче яктан тарантаска килеп утырмакчы булдылар. Соломон Моисеевич артына карап бер елмайды да кул болгады. Китте дә барды. Кызлар беркадәр җир йөгергәндәй иттеләр дә көлә-көлә артка калдылар.

Шулай көлешеп-шаярып без юлга чыктык. Мин утыру турында уйламадым да. Җәяүләп мин хәзер әллә кайларга барырга әзер. Тик алдан Соломон Моисеевич кына барсын!

Авылны чыккач, ул безне көтеп алды, артына борылды да, елмаеп:

— Ягез, кызлар, кем куып җитә?— диде.

Соня кыланып йөгереп караган булды. Соломон Моисеевич шундук атын куарга тотынды. Бераз гына чаптырды да тагын атлатып бара башлады. Без, пычрак юлда ләпек ярып, шат, көр күңел белән, батырларча аның артыннан атладык.

## IX

Көн болытлы. Дымсу. Ике якта да сөрелгән кара җирләр җәелеп ята. Тракторлар юлны сөрдереп киткәннәр. Юл әле тиешенчә тапталмаган. Тарантас тәгәрмәченә ка-

лын булып ләпек урала, аякларга ләпек сылаша. Күтәрерлек тә түгел.

Соломон Моисеевич тарантаска кырын-ярын яткан. Әледән-әле безнең якка карап ала, елмаеп берәр нәрсә әйтеп куя. Аның шулай безгә бер елмаеп каравы була, тиләләр кебек, без шундук көләргә тотынабыз. Ни өчен көлгәнлегебезне үзебез дә аңламыйбыз. Техникумда укыганда безгә бер укытучы әйткән иде: биш минут көлү ике сәгатьлек ялны алыштыра дигән иде. Күрәсең, дөрестер. Мин ул көнне унике чакрым җир барып, тамчы да арымадым.

Таш юлга чыккач, Соломон Моисеевич безне көтеп алды, Мәдинә апага үзе янына утырырга кушты. Мәдинә апа утырмады: «Рәхмәт, мин җәяү йөрергә яратам»,— диде. Соломон Моисеевич тагын берүзе кузгалып китте. Киткәндә артына борылды, уч төбен үпте дә, сау булыгыз дигән сыман, безгә кул болгады.

Атка үзе генә утырып ул, билгеле, дөрес эшләде. Әгәр дә мәгәр безнең берәребез утырса, икенчебез үпкәләр иде. Үпкәләмәсә дә, хәтере калыр иде. Ул әнә үзенең Улечкасын да утыртмады. Кем белә бит әле — үзенеке микән? Күрәсең, түгелдер. Кеше сүзе генәдер. Ул, ахрысы, чынлап та мине ярата. Ихластыр менә, шулай, ахрысы!

Шулай үз алдыма хыялланып, күзем маңгаема менеп бара идем, көтмәгәндә ниндидер чокырга батып киттем. Бу вакытта инде без, таш юлдан чыгып, ниндидер болынлыкка килеп кергән идек. Безнең юлны аркылы кисеп, ниндидер су агып ята. Су тирәсе баткак, сазлык. Башкалар җиңел генә чыгып китте, мин ничектер карамыйчарак калдым. Уң аяктагы бота сазга керде дә китте.

Тартам-тартам — һич алып булмый. Үзем көләм, үзем кычкырам. Барысы да миңа борылып караганнар. Алар да көләләр, шаярткан булалар. Гөнаһың күп, ахрысы, шуңа күрә баттың, диләр. Җир йота хәзер, васыятьләреңне әйтеп кал, диләр. Үзләре минем янга җыела башладылар. Соломон Моисеевич та атын туктатты, сикереп җиргә төште. Карасам, туп-туры минем янга килә! Аягында яхшы кызыл туфли, шакмаклы чалбары әйбәт итеп үтүкләнгән. Пычракны уйлап та бирми — килүен белә! Килеп җитте дә, кулын сузып:

— Бир кулыңны!— диде.

Кулны сузарга да итәм, кыюлык та җитми. Суздым исә, никтер егылып китәрмен төсле.

Мин шулай икеләнебрәк торган арада, Соломон Моисеевич ике куллап минем билдән кысып тотты да, күз ачып йомганчы, күтәреп тә алды. Мин кинәт хәлсезләнеп

калдым. Беркайчан да булмаганча хәлсезләнеп, йомшап калдым. Мин аны шулкадәр көчледер, үземне шулкадәр җиңелдер дип һич тә уйламаган идем. Юан дип мин үз-үземне юкка гына кимсетәм, ахрысы. Чынында мин бик нечкә, бик җиңел бугай.

Шулай мине күтәрде дә бер-ике адым читкәрәк алып куйды. Аягыма басыйм дигән идем, бота ләпектә торып калган! Китте чыр-чу, китте көлеш!

Соломон Моисеевич мине инде ычкындырып өлгергән иде. Мин аягымны югары күтәрдем, чайкалып киттем. Ярый әле янда гына Улечка бар иде, аңа тотынып калдым. Ул арада Соломон Моисеевич, иелеп, ләпектән сыңар ботаны тартып алды.

— Соломон Моисеевич Саҗидәне кул очында гына йөртә!

— Өрмәгән җиргә дә утыртмый!

— Тикмәгә генә түгел бу, нидер бар монда!— диештеләр кызлар, шаяртып.

Мин аларның уйнап сөйләгәннәрен бик яхшы аңлыйм, шулай да тиле күңел нишләргә белми: үсенә, җилкенә.

## X

Куштирәк бәләкәй авыл. Бер генә урамлы. Тигез җиргә утырган. Урамында яшел чирәм. Тыныч, күңелле.

Килеп төшкәч тә, бөтен көтүебез белән авыру бала яткан өйгә китмәдек. Куштирәктә медсестра бар иде. Иң элек без шуларга юнәлдек.

Урамнан узганда, күреп барабыз: тәрәзәләргә кешеләр капланган, карыйлар безгә күзләрен шәмрәйтеп. Кайберәүләр тавыш-тынсыз гына киртә-койма аша карап кала. Барысы да безгә исләре китеп карыйлар төсле. Мин шундук көлүдән туктадым, башны югарырак күтәрдем, әле һаман пырх-пырх килеп барган Соняга җиңелчә генә шелтә ясап алдым. Бит монда «минем авырулар» яши! Алар мине күреп торалар, сынап карыйлар. Алар алдында әдәпсезләнеп, авыз ерып бармассың лабаса!

Җыйнаулашып барып төштек медсестра тора торган йортка. Өйдән бер агай белән бер-ике хатын-кыз килеп чыкты. Яшьрәге — медсестра. Икенчесе — аның әнисе. Килеп чыктылар да елмаешып капка ачтылар, йөгәненнән тотып, атны ишегалга алып керделәр, исәнләштеләр, хәл-әхвәл сорашырга тотындылар.

Без тыныч кына ишегалга уздык, җыйнаулашып өйгә кердек, сәлам бирдек. Хуҗа хатын тыз-быз килеп самовар куярга тотынды. Өй эче җылы, җыйнак. Идән ап-ак итеп

юылган, тәрәзәләргә ап-ак кашагалар, пәрдәләр эленгән. Мендәрләр яхшы итеп кабартылган. Өстәлдә өр-яңа клеенка. Исләре килеп тора. Урындыкларда чуар чүпләмнәр. Мич ап-ак, мич алдына чаршау корылган. Бөтен җирдә чисталык, пөхтәлек.

Хуҗалар безгә: «Чәй өлгергәнче ял итеп алыгыз»,— диделәр. Без алай кыстатып тормадык, кайда урын бар — шунда утырыштык.

Минем утыруым булды, яныма Улечка килеп тә җиткән.

— Акыллым, җылы сулары юк микән, сора әле,— ди миңа, русча пышылдап.— Соломон Моисеевич юынырга тели.

Мин, чаршау артына чыгып, Улечканың теләген белдердем.

— Юынгычта су җылы, юныгыз, юныгыз!— ди хуҗа хатын.— Сабыны да шундадыр. Халисә, карале, шундамы?

— Шунда, шунда!— ди Халисә, юынгыч янына барып әйләнгәч.

Мин, олы якка чыгып, юынырга мөмкин икәнлеген әйттем. Соломон Моисеевич никтер кәефсез күренә. Ниндидер начар ис сизгән кебек, борынын тартып-тартып ала. Мин дә, шикләнеп, борынны тартып карадым, юк, андый-мондый ис сизелми.

Соломон Моисеевич юынган арада, без Улечка белән нишләргә кирәклеге турында киңәшеп алдык. Иң элек авыру бала янына барып кайтырга булдык. Шуннан соң йортлар буенча йөреп, бөтен авылны карап-тикшереп чыгарга кирәк булыр, дидек.

Улечка тиз генә Соломон Моисеевич янына барып килде дә:

— Акыллым, сора әле, берәр таска су әзерләп бирмәсләрме?— ди миңа.— Соломон Моисеевичның туфлиләрен юарга кирәк.

Мин тагын апага моның үтенечен белдердем. Апа, озак көттермичә, эмальле чиста таска казаннан җылымса су салып бирде. Суны Мәдинә апа алды. Тышка чыгып китте. Сизеп торам, Соломон Моисеевичның туфлиләрен юарга аңа Улечка кушкан.

Шуннан соң мин ашыгып Мәдинә апа артыннан чыгып киттем. Чыксам, чыннан да Мәдинә апа, сукранасукрана, кызыл туфлиләрне юып ята!

— Хәшәрәт!— ди, үртәлеп.— Барин булган, әрәмтамак!

— Мәдинә апа, каяле, үзем юыйм?— дидем мин, ипләп кенә.

## XI

Бераз торгач, без Улечка белән, Гөлчирә белән авыру баланы карарга киттек. Соломон Моисеевич бармады, тагын да: «Мин сиңа ышанам, Улечка»,— диде. Соня белән Мәдинә апа урамның бер ягы буйлап өй борынча йөрергә тиеш булды. Медсестра Халисә безгә иярде.

Юлда килгәндә мин никадәр шат, гамьсез булмыйм, шулай да авыру бала янына барганда тынычсызлана башладым. Барыннан да элек мине: диагнозым дөрес микән? дигән сорау борчыды. Мин, билгеле, үзем куйган диагнозның дөрес булуын телим. Калганы турында бик үк кайгырмыйм да. Янымда шулкадәр күп медиклар булганда, кайгырасың килсә дә кайгырмассың!

Барып җиттек. Хуҗалар безне борчулы, куркынган йөз белән каршы алдылар. Аяк киемнәрен чиста итеп юылган баскыч төбендә калдырдык та өйгә кердек. Авыру бала янына килдек. Баланың баш өстенә аскан кызыл чаршау итәгеннән кайтарып куйдык. Һаман шул ук хәл. Күзләре ярым йомык. Тын алуы авыр. Бите кып-кызыл. Тик бүген тәнендә үзгәрешләр күренә. Ясмык зурлыгындагы кызыл тимгелләр калкып чыккан. Температурасы кичәгечә: 39 чамасы.

Безнең янга шундук баланың әнисе белән әтисе килеп җитте. Барыбыз да, ни әйтер икән бу дип, Улечканың авызына карап катып калдык. Мин инде аңа авыру бала турында сөйләгән идем. Минем әйткәннәр белән генә канәгатьләнмичә, Улечка яңабаштан төпченеп сораштырырга тотынды. Кайчан авырый башлады, башта ничегрәк булды, диде, нинди балалар белән уйнады, диде, авылда шундый ук чир белән чирләүчеләр юкмы, диде. Хуҗаларның әйтүенә караганда, авылда чирләүче балалар юк икән. Димәк, инфекция таралырга өлгермәгән. Монысы инде куанычлы хәл.

Сораштырып бетергәч, Улечка баланың йөрәген, үпкәсен тыңлап карады.

— Куркырлык берни юк — диде, ниһаять, ата белән анага карап.— Кызамык. Полиомиелит түгел.

Ата белән ана, җиңеләеп, көрсенеп куйдылар, бер-берсенә карашып алдылар да, бер-берсен бүлеп, такылдарга да керешеп киттеләр.

— Кызамык кына булгач ярый әле ул!— ди абый кеше.— Нәрсә ул кызамык! Ата-баба җоласы.

— Чиратын үткәргәне яхшы инде,— ди хатыны да.

— Кызамыктан соң баланың үпкәсе шешәргә мөмкин,— диде Улечка.— Бу чүпрәкләрне алып куегыз. Битен капламагыз. Өйдәге һаваны алыштырып торыгыз.

Хуҗалар, рәхмәт әйтә-әйтә, безне озата чыктылар. Аларның хәзер сөйләшүләре дә, үз-үзләрен тотышлары да бөтенләй икенче. Күренеп тора, кисәк кенә күңелләләнеп киттеләр. Йөзләре ачык, ягымлы. Алар гына түгел, мин дә сөенәм. Чын күңелдән сөенәм. Сөенмичә, уен эшмени ул сиңа полиомиелит!

## XII

Без, күңелле шаулашып, болардан чыгып киттек тә күршеләргә юнәлдек. Ул көнне без барлык өйләргә кереп чыктык. Авыруларыгыз юкмы, дибез. Чисталык саклау мәсьәләсендә кайбер киңәшләр бирәбез.

Кайсы гына йортка барып кермә, безне ачык йөз белән каршылыйлар. Аннары шунысы куанычлы: һәркемнең ишегалды, абзар-лапас тирәсе чип-чиста итеп себерелгән, бернинди чүп-чар, тирес-салам күренми. Урам ягы, капка аллары да шулай ук чип-чиста, ямь-яшел. Баскычлар, өйаллары, идәннәр ап-ак итеп юылган, өйләр җыештырылган — кунак көтәләрмени!

Минем инде авылларда йөргәнем бар. Авыл өенең ничек булганын беләм. Кешенең төрлесе була. Берсе аның бик чиста торырга ярата, икенчесе гамьсезрәк була яисә чисталык сакларга аның яшәү шартлары җитеп бетми. Шулай ук авылларның да төрлесе була. Мәсәгут ягындагы авыллар болай төзек, чиста. Шул авыллар арасында Куштирәк шулай да яхшы яктан ныграк күзгә ташланып тора шикелле.

«Ни булган боларга?» — дип уйлыйм мин. Әллә безнең киләсене алдан белеп торганнармы? Менә ничек хөрмәт итәләр безне!

Ихтимал, ул көнне Улечка да, Гөлчирә дә, Соня белән Мәдинә апа да — барысы да шундыйрак нәрсә кичергәннәрдер.

Өйдән өйгә йөри торгач, көтмәгәндә, Гөлчирә сорап куйды:

— Нишләп соң боларда бер дә бала-чага күренми? — диде.

Шулай диде дә миңа карап алды, әйтерсең Куштирәк балаларын мин ашап бетергәнмен!

Мондый сорау миңа баштарак бик мәгънәсез булып тоелды. Ләкин шул ук вакытта мин Гөлчирәнең хаклы икәнлеген аңлап алдым. Чыннан да, баласыз авыл буламыни? Ә боларда уку яшендәге балалар да юк, яшь балалар да юк. Үзләре дә күренмиләр, тавышлары да ишетелми. Әллә ничек — үлеп беткәннәр диярсең! Кемгә

кермә, барысы да олылар, барысы да тап-таза, ягымлы, ачык йөзле. Бераз гына киноны хәтерләтә. Ә бит кичәгенәк болай ук түгел иде шикелле.

Бер йортка кергәч, без шул турыда әйттек. Безнең үзебезнең балаларыбыз юк, калганнарны белмибез, диделәр болар. Без шуның белән канәгать булгандай булдык. Мәсьәләнең сере миңа бары соңыннан гына беленде.

Былтыр Куштирәктә скарлатина инфекциясе таралган булган икән. Скарлатина авылдагы барлык балаларга диярлек йоккан. Шул турыда белгәч, Яңавылдан килгәннәр дә, авыру балаларны машинага төяп, больницага алып киткәннәр. Ата-ана моңа каршы килгән, балаларыбызны үтерергә генә алып киттеләр инде дип кайгырышып торганнар. Кичәгенәк мин: «Яңавылга хәбәр итәргә кирәк булыр»,— дигәч, авыл халкы шаулашып алган. Без килүгә алдан әзерләнеп торганнар һәм, быел да былтыргы кебек хәл кабатланудан куркып, балаларын кайсы кая качырып бетергәннәр.

Әйе, барысы да олы яшьтә, барысы да тап-таза... Бөтен авылда без бары бер генә авыру таптык. Безгә килеп әйттеләр, фәлән йортта фәлән кеше авырый, барып карамассыз микән, диделәр. Без, керәсе йортыбызга кереп тормыйча, төркемләшеп шунда киттек.

Бу урта яшьләрдәге бер агай булып чыкты. Тимер караватта ята. Баш астында кат-кат мендәр. Аягында иске киез итек. Зур гәүдәле. Сөякчел, ябык. Аяк-куллары йөрми икән. Сул кулы бөтенләй хәрәкәтләнми, уң кулы бераз кыймылдаштыра. Шулай ук аякларын да көчкә генә кузгата икән. Яздан бирле ята икән.

Улечка бик җентекләп карады, ләкин кистереп кенә бер нәрсә дә әйтә алмады.

— Соломон Моисеевичны чакырырга кирәк булыр,— диде бу, теләр-теләмәс кенә.— Миңа караганда ул нервы авыруларын яхшырак белә.

— Үзем генә чакырып килим!— дидем мин, чәчрәп торып.

— Сиңа гына килмәс, үзем барырмын,— ди Улечка.

Бер биш-алты минуттан, ул Соломон Моисеевичны алып та килде. Соломон Моисеевич һаман күңелсез. Мин андагы һәрбер үзгәрешкә игътибар итәм. Минем әле беркайчан да аның болай күңелсез булганын күргәнем юк. Бүген әнә әллә нишләгән. Бүген дә түгел, менә монда гына, авылга килгәч кенә.

Авыруны ул теләмичә генә, эре генә, һавалы гына кыланып карады. Күрәсең, райздрав кешегә гади врач ролендә булу чыннан да күңелле эш түгелдер. Авыру

агай берәр каты, тупас сүз ычкындырып ташламасын тагын дип, мин чын-чынлап куркып куйдым. Ләкин авыруның үз хәле хәл. Соломон Моисеевичның салкынлыгына ул бөтенләй игътибар итмәде. Әллә шулай күренде генә микән?

Менә авыруны карау тәмам булды. Без барыбыз да җиңел сулап куйдык. Соломон Моисеевич авыру кешенең тәненә тигән кулларын, резина чүкеч, энә ише нәрсәләрен спиртлы мамык белән сөртеп куйды. Латинча үзенең диагнозын әйтте дә, киләчәктә нишләргә, нинди дарулар кулланырга кирәклеге турында киңәшләр бирде. Мин агайга аның кайбер сүзләрен тәрҗемә итеп тордым. Улечка рецептлар язды.

Авыру агайлардан чыгып барганда, мин Соломон Моисеевич белән Улечка арасында шундый сөйләшү ишетеп калдым:

— Авыл чиста, Саша,— диде Улечка.

— Әйе, идиллия, романтика!— диде Соломон Моисеевич, ирония белән.— Авыл авыл инде ул, нинди генә булмасын...

— Мин алай димәс идем, Саша. Әнә нинди күңелле монда: ямь-яшел, бары да төзек, чиста.

— Авылның исемен ишетү белән миндә рефлекс эшли башлый. Авыл минем нервы системама начар тәэсир итә.

— Ләкин Буә буена балыкка йөрү синең нервы системаңа уңай тәэсир итә!— диде Улечка, көлеп.

— Ул бит балыкка йөрү!— диде Соломон Моисеевич, үртәлеп.

Шуннан башкасын мин ишетмәдем. Ишетәсем дә килмәде. Миңа бик-бик кыен булып китте. Яраткан кешеңнең авызыннан яман сүз ишетү кайчакта бик кискен «рефлекс» тудырырга мөмкин. Ул минутта миндә дә шундыйрак нәрсә булды.

## XIII

Болай да болангыр көнне тиз арада караңгылык басты. Йортларны карап-тикшереп бетергәч, бөтенләй диярлек тоткарланмадык. Халисә колхоз утарыннан ат җигеп алып кайтты. Арбасы тарантас кына түгел, зур арба. Күп итеп арыш саламы салынган. Яхшырак урын алып калу өчен, без шундук арбаны сарып алдык, чыр-чу килеп, салам кыштырдатып, урнаша да башладык.

— Кызлар, кем минем янга утыра?— диде шул чакны Соломон Моисеевич.

Аның ягымлы, ачык йөзен күреп, без барыбыз да

яңадан күңелләләнеп киттек. Чәүкә балалары кебек: мин дә мин дип кычкырырга тотындык. Соня хәтта, барысыннан уздырмакчы булып, тарантаска барып ук утырды.

— Юк,— диде Соломон Моисеевич,— болай дөрес булмый. Шобага тотыгыз, кызлар, шобага!

Улечка безнең шау-шуга катышмады, уңайсыз елмаеп, үз-үзен кыен сизеп, бер читтәрәк басып тик торды. Мәдинә апаны әйтеп тә торасы юк. Ул инде күптән арбада саламга чумып утыра. Без өчәү: Соня, Гөлчирә, мин.

Мин утынлыктан озын гына чыбык алып килдем. Шуннан соң без көлешә-көлешә шобага тота башладык. Барысы да безгә карап торалар. Соломон Моисеевич елмайган, Халисә елмайган. Мәдинә апа ачулы. Хуҗа абзыйның йөзе берни аңлатмый. Тыныч кына тәмәке пошкырта. Мәсәгуткә чаклы ул ат тотып барачак. Аягына зур күн итек кигән, озын брезент плащ кигән, башында — бүрек, кулында — чыбыркы.

Минем өчен искиткеч бәхетле булды ул көн, шобагада мин өскә чыктым! Кызлар шаулашып көлергә тотындылар. Гамьсез агай елмаеп куйды. Шатлыктан мин уттай кабынып киттем.

— Мин бик шат,— диде Соломон Моисеевич, елмаеп.

Бөтенесе алдында мине култыклап алды да, киноларда күрсәтелә торган аристократ кызлар кебек итеп, кыландырып мине тарантаска утыртты. Мин йомшак саламга кереп утырдым да аякларны сузып җибәрдем.

Хуҗа агай атны авызлыклады, ат өстендәге дилбегәне Соломон Моисеевичка алып бирде, аннары атны чиктерде, капка ягына борды. Халисә киң итеп капка ачты. Агай урам якта сабыр гына көтеп торган үз аты янына китеп барды. Барса, арбада үзенә урын да калмаган!

— Әллә берәрегез күчеп утырасызмы, кызлар?— диде безнең якка карап.— Авыррак булмасмы? Бер атка — биш кеше, бер атка — ике кеше. Тигез түгел.

— Нәрсә сөйли ул?— диде Соломон Моисеевич, аның ризасыз тонын сизенеп.

Мин аңа агайның сүзләрен тәрҗемә итеп бирдем.

— Без икебез биш кешегә торабыз!— дип кычкырды Соломон Моисеевич, алдагыларга ишетелерлек итеп.

Кызлар көлештеләр. Агай көлмәде.

— Миңа ярый. Хайван хакы бар,— диде. Шуннан ул арба кырыена гына урнашты да дилбегәсен кагып җибәрде. Майланган арба җиңел генә кузгалып китте. Соня бер дә юктан чыркылдап җибәргән булды, борылып безнең якка йодрык күрсәткән булды.

Беренче ат артыннан без дә кузгалдык.

## XIV

Авыл бик тиз артта калды. Авылдан чыккач та, басу башланды. Тирә-як караңгы. Караңгылык аша якында гына булып болганчык күк йөзе күренә дә, беленер-беленмәс кенә җир өсте күренә. Бар яктан да сине нидер чолгап алган кебек, шулай да монда үзенә бертөрле киңлек-иркенлек сизелә. Кырлар-басулар иркенлеге генә түгел, күңел иркенлеге сизелә. Авылдан, шәһәрдән чыккач, мин һәрвакыт шундый күңел иркенлеге тоям. Мин үземне ниндидер тоткынлыктан котылгандай хис итәм. Минем бик борынгы ата-бабаларым бер урыннан икенче урынга күчеп йөргәннәр, бөтен гомерләрен киң далада, кырда-басуда үткәргәннәр. Күрәсең, миндә әле булса шул ата-баба каны үзен сиздерәдер.

Куштирәктән чыгып бераз җир киткәнче шулай булды. Ләкин мондый иркенлек тойгысы шулай да озакка бармады. Күп тә үтмәде, мин үземне яңадан тоткынлыкта итеп сизә башладым. Беренче исерткеч шатлык-куаныч тиз арада юкка чыкты. Көтмәгәндә, мине тыелгысыз бер каушау-курку тойгысы, ни өчендер тартыну, газаплану тойгысы биләп алды. Мин тынып калдым, бөрешеп, йомылып калдым.

Мондый курку-каушауның ахмаклык икәнлеген мин үзем дә аңлыйм. Чуалган уй-фикерләремне, таркалган ихтыяр көчен бергә тупларга азапланам. Ләкин берни эшләп булмый. Мин дисәң — мин түгел, әллә кем шунда. Куллар да минеке түгел, аяклар да, баш та, йөрәк тә...

Кичке һава салкын. Тирә-як тын. Бик тын. Җәйге вакыттагы кебек кошлар чыр-чуы да ишетелми, чикерткәләр сайравы да ишетелми. Юл пычрак, лыстыр-лыстыр ат тарта, тарантас тирбәлә, юлда сыек ләпек пычтырдый, тәгәрмәчләрдән ычкынган балчык кисәкләре шап та шоп артта төшеп калалар.

Мин тыңлыйм, юк-бар нәрсәгә колак салам, тояк тавышларына, артта чәчрәп калган балчык тавышларына игътибар иткән булам, ә күңелем бөтенләй икенче нәрсәдә. Минем сул ягымда утырып барган, мине чикләп-богаулап алган, шул ук вакытта мине магнит сыман үзенә тарткан зур, серле нәрсәдә...

Нишләргә, үз-үземне ничек тотарга? Нәрсә дияргә? Ничек сүз башларга? Ялгышмадыммы мин аның янына утырып? Менә ул мин теләгән кеше, мин хыялланган кеше. Караңгы басулар буйлап шушылай аның белән икәүдән-икәү тарантаста утырып баруны мин хәтта төшемдә дә

күрмәдем. Минем өчен моннан да зур бәхетнең булуы мөмкинме? Ләкин нишләп соң куркам, нишләп газаплანам, ни өчен мин бернинди шатлык, куаныч тоймыйм?

Күңелдә минем шундыйрак уйлар бутала. Мондый уйлар миңа бик катлаулы, бик авыр булып тоела. Күпмедер вакыт мин шундый каршылык эчендә барам.

— Карале, Сонечка, нинди гүзәллек!— ди минем уң яктагы кеше, әкрен генә пышылдап.

«Сонечка» дигән сүз мине чиркәндереп җибәрә. Сажидә башым белән нишләп мин «Сонечка» булыйм ди!

— Мин бит Сонечка түгел,— димен.— Сонечка алдан бара.

— Анысы — алдагы Сонечка, син — арттагы Сонечка.

— Мин алдагы Сонечка да түгел, арттагы Сонечка да түгел!— димен.— Мин — Сажидә.

— Әлбәттә, Сажидә!— ди Соломон Моисеевич, тиз генә минем белән килешеп.

Шулай диде дә бу, иплəп кенә кулын минем иңбашыма салды. Миңа бу әллә ничек тәэсир итте. Ямьсез булып, тупас булып тоелды. Иңбаштагы авыр кулны минем читкә этәрәсем килә, ләкин берни эшли алмыйм. Тагын да ныграк тынып-йомылып калам.

— Төнлә нинди күңелле, Сажидә!— ди Соломон Моисеевич, әкрен генә, серле генә.— Менә без синең белән утырып барабыз. Әкияттәге кебек, ә?

Шулай сөйләнә-сөйләнә үзе һаман миңа таба елыша. Хәер, анда инде елышасы да юк. Без болай да бер-беребезгә терәлеп утырабыз. Ул бары башын гына миңа таба ия төшә дә, иңбаштагы кулын аскарак, бил турысынарак шуыштыра. Шуыштырып китерде дә бу, минем билдән кочып алмакчы булды.

— Кыен...— дидем мин, кыюсыз гына, кымшангандай итеп.

— Кыен шул,— ди Соломон Моисеевич, бернинди каршылыксыз.

Бераз вакыт без тып-тын гына барабыз. Минем йөрәк дөп-дөп тибә, яңаклар кызыша. Соломон Моисеевич минем белән шундый үз итеп сөйләшә, минем янда үзен шундый ышанычлы итеп тота — аның белән үземнең арада мин кинәт туганнарча бер якынлык тойгандай булам. Курку-каушау юкка чыга, ихтыяр көче кире үземә кайта.

## XV

— Сез Мәскәүнең үзеннәнме, Соломон Моисеевич?— димен, сүз башлап.

— Әйе, Саҗидә!— ди Соломон Моисеевич, җиңел генә елмаеп.

Мин аның йөзен күрмим, ләкин елмайганлыгын бик яхшы сизәм. Тавышы буенча.

— Кайда торасыз соң сез анда?

— Кызыл Мәйданда, Кремльгә каршы,— ди Соломон Моисеевич. Миңа ул шаярта шикелле тоела.

— Алдыйсыздыр әле,— дигән булам, көлеп.

— Нишләп алдыйм ди?! Чынлап, Саҗидә!— ди Соломон Моисеевич.

Ул моны ант итеп әйткәндәге кебек әйтә, ләкин бик җиңел генә, көлеп сөйләшкәндәге кебек кенә әйтә.

— Кызыл Мәйданда кеше торамыни?!— димен мин, аның ялганын тотмакчы булып.

— Ник тормасын, тора!— ди бу.

— Алдыйсыз ла сез!— димен тагын да.— Анда теге рәсемнәргә төшерелә торган чиркәү белән мавзолей гына түгелмени?

— Анда кешеләр яши торган йортлар да бар. Зу-ур йортлар!— ди Соломон Моисеевич, өч яшьлек балалар белән сөйләшкән шикелле.

— Их, күңелледер анда!— димен мин, хыялга бирелеп.

— Синең Мәскәүне күргәнең юкмыни?

— Юк шул.

— Телисеңме, мин сине алып кайта алам Мәскәүгә.

— Мәскәүгә?!— димен мин, исем китеп.

— Әлбәттә, Мәскәүгә! Киләсе елга, җәй көне... отпуска вакытында.

Мин тагын тынып калам. Тагын йөрәк ешрак тибәргә тотына. Тагын күңелгә мең төрле уй-хыял килә. Мәскәүгә?! Соломон Моисеевич белән! Белмим... Мөмкин нәрсәме ул?

— Сез бит болай гына әйтәсез,— димен мин, әкрен генә.

— Юк, Саҗидә...— ди бу, шулай ук әкрен генә, серле генә пышылдап.

Сул кулындагы дилбегәне тарантасның кәкре тимеренә эләктереп куйды да бу, яртылаш миңа борылып утырды. Бушап калган сул кулы белән минем кулны тотып алды. Караңгыда тагын да нурлырак булып, серлерәк булып күренгән зур кара күзләрен минем күзләргә төбәде дә:

— Әйе, чынлап әйтәм, Саҗидә,— диде елмаеп, пышылдап.

Мин эндәшмим. Эндәшә алмыйм. Телем көрмәлә. Әйтер сүз дә табылмый. Минем ышанасы килә. Мин инде ышандым да кебек. Ләкин аңа ничек әйтәсең шул турыда? Аның мине җиңел акыллы дип, бик тиз ышанучан дип уйлавы мөмкин.

Күпмедер вакыт тавыш-тынсыз барганнан соң, мин тагын беренче булып сүз башлыйм.

— Институтка керү сезгә авыр булдымы, Соломон Моисеевич?— димен.

— Юк,— ди Соломон Моисеевич.— Урта мәктәпне мин алтын медаль белән тәмамладым.

— Алтын медаль белән?!

— Әйе.

— Алайса, сез имтихансыз гына кергәнсез?

— Әйе. Аттестатны күрсәттем дә, кердем дә киттем... кинога кергән кебек.

— Нинди бәхетле кеше сез, Соломон Моисеевич!— димен мин, ихлас бер көнләшү белән.

— Юк, бәхетле түгел,— ди Соломон Моисеевич, чак-чак кына уйчанланып.

— Бәхетле түгел?! Ник, Соломон Моисеевич?

— Институтны бетергәч, мин аспирантурага керергә тиеш идем. Алмадылар. Көчләп менә монда авылга җибәрделәр.

— Әллә сезгә чынлап та ошамый бездә?— димен мин.

— Юк, ошый, Сажидә!— ди Соломон Моисеевич, шат күңел белән.

— Бездә күңелле!— димен мин, аның шул шаяртып әйткән «ошый» сүзенә дә куанып.— Бүә буе үзе ни тора! Урманнар, болыннар!

— Идиллия! Романтика!

— Чынлап, Соломон Моисеевич!

— Аспирантура тагын да күңеллерәк, Сажидә.

— Институтка керүен керсәм, аспирантуралар турында баш ватып тормасыем әле.

— Бик керәсең киләме институтка?

— Бик килә, Соломон Моисеевич. Мин барыбер керәчәкмен. Кайчан да булса керәчәкмен!— димен мин, батыраеп.

— Мин сиңа булыша алам, Сажидә,— ди бу, тагын да әкрен генә, серле генә пышылдап.

— Ничек? Нәрсәгә?

— Институтка керергә. Мәскәүдә минем дуслар, танышлар җитәрлек. Аннары әти минем профессор.

— Профессор?! Менә белмәгәнием...

Борылгандай иттем дә карап барам күзләремне зур ачып.

— Әйе, профессор,— ди Соломон Моисеевич, елмаеп.

«Нәрсә, мине сынап карамакчы була микәнни?»— дип уйлап алдым шунда үзалдыма.

— Юк, мин алай кермәячәкмен,— димен мин, нык итеп.

— Шәп кыз син, Саҗидә!— ди Соломон Моисеевич, мактап.

Шулай диде дә бу, искәрмәстән үпте дә алды.

## XVI

Бу бөтенләй көтмәгәндә булды, кинәт кенә булды. Мин ни әйтергә дә белми калдым. Минем әле моңарчы беркемнән дә үптергәнем булмады. Үбешүне мин, гомумән, начар нәрсә дип исәплим. Минем карашымча, бары киноларда гына, романнарда гына үбешәләр. Аннары, аерылышканда вокзалда үбешәләр икән әле. И, яратмыйм да шул картаеп беткән марҗаларның ярдай халык алдында чут та чут үбешүләрен! Ә тормышта... чын тормышта минем беркайчан да үбешкәнне күргәнем юк.

Китапларда язылганча, мин бернинди ләззәт тә, рәхәт тә тоймадым. Бу үбешү ничектер чиркәнгеч, җирәнгеч үбешү булды. Янымда утырган кешене олылау, хөрмәтләү хисе кинәт кенә юкка чыкты. Минем күз алдында ул кечерәеп, гадиләнеп калды. Шулай да ул вакытта мин аңа ачулана да алмадым, каршылык та күрсәтмәдем. Ул тагын кочты, тагын үпте. Хәзер инде бернинди тартынусыз кочты, үпте...

Ат әкрен генә юртуында булды. Колакка шул чакны алдагы арбада утырып барган кызлар тавышы чалынып калды. «Күрделәр микәнни?»— дип уйладым мин, куркып. Таштай катып калган авыр гәүдәмне кузгаткандай иттем дә чәчне, яулыкны төзәткәләп куйган булдым.

Икебез дә тынып калдык. Бер-беребез янында икебезгә дә кыен, уңайсыз кебек. Ләкин беркая бара алмыйбыз. Арба тар, урын тар. Җәяүләп китеп барыр идең, булмый, мөмкин түгел. Телисеңме, теләмисеңме — барырга туры килә шулай парлашып.

— Сез бит мине яратмыйсыз, Соломон Моисеевич,— димен мин, беркадәр тынычлангандай иткәч, үпкәләп.

Соломон Моисеевич эндәшми. Минем моңа хәтер калгандай булды. Минем ничек тә аннан «яратам» сүзен әйттерәсем килә башлады.

— Сез бит болай гына...— димен тагын да.

Монысында инде «яратмыйсыз» дигән сүзне әйтергә телем бармый. Шул ук вакытта күңелгә: «Әллә елап җибәрим микән?»— дигән бер уй килә. Елап җибәрдем исә, Соломон Моисеевич мине юата башлар, иркәләр, яратам, кадерлем, дияр шикелле тоела. Бит театрда һәрвакыт шулай итәләр!

Шулай да мин еларга өлгерми калдым. Шып итеп

кинәт ат туктады. Кызлар чыр-чуы якында гына ишетелә башлады. Күрәсең, туктаганнар да безнең килеп җиткәнне көтеп торалар.

— Соломон Моисеевич, ә, Соломон Моисеевич!— дип кычкыра Улечка.— Түбән Чатка керәбезме, юкмы?

Икебез дә, саңгырау кешеләр кебек, берни эндәшмибез. Улечка бераз тынып торгандай итә дә соравын тагын кабатлый. Аның сүзен бүлеп Соня кычкыра, Гөлчирә кычкыра. Үлеп беттегезме әллә, диләр, арбадан төшеп калдыгызмы әллә, диләр. Үзләре көлгән булалар.

— Нәрсә, Улечка?— диде, ниһаять, Соломон Моисеевич, тавыш биреп.

Аның шулай «Улечка» дип үз итеп эндәшүе миндә көнләшү шикелле бернәрсә кузгатып куйды. Атны туктатып, бөтенләй кирәкмәгән нәрсә турында сорашуы өчен Улечкага ачуым килде.

— Исәннәр икән, исәннәр!— дип кычкыра Соня, кыланып.

— Саҗидә андамы, төшеп калмадымы?— дигән була Гөлчирә.

— Монда,— димен мин, көттеребрәк кенә.

Улечка, караңгыда пычрак ярып, безнең янга килә.

— Түбән Чатка кереп торабызмы, Саша?— ди.

— Кермәбез,— ди Соломон Моисеевич.— Бу караңгыда нәрсә калган анда!

— Ә Гөлчирә нишләр?

Сизеп торам: Улечка юри сүз озайтып маташа, безнең янда озаграк торасы киләдер инде.

— Нишләсен, менә Саҗидәләрдә кунар да, кирәкле медикаментларын алып, иртәгә үз пунктына китәр,— ди Соломон Моисеевич.— Авыл Советы белән сөйләшенгән, бүлмәсе бар. Кирәк икән, Саҗидә булышыр. Шулай ич, Саҗидә?

— Булышырмын, Соломон Моисеевич,— димен мин.

— Ярый, киттек,— ди Соломон Моисеевич коры гына.— Вакыт тар.

Улечка тавыш-тынсыз гына үз арбасына китеп барды. Без яңадан кузгалып киттек.

«Барыбер, яратам дип әйтмәде!»— дип уйлыйм мин, бүленгән уйларыма кире кайтып. Ник әйтми ул? Юри генә әйткәнме, әллә чынлапмы? Ничек әйттерергә аннан ул сүзне?

## XVII

Соломон Моисеевич мин көткән сүзне барыбер әйтмәде. Мәсәгуткә кайтып җиткәнче, без рәтләп берни сөйләшмәдек. Әллә сөйләштек микән соң? Никтер хәтердә калмаган...

Ә Мәсәгуткә без бик тиз кайтып җиттек. Кайтып җиттек тә пункт турысында арбадан төштек. Авыл Советы дежуры көтеп торган икән — атны шундук алып китте. Куштирәк агае да, үз бурычын үтәгәч тә, үзләре ягына борылды. Безнең каршыга йөгереп Таня чыкты.

— Чәй кайнаган, эчәсезме?— диде. Соломон Моисеевич тизрәк кайтып китәргә ашыкты. Безне көтә-көтә ялыгып беткән шофер машинасын кабызды. Соломон Моисеевич, Улечка, Соня, Мәдинә апа безнең белән саубуллаштылар да машинага кереп утырдылар. Таня капка ачты. «Ашыгыч ярдәм» машинасы ипләп кенә капкадан чыкты, юлга борылды, як-якка чайкалгалап, урам буйлап китеп барды. Без өчәүләшеп капка төбендә торып калдык. Озаттык та, капканы ябып, өйгә кердек.

Миңа күңелсез. Никтер елыйсы килә. Ләкин Гөлчирә бар — аның алдында еларга ярамый. Минем ни өчен елаганымны сизенүе мөмкин. Болай да әллә нәрсәләр уйлыйдыр әле.

— Сиңа хат бар,— диде Таня, өйгә кергәч.

Өстәлдә чыннан да хат ята. Кемнән дисәң, Галиядән икән. Ачтым да укый башладым.

*Минем,* дигән, *күптәнге хыялым тормышка ашты,* дигән. *Мин институтта укый башладым, мин — студент,* дигән. *Медтехникум укучысы гына түгел, студент,* дигән. *«Студент»* сүзен зур итеп язган. *Безнең группада яртысы кызлар, яртысы егетләр,* дигән. *Көн дә лекция тыңлыйбыз, анда чабабыз, монда чабабыз — ашарга да вакыт юк, аяк өсте генә ашыйбыз,* дигән. *Лекцияләрне атаклы профессорлар укый, бер аудиториядә өчәр йөз кеше була,* дигән.

Шулай үзе турында аз-маз гына язган да мине тәнкыйтьләргә тотынган. Мин аңа авылга килгәч тә нишләвем, кемнәр белән танышуым, вакытны ничек уздыруым турында язган идем инде. Галиягә минем бернәрсәм дә ошамаган.

*Әһә,* дигән, *авыл егетләре белән таныштыңмы,* дигән. *Хәзер инде авыл хатыннары белән ызгышып йөри башлагансың икән,* дигән. *Сиңа инде кияүгә генә чыгасы да бала табасы, мал-туар үрчетәсе генә калган,* дигән. *Үрчет әйдә, үрчет, мин сине бик яхшы беләм — күрәсең, син инде мәңгегә шунда күмелеп калырсың,* дигән. *Бака тавышы тыңлап, сыер савып, бала күлмәкләре юып гомерең үтәр,* дигән.

Шулай да хатының азагында миңа ярдәм кулы сузмакчы булган бу. *Кулыңа китап тотып караганың бармы бераз вакыт,* дигән. *Искә төшерәсеңме безнең бергә укыган чакларны, искә төшерәсеңме безнең бер-беребезгә биргән антларыбызны,* дигән. *Кеше булырга омтылу, дәрт, ялкын калдымы әле синдә әз генә булса да,* дигән.

Хат мине бик нык уйга калдырды. Хат турында уйлау миңа юлда булган нәрсәләрне онытып торырга ярдәм итте. Нишләптер мин хәзер Галиягә сукырларча табына алмадым. Аның сүзләрендә миңа нindидер хаксызлык бар сыман тоелды. Мин әле аны гаепләргә дә җыенмадым, аннан баш тартырга да уйламадым. Шулай да күңел түрендә нindидер үзгәреш барлыкка килде. Мин үземнең кайсыдыр мәсьәләдә аннан өстенрәк икәнлегемне аңладым.

Бит ул минем мондагы тормышны тулысынча белми. Ул бары хатлар буенча гына фикер йөртә. Ярар, кайбер нәрсәдә ул хаклы да булсын... Ә инде «күмелеп калу» мәсьәләсендә, эш, уку мәсьәләсендә... Юк, анысында ул ялгыша, бик нык ялгыша! Дөрес, минем әле ул әйткән китапларны — физика, химия дәреслекләрен кулыма да алганым юк. Ләкин дөньяда бит андый дәреслекләрдән башка да китаплар җитәрлек! Мин инде аларның күбесен укып та чыктым. Тик әле укып кына бетерә алмадым. Күрәсең, беркайчан да укып та бетерә алмам. Мин монда бөтенләй икенче төрле китаплардан өйрәнәм, тормыш китабын өйрәнәм. Әйе, минем хәзер күзем ачыла башлады кебек. Мин моны бик яхшы сизенәм.

Юк, Галия җаным, син хаклы түгел. Мин әле күмелмәм. Күмелү алай булмый. Киресенчә, күмелүдән азат була бару түгел микән әле бу!

## XVIII

Икенче көнне авыруларны мин аеруча игътибар белән карадым. Кичәге уйлардан соң, минем үз-үземә ышанычым арта төшкән кебек булды. Ләкин бу инде элеккечә масаю түгел. Бу — күңелдә җаваплылык хисе арттыра торган ныклы, төпле ышаныч.

Төшкә кадәр вакытым шулай авырулар карап үтте. Төштән соң мәктәпкә киттем. Мәктәпкә барганда, юл буенча Галия белән сүз көрәштереп бардым. Уйлый торгач, күп кенә нәрсәдә мин тагын да үземнең хаклы икәнлегемне күрдем. Мәктәпкә мин күтәренке күңел белән барып кердем.

Мәктәп авылның иң очына урнашкан. Якында гына Гәрә елгасы ага. Елга аръягында әрәмәлек, әрәмәлек артында иркен кырлар-басулар җәелеп ята.

Мәктәпкә әле минем беренче килүем. Укытучы халкыннан мин әлегә беркемне белмим. Күрше Кәрим абыйны исәпләмәгәндә, билгеле. Күрше дигәннән, мин хәзер алар белән татулаштым. Заһидә апа элеккечә ал-ял белми эшли дә эшли: мал-туар карый, утын кисә, утын кертә.

Кәрим абый көн дә Тау-авылга укытырга барып кайта. Алар үзара болай әйбәт кенә яшиләр. Тик менә Кәрим абый салырга ярата, аннары балалары гына чорсызрак: сугышалар, елыйлар, кычкыралар. Хәер, балалар барысы да шулайдыр инде...

Менә хәзер дә, мәктәп капкасыннан килеп кергәч тә, иң элек чыр-чу килгән бала-чага тавышы ишетелде. Тәнәфес вакыты бугай. Укытучылар дәрескә кереп киткәнче кирәкле кешеләрне очратырга теләп, кызурак атларга тотындым. Ләкин барыбер өлгерә алмадым. Мин укытучылар бүлмәсенә барып кергәндә, звонок булды. Мин бары исәнләшә генә алдым. Укытучылар, кулларына дәфтәр-журнал тотып, урыннарыннан кузгалдылар, бер-бер артлы чыга башладылар.

Бүлмәдә бары бер яшь кыз гына утырып калды. Чибәр генә. Түгәрәк битле. Гәүдәгә миннән бәләкәйрәк. Өстенә укучылар кия торган көрән йон күлмәк кигән. Чәче кистерелгән. Укучы дисәң, укучы түгел. Мәсәгуттә җиде еллык мәктәп. Андый зур укучылар монда булмас.

Мин кыю гына аның янына бардым, исәнләштем, үземнең кем икәнлегемне, ни өчен килүемне әйттем. Мәктәп күлмәге кигән кызый башланмаган дәфтәргә ниндидер исемлек шикелле нәрсә язып утыра иде. Мине күргәч, бу эшеннән туктады, оялчан гына елмайды да:

— Таныш булыйк алайса,— диде.— Мин монда пионер вожатые булып эшлим. Исемем — Лилия.

— Шулаймыни?— дигән булдым мин. Без сөйләшеп киттек. Башта бер-беребез турында сораштык: кайсы авылныкы, кайда укыдың, ничәне бетердең, дидек. Лилия Мәсәгутнеке икән. Быел җәй Ямадыда унны бетергән.

— Нишләптер мин сезне белмим,— дидем мин, Мәсәгутне бик яхшы белгән кеше кебек.

— Сез эшли башлаганда, мин өйдә булмадым,— диде Лилия.

Шулай диде дә никтер кызарынып китте. Мин аның ни өчен кызарганын сизеп алдым.

— Уфада булдыңмы?— дидем.

— Юк, Казанда,— диде Лилия, тагын да ныграк кызарынып.

— Нинди институтка?

— Университетка...

— «Балл» җитмәдеме?

— «Балл» җитмәде.

«Менә тагын миңа иптәш артты»,— дип уйлап алдым мин. Миңа аның кызарынуы да, оялуы да — барысы да таныш. Мин инде аларны кичергән. Институтка

керергә итеп тә, керә алмый калган һәркем миңа таныш, һәркем якын. Алай гына да түгел, андый һәрбер кеше минем иң якын сердәшем, иң якын туганым. Без — бер сыйныф кешеләре.

Лилия белән якыннан танышкач, мин аның кебек үк икенче бер «туганымны» исемә төшердем. Миңа моңсу булып китте. Үзем дә сизмәстән, көрсенеп куйдым. Минем көрсенүне Лилия үз кайгысын уртаклашу дип белде, ахрысы.

— Мин алай кайгырмыйм!— диде бу, шат күңелле булып күренергә тырышып.— Минем анда бик үк барасым да килмәде. Монда миңа ныграк ошый. Балалар белән күңелле. Берәр ел эшлим дә пединститутка биреп карыйм.

— Дөрес,— дидем мин, олыларча.— Нәрсә әле монда мүкләнеп ятырга!

Ләкин «мүкләнеп яту» хәзер минем үзем өчен дә ышандыргысыз булып ишетелде. Галиянең «күмелеп калу»ын хәтерләтте. Мин тынып калдым. Институт турында, «күмелү», «мүкләнү» турында сөйләшү хәзер миңа урынсыз булып, кызыксыз булып тоелды.

## XIX

Лилия, яңадан үзенең дәфтәренә иелгәндәй итте дә:

— Нишләп син бер дә дөньяга чыкмыйсың?— дип куйды.

— Вакыт юк,— дигән булдым мин.— Эш күп. Авылларга йөрергә кирәк.

— Шулайдыр инде,— диде Лилия.

— Арып-алҗып кайтасың. Анда инде клуб кайгылары калмый. Буш вакытың калды исә, укырга тотынасың,— дигән булдым мин, зарлангандай итеп.— Медицина бит ул! Анда бөтенесен яттан белергә кирәк.

— Шулайдыр инде,— диде Лилия тагын да.

Ләкин миңа бүген әллә нәрсә булды. Мин тагын тынып калдым. Зарланасы да килми. Кызыгы юк. Мине бүген бернәрсә дә тулысынча мавыктыра да, кызыктыра да алмый кебек. Мин үземнең һәрбер сүземдә, һәрбер фикеремдә хата күрәм, мәгънәсезлек күрәм шикелле. Аннары бер генә нәрсә турында уйлап та булмый. Әле кичәге кич турында уйлыйм, әле «сыйныфташ туганым» турында уйлыйм. Борчылып, газапланып уйламыйм. Бераз гына олы булып, хәтта бераз гына чит кеше булып уйлыйм. Ник алай икән бу? Нәрсә сәбәпче булды соң моңа? Галия хатымы, әллә Лилияме? Лилия дисәң, сәбәпче булыр нәрсәсе дә юк. Бары тик иске яраны гына кузгатты.

Бүлмә уртасында озын зур өстәл. Өстәлгә кызыл сатин җәелгән. Өстәлнең икенче ягында — Лилия. Мин тын гына утырам. Тышта, тәрәзә башында чыпчыклар чыркылдаша. Бүлмәдә салкынча. Тәмәке исе, кәгазь, акбур исе килә.

— Карале, Саҗидә,— диде Лилия, башын калкытып.— Октябрь бәйрәменә без пьеса әзерлибез. Кешеләребез җитми. Әллә катнашасыңмы?

Мин, урындыкны шыгырдатып, аңа табарак борылып утырдым. Ни әйтергә белмичә, беравык тынып тордым да:

— Кемнәр әзерли?— дидем.

— Мәктәп коллективы. «Зәңгәр шәл»не куймакчы булабыз,— диде Лилия.

Мондый тәкъдимгә мин бернинди икеләнүсез риза булырга әзер. Тик шулай да нидер тотып тора шикелле. Нәрсә соң ул «нидер»? Минем авылда клубка йөрмәскә, теләсә кем белән аралашмаска дип, үз-үземә биргән сүземме, Галиядән шүрләүме, әллә соң бөтенләй башка нәрсәме?

Мин сораштыра башладым: нинди рольләргә кеше җитми, дидем, син үзең уйныйсыңмы, дидем. Минем каршы килмәүне күреп, Лилия елмаеп җибәрде.

— Мөслим абыйны куандырыйм әле!— диде бу, иң элек үзе куанып.

— Без синең үзеңә дә бармакчы булганыек та... Менә үзең килдең. Яхшы булды әле. Кеше белән аралашмый, авыл яшьләрен яратмый, диделәр, шуңа да бармадык.

Күзгә карап әйтелгән мондый «мактау» сүзләреннән соң, мин сизелерлек дәрәҗәдә уңайсызланып киттем. «Минем турыда әнә тагын нәрсәләр сөйлиләр икән әле!» — дип уйлап алдым.

— Моннан соң мин сезгә гел килеп йөрермен әле,— дигән булдым үзем Лилиягә.

— Миңа Заһирә ролен бирделәр,— диде Лилия.— Беләсеңме, Булатның сеңлесе? Бер репетиция булды. Бүген тагын җыелабыз. Кичке җидегә.

— Миңа нинди роль бирмәкче буласыз инде?— дидем мин.

— Синңамы?— диде Лилия, тотлыккандай итеп.— Белмим. Анда бераз тавыш булып алды. Мөслим абый әйтер әле.

## XX

Күп тә үтмәде, яңа тәнәфес башланды. Бүлмәгә укытучылар керә башладылар. Менә ишектә директор да күренде. Мин аның белән таныш түгел, шулай да аның турын-

да ишеткәнем бар. Кыскарак буйлы, киң җилкәле. Юан, таза бер агай. Зур башлы, зур битле. Салмак кына атлап килде дә түргә, өстәлгә таба узды. Узышлый миңа таба карап алды. Мин урынымнан тордым, беренче булып сәлам бирдем, үземнең кем икәнлегемне әйттем.

— Ярый торган эш,— диде Мөслим абый салмак кына, ашыкмыйча гына.— Медиклар белән без моңарчы тату яшәдек. Күз күне, яз күне томау төшүләрне исәпкә алмаганда, авыручыларыбыз булмады. Медицинаның ярдәме гел тиеп тора.

— Балалар ничек?— дидем мин, җитди генә. Директорны мин чынлап сөйләшә дип уйладым. Йөзенә игътибар беләнрәк караган идем, кысылган күзләрендә елмаю чаткылары күреп алдым. Чыннан да, минем «җитди» сорауга ул җавап биреп тормады, шулай күзләре белән генә елмайгандай итеп, баштагыча салмак кына үз сүзен сөйләвендә булды.

— Асыл кошны аягыннан эләгә диләр, әй!— диде.— Болай булгач, сез асыл кош булып чыктыгыз инде, Саҗидә.

— Асыл кош читлектә яши. Иптәш Фәррахованы читлеккә ябып куярга туры килә,— дигән булды шунда кемдер, шаяртып.

— Үземнең нинди кош икәнлегемне белсәм, бөтенләй килеп йөрмәгән булырыем,— дидем мин, алардан калышмаска тырышып.

— Без аны читлеккә япмабыз,— диде Мөслим абый.— Аягына җеп бәйләп җибәрербез дә кирәк чакта тарттырып кына алырбыз.

Укытучылар күңелле генә көлешеп алдылар. Мин дә аларга кушылган булдым. Көлешү басылганын көтеп тордым да, үз йомышымны ачыкламакчы булып:

— Мөслим абый, мин сезгә эш белән килгәнием,— дидем.

— Сөйләп кара,— диде директор. Папирос кабызды да тәрәзә янынарак китеп барды. Ачык форточкадан өрәөрә тартырга тотынды.

— Балаларның тазалыгын тикшерергә кирәк,— дидем мин.— Аннан соң минем балалар белән гигиена турында, чисталык турында әңгәмә уздырырга да исәбем бар. Менә шул хакта сөйләшәсе иде. Тәнәфес вакытында эшләрбез микән, дәрестән соңмы?

— Ярар, булыр,— диде директор. Аннары, тәрәзә яныннан аерылып, өстәлгә якынрак килде.

— Без медикларга каршы килә алмыйбыз. Ләкин бер шарт белән,— диде.

— Нинди шарт?
— Ул инде белә, Мөслим абый!— диде Лилия.
— Белә? Син алып килдеңмени?— диде директор, Лилиягә карап.
— Юк, үзе килде.
— Ярый торган эш! Кыскасы, Саҗидә сеңлекәш, «Зәңгәр шәл»дә уйнарга безнең кешеләребез җитми,— диде директор.— Шунда катнашырга без сине чакырмакчы булганыек.
— Шулмы шартыгыз?— дидем мин.
— Шул. Ризамы?
— Белмим шул,— дигән булдым мин.
— Бүрегегез белән киңәшеп карагыз.
— Бүрегем юк шул.
— Эх, хатын-кызның менә шунысы яман да инде аның!— диде Мөслим абый.— Шәһәрдә әнә бүрек кия башлаганнар бугай, иншалла, дөньялар иминләнер болай барса.
Укытучылар тагын көлешеп алдылар. Мин дә көлгән булдым. Тавыш басылганны түземсезлек белән көтеп тордым да:
— Нинди рольләргә кеше җитми соң?— дидем.
— Дипломатик сөйләшүләрне менә шуннан башлыйк та без,— диде директор, елмаеп.— Мәйсәрәгә сез соңга калдыгыз. Мәйсәрә безнең бар. Шулай ук Заһирә дә бар. Безгә хәзер ишан хатыннары җитми. Мин үзем ишан булачакмын. Ике хатыным бар, өченчесен менә һич таба алмыйбыз. Коткарыгыз безне, Саҗидә сеңелкәш!
Соңгы сүзләрен ул театрдагычарак итеп, ялварып, ике кулын сузып әйтте. Безнең сөйләшүне тыңлап, безгә карап торган укытучылар күңелле генә гөрелдәшеп алдылар.
— Ярар, килеп карармын,— дидем мин, риза икәнлегемне белдереп.
— Юк, карарга килмәгез, уйнарга килегез,— диде Мөслим абый.
— Ярар, уйнарга килермен,— дидем мин, сүземне төзәтеп.— Эш мәсьәләсендә ничек?
— Эш мәсьәләсендәме? Бүген булмас. Озын тәнәфес үтте. Алдан билгеле булмагач, кыенрак булыр. Иртәгә! Килерсез, җаныгыз ни тели, барысын да эшләрсез. Бүген менә таныштык-белештек, җитеп торыр. Кич тагын килегез. Сәгать төп-төгәл җидегә.
— Ул инде белә, Мөслим абый!— диде Лилия.
— Беләмени? Ярый торган эш. Алайса сөйләштек?
— Сөйләштек!— дидем мин.

## Дүртенче бүлек

### I

Шулай итеп, минем тормыш икенче эзгә кереп китте. Мин репетициягә йөри башладым.

Бәйрәмгә инде күп калмады, шуңа күрә без көн дә әзерләнәбез. Үзем белән мин Таняны да алып барам. Ул уенда катнашмый, безнең кыланышларны карап кына утыра, әледән-әле үзалдына елмаеп куйган була. Ялыктыра башлады исә, рәсемле журналлар карарга тотына. Ә без кычкырабыз, җырлыйбыз, чыр-чу киләбез.

Безнең «баш режиссер» — Мөслим абый. Үзе уйнамаганда, ул безне читтән генә карап тора, өйрәтә, кабатларга куша, кайчагында әйткәләп тә ала. Аның әйтүе — безнең өчен закон. Билгеле, аның бернинди театраль белеме юк. Ләкин ул яшьтән үк спектакльләрдә уйнап йөргән. Аннары, үзе әйтүенә караганда, укытучылар институтында укыганда драмтүгәрәктә катнашкан. Ә ул драмтүгәрәкнең җитәкчесе ниндидер атаклы артист булган, имеш.

Үз ролем миңа бик ошый. Мин яратып, бирелеп уйныйм. Бер карчыктан миңа борынгы күлмәк табып китерделәр. Күлмәк зур, ләкин миңа таман гына. Шул күлмәкне кидемме, Таня тыела алмыйча көлергә тотына. Бүтәннәр дә көләләр. Шаяртккан булып, Саҗидә, сиңа гел ишан хатыны гына буласы калган икән, диләр.

Кичләрен, репетиция беткәч, караңгы урам буйлап төркемләшеп өйгә кайтабыз. Таня белән без төркемнән аерылабыз да пунктка кереп калабыз. Авылның икенче очында торган артистлар безне узып китәләр.

Көн дә шулай репетициягә йөрү, балалар белән, укытучылар белән аралашу мине кинәт үзгәртеп җибәрде. Моңсулык, юкка-барга эч пошу, аннан да бигрәк, минем турыда нәрсә сөйлиләр икән, тагын берәр гайбәт тараттмадылар микән, дип шикләнеп яшәү үзеннән-үзе юкка чыкты. Ул гына да түгел, хәтта Соломон Моисеевич та, аның белән булган оятлы, үкенечле үбешү дә онытылгандай булды. Минем өчен әйтерсең икенче дөнья ачылды. Мине бөтенләй яңа дәрт, яңа хис биләп алды. Мин хәзер өмет белән, киләчәктә, бик якын киләчәктә ниндидер яхшы, куанычлы нәрсә булыр дигән бер өмет белән яши башладым.

Ул көннәрдә мин очынып кына йөрдем. Нәрсә әйтсәләр, шуңа килешәм, нәрсә кушсалар, шуңа риза булам. Ә миңа кем куша ала? Йә Галим абый, йә Вәзир. Алар минем турыдан-туры начальникларым. Ләкин минем бу арада

авыл Советына бөтенләй кергәнем юк. Минем өчен хәзергә иң зур начальник — Мөслим абый. Үзеңнән олырак, тәҗрибәлерәк кешегә буйсыну кайчагында куаныч хисе тудыра. Ул вакытта мин дә шундыйрак нәрсә тойдым. Репетиция буенча гына түгел, башка мәсьәләләрдә дә Мөслим абыйның сүзе минем өчен авторитет булып әверелде.

## II

Беркөнне Мөслим абый белән минем арада шундыйрак сөйләшү булып алды.

— Карале, Саҗидә, сине картайган дигәннәрие, дөрес булып чыкты бит әле бу, әй!— ди Мөслим абый.

— Ник?— димен мин.

— Карт хатыннарны бик килештереп уйныйсың. Үзе карт булмаган кеше алай ук булдыра алмаган булырые димен шул.

Мин моңа көләргә дә, үпкәләргә дә белмәдем. Көлсәм, үземнән-үзем көләрмен шикелле, үпкәләсәм, үпкәләр нәрсәсе дә юк сыман. Аннары, Мөслим абый мыскыллап та әйтми, шаяртып кына әйтә.

— Белмим тагын,— димен, тотлыгып.— Картлар роле булгач, картларча кирәктер инде. Шулай да аңламыйм: кем мине картайган ди?

— Егетләр әйтә!— ди Мөслим абый.— Миңа жалоба белән кергәннәр.

— Жалоба? Кемнәр?— дидем мин, сискәнеп.

Шул чакны Равил белән Тимерҗанны күз алдына китереп, кызарынып киттем.

— Әһә!— ди Мөслим абый, күзләре белән генә елмаеп.— Кемнәр икәнлеге кызыксындыра, алайса? Анысын әйтмим. Егетләр булгач, егетләр. Син, Мөслим абый, колхозның парторгы буларак, Саҗидәгә тәэсир ит әле, диләр, кичләрен уенга чыксын, клубка барсын, безнең белән аралашсын, диләр. Югыйсә, ул чирлеләрне генә ярата, безне санга да сукмый, диләр. Саҗидәнең нурлы йөзен күрү өчен генә аяк-кулны имгәтеп булмый лабаса инде, диләр. Чын, әй, шулай диләр!

— Сез нәрсә дидегез соң?— дигән була шунда бер укытучы.

— Нәрсә дисең, әй! Мин яшь кеше түгел, минем сүзне тыңламас ул, дидем. Шулай да сөйләшеп карармын үзе белән, дидем.

Мөслим абый әле миңа, әле теге укытучыга карап ала. Укытучыга караганда, күз дә кыскалап куя. Мин инде

барысын да күреп торам. Мөслим абыйның шаяртып сөйләвен дә аңлыйм. Шулай да оят. Ни өчен оят булуын үзем дә төшенмим.

— Вакыт юк бит, Мөслим абый,— дигән булам, акланмакчы булып.

— Вакыт ул, сеңлем, безнең һәммәбезгә дә тәүлегенә 24 сәгать бирелгән. Бәлки, синеке 23 кенә сәгатьтер?

Укытучылар елмаешып алдылар.

— Болай сөйләвем өчен үпкәләмә, сеңлем,— диде Мөслим абый, җитди итеп.— Син бит яшь кеше. Яшь чакта яшьләрчә булырга кирәк. Яшьлек кайда да бер — авылда да, шәһәрдә дә. Гел шәһәр турында гына уйлап йөрсәң, бик тиз картаерсың. Чын, әй! Гомер ул искән җил кебек. Уза да китә.

— Нишлим мин анда чыгып?— дидем мин, үземнең гадәттәге фәлсәфәмә тотынып.

Мөслим абый тынып калды. Аптырагандай итеп беравык карап торды да:

— Алай кызык булмагач, булмый инде,— диде.— Ә мин сиңа бернәрсә тәкъдим итмәкче булганыем.

— Нәрсә?

— Нәрсәме? Халык алдында лекция укырга кирәк. Медицина темасына. Клубта.

— Безгә дә әйтәләр ул турыда,— дидем мин, сер тотмас балачага кебек.

— Әйткәч, бик яхшы! Тот та әзерлән, һәр айның унында, уникеләрендә кино килә. Кино башланыр алдыннан сөйләргә була. Белдерү язып, аерым җыярга да була халыкны.

— Юк, белдерүсез генә!— дидем мин. Мәктәптән кайтканда, мин юл буена Мөслим абыйның тәкъдиме турында уйлап кайттым. Нинди темага сөйлим икән, дидем. Ул көзне бөтен илдә, хәтта бөтен дөньяда вируслы грипп авыруы таралды. Мәсәгуттә әле ул сизелми иде, ләкин районда инде ишетелә башлаган иде. Мин шул турыда сөйләргә булдым. Кайттым да кул астында булган барлык материалны барлап чыктым. Әзерләнергә дә тотындым.

Минем өчен бу тагын бер яңалык булды. «Чынлап та, нишләп әле миңа тумас борын картаерга?!»— дип уйладым. Техникумда укыганда безгә әйттеләр ич, авылның җәмәгать тормышында актив катнашыгыз, халык арасында аңлату эшләре алып барыгыз, медицина темасына лекцияләр укыгыз, диделәр.

Соломон Моисеевич та әйтмәде микән әле? Әйтмәсә, аның әйтүе генә идемени?

Үземдәге материал гына миңа аз булып тоелды. Икенче көнне кабул итүдән соң, уку өенә кердем. Беренче мәртәбә. Бары урам аша гына чыктым. Бик озак газета-журналлар карап утырдым. Ә кичен тагын мәктәпкә киттем.

Әйе, ул көннәрдә мин гел нәрсәдер көтеп яшәдем. Уку өендә утырганда, репетиция башланыр сәгатьне көттем. Репетиция беткәч, тизрәк икенче көн тууын, тизрәк авырулар белән очрашуны көтә башладым. Икенче көнне тагын шул ук хәл кабатланды. Болай гына әйткәндә, мин тизрәк бәйрәм җитүен, тизрәк спектакль куелуын көттем. Аннары бәйрәмнән соң тизрәк кино килүен, үземнең тизрәк лекция укуымны көттем.

Тагын нәрсә көттем икән соң? Тагын мин бәйрәмнәрдән дә, спектакльдән, лекциядән дә зуррак икенче бер нәрсә көттем. Мин Тимерҗанны сагындым.

## III

Бишенче ноябрь иде. Ул көнне авырулар күп булмады. Кабул итеп бетердем дә үземнең эшемә тотындым. Зөһрә тиз-тиз генә идәнне юып чыкты. Аннары, эш сәгате беткәнне дә көтеп тормастан, өйләренә кайтып китте. Мин каршы килмәдем. Зөһрә дигәннән, аның белән минем арада соңгы көннәрдә сәер мөнәсәбәт урнашты. Без хәзер бер-беребезне элеккегә караганда да ныграк яратмыйбыз. Яратмау гына түгел — дошман күрәбез! Без инде бер-беребезнең күңелен шактый белеп өлгердек.

Шуның өстенә, озын колак аша, мин Зөһрә турында кайбер бүтән нәрсәләр дә ишеттем. Аулагөй турындагы, авырулардан май-күкәй алу турындагы гайбәтләрнең барысын да ул тараткан. Элекке фельдшерлар турында да ул шулай юк-бар сөйләп йөри торган булган. Гайшә апа: «Сак бул, сеңелем. Астан кисеп өстән ямай торган кыз ул»,— диде аның турында. Мин башта ачуымнан, нәфрәтемнән нишләргә дә белмәдем. Шундук Галим абыйга барып бөтенесен сөйләп бирергә, Зөһрәне бер көн торгызмый эштән куарга уйладым. Ләкин шулай да вакытында тыелып калдым. Гайбәт сөйли дип, әләкләшүнең үзенең гайбәт булуын чамаларга ничектер баш җитте. Чыннан да, ничек исбат итәсең аның гайбәт сөйләгәнлеген?! Үз эшен ул яхшы башкара. Ничек, кайсы яктан бәйләнәсең аңа? Аннан соң, гомумән, минем хәзер беркем белән дә тавышланып йөрисем килмәде. Ни генә булмасын, хәзергә мин эчтән тынарга булдым.

Ул да, күрәсең, эчтән тына. Ул да минем белән ачыктан-ачык бозылышмаска тырыша. Ул бераз гына койры-

гын кысарга мәҗбүр. Мин инде дәрәҗә саклыйм. Билгеле, болай бик кыен. Ләкин берни эшләп булмый. Бер очы чыгар әле кайчан да булса.

Зөһрә кайтып киткәч, без Таня белән икәүләп күлмәкләрне үтүкләдек, ашарга пешердек. Ашагач, Таня авылларына, төрле җирләрдәге таныш-белешләренә хат язарга утырды. Ул инде көн дә яза. Үзе һаман бәйрәм хаты язам дип сөйләнә. Минем Галиядән башка язар кешем юк. Ләкин минем аңа хәзер берни язасым килми. Чит, ят ул миңа хәзер.

Ашадым-эчтем дә, китап укырга утырдым. Нишләптер китап та укыйсы килми. Бернәрсәгә кул бармый. Бит бүген соңгы репетиция. Генераль репетиция. Иртәгә, алтысында мин сәхнәгә чыгачакмын. Тизрәк вакытны уздырасы килә, тизрәк мәктәпкә китәсе килә. Күңел түзми, җан түзми.

Мин инде үземнең сүзләрне күптән ятладым. Биш бармагым кебек беләм. Сүзе аның әллә ни күп тә түгел. Эш юктан тагын шуны кабатларга керештем. Кызларның күмәк җырын җырладым. Кычкырам бөтен бүлмәгә. Үзем төрлечә кыланган булам. Ярый әле, Таня ачуланмый.

Шулай ничек кирәк алай берничә сәгать узып китте. Иң яхшы дигән киемнәремне кидем дә, ашыгып, урамга чыктым. Таня кер юарга тотынды, мәктәпкә соңыннан барырмын, диде.

Тышта салкын гына һава коры, тын алуы рәхәт. Аяк асты туңган — баскан саен шакылдап-шакылдап кала. Көзге көн инде кичкә авышкан. Кичкә генә түгел, төнгә әйләнеп бара. Урамда беркем күренми. Барам шулай ашыгып йортлар, коймалар буйлап. Алга да карамыйм, артка да карамыйм.

Шулай бара торгач, каршымда кемдер барлыгын шәйләп, кинәт туктап калдым. Карасам — Тимерҗан! Күзләрне зур иттереп ачканмын да торам карап тавыш-тынсыз гына. Ул да миңа караган. Ул да аптыраган. Торабыз карашып ни алга, ни артка китмичә.

— Саҗидә!— диде бу, телгә килеп.

— Тимерҗан!— дидем мин дә.

— Исәнме,— диде бу.

— Исәнме,— дидем мин.

Икебез дә бер үк вакытта сөйлибез, шуңа күрә бер-беребезнең сүзен рәтләп аңламыйбыз да шикелле. Мин моңа күтәрелеп карагандай иттем. Өстендә эш киеме түгел. Клубка бара микән, идарәгәме? Ул да минем турыда шулайрак уйлады, ахрысы.

— Кая барасың?— диде.

— Менә... мәктәпкә,— дидем.

— Әллә фельдшерлыкны ташладың?— дигән булды бу.
— Йомыш белән барам,— дидем мин.
— Анда хәзер нинди йомыш? Балалар кайтып беткәндер?
— Балалары булмаса, олылары бардыр,— дигән булдым мин.
— Шулай микән...
— Шулайрак шул...
Шулай дидем дә урынымнан кузгалып куйдым, саубуллашып:
— Ярый, хуш... ыгыз,— дидем.
— Әгәр мин сине озата барсам?— диде Тимерҗан.
— Рәхмәт, юлны беләм,— дидем, сер сынатасым килмичә.
— Беләсеңдер дә, юлыңда бүреләр очравы бар бит әле.
— Очраганнары да җитәр инде!
— Очраганы аның бүре түгелдер.
— Бүре булмаса, төлкедер. Мин кузгалып киттем. Тимерҗан да кире борылды. Минем яннан атлап килә бу.
— Безнең халык турында син гел шулай уйлыйсың икән,— ди, ясалма бер үпкә белән.
— Ничек?
— Бүре дә төлке.
— Син шаярткынны аңламыйсың икән,— димен мин, җиңелчә шелтә белән.
— Аңлаштырам.
Шулай диде дә бу, күрәсең, бу турыда сөйләшәсе килмичә, тәмәке кабызырга азаплана башлады.

## IV

Без урам уртасына чыктык. Монда иркенрәк булып китте. Ләкин сүз барыбер ялганмады. Мәктәпкә барып җиткәнче берни сөйләшмәдек.
Репетиция башланырга әле иртә. Мәктәпкә беркем килмәгән булырга тиеш, чөнки тәрәзәләрдә ут күренми.
— Китереп куюың өчен рәхмәт,— дидем мин, мәктәп капкасы алдына килеп җиткәч.
— Сау бул,— диде Тимерҗан. Мин капканы ачтым, эчкә кердем. Бу да минем арттан иярде.
— Ишек төбенә кадәр илтеп куйыйм әле, булмаса,— дигән булды.
Мин эндәшмәдем. Ишек төбенә җиткәч борылдым да, көлеп:
— Җиттек. Рәхмәт,— дидем.
— Ике рәхмәт алдым. Өч булсын инде — әйдә, класска кадәр озата куйыйм,— диде бу.

— Юк, җитте,— дидем мин.

Ә үзем күңелдән: «Китмәсә ярар иде!»— дип уйлыйм.

Караңгы коридорга килеп кердек икәүләп. Мин үзебезнең репетиция була торган класска барам. Класс ачык. Килеп керү белән, борынга бераз тынчурак җылы һава бәрелде. Тәрәзә янына бардым да, партага басып, форточканы ачып җибәрдем.

— Кешенең медик икәнлеге әллә каян күренеп тора,— диде Тимерҗан.

Мин җавап кайтармадым. Партадан төштем дә аяк белән баскан җирне сөртеп куйдым, кысылыштырып шундагы парта арасына кереп утырдым. Ник утырганмындыр — үзем дә белмим. Гомумән, нишләргә дә, нәрсә уйларга да белмим. Икәүдән-икәү бер бүлмәдә булу, караңгы бүлмәдә булу шомлы да, сәер дә. Күңелдә шулай ук ниндидер вәсвәсә бар, куаныч-шатлык бар.

Тимерҗан да минем янга утырды. Кесәсеннән папирос чыгарды.

— Класста тартырга ярамый,— дидем мин.

— Укытучы күрмәгәндә ярый ул,— диде Тимерҗан.

— Фельдшер күргәндә ярамый.

— Алар үзләре дә тарта,— диде бу. Шулай да папиросын кесәсенә салып куйды. Тик торганда, тарту-тартмау мәсьәләсендә ике арада сүз ялганып китте.

— Алар фельдшер булганчы тарта башлаганнардыр,— дидем мин, тартучы фельдшерларны яклаган булып.

— Ничек кенә булмасын, фельдшер халкына барыбер ышанып булмый.

— Нишләп алай?

— Алар әнә эчмәскә дә кушалар да, үзләре эчәләр.

Миңа кинәт кайнар булып китте. Ярый әле караңгы — ул минем йөзне күрми. «Димәк, теге көнне кибеттән аракы алып кайтканны күргән»,— дип уйладым мин. Алып кайтканны гына түгел, Соломон Моисеевич белән эчкәнне дә белә торгандыр әле. Әллә соң болай гына сөйләнәме? Мин, гаепле кеше сыман, тып-тын калдым.

— Чынлап та, нигә алай икән ул?— диде Тимерҗан, миннән киңәш сораган кебек.— Кеше бертөрле сөйли, икенче төрле эшли. Ул сиңа тәртипле булырга куша, үзе тәртип боза. Тартмаска куша, үзе тарта, эчмәскә куша, үзе эчә. Яхшы булырга куша, үзе начарлык эшли. Нигә алай соң ул?

— Каян белим мин аны?— дидем мин.

— Син бик тиз ачуланасың икән, Саҗидә,— диде бу.

— Әллә тагын,— дидем мин.

— Син һаман да миңа ачу саклап йөрисеңме?

— Ни өчен?

— Теге сүзләр өчен соң...

— Кайсы сүзләр өчен?— дидем мин, гаҗәпләнеп.

— Ярар инде, белмәмешкә салынма.

— Юк, чынлап белмим!— дидем мин, ихлас күңелдән.

Тимерҗан тынып калды. Минем чыннан да ялганламаганны белергә теләгән кебек, сынап, миңа карап тора башлады.

— Мин сине ачулангансыңдыр дип уйлаганыем,— диде бераздан.

— Юк, мин сиңа ачуланмадым,— дидем мин.

— Минем сине гел күрәсем килде,— диде бу, әкрен генә.

— Шулаймыни?

— Әллә ышанмыйсың?

— Ышанам,— дидем мин, пышылдап. Нәкъ шул чакта тышкы ишек ачылган тавыш ишетелде. Без икебез дә, тынны кысып, көтә башладык. «Безне шушы килеш күрсәләр, нинди оят!»— дип уйлап алдым мин шул ук секундта.

— Репетиция бетүгә, мин сине көтеп торырмын, яме?— диде Тимерҗан, ашыгып, пышылдап.

Мин эндәшмәдем.

— Шушында, мәктәп янында, яме?— диде бу, чыгып китәргә җыенып.

— Ярар,— дидем мин, көчкә тын алып.

## V

Ишектән керүче туп-туры безнең класска килде. Тимерҗан чыгып китәргә өлгермәде. Белмим, нәрсә уйлаптыр, класста качып калмакчы булды. Бу тиз генә караңгы почмакка йөгерде.

Менә ишек ачылып китте. Ярым караңгыда мин Таняны танып алдым.

— Ә-ә, Та-аня!— дидем, куанып.

Мин моны шундый итеп әйттем, әйтерсең бер ел күрешми торганбыз.

— Син мондамыни?— диде Таня, тыныч кына.

— Монда, монда!— дидем мин, тагын да ныграк куанып.

— Син нәрсә, спектакль уйныйсыңмыни монда берүзең?

— Без икәү!— диде Тимерҗан, караңгыдан чыгып.

Таня, куркып: «А-а!»— дип кычкырып җибәрде. Өчебез дә көләргә тотындык.

— Менә нәрсә икән!— дигән булды Таня.

— Качышлы уйныйбыз. Уйныйсыңмы син дә?— диде Тимерҗан, татарча.

Таня Тимерҗан әйткәнне тулысынча аңлап җитмәде.

— Нәрсә ул «качышлы»?— диде Тимерҗанга карап. Аннары русча өстәп куйды: — Мин, бәлки, сезгә комачаулаганмындыр?

Мин Таняга «качышлы»ны тәрҗемә итеп бирдем.

— А-а, шулаймы качышлы уйныйлар?!— дигән булды Таня татарча.

— Шулай, шулай!— диде Тимерҗан.— Сажидә апагыз белән без әнә гел качышлы уйныйбыз.

— Алдый, алдый!— дидем мин.

— Белмим, кайсыгыз алдыйдыр,— дигән булды Таня.

— Карале, син бит каядыр барырга чыкканыең бугай?— дидем мин Тимерҗанга.

— Дөрес,— диде Тимерҗан.— Мин дә бит репетициягә барасы кеше.

— Репетициягә?!

— Әйе, мин гармунда уйныйм. Минсез анда... клубта берни барып чыкмаячак.

— Гармунда уйныйсың?!— дидем мин, никтер ышанасы килмичә.— Нишләп соң минем бер дә ишеткәнем юк?

— Гармун уйнаганны ишетү түгел, минем белән рәтләп сөйләшкәнең дә юк синең.

— Ләкин синең урамда уйнап узганың да юк.

— Урамда хәзер гармун уйнау, авыз күтәреп җырлау тыела.

— Тыела?!— дидем мин, аптырап.

Тимерҗанның сүзләре миңа көлке булып тоелды. Ләкин шул ук вакытта күңелгә: «Чыннан да, урамда гармун уйнаганны, җырлаганны ишеткәнем юк бит!»— дигән уй килеп китте.

— Әйе, тыела,— диде Тимерҗан.

— Теге, элек муллалар тыйган кебекме? Алар да таяк белән куалап йөргәннәр ди ич җырлаган, гармун уйнаган яшьләрне.

— Мулла нәрсә ул! Хәзер алай таяк белән кумыйлар.

— Кем тыя соң аны шулай да?

— Хуҗалар. Янәсе, культурасызлык... тәртип бозу...

— Кичә үлсәм, бүген ишетмәгән булырыем,— дидем мин.

— Бик зур яңалык белмичә үлә язгансың икән,— диде Тимерҗан.

Шулай диде дә ашыгып ишеккә таба китеп барды. Чыгып китәр алдыннан тагын баягы сөйләшү-килешү турында искә төшерде, Таняга: «Сау бул, Таня»,— диде.

— Мин бит сиңа өченче рәхмәтне әйтмәдем!— дидем мин, аның артыннан кычкырып.

— Нәрсә?— диде Тимерҗан, кире ишеккә килеп.

— Рәхмәт!— дидем мин, көлә-көлә.— Класска китереп куюыңа рәхмәт.

— Нәрсәгә рәхмәт?— диде Тимерҗан.

Аңлап алды да көлеп җибәрде.

— Бер рәхмәт мең бәладән коткара, ди. Мин хәзер өч мең бәладән котыла алам,— диде.

Ул китеп күп тә үтмәде, караңгы бүлмәгә Фәгыйлә апа килеп керде.

— Абау, әллә кеше бар?— диде, безне шәйләп.

— Без бу, Фәгыйлә апа, килегез монда,— дидем мин, кычкырып.

— Сезмени әле?— диде Фәгыйлә апа.— Ишәй белән Кушай килеп тә җиттегезмени әле?

— Җиттек шул,— дигән булдым мин.— Утыра торыгыз, хәзер лампа алып киләм.

— Йөрмә, үзләре кертерләр әле,— диде Фәгыйлә апа.— Караңгыда күңеллерәк.

Фәгыйлә апа Мәйсәрә ролен уйный. Аның тавышы искиткеч. Уфа, Казан артистларында да аныкы кебек тавыш юктыр. Чынлап. Минем инде тыңлаганым гына бар артистларны. Уфада ике ел торган кеше лә мин. Артистның тавышы аның икенче төрлерәк була. Ясалмарак диимме, шомартылганрак диимме... Музыкаль белемең булмагач, дөресен генә әйтеп тә булмый. Ә Фәгыйлә апаның тавышы саф, көчле. Чын-чынлап табигый тавыш.

Фәгыйлә апалар өендә бер ул гына түгел, барысы да җырчы. Әниләре дә, абыйлары да, сеңелләре дә. Рафика апа гына җырчы түгел. Барысыннан да яхшырак җырлаучы, әлбәттә, Фәгыйлә апа. Шуңа да Мөслим абый аны Мәйсәрә роленә алган. Булат роленә Хисам абыйны алмакчы булганнар икән дә, чын исеме Булат булган бер укытучы каршы төшкән. Үзе җырлый. Тавышы әллә ни көчле түгел, шулай да ярый инде. Үзе теләгәч, көчәнә шунда.

Ә Фәгыйлә апага беркем каршы төшәрлек түгел. Ул инде күптән шулай авыл сәхнәсендә җырлап килә икән. Ел саен Яңавылга смотрга бара икән, ел саен Мактау кәгазьләре алып кайта икән. Ул кәгазьләрне мин үзем дә күрдем. Стенага «кәртечкәләр» куелган рамнар янынаябыштырылган. Бервакыт Башкортстан филармония артистлары Фәгыйлә апаны үзләре белән алып китәргә дә иткәннәр, укытырбыз, өйрәтербез, дигәннәр. Фәгыйлә апа, дивана, риза булмаган. Ул нәкъ теге гәзитләрдә мактала торган кеше, үзе фермада бозау карый, үзе алдынгы. Үзе чибәр, үзе җырчы. Бар яктан да килгән инде менә.

Болай ул мине якын күрә, хәтта бераз гына ярата да бугай әле. Сөйләшкәндә гел үз итеп сөйләшә. Бүген эштән

бик арып кайткан, ахрысы. Әллә ничек, тик кенә утыра. Аның киеменнән ислемай исе, җылы өй исе килгән сыман. Ул эндәшмәгәч, без дә тынып калдык.

— Тимерҗан нишләп йөри монда?— диде бу, шулай тып-тын гына утыра торгач.

Мин дерт итеп киттем. Фәгыйлә апа авызыннан мондый сүз ишетү мине әллә нишләтеп җибәрде. Тимерҗан белән булган әлеге очрашудан, сөйләшүдән соң күңелдә шатлык-куаныч тойгысы саклана иде. Мин, әйтерсең, класста түгел, кайдадыр биектә, җиденче кат күктә утыра идем. Фәгыйлә апаның сүзләре шундук Зөһрәне күз алдына китереп бастырды. Мин бөрешеп калдым. Үземнең Тимерҗан мәсьәләсендә дә икеле-микеле хәлемә, җебегәнлегемә ачуым килеп куйды. Нишләп соң мин бер дә горур түгел, нишләп минем үз фикерем, ихтыяр көчем юк?! Нишләп соң әле мин бүген тагын аның алдында җебеп төштем? Зөһрәсе була торып, ник борчый ул мине? Алар барысы да шул: беркөнне берсе белән, икенче көнне икенчесе белән... Алар шулай. Ләкин ник соң мин дә алар кебек?!

Бик кыска гына вакыт эчендә минем күңелгә шундый сораулар килде.

— Таняда йомышы булган бугай,— дидем Фәгыйлә апага, ялганлап.

— Нярся Таня?— диде кызый, үз исемен ишетеп.

— Юк, бернәрсә дә юк,— дидем мин.

— Син мине алдый,— диде Таня, татарча җөмлә төзеп.

— Што син, разве сине алдарга ярый!— дидем мин.

— Карале, бу Танә дигәнегез көннән-көн ачыла бара бит,— дип куйды Фәгыйлә апа.

Ул моны болай гына, тынычсыз икәнлеген сиздермәс өчен генә әйтте. Шуннан соң тагын тынып калды.

Коридорда аяк тавышлары ишетелде. Ишек ачылды. Мәктәп караучы апа лампа күтәреп керде. Аның артында Мөслим абый, хатыны, тагын бер-ике укытучы күренде.

## VI

Репетициядән соң, мин Таня белән, укытучылар белән кайтып киттем. Як-ягыма әйләнеп тә карамадым. Пунктка җиткәнче, без бер төркем булып кайттык. Үзебезнең турыга җиткәч тә, мин туктап тормадым — кердем дә киттем. Таня белән икәүләп.

Өйгә кергәч, шулай да бераз гына кыен булды. Бит мин вәгъдәмдә тормадым! Менә, бер төрле сөйләдем, икенче төрле эшләдем. Ә бит мин үзем болай намуслы гына кеше.

Вакыт соң булса да, Таня белән чәй кайнатырга куйдык. Таня ут яндырмакчы булды. Мин яндыртмадым. Тәрәзә янына килдем дә карыйм урам якка. Күп тә үтмәде, урам уртасында Тимерҗан күренде, йөрәк кысылып куйды.

Мәктәп ягыннан килә. Әкрен генә килә. Безнең турыга җиткәч, туктагандай итте, тәрәзәгә карады. Нәкъ мин капланган тәрәзәгә. Мин читкәрәк киттем. Карап торды-торды да өйгә таба атлап куйды. Тагын карап тора башлады. Тәмәке тартырга кереште. Шактый озак басып торды. Торды-торды да теләр-теләмәс кенә кузгалып китте.

Баягынак мәктәптә чакта уйлаган шелтәле, ачулы уйларым кинәт юкка чыкты. Сүземдә тормавым өчен тагын бик-бик кыен булып куйды. «Җүләр!» — дидем, үз-үземне тиргәп. Яратмаган кеше шулай йөримени? Бәлки, ул Зөһрә турында уйлап та карамыйдыр әле. Зөһрә үзе генә ялынып йөридер!

Мин шундый фикергә килдем. Ул төнне мин бик тыныч йокладым. Иртән, гадәттәгечә, бик иртә тордым. Күңелдә — шатлык, тәндә — җиңеллек. Бәйрәм шатлыгы гына түгел. Аннан да зуррак шатлык-куаныч. Бөтен дөньяны ямьле итеп, гүзәл итеп күрсәтә торган шатлык-куаныч. Беренчедән, бүген спектакль. Икенчедән, бүген мин беренче мәртәбә халык арасына чыгачакмын. Чынын гына әйткәндә, пунктта ятып мин инде күптән ялыгып беттем. Өченчедән, әлбәттә, мин аны күрәчәкмен! Мин инде очрашкач, аңа әйтәчәк сүземне алдан ук әзерләп куйдым. Төркемнән аерылып булмады, диярмен.

Бүген авырулар бөтенләй диярлек булмады. Бер-ике кешегә укол кададым да бер кызның кайнар суда пешкән кулын бәйләдем. Эштән соң, Таня белән икәүләп, пункт капкасына кызыл байрак чыгарып кадакладык. Шуннан соң кичәгә әзерләнергә керештек.

Алдан исәпләп куйган план буенча, мин бәйрәм көнне Яңавылга кайтып китәргә тиеш идем. Җидесен дә исәпләгәндә, өч көн ял булачак бит. Үз урыныма Таняны калдырырга уйлаган идем. Яңавылга киткәндә мин гел шулай итәм. Бүген баштагы фикеремне үзгәртергә булдым. Бәйрәмне Мәсәгуттә уздырырга кирәк дигән фикергә килдем. Шул турыда әйткәч, сөенеченнән Таня елмаеп җибәрде, мине кочаклап алды, күтәрергә итеп караган булды — күтәрә алмады. Без икебез дә рәхәтләнеп көләргә тотындык.

Сөенми, сөенерлек тә шул. Берүзенә аңа өч көн буена бик үк күңелле булмас иде. Икәү булгач, без ничек тә бирешмәбез. Кая ул бирешү! Менә дигән иттереп үткәрер-

без бәйрәмне! Бүген кичне клубта уздырырбыз. Иртәгә дә клубка барырга була. Анда бармасак, мәктәпкә барырга була. Укытучылар үзара мәҗлес ясамакчылар. Шунда безне дә чакырдылар.

Монда мәсьәләнең икенче ягы да бар. Таня Равилгә чын-чынлап гашыйк, ахрысы. Миңа сиздермәскә тырышкан була. Тапкан сиздермәс кеше! Әйтерсең мин инде берни аңламыйм. Вәзир белән әйтешкән теге көннән соң, Таняның да эшләре чуалып китте. Равил пунктка килми башлады. Шулай да алар бер-ике мәртәбә кинога баргаладылар. Кино булмаган көннәрдә мин Таняны беркая җибәрмәдем. Чынлап. Усал бианалар кебек, тегене уч төбендә йомарлап тоттым.

Ә бүген... иртәгә... иртәгәдән соңга без икәүләп барачакбыз! Килен белән биана. Ха-ха-ха! Трам-та-там, трам-та-там, бүген театрга барам!

Клубка без бик иртә кердек. Халык җыела башлаганчы беренче рәттә утырып тордык. Бездән соң төркемләшеп, бала-чагалар керде. Аннары яшьләр күренде. Соңарак берән-сәрән олылар да килә башлады. Клуб эче әкренләп халык белән тулды.

Бер заман таягына таянып, Шәйхаттәр бабай килеп керде. Башында бүрек, өстендә сырма, аягында күн итек. Нәкъ теге каравылда торган чагындагы кебек. Килеп керде дә, ишек төбендә туктап, халыкка карап алды, кычкырып сәлам бирде.

— Исәнмесез, җәмәгать!— диде.

— Бик исәнбез, Шәйхаттәр абзый!

— Әйдә, түрдән уз!— диештеләр кешеләр.

Шәйхаттәр бабай, көлештереп, таягын тукылдатып, алгарак узды. Туп-туры безнең янга килде. Ләкин безнең арттагы кемдер аны үз янына чакырды.

— Бабагыз килде, башларга була,— дигән булды Шәйхаттәр бабай, арттагы утыргычка урнашып.

Таня белән мине танып алды да, табактай бите белән елмаеп:

— Иске танышлар икән ләбаса!— диде.

— Исәнме, бабай,— дидем мин.

— Исәнме, кызым, исәнме,— диде Шәйхаттәр бабай.— Исәнлеккә ис киткән, печәнлеккә ут киткән дигәндәй... йөрәк авырта әле, кызым, менә шуңа килдем... Өйдә утырып булмай. Кызлар янына тарта күңел.

Шул чакны кеше арасында Равил күренеп китте. Таня күрде дә авызын ерып җибәрде. Җитмәсә, үзе минем артка яшеренгән була. Янәсе «качышлы» уйный. Тапкан качар җир!

Равил дә безне күреп алды. Килә кешеләрне ырып-ерып.

— Исәннәрмесез, апалары!— диде бу, бөтен залга кычкырып.

— Равил, кил монда, кил!— дидем мин, кул болгап.

— Каягыз әле, кереп утырыйм әле шунда,— дип кычкыра Равил безнең рәттәге кешеләргә.— Әнә бит көтеп утыралар. Зарыгып беткәннәрдер.

Кысылыштырып бу минем янга килеп җитте, утырды. Мин Таня белән аның уртасында торып калдым. Урыннарны алыштыру өчен кузгала гына башлаган идек, халык арасыннан Мөслим абый килеп чыкты. Аның янында тагын хатыны белән берничә «артист» бар. Сәхнәгә баралар. Равил белән Таняның икесен генә калдырып, мин дә алар артыннан иярдем.

— Убыр китте, урыны калды!— диде Равил минем арттан.

Ишетеп торам — шундук Таняга тәрҗемә итәргә дә тотынды. Таняга инде җитә калды. Көлә. Аңа кушылып Равил көлә. Кеше артыннан көлеп калмасалар ярамагандыр!

Сәхнәгә менгәндә, мин, чак-чак кына башны борып, залдагы шаулашкан халык өстенә карап алдым. Беркемне аерырлык түгел. Кешеләрнең йөзләре барысы да бертөсле булып күренә. Барысы да кызгылт-сары, барысы да бер якка — сәхнә ягына төбәлгән...

Без җыйнаулашып сәхнәгә менгәч, тавыш басыла төште. Ә бераздан пәрдә ачылды. Мөслим абый, трибуна алдына чыгып, Октябрь революциясе турында доклад укырга кереште. Халык шып булды.

Мөслим абый доклад укыган арада, без киемнәрне алыштырдык, төзәндек-бизәндек, грим сөрттек. Доклад озак булмады. Докладтан соң, пәрдә ябылды. Озын күлмәкләрне өстерәп, җилбер-җилбер килеп, без барыбыз да сәхнәгә чыгып җыелдык. Мөслим абый, папкасын кул очына тотып, ашыгып, сәхнә артына узды.

Күп тә үтмәде, тиешле декорацияләр эленде, кое «образын» чагылдырырга тиеш булган бура сыман нәрсә сәхнә уртасына чыгарып куелды. Кыллавына бау бәйләнгән чын чиләк тотып, Мәйсәрә — Фәгыйлә апа кое янына барып басты. Ишан киемендәге Мөслим абый яңадан сәхнәгә килеп чыкты да, пышылдап, ләкин сәхнәдәге һәркем ишетерлек итеп:

— Башладык!— диде.

Без — сәхнә уртасында, яктыда буталып йөргән хатын-кызлар, су сипкәндәй, сәхнә артына кереп яшерен-

дек. Бер җиргә җыелдык та тынып калдык. Без — хор. Хорда мин дә катнашам.

Кемдер чыгып халыкка спектакль башлануын белдерде. Пәрдә ачылды. Бөтен зал бер ноктага — кое янында су алып торган Мәйсәрәгә — Фәгыйлә апага текәлде. Мөслим абыйның югары күтәрелгән кулы кинәт аска төште. Авызларны зур ачып, без җырлап җибәрдек:

Һаваларда йолдыз, суларда
кондыз,
Газизәкәй, балдыз,
Елама, калдырмам ялгыз...

## VIII

Спектакльне халык бик яратып карый. Тын да алмый утыралар. Фәгыйлә апа җырларга тотынгач, шундук дәртле бер җанлану сизелә башлады. Кайберәүләр ишеттереп көрсенеп куя, кайберәүләр борынын тарткалый. Пәрдә беткәч, шаулатып кул чаптылар, кычкырдылар, аяк типтеләр. Шунда берсе торып тәртипкә өндәгән булды. Ләкин халык барыбер тыңламый, күңелләре тулган — җенләнүен белә. Бары пәрдә ябылгач кына, кул чабу, шаулашу кимегәндәй булды. Аннары инде күңелле гөрләшү башланды.

Пәрдә артыннан пәрдә алышына торды. Безнең һәммәбездә искиткеч күтәренкелек. Сәхнә артында тыз-быз чабышып йөрибез, ашыгып сөйләшәбез, кайчагында исә бер-беребезгә ачуланып алабыз. Мөслим абый тыныч, җитди, киеренке. Күңелләрдә горурлык хисе. Беркайчан да булмаганча үзеңне бәхетле итеп тоясың. Үзеннән-үзе көләсең килә...

Көлү дигәннән, ул көнне мин сәхнәдә бик күп көлдем. Беренче пәрдәдә әле ярый. Ул-бу булмады. Ә менә бишенче пәрдәдә үземнең чамадан тыш көлүем белән чак-чак кына эшне бозып ташламадым.

Минем төп ролем — Сабира роле, ягъни ишанның өченче хатыны. Яшьрәк хатыны. Ишанның карт хатыны ролендә Мөслим абый бичәсе Нәфига апа уйный. Алар нәкъ тормыштагыча, тик исемнәре генә алышынган да, киемнәре генә алышынган. Алар икесе дә менә дигән уйныйлар. Аларның килмәгән җирләре юк. Ишан — Мөслим абый салмак, мәкерле, хәйләкәр. Хәдичә, ягъни ишанның карт хатыны — усал, явыз.

Хәдичәнең — Нәфига апаның сәхнәгә чыгуы булды, Мәйсәрәгә кычкырына башлавы булды, залдагы халык тыела алмый көләргә тотынды. Болай караганда, бер дә

көләр җире юк инде. Киресенчә, тып-тын гына утырырга кирәк. Чөнки көчләп ишанга дүртенче хатынлыкка бирелгән Мәйсәрә, уйлавымча, иң таш күңелләрдә дә кызгану хисе уятырга тиеш. Аның пәрдә ачылганда җырлаган җыры гына да нинди кызганыч! Халык исә уйлап та бирми, көлепме-көлә!

Хәдичәдән соң, Мәйсәрә янына ишанның икенче хатыны чыга. Талаш-кычкырыш башлана. Дөресе, талаш-кычкырыш дәвам итә. Ишанның карт хатыннары талаша. Аларны аермакчы булып, хатыннар арасына Мәйсәрә дә килеп кысыла. Сәхнәдә хатыннар талашын күреп, халык һаман буынсыз булып көлә. Хәзер инде чыннан да көлке.

Нәфига апа — Хәдичә сәхнәдә әле берсенә, әле икенчесенә очып куна. Теле телгә йокмый, кулы кулга йокмый. Шундый шәп уйный! Атказанган артисткаларың бер читтә торсын. Репетиция вакытында ул алай ук уйнамаган иде шикелле. Монда аны, әйтерсең, алыштырып куйганнар.

Мин бары соңыннан гына аңладым — халык бигрәк тә Нәфига апаның кыланышыннан көлә икән. Ул тормышта да нәкъ спектакльдәгечә усал, явыз икән. Усаллыгы аның бөтен тирә-якка таралган икән. Ул вакытта мин берни белмәдем. Шуңа күрә, залдагыларга ияреп, көләм тыела алмыйча!

Менә миңа да чыгар вакыт җитте. Чыктым да, ишан хатыннарының талашуын күреп:

— Бу ни эшегез, җирбитләр, хәзрәткә йокларга ирек бирмисез!— дип кычкырып җибәрдем.

Мин моны бик усал итеп, җикеренеп әйтергә тиеш. Ләкин минем кычкыруда бернинди җикеренү ишетелми. Мин ничектер көлә-көлә әйттем бугай.

Мин шулай җикеренгәч тә, карт хатыннар миңа ябырылдылар, мине мыскылларга тотындылар. Мин инде, ишанның яшьрәк хатыны буларак, алардан да арттырып җибәрергә тиеш. Ләкин, үтерәсеңмени, булмый гына бит! Һаман көләсе килә. Тиешле сүземне әйтәм дә, читкә борылып көлеп алам, тиешле сүземне әйтәм дә, тагын көләргә керешеп китәм. Залдагылар күреп алдылар, менә хәзер минем көлүдән көләләр! Мин инде болай ярамаганлыгын бик яхшы аңлыйм, шулай да берничек тә тыелып булмый.

Сизеп торам — сәхнәдә дә, залда да ниндидер үзгәреш башланды. Сәхнә артындагы Мөслим абый, ачуланып, миңа нидер пышылдарга тотынды. Нәрсә пышылдаганлыгын аңламыйм, пышылдавын гына ишетәм. Ул арада без —

ишан хатыннары үзара сугыша башлыйбыз. Безне бары Мәйсәрә генә аерырга тырыша. Бераз гына аерылгандай итәбез дә тагын эләгешеп китәбез. Мин әле һаман чын-чынлап ачуланып китә алмыйм. Үзем сугышам, акырам, җикеренәм, ә үземнең авыз ерыла! Аптырадым бит менә.

Шуннан бервакыт ыгы-зыгы арасында Нәфига апа ана каздай миңа очып кунды да, күзләрен акайтып:

— Көлмә!— дип ажгырды.

Шул ук секундта бар көченә минем беләктән борып та алды. Авыртудан чак-чак кына кычкырып җибәрмәдем. Көләсе килү шундук юкка чыкты. Күңелдә ташып ярсу кузгалды. Ләкин ул вакытта инде ишан хатыннарының талашы бетеп килә иде.

## IX

Спектакль беткәч, без залга төшеп утырдык. Спектакльдән соң, авыл яшьләре концерт башлап җибәрделәр.

Концертка мин әллә ни игътибар итә алмадым. Спектакль тәэсире тиз генә бетеп җитмәде. Мин ничектер кыйнап ташлагандай булганмын. Бөтен бит яна, колак очлары яна. Үзем сәхнәгә караганмын, үземнең күз бернәрсә дә күрми. Әле Таня, әле Равил нидер әйткән була, мактаган була — берни аңламыйм. Арттагы халык тавышы да шулай ук ерактан килгән тонык гөрелдек кенә булып ишетелә.

Шундый хәлдә мин шактый озак утырдым, ахрысы. Менә бер заман конферансье күмәк җыр башкарылачагы турында белдерде. Сәхнәгә җыйнаулашып дүрт-биш кеше чыкты. Күзләремне ныграк ачып карасам — Зөһрә, Фәгыйлә апалар! Хисам абый да алар белән, сеңелләре дә... Бөтен өй эчләре белән чыкканнар. Нәсимә апа гына юк.

Тезелделәр болар сәхнә уртасына. Иң алга Зөһрә белән Сәлимә басты, артка Фәгыйлә апа белән Хисам абый басты. Ә алардан алга, урындыкка, кулына гармун тотып... Тимерҗан утырды!

Мин айнып киттем. Күзләр тагын да ныграк ачылды, колаклар үрә торды.

Зөһрә мине күреп алды да эре генә читкә карады, башын югарырак күтәрде. «Спектакль уйнап шаккатырдым дип уйлыйсың инде? Бик исләре китте! Күр менә хәзер безне!»— дигән кебек булды аның бу тәкәббер кылanышы.

Тимерҗан бөтенләй карамады да. Хурланудан, оятымнан нишләргә белмәдем. Тимерҗаннан бигрәк Зөһрә ачуны китерде.

Ул инде баядан бирле минем күңелне кытыклады. Клубка беренче мәртәбә килеп кергәч тә, без аны очраттык. Безгә карамады да, эндәшмәде дә. Эчтән генә ул миңа, пунктта син хуҗа булсаң, монда мин хуҗа, дигән кебек булды. Туктаусыз ул безнең күз алдында чуалып йөрде. Әле сәхнә артына узып киткән була, әле лампаның утын калкыта, әле трибунага графин белән су китереп куя.

Күмәк җырны халык бик яратты. Шаулатып кул чаптылар.

Концерт номерлары алышына торды. Берәүләр биеделәр, җырладылар, икенче берәүләр чыгып шигырь укыдылар. Берсе дә ныклап торып хәтердә калмаган. Хәтердә бары бер генә «номер» калган. Бик нык калган.

— Аерым җыр!— диде әйтеп торучы.

Сәхнәгә Зөһрә чыгып басты. Аның янындагы урындыкка Тимерҗан килеп утырды. Мин инде моңа артык гаҗәпләнмәдем. Шулай кирәктер, дип уйладым. Соң, гармунчылары ул булгач, ул уйнамый кем уйнасын!

Үзе генә басып торганда Зөһрә миңа тагын да матуррак, тагын да тәкәбберрәк булып күренде. Өстендә кыска итәкле йон күлмәк. Алсу төстә. Итәге тар, биле нечкә. Нәкъ шәһәрчә. Күкрәкләре калку, муены ачык. Аягында биек үкчәле туфли. Капрон оек. Шатлыктан йөзе алсуланган, күзләре уттай яна. Сокланмасаң да сокланырсың дошманга!

Чыннан да, сәхнәгә бу чыгып баскач та, тирә-якта чыш-пыш тавышлар ишетелә башлады. Берсе әйтте: курчакмыни! диде, икенчесе әйтте: бер кашык су белән йотарлык, диде. Кайсыдыр көлеп куйган булды: сыйрагы нечкәрәк шул, авыр эшкә ярамас, дигән булды. Аңа каршы тагын берсе әйтте: беләге дә нечкә — сәнәк тота алмый бу, диде. Билгеле, көнләшеп сөйләнәләр. Тишек авыз ни әйтмәс.

Шундый чыш-пыш арасында колакка кинәт икенче төрле сүзләр чалынып калды.

— Нинди пар килгәннәр!— диде бер яшьрәк хатын, пышылдап.

— Аларны бит өйләнешергә йөри дигәннәрие,— диде янындагы ир кеше.

— Тимерҗаны киреләгән түгелме соң?— диде хатын кеше.

— Әллә тегесе микән соң? Бик чибәр бит, анасы!..— диде ире.

— Ярар, шаулама, тик кенә утыр!— диде хатыны.

## X

Шуннан башка мин берни ишетмәдем. Мин бөтенләй ишетмәс булдым. Залда бик кызу була башлады, дөнья тараеп калды. Бөтен халык арасында мин үземне кирәксез итеп сиздем.

Мин көчкә утырдым.

Концерттан соң халык тарала башлады.

— Кайтабызмы?— диде Таня.

— Кайтабыз,— дидем мин.

Равил безнең юлга аркылы төште.

— Юк, апалары, мин сезне кайтармаймын бүген!— диде, бик яман кычкырып.— Без сезнең уйнаганны карадык, хәзер сез безнең уйнаганны карагыз.

— Нярсә сулисен?— диде Таня.

— Шуны сулим, марҗа апасы,— дип кычкырды Равил,— кайтмыйсыз өйгә. Ни пайдет дамуй! Аңлашылдымы?

— Аңлашылдым,— диде Таня.

— Аңлашылдым түгел, аңлашылды!

— Аңлашылды,— диде Таня, төзәтеп. Аннары миңа карап алды да: — Таңга кадәр вакыт җитәрлек, калыйк, яме?— диде.

— Калыйк,— дидем мин.

Минем өчен барыбер — кайтсак ни дә, кайтмасак ни. Миңа хәзер бернәрсәнең дә кызыгы юк. Мин төштәге кебек. Шулай ук Таня да, Равил дә миңа төш кешеләре кебек тоела. Алар гына түгел, барысы да, барлык кешеләр дә, зал да, клуб та, сәхнә дә... Әйе, төштәге кебек.

Равил каядыр китеп барган иде, Таняга борылдым да:

— Син үзең кайтырсың... Минем баш авырта,— дидем.

Таняның берүзен калдырып чыктым да киттем. Таня аптырап калды. Иярмәде. Калсын. Алар икәү...

Тышка чыккач, йөгердем генә. Ишекне ачып өйгә кердем. Кергәч эчтән бикләп куйдым, үзебезнең бүлмәгә уздым. Үзебезнең бүлмә ишеген дә эчтән бикләп куйдым. Ашыкмадым, кабаланмадым. Бик җентекләп эшләдем. Шуннан соң өс-баш, аяк киемнәрен салып куйдым.

Бүлмә салкынчарак тоелды. Бернинди кайгым юк сыман, әкрен генә кыланып, мичкә ягарга керештем. Лампага ут яндырып тормадым. Мистә көндездән калган аш бар иде. Мич яна башлагач та шуны плита өстенә утырттым. Аннары өстәл өстендә җыештырылмый калган табак-савытларны җыештырырга тотындым. «Боларны бит юарга да кирәк әле»,— дип уйладым. Барып чиләккә тотынган идем, чиләк буш. Су беткән икән.

Яңадан өскә-башка киендем, кулга чиләк алып, суга киттем.

Клуб ягында тавышлар тынмаган. Кычкырып сөйләшәләр, кемдер гармун уйный, кемдер җырларга азаплана. Клубы да, тавышы да бик еракта, әллә кайда еракта булып тоела. Минем аларда бернинди катнашым юк. Мин читтә, бөтенләй чит дөньяда.

Ашыкмый гына тыкрыктан төшеп киттем. Коедан су алдым. Шулай ук ашыкмыйча гына өйгә кайттым. Яңадан ишекләрне бикләп куйдым. Плитә өстенә җылынырга су утырттым. Мистәге аш кайнарланып беткән. Өстәл янына килеп ашарга утырдым. Бер-ике кашык кына каптым да тәмсез ашны кире өтеп куйдым. Төш күрү өзелмәде. Табак-савытларны юып бетердем дә: «Тагын нишлисем бар икән?» — дип уйладым. Ә-ә, мичнең янып беткәнен көтәсе бар икән әле!

Утырдым да мичнең янып беткәнен көтә башладым. Озак утыра алмадым. Бернинди хәрәкәтсез утыру никтер куркыныч, бик куркыныч булып тоелды. Тышка чыгып киттем... Таня кайтмый микән дип...

«Ул кайтканчы ятып торыйм әле, булмаса», — дип уйладым. Шуннан соң чишенмичә генә караватка сузылып яттым. Күп тә ятмадым, күңелгә: «Йә йоклап китәрмен, ишекләрне ачып керим әле», — дигән уй килде. Тордым да ишекләрне ачып кердем.

Төш күрү дәвам итте. Өнне хәтерләтә торган бар нәрсәне куалап җибәрергә тырыштым. Әгәр дә мәгәр уянып киттем исә, әгәр дә мәгәр хакыйкать турында ныклап торып уйлана башладым исә, искәрмәстән карап булырмын шикелле тоелды. Ә минем әле яшисем килә. Төш күреп булса да яшисем килә.

Шулай аңгы-миңге ята торгач, чын-чынлап йокыга киткәнлегемне сизми дә калганмын.

## XI

Кайткач Таня, күрәсең, мине уятып тормаган. Мин берни белми йоклаганмын. Мин уянып киткәндә, әле караңгы иде. Шулай да таң аткан бугай. Сәгать бишенче ярты чамасы. Бер уянгач ятасы килмәде. Иплән кенә тордым. Юындым. Киендем. Кайбер нәрсәләрне сумкага салып, шүрлектән бер телем икмәк алдым. Ашана-ашана ишеккә юнәлдем.

«Таняга язу язып калдырырга кирәк» — дип уйладым кинәт. Кире борылып өстәл янына килдем. Башланмаган бер дәфтәр бите ертып алып: «Таня, мин Яңавыл-

га кайтып китәм. Минем урынга син каласың»,— дип язып куйдым. Йоклап яткан Таняга бер карап алдым да тыныч кына, ашыкмыйча гына чыгып киттем.

Тышта салкын. Ләкин минем өстә җылы. Иртәнге һаваның салкын булуы миңа хәтта ошап куйды. Урамда беркем юк. Яктырып килә. Мин урам уртасыннан барам.

Менә басуга да килеп чыктым. Авыл артта калды. Таш юлга кадәр нибарысы чакрым ярым. Бүген машиналар очравы шиклерәк. Очрап та куюы бар. Кичәге төш әле булса бетеп җитмәгән. Шулай да иртәнге саф һава, иртәнге салкынлык һәм җәяү бару үзенекен итә. Томанлы төш әкрен генә тарала бара, йокымсыраган йөрәк һәм баш миенең хәтер учаклары уяна бара. Күз алдына бер үк нәрсәләр килә башлый, күңелдә бер үк уйлар, чишелмәгән һәм, күрәсең, беркайчан да чишелмәячәк уйлар тыпырчына башлый.

Алайса, алар чынлап та яратышалар? Өйләнешергә йөргәч, билгеле яратышалардыр... Ә мин алар арасына кергәнмен. Үз санитаркамның сөйгән ярын тартып алмакчы булганмын. Мин — әхлаксыз...

Туктале, әллә соң санитарканың сөйгән яры әхлаксызмы? Мин аны белмәдем. Мин аны чакырмадым. Мәктәпкә үзе ияреп барды. Класска үзе керде. Көтеп торырмын дип, үзе сүз куйды. Чыннан да, бәлки, ул үзе әхлаксыздыр? Нинди әхлак ул! Авыл малаенда әхлак буламыни?! Беркөнне күрешәләр, икенче көнне өйләнешәләр, өченче көнне аерылышалар. Бармыни аларда чын ярату? Юк, билгеле. Хәтта җырда да җырлыйлар: яшь чагында типтереп кал, үкенерсең картлыкта, диләр. Менә шулай типтереп йөриләр дә инде алар.

Хәзер инде минем өчен барыбер. Кирәкми берсе дә. Санитаркасы да, сөйгән яры да. Яши бирсеннәр сөешеп. Минем үз-үземә егетләр белән йөрмәскә дигән сүзем бар. Галия хаклы. Мең мәртәбә хаклы.

Чыннан да, нинди ахмаклык эшләдем мин! Юк, эшләп үк җиткермәдем әле. Чак-чак кына харап булмадым, чак-чак кына «күмелеп» калмадым. Менә шулай «күмелеп» калуың бик тиз. Нәкъ Галия әйткәнчә. Башта шулай ихахай-михахай йөрерсең, аннары сизмәенчә генә чыгып куярсың, йортың булыр, балаң булыр, мал-туар дип кайгыра башларсың, печән, салам дип, балаларга күлмәкыштан дип кайгыра башларсың... Фу! Яшь кеше шул турыда уйлыймыни? Бит минем бөтен тормышым алда. Бит минем рәтләп яши дә башлаганым юк!

Болай булуы аның яхшы да булды әле. Икенче мин анда кайтмаячакмын. Бармыйм. Соломон Моиссеевич белән сөйләшәм дә район больницасына урнашам.

Соломон Моисеевичны искә төшерү белән, минем уй җепләрем чуалып китте. Күңелдә кинәт яшен кебек булып өмет чаткысы кабынып алды. Уйлар, теләгемә буйсынмыйча, берән-сәрән икенче якка йөгерешә башладылар. Күңел шатланып куйды. Менә бит ул нинди күңел! Нишләтәсең аны? Оят юк, намус юк. Бары үз кайгысын гына кайгырта. Чынлап. Мин инде аны берни эшләтә алмыйм. Күрәсең, аның үз законнары бардыр. Әллә берниндиг законы да юкмы соң? Каян белим мин аны. Миндә хәзер аның кайгысымыни?!

Таш юлга чыгып бер-ике чакрым киткәч, мине бер машина куып җитте. «Победа». Нининдидер начальник Яңавылга демонстрациягә барып җитәргә ашыга, ахрысы. Бәлки, кунакка барадыр яисә өенә кайтадыр. Мин инде сорашып тормадым. Минем анда эшем юк. Мине бары Яңавылга гына кайтарып ташласыннар.

Утырттылар. Бер ярты сәгатьтән кайтып та төштем.

## XII

Мин беркая чыкмадым. Өйдә генә яттым. Җидесендә өйдә аш-су булды. Кунакка әтинең-әнинең туганнары килде. Мәҗлес ярыйсы гына узды. Мин туйганчы ит, бәлеш ашадым да кунаклар таралганчы йокларга яттым. Икенче көнне төшкә кадәр йокладым. Кичкә чаклы йокларга да исәп бар иде, булмады — йокы туйган булып чыкты. Барыбер урыннан тормадым. Торасы килмәде. Уяу килеш ята бирдем.

Күңелгә тагын кичәге, өченче көнге хәлләр килде. Хәзер инде икенче төрлерәк итеп уйладым. Әрнеп, сызланып уйладым. Әледән-әле көрсенеп куйдым. Үземне үзем кызганып, юрган астында гына балавыз да сыгып алдым. Ярату шулай була торгандыр инде ул. Чынлап та, балавыз сыга белмәгән кеше ярата да белмидер ул. Яратмаган кешең өчен ник күз яше әрәм итеп торырга?

Ә бит мин аны чын-чынлап яратам бугай! Бернәрсәгә карамыйча яратам бугай. Ул мине ярата микән соң? Минеме, Зөһрәнеме? Белмим. Белмим булгач белмим!

«Туктале, нишләп яратмасын?» — дип уйладым бераздан, үз күңелемне үзем күтәреп. Яратмагач, минем арттан килер идемени? Очрашырга вәгъдә куяр идемени?!

Яшь аралаш мин елмаеп җибәрдем. Чак-чак кына сикереп тормадым. Нәрсәдер тотып калды. Күңелгә тагын каяндыр шик төште. Дөнья тагын караңгыланып, күңелсезләнеп калды.

Нишләп әле мин аларның арасына керергә тиеш?! Юк,

беркайчан да! Миңа әле табылыр үземә дигәне. Мин әле барыбер бәхетле булырмын. Барыбер.

Уйлый-уйлый минем баш авыртып бетте. Әллә күп йоклаганга микән соң? Ни булса да булгандыр, әмма әни килеп юрганны тартып алгач, шундук аягыма торып бастым. Ашагач-эчкәч, сеңлем белән энемне ияртеп, урамга чыгып киттем. Тимер юл станциясенә бардым, базарга төштем. Базарда ике стакан көнбагыш сатып алдым. Бер стаканны урталай бүлеп, энем белән сеңлемнең кесәсенә салдым, икенче стаканны үземнекенә салдырдым. Көнбагыш чертләтә-чертләтә киттек өчәүләп урам уртасыннан. Яңавылның үзәгенә — клуб, мәктәп, бакча ягына киттек.

Кая карама — йортларда, капкаларда кызыл байраклар, лозунглар, плакатлар, портретлар. Урамда халык. Кайсы безнең кебек көнбагыш чиртә, кайсы чикләвек ашый. Кайсы — кызмача. Һәркем шат, һәркемдә бәйрәм күтәренкелеге.

Өйдән чыкканда мин: «Урам күрергә барабыз»,— дидем. Чынында күңелдә икенче уй. Бик яшерен уй. Мин Соломон Моисеевичны күрергә өметләнәм. Урамда. Берүзен. «Бәлки, киногa чакырыр»,— дип уйлыйм. Кич хәтта озатып куюы да мөмкин, димен. Шунда, бәлки, Яңавылга күчү турында да сүз чыгарып куярга булыр, димен.

Шундыйрак уйлар уйланып барам урам уртасыннан. Райздрав турысыннан узып киттем. Бакчага кереп чыктым. Клубта бүген кич нинди кино булуын белештем, аннары үзебезнең мәктәпкә бардым. Аннан арырак та узып киттем. Арырак — аптека, больница. Анда — авырулар һәм медицина дөньясы. Соломон Моисеевичның кайда торганлыгын гына белмим. Белгән булсам, бер карамый барып чыккан булыр идем.

Ләкин, күпме генә йөрсәм дә, барыбер очратмадым. Күңелсез була башлады. Энекәш белән сеңлекәш тә: «Кайтабыз!»— дип теңкәне корытып бетерделәр. Тоттым да, кайту ягына борылдым. Никтер кайтасы да килми. Анда кайтып нишләргә?

Шулай да кайттык. Кайткач, тагын ашадык, эчтек. Өйдә бер-ике сәгать чамасы гына тордым да киенеп яңадан урамга чыгып киттем. Әйтерсең, тоз сипкәннәр! Клубка бардым, кинога кердем. Кинодан үземә генә кайтырга туры килде. Бик ямансу булды.

Нәрсә белән булса да юанмакчы булып, күңелдән грипп турындагы лекцияне кабатлап чыктым. «Уннарында бит кино килергә тиеш»,— дигән иде Мөслим абый! Мин аңа сүз бирдем, лекциянең темасын да әйттем.

Бармасаң, сөйләмәсәң, алдау була лабаса. Тагын сүзеңдә тормау була. Мөслим абыйны ничек алдамак кирәк? Атаң кебек кешене...

Тугызында эш көне иде. Иртүк тордым да җәяүләп Яңавылның Җобанай ягына юнәлдем.

## XIII

Зөһрә белән бөтенләй сөйләшмәдем. Шулай ук Таня белән дә сөйләшәсе килмәде. Мин киткәч, ниләр булуы турында да, Танянын кичләрен ничек уздыруы турында да — бернәрсә турында да сорашмадым. Таня үзе дә сөйләмәде.

Тугызы шулай моңсу гына, күңелсез генә узып китте. Кич йокларга ятар алдыннан, Таня шулай да әйтеп куйды:

— Җидесендә Тимерҗан килде,— диде.

— Шулаймыни?— дидем, гамьсез генә.

— Сине сорады. Кызмача. Син яшергәнсең аны, кая куйдың, ди...

— Яратмыйм исерекләрне!— дидем мин.

— Ул исерек түгел иде,— диде Таня, Тимерҗанны яклап.

— Барыбер!— дидем, кырт кисеп.— Бүген әнә берәү килгән. Эчәргә ярамый үзенә. Эчкән дә кан басымы күтәрелгән. Нишләргә белми. Эчкечеләрнең барысы да гипертоник та неврастеник. Әйткәнне тыңламыйлар, эчмә дисәң, кырык сүзгә җитешәләр, акыллы булган булалар. Эчмәгәч тә ни кызыгы бар бу дөньяның, диләр. Шәп фәлсәфә — әйтәсе дә түгел.

Үзем дә аңламыйм, никтер үртәлеп сөйлим. Ни өчендер кыерсытылган кеше кебек сөйлим. Аракының зарары турында Таня, билгеле, минем кадәр генә белә булырга тиеш. Ләкин минем анда эшем юк — күзгә күренмәгән ниндидер эчкечене тиргәвемне беләм.

Таня эндәшми. Ул эндәшмәгәч, мин дә тынып калдым.

Икенче көнне көткән кино килде. Белдерүне мин төштән соң күрдем. Кулдан язылган лекцияне эшем беткәч, яңадан бер кат укып чыктым. Аннары, дәфтәргә карамыйча гына, үз-үземә сөйләп карадым. Таня иртән Кызыл Ярга китте. Ул әле кино килгәнне белми. Аңа әйтмичә генә чыгып китүне килештермәдем. Аның кайтып җиткәнен көтеп тордым да:

— Бүген кино килгән бит,— дидем.

— Барабыз алайса!— диде бу, сикергәләп.— Лекцияңне онытмадыңмы соң?

— Юк,— дидем.

— Үз вакытың белән керерсең. Мин алдан киномеханикны күреп сөйләшәм.

Чыгып киттем. Клубта киномеханикны эзләп таптым. Кино башланыр алдыннан медицина темасына лекция укырга исәпләвемне әйттем. Киномеханик берсүзсез риза булды. Күңел тынычланып калды. «Халык җыелганчы Таня янына кереп чыгыйм, булмаса»,— дип уйладым.

Клубтан чыктым да яңадан үзебезгә кереп киттем. Шул чакны күзгә Тимерҗан чалынып калды. Идарә турында туктап тора. Янында кемнәрдер бар. Бу да мине күреп алды. Күрде дә урыныннан кузгалды. Миңа таба килә. Үзе кычкыра:

— Саҗидә, туктале!— ди.

Аның шулай урам бетереп кычкыруы миңа әдәпсезлек булып тоелды. Шул чагында миңа, бәлки, йөгерергә кирәк булгандыр. Ләкин мин йөгермәдем дә, ашыкмадым да.

Ул арада Тимерҗан килеп тә җитте, минем юлга аркылы да төште.

— Саҗидә! Саҗидә!— ди кабаланып,— артыннан куа киләләрмени!

— Сезгә нәрсә кирәк?— дидем, тыныч кына.

— Син кирәк, Саҗидә!

— Кабул итү сәгате бетте, иртәгә килерсез,— дидем.

Мин моны чынлап әйттем шикелле, ләкин бу теге шаяртып сөйләшкәндәге кебегрәк килеп чыкты.

— Әллә нинди син, Саҗидә, валлаһи!— диде бу, ачыргаланып.— Качасың, сүзеңдә тормыйсың. Ник теге көнне калмадың?

— Гафу итегез, вакытым юк,— дидем, китеп бармакчы булып.

— Туктале! Бераз гына...— диде бу.

Үзе никтер ашыга, кабалана, юлга аркылы төшә, хәтта минем кулдан тотып алмакчы була.

— Туктап торырга вакытым юк!— дидем мин тагын да.

— Бер генә сүз! Бер генә сүз сөйләшәсе бар синең белән, Саҗидә!— диде бу.— Ныгытып сөйләшәсе бар, аңлыйсыңмы?!

— Сөйләш әнә Зөһрәң белән!— дидем, усал итеп.

Әйе, бик усал итеп әйттем. Барысын да — үпкәсен дә, ачуын да, нәфрәтен дә бергә җыеп әйттем. Кырт кына читкә тайпылдым да, киттем дә бардым.

— Менә шул турыда, Саҗидә! Шул турыда, аңлыйсыңмы?!— диде бу, өзгәләнеп.

Юк, туктамадым. Арттан килергә батырчылык итмәде. Урамда, капка төбендә туктап калды.

## XIV

Без Таня белән клубка барып кергәндә, халык җыела башлаган иде инде. Тимерҗан да шунда кергән, ниндидер егетләр арасында күренә.

Кердек тә алгарак уздык. Безнең утыруыбыз булды, яныбызга Тимерҗан килеп җитте. Таняга карап:

— Исәнме, Таня,— диде.

— Исянме, Тимерзян,— диде Таня.

Мин читкә борылдым. Кыймыйча гына Тимерҗан урынга утырды. Сүз башларга итеп карады, ләкин сүз ялганмады.

Утырабыз шулай өчебез дә ни өчендер үпкәләшкән кешеләр сыман. Таня әледән-әле ишек ягына караштыра, үзенең Равилен көтә. Тапкан көтәр кеше! Анысы да шундый ук Донжуандыр әле. Йөрсен әле әйдә ышанып. Татарча өйрәнә, имеш! Әйтерсең мин аны кытайча өйрәтәм. Мин өйрәткән ярамаган. Өйрәтерләр әле сине татарча!

Безнең янга әкрен генә атлап киномеханик килеп җитте.

— Әллә лекцияне башлап җибәрәсеңме?— диде миңа.— Кино соңга кала. Халык җитәрлек җыелды.

— Ярар,— дидем мин, урынымнан кузгалып.

— Хәзер утны кабызам,— диде киномеханик.

Ашыкмыйча гына тышка чыгып китте. Озакламый урамда дөп-дөп мотор эшли башлады. Клуб эче гөлт итеп китте. Мин, лекция язылган дәфтәрне кулыма тотып, сәхнәгә таба атладым.

Ләкин шул вакыт көтелмәгән бернәрсә булды. Мин сәхнәгә менеп җитә алмый калдым — алгы рәтләрнең берсендә утырган Мирсәет абый — колхоз председателе басты да:

— Иптәшләр, тавышланмагыз,— диде.— Хәзер, кино башланганчы, раюннан килгән лектор иптәш Кашапов сезнең алда раюн партия кәмититенең чираттагы плинум карарлары хакында бисида ясаячак.

Мин тукталып калдым. Залга борылдым да, аны-моны уйлап тормыйча:

— Юк, хәзер мин лекция укыйм!— дидем.

Бик ышанып әйттем, үземнең хаклылыгыма, укыячак лекциямә ышанып әйттем. Барысы да миңа күтәрелеп карадылар. Клуб эче тып-тын калды.

— Өченче көн генә доклад булды лабаса!— дип кычкырды кемдер.

— Лекторлар күбәйгәч, харап икән эшләр, малай!— диде икенчесе.

— Мин медицина темасына укыйм,— дидем мин, кычкыручыларга җавап итеп.

Председатель, кулын күтәрде дә, халыкка тагын тавышланмаска кушты. Аннары, сөзәргә җыенган үгез төсле, миңа карады.

— Нәрсә сез, иптәш Фәррахова?— диде.— Сезгә кем кушты?

— Бүген мин әзерләндем,— дидем мин.— Грippка каршы көрәш турында. Безгә районнан куштылар, Мөслим абый кушты. Киномеханик әнә утны минем өчен яндырды.

Залдагылар көлешергә тотындылар.

— Тавышка куярга!— дип кычкырды кемдер.

Председатель яңадан халыкны тынычландырды да, ике төрле уйларга урын калдырмыйча:

— Бик яхшы алай әзерләнгән булгач,— диде.— Сез мондагы кеше. Икенче кино килгәч укырсыз.

Шулай диде дә, янындагы ят кешегә:

— Рәхим итегез, иптәш Кашапов,— диде.

Кашапов дигән кеше сәхнәгә таба атлады. Баскычтан менде. Минем яннан үткәндә илтифатсыз гына миңа кагылып, орынып китте. Хурлыгымнан җир тишегенә керердәй булдым. Хурланмаслык та түгел шул — никадәр тырышып әзерлән-әзерлән дә, кисәк кенә, җиңел генә синең өметеңне киссеннәр, имеш! Бернинди сораусызнисез, бернинди сөйләшүсез! Бөтен халык алдында адәм көлкесе итсеннәр, имеш! Юри эшләгәннәр дип торырсың.

Минем күңел тулды. Тамак төбенә ачы төер килеп тыгылды.

Ул арада лектор сөйләргә дә керешеп китте. Кисәк кенә урынымнан куптым да, кызарынып-бүртенеп, бөтен зал аша ишеккә йөгердем.

Бүлмәгә кергәч, чишенеп тә тормыйча, мендәргә капландым, еларга тотындым. Туйганчы еладым. Авылда бер көн торасым килмәде. Авылда гына түгел, дөньяда торасым килмәде. Беркем кадереңне белми икән, адым саен кыерсыталар икән, ник торырга, ник яшәргә?!

## XV

Үзалдыма тузынып, мин икенче көнне тагын Яңавылга кайтып киттем. Инде монысында бөтенләйгә. Чынчынлап. Бернинди икеләнүсез, бернинди үкенүсез...

Яңавылда үзебезнең өйгә дә кайтып тормадым — туптуры райздравка киттем. Соломон Моисеевичның мине

аңлаячагына, миңа ярдәм итәчәгенә мин әз генә дә шикләнмәдем.

Күземә ак-кара күренмичә, әле һаман ярсып, тәвәккәл бер кыяфәт белән ишек шакыдым. Җавап та көтеп тормастан, ишекне иңеләй ачып җибәрдем. Кердем дә, кычкырып:

— Рөхсәтме?— дидем.

Рөхсәт бирделәрме, юкмы — хәтерләмим. Кыю гына түргә уздым. Бүлмәдә ике кеше күренгәндәй булды. Берсе Соломон Моисеевич булырга охшый, икенчесе әллә секретарь хатын, әллә бүтән хатын-кыз. Үзе бераз таныш кебек. Мин ишектән килеп кергәндә, алар бер-берсенә бик якын торалар иде шикелле. Мин кергәч, берберсеннән аерылып киттеләр. Күңелдә шундук: «Әллә үбешеп торалар инде?»— дигән бер шикле уй туып алды. Чынлап та, шулай булды, ахрысы.

— Ә, иптәш Фәррахова! Саҗидә!— диде Соломон Моисеевич, чамадан тыш ягымлы елмаеп.— Әйдә, әйдә, түрдән уз!

Соломон Моисеевич күлмәк якасын, галстугын төзәткәләп алды да үзенең кресло сыман итеп ясалган урындыгына килеп утырды. Мин дә утырдым. Аның каршысына. Мин тынычсыз. Иреннәр кысылган, йодрыклар йомарланган. Сугышка ташланырга җыенган яшь әтәч кебек. Соломон Моисеевич та бик үк тыныч түгел шикелле. Күз кырые белән генә тәрәзә ягына карап-карап ала. Караганын миңа күрсәтмәскә иткән була, ләкин ничек күрмисең — каршыда гына утыра лабаса! Артта, тәрәзә янында теге хатын-кыз басып тора, ахрысы.

— Сөйләп җибәр — эшләр ничек бара?— ди Соломон Моисеевич, миңа эндәшеп.

Мин нәрсә сөйләргә дә белмим, каткан агач кебек тик утырам. Сүз башларга нәрсәдер комачаулый шикелле. Күңелдәге уйлар түгел, мондагы ниндидер серлелек, аннары минем арттагы ят хатын-кыз комачаулый шикелле.

Нәрсәдән сүз башларга белми аптырап утырганда, минем арттагы хатын-кыз телгә килде.

— Ярый, мин китим, Саша,— диде.

Тавышы моның калтыранып чыкты. Бик таныш тоелды бу миңа. Чак-чак кына артыма борылгандай иттем. Соня! Безнең белән Куштирәккә барган фельдшер Соня. Кызарынган, күз карашы томанлы. «Чынлап та үбештеләр микәнни?»— дип уйладым тагын да.

— Ярый, ярый, рәхим ит!— диде Соломон Моисеевич, Соняга баш иеп, елмаеп.

Соня мине күрде, таныды. Шулай да танымаганга салынды. Мин дә аны танымаганга салыштым: тиз генә

башымны бордым да, иреннәремне тагын да ныграк кысып, үртәлеп, өстәлдәге кара савытларына карап утыра башладым. Соня, биек үкчәле туфлиләре белән шак-шок басып, ишеккә юнәлде.

— Туктале!— дигән булды Соломон Моисеевич, урыныннан торып.

Ниндидер бик кирәкле сүзе калган кеше сыман, ул Соня артыннан кузгалды, аны ишеккә кадәр озата барды. Ишекне ачып, коридордагы Соня белән тагын пышылдап кына нидер сөйләнеп алды.

Мин барысын сизеп, ишетеп утырдым. Мин үземне утлы табадагы кебек хис иттем. Юл буена ташып килгән ярсу, тәвәккәллек — барысы да юкка чыга барды.

Соломон Моисеевич, Соняны озатып кергәч, кире үз урынына килеп утырды. Ул минем яннан узып китте. Шул чакны корсагы күзгә ташланды. Бәләкәй генә тау кебек булып, чалбар каешын төртеп тора. Ияк асты да салынып төшкән. Мин аны элек күреп җиткермәгәнмен, ахрысы. Баксаң, ул да симез кеше икән ләбаса!

— Йә тыңлыйм,— диде бу, матур кара күзләрен яңадан миңа төбәп.

«Нәрсә әйтергә соң?» — дидем мин кинәт үз-үземә. Чынлап. Барысын да онытты. Миндә хәзер икенче нәрсә башланды. Әллә күңел кайту, әллә ышанмау, әллә җирәнү...

— Нәрсә булды? Нишләптер борчулы күренәсең, Саҗидә,— диде райздрав мөдире.

Ул моны бик ягымлы итеп, күңелгә кереп әйтте. Ләкин сизеп торам — чын күңелдән түгел. Шулай булса да аның бу ягымлылыгы күңелдәге кире тойгыларны юкка чыгара алды. Күз ачып йомганчы, мин яңадан элекке Саҗидәгә әйләндем.

— Китәм мин Мәсәгуттән, Соломон Моисеевич!— дидем, телгә килеп.— Мин анда эшли алмыйм. Күчерегез мине районга.

— Нишләп алай? Нәрсәсе ошамый Мәсәгутнең?

— Тынычлап эшләргә ирек бирмиләр. Адым саен аяк чалалар. Бигрәк тә колхоз җитәкчеләре. Булмый, эшләмим! Теләсәгез нишләтегез.

Бөтенләй кирәкмәгән чакта Кәрим абый күз алдына килеп китте. Ул да бит башта ук, очрашкач та миңа колхоз, авыл җитәкчеләрен хурлаган иде. Ул вакытта аның да, күрәсең, шулай тузынган чагы булгандыр.

— Эшләп булмый алайса?— дип куйды Соломон Моисеевич, уйлангандай итеп.— Син бит институтка керергә хыялланасың?

— Әйе,— дидем мин, теләр-теләмәс кенә.

— Ярар, булыр, Саҗидә!— диде кинәт Соломон Моисеевич, күтәренкелек белән.— Район больницасында бер урын бар. Мин сине шунда күчерермен. Ризамы?

— Риза,— дидем мин, әкрен генә.

Тик нишләптер мин моңа чын-чынлап шатлана алмадым.

— Иртәгә килерсең,— диде Соломон Моисеевич.— Секретарь чирләп киткән. Иртәгә эшкә чыга. Приказны да шунда язарбыз. Ә хәзер бар, тынычлан, ял ит.

## XVI

Ул шулай мине юатып, юмалап чыгарып җибәрде. Миңа ул каядыр ашыга, шуңа күрә мине тизрәк чыгарып җибәрергә тырыша кебек күренде. «Коридорда Соня көтеп тора микәнни?»— дип уйладым мин. Коридорга чыккач, Соняны күрмәкче булып, як-ягыма карандым. Соня күренмәде.

Әкрен генә атлап үзебезгә кайтып киттем. «Дөрес, үбешеп торалар иде»,— дигән уй килде күңелгә. Яңадан барысын да күз алдыннан үткәреп чыктым. Мин кергәндә үбешеп торуларына тамчы да шигем калмады.

«Үбешсәләр әллә!»— дидем үз-үземә, бераз баргач. Бер дә исем китми шикелле тоелды. Бары тик икенче урындагы үбешү генә күңелне тырнап, ачыттырып алды. Аякларым ирексездән кызурак атларга тотынды. Эх, бөтенесе буталды, бөтенесе баш-аяк килде...

Кайтканда базарга сугылдым. Өченче көнге кебек, кесә тутырып көнбагыш алдым. Энекәш белән сеңелкәшкә. Алар бит күчтәнәч алып кайтканны яраталар. Күчтәнәчне кем дә ярата. Ә теге вакытта мин алмадым. Әгәр алган булсам? Күрәсең, күчтәнәч белән күчтәнәч арасында аерма бар.

Тимер юлны чыктым да үзебезнең якка бара торган юлга борылдым. Озакламый таш юлга барып чыктым. Ике якта йортлар. Мин юл читеннән барам. Алдан да, арттан да машиналар килә. Тыз да быз чабып кына торалар.

Менә бер заман таныш автомашина тавышы ишетелеп китте. Шундук артыма борылып карадым. Борылмадан маңгаена кызыл хач билгесе куелган «ашыгыч ярдәм» машинасы килеп чыкты. Килеп чыкты да, җилләнеп, тузан туздырып, минем яннан узып та китте.

Шофер янына Соломон Моисеевич утырган. Шофер белән аның арасына авызы колагына җиткән Соня кысылган. Соломон Моисеевич та көлә. Күрәсең, бик кызыктыр.

Әйе, алар. Узып киттеләр. Мин карап калдым...

Кая баралар алар? Бүә буенамы? Балыкка? Аны бит, «ашыгыч ярдәм» машинасына утырып балыкка йөри дип, район газетасына язып та чыкканнар иде. Димәк, дөрес язганнар. Әнә тагын киттеләр. Ләкин мондый салкында нинди балык ди ул?! Хәер, бер балык капкан ич инде. Әллә авырулар янынамы? Ник врачлар бармый? Ник халат кимәгәннәр? Фельдшер Соняның «ашыгыч ярдәм»гә ни катнашы бар? Алайса, урманга, табигать кочагына!

Кая барсалар да минем өчен барыбер түгелмени? Барсыннар. Кирәгем исә, Каф тау артына китсеннәр. Әллә кая олаксыннар. Миңа хәзер барыбер.

## XVII

Кайттым. Әти гәзит укып утыра. Минем әти бик кызык кеше. Гәзитне ул баштанаяк укып чыга. Беренче битендәге беренче хәрефтән алып соңгы битнең соңгы хәрефенә кадәр укый. Укып чыга да күзгә күренмәгән берәр бюрократны сүгә, каракларны йә булмаса американнарны-фәләннәрне сүгә. Ул да булмаса, үз-үзе белән бәхәсләшә башлый. Әле укып чыкмаган, тып-тын утыра.

Энекәш белән сеңелкәш уенда. Әни казан тирәсендә. Мине күргәч, болар аптырап киттеләр. Әти гәзит укуыннан туктады да:

— Ни булды, кызым?— диде.— Ни шимбә, ни җомга дигәндәй, әле генә кайтып киттең ич!

— Кайтсани!— дидем мин.

Чишендем дә түргә уздым. Эш юктан эш булсын дигән сыман, әпи ашарга керешеп киттем. Эш юктан гына түгел инде — ашыйсы да килә.

— Аш өлгерә, сабыр ит,— диде әни.

— Өлгерсә!— дидем, кыты гына.

Аш өлгергәнне көтеп торасым килмәде, туңдым әле, дидем дә төренеп урынга яттым.

— Нәрсә, башыңа бер-бер кайгы төштеме әллә?— диде әти.

— Төшмәде,— дидем.

— Нишләп алай кара көйдең соң?

Эндәшмәдем. Шулай тып-тын гына яттым да, өйдәгеләрне сөендермәкче булып:

— Мәсәгуткә бармыйм,— дидем.— Район больницасына күчәм. Иртәгә приказ язылачак.

— Ни булды?— диде әти.— Ошамадымыни? Әллә кешеләр белән килешмәдеңме?

Нишлисең, барысын да сөйләп бирдем әтигә. Дөресрә-

ге, кичәге күңелсезлекләрне. Үземне хаклырак итеп күрсәтү өчен, колхоз председателен юри ныграк яманладым. Аннары Вәзирне дә искә төшердем. Моңарчы әле мин әти-әнигә берни әйтмәгән идем. Безнең өйдә әләкләшкәнне, гайбәтләшкәнне яратмыйлар. Бигрәк тә әти яратмый. Мин хәзер андый нәрсәләр турында уйлап тормадым — бөтенесен берьюлы чыгардым да салдым.

Әти тыныч кына тыңлап утырды да көлемсерәп куйды.

— И, кызым, кызым!— диде, башын селкеп.— Нигә аны башта ук әйтмәдең? Мин әллә Мәсәгут ягында җирнең берәр чите кителеп төшкәнме дип торам! Мәсәгут үз урынында калгандыр ич?

— Сиңа көлке!— дидем, үпкәләп. Ләкин сизеп ятам, чынлап торып үпкәләп булмый. Киресенчә, ничектер җиңелрәк булып киткән сыман. Бөтенесе ап-ачык, гапгади. Нәрсәнең ап-ачык булганын мин әле үзем дә аңламыйм, шулай да инде авыр йөк — күңел газабы — кире кайтмаслык булып артка ташланды.

— Нәрсә, әллә еларгамы?— ди әти.— Шуның өчен район больницасына күчәсеңме? Сине тыңлаган Саламуныгызны әйтерием инде! Һай, егетләр! Нинди нәрсә соң ул? Шуның өчен кешене эшеннән күчерәләрмени? Ә синең урынга кем кала? Танямы? Таня урынына кем? Чирлеләр нәрсә дияр... авыл халкы?.. Уйладыңмы шул турыда? И, кызым, кызым. Чебен тимәс чер итәр менә шул була инде ул!

Мин тып-тын ятам. Әтинең шелтәле сүзләре йөрәкне чәнчеп-чәнчеп ала. Авырттырып-авырттырып ала. Карале, нишләдем соң әле мин? Нәрсә кыланып йөрим соң мин? Үпкәләгән булып, ачуланган булып... Кемгә үпкәләп? Колхоз председателенәме, Вәзиргәме? Кемгә? Тимерҗан белән Зөһрәгәме, югыйсә? Вәзирләрдән, колхоз председателләреннән башка анда бит әле тагын Галим абыйлар, Мөслим абыйлар бар. Шәйхаттәр бабайлар, Фәгыйлә апалар... Бөтен бер авыл! Алай гына да түгел, Кызыл Яр, Алдар, Тау-авыл бар. Мин бит Саҗидә генә түгел, мөдир Саҗидә. Минем өстә никадәр бурыч, никадәр җаваплылык. Шуларның барысын да ташла да, оныт та... шуларның барысына да төкер дә... кемнәндер куркып... җиңелеп... качып кит, имеш!

Менә сиңа кирәк булса, малайкай! Ничек баш җитмәгән шуны уйларга? Нәрсә, иртәгә тагын райздравка барыргамыни? Инде кире уйладым, район больницасына керәсем килми дияргәмени? Юк инде, ике аягымның берсен дә атламаячакмын!

Шул чакны әни өстәлгә кайнар аш китереп утыртты.

— Әйдә, тор, ятма анда көпә-көндез иркәләнеп!— диде, ачу белән.— Бала-чага уены дип белдеңме әллә аны бер кайтып, бер килеп йөрергә! Килешмәгәнне...

Мин кинәт сикереп тордым. Юындым да ашарга утырдым. «Әллә бүген үк китәргә инде?»— дидем үз-үземә. Әйе шул, китәргә кирәк. Әле соң түгел. Кеше-кара сизенгәнче, тизрәк таярга кирәк моннан.

Ашап туйгач, беркемгә бер сүз әйтмичә, киенә дә башладым.

— Кая җыенасың тагын?— диде әни.

— Җыенам әле,— дидем.— Авылга китәм. Мәсәгуткә.

— Китәсең?! Әллә тагын ут капканмы?— диде әни, ачуланасы килеп.

— Мәсәгуткә ут капмаган. Миңа капты, миңа!— дидем мин.

— Син нәрсә эндәшмисең?— диде әни әтигә.— Минем сүзне колагына да элми әнә синең уңган кызың. Үзең әйт. Иртәгә китәр. Кайчан барып җитә ул... Төнгә калса...

## XVIII

Әти җавап бирергә өлгермәде, урамда, безнең турыдан гына бик каты үкереп, тирә-якны дер селкетеп, ниндидер машина узганы ишетелде. Без барыбыз да никтер тынып калдык. Машина исә ары китмәде, безнең капка турысында шып туктады. Кабинадан, кузовтан ниндидер кешеләр төште.

Мин, аптырап, тәрәзәгә якынрак килдем. Карыйм... кемнәр соң болар? Безгә керәләр түгелме соң? Аһ Аллам, харап кыналар булдым, мине алырга килделәр микәнни?

Тәрәзәгә карана-карана керделәр болар капкадан. Баскыч төбендәге тимер сыртына күн итекләрен кырдылар, текә баскычтан менә башладылар. Иң элек Кәрим абый килеп керде. Күземә күренәме әллә дип торам! Теге безнең күршедәге укытучы. Аның артыннан... Равил, аннан шофер...

— Исәннәрмесез әле,— диде Кәрим абый.

Аның янындагылар да тыелып кына гөрелдәшеп алдылар, исәнмесез-саумысез, диделәр. Равил, мине күрде дә, бер дә юктан авызын ерып җибәрде, үз кеше булып миңа каш сикертеп алган булды. Мин торам нишләргә белмичә, үз өемдә үземне чит санап.

— Бик исәнбез. Әйдәгез, түрдән узыгыз,— диде әти, кунакларга каршы атлап.

— Узып тормабыз,— диде Кәрим абый.

Үзе шундагы урындыкка иркенләп утырды да сүзсез генә миңа карап алды, аннары әтигә, әнигә карады.

— Менә...— диде, чигәсен кашыштырып.— Саҗидә күршене алырга кердек. Мәсәгутнекеләр без. Яңавылда икәнен белдек тә, сугылып чыгыйк әле, дидек. Илебатырга ашлык китергәниек. Якын гына торасыз икән шул монда.

— Мин үзем дә китәргә җыенып ятадырыем әле,— дидем мин, ашыгып.

— Ә? Шулаймыни?— диде Кәрим абый.— Әйдә, алайса, сеңлем. Сине көтәләр анда. Синсез эш бармай.

— Кая, нинди китү әле ул? Менә чәй кайнады, чәй эчеп китәрсез,— диде әни, кунакларның кемнәр икәнлеген шәйләп.

— Рәхмәт, килен, эчеп тормабыз,— диде Кәрим абый, аягүрә басып.

Әти дә кабалана башлады, нишләп алай бик тиз генә, диде, әзер ашны ташлап китү килешми инде ул, диде. Мин кыстап-нитеп тормадым, чөйдәге плащымны кулга элдердем дә өйдән тизрәк чыгып китү ягын карадым. Кәрим абый әллә минем турыда сүз куерта башлар тагы... әни алдында, әти алдында юкны-барны искә төшерә башлар...

Чыктым да баскыч төбенә, көтеп торам кызарынып-бүртенеп, оятымнан нишләргә белмичә. Менә күп тә үтмәде, ишек ачкан тавыш ишетелде. Чыгалар, ахрысы! Һай, рәхмәт төшкере Кәрим абый! Өстән тау-таш ишелеп төшкәндәй булды. Сөенеп, көлә-көлә шундук капкага йөгердем.

Кузовта берничә ир кеше, хатын-кыз күренә. Мәсәгутнекеләр. Төсләрен аера алмыйм, шулай да үзебезнекеләр икәнлеген ерактан ук күреп торам.

— Саҗидә, кил монда!— диде ниндидер кызый, кулын болгап.

— Апасы, кабинага утырасыңмы, безнең беләнме?— дип кычкыра арттан Равил.

— Сезнең белән. Кабинага Кәрим абый утырыр,— димен, артыма борылгандай итеп.

Сузылган кулларга үрелдем дә, тәгәрмәчләргә бастым да... тукта... авызы ерылганы Лилия... икенчесе Тимерҗан лабаса! Кулдан ныгытып тоткан, елмайган...

Кинәт йөрәгем кысылып куйды. Хәл бетте. Үзем көлгән булам, елмайган булам. Алар да елмая. Никтер барысы да чамадан тыш шат, күңелле кебек күренә.

Менә Равил дә менеп утырды. Машина кузгалып китте. Әти белән әни нәрсәдер кычкырып калдылар — рәтләп ишетмәдем дә. Аяк астында машина тирбәлә, каршыга җил исә. Кайнар җил.

Юк, җиле кайнар түгел, чигәләр кайнар. Якында гына Тимерҗан, Равил… Алда, киләчәктә — киңлек-иркенлек, билгесезлек һәм… бәхет. Бәхет? Алда микән, артта микән ул? Әллә янында гына микән соң?

*1962, Казан*

## ЭЧТӘЛЕК

Нурихан. *Зәет Мәҗитов*
7

Сезнеңчә ничек?
11

Мөдир Саүидә
312

Литературно-художественное издание

Фаттахов Нурихан Садрильманович

*(Нурихан Фаттах)*

Избранные произведения
в пяти томах

Том 1

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректорлары *Р.В.Сабирҗанов, Г.Х.Сундукова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 3.09.2002.
Форматы 84×108 1/32. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 24,36+форз.0,21. Шартлы буяу-оттиск 24,68.
Нәшер-хисап табагы 26,47+форз.0,36.
Тиражы 3 000 данә. Заказ Б-453.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.